Вакыйф Нуруллин

# ЯШЬНӘП ҮТКӘН ЯШЬЛЕК

Повестьлар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-31
ББК 84 (2Рос/Тат)=44
Н83

**Нуруллин, В.Н.**

Яшьнәп үткән яшьлек : повестьлар / Вакыйф Нуруллин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 351 б.
ISBN 978-5-298-01919-4

Әлеге китапка язучының укучыларга яхшы билгеле әсәрләре – «Шинельсез солдатлар», «Күпер чыкканда», «Яшьнәп үткән яшьлек» повестьлары туплап бирелде.

УДК 821.512.145-31
ББК 84 (2Рос=Тат)-44
ISBN 978-5-298-01919-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Нуруллин В.Н., 2010

**ШИНЕЛЬСЕЗ СОЛДАТЛАР**

**Бала чакның соңгы көне**

Туу турында таныклыгым буенча миңа хәзер утыз ике яшь. Ә үземчә әле егерме өчтә генә кебек. 1932 елда түгел, 1941 елның җәендә генә тудым шикелле, чөнки аңа кадәр бу якты дөньяда ниләр булган, мин нәрсәләр эшләгәнмен – берсен дә анык кына хәтерләмим. Ә 1941 елның җәе...

Күрше малайлары Миңлеәхмәтләр, Фәрзетдиннәр белән таякка атланып ат-ат уйнап йөри идек, кинәт авыл халкы куркыша, кычкырыша башлады:

– Сугыш чыккан!

– Герман безгә каршы сугыш ачкан!

Аннары кайсы кайда кырда эшләүче ир-атлар да, җиккән атларын чаптырып, авылга кайттылар.

Барысының йөзләре җитди, борчулы иде.

Ә без, малайлар, бу хәлгә бераз сәерсенеп тордык та, берни булмагандай, яңадан уеныбызны дәвам иттек. Чөнки «кайда сугышалар, кемнәр сугыша?» дип соравыбызга каршы, Миңлеәхмәтнең атасы:

– Ерак ул, оланнар, моннан күренми, – дигәч, безнең өчен ул сугышның кызыгы беткән иде инде.

Хәзер утыз ике яшьлек акыл белән уйлап карыйм да, ул көнне уеныбызны дәвам итү әйбәт булган әле, дип куанып куям. Без уеннан тукталганга карап кына сугыш барыбер туктамас иде бит. Ә болай рәхәт, ваемсыз бала чагыбызның соңгы көнен берничә сәгатькә булса да озайтканбыз, ичмаса...

Икенче көнне иртүк авылның ир-атлары, җиккән атларга утырып, авыл буйлап җырлашып йөри башладылар.

Китәбез инде, китәбез,
Без китмичә, кем китәр?
Илне дошманнардан азат
Без итмичә, кем итәр?

Менә монысы безгә кызык иде! Агайларның җырларын тыңлап, бер адым да калмыйча, аларга ияреп йөрдек без.

Җырлашучы агайларның үз-үзләрен тотышына караганда, алар әле тиз генә тукталмаслар, көн буе шулай йөрерләр, һәм бу кызык кичкә кадәр дәвам итәр шикелле иде. Ләкин алай булмады. Нибары утыз җиде йорттан торган авылыбызны өч тапкыр гына әйләнделәр дә атларын туктаттылар. Җырлар өзелде. Кешеләрнең йөзләре караңгыланды. Елашулар, хушлашулар китте.

Без малайларга шунысы сәер иде: карап торуга зур-зур кешеләр булсалар да, ник балалар сыман итенә икән бу олылар? Ничек инде ул: әле җырла, әле ела? Син тагын шунысын әйт, Миңлеәхмәтнең әнисенә тикле елый бит! Миңлеәхмәт кайчакта кирелләнеп чак кына шыңшый башласа да:

– Җылама, улым, җылаган кешенең бәхете булмый аның, – дия иде. Ә үзе... әнә ничек сулкылдап-сулкылдап елый. Миңлеәхмәтнең атасын кысып кочаклаган да һич кенә дә җибәрәсе килми.

Ул елашу, ул саубуллашу, белмим, тагын күпмегә сузылыр иде икән, ләкин шулчак Кече Әшнәк юлыннан авыл советы секретаре Мөсфирә апа, килеп җитеп:

– Ярый, иптәшләр, елашмыйк, елаудан мәгънә юк хәзер. Киресенчә, ныграк, каты күңеллерәк булырга кирәк безгә! Әйдә, матур гына итеп саубуллашыгыз да, озатыйк китүчеләрне! – дигәч, барысы да тынып калды.

Әмма озакка түгел. Мөсфирә апа, үзе утырып килгән тарантастан төшеп, атын Хәбир бабайлар коймасына бәйләп килгән арада, баягыдан да битәррәк шау-шу, хушлашу, елашу башланды. Ул да түгел, әле генә кешеләрне каты күңелле булырга өндәгән Мөсфирә апа үзе дә сугышка китәсе абыйсы янына килеп кычкырып еларга тотынды. (Ул үзе безнең авыл кызы, авыл советында эшләгәнгә күрә генә Кече Әшнәктә яши иде.)

Монысы инде минем өчен чамадан тыш сәер хәл иде. Чыннан да, ничек инде ул, Мөсфирә апаны әйтәм, үзең шундый зур урындагы кеше бул, үзең ела? Ә мин, юләр, начальникларның күзеннән яшь чыкмый торгандыр, дип йөри идем... Бик акыллыдыр ул, бик башлыдыр, дип уйлый идем мин Мөсфирә апаны. Чөнки ул безнең авылда бердәнбер зур белемле – җиде класс тәмамлаган кеше. Авыл халкы да ярата үзен: «Ай-яй, башлы булып чыкты ул кыз, укып та бетерде, сиклитар да итеп куйдылар. Менә күрерсез, районга да берәр нәчәлник итеп алырлар әле шуны», – дип сөйлиләр иде аның турында. Ә ул, кара, ничек балавыз сыга!..

Әмма, ничек кенә булмасын, башкалар кебек дөньясын онытып, озаклап еламады Мөсфирә апа: ике-өч минут та үтмәгәндер, абыйсы күкрәгенә сыенып елаганда як-якка шуышып төшкән кап-кара озын толымнарын бер селтәнүдә аркасына салды да тагын элекке хәленә кайтты. Костюмы кесәсеннән челтәрле матур кулъяулык алып яшьләрен сөрткәч:

– Ярар, иптәшләр, кузгалыйк! – дип, китүчеләргә эндәште. Аннары аты янына китте. Тарантасына утырды. Тагын бер тапкыр, бу юлы барысы да ишетерлек итеп: – Кузгалыйк, иптәшләр! – диде дә атын районга бара торган юлга борды.

Китәсе кешеләр дә арбаларга утырдылар. Атлар кузгалды, һәр ике яктан да яулыклар җилферди башлады. Китүчеләрнең соңгы җыры яңгырады:

Без авылны чыккан чакта
Күтәрелде тузаннар.
Ул-бу булып кайталмасак,
Сау булыгыз, туганнар...

Китүчеләрне тәмам күздән югалганчы карап торганнан соң, моңарчы кул болгап, яулык болгап торган озатучылар, күз яшьләрен сөртә-сөртә, атлар-атламас кына авылга борылдылар.

Иртәдән бирле кызык карап йөргән без малайларга да ничектер дөньяның яме бетеп, аны хәвеф, шом каплап алгандай булып калды.

* * *

Күрәсең, безнең йорттан берәү дә китмәгәнгә шулай булгандыр, башта мин сугышына да, китүчеләргә дә әллә ни шаккатмадым. Әмма сугыш башлануга атна-ун көн дигәндә, әтинең энесе Искәндәр абыйны да районга чакыртып, аңа да машинасы белән фронтка китәргә дигән кәгазь биреп җибәрүләреннән соң, дөресен әйтергә кирәк, эшләр хөртиләнде минем. Соң, шулай булмыйча! Авылыбызның бердәнбер машинасын йөртүче кеше ич минем Искәндәр абыем! Бөтен колхозның йөген берүзе ташый дип әйтергә була бит аны. Ул да киткәч, колхоз нишли ди инде? Аннары, колхоз гына түгел, мин дә бар бит әле дөньяда. Ярты гомерем Искәндәр абыйларда үтә иде ич минем...

Әмма беркем дә минем теләк белән исәпләшеп тормады. Тиешле көне килеп җитүгә, абыйны да озаттык. Башкалар бик елашып, көчкә-көчкә генә аерылып киткәнгә күрә, Искәндәр абый да шулай булыр инде дип уйлаган идем. Ләкин ник бер тамчы яшь күрсәтсен Искәндәр абый! Еламады да, җырламады да. Ни кыстап карасалар да, шофер кешегә ярамый ул әйбер, дип, аракыны да авызына алмады. Нәкъ башка көннәрдәгечә, колхоз әйберләрен ташып йөрде-йөрде дә, тәмам китәр сәгате килеп җиткәч кенә, машинасын капка төпләренә куеп, бик әйбәтләп ашап чыкты. Аннары, машинасына утыртып, үзен озатырга җыелган авыл халкын урам әйләндерде. Аннары, янә капка төпләренә тукталып, барысы белән дә саубуллашты да, элек хатынын – Нәсиха җиңгине, соңыннан мине кочаклап үбеп:

– Исән булсам – кайтырмын, кайта алмасам – үпкәләмәссез, – дип шаяра-көлә, машинасын кабызып китеп барды. Хәтта районга кадәр озата барырга теләгән җиңгине дә алмады. – Күпме барсаң да, барыбер бер аерыласы булыр инде, Нәсиха җаным, лутчы шушында гына кал, – диде.

Искәндәр абый шулай шаярып-көлеп киткәч, мин артык борчылмадым. Әни дә әллә ни озак еламады, әмма Нәсиха җиңгинең елавына чик-чама булмады инде. Тәмам хәле бетеп, күзеннән – яшь, авызыннан сүз чыкмый башлагач кына тукталып, йоклап китте ул...

Ул көнге үрсәләнүенә караганда, җиңги Искәндәр абыйдан башка бер ай да ялгыз яши алмас: йә хәсрәтеннән саргаеп үләр, яисә акылыннан язар төсле тоелды миңа. Шуңа курыктым, шуңа бик кызгандым мин аны. Ләкин үтәр нибары өч-дүрт ай һәм шул чакта җиңгәм бөтенләй башка, миңа карата таш йөрәкле кеше булып чыгар дип күңелемә дә китермәдем.

### Үскәнче көтәргә туры килмәде

Искәндәр абыйны озаткан көнне әни белән җиңги бик елаша башлаганга аптырап:

– Нигә шултикле елыйсыз соң сез? – дидем мин әнигә. – Немецларны җиңгәч кайта бит Искәндәр абый! Башкалар да кайта. Гомергә китмәгәннәр ич алар! Искәндәр абый үзе еламаганны, сез елап торган буласыз тагы, эч пошырып.

Мин бу сүзләрне чын күңелемнән әйттем. Чөнки минем Искәндәр абый, гәүдәгә гадәти генә булса да, бик таза, бик куәтле кеше. Авылыбызда гына түгел, бөтен районда сабан туе батыры булып калды ул быел. Икешәр потлы ике герне туп урынына чөеп кенә уйный торган иде. Шулай булгач, мин аның сугышта да немецларны җиңәчәгенә, аннары исән-сау килеш авылга кайтачагына шикләнми идем.

Ләкин әни бу мәсьәләдә башкачарак уйлаган булса кирәк, чөнки ул, минем белән бик үк килешеп бетмәгән сыманрак итеп:

– Әй улым! Яшьрәк шул әле син, сабыйлыгың аркасында аңлап җиткермисең ул сугыш дигән фетнәнең мәгънәсен! – дип җавап бирде.

– Аңлатып бир алайса, әни?!

– Ярар инде, улым, кызыклы нәрсә түгел ул. Аңламый торуың әйбәтрәк хәзергә. Үсә төшкәч, үзең дә аңларсың әле, исән калсак...

Бу җавабыннан канәгатьләнеп үк җитмәсәм дә, әнине бүтән борчып тормадым. Рас ул «белми торуың әйбәтрәк» дигән икән, димәк, шулай кирәк дип уйладым да үскәнче көтәргә булдым. Ләкин...

Әле кар яумаган, әмма җир таштай туңган, һәм шунлыктан чамасыз суык тоелган ноябрь кичләренең берсендә әнине колхоз идарәсенә чакырттылар. Үзем генә өйдә калырга куркып, мин дә әнигә ияреп киттем.

Колхоз председателе Самат абый чакырткан булган икән. Без килеп кергәндә, идарәдә үзе генә утыра иде.

– Менә нәрсә, Мәгъсүмә иптәш, – диде ул, кырыс кына итеп, – бүген районнан күрсәтмә килде. Окоп казырга кеше җибәрергә кушканнар. Так...

Шкафтан ул нидер алырга тели иде.

Гәүдәсе кечкенә булганлыктан, элекке председатель утырган урындыктан үрелеп кенә шкафны ачарга буе җитмәгәч, Самат абый өстәлдән азрак читкәрәк куелган шкаф янына үзе барды. Аннары яңадан урынына килеп утырды да мәче башлы ябалакныкына охшаган түгәрәк зур күзләрен безгә текәп дәвам итте:

– Разнарядка буенча, безнең колхоздан егерме бер кеше окоп казырга барырга тиеш. Сиңа да шунда барырга туры килә. Бар, хәзер кайт та әзерләнә башла! Берсекөнгә юлга чыгарсыз.

– Минем йорт-җирем, терлек-торышым нишли ди соң инде, Самат абый? Равилемне кайда калдырыйм мин? – диде әни, тәмам коты алынып.

Ә мин куркуымнан еларга ук тотындым. Соң, шулай булмыйча! Менә монда да өйдә үзем генә калырга курыкканга килдем бит инде мин! Әни киткәч, берүзем нишләрмен ди?.. Ах, чулак пәри! Председатель булып эшләргә тотынганына әле бер ай бар микән, кара, ничек итеп бугазын киерә башлаган! Элек, сугышка кадәр амбар-урам каравылчысы булып эшләгән чагында, бер дә алай түгел иде. Ир-ат сөйләшкәндә, авыз ачарга да кыймыйча, башкаларны тыңлап кына тора, хәтта төчкерәсе килгәндә дә читкә китеп төчкерә торган иде. Ә хәзер...

Ләкин мин юкка гына әтәчләнгәнмен икән. Барысын да уйлап, хәл итеп куйган булып чыкты Самат абый.

– Беләбез, барысын да беләбез, Мәгъсүмә иптәш, – диде ул, әнинең каршы килүенә һич тә исе китмичә. – Бер дә борчылма, барысы да хәл ителгән. Син дә хафаланма, наным Равил. Бер сыерың, ике сарыгың бармы әле синең, Мәгъсүмә иптәш?

– Әйе, – диде әни.

– Значыт, менә болай, Мәгъсүмә иптәш: терлекләреңне дә, Равилеңне дә килендәшең Нәсихага калдырасың, ул карый торыр. Ә өеңне бикләп торасың. Бәрәңгеңне генә идән астында калдыра күрмә. Ягылмаган өйдә өшер ату, базыңа тутырып куй.

Менә бит нинди кеше икән ул Самат абый! Һәр ягын уйлап-үлчәп куйган бит. Әле ярый бая теге уйларымны кычкырып әйтмәдем. Югыйсә...

Хәзер инде мин әнинең китүенә каршы түгел, ул үзе дә ризалашыр дип көттем. Әмма гомер-гомергә начальниклар алдында куркып, калтыранып тора торган оялчан, юаш кеше булса да, бу юлы ризалык бирергә ашыкмады әни.

– Алай итеп мәшәкатьләнгәнче, окопка Нәсиханың үзен генә җибәрү мәслихәтрәк булмасмы соң? – диде ул. – Аның бала-чагасы да юк, миңа караганда яшьрәк тә, тазарак та.

Карале, әни дөрес әйтә ләбаса, чыннан да шулай ич!

Ләкин Самат абый бу мәсьәләне дә алдан ук уйлап куйган булып чыкты.

– Беләбез, Мәгъсүмә иптәш, барын да беләбез, – диде ул. – Анысы да уйланган. Әмма Нәсиханы окопка җибәреп булмый. Ул монда кирәгрәк. Галәви ике көннән фронтка китә, менә шуның урынына зафхуз итеп куябыз Нәсиханы.

Менә сиңа кирәк булса! Галәви абыйның бер күзе кылый бит аның. Андыйларны сугышка алмыйлар, дип әйткәннәр иде ләбаса...

– Башка кеше юкмыни соң Галәви урынына? – диде әни, әле һаман да ризалашасы килмичә.

– Син соң кемне куяр идең? Йә, әйтеп кара! Или үзеңне генә зафхуз итикме әллә? Мин аңа да каршы түгел, булдыра алсаң. Әмма башка кеше юк!

– Һәй, Самат абый! – диде әни, куркуга төшеп. – Зафхуз булырлык кешеме соң инде мин, ике класс белем белән... Миннән башлырак кешеләрнең дә күбесе буталып бетә бит ул эштә. Юк, юк, авызыңны да ачма, анда эшләп башны Себер җибәргәнче, акупка китәм мин. Түлке әйтүем шушы, Самат абый, син авылның хуҗасы, малайга син дә күз-колак бул. Килендәшнең характеры тырт-пыртрак аның, малайга бер-бер хәл ясый күрмәсен.

– Син алай ук каты куйма мәсьәләне, Мәгъсүмә иптәш. Прсидәтел дигәч тә, мин малайлар карап йөрергә әбәзен түгел. Ну шулай да борчылма артык. Кулдан килгәнчә тырышырбыз.

Аннары әни мине җитәкләде дә, кайтырга чыктык.

– Курыкма, әни, – дидем мин, идарә күтәрмәсеннән төшкәч, аны юатырга тырышып, – өч айга ничек тә түзәрсең. Җиңги ярата ул мине, терлекләрне дә ач итмәбез, ничек тә карарбыз. Бәлки, сугыш та бетеп куяр әле.

– Әй улым, – диде әни, барган уңайга башымнан сыйпап, – ниләр генә әйттең иде дә бит бетсә! Алай тиз генә бетәр чамасы күренми шул әле ул афәтнең. Мәскәүгә якынлаша, ди, анда немесләр, һаман безнекеләрне куып киләләр, ди. Бигрәк бәхетсез заманага туры килдең шул, балам!

– Миңлеахмәт белән Фәрзетдиннең әниләре дә барамы соң ул окопка?

Болай соравымның сәбәбе шул: әгәр әни «алар да бара» дисә, мин аны: «Алай булгач, нигә син мине генә бәхетсез дисең, дөньяда бер мин генә түгел ич әле ялгыз калучы», – дип юатмакчы идем. Әмма мин көткәнчә булмады: Миңлеахмәтнең дә, Фәрзетдиннең дә әниләре окопка бармаячак икән.

– Аларның аталары сугышта шул, улым, – дип җавап бирде әни, мин, нигә бармый соң алар, дип сорагач. – Әтиең сугышта булса, мине дә җибәрмәсләр иде дә бит...

Минем әти миңа өч тулып дүртенчегә киткән елны үлгән. Шунлыктан моңарчы мин аны белмәдем дә, юксынмадым да. Ә менә хәзер, эшләр болайга киткәч, әтиле буласым килә башлады. Бик-бик кирәк иде ул миңа хәзер. Нигә яшереп торырга, үлгәч-үлгәч фронтка китеп үлмәвенә дә хәтерем калды.

Сугыш!.. Шулай итеп, аның нәрсә икәнен белү өчен, үскәнче көтәргә туры килмәде миңа. Бүген колхоз идарәсеннән өйгә кайтып барганда ук чамалый башладым мин аның мәгънәсен... Мине һәм минем шикелле бик күп балаларны газиз әнкәйләреннән аерырга чыккан бәла икән ул.

**Их, әнием булса...**

Самат абый әйткән көнне әниләр окоп казырга китте, ә мин Нәсиха җиңгиләрдә калдым. Шул ук көнне, авылның ир-атлары сугышка китеп беткәннән бирле ат җигеп йөри башлаган Фәйрүзә апа белән Мәүлиха апаларны кушып, Самат абый безнең тезмәдәге барлык печәнне җиңгиләргә күчерттерде. Хайваннарны да аларга алып килдек. Шуннан башка үзгәреш булмады. Әнине дә әллә ни юксынмадым, күңелсезләнмәдем дә ул көнне. Ә кичен, җиңги пешергән токмачлы ашны ашап җибәргәч, минем эшләр бөтенләй шәбәеп китте. Ихтимал, сугыш башланганнан бирле андый тәмле аш ашаганым юклыктан шулай булгандыр инде.

Аштан соң, җиңги табак-савытларны җыештырган арада, мин аларның йонлач бохар песие белән уйнадым. Аннары җиңги пружиналы тимер караватка урын җәйде дә, йокларга яттык.

Белмим, җиңгинең җылы куены шулай рәхәт булгандырмы, әллә йомшак караватка ятткангамы икән – башым түшәккә тию белән йокыга киткәнмен. Йоклаганда бик матур бер төш тә күргән идем дә, әмма нинди төш икәнлеге хәтеремдә калмаган.

Ә менә иртән җиңгинең мине ничек итеп йокыдан уятуын аермачык хәтерлим.

Үзебездә соң гына, кояш тәрәзәбез каршындагы алмагач биеклеге күтәрелгәч кенә тора идем мин. Ә безнең ул алмагач кечкенә түгел, юанлыгы минем беләктән чак кына кайтыш аның. Озынлыгы да ярыйсы гына: миннән ике тапкыр биегрәк. Әгәр инде кояш шул алмагач башына менеп җиткәч тә торасым килми икән, әни ул чакта да бер сүз дә әйтми торган иде.

Күрәсең, әнә шулай туйганчы йоклап өйрәнелгәнгәдер инде, теге көнне иртүк, әле көн яктырганчы ук, җиңги, үзенең нык, йомры куллары белән беләгемнән эләктереп:

– Равил, тор инде, тор, тор! – дип йолыккалый башласа да, башта күзләремне ачасым килмәде. Әмма ул: – Ах, әле син шулаймы?.. Торасыңмы, юкмы? Хәзер сөйрәп урамга чыгарып ташлыйм бит! – дип ныклап ук ачуланырга керешкәч, җылы түшәктә яту бик-бик рәхәт булса да, тизрәк торудан башка чара калмады.

Әле һаман да йокы исереклегеннән айнып җитә алмыйча, өс-башымны киенгән арада, урынында яткан килеш кенә, җиңги миңа:

– Хәзер озаклап йоклар заман түгел, малай, аң бул аны! Хәзер сугыш вакыты, авыр чак. Бүгеннән алып укуыңны да ташларга кирәк булыр. Әнә, сугыш беткәч укырсың! – диде.

Шушы соңгы сүзен әйткәнче, башыма таяк белән сукса, мең өлеш артык булыр иде. Ни уйлап әйтте икән ул моны? Сугыш дип, ничек укуымны ташлыйм ди инде мин? Булмаганны! Укымагач, ничек шофер булырмын соң? Искәндәр абыем кебек шофер буласы кеше ич мин!..

Ачуым килгән иде, түзә алмадым, тоттым да:

– Әбиең сызгыра беләме, җиңги? – дидем тегеңә. – Бабаң утырмага килсен, яме! Әйтмә дә, сөйләмә дә, укыйм булгач укыйм!

Җиңги миннән мондый кискен җавап көтмәгән иде булса кирәк: болай да зур зәңгәр күзләрен тагын да зуррак ачып, гаҗәпләнеп, байтак вакыт миңа текәлеп карап торды. Башка чакта бик матур иде аның ул зәңгәр күзләре. Мин аның, дөресен генә әйткәндә, иң элек әнә шул зәңгәр күзләрен ярата идем. Искәндәр абыем башка кешегә түгел, нәкъ менә шушы Нәсиха җиңгигә өйләнгәнгә куанып, малайлар арасында горурланып йөри идем. Әмма бу юлы нигәдер ямьсез, куркыныч булып күренде җиңгинең

күзләре, һәм мин җиңги үземне йә бик ныклап орыша, яки тотып кыйный хәзер дип көттем. Тик эш алай зурга китмәде: күрәсең, мин бала белән булашып, вакланып торасы килмәгәндер инде җиңгинең.

– Ә мин әйтәм укымыйсың! – диде ул ипләп кенә. – Укыр чак түгел хәзер. Әллә сезнең ул хайваннарны мин карар дип беләсеңме? Көт Аллаңнан! Әнә, ишек катында фләге бар бит, хәзер шуны... тукта, башта бар, тәрәзәдән кара әле, кар яумаганмы анда?

– Юу-у-ук, – дидем мин, барып урамга карагач.

– Алайса, фләгене алып чыгып арбага утырт та су апкайт! – диде җиңги, кырт кисеп. – Хайваннарыгызны эчерәсе булыр. Аннары абзарны җыештырырсың. Ишегалдын да себерергә кирәк. Тиресләрен дә түгәрсең.

Гомеремдә бу тикле эш эшләргә туры килгәне булмаса да, мин болай итәргә уйладым: суны тиз генә алып кайтам да ишегалдын себереп ташлыйм. Аннары ялт кына ашап алам да мәктәпкә йөгерәм. Ә абзарны төштән соң, мәктәптән кайткач җыештырам. Иптәшләр белән уйнарга вакыт калмый инде калуын, ләкин нишләмәк кирәк? Әнә бит, җиңги әйтеп тора, уен заманы түгел, ди.

Шулай итеп, җиңгинең дә күңелен күрмәкче, укуымны да дәвам итмәкче идем. Һәм бу минем өчен әллә ни кыен да булмас шикелле иде. Әмма гел син теләгәнчә генә булмый икән шул. Кая ул!..

Арбаны яр кырыена куеп, яр астыннан суны яртышар чиләкләп ташып, фляганы тутырганчы гына да дөнья хәтле вакыт үткән булып чыкты. Ә арбаны дыңгырдык юлдан көч-хәл белән җиңгиләргә алып кайтып җиткергәндә, ачуым да килмәгәе, төш җитә язган иде инде. Шулай да минем өмет тәмам өзелмәгән, соңга калып булса да, мәктәпкә бармакчы идем. Кичә дә, башта әнине озатып, аннары җиңгиләргә күченеп йөреп, дәрес калдырган кеше ич мин...

Тик бу ниятем дә барып чыкмады. Тирләп-пешеп капка төбенә кайтып туктавым булды, җиңги чәчрәп килеп чыкты да орышырга тотынды. Имеш, эчендә җаны булган кеше бу тикле озак йөриме соң: тиккә генә түгелдер бу, юлда уйнап йөргәнмен, янәсе... Китте тезеп, китте тузынып – чыда гына!

Кара инде син аны, ә? Мин, ярылырга җитешеп, ашыгып йөргән булам, ә ул әнә ни кылана! Аларның ул буш килеш тә иләмсез авыр арбаларына бер фляга су утыртып, аны шушындый каткан юлдан, җитмәсә, үргә каршы сөйрәп кайтуны җиңел эш дип уйлый, ахры... Их, үз әнием булса! Болай кадерсезлектә йөри торган кешеме соң мин?..

Җиңги шулай пыр китереп ачуланып торгач, мәктәп кайгылары китте миннән. Ничек итеп курыкмыйча ул турыда сүз кузгатмак кирәк? Күңелемнән тотып ашарлык дәрәҗәдә ачулансам да, тыштан берни дә сиздермәдем җиңгигә. Тамакка капкалап алдым да калган эшләргә тотындым. Алары су алып кайту кебек читен дә булмады, әллә ни озакка да бармады. Кичке якта уйнарга да бераз вакыт калды әле.

Ул көнне без – Фәрзетдин, Миңлеәхмәт, мин – ындырда ашлык сугучылар янында булдык. Чөнки, әле кар төшмәгәнлектән, чана шуып булмый, тәгәрмәч тәгәрәтеп уйнарга да салкын. Ә ындырда салам арасында рәхәт. Күпме телисең, шулчаклы уйна! Һәм без, туйганчы ук булмаса да, шактый уйнадык. Салам тарттыручы атның салам бәйли торган бавына тотынып чабышып та йөрдек; ат куучы апаларны ял иттереп, алар урынына атларын да кудык; көлтә ташучыларга утырып, кырга кибән янына да барып килдек. Кыскасы, рәхәтләндем мин ул көнне. Җиңги янына тәмам караңгы төшкәч кенә кайттым һәм, нигә яшереп торырга, кушып калдырган эшләрен эшләп куйган өчен мактар да әле үземне дип өметләнгән идем. Әнием мине, берәр эшенә булышкан саен:

– Ай улым, миңа рәхмәт! Миңа әйбәт иттең! – дип, аркамнан яки башымнан сыйпап, тупылдатып сөя торган иде.

Андый вакытларда миңа бик-бик рәхәт булып китә һәм әнигә тагын да булышасым килә иде. Әгәр минем эшемне мактасалар, хәзер дә эреп китәргә әзер әле мин. Тик, күрәсең, бөтенләй үк эреп бетмәсен әле бу егет диптер инде, алай еш мактамыйлар гына.

Кем белә, бәлки, җиңги дә эреп китүемнән шикләнгәндер, ул да мине зурлап мактамады.

– Кушкан эшләрне үтәвең яраган анысы, – диде ул, ишектән килеп керүемә үк, – ә менә шушы вакытка тикле уйнап йөрүең өчен нишләтергә инде сине?! Әйтмәдеммени мин сиңа, хәзер сугыш заманы, дип. Гел әйткәнне генә эшләргә дигәнмени сиңа! Беләсең ич минем эштә икәнне, бәрәңге әрчи торсаң, кулың корыр идемени? Ярар, искә алырмын әле мин боларны, табармын мин сиңа эш...

Ә мин, юләр, иртәгә мәктәпкә барырга рөхсәт итәр әле җиңги дип өметләнгән идем тагы. Көт инде болай булгач, җибәрер, җибәрәме соң!

Әнә шулай уйладым да, картлар әйтмешли, бу шайтаннан барыбер иман алып булмас, ахры, дип, гомеремдә ул нәрсәгә кулым бармасын белсәм дә, тәвәккәлләп:

– Мин сиңа бала-чага түгел, җиңги, ачуымны кабартып торма әле, яме! Эшләгән эшнең кадерен белмисең икән, тотармын да йә өеңә ут төртермен, йә, төнлә торып, үзеңә бер-бер хәл ясармын! – дидем.

Яхшылык белән ярый алмагач, куркытып, усаллык белән игә китереп булмасмы, дип уйлаган идем. Әмма соңыннан ник авыз ачканыма үкенеп бетә алмадым.

– Әһә, әле син шулаймы! Аш белән атканга таш җибәрергә җыенасыңмы! – дип гөлт итеп кабынып китте дә тотынды җиңги кыйнарга, тотынды кыйнарга, оят булса да әйтим инде, чалбар төбем юешләнеп, юеше идәнгә саркып чыккач кына тукталды. Һәм әйтте: – Әгәр тагын теш агартып шундый сүз ычкындырасы булсаң, – диде, – болай гына калдырмыйм, билләһи, үтергәнче сугам!

Нигә шулай тиз, танымаслык булып үзгәрә икән бу адәм баласы?! Моңарчы мин җиңгидән дә матуррак кеше юктыр бу дөньяда дип йөрдем бит. Һәрвакыт елмаеп кына тора, иплэп кенә сөйләшә торган иде ул. Бигрәк тә Искәндәр абый белән сөйләшкәндә ярата идем мин аның тавышын: шундый йомшак, шундый җылы итеп әйтә иде сүзләрен, күңелләр әллә ничек рәхәтләнеп китә дә тыңлаган саен тыңлыйсы килеп тора иде.

Хәзер дә шул ук җиңги бит инде югыйсә: буе да, сыны да шул ук – бар җире элеккечә. Әмма шулай булса да ул инде Искәндәр абый вакытындагы җиңгигә тамчы да охшамаган. Йөзе караңгы, тавышы ямьсез. Зур зәңгәр күзләренең дә нуры качып, ничектер тоныкланып калган...

Эшләр болайга киткәч, бүген мине ашатмас та инде бу, дип уйладым мин. Ләкин, белмим, ни хикмәт булгандыр, элекке хәленә үк кайтмаса да, шундук әйбәтләнеп китте җиңгәм:

– Бар, Равил, кече якка кер дә аша! – диде.

Үзе урын җәяргә тотынды...

Мин тамакны туйдырып олы якка чыкканда, җиңги инде чишенеп урынына яткан, әмма йокыга китәргә өлгермәгән иде әле.

– Кил, Равил, ят! – диде ул, минем идән уртасында кыюсыз гына басып торуымны күргәч. – Кил, ят, ачуым бетте инде.

Шулай дисә дә, шикләнебрәк кенә янына барып ятуым булды – җиңги үземне кочаклап та алды. Аннары, гафу үтенгәндәй итеп:

– Үпкәләмә инде син, яме? Ачуым бик килгән иде шул... Үзең дә инде, шундый чакта шулай дип торасың аны, – диде.

Мин дәшмәдем. Болай җайланып киткәч, җиңгигә ачуым сүрелгән, шул ук вакытта гаепне үз өстемә алырга да күңелем тартмый, чөнки ул суккан урыннар әле дә авырта иде.

– Ярар, бетсен ул, Равил, – диде җиңги, эссе йомшак куллары белән әле һаман мине кочаклаган килеш, – онытыйк без бүгенге хәлне, яме?!

Шулай диде дә ике битемне үбеп тә алды. Аркам тәмам ут янып, авыртып торса да, мин нигәдер җиңгине кызганып куйдым да, тынычландырмакчы булып:

– Борчылма, җиңги! Ачу саклый торган гадәт юк миндә, – дидем. – Күптән оныттым инде мин син кыйнаганны. Курыкма, сәвиткә дә барып чакмам. Үзем гаепле булганмын инде, җиңги.

– Әйе шул... Беләсеңме нәрсә, Равил?..

Ул нидер әйтмәкче иде, ләкин тыелып калды һәм ни турындадыр уйланып ятты.

– Беләсеңме, Равил, – диде аннары, – бүген Мәдинә апаң килде бит безгә. «Равил нишләп мәктәпкә бармады?» – ди.

– Син аңа ни әйттең соң, җиңги?

– Ашыкма, тыңла яхшылап! Мин аңа: «Равил үзе барырга теләмәде, укыйсым килми, дип әйтте», – дидем.

– Нигә алай дип әйттең соң, җиңги? Минем укыйсым килгәнне беләсең ич.

– Нигә алай әйттемме?.. Шулай кирәк булды. Әйтелде бит инде сиңа, укуыңны ташларсың, дип. Әйттем бит, укудан башка да эш җитәрлек, дип. Иртәгәдән мин зафхуз булып эшли башлыйм, көннәр буе амбарда булырга туры киләчәк. Шулай булгач, йорт-җир эшләре гел сиңа гына кала. Бүген эшләгән эшләреңнән тыш идән юарга да, бәрәңге әрчергә дә сиңа туры килер, ашавын миннән бер дә ким ашамыйсың бит.

Шунда тукталып, җиңги тагын бераз уйланып ятты да тавышын йомшарта төшеп дәвам итте:

– Мәдинә апаң иртәгә дә килер әле, киләм, дип китте. Әгәр, ник укырга йөрмисең, дип сораса, укыйсым килми, диген. Нигә укыйсың килми, дисә, әнине окопка җибәрмәсеннәр ие, шуңа укымыйм, диген. Ниләр генә әйтеп куркытырга тырышсалар да курыкма, сине берни эшләтә алмый алар. Түлке, кара аны, бу сүзләрне мин әйтте дип ычкындыра күрмә! Алай-болай, мин әйтте дип әйтә калсаң, иман заты көтмә, бүгенге шикелле генә итмәм, бер бирүдә тынсыз ясармын. Ишеттеңме?

Ишетмәгән кая инде ул! Җелекләремә үтте! Әмма «ишеттем» дияргә телем бармады. Күрәләтә ялган сөйләр өчен үз авызым белән ризалык бирәсем килмәде.

– Ишеттеңме? – дип кабатлады җиңги.

Ул моны шундый кискен итеп әйтте, җавапсыз калу һич тә мөмкин түгел иде.

– Әй-е-е, – дидем сузып кына, – ишеттем, җиңги.

– Нәрсә ишеттең?

– Шул син әйткәннәрне инде.

– Яле, мин нәрсә дидем, кабатла әле шуны!

Нишлисең, ул әйткәннәрне кабатлап чыгудан башка чара калмады.

– Менә шулай! – диде җиңги кырыс кына. – Онытма, Мәдинә апаңа да шуларны әйтерсең!

Бары шуннан соң гына тынычлангандай булды ул. Аннары, караватны сытарлык дәрәҗәдә шыгырдатып, стенага борылып ятты.

Күрәсең, көндез эшләп, кичен минем белән булашып, ул да шактый талчыккан булгандыр инде, биш-ун минут дигәндә, пуфф-пуфф итеп йоклап та китте. Ә мине, ни тырышсам да, тиз генә йокы алмады. Шушылай бәхетсез булып дөньяга килүем өчен башта үземне үзем орыштым. Аннары, сугышка тикле генә булса да яшәп, үлгәч-үлгәч сугышка китеп үлмәгәне өчен, тагын бер тапкыр әтигә үпкәләдем. Самат абый белән аяк терәп сөйләшмәгәнгә, мине шушылай кеше кулына калдырып киткәнгә, әнигә дә хәтерем калды. Ул окопта булганга болай кимсетелеп йөрим бит инде мин. Югыйсә бу җиңгигә әйләнеп тә карыйсы кеше түгел. Ник кадалып китми шунда... Их, әнием өйдә булса!.. Кат-кат уйлый торгач, боларның барысына да сугыш гаепледер, ахрысы, дигән фикергә килдем дә Гитлерны каргарга керештем...

**Барыбер минемчә булды**

Ул көнне дә җиңги мине иртүк уятты һәм, тагын шулай караватында яткан килеш кенә, мин эшләргә тиешле эшләрне санап чыкты. Алда әйтеп үткән эшләрдән тыш мин бүген, олаучылар колхоз болыныннан кайтканны саклап торып, аларның йөкләреннән печән йолкып алып кайтырга да тиеш булдым.

Әнә шул хәл аеруча борчуга салды мине. Соң, шулай булмыйча! Күрәләтә урлау булачак бит инде ул, йөк өстендә хуҗасы утырачак ич аның. Яшьтән мутлыкка ияләшеп үскән кеше булсам, тагын бер хәл иде әле. Юк бит, юк! Кешенең энәсенә дә кагылган малай түгел ич мин. Яшелчә каравылчысы Хәбир бабай төшке ашка өйләренә кайтып киткән чакларда, башка малайлар кыярга кергәндә дә, алар өчен оялып, читкә йөгерә торган идем. Әни шулай өйрәтте мине.

– Нәрсә генә эшләсәң дә кичерергә булыр, – ди торган иде ул миңа, – әмма кеше әйберенә кагылсаң, әни дип тә әйтмә, яныма да кайтма!

Һәм, чыннан да, бездән ике өй аркылы гына булган Фәйрүзә апаларның бакча рәшәткәсе буенда ук күзләрне кызыктырып торган чияләренә дә кагылганым булмады. Шуңа күрә яраталар да иде үземне. Башка малайлар кыяр сорап килгәндә:

– Һей, тоз күзләр! Урлап ашавыгыз гына җитмәгән, оялмыйча сорарга да килгәнсез! Каяле, мин сезне!.. – дип, пыр туздырып куып җибәрә торган әлеге шул Хәбир бабай мине үз шалашына чакырып кертеп сыйлый торган иде.

...Ә бүген мин күрәләтә печән урларга тиеш. Башыңа төшкәч, башмакчы буласың, дип, тиктомалга гына әйтмәгәннәр, күрәсең. Бүген тагын кичәге хәлнең кабатлануын теләми идем мин. Башка эшләрне тиз-тиз генә эшләп ташладым да, курка-курка гына булса да, бау тотып, печәнчеләр каршына – авыл башындагы үр буена киттем. Җиңги шулай кушты.

– Тау менгәндә олаучылар йөк өстеннән төшәләр дә арттан бара башлыйлар, – диде ул. – Менә шул чакта иң беренче йөкнең алгы ягыннан килеп йолкы да читкә ат печәнне. Беркем дә күрмәс. Аннары, олаулар үтеп киткәч, җыеп алып кайтырсың...

Әйе, аның сүзе дөрес булып чыкты: Фәйрүзә апа да, башка олаучылар да, үргә җиткәндә йөкләреннән төшеп, артка калдылар. Иң алда Фәйрүзә апа йөге. Нишләргә соң? Күрсә ачулана бит инде ул. Ә минем аны ачуландырасым килми. Чөнки мин аны үз апам күк яратам. Кечкенә чагымда, әни эштә вакытларда, мине карап, тәрбияләп торган кеше бит ул. Ул чакта Фәйрүзә апа үзе дә әле яшь, нибары ун-унберләрдә генә булган. Ә шулай да мине караган, ташлап китмәгән. Кирәк булганда, тәпиемне тоткан, еласам – ашаткан, эчерткән. Хәзер дә бик ярата әле ул мине. Инде мин менә шул үземне туган энеседәй күреп яраткан Фәйрүзә апаны ачуландырырга тиеш. Эшме соң инде бу, ә?!

Әй җиңги, җиңги! Нигә ялкауландың соң син? Җәй көне, кеше печән җыйганда, нигә җиләккә йөрдең?..

Мин шулай уйлап торган арада, Фәйрүзә апаның аты минем янга килеп тә җитте, узып та китте. Әмма печән йолкырга кулым бармады.

– Нишләп йөрисең монда, энем, бу суыкта? – диде Фәйрүзә апа, мине күреп алгач.

Аның башка чакта ап-ак йөзе, күрәсең, суыкта җилдә эшләп йөргәнгәдер инде, бүген чиядәй кызарып киткән, ә аксыл сары чәчләре шәленнән чыгып тузгып тора иде.

– Җиңги сезнең йөкләрдән печән йолкып алып кайтырга кушкан иде, – дидем мин, алдашырга телем бармыйча.

– Ә-ә, шулаймыни? Нигә йолкымадың соң?

– Ачуланырсың дип курыктым.

– Дөрес иткәнсең, энем! – Фәйрүзә апа тигез тешләрен күрсәтеп ягымлы гына елмаеп куйды һәм: – Тпру! Кил әле монда, – дип, атын туктатты да, йөгеннән йолкып, миңа бераз печән бирде. – Менә, алып

кайт, энем, җиңгәңә. Аның өчен бирүем түгел. Җәй буе кеше печән җыйганда, йоклап ятты ул. Искәндәр абыең киткәннән соң әллә нишләп бик гамьсезләнеп калды. Сине кызганып бирәм мин бу печәнне.

– Рәхмәт инде, Фәйрүзә апа.

– Ярар, зур үс, энем. Әниеңне сагынасыңмы?

– Сагына-ам, Фәйрүзә апа.

– Сагына торгансыңдыр шул, җиңгәң бик коры кеше бит синең. Ярар, чыда инде, энем, ничек тә түз. Солдат бит син хәзер, солдат түзәргә тиеш ул.

– Нинди солдат булыйм ди инде мин, Фәйрүзә апа? Солдат булсам, сугышта булыр идем мин, болай бер уч печән теләнеп йөрмәс идем.

– Юк, энем, солдат син хәзер. Сугыш вакытында бөтен кеше солдат була. Барыбыз да солдат без хәзер...

Мин теге печәнне күтәреп кайтып кергәндә, җиңги ишегалдында Мәдинә апа белән сөйләшеп тора иде. Укытучымны күргәч, җаннарым рәхәтләнеп китте. Әниемнән кала иң яраткан кешем бит ул! Беркайчан да, беркемгә дә ачуланмый, һәрвакыт йомшак кына, ягымлы гына сөйләшә. Хәтта кайбер балалар дәресләрен белмәгән чакларда да кызып китми, иплэп, ашыкмый гына аңлата. Белмим, үземә генә шулай тоеламы икән, ул мине аеруча якын итә шикелле.

Менә ул, миңа карап, һәрвакыттагыча матур итеп елмайды да әйтте:

– Без синең турыда сөйләшә идек әле, Равил. Җиңгәң әйтә, Равил «укуымны ташлыйм» дип әйтә, ди. Чынмы бу сүз?

Нишләргә инде? Нәрсә дияргә бу Мәдинә апага? Укыйсым бик-бик килә торып, ничек итеп «укымыйм» дип әйтергә?

Ни дип җавап бирергә дә аптырап, җиңгинең күзләренә карадым һәм шундук кичә ул өйрәткәнчә әйтүдән башка юл булмавын төшенеп алдым. Чөнки ул зур зәңгәр күзләренең агы белән шундый итеп карап тора, әгәр дә мәгәр Мәдинә апага дөресен сөйләп бирсәм, мине шундук кабып йотар төсле.

– Укымыйм инде мин, Мәдинә апа, – дидем мин. – Укыйсым килми.

– Нишләп? – диде Мәдинә апа, кинәт сискәнеп китеп. Миннән мондый җавап көтмәгән иде булса кирәк, ул тәмам аптырап калган иде. – Ничек инде ул «укыйсым килми»? Класста иң яхшы укучыларның берсе ич син. Ни дигән сүз инде бу?

Мин, башымны иеп, борынымны лыш-лыш тартып, ни әйтергә дә белмичә, өнсезләнеп тора бирдем.

– Әллә җиңгәң укытырга теләмиме? Яшермә, дөресен әйт син! – диде Мәдинә апа, таләпчән итеп.

Әйтерсең дөресен! Әйтеп кара! Әйттем дә бетте генә түгел бит ул. Кичен җиңги янына ятасы бар ич әле минем. Йә бәреп үтерер төнлә. Әнине дә күрми калуың бар...

– Юк, җиңги түгел, үземнең укыйсым килми, әнине окопка җибәрмәсеннәр иде, – дидем мин, тәмам елар чиккә җитеп һәм тагын җиңгигә күз төшердем. Бу юлы аның йөзе ай да кояш иде, хәтта күзләре дә көлеп тора шикелле тоелды.

– Менә, Мәдинәкәй, әйттем бит мин сиңа! – диде ул, куанычыннан нишләргә белмичә. – Әйттем бит, үзе укырга теләми, дип. Шулай булгач, мин аны нишләтим ди? Үз малаем түгел бит, тотып кыйнап булмый ич аны!

Ничектер шулай килеп чыкты, җиңгинең күз алдында ялганлап, авыз ерып торуына җен ачуларым кузгалып китте.

– Ы-ы, кыйнамассың син? Кичә ничек кыйнаганыңны оныттыңмыни? – дигәнемне үзем дә сизмичә калдым. Аннары үз сүзләремнән үзем куркып еларга ук тотындым.

– Әй Нәсиха, Нәсиха! – диде Мәдинә апа. – Ничек оялмыйсыз сез шушылый алдашып торырга?.. Ярар, анысын соңыннан тикшербез. Ләкин, карагыз аны, балага кул тидерәсе булсагыз, җавабын бирергә әзер торыгыз! Ә син, Равил энем, иртәгә үк мәктәпкә кил. Курыкма җиңгәңнән, кил, ярыймы!

Шулай диде дә, җиңгине тагын бер кат кисәтеп, капкага юнәлде, ә мин шикләнеп җиңгигә карадым. Аның күзләре яңадан нурсызланып калган һәм ул мине ботарлый башлаудан үзен бик зур кыенлык белән генә тыеп тора иде.

Мондый чакта җиңги белән икәүдән-икәү калу шактый хәвефле иде. Шунлыктан тиз генә Мәдинә апа артыннан йөгердем. Куып җитеп, чабуыннан тоттым да:

– Апа, мин җиңгиләрдә кунмыйм бүген, куркам мин аннан, – дидем.

Мәдинә апа, нишләргә икән синең белән дигәндәй, бер мәлгә аптырабрак торды да:

– Ярар, Равил, әйдә, мин сине үзебезгә алып кайтам. Минем янда кунарсың, – дип, Хәбир бабайларга алып китте. Ул үзе безнең авылныкы түгел, Чистай ягыннан килгән, ә Хәбир бабайларда фатирда тора иде.

Мәдинә апа минем хәлне сөйләп биргәч, Хәбир бабай да, карчыгы Мәфтуха әби дә башта мине бик кызгандылар, аннары хәзинәләрендә булган ризыклары белән әйбәтләп туйдырдылар. Аннары йокларга яттык.

Әмма мин тагын тиз генә йоклап китә алмадым. Күңелгә әллә нинди борчулы уйлар килә: миңа үч итеп, җиңги терлекләрне ач калдырмады микән, дип тә уйлыйм; бүген ярый, Мәдинә апа янында ятам, иртәгә кайда кунармын, дип тә борчылам. Ләкин барыннан да бигрәк, әни өчен кайгырам, аны сагынам. Ул бичара кайларда икән хәзер? Көнозын туң балчыкны казып бик арый микән? Алар окоп казый торган җиргә немецлар бик якын түгел микән? Ул да мине шушылай минем кебек сагына микән?..

Иртән Мәдинә апа белән мәктәпкә баргач та күңелем укуда булмады. Кичәге уйлар һаман күңелне тырнап торды.

Дәресләр беткәч, иптәшләрем өйләренә таралышты, ә мин партамда утырып калдым. Кая барыйм соң?

– Бер дә борчылма, Равил! – диде Мәдинә апа, яныма килеп. – Бар, безгә кайт та шунда утырып тор. Ә мин хәзер идарәгә барам. Анда Мөсфирә апаң килгән булырга тиеш, чакыртып җибәргән идем. Курыкма, барысын да рәтләрбез, әллә кая сикерә алмас җиңгәң. Сугыш заманасы булса да, совет властеның аңа җитәрлек кенә көче бар аның...

Хәбир бабайларга кайтып берәр сәгать утырдым микән, Мәдинә апа белән Мөсфирә апа да килеп җиттеләр. Мөсфирә апа хәзер авыл советы председателе булып эшли иде инде.

– Әйдә, энем, – диде ул миңа, килеп кереп, Хәбир бабайлардан исәнлек-саулык сорашканнан соң, – киен, хәзер җиңгәң янына кайтарып куярбыз сине.

– Кыйнар дип куркам мин аннан, Мөсфирә апа, – дидем мин, бишмәтемне кия-кия.

– Без аның белән бик ныклап сөйләштек инде, курыкма, энем, тимәс. Әгәр ялгыш кына кул тидерсә дә, килеп Мәдинә апаңа әйт. Белербез без аны нишләтергә. Ә укуыңны ташлама, ярыймы?

– Ярый, Мөсфирә апа, ташламам. Җиңги риза булырмы икән соң?

– Булыр, булмый хәле юк. Әгәр монда сезнең терлекләрне карарга иренсә, әниең урынына җибәрергә дә күп алмабыз!..

Без өчәүләшеп килеп кергәндә, җиңги идән-сәке юып йөри иде.

– Һу, кунаклар килә икән! – диде ул, без бусагадан атлауга. – Әйдәгез, әйдә! Түргә узыгыз.

Мине гаҗәпкә калдырганы шул булды: майлап куйганнар диярсең җиңгине – шундый ягымлы, шундый ачык.

– Әйдә, Равил, син дә чишен, сагынып беттем инде үзеңне, – диде миңа. Әйтерсең беркайчан да ачуланмаган да, кыйнамаган да мине.

Минем дә йөрәгем таш түгелдер, ахры: укырга рөхсәт итмәве өчен үлгәнче ачу тотып йөрермен, дип күңелемә беркетеп куйган булсам да, әлеге тәмле сүзләреннән соң тагын үз итеп куйдым җиңгине. Шулай да:

– Ә мине укырга йөртәсеңме соң инде, җиңги? – дип сорамыйча түзә алмадым. Укытучы белән председатель бар чакта мәсьәләне ачыклап каласым килде.

– Йөрерсең, йөрерсең, Равил! – диде җиңги.

Шулай итеп, барыбер мин дигәнчә булды.

**Эшләр җайланган иде дә...**

Җиңги миңа укырга рөхсәт биргән көнне аның үзен дә завхоз итеп куйганнар иде. Шул көннән алып ул да, элекке кебек, арт ягын кояш кыздырганчы йокламый, иртәрәк тора башлады, һәм без, икәүләшеп, йорт-җир эшләрен кул-кулдан тиз генә эшләп ала торган булып киттек. Җиңги мичкә яга, иртәнге аш әзерли торган арада, мин юырттырып кына су алып кайтам, чөнки инде кар яуган, фляганы үземнең үрәчәле кечкенә чанага утыртып йөрим. Ә чана арбага караганда күп җиңел ул. Җиңги мал-туарга печән сала, су эчерә торганда, мин абзарларны җыештырып куям. Аннары тиз-тиз генә ашыйбыз да, ул – амбарга, мин мәктәпкә китәбез. Ә тирес түгү, идән юу, бәрәңге әрчү кебек вак-төяк эшләрне мәктәптән кайткач эшләп алам. Кыскасы, хәзер минем эшләр шактый көйле. Җиңги белән дә үзара ярыйсы гына тату яшибез.

Ә тора-бара минем эшләр тагын да шәбәеп китте: төштән соң, җиңги амбарда вакытта, Миңлеәхмәтләр, Фәрзетдиннәр белән чана да шугалый башладым. Җиңги кушып калдырган эшләрне мәктәптән кайтуга бергәләп эшләп ташлыйбыз да тауга чабабыз. Ә алар миңа бик теләп булыша, чөнки мин аларга икмәк бирәм. Икмәк дигәндә, малайлар утка керергә әзер, чөнки Миңлеәхмәтнең дә, Фәрзетдиннең дә әниләре күптән инде икмәк салмыйлар. Оннары юк.

Фәрзетдин аеруча хирыс ашауга. Әнисе кушып киткән эшләрне эшләмәсә эшләми, әмма борынын сузып, Миңлеәхмәттән алдан кереп җитә минем янга. Керә дә:

– Бүген нинди эшләрең бар? – дип сорый. Мин санап күрсәткәч: – Кайгырма, малай, хәзер бетерәбез без аларны. Тик иң элек ашап аласы иде бит, карын бик ач минем, – ди.

Ләкин алдамый үзе. Ашаганнан соң җен урынына эшли. Гәүдәгә дә миннән зуррак, тазарак та ул.

Ә мин алардан ашауны кызганмыйм. Җиңги амбарда эшләгәнлектән, оныбыз бер дә бетеп тормый. Икмәкне күпме ашасам да, җиңги миңа ачуланмый. Бары:

– Кара аны, Равил, җиңги он алып кайта, дип, кешегә-фәләнгә ычкындыра күрмә! – дип кисәтеп кенә куйды.

Әйтәмме соң инде! Тиле түгел лә мин: халыкка ишетелсә, җиңгине ни эшләтәселәрен һәм җиңги мине ни эшләтәчәген аңларлык кына башым бар ич!

Авылыбызның Тәгъзимә исемле бер хатынын әнә ындырдан бишмәт кесәсенә салып борчак алып кайтканы өчен генә дә өч елга утырттырды бит Самат абый. Әле ул өч елны да балалары күп булуын искә алып кына биргәннәр. Югыйсә җиде ел ук сыламакчы булганнар, ди. Биш баласын да ниндидер детдом дигән җиргә алып киттеләр. Атасыз-анасыз балаларны тәрбияли торган урын, ди, бугай анысы... Җиңги амбардан он алып кайта, дисәм, мине дә шунда җибәрмәсләр дисеңме әллә? Әни юк бит минем хәзер, кем алып калсын ди мине...

Кыскасы, ашау ягыннан да кайгым юк, картлар әйтмешли, кияү сыенда яши башлаган идем хәзер мин. Әмма... Ипләп кенә, әнине сагынудан башка читенлек күрмичә генә яшәп яткан көннәрдә тагын минем өчен шактый күңелсез хәл килеп чыкты: бер дә бер кичне җиңги миңа мич башында ятарга кушты.

– Син бик тынгысыз йоклыйсың, Равил, – диде, – бөтен өстемне ачып ташлыйсың, тибенәсең.

Нихәл итмәк кирәк, гаеп үземдә булгач, буйсынудан башка чара юк инде. Тик шунысы сәеррәк: нигә моңарчы ул турыда бер сүз дә әйтмәде икән соң бу җиңги?

Ләкин, ничек кенә булмасын, карышып торудан файда юк. Әнием түгел бит, эреплэшеп булмый җиңги белән. Ышанма аңа, йә, ачуы килер дә, бөтенләй идәндә үк йокларга кушар...

Шуларны уйладым да мендем тәвәккәлләп мич башына. Әмма ул төнне керфек тә какмадым дисәм дә ялгыш булмас. Чөнки гомеремдә дә ялгыз ятканым юк, һәрвакыт әни куенында төн үткәргән кеше мин. Җитмәсә, мич башында таракан бик күп булып чыкты. Шулар кыштырдашудан куркып, беренче төнне йокысыз үткәрсәм дә, соңыннан анысына да күнектем тагы. Әмма ул тынычлык та озакка бармады. Кышкы буранлы кичләрнең берсендә безгә Самат абый килеп керде.

– Мәгъсүмә малае синдә тора бугай, нишләп күренми, әллә берәр җиргә җибәрдеңме? – диде ул, өй эчен күздән кичергәч.

Мин мич өстеннән башымны сузып карап тора идем.

– Мин монда, Самат абый! – дип кычкырдым. Әни турында берәр куанычлы хәбәр алып килдеме икән әллә, дип өметләнгән идем. Юк икән, булса, әйтми калмас иде.

Ә ул:

– Әһә! Андамыни? Йокла инде, энекәем, йокла, урының җылыда икән! – диде дә, мине шундук онытып, җиңги белән пышын-пышын сөйләшә башлады. Мин аның «суган», «булса, икмәк тә...» дигән сүзләрен генә ишетеп калдым. Аннары голт-голт итеп шешәдән нәрсәдер агызган тавыш килде. Аракы эчте, ахры. Бераздан җиңгине дә кыстый башлады, әмма җиңги якын да китермәде:

– Юк, юк, Самат абый! Әйтмә дә, сөйләмә дә! Әйдә, тизрәк эшеңне кара да юлыңда бул. Югыйсә кеше әллә ниләр сөйли башлар.

– Курыкма, Нәсиха сеңел, – диде Самат абый, бу юлы шактый нык кычкырып. – Сөйләрлек кеше бармыни хәзер авылда. Сөйләсәләр дә аптырама. Эт өрер, бүре йөрер!

Шулай дигәннән соң җиңгине кочакларга итте булса кирәк, чөнки җиңги:

– Самат абый, нишлисең син? Җибәр, югыйсә разбуй салам! – дип, чырыйлап кычкырып куйды.

Эшләр болайга киткәч, Самат абый шикләнә төште:

– Ярый, ярый, бетте, – диде. – Бүлше кагылмыйм. Тик кума гына. Синең яныңда утыру гына да үзе бер гомер минем өчен.

Ах, чулак пәри! Кара, ни сөйләнеп торган була бит, ә?! Их, көчем җитсә! Якасыннан гына эләктереп алыр идем дә... Йә менә хәзер Искәндәр абыем кайтып керсен иде. Ну булыр иде дә соң кызык хәлләр!..

– Шулай да, әйт әле, Нәсиха, – диде Самат абый, байтак гомер дәшми торгач, – ниме дип чакырдың син мине, куасы булгач?

– Кем? Минме? – диде җиңги, гаҗәпләнгән тавыш белән. – Мин чакырдыммы сине? Ачуымны китереп торма, Самат абый, прсидәтел дип тормам, типкәләп чыгарырга да күп алмам. Соң, үзең «кереп чыгам» дидең ләбаса!

– Син мине нигә килә дип уйладың соң? Әллә шушы аракыны эчәр урын тапмас дип белдеңме?

– Мин берни дә уйламадым. Кереп чыгармын, дигәч, кермә, дип әйтеп булмый ич кешегә. Ә син үзең нәрсә уйлаган идең соң?

– Ярар, исерә башладым, ахры, мин. Кая, кайтыйм әле булмаса...

Чыгарга дип ишек катына килгәч, тагын туктап калды:

– Ә, мижды пручим, сине окоп казырга җибәрмичә хата эшләгәнмен мин, Нәсиха. Мин сине болай ук каты күңелле булырсың дип уйламаган идем. Хата эшләнгән, хата-а!

– Ярар, ярар, Самат абый, әйе, дөрес әйттең, хата булган. Бар, кайт инде, кайт, балаларың янына кайт!

– Әйе шул, кайтыйм әле. Иртәгә килермен, яме!

– Әйе, әйе. Китерермен мин сине! – диде җиңги, тешләрен кысып, һәм, җилтерәтеп, тегене чыгарып та җибәрде.

Шушылай борып җибәргәч, Самат абый бүтән килмәс, оялыр, дип уйлаган идем мин. Әмма намус саклаучылардан түгел икән ул, икенче кичне үк килеп җитте. Тагын аракы алып килгән бу. Бераз эчеп алгач, тагын җиңгигә бәйләнергә тотынды. Тик бүген җиңги аның белән артык сатулашып тормады. Яртылаш бушаган шешәсен кесәсенә тыкты да, таза, көчле куллары белән якасыннан алып, кичәгедән дә хәтәррәк җилтерәтеп куып чыгарды.

Әрсезнең дә әрсезе икән инде ул Самат абый. Кешегә әйтсәң, кеше ышанмас – өченче кичне дә килде бу безгә. Әмма монысында өйгә дә кертмәде аны җиңги: өйалды ишеген дөбердәткән тавышка, өй ишегеннән башын тыгып, кем бар анда, дип сорады да, Самат абый икәнен белгәч:

– Сорама да, ачмыйм да! – дип шартлатып өй ишеген дә бикләп куйды да урынына ук барып ятты.

Шуннан ары байтак вакыт Самат абый безгә килмәде.

**Бәла өстенә бәла**

Көннәр акрынлап үтә торды, минем тормыш үз көенә ага бирде: укуым да әйбәт кенә бара; үземә тапшырылган эшләрне дә Миңлеәхмәт, Фәрзетдин белән бергәләп ансат кына эшләп ташлыйбыз; җиңги дә хәзер минем белән булашмый: мактамый да, ачуланмый да. Ләкин, ничек кенә булмасын, күңелем һаман тыныч түгел – өзелеп-өзелеп әниемне сагынам. Ул кайтып, үз өебездә яши башлагач, икмәк түгел, бәрәңгесе дә туйганчы эләкмәячәген дә беләм, тик барыбер әнине тизрәк кайтарасы килә. Миңлеәхмәтләр, Фәрзетдиннәр әнә ачлы-туклы да торалар ич әле. Дөрес, хәлләре бик үк шәптән түгел инде түгелен. Миңлеәхмәт соңгы вакытта бигрәк нык ябыкты. Муены нечкәргәнлектән, элек тә ярыйсы ук дәү башы хәзер тагын да зураеп калды, битендәге сипкелләре дә куерып китте. Хәтта кай көннәрне дәрес барганда ничектер өнсезләнеп калган чаклары да була.

Әмма мин аны барыбер үземнән бәхетлерәк саныйм, чөнки ул әнисе белән бергә тора. Мин дә ничек тә түзәр идем әле. Ахыр чиктә, ачка үлсәм дә, әни кочагында үлү җиңгидән куркып, аңа ярарга тырышып яшәүдән мең өлеш артыграк булыр шикелле. Тик әнием генә тизрәк кайтсын!..

Ә ул кайтмый да кайтмый. Киткәннәренә инде ике айдан артык вакыт үтте, әмма кайтыр чамалары юк әле. Җиңгинең сүзе хак булса, тагын берәр айсыз кайтмаячаклар, ди.

Тәки, шул алдан әйткәнчә, өч ай тотарлар, ахры.

Тагын бер ай!.. Ай-яй озак үтә икән ул ай дигән нәрсә!.. Сугышын да әйтер идем инде, шултикле озакка бармаса... Шулай безгә каршы торырлык дәрәҗәдә үк көчле микәнни ул немецлар, нигә тизрәк бөтереп тыкмыйлар икән инде шуларны?.. Без чит илләрнең бер карыш җиренә дә тимибез, әмма үзебезнекенә кагылсалар, ул чакта рәхим-шәфкать көтмәсеннәр... Без укый торган китапларда әнә шулай дип язылган иде ләбаса. Соң ул сүзләр шапырыну гына булды микәнни? Нигә тизрәк кырып салмыйлар икән инде ул фашистларны? Ә алар безнең авылның байтак кешесен харап иттеләр бит инде. Җиңги белән санап караган идек, авылыбыздагы шул нибары утыз җиде йорттан кырык өч кеше сугышка киткән. Шуларның егерме тугызы турында йә «үлде», яки «хәбәрсез югалды» дигән язу да килгән инде. Әгәр гел шушылай барса, безнең авылның бер кешесе дә кайтмаячак бит! Җиңги әйтә, әле һаман фашистлар безне кысрыклый, ди. Белмим, ни белән бетәр икән инде моның ахыры?!

Мин шул рәвешле борчылып йөргән көннәрдә Фәрзетдиннең атасы турында да «Геройларча үлде» дигән хәбәр килде. Герой булып үлүе ярый инде анысы. Ни әйтсәң дә, йөзләп фашистның башына җиткәндер әле. Югыйсә алай дип язмаслар иде. Әмма, ничек кенә булмасын, ул юк бит инде, Вафа абыйны әйтәм. Кайтмаячак ич инде ул, беркайчан да кайтмаячак! Әй яхшы да кеше иде соң үзе! Аның ат җиккәнен күрдекме, хәзер Фәрзетдин белән арбасына менеп кунаклый идек. Бер сүз дә әйтмичә авыл башына тикле утыртып барыр иде. Сугышка китәр алдыннан гына безгә мич тә чыгарып биргән иде. Әни ничек кенә кыстаса да, бер тиен хезмәт хакы да алмаган иде, мәрхүм... Әй бу дөнья! Андый әйбәт кешеләрне үтергәнче, әнә, Хәбир бабай әйтмешли, председатель Самат шикелле ни Аллага, ни муллага игелек күрсәтә алмый, күрсәтергә дә теләми торган адәми затларны тончыктырасы иде дә бит... андыйлар сугышка ярамый шул...

Атасы үлгәннән соң, Фәрзетдин дә безгә кермәс булды. Чөнки Вафа абый турында теге өмет өзгеч хәбәрне алганнан ары анасы еш кына авырып егыла башлады аның. Әнисен ташлый алмый шул.

Аннары Миңлеәхмәтнең атасы турында да «Батырларча һәлак булды» дип яздылар. Шуннан соң ул да миңа булышудан туктады, чөнки әнисе аңа да эшне күбрәк куша башлады. Ләкин мин аларга үпкәләмим, һәм без өчебез дә элеккечә бик дус яшибез. Миңа ярдәм итәргә вакытлары булмаса да, алар

икесе дә көненә бер тапкыр безгә кереп чыкмыйча калмыйлар. Мин аларга йә калган ашны ашатам, йә җиңги миңа дип калдырып киткән икмәктән өлеш чыгарам.

Соң, шулай булмыйча! Тәпи йөри башлаганнан бирле өчебез бергә уйнап, әниләребез биреп чыгарган ризыкны үзара бүлешеп ашап үскән дуслар ич без. Җәй көннәрендә урамда уйнап йөргәндә берәребезгә югары оч малайлары бәйләнә башласа, хәзер калган икебез килеп җитә дә бер-беребезне яклап алып кала торган идек.

Ә хәзер... һәркайсыбызның үз хәсрәте...

Кыскасы, соңгы көннәрдә минем эшләр яңадан көйсезләнеп китте. Бердән, эш күп, икенчедән, уйнарга һич вакыт калмый. Аннары дусларым Миңлеәхмәт, Фәрзетдиннәр белән дә рәхәтләнеп сөйләшеп утырып булмый. Җитмәсә, Миңлеәхмәт атасы турында теге язу килгәнгә бер атна да үтмәгәндер, минем Искәндәр абыйның да хәбәрсез югалуын әйткән кәгазь килде. Монысын мин һич тә көтмәгән идем инде. Минем Искәндәр абыем гади солдат кына түгел бит. Шофер иде ләбаса ул, сугышка да үз машинасы белән киткән иде ич... Ярый, җәяүле солдатларны үтерсеннәр дә ди немецлар. Соң, машиналы кешене ничек итеп тоттылар икән алар, ничек куып җитмәк кирәк ди аны? Әллә машинасына бер-бер хәл булдымы икән? Пуля тиеп ватылды микән әллә?.. Шулай булган тәкъдирдә дә немецларга бирешергә тиеш түгел бит ул. Бөтен районда беренчелекне алган батыр ич ул... Белмим инде, белмим!.. Ә бит Искәндәр абый минем этием урынына калган кеше иде. Туры килгәндә һәрвакыт үзе янына кабинага утыртып йөри торган иде. Бервакыт районга да алып барган иде хәтта. Бик тиз йөри иде ич аның машинасы, җәяүлеләрне генә түгел, атлыларны да выжт итеп кенә узып китә торган иде. Үзе дөнья хәтле йөк тә төйи торган иде әле. Шуңа күрә үскәч үзем дә шофер булмакчы идем бит мин. Ә икенче теләгем гармунчы булу иде. Минем бу уемны Искәндәр абый да белә, сугышка киткәндә:

– Исән калсам, сиңа гармун алып кайтырмын, энем, яме, – дигән иде.

Гармуны кадалып китсен, үзе исән кайтса да ярар иде әле. Ә ул әнә югалган. Машинасы нишләде икән инде аның? Анысы да югалдымы икән? Хәбәрсез югалган кеше кайта микән соң ул? Минемчә, кайтырга тиеш. Сугыш кызуында фашистларны куып алгарак киткәндер дә, юл язып, адашып кына калгандыр. Машинасы да югалмагандыр әле. Әйе, шулай гынадыр. Әнә узган җәйдә җиләккә баргач, иптәшләремнән аерылып китеп, үзем дә адашып калган идем ич. Әни минем өчен куркып үлә язган ул чакта. Ә миңа берни дә булмады. Юл эзләп йөри-йөри тәмам арыгач ятып йокладым да иртән, әтәчләр кычкырган, этләр өргән якка чамалап барып, үзебездән биш километрдагы Ильиновка авылына килеп чыктым. Анда шофер Искәндәр энесе икәнлегемне шундук танып алдылар да, бер рус агае ат җигеп өйгә үк китереп куйды... Искәндәр абый да әнә шулай адашыбрак киткәндер. Ә иптәшләре аны югалды дип уйлаганнардыр да җиңгигә хәбәр иткәннәрдер...

Әмма җиңги башкачарак уйлый иде, ахры. Хат ташучы теге язуны китергәч, ул бик нык куркып китте, бүтән вакытта пешкән алма шикелле булып кызарып торган йөзе кинәт агарып калды. Аннары лып итеп урындыкка утырды, байтак вакыт хәлсезләнеп торды да үзәкләрне өзәрлек итеп кычкырып елап җибәрде. Озак, бик озак елады җиңги ул көнне. Гитлерын да, Алласын да, мулласын да каргый-каргый елады. Кулы – эшкә, авызы ашка бармады. Ә кичен ниндидер моңарчы мин ишетмәгән моңлы бер көйгә җырлады-җырлады да:

– Их, ник чукынып китми дөньясы! Искәндәрем булмагач, ни кызыгы кала инде аның миңа? Ичмаса, бераз хәсрәтем таралмасмы! – дип, абый кайта-нитә калса, аны сыйларга дип әзерләп куйган бер шешә аракысын мич астыннан тартып чыгарды. Аннары шул шешәдән бер стакан тутырып салды, аны эчеп җибәрде дә тагын озак итеп җырлады һәм, караватта утырган җиреннән бер якка кыйшаеп, гырлап йокыга китте. Өй эче шундый шомлы, шундый куркыныч булып калды, ул кичне минем мич башына менәргә йөрәгем җитмәде: бер очы җиңги астында калган юрганны көч-хәл белән генә тартып чыгардым да, шуны ябынып, караватта гына йокладым.

Әллә шуны гына көтеп торган инде, Искәндәр абыйның хәбәрсез югалуы турында язу алганның икенче кичендә үк Самат абый тагын безнең ишеккә килде. Ләкин җиңги бу юлы да кертмәде аны:

– Зинһар, йөрмә йөрәгемне бозып, сине көндез күреп тә туйган мин, гарык! – дип борып җибәрде.

Ә Самат тагын, тагын килде. Мин юри санап бардым, нәкъ җиде кич рәттән борып җибәрде аны җиңги. Бары тик сигезенче кичне генә түзмәде, ачты ишекне.

Тагын җиңгигә бәйләнә башламаса ярар иде, дип куркып, Самат абый чыгып киткәнче йоклый алмыйча яттым ул кичне. Әмма Самат абый җиңгигә кагылмады. Матур гына сөйләшеп утырды да, алып килгән аракысының да бер генә стаканын эчеп, иплəп кенә чыгып китте.

Шуннан ул һәр кичне диярлек безгә килә башлады. Аның әйтүенчә, хатыны Бибиҗамал апа эчкән кешене һич тә яратмый икән, шулай ук башка кешегә керергә дә яхшы түгел, колхозныкын эчә, дип әйтүләре бар. Ә җиңги аңа үз кеше, бер табактан ашаучы, имеш.

– Менә шуңа киләм мин сезгә, Нәсихакаем, – дип аңлатты Самат абый, үзенең болай еш керүенең сәбәбен.

Ә ул киләсе кичне җиңги, амбардан ит алып кайтып, бик шәпләп аш пешереп куя һәм, әлбәттә, миңа да өлеш чыга. Районнан килгән начальникларны ашатырга колхоз һәрвакыт сарык суеп куя, шуңа амбарда ит бетеп тормый.

Шулай итеп, җиңгигә дә тимәгәч, ул киләсе көнне ит тә пешә башлагач, Самат абыйга ничектер күнегеп киттем, ахры. Ул киткәнче үк йоклый идем хәзер. Ләкин бер дә бер төнне һич тә истә-оста булмаган күңелсез хәл килеп чыгып, хәйраннарга калдырды мине.

Төн урталары булгандыр, кинәт безнең өйалды ишеге бик нык дөберди башлады. «Беттек болай булгач, немецлар безнең авылга килеп җиткәннәр икән! Әнине дә күрми үләм, ахры» дип уйлап алдым мин. Аннары:

– Җиңги, җиңги! – дип кычкырып, еларга ук тотындым.

Җиңги урынына бер ир кеше җавап бирде:

– Тик кенә ят син анда, малай актыгы! Пычак кердеме әллә, шултикле акырасың? – диде ул, коры гына итеп. Шундук танып алдым – Самат абый тавышы иде бу.

Хәзер минем эчкә җылы керде инде. Самат абый бездә булгач, немецлар түгел, Гитлер үзе килеп керсә дә курыкмас кебек идем. Чулак һәм гәүдәгә кечкенә булса да, ир кеше ич әле ул, немецлар килеп керә калса, ирек бирмәс...

Ә ишек һаман дөберди.

– Бар, чыгып кер инде, Нәсиха, – диде Самат абый, дөбердәтүченең һич тә туктар чамасы сизелмәгәч. – Кем икәнен сора да кер, ишегеңне ачасы булма!

Кем булыр икән бу вакытта? Әни кайтмагандыр бит? Әллә Искәндәр абый микән? Нигә тизрәк керми икән?

Мин шулай уйлап, баш ватып яткан арада җиңги әйләнеп керде дә, Самат абый янына барып:

– Нишлибез инде менә хәзер? Бибиҗамалың килгән бит! – диде. – Безнеке сездә булырга тиеш, өеңне кереп карамыйча китмим, ди. Менә әйттем мин син йолкышка, вакытында чыгын кит, дип. Хәзер бөтен дөньяны сасыта инде!

– Ах, ан-насын... Кая, идән астыңны ач әле, сеңлем Нәсиха, – диде Самат абый, киенергә тотынып.

Ул арада өйалды ишеге баягыдан да битәррәк дөберди башлады.

– Ә-ә-ә! Шулаймыни? Әле син качып котылырга уйлыйсыңмыни? – диде җиңги, белмим, нигәдер бик каты ачуланып. – Юк инде, алай итмибез аны! Куркырлык булгач, кермәскә кирәк иде, чакырып китердемме әллә мин сине?! Үзең юхаланып, ташлыйм Бибиҗамалны, сизсә дә курыкмыйм мин аннан, дип әтәчләнеп йөрдең түгелме соң?!

Шулай диде дә ишеккә юнәлде.

– Ашыкма әле, кая, ут кабыз әле, итекләрне табыйк әле, – диде Самат абый, ялварып. – Ишегегез нык бугай, түзәр, җимерелмәс. Шакысын әле куллары авырткančы. Гел мине генә тукмарга димәгән... Болай да буш итмәс әле, беләм мин аның холкын...

Самат абый мыгырдана-мыгырдана киенеп торган арада, җиңги чыгып ишекне ачуы булды, авызыннан утлар чәчеп, Бибиҗамал апа килеп тә керде.

Немецлар керсә дә ирек бирмәс әле, дип бушка өметләнгәнмен икән, юк икән Самат абыйның көче. Көче булса, хатынына бераз каршы торыр иде.

Ну бирде дә соң Бибиҗамал апа үзенә!

– Ах, әле син шулаймы, чулак тәре! Шундый эш белән шөгыльләнәсеңме, оятсыз! – дип, башта битенә төкереп, аннары коелганнан калган сары чәченнән эләктереп алды да тотынды кисәргә, тотынды тукмарга тегене – үрле-кырлы сикерә Самат абый:

– Бибиҗамал, тукта, тилермә! Бибиҗамал, җитте!

«Сыер дуласа, аттан яман» дип бер дә юкка гына әйтмәгәннәрдер, ахры. Бибиҗамал апага каршы сугу түгел, кулын да күтәрә алмады Самат абый. Хәер, хатыны да таза иде инде. Самат абыйдан буйга да күп озын, аркага да ике-өч мәртәбә киңрәк иде шул Бибиҗамал апа.

Ирен туйганчы тәпәп, аннары типкәләп ишектән чыгарып җибәргәч, берочтан җиңгигә дә очып кунмакчы иде, җиңги якын да китермәде. Гәүдәгә Бибиҗамал ападан күп кайтыш булса да каушап калмады:

– Якын киләсе булсаң, миңа үпкәләмә, мин сиңа чулак Саматың түгел! – дип, кулыннан тотып алды да ансат кына читкә кагып куйды тегене.

Күрәсең, көч белән алдырып булмаслыгын сизенгәндер, Бибиҗамал апа җиңгигә бүтән ыргылмады. Әмма тел белән... дөньядагысын калдырмады инде!

Ә җиңги, берни булмагандай, бөеренә таянып (тегеләр сугышканда да шулай торган иде ул) тыныч кына тыңлый бирде. Аннары мыскыллы елмаеп:

– Җитте, Бибиҗамал апа, кызыгы китте, тукта! Сүзләреңне кабатлый башладың! – диде.

– Ә-ә! Шулаймы? Туйдыңмыни? Оятыңа көч килә башладымыни? Ах җир бит! Оятың кая синең, сөйрәлчек?

Моннан йөз мәртәбә әшәкерәкләрен әйткәндә дә тыныч кына тыңлап торган җиңги Бибиҗамал апаның соңгы сүзләреннән соң түзеп тора алмады булса кирәк:

– Ахмак син, Бибиҗамал апа! – диде, нигәдер көлеп җибәреп. – Ахмак булмасаң, шушы сүзләрне сөйләп тормас идең. Болай дөнья сасытып йөрмәс идең. Иреңне шушындый яшь, чибәр хатын өенә керткәнгә сөенер идең син. Акылың булса, үзең уйлап кара әзрәк: синең ул өрсәң очып китәргә торган йолкышыңны яратканнан өемә керткән дип уйлыйсыңмы әллә? Башка замана булса, мин аны бусагамнан атлату түгел, урамда очратканда да төртеп егып китәр идем дә бит, заманасын Алла каһәрләгән! Син миңа ачуланма инде, Бибиҗамал апа җаным, бар, әнә Гитлерга ачулан. Нигә, сугыш ачып, мине ирсез калдырды икән ул?

Бу сүзләрне җиңги бер дә ашыкмыйча, иплән кенә әйтте. Күрәсең, аның мондый сабырлыгы Бибиҗамал апага да күчте булса кирәк:

– Анысы шулаен шулай да соң... күрә торып, иремне синең янга йөртә алмыйм бит инде! И, минем урында булсаң, син дә шулай ук риза булмас идең, – диде ул, ипкә килеп.

– Ярар, Бибиҗамал апа, булган беткән инде. Узган эшкә салават. Аны тикшереп тормыйк. Ә хәзер, бар, кайт. Дөнья сасытып, шаулап йөрмә! Ирең прсидәтел кеше, кеше теленә менсә, әйбәт булмас. Әле, ни дисәң дә, колхоз икмәге белән туенып торасыз бит. Прсидәтеллектән очырсалар, биш балагызны туйдыру сезгә дә җиңел булмас. Мондый чакта кызып китәргә ярамый, акыл белән эш иткәндә дә таманга килә. Сугыш бит, дөньяның асты өскә килә торган чак...

– Сугы-ыш! – диде Бибиҗамал апа, тирән сулап. – Әй, шул Гитлерны тотып асасы иде, каһәрне!.. Ә син, Нәсиха, шулай да минем сүзләрне дә колагыңа ал әле, наным: Саматны, килсә дә, борып җибәр.

Шулай диде дә, йомышка кергән кешедәй, акрын гына атлап чыгып китте. Мин дә, мәсьәләнең болай ансат хәл ителүенә куанып, мич өстеннән башны алдым.

Тиз генә йокыга китеп булмады. Җиңги белән Бибиҗамал апа арасында булып үткән әлеге сөйләшү гаҗәпкә калдырды мине. Соң, шулай булмыйча! Бигрәк кызык икән бу олылар; башта пыр тузышып ачуланыштылар, аннары шундук татуланышып та киттеләр. Ә без, малайлар, бер-беребезгә үпкәләшсәк, өчәр көн сөйләшми йөргән булабыз...

**Күрәселәребез алда икән әле**

Бибиҗамал апа тузынганда үзен бик тыныч кына тоткан кебек булса да, теге төнге вакыйга җиңгине дә тетрәткән иде, ахры: шуннан соң ул күзгә күренеп үзгәрде, усалланып китте. Миңа да, бер дә гаебем юк шикелле булса да, тагын теге зур зәңгәр күзләренең агы белән карый, Самат абыйны да кертми, кире борып җибәрә башлады. Шулай ук йорт-җирдән дә күңеле суынды аның. Хәзер ул ит тә, он да алып кайтмый, ашау-эчүгә дә игътибар бирми: пешерсә пешерә ашны, пешермәсә – юк. Калдык-постыкны ашыйбыз да ятабыз.

Терлекләрне дә элекке кебек вакытында ашатмый хәзер җиңги. Мин моны шуннан әйтәм, соңгы көннәрдә безнең сыер күзгә күренеп ябыга башлады. Ә мин сыерыбызны яратам, аны күрсәм, әнине күргән шикелле булам. Менә шуңа бик борчылып, җиңгигә сүз катып караган идем каравын, нәтиҗәсе булмады.

– Сезнең ул сыерыгыз сыер гына түгел ул, – диде җиңги, кашын-күзен җимереп, – тәмугы ул! Барлы-юклы ике йөк печәнне шушыңарчы төткәргәнгә рәхмәт әйт!

Менә сиңа кирәк булса! Соң әле кышның уртасы гына бит, инде шул ике йөк печән бетте дә микәнни соң? Әни аны, колхоз бераз салам бирсә, бөтен кышка җитәр дип әйткән иде ләбаса! Дөрес, халык окоп казудан кайткач, салам бүлмәкче булалар бугай. Соң инде печән беткәч, коры салам белән генә сыерны ничек кыш чыгармак кирәк? Тукта әле, иртәгә тезмәләренә менеп карыйм, җиңгиләрнең үз печәннәре ни хәлдә икән. Үз сыерына да безнекен ашатып ятмады микән?

Икенче көнне тезмәгә менсәм – шаклар каттым: җиңгиләрнең үз печәннәре мин аларда тора башлаганда күпме булса, хәзер дә шул килеш. Ә безнеке, күп булса, ун көнлек нәрсә калган! Кара инде, ә! Үз сыерына да, сарыкларына да безнең печәнне ашатып яткан ич бу, болай булгач... Их, үзем ашаткан булсам, белер идем мин аның кадерен! Юк шул, миңа ышанмаган булды:

– Курмыңы үзем ашатырмын терлекләргә, син әрәм-шәрәм итәрсең йә тезмәдән егылып төшәрсең, – диде.

Ярар, сыер әни кайтканчы аяктан егылмаса, әни ничек тә җаен табар әле...

Үз-үземне шулай юатып, ике күземне дүрт итеп, әнине тагын да ныграк көтә башладым. Ләкин булмады, түзмәде сыер ул кайтканчы! Әниләр кайтырга ике көн калды дигәндә бозаулый башлады да, бозавын китерә алмыйча үлә башлады. Аннары, бозавын гына булса да исән килеш алып калырга кирәк, дип, Хәбир бабай сыерның эчен ярды һәм, чыннан да, бозау исән иде. Мин барыбер тормас бит ул бозау, имезергә әнкәсе юк ич аның, дип кайгырып-куркып торганда, Миңлеәхмәтнең әнисе кич

белән бер чүлмәк сөт алып керде. Аннары шуңа бармагын тыгып бозауның авызына китерде һәм – гаҗәп хәл! – бозау чупылдатып имә башлады.

Көтә торгач, окоп казучылар кайтыр көн дә җитте. Ул көнне мин иртүк тордым. Үземә тиешле эшләрне тиз-тиз генә әмәлләп ташладым да, чанамны тартып, авыл башына әнине каршыларга киттем. Мәктәп кайгысы түгел иде бүген миндә, әнине тизрәк күрәсем килә иде.

Җиле, бураны булмаса да, көн шактый салкын. Мин авылны чыккач, тагын да салкынайтып җибәргәндәй булды, йортлар ышыгында чакта гына сизелмәгән икән, җиле дә бар, ара-тирә җәяүле буран да себерткәләп куя. Күк йөзе аяз, кояшлы, шунлыктан урман да, тирә-яктагы кырлар да бик яхшы күренә иде.

Әниләр кайтасы юлга карап тора-тора туңа башлагач, авыл читендәге тауга бардым да чана шуарга тотындым. Ләкин таудан өч-дүрт мәртәбә шуып төшүгә, бу уенның кызыгы бетте. Башка көннәрдә, уйныйсы килсә дә, вакыт булмый, ә бүген киресенчә: вакыт күп, уйнарга дәрт юк. Шулай да салкын үзенекен итте, мине әледән-әле тауга куып менгерә торды.

Менә төш вакыты да җитте, үтеп тә китте, ә әниләр һаман юк әле. Инде карыным да ача башлады. Барыбер өйгә кайтмадым – әнине авыл башында ук каршылыйсым килде.

Ниһаять, дөньяны кичке эңгер каплый башлагач, урман ягыннан чаналар шыгырдавы, атлар пошкыруы, кешеләр сөйләшүе ишетелә башлады. Мин шундук аларга каршы йөгереп бардым да әнием кочагына ташландым. Әни мине күтәреп үк алды, кайнар иреннәре белән салкын битләремне үбәргә тотынды. Аннары юлга бастырды да йорт-җир, терлек-торыш турында сораштыра башлады.

– Кит аннан! – диде ул, мин әле өченче көн генә сыерыбыз үлүен әйткәч. Беркавым аптырап, өнсезләнеп торды.

– Әйе, әни, бозаулый алмыйча үлде ул, ә бозавы исән, – дидем мин, үземчә аны юатмакчы булып.

– Ярар, улым, – диде әни, мөлдерәп аккан күз яшьләрен сөртеп. – Без күрәсен кеше күрмәс, күрәчәгебез булгандыр инде... Ярый әле үзең исән-сау икәнсең, шунысы әйбәт.

Шуннан соң без туп-туры үз өебезгә кайттык. Әни мичкә ягып җибәрде.

Ә бераздан безгә җиңги килеп керде. Бик кайгырган атлы булырга тырышып, сыерның үлүен сөйләргә тотынды.

– Ярар, килендәш, рәхмәт инде, тырышкансың, – диде әни, ачуланмыйча гына. Башка бер сүз дә әйтмәде, кисәү алып, мичтәге утыннарны рәтләргә тотынды.

Әни ачуланмагач, җиңги сөенер инде дип уйлаган идем. Алай булмады. Киресенчә, ничектер күңелсезләнеп, кара янып китте ул. Аннары:

– Фи! Тыңламаган да була, әйтерсең аның сыерын мин бәреп үтергән! – диде дә, ишекне шартлатып ябып, чыгып китте. Шул китүеннән соң, миннән башка беркем дә ышанмаган-көтмәгән хәл килеп чыкканга тикле, ул да безнең өйгә, без дә аның йортына аяк басмадык.

Мичкә тәгәрәтеп пешергән бәрәңгене ашарга утыргач, әле яңа гына күргәндәй булып, әнигә карап тордым мин. Артык үзгәрмәгән иде ул: керфекләре дә элеккечә кара, озын; чәчләре дә һаман шулай коңгырт, калын; уң як битендәге энә күзе тикле генә бер бөртек миңе дә нәкъ үз урынында иде. Тик йөзе бераз сулыгып, һаман җилдә, суыкта йөргәнлектән каралып калган да гәүдәгә азрак кечерәеп киткән. Ә элек аның йөзе алсу һәм түгәрәк иде...

Тамакларны туйдыргач, шул ук кичне кул чанасы тартып бардык та бозауны җиңгиләрдән үзебезгә алып кайттык. Ә иртәгесен, мин йокыдан торганда (ул төнне мин рәхәтләнеп, туйганчы йокладым!), әни сарыкларны да алып кайткан иде инде.

Аннары, бәрәңге алмакчы булып, базны ачтык. Ачтык та шаккатып калдык. Суыкка чыдый алмыйча, базның өстендәге җир ярылып, бәрәңгебез дә өшегән булып чыкты. Кичә күршеләрдән үтечкә алып торган бер чиләк бәрәңгене түләрлек булса да исәннәре чыкмасмы дип, ни эзләсәк тә, бер сау бәрәңге дә таба алмадык.

– Хәзер бу базны ябып торудан мәгънә юк инде, – диде әни, тәмам өмете өзелгәч, – буласы эш булган монда...

**Әтием белән очрашу**

Өшегән бәрәңгене таза бәрәңге белән чагыштырып булмый, әлбәттә. Ләкин, нужа бабай муенныңнан кысып тоткач, алай авызга алмаслык ук дәрәҗәдә начар да түгел икән ул. Һәрхәлдә, җан асрап була икән аның белән. Эссе суга салып кабыгын сыдырып аласың да, кирәк икән, шуннан аш пешерәсең, кирәксә, шул килеш ашарга да була.

Ләкин безне мәсьәләнең икенче ягы борчый иде: орлыкка бәрәңге кайдан алырга? Өшегән бәрәңгене утыртып торасы да юк, барыбер тишелмәячәк.

Әни белән нәк шул турыда кайгырышып йөргән көннәрдә Самат абый килеп керде безгә:

– Ишеттек, Мәгъсүмә иптәш, ишеттек, казалы булгансыз икән, – диде ул, – зур казалы булгансыз икән! Хәзерге заманда сыер – крестьянның бөтен байлыгы, бөтен өмете, бөтен куанычы ул. Анысы һәркайсыбызга мәгълүм. Әмма дә ләкин син артык хафаланма, Мәгъсүмә иптәш. Илдә чыпчык үлми, диләр, бер рәте чыгар әле. Без дә кулдан килгән тикле ярдәм итәргә тырышырбыз. Әле менә бүген идарә членнары белән сөйләштек тә бозавыгыз ашый башлаганга тикле һәр көн калхуздан дүртәр литр сөт биреп барырга булдык. Бәрәңгегез дә өшегән икән, аны да искә алдык, и менә болай итәргә булдык: давай, күпме бәрәңгегез бар, барысын да фермага илт, дуңгызларга ярар, тамакларына тыгылып калмас әле. Ә үзең аның урынына калхуз подвалыннан өшемәгәннәрен алып кайт.

Самат абыйның бу сүзләрен ишеткәч, шатлыгымнан чак кына кычкырып җибәрмәдем. Әни дә чамасыз куанган иде бугай.

– Рәхмәт инде, Самат абый, бик зур рәхмәт инде! Орлыкка бәрәңге каян алырбыз, дип ут йотып йөри идем.

– Анысы шулай инде, Мәгъсүмә иптәш, кулдан килгәнчә тырышабыз инде аны, – диде Самат абый, нигәдер утырган урынында калкынып куеп, – тик, кунак ашы кара-каршы дигәндәй, үзең дә калхузга булышырсың.

– Һей, Самат абый, нәрсә сөйлисең инде син, калхуз яралганнан бирле бер көн дә эштән калганым юк лабаса! Моннан ары да кая кушсагыз, шунда эшләрмен.

– Туктале, Мәгъсүмә иптәш, – диде Самат абый, нигәдер йөзен чытып, – ашыкма әле син. Мин бит син начар эшлисең диюем түгел бу. Дөрес аңламадың, ахры. Без синең именны менә шул яхшы эшләвеңне искә алып, атвитствынный урынга куймак булдык...

«Атвитствынный» дигәне шул: фермага дуңгыз карауччы кирәк, әнине шунда куймакчы икән Самат абый.

Хәзерге заманда ферма эше бик үк мактаулы эш түгел инде түгелен. Читенлеге өстенә ялгыз кешегә җайсызлыгы да бар: бер караңгыдан икенче караңгыга тикле йөрергә туры килә. Башка чак булса, ихтимал, әни ризалык бирергә ашыкмас иде ул эшкә. Әмма хәзер, колхоз шушындый зур ярдәм итәргә торганда, каршы килә алмады.

– Ярар, ярар, Самат абый, мин риза, кайчан эшли башларга кушасыз соң? – дип кенә сорады ул.

– Бүген үк фермыга менәргә туры килер, Мәгъсүмә иптәш, – диде Самат абый. – Теге сорхантай, моңарчы дуңгызлар караган кызны әйтәм, кичә дуңгызларын ташлап, каядыр башка авылга чыгып сызган. И әйткән: «Мине көтмәсеннәр, тиз генә кайтасым юк, кайтсам да, фермыда эшләмәячәкмен, дуңгыз карап кияүгә чыкмыйча калыр хәлем юк, ансыз да кияү табулары бик кыен хәзер!» – дигән. Кайта-нитә калса, кияү табып бирер идем мин аңа бирүен. Шундый политика тараткан өчен, бер сигез-ун елны сылаттырыр идем сылаттыруын!..

Шулай итеп, әни фермада эшләргә тотынды. Ул тизрәк эшен бетерсен өчен, мин дә аңа булышкалый башладым.

Өйдә үзем генә калырга курыкканга, башта мин дә әни белән фермада кунып йөрдем. Ә аннары, күрәсең, әнине кызганыптыр инде, ферма каравылчысы Шәйхи бабай минем белән генә куна башлады.

Бик әйбәт кеше ул. Без аның белән төннәр буе сөйләшеп утырабыз. Ул миңа үзенең башта, патша вакытында, немецлар белән, аннары Чапаев дивизиясендә аклар белән ничек сугышып йөрүләрен, төрле кызыклы вакыйгалар, экиятләр сөйли.

Инде әйткәнемчә, мин әтиемне хәтерләмим. Шунлыктан аның холкы, гадәтләре нинди булганлыгы да мәгълүм түгел иде миңа. Әмма кышкы озын төннәрнең берсендә Шәйхи бабай миңа әтием хакында шундый итеп сөйләп бирде – мин әтиемне, чыннан да, тере килеш күргәндәй, хәтта аның белән сөйләшкәндәй булдым. Минем әти озынчарак каратут йөзле, калын кара кашлы, гәүдәгә шактый зур һәм таза булса да, бик җиңел сөякле кеше булган. Аны зирәклеге, карусыз булганы өчен яшьтән үк яратканнар. Хәтере дә бик әйбәт булган. Хәтта безнең авылдан берүзе, теге чакта мин адашып барып чыккан Ильиновка исемле күрше авылга йөреп, русча да укыган ул. Шунлыктан русчаны су урынына эчкән. Егерме яшендә, 1929 елны, колхоз председателе итеп сайлаганнар аны. Әнигә дә шул елны өйләнгән. Бабай белән әби (әнинең әти-әнисе була инде): «Кызыбызны рус сабагы укыган каммун кешегә бирмибез», – дип, башта аяк терәп каршы торсалар да, әти, тегеләргә төн уртасында барып кереп: «Яхшылык белән Мәгъсүмәне миңа бирмәсәгез, икегезне тиң тынсыз итәм!» – дип, наганын чыгарып төзәгәч, теге бичаралар берсүзсез риза булганнар һәм соңыннан, инде әти белән әни кавышып матур гына тора башлагач, җитәкләшеп килеп, әтидән гафу үтенгәннәр.

Колхозны да «уйнатып кына, бер дә көчәнмичә генә» җитәкләп барган әти. Әни белән дә тату яшәгән. Мине дә бик яраткан. Хәтта идарәгә килгәндә дә мине үзе белән алып йөри торган булган.

Менә шулай матур гына эшләп, әйбәт кенә гомер итеп торганда, 1935 елның кышында, районнан кайтышлый әти көчле буранга юлыга. Аты юлдан язып туктап кала. Әти юлны эзләмәкче булып чанасыннан төшүгә, яшь айгыр, нәрсәдәндер өркеп, кар ерып чабып киткән. Шул караңгы төндә япан кырда берүзе калган әти. Җитмәсә, өстендә дә юка, кыска пинжәк кенә икән, толыбы чанада киткән.

Катып үлмәс өчен, арлы-бирле йөрергә керешкән ул. Ләкин ел озынлыгы кышкы төн үзенекен иткән – эти тәмам арыган да, бераз ял итеп алырга дип, кар өстенә утырган һәм... шунда йоклап киткән.

Ихтимал, ул шунда туңып үлгән дә булыр иде. Ләкин таң вакытында буран басылгач, юлга чыккан күрше авыл олаучылары коткарган аны. Дөресрәге, олаучыларның эте коткарган: эти янына килеп өрергә тотынгач, тегеләр килеп тапканнар этине һәм, шундук танып алып, безнең авылга алып кайтканнар. Өйгә керүгә, эти мич башына менеп яткан һәм шул ятудан бүтән тора алмаган; суыктан җылыга кергәч, үпкәләре шешенеп киткән дә үпкә авыруы башланган. «Колхоз тикле колхозны алып барырга башы җиткән кеше иде атаң, әмма мич башына менәргә ярамавын уйлап җиткерә алмаган, мәрхүм, – дип сөйләде миңа Шәйхи бабай. – Әнә шул гына харап итте аны. Авырып сигез ай ятты да үлде. Әй, үләсе килмәде дә инде үзенең. «Шушы Равилем җиде-сигез яшькә җиткәнче генә торсам да үкенмәс идем» ди торган иде, бичара. Ничәдә инде син, улым?»

– Майда ун тула, Шәйхи бабай.

– Кара инде, ә? Гомернең үтүен сизми дә каласың. Су күк ага да тора... Ичмаса, замананың да бик болгавыр чагы. Ну бу сугышны!..

Шәйхи бабай миңа әкиятләр сөйләү белән бергә чабата үрү белән дә шөгыльләнә. Чын-чынлап, бөтен күңелен биреп эшли. Аның чабаталарын безнең авыл халкы гына түгел, күрше авыллардан да килеп алалар, мактый-мактый кияләр.

Чабата үрү башта миңа бик читен, баш җитмәстәй эш булып күренгән иде. Әмма, ныклап торып тотынганда, бер дә алай искитмәле нәрсә түгел икән. Шулай Шәйхи бабайның эшен игътибар белән карап йөри торгач, мин үзем дә хәйран гына маташтыра башладым ул нәрсәне. Ә язга таба Шәйхи бабай ярдәменнән башка да, баштанаяк үзем үрә торган булып киттем. Аннары инде үземә генә түгел, әнигә дә үреп бирә башладым. Эх, күрсәгез иде сез әнинең бу һөнәремә ничек куанганын! Хәер, үземнең дә башым күккә тигән иде бугай. Соң, шулай булмыйча! Бер киеме 15–20 сум тора бит чабатаның. Дөрес, акчасы да әллә никадәрле түгел инде. Тик, ничек кенә булмасын, безнең әнинең, сыер да үлеп киткәч, килер җире бөтенләй юк лабаса...

Тора-бара әни белән үземә генә түгел, күрше-күләнгә дә чабата үреп бирә торган булып киттем. Ә алар безгә сөт, катык, кайчакта хәтта бераз май да кертәләр.

Бер ияләшкәч, бик кызык икән ул чабата үрү. Берсен үреп бетермисең, икенчесенә тотынасы, анысын тагын да матуррак итәсе килә, күңел үсканнән-үсә бара икән. Шуның өстенә хәзер авыл халкы да, мине мактап:

– Әнә Мәгъсүмә малае нишләтә: үзе калыптан печтик кенә зуррак булса да, коеп кына куя чабатаны! – дип сөйли башлагач, ничек куанганымны үзем генә беләм.

**Дүрт көн эчендә алты мәет!**

Саескан сумалага төшкән. Башын алса, койрыгы ябыша, ди. Безнең дә хәлләр шулайрак булып чыкты.

Үксез бозавыбыз да үсеп килә, чабатаны да сатып алмыйбыз; кара җиргә аяк бассак, ничек тә үлмәбез, дип кенә торганда, кинәт бәрәңгебез бетеп китте. Бетте дигәч тә, бөтенләй үк бетмәде ул, унбиш чиләкләп бар әле барын. Әмма әни, ашарга ярамый аны, улым, орлыкка кирәк, ди. Хәзер безнең ризык – элмә кайрысы да юкә кабыгы. Көненә бер мәртәбә бер уч арыш ярмасыннан пешерелгән аш эләгә. Күрше-күләннең дә эшләре мөшкелләнде булса кирәк: сөт, катык керткәләүне туктаттылар.

Кар озаграк яткан булса, нишләгән булыр идек икән, безнең бәхеткә яз иртә килде. Кырлар аллана башлауга, колхозның узган елгы бәрәңге җиренә черек бәрәңге җыярга киттек. Сөт-май булганда, шул черек бәрәңге онынннан пешергән ботканың нинди тәмле булуын әйткән дә юк инде. Хәтта, кабыгын да әрчеп тормыйча, учакка күмеп пешерелгәнен ашаганда да дөнья рәхәте була. Тик күбрәк кенә булсын.

Ләкин аны да күпләп җыеп булмады. Без ике генә көн иркенләп йөреп калдык, аннары, бездән күреп, бөтен авыл кырга чыкты һәм өч-дүрт көндә бәрәңге җирен актарып ташладылар.

Нужа калач ашата, диләр. Безгә калач ук ашарга туры килмәде килүен, шулай да күп нәрсәгә өйрәтте безне нужа бабай. Черек бәрәңге җыелып беткәч, халык узган елда коелып калган башакны җыярга ябырылды. Без дә, башагыннан аерып җилгәргәннән соң, бер чиләккә якын ризык җыйдык. Зур хәзинә иде бу безнең өчен. Икенче төрле итеп әйтсәк, кузгалак, какы һәм юалар үсеп җиткәнче яшәргә була дигән сүз. Ә аннары кычыткан, кузгалак, алабута өлгерәчәк. Әни әйтмешли, Алла яңгырларын гына бирсен дә, дөньяны кызу гына көйдермәсен.

Тик кайберәүләргә кычыткannар үсеп җиткәнче торырга насыйп булмаган икән шул. Һич тә көтмәгәндә, истә-оста юк чакта, беркөнне минем кечкенәдән бергә уйнап үскән дустым, яшьтәшем, күрше малае Миңлеәхмәт кинәт кенә үлеп китте. Аны күмеп кенә кайтканнар иде, Фәрзетдин дә дөньядан китеп барды. Аннары башкалар...

Кыскасы, ике көн эчендә безнең кечкенә генә авылдан алты кеше вафат булды.

Элек, сугышка кадәр, мәетне зиратка ирләр күтәреп алып барып күмә торган иде. Хатын-кызлар ул тирәгә якын да бармый иде. Кабер казырга берәү дә әйтеп тормый, кешеләр үзләре белеп киләләр иде. Ә хәзер, ирләр булмагач, әлеге мәетләрне Самат абый, махсус наряд биреп, хатын-кызларга күмдертте, кабер казучыларга хезмәт көне дә язган, дип сөйләделәр.

Мин Миңлеәхмәтнең дә, Фәрзетдиннең дә мәетләрен карарга кермәдем. Аларны күмгәндә зиратка да бармадым. Юк, куркудан түгел. Үземнең иң якын дусларымның бу дөньядан мәңгегә китүенә ышанасым килми иде. Соң әле кайчан гына бергә уйнап йөргән идек ләбаса без! Ничек итеп шуларның мәетен карарга йөрәгем җитсен ди?

Соңыннан беленде: Миңлеәхмәт тә, Фәрзетдин дә һәм башкалар да теге кар астында кышлаган башак бодаен ашап агуланганнар икән.

Эшләр болайга киткәч, районнан врачлар килеп тикшерделәр дә, кемнең күпме җыйган бодае бар – барысын да күрше совхоздагы спирт заводына илтеп алмаштырырга куштылар. Хәер, алай итмәсәләр дә, ташламаган булыр идек без әлеге бер чиләк әйберне. Ни дисәң дә, ач үлгәнче, туеп үлү хәерлерәктер кебек. Әмма болай эшләүләре әйбәт булды, агуланып үлүләр тукталды...

Тукталуын тукталды да, тик Миңлеәхмәт белән Фәрзетдин юк иде шул инде. Ә бит без гомер буе дус булырга, җиденче классны тәмамлаганчы бергә укырга, бергә армиягә барырга, аннары барыбыз да шофер булырга сүз куешкан идек... Бу кадәр гел миңа гына кәкре килеп торыр икән!

**Булыр, әни...**

Күрәсең, адәм баласының табигате шундыйдыр инде: тәнендә җаны булып, чак кына хәрәкәтләнә алганда, дөнья белән кызыксынудан туктамыйдыр ул. Мин моны үземнән чыгып әйтәм. Соң, черек бәрәңге белән генә җан асрыйм бит инде үзем! Шулай булгач, нинди уен кайгысы булырга тиеш? Әмма яшь күңел барыбер үзенекен итә икән. Атка атлану рәхәтенә ирешү өчен, язын колхоз сабанга чыккач, иртәнге өченче яртыдан торып, кәнүшнигә бара торган булып киттем. Моның үзенә күрә сәбәбе дә бар: барыбер игелек күрсәтми алар, дип, Самат абый колхоз дуңгызларын дәүләткә тапшырттырып бетергәч, әнине ат караучы итеп куйдылар. Ә мин, әлеге дә баягы шул куркаклыгым аркасында, һәрвакыт иртән әнигә ияреп кәнүшнигә йөри башладым. Менә шунда колхозчы апалар атларны җитәкләп кырга җир сөрергә чыкканда, мин дә, аларның бер атына атланып, сөрә торган җирләренә кадәр барам. Аннары, атка атланганнан соң күңелдә туган рәхәтлеккә чумып, чатыр-чотыр өйгә йөгерәм. Анда әни иртән кушып калдырган вак-төяк эшләрне тиз генә эшләп ташлыйм да төшкә тагын кырга чабам. Тагын атка атланып кайтам.

Шулай берничә көн йөргәч, Фәйрүзә апа (мин күбесенчә аның Дүпләненә атланып йөри идем) миңа, атларны үзем тотып, җир сөреп карарга да рөхсәт итте. Монысы инде атка атланып йөрү генә түгел, аннан ун өлеш рәхәтрәк. Бер кулың белән дилбегәне, икенчесе белән сабан тоткасын тотасың да, төрәннәрнең җир кантарын ничек әйләндереп салуын карап барасың. Бернинди кыенлыгы юк. Атларның берсе – буразнадан, берсе сөрелмәгән җирдән салмак кына атлап бара. Әйләнгән саен җирнең сорысы кими, ә карасы – кояш нурында ялтырап, түшәктәй күпереп ятканы артканнан-арта бара. Синең эшләгәнеңне күреп, шуңа сөенешеп, күккә эленгән тургайлар җырлап тора. Тик җир башында борылуы гына бераз кыенрак, сабанны күтәрергә көч җитеп бетми. Ләкин бу кыенлык күпкә бармады, Фәйрүзә апа миңа ул бәладән котылу юлын да өйрәтте.

– Атлар борылып җиткәндә, сабан тоткасын чак кына үзеңә таба каерып җибәр син, нәнем, – диде ул. Минем белән бер әйләнеп, ничек-ничек итәргә икәнен күрсәтеп, аңлатып чыкты да, җир башына барып, сырмасын баш астына куеп ятып йоклады. Ә мин төшкә тикле аның җирен сөрдем. Төштән соң да бармакчы идем дә, әни җибәрмәде:

– Вакыты җиткәч тә ватылырга өлгерерсең әле, балам, йөрмә! – диде. – Йорт-җир эшләрен караштыр әнә. Бик эшлисең килсә, урманга кер дә коры-сары утыннар җыеп кайт, учакка ягарлык кына булса да, бер аш пешерергә җитсә дә ярар, зыяны тимәс...

Әни дөрес әйтә, бик нык вата икән ул җир сөрү. Көнозын сабан койрыгы тотып йөреп, аяклар калмый. Ләкин барыбер җир сөрәсем килә иде минем.

Колхозыбыз кечкенә булганлыктан, бездә бригадир юк, бөтен эшне әлеге шул председатель Самат абый алып бара. Аны бик үк яратып бетермәсәм дә, беркөнне идарәдән чыкканын саклап тордым да миңа атлар биреп, җир сөрергә рөхсәт итүен үтендем.

– Ниятең әйбәт синең, малай, – диде ул, мәче башлы ябалакныкы кебек түгәрәк кызгылт кара күзләрен кыскалап, мине тыңлаганнан ары, – тик атка йөгән ора алырсың микән соң? Камыт та кигерәсе була бит әле аңа.

Әйе, ул хаклы. Атка йөгән кидерерлек буем юк минем. Ләкин каушап калмадым:

– Фәйрүзә апа кигереп бирер әле, Самат абый, – дидем. – Без гел аның белән бергә сөрербез.

– Карале! – диде Самат абый, кинәт елмаеп җибәреп, – атаңа охшыйсың, ахры, син, малай актыгы. Башың эшләр төсле күренә синең. Давай болай итәбез: иртәгә Мәүлиха апаңның атларын ал да җир сөрергә чык, аңа башка эш бирербез. Аякларым сызлый, дип сукрана иде, аңа да бераз ял булыр.

– Әни! – дидем мин, шатлыгымнан кая басканымны да белмичә йөгереп кайтып. – Әни! Иртәгәдән мин эшли башлыйм! Самат абыйдан сорадым. Ул Мәүлиха апа атларын җигәргә кушты. Әни, барам, яме, ачуланма, яме!

– Әй улым, улым! – диде әни. – Бик яшь бит әле син. Әле яңа унберенче яшь китте ич сиңа. Көннәр буе ат артыннан йөрер вакытың түгел ләбаса! Син түгел, олыларның да җелеген суыра торган эш ич ул. Белмим инде, белмим, нәрсә эшләп болай ашкынасың икән! Булдыра алырсыңмы икән соң, улым?!

– Булыр, әни, менә күрерсең! Мин хәзер зур бит.

Шулай дигәч, әни каршы килмәде:

– Карап кара инде, алай бик эшлисең килгәч.

Ләкин Мәүлиха апа атларын җигеп эшкә чыкканның беренче көнендә үк чамасыз нык арыдым мин. Кояш батканны көтә-көтә җаным чыга язды. Шулай да сер бирәсе килми, Фәйрүзә апага ул турыда бер сүз дә әйтмәдем. Бары кайтырга чыккач кына:

– Фәйрүзә апа, Самат абыйга әйт, иртәгә эшкә чыкмыйм мин, бик арыдым, – дидем.

– Шулайдыр шул, энем, – диде Фәйрүзә апа, – кечерәк шул әле син. Синең күкләр әнә берсе дә мондый авыр эштә эшләми бит. Без лутчы болай итик: мин Самат абыйга әйтермен, сине тырмага кушсын, анда җиңелрәк булыр, атка атланып йөрерсең.

– Самат абый рөхсәт итәрме икән соң?

– Итәр, Равил, итми хәле юк, бер кешене бишкә ярырдай заман бит хәзер.

Ахры, чыннан да шулай булгандыр, икенче көнне Самат абый миңа тырмага чыгарга кушты.

– Атларга чиратлап – төшкә кадәр берсенә, төштән соң икенчесенә атланып йөрерсең, – диде ул һәм үзе үк атка атлану өчен ничек итеп баудан баскыч ясарга икәнен өйрәтеп торды...

Шулай итеп, мин язгы чәчү беткәнче тырмада йөрдем. Күрәсең, олылардан ким эшләмәгәнмен, чәчү беткәннең икенче көнендә колхоз идарәсе тарафыннан бүләкләнүчеләр арасында минем фамилиям дә бар иде. Яхшы эшләвем өчен мактый-мактый, Самат абый үз кулы белән миңа өч метр соры ситсы бирде. Бик ярап куйды ул. Күлмәгем тузып, менә бетә, менә тәмам төшеп кала дип курка-курка гына йөргән чакта, кулыбызга эләккән шул ситсыдан бик әйбәтләп бер күлмәк тә, кыска булса да, бер ыштан тегеп бирде әни. Шуның өстенә байтак кына хезмәт көне дә эшләгән идем әле.

**Бүген генә түзәм дә...**

Язгы чәчүдән соң колхозда парга сөрү, тирес түгү кебек эшләр башланды. Болары миңа ярарлык эшләр түгел иде: тирес түгәргә барсаң, арба аударасы була, ә җир сөрүдә авызым бер пеште инде. Шуңа күрә Самат абый да ирексезләмәде, үзем дә ашкынып тормадым.

Җәй – чабатаның иң үтемле чагы. Бердән, кышка караганда җәен тиз туза ул, икенчедән, бөтен авыл җәен чабата кия. Киез итек кышын кадердә йөрсә дә, минем кебек итексезләргә аны киеп урам әйләнүе үзе бер гомер булыр кебек тоелса да, җәен сукыр бер тиенгә дә тормый ул. Безнең авылда бер генә кеше – Хәбир бабай гына кия аны. Анда да яратканнан түгел, аяклары авыртканга гына... Ә чабата үтә. Нәкъ менә шуңа күрә дә мин яңадан чабатага тотындым. Үземә – өч, әнигә биш кием әзерләп куйганнан соң, күрше-күләнгә дә үреп биргәли башладым.

Ул арада печән өсте дә килеп җитте. Самат абый мине, атка атланып, богыл өючеләргә печән тарттырырга кушты. Монысы инде тырмада йөрү түгел – мең өлеш күңеллерәк. Болында кырдагы кебек тузан да юк, көннәр буе берьялгызың кеше белән сөйләшергә зар булып, бик аптырагач, ат белән сөйләшеп тә йөрисе түгел. Инде килеп, Хәбир бабай әйтмешли, хайван түгел, үзең тотып ашарга ярарлык җиләкле, чәчәкле ямь-яшел печәннең хуш исе үзе бер җәннәт нигъмәте бит ул!

Хатын-кызлар печәнне җыеп, чүмәләгә өеп тора, син шуны тарттырып богыл янына илтеп торасың. Бер чүмәлә китергән саен, богыл биегәеп, Хәбир бабай югарырак күтәрелә бара, әнә шул күренеш күңелдә әйтеп бетергесез горурлык хисе тудыра. Менә шушы рәхәтлекләрнең барысыннан тыш, печән өстендә ашау да колхоздан булганлыгын искә алсак, минем ни өчен алай бик куанып эшләп йөрүем аңлашыла булса кирәк. Чыннан да, көнгә өч тапкыр токмачлы аш, ярты кило ипи – хәзерге заман өчен, Хәбир бабай әйтмешли, кода сые бит ул. Икмәк турында сөйләп тә тормыйм инде, өйдә ашының да рәте юк ич аның: кузгалак та берәр уч оннан әмәлләнгән умач. Анысы да көн саен тәтеми әле.

Башкалардан шактый кечкенә булганлыктандыр инде, минем корсак печәнчеләргә бирелә торган аш белән дә тула, ә үземә тиешле икмәкне әнигә алып кайтам. Гомеремдә онытасым юк, беренче көнне икмәк алып кайтып биргәч:

– Әй заманалар! Синең кулдан икмәк ашар кешеме соң инде мин?! Беләм бит, балам, ашыйсың килмәгәннән алып кайтмагансың син моны. Көн буе эштә йөргән кешегә, башка замана булса, бу икмәк

чәп итәргә дә җитмәс иде. Заманы каһәрләнгән шул! Ярар инде, балам, бик зур рәхмәт инде! – дип елый-елый аркамнан сөйде әнием.

Хәер, әни сүзендә дә дөреслек бар: богылга печән биреп торучы Фәйрүзә апалар ничек чыдаганнардыр, хәтта мин дә, атка атланып йөрсәм дә, шактый нык арыйм. Ник дисәң, һаман юыртып йөреп тә җитешеп булмый. Богыл башында торучы Күлти бабай:

– Давай, малай, тизрәк! Давай, давай! – дип кычкырып кына тора.

Күлти дигәнем әлеге шул элек яшелчә каравыллаган Хәбир бабай инде. Гражданнар сугышында кулын имгәтеп кайткан ул. Сул кулының бармаклары культиватор кискечләре сыман тырпаеп торганга, ачуыбыз килгән чакларда – үзе ишетмәгәндә, билгеле, – Күлти дип йөри идек без аны. Гарип булса да, сугыш чыкканнан бирле, яшелчә бакчасын ташлап, төрле эштә йөри башлады ул, һәм эшкә дә бик таза үзе. Сәнәк сабын теге «күлтиләре» арасына кыстырып куя да иртәдән алып төшкә, төштән алып кичкә чаклы һаман шулай «давай, давай» дип куыра.

Берәү дә ныклап ачуланмый аңа, чөнки һәркем белә: үзе өчен давайламый бит ул, колхоз өчен, бөтен авыл халкы, бөтен ил өчен тырыша. Әгәр дә берәрсе сукрана башласа:

– Чыда, балакай, минем өчен эшләмисең бит. Вакытында шушы җиләк күк печәнне җыеп калмыйча, узган кыштагы кебек, быел да колхоз терлекләренә түбә саламы ашатмыйк инде. Бакчи, көне нинди матур. Түз, балакай, яңгырлар киткәнче ничек тә бетерик, яңгыр көнне ял итәрсең, яме. Сугыштагы кешеләргә моннан йөз тапкыр кыенрак. Алар да түзә. Немечләрне дөмектергәнче ничек тә түзегез, аннары болай ук читен булмас, – дип көйләп тә куя Хәбир бабай...

Барлы-юклы көч белән тырышып, колхозның печәнен чабып-өеп бетергәнче, арыш та өлгереп җитте. Авылның аз гына булса да кыймылдый алган карчыкларыннан алып урак тотарга көче җиткән кыз балаларына тикле кырга чыкты.

Уракка керешүгә берәр атна үтте микән, сугу эшләре башланды. Хәзер инде печән өстендәге кебек кенә түгел! Печәнне, теләсәң дә, чык кипмичә җыярга ярамый. Ә көлтәне тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ташы. Халык көндез урак уруда, ә төннәрен, ике көннең берендә үз сыерларын җигеп, ындырга көлтә ташыйлар.

Ат җигеп йөрүчеләргә дә ансат түгел. Көндез ындырга көлтә ташысалар, төнлә дәүләткә ашлык илтергә китәләр. Заготзерно безгә унсигез километр. Анда барып кайтканнан соң, куян койрыгыдай кыска җәйге төннең күпмесе кала? Шул ук атлар, шул ук кешеләр көндез тагын йә көлтә ташыйлар, йә җир сөрергә чыгалар...

Ул чорларда мин ат кудым. Безнең колхозда трактор-фәлән юк, игенне дә алты ат көче белән эшли торган алты тешле машина белән сугалар. Шул алты атның икесен мин куам. Без, өч малай (алар миннән олырак), иртәнге алтыдан кичке тугызга кадәр бер түгәрәк эчендә әйләнәбез. Барабан, туктаусыз үкереп, авызына Хәбир бабай тараткалап тыккан көлтәләрне йотып тора, хатын-кызлар кайсы саламын селкеп, кайберләре арышын, бодаен, кыскасы, нәрсә сугылса, шуны җилгәрүчеләргә тырма белән эшереп илтеп тора. Ындыр табагыннан күтәрелгән тузан болыт булып күкләргә аша...

Хатын-кыз бар җирдә сүзсез генә эшләү булмый, ындыр табагындагылар да үзара сөйләшкәннәрдер, әлбәттә, тик безгә аларның тавышы ишетелми. Әмма Хәбир бабай сүзләрен аермачык ишетеп торабыз:

– Малайлар! Йокламагыз! Солдат бит сез хәзер!

– Малайлар, анагызны корт чаккырлары, давай!

Хәтта беркөнне, барабанын ташлап, «күлти» бармакларын селти-селти йөгереп килеп, Габделгазизгә эләктереп тә ала язды ул. Хәер, Габделгазизнең үзендә дә гаеп булды. Атларын яхшылап кумаган иде. Хәбир бабай бик дөрес пыранлатты аны. Кусын атларын яхшылап, югыйсә безнекеләр дә трактор түгел ич, авырга килә бит аларга!..

Анысы шулай, әмма мин үзем дә бик арыйм. Соң, уйлап карагыз: иртәнге алтыдан кичке тугызга кадәр эш. Барлыгы унбиш сәгать буламы? Ярый, төшке ялга, ике әбәткә (төшкә кадәр унбиш минут, төштән соң унбиш минут) барысы ике сәгать китсен ди. Калган унөч сәгате гел аяк өстендә йөреп үтә бит аның. Сәгатенә биш километр гына йөрсәк тә, көн буена алтмыш биш километрга тула бит ул. Әллә нигә бер генә түгел, айлар буена һәр көн шултикле җир йөри башласаң – күзләрең күгәрер.

Дөрес, Хәбир бабай миңа:

– Тәртәгә утырып йөр, улым, синең әллә ни авырлыгың юк, – дип әйтә әйтүен. Ләкин Гәрәй белән Габделгазиз утырмагач, ничек берүзем генә утырып йөрим инде. Габделгазиз әйтмешли, «трут»ны барыбызга да бертигез язалар ич, шулай булгач...

Ә Хәбир бабай тегеләргә утырып йөрергә һич тә рөхсәт итми. Кичкә таба, бик арыгач, тәртәгә менеп кунакласалар да, «күлти»ен күрсәтеп, хәзер себереп төшерергә генә тора. Яшерен-батырын түгел, бик арыган минутларда мин машинаның ватылуын тели идем. Ә ул, үч иткәндәй, тагын да шәбрәк үкереп эшли башлый. Шундый көннәрне үз-үземә: «Бүгенгә генә түзәм дә иртәгә үтерсәләр дә чыкмыйм ат куарга. Әнә минем шикелле малайлар рәхәтләнеп уйнап йөриләр», – дим. Ә иртән, төнлә йоклап ял иткәннән соң, кешеләр: «Булмады, йомшак икән Мәгъсүмә малае, укулары башланганчы да

түзә алмады, биреште – ташлады эшен!» – дип әйтмәсеннәр өчен, шул ук вакытта, хезмәт көне эшләп, әнигә дә булышу нияте белән, йөгәннәремне иңемә асып, тагын кәнүшнигә менәм...

**Укыйсым бик килә дә бит...**

Шулай көн артыннан көн үтте, мин түземсезлек белән көткән вакыт – уку башланыр чак та килеп җитте. Укыйсым бик-бик килә. Яз көне дә, Мәдинә апа авырып киткәнлектән, укудан бик иртә – апрельнең егерме өчендә үк туктаган идек. Аннары уку миңа бик җиңел бирелә. Мәдинә апаның аңлатканын тын да алмый тыңлап утырам да барысын да хәтерләп калам. Өйдә озаклап дәрес әзерләп торырга кирәк түгел, арифметикадан бирелгән мисаллар белән язма күнегүләрне генә эшлим дә вәссәлам. Ә башка фәннәрне икенче көнне дәрес башланыр алдыннан бер кат күз йөртеп, китаптан карап чыгам да, шул җитә. Әйтмәгәнем булсын, тфү-тфү, моңарчы әле бервакытта да «яхшы» яки «бик яхшы»дан түбән билге алганым юк.

Ә мәктәптә Мәдинә апаның йөзенә карап утыру үзе нинди зур бәхет! Бүтән балалар да шулаймы икән, үлеп тә яратам мин Мәдинә апаны. Дөньяда аннан да зур белемле, аннан да акыллырак кеше юктыр шикелле. Башкалар шикелле гади генә кеше түгелдер ул. Шулай булмаса, ул тикле дә түзем була алмас иде. Бер үк бүлмәдә утыручы дүрт классның барысын берьюлы укыта бит ул. Утыз тугыз баланы, икенче төрле итеп әйткәндә, бер сәгать эчендә дүрт класска дүрт төрле дәрес аңлата... Инде килеп, шофер буласы кеше ич мин. Ә укымыйча ничек шофер булмак кирәк? Менә ни өчен уку башланыр көнне ике күземне дүрт итеп көтеп алдым.

Ләкин беренче сентябрь көнне башкалар белән бергә укырга барырга туры килмәде: әни мине укытырга теләмәде.

– Укып мулла булмассың, балам, – диде ул. – Аннары бөтен кеше укый башласа, кызыгы да калмас аның. Калхузда эшләүчеләр дә кирәк бит. Бер трут эшләсәң дә файдасы булыр. Үземә генә бик кыен бит, улым. Түләүләребез дә күп бит әле. Әнә кичә үзең күрдең ләбаса: «Шушы айда ит түләвегезне бетермәсәгез, бозавыгызны алып чыгабыз», – диделәр ич.

– Бер сарыкны илттек бит инде, әни, – дидем мин, әле һаман түләү бетмәгәнгә гаҗәпләнеп.

– Бер сарык кына җитми шул, балам, кырык кило кирәк бит! Менә шуңа әйтәм мин сиңа, укыма, дип. Икәүләп эшләсәк, калхуз икмәк бирсә, шуны сатып түләрбез итне. Әтү, син дә эшләмәсәң, бозауны да алып китәрләр. Сугыш бит, улым, сугыш! Сау булсаң, сугыш беткәч, укырсың, балам...

Хәзер әнинең ни өчен мине укытасы килмәве аңлашылды. Ни хәл итәсең – үпкәләп тә булмый аңа. Соң шулай булмыйча! Актык бозаудан да колак кагарга ярамый бит инде. Тагын бер елдан сыер булырга тора бит ул!

Менә шуңа күрә, бик укыйсым килсә дә, әнигә каршы килмәдем. Рас ул «укыма» ди икән, димәк, белеп әйтә, бүтән чарасы калмаганга, ярдәм итәр кешесе булмаганга әйтә. Теге вакытта җиңги мине бары тик кирелеге, ялкаулыгы аркасында гына укытмаска исәпләгән иде бит. Ә әни нужадан, аптыраганнан мине эшләтмәкче. Шулай булгач, аңа ничек каршы киләсең ди? Аннары шоферлыкка укырга да яшем җитми бит әле минем.

Менә шуларны уйладым да, сугыш беткәч тә соңга калмам әле дип, укуга бармыйча, ат кууымны дәвам иттем. Хәзер эштә минем кадер тагын да арта төште. Чөнки Гәрәй дә, Габделгазиз дә укыйлар, ә аларның атларын дүрт классны инде өч-дүрт ел элек үк бетереп чыккан олырак кызлар куа. Миңа хәзер тәртәгә утырып йөрергә дә ярый, оят түгел, чөнки мин кечкенә ич әле... Тик акыл белән әни яклы булып, аныңча эшләп йөрсәм дә, иртә-кичләрен мәктәп яныннан үткән чакларда, күңел һаман шунда тарта бит, шайтан.

**Тилермә, Мәгъсүмә апа!**

Укымый йөрү бик кыен миңа. Мәдинә апа да минем өчен борчыла. Ике мәртәбә өйгә килеп, әни белән дә сөйләшеп карады инде. Хәтта соңгы килүендә:

– Яхшылап әйткәнне тыңламасаң, без закон нигезендә дә мәҗбүр итә алабыз! – дип өркетеп китте.

Ун көнләп вакыт үтте инде, мине мәҗбүр итүче юк әле. Ихтимал, әни әйткән сүз дөрестер: безнең ише тамагы ач, өсте ялангач кешеләрне закон да берни эшләтә алмый торгандыр. Эшләтсә, бик әйбәт булыр иде кана. Мин үзем дә укуга атлыгып торам да бит! Ләкин ни хәл итәсең? Хәбир бабай әйтмешли, солдат бит мин хәзер... Уку дип, мең бәла белән тернәкләндереп, исән-сау саклап алып калган бердәнбер бозавыбыздан коры калырга да ярамый лабаса!

Бозау дигәннән, без аны тәки саклап алып калдык бит, әй. Әнинең сүзе чыннан да дөрес булып чыкты; колхоз хезмәт көненә биргән икмәкнең ике потын сатып, шуның акчасына кәҗә алып дәүләткә тапшырдык та түләүдән котылдык. Ә бозау инде зур, тана хәтле булып килә. Бер дә үксез бозау димәссең. Түп-түгәрәк, йоп-йомры гәүдәле, нәкъ әнкәсе төсле аклы-каралы. Шундый акыллы тагын

үзе: көтү каршына барып торасы да юк – туп-туры өйгә кайта. Мине күреп алды исә, исәнләшкән сыман итеп, «мме-ө» дип сузып бер кычкырып җибәрә дә, көн буе кырда йөреп арыган булуына карамастан, яныма йөгерә үк башлый. Күрәсең, үксез үскәнгә, кече-кечкенәдән миңа ияләшкәнгә шулай итә торгандыр инде... Йә ул кайтышка мин әзерләп куйган чәчәкле, хуш исле яшел печән исен чамалаптыр... Яки колак артларын, муеннарын кашытасы, койрык очларына, корсак асларына ябышкан кырмавыклардан арынасы, шуларны чүпләтәсе килептер... Ничек кенә булмасын, мине сагынып, минем янга тизрәк кайтып җитәргә ашыга бит ул. Мин аның шулай булуын сизәм дә, күземә яшьләр килә...

Аннары көз җитте. Көннәр салкынайды, яңгырлар ява башлады. Ләкин яңгыр чиләкләп ормаган көннәрдә ашлык сугуны туктатмыйлар. Андый чакта алдан ындырга ташып, кибәнгә өеп куйган игенне сугалар. Башкаларга ярый, алар балаган эчендә эшлиләр, ә менә безгә – ат куучыларга кыен. Яңгыр сибәләп кенә торса да, көннәр буе ачык һавада йөргәч, барыбер өс-башны манма су итә.

Ярый әле минем шинель әйбәт. Әйтергә онытып торганмын: узган кыш окоп казырга барган җиреннән, ярты бөтен ипигә алыштырып, әни алып кайткан иде аны. Бик игелекле булды ул шинель. Алып кайтканда миңа озын булгач, кистермәкче идем, әни риза булмады, итәген, җиң очларын бөкләп тегеп кенә куйды. Ә менә хәзер, мин үсә барган саен, әни аның итәген дә, җиңен дә түбәнрәк төшереп, озынайтып тегә тора. Шулай итеп, мин һаман үземә «таман» гына кием киеп үсәм.

...Шинель әйбәт булгач, көнозын яңгыр астында йөргәндә дә артык туңдырмый. Тик нигәдер тешләрне генә бер-берсенә тидереп булмый. Тидерә башладыңмы, хәзер шакылдарга тотыналар. Соңыннан аның да хәйләсен таптым – авызны ачып йөри башладым. Кызлар «туңдык» дип елаша башлаганда да, мин еламыйм. Хәбир бабай:

– Әнә, Равилне карагыз, сездән кечкенә булса да сукранмый! Түзегез, балакайлар, заманасы шундый бит, сугыш вакыты ич, – дип, тегеләрне юатканда, мин аның үземне башкаларга үрнәк итеп куюына куанып торам һәм, тешләремне шакылдатмаска тырышып:

– Әйе шул, Хәбир бабай, эшлик әле бераз, яме, – дигән булам. Ә үзем секунд саен, машина ватылуны теләп, тизрәк җылы урынга кайтып егылу турында уйлыйм инде югыйсә...

Белмим, мондый хәл күпме дәвам иткән булыр иде, беркөнне, һич тә көтмәгәндә, әнине дә, мине дә колхоз идарәсенә чакырттылар. Авыл советы председателе Мөсфирә апа килгән икән, ул дәштергән булып чыкты. Аның янында, култык таякларын тотып, бер рус агае һәм Мәдинә апа утыра иде.

Миңа шунысы гаҗәп тоелды: Мөсфирә апа бу юлы нигәдер бик нык үзгәреп киткән. Теге озын, кап-кара толымнарын кистергән, җете кызыл булып, балкып тора торган түгәрәк бите агарып, озынчаланып калган, карашы кырысланган иде аның.

– Нихәл, энем Равил? – диде Мөсфирә апа, әни белән салкынрак кына исәнләшкәннән соң.

– Әйбәт әле, – дидем мин.

Ә үзем, әллә укымаган өчен әнине дә, мине дә алып китеп утыртмакчылар микән, дип куркып куйдым.

– Әйт әле, Равил, укыйсың киләме синең?

Ни дияргә инде моңа?

– Килүен килә дә бит...

– Ә нигә мәктәпкә йөрмисең, әллә әниең җибәрмиме?

– Мин укырга йөрсәм, трут эшләүче калмый бит, – дидем мин, әнине якларга тырышып, – трут булмагач, колхоз икмәк бирми. Ә икмәк булмаса, ит түләвен түләп булмый да, бозауны алып чыгалар. Менә шуңа йөрмим мин мәктәпкә.

Мөсфирә апа ачуланмады, көлеп тә җибәрмәде микән әле. Аннары янында утырган теге култык таяклы кеше белән (соңыннан белдем, роно мөдире булган ул) русча нидер сөйләшеп алды да, әнигә карап:

– Менә нәрсә, Мәгъсүмә апа, иртәгәдән башлап малаеңны мәктәпкә җибәр син, яме! – диде.

– Әллә сугышлар беткәнче укымый торса да ярар микән, Мөсфирә, – диде әни, гадәтенчә куркып-оялыбрак кына, – үземә генә бик кыенга туры килә, түлисе түләүләрем дә күп ич әле.

Әмма Мөсфирә апа үз сүзендә кала бирде:

– Кыен икәнен беләм, апа, – диде ул, – бик беләм. Шулай да малаеңны укытырга кирәк булыр. Соңыннан, менә шушы Равилең укып кеше булгач, үзең үк миңа рәхмәт әйтерсең. Сугыш беткәнне көтәргә ярамый. Безнекеләр хәзер немецны кысрыклый башладылар инде башлавын, әмма сугышның тиз генә бетәр чамасы күренми әле. Кем белә, бәлки, тагын өч-дүрт елга сузылыр ул. Өч-дүрт ел малаеңны укытмый торырсыңмыни?.. Юк, ярамый алай, тилермә, Мәгъсүмә апа! Мөмкин кадәр үзебез дә булышырбыз... Ирең фронтта үлгән булса, ронодан да ярдәм сорап булыр иде дә бит... солдат балаларына ярдәм фонды бар аларның. Әмма... Ярый, авыл советыннан ничек тә ярдәм оештырырбыз. Анысы өчен борчылма, Мәгъсүмә апа, укыт малаеңны! Сугыш гомергә бармас, ә менә малаеңа уку гомер буена кирәк булыр. Аннары закон дигән нәрсәне дә онытма, Мәгъсүмә апа. Яхшылык белән тыңламаган кешеләрне закон тәртибендә мәҗбүр дә итәргә була.

Мөсфирә апаның үгет-нәсихәте күпме тәэсир иткәнен әйтә алмыйм, әмма «закон» сүзенең тәэсире бик зур булды әнигә.

– Ярый инде алайса, – диде ул, кинәт каушап-куркып китеп, – укыр алай булгач, нишлисең бит.

**Куып та җитәрбез, узып та...**

Гаҗәп хәл: мәктәпкә йөрергә мөмкинлек булмаганда күңел гел шунда тартып, атлыгып тора иде, ә хәзер, инде әнидән рөхсәт булып, укырга мөмкинлек тугач, мин мәктәпкә теләр-теләмәс кенә килдем. Ихтимал, иптәшләрем белән бергә укый башламаганга, алардан ике айга якын соңга калганга шулай булгандыр инде бу.

Сигез туларга биш минут калганда, Мәдинә апа да мәктәпкә килеп керде. Исәнләшеп, исемлек буенча барлык дүрт класс укучыларын барлап чыкты да дәресләрне башлап җибәрде.

Исемлектә минем фамилиям юк иде. Мәдинә апа әллә мине бөтенләй күрмәде, әллә күреп тә, моңарчы укырга йөрмәвемә үпкәләгәнлектән, юри күрмәгәнгә салышты микән – ләм-мим дип тә дәшмәде. Менә шул хәлгә бик нык борчылып утырдым мин. Соң шулай булмыйча! Йә берәр җылы сүз әйтсен иде ул, йә, ачуы килгән булса, орышсын иде. Барыбер җиңелрәк булыр иде. Ә болай... әйтерсең мин кеше дә түгел, әйтерсең ниндидер бер бөҗәк кенә аның каршында. Китапларың бармы, Равил, ручкаң, дәфтәрләрең бармы, дип сорамаса да, һич югында, килдеңме, дисә дә күңелең булыр иде. Юк бит, юк!..

Төрле фикерләр үтте ул дәрестә башымнан. Әллә бу Мәдинә апа хәзер мине яратмый башлады микән, шуңа сүз әйтергә теләми микән дип тә уйладым; инде иптәшләремнән ике айга якын соңга калдым ич, укый алырмынмы, аларны куып җитә алырмынмы дип тә борчылдым. Уйлый торгач, шундый нәтиҗәгә килдем: әгәр Мәдинә апа калган өч сәгатьтә дә бер сүз дә әйтмәсә, мәктәпкә әйләнеп тә карамыйм...

Менә дәресләр дә бетте. Ә Мәдинә апаның миңа сүз катып караганы юк әле.

Иптәшләрем, сумкаларын җыештырып, өйләренә тарала башладылар. Болай булгач, мәктәпкә йөрмим, дип, мин дә ишеккә таба юнәлдем.

– Син калып тор әле, Нәҗметдинов! – диде Мәдинә апа.

Әһә, бөтенләй үк күрмәгән түгел икән! Күргән икән ул мине. Тик нигә шушы вакытка тикле эндәшмәде икән соң? Нишләтмәкче була икән? Ачуланырга исәплиме, әллә үземә генә дәрес өйрәтмәкчеме. Озак тотмаса ярар иде, карын ачты бит минем. Бәрәңге күпкә барамыни ул?

Мәдинә апа китапларын, дәфтәрләрен җыештыра торган арада, мин әнә шулай уйладым.

Әйберләрен җыештырып бетергәч, Мәдинә апа мин утырган иң арттагы парта янына килде дә:

– Ашыйсың килдеме, Равил? – дип сорады.

Каян сизде икән ул минем карын ачканны? Әллә кешенең нәрсә уйлаганын да белеп тора микән бу укытучылар? Минем иртәгә мәктәпкә килмәскә булуымны да сизде микән әллә?

– Юк, Мәдинә апа, – дидем мин юри, аны саташтырырга тырышып, – ашыйсым килми минем.

– Шулаймы? Алайса, бик яхшы. – Мәдинә апа минем янга, парта арасына кереп утырды. – Әйдә әле, Равил, без синең белән бераз сөйләшеп алыйк әле...

Ул миңа иптәшләремне куып җитәргә кирәклекне, ләкин бу эш шактый кыен булачагын аңлатты.

– Менә шуңа күрә, – диде аннары, – сине мин төштән соң үзеңне генә укытырмын, һәр көн, мәктәптән кайткач, безгә килерсең, ярыймы?

Юк, төштән соң да укырга риза түгел мин. Моңа әни дә риза булмас, өйдә дә эш бетәсе түгел! Әни әйтмешли, ишегалды себерсәм яки ипигә бәрәңге кырсам да файда бит. Аннары, кар яугач, чана шуасы да бар ич әле. Җәй көне дә, гел эшкә йөреп, бер көн дә уйнап булмады.

– Кирәкми, төштән соң укымыйм, – дидем мин Мәдинә апага, – әни дә орышыр. Әле болай да көчкә-көчкә генә ризалык бирде. Аннары барыбер башкаларны куып җитә алмам мин.

– Әниең каршы килмәс, мин аның белән сөйләшермен, – диде ул. – Ә куып җитү турында борчылма. Менә күрерсең, куып та җитәрбез, узып та китәрбез әле без аларны.

Әнә шул «без» дип якын итеп әйтүе әллә нишләтеп җибәрде мине. Күңелем рәхәтләнеп, ышанычым артып киткән төсле булды һәм төштән соң да укырга ризалык бирдем. Шулай да башта әнинең ризалыгын алырга кирәк икәнлекне әйттем...

Чыннан да, барысы да Мәдинә апа әйткәнчә булды бит, әй. Шул сөйләшүдән соң һәр көн төштән соң бер-ике сәгать Мәдинә апа янына йөри башладым. Бу бер дә кыен булмады, хәтта күңелдә ниндидер горурлык хисе дә уянды әле. Чөнки Мәдинә апа мине ярата. Мин юкта үтелгән темаларның барысын да иренмичә, кат-кат аңлата. – Һей, юләр! Мәдинә апа янында утыру үзе бер бәхет. Аның ягымлы тавышын тыңлап, киеменнән килгән хушбуй исен иснәп утыруы дөнья рәхәте бит ул!

Белмим, бу Мәдинә апа кебек әйбәт бүтән кеше бармы икән бу дөньяда? Мөгаен, юктыр. Соң, үзегез уйлап карагыз: туганым түгел бит ул минем, бөтенләй чит-ят кеше. Мин үзем аңа берничек тә ярдәм итә алмыйм лабаса! Һәм ничек кенә теләсәм дә, тиз генә ярдәм итә алачак кеше дә түгел. Дөрес,

исән-сау үссәм, дөньяның аргы читеннән табып булса да, изгелек итәчәкмен мин аңа. Әмма аңарчы бик озак бит әле. Һәм бу уйларымны ул белми дә әле. Ә шулай да ярата мине. Яратмаса, ничек итеп, бер тиенсезгә, һәр кичне икешәр-өчәр сәгать мине укытып-өйрәтеп йөрсен ди? Әллә вакытын кая куярга белмәгәннән алай итәдер дисезме? Юк, билгеле. Мине яратканга күрә тырыша ул... Яки менә монысы: дөресен генә әйткәндә, ул елны киез итек киеп йөрү турында хыялланырга да курка идем мин, чөнки сарыкларыбыз инде күптән беткән иде безнең. Әмма кырык өченче ел башында Мәдинә апа мине итекле итте. Кышкы каникулга әтиләре янына кайткан җиреннән, белмим, ничек юнәткәндер, бик яхшылап олтан салынган бер пар киез итек алып килде ул миңа. Алгарак китеп булса да әйтим, мин ул итекләрне, ел саен олтанын яңарта-яңарта, кырык җиденче елга тикле киеп йөрдем.

Юк, гади генә кеше түгелдер ул Мәдинә апа, изге җандыр ул. Югыйсә барысын да ничек алдан белеп торсын ди? Ул миңа теге вакытта «куып та җитәрбез, узып та китәрбез әле» дип әйткән иде бит, әйеме? Узып китү мәсьәләсендә өзеп кенә әйтә алмыйм, әмма кышкы каникулга чыкканда иптәшләремне тулысынча куып җиттем мин...

Мөсфирә апа да сүзендә торды: миңа авыл советы хисабына бер бүрек һәм уку әсбаплары алып бирдертте.

**Әйткән идем бит «исән» дип!**

Бала булсам да, күңелем дөрес сизенгән бит, әй! Искәндәр абыйның хәбәрсез югалуы турында хәбәр килгәч, мин аңа тамчы да ышанмаган идем. Югалырга тиеш түгел ул, исән булырга тиеш, берәр җирдә адашып кына вакытында кайтмый калгандыр да иптәшләре, юкка чыкты, ахры, бу, дип уйлап, безгә теге кара кәгазьне җибәргәннәрдер дигән идем. Тәки минем сүз хак булып чыкты.

Адашып йөргәндерме, әллә немецлар кулына эләгеп, аннан качып кайткандырмы – анысы әлегә миңа билгесез. Ләкин шунысы ачык – Искәндәр абый исән-сау! Фашистларны тукмап йөри. Хатында үзе шулай дип язган. Әйе, үзе! Җиңги әйтә, аның кулы бу, тәгаен, аның кулы язган бу хатны, ди. Сөенеченнән нишләргә белми, бичара. Әле март башы гына булуга карамастан, абыйның хатын тотып, кая басканын да белмичә, күлмәкчән килеп керде безгә. Әни окоптан кайткан көнне кереп чыкканнан бирле өебезгә аяк та басканы юк иде. Урамда очрашканда әни белән дә, минем белән дә туктап сөйләшкәне юк, күрмәмешкә салышып үтә иде безне. Ә бүген әйтерсең алыштырып куйганнар җиңгине. Куанычына чыдый алмыйча:

– Менә, Равил наным, абыең исән икән бит, бәлки, озакламый кайтып та китә алмаммы әле, дигән!.. Кара инде, Мәгъсүмә апа, исән икән бит! Кем уйлаган аны болай булырын! – дип туктаусыз сөйләнеп утырды.

Шул ук вакытта нигәдер борчыла да иде бугай ул. Мин моны шуннан чыгып әйтәм, чөнки җиңги, бердән, чамасыз нык сырпалана, икенчедән, әлеге шул «кем уйлаган болай булырын» дигән сүзне шактый еш кабатлый иде. Аннары әнине дә, мине дә үзләренә итле аш ашарга барырга үтереп кыстарга тотынды бу. Ә башка вакытта, безнең хәлнең мөшкеллеген бик әйбәт белеп торса да, тешен дә агартмый иде ул хакта.

Менә шулай кинәт кенә үзгәреп, әйбәтләнеп, туган җанлыланып китүенә шактый ачуым килсә дә, ашын ашап кайтырга каршы түгел идем мин. Әмма әни якын да китермәде:

– Юк инде, килендәш, – диде ул, – рәхмәт! Алай бик туган итәсең килгәч, алданрак, хәлебез авыр чакларда дәшкәләргә иде аны. «Эзегез дә, эшегез дә булмасын минем йортымда!» дип, син әйткән идең түгелме соң әле кайчан гына?

Әйткән идем бит, нигәдер борчыла бугай, дип. Әнинең шушы сүзләреннән соң җиңги юхаланып еларга ук тотынды:

– Мәгъсүмә апа! Килендәшем! Җаным-бәгърем, дип әйтәм. Искәндәр кайта-нитә калса, зинһар, мине харап итмә инде син! Белсә, үтерә ул мине. Бер минут та тотмый, холкы шундый аның. Зинһар, дип әйтәм, ул кунакка кайтып киткәнче генә аны-моны шауламый тор, яме. Аннары ул бөтенләй кайтканчы берәр җае чыгар иде әле.

– Әй Нәсиха, Нәсиха! – диде әни, җиңгине кызганган да һәм аңа хәтере калган да сыманрак тавыш белән. – Әйттем бит мин сиңа, төкер шул чулакка, дип, якын китермә шуны, бер син генә түгел тол хатын, бөтен авыл, бөтен ил хатыннары тол хәзер, алар түзә бит, син дә түз, дип. Дөнья эшен белеп булмый, тереләр үлә, үлеләр терелә торган заман, дип әйтмәдемме мин сиңа?.. Курыкма, миннән чыкмас анысы. Ачу саклап йөри белмим мин алай. Кайтса, атна-ун көнгә кайтыр, Искәндәрне әйтәм. Болай да йөрәге бозылып беткәндер инде сугышта. Тагын шунда, үлем каршына китәсе кешегә ул турыда сүз катарга Аллам сакласын. Әмма бер мин генә белә торган эш түгел бит бу. Дусы бар, дошманы бар бит аның...

Исемен атап әйтмәсәләр дә, сүзнең Самат абыйның җиңги янына килеп йөрүе хакында баруын чамалап алган идем инде мин. Бер яктан, кыен хәлдә калган җиңгине кызганам, икенче яктан, җиңги

тарафыннан алданачак абыем өчен борчыла идем. Шунлыктан абыйның хаты китергән шатлык тоныкланыбрак калган кебек булды.

– Белмим инде, килендәш, аптыраган инде үзем дә, нишләргә дә аптыраган, – дип сөйләнгәләп, пышык-пышык елап байтак утыргач, шыпырт йомышым бар иде сиңа, дип, җиңги әнине өйалдына алып чыгып китте. Мыдыр-мыдыр сөйләшеп, алар анда байтак гомер торып керделәр. Аннары җиңги тагын мине үзләренә чакырырга кереште. Ул, бик борчылып:

– Итле аш та ашарсың, минем янда кунып та кайтырсың. Ату үзем генә кунарга куркам бүген, әллә ничек шунда, үз-үземне берәр нәрсә эшләтермен төсле, – дигәч, әни дә хәзер аның сүзен куәтләп торгач, мин риза булдым.

**Барысы да шул чулак Самат аркасында...**

Ә икенче көнне, әнигә йорт-җиренә күз-колак булып торырга кушып, үзем өч-дүрт кенә көнгә кунакка барып кайтам, дип, җиңги Баткаклыга – туган авылына китте. Анда аның әти-әнисе яши иде.

Сүз уңаенда җиңгинең безнең авылга ничек тап булуын әйтеп үтим инде. Әнинең сөйләвенә караганда, егет чакта, районга барышлый Баткаклы авылын үткәндә, юл читендә кулын күтәреп торучы бик матур бер кызны күргән Искәндәр абый. Машинасын туктаткан да:

– Әйдә утыр, чибәрем! Бер үбәр булсаң, дөньяның аргы ягына да илтеп куям мин сине! – дигән.

– Алай ук еракка илтмәсәң дә ярый, абыкаем, әмма районга тикле утыртып барсаң, мең-мең рәхмәтләр әйтер идем үзеңә, – дигән кыз. Шулай дигән дә, ялт итеп, кабинага Искәндәр абый янына менеп тә кунаклаган.

Сөйләшеп, танышып киткән болар. Кызның шәһәргә китәргә икән исәбе, шуңа паспорт юлларга барышы икән районга.

– Ничектер шулай туры килгән, – дип сөйләде миңа әни, – кайтканда тагын очраткан Искәндәр абыең теге кызны. Тагын машинасына утырткан да, юлың уңдымы соң, дип сораган.

– Юк шул, абый җаныем, – дигән кыз, – уңмады әле, тагын бер атнадан килергә куштылар. Бигрәк бәхетсез икәнмен инде...

Шуннан абыең юатырга керешкән тегене. Аннары, сүз арасында җаен туры китереп, шаяра-көлә:

– Әйдә, чибәрем, мин сине үзебезгә генә алып кайтыйм, – дигән. Күрәсең, чәчләре чәчкә үк бәйләнеп туганнардыр инде – кыз башта икеләнебрәк торса да, соңыннан риза булган. Менә шулай итеп кавыштылар синең Нәсиха җиңгәң белән Искәндәр абыең...

Алай ансат кына кавышып китүләре бераз сәеррәк инде сәеррәген, әмма, күрәсең, дөньяда андый хәлләр дә була торгандыр... Өч-дүрт көнгә генә дип туган авылына киткән җиңгәбез бер атнадан соң да кайтмады. Башта без моңа әллә ни шаккатмадык, чөнки җиңгинең хәзер терлек-торышы юк – сыерын саткан, сарыкларын күптән суеп ашаган иде инде ул. Шулай булгач, аның өендә эш күп түгел: бәрәңгесе өшемәсен өчен, көненә бер тапкыр миченә ягасы да өч тавыгын, бер әтәчен ашатасы гына.

Ләкин авыл халкы җиңгинең болай озаклап ятуына шактый тынычсызлана башлаган иде инде. Беркөнне кич безгә кереп, мәрхүм Миңлеәхмәтнең әнкәсе әнигә менә болай диде: «Тикмә түгелдер бу, Мәгъсүмә, килендәшеңнең кайтмавын әйтәм. Бардыр моның берәр хикмәте. Соңгы көннәрдә юанаеп, калынаеп та киткән төсле ие. Искәндәр кайтканчы дип, ябыгып йөрми микән ул анда. Баткаклыда шундый эшләр белән чуала торган бер карчык бар, диләр ие. Югыйсә, җаны бар кеше болай онытылып ятамы соң? Бардыр берәр тамаша, бардыр...»

Әмма барысыннан да битәррәк Самат абый борчыла иде булса кирәк:

– Кайтмадымы әле? – дип, көненә өчәр тапкыр килеп сорый ул бездән.

Җиңги завхоз бит, шуңа кирәктер ул Самат абыйга, дип уйлаган идем мин. Ләкин эш анда гына булмаган, ахры.

– Юк, улым, – диде миңа әни, – завхоз булган өчен генә кирәк түгел аңа җиңгәң. Ачкычларын аның үзенә калдырып китте бит Нәсиха. Бүтән сәбәп аркасында кайгырта ул аны.

Ләкин, ни ялынып сорасам да, нинди сәбәп икәнен әйтмәде әни.

– Күп белгән бала тиз картая, – дип кенә җавап бирде.

Ул арада тагын бер атна вакыт үтте, ә минем җиңгәм һаман юк иде әле. Эшләр болайга киткәч, әни дә ныклап торып пошаманга төште. Җиңгинең әни окопта чакта эшләгән усаллыклары исемнән чыкмаса да, мин дә аны юксына башладым. Көн үткән саен, авыл халкы арасында төрле имеш-мимешләр дә арта башлады. Янәсе, минем җиңги Баткаклыга кунак булу өчен түгел, бәлки Искәндәре кайтканчы үзен тәртипкә китермәкче булып киткән. Имеш, моңа тикле ансат кына котыла килде дә бит, капкан саен калҗа булмый шул...

Төрлечә сөйлиләр җиңги турында, тик берсе дә мин аңларлык итеп әйтми. Миңа бер генә нәрсә ачык: җиңгигә нидер булган. Югыйсә болай онытылып ятмас иде. Ни генә димә, эш кешесе ич ул. Колхозның бөтен байлыгы аның өстендә бит. Әни әйтмешли, ул чулак Саматка ышаныч юк: җиңги

озаграк ята калса, колхоз икмәген төрле якка таратып бетерер дә аннары җиңги өстенә аударып калдырыр. Әнә бит, һәр көн кызмача йөри ул. Шул колхоз җилкәсеннән булмыйча, каян алып эчсен ди. Биш баласы бар өстенә хатыны да эшләми. Ә балалары һәрвакыт урамга ипи тотып чыга. Күктән төшмидер бит ул икмәк...

Без әнә шул рәвешле уйлап, борчылып йөри торгач, ниһаять, мәсьәлә ачыкланды: киткәненә нәкъ унтугыз көн дигәндә, безгә кода бабай (җиңгинең атасы) килеп керде. Мин аны күп мәртәбәләр күргәнем бар, шуңа бик яхшы беләидем. Һәрвакыт шат күңелле, шадра булса да якты, мөлаем йөзле, таза гына бер кеше иде ул. Сүзгә дә бик җор, картаеп баруына карамастан, әле буй-сыны да бик төз, күркәм иде. Әмма бу юлы башта танымый тордым мин аны. Ничектер ябыгып, кечерәеп калган, кыяфәте дә мескенәйгән иде аның.

Күрәсең, хәвеф барын шундук сизенеп алгандыр:

– Берәр хәл булмагандыр ич? – дип сорады әни, кода бабай безгә килеп керүгә.

– Булды-ы! – Шушы сүзне әйтүгә, кода бабайның күзләреннән мөлдерәп яшь чыкты. – Булды, наным Мәгъсүмә, мантый алмады килендәшең, кичә төштән соң дөнья куйды. Син беләсеңдер бит аның нинди эш белән йөргәнен. Киткәндә әйткәндер бит ул сиңа?

– Әйткән иде әйтүен...

– Менә шул инде, наным Мәгъсүмә, шуннан үлде инде. Врач әйтә, нигә башта ук больнискә аппармадыгыз, ди. Без аны коткарып калган булырыек, ди. Мин дә әйтеп караган ием кана да бит, үзе риза булмады Нәсиха, курыкты. Теге сихерче Хөппениса карчыкны эләктертәсе килмәде. Менә хәзер үзе дә әрәм булды, Хөппениса пәрине дә кулга алдылар бүген. Әй бала, бала-а!.. Искәндәр кияү кайтам дип торганда гына бит, җитмәсә!..

Шунда сүзен туктатып, шактый вакыт тыныч кына оеп утырды кода бабай. Аннары җиңгине җирләү өчен кирәк булачак кайбер әйберләрне алып китәргә килүен әйтте дә:

– Үзебезнең Баткаклыда гына күмәргә булдык инде, наным Мәгъсүмә, монда хәзер беркеме дә юк бит аның, – диде. – Соңгы тапкыр хушлашып, күреп калыйм дисәң, әйдә, миңа утырып барырсың.

Атларны карарга үз урынына башка кеше куеп торуын үтенеп, әни тиз генә Самат абый янына барып кайтты да кода бабай белән Баткаклыга китте. Мин дә бармакчы идем дә, әни риза булмады:

– Юк, юк, балам, суык туңдырып йөрисе түгел, аннары өйне дә бикләп китә алмыйм ич инде мин, – диде. – Әнә, кич белән Фәйрүзә апаң «керермен» диде, аның белән кунарсыз...

Бер кичкә – кер мичкә, диләр, анысы өчен аптырамый идем мин. Ә менә җиңгине күрә алмый калуыма үкенеп бетә алмадым. Яхшымы-яманмы, Искәндәр абыем хатыны, миңа җиңги тиешле кеше иде ләбаса ул. Дөнья булгач, төрле вакыты булгандыр, шулай да кызганыч иде җиңги. Кем белә бит аны мондый хәл буласын? Һаман шул чулак Самат аркасында килеп чыккан бәла инде бу. Үзе дә капты кабуын соңыннан. Ләкин соңрак капты шул.

**Он итеп тартсаң...**

Җиңги урынына завхоз итеп башка кешене куярга кирәк иде хәзер. Завхозны, гадәттә, еллык отчет вакытында, колхозчыларның гомуми җыелышында сайлыйлар. Әмма шушындый көтелмәгән хәл килеп чыккач, Самат абый, идарә членнары белән киңәшеп, завхозны гомуми җыелыш җыеп тормыйча гына билгеләргә булган һәм бу эшкә бердәнбер яраклы кеше итеп Фәйрүзә апаны күрсәткән. Фәйрүзә апа каршы килмәгән, тик әйткән:

– Башта колхозның бөтен икмәгенә һәм башка мал-мөлкәтенә ревизия ясарга кирәк булыр. Шунсыз мин бу эшкә тотынмыйм, кеше өчен җавап бирер хәлем юк, – дигән.

Самат абый андый мәшәкатьләр чыгарып тормыйча гына эшли башларга ни кыстап та, Фәйрүзә апа риза булмагач, колхоз малына ревизия ясарга булганнар. Комиссия председателе итеп (бу юлы да шул ук Самат абый тәкъдиме белән) Хәбир бабайны билгеләгәннәр иде, чөнки ел башында сайлап куелган ревкомиссия председателе нindидер йомыш белән Казанга киткән чак иде ул. Кем белә, бәлки, Самат абый берәр төрле уй белән аны юри җибәргән булгандыр, һәрхәлдә, халык шулайрак сөйләде ул вакытта...

Белеме бик чамалы – исем-фамилиясен язарга гына җитәрлек булгандыр, күрәсең, Мәдинә ападан рөхсәт сорап, Хәбир бабай мине ревизия көннәрендә үзенә ярдәмче итеп алды.

Ревизия дүрт көн буена сузылды. Ул көннәрдә мин Хәбир бабай әйткән саннарны, әйбер исемнәрен язып тордым. Аннары идарәгә кайтып, кенәгәләр буенча нәрсәнең күпме булырга тиешлеген карап, чагыштырып чыктылар. Нәтиҗәдә колхоз амбарында унбиш центнер чәчүлек бодай, фәлән хәтле ит, фәлән хәтле май һәм фәлән хәтле балның ким чыгуы мәгълүм булды. Әйе, ул чулак Саматка ышаныч юк, дип, әни дөрес әйткән шул. Соң, аннан башка кем кагылсын ди инде ул әйберләргә? Җиңги амбар ачкычларының барысын да аңарга калдырып киткән иде ләбаса!

Билгеле, җиңги үзе дә сөттән ак, судан пакь булмагандыр. Әмма хәзер ул юк ич, җавапка тартып булмый бит аны. «Ну әлегә инде, болай булгач, Самат абыйга!» дип уйлаган идем мин. Чынында алай булып чыкмады. Районнан килеп тикшереп-тикшереп карасалар да, Самат абыйны гаепли алмадылар, чөнки ул бар гаепне мәрхүмә җиңги өстенә аударган дип сөйләделәр.

Эшләр болайга киткәч, җитмәгән әйберләрне чигереп ташлау өчен, колхозчыларның гомуми җыелышын җыйдылар. Хәбир бабай җыйдыртты ул җыелышны.

Ревизия эшенә катнашмаса да, белмим, ни өчендер ревизия нәтиҗәләрен Самат абый сөйләргә тотынды. Башта, колхоз милкенә салкын каравы өчен, инде гүр иясе булган җиңгине озак итеп орышты. Аннары ким чыккан нәрсәләрне санап күрсәтте дә менә болай дип нәтиҗә ясады ул:

– Күрәсез, җәмәгать, җитмәүчелек зур. Моның өчен, әгәр исән булса, тотып атарга кирәк иде Нәсиха Хәйретдинованы. Әйе, бер минут та тотмыйча атарлар иде аны. Шушындый кыен чакта, сугыш вакытында, колхоз малын туздыручыларга закон бик каты хәзер. Әйе... Әмма дә ләкин Хәйретдинова безнең арада юк, бәхете – үлеп котылды. Шулай булгач, иптәшләр, нинди чара кала инде? Бердәнбер чара шул: җитмәгән продуктыларны, гаепле кешесе инде вафат булганлыктан, вафат кешене хөкем итеп тә, аңардан түләтеп тә булмаганга күрә, списәйт итәргә. Башка юл юк, иптәшләр! Фәйрүзә Әхмәтҗанова иптәшне дә гомуми җыелыш карары белән беркетеп китик инде, иптәшләр. Сез аның зафхуз булып эшләвенә каршы түгелдер бит? – Самат абый, елмаеп, ваемсыз кыяфәт белән җыелыштагыларга карап торды. Сүз әйтергә җыенучы юк иде булса кирәк, барысы да тып-тын утыралар иде. – Даваегыз, алайса, – диде аннары председатель, – фурмасын китерү өчен, кул күтәреп, хәер-фатиха бирик Фәйрүзә сеңелкәшкә.

Җыелыш дәррәү кул күтәрде.

– Менә шулай, шулай! – диде Самат абый, иркен сулап. – Ә хәзер таралышсагыз да була инде, байтак утырдык бугай.

Ишек буендагылар урыннарыннан кубып чыга башлаганда, кинәт мич артыннан Хәбир бабай тавышы ишетелде:

– Юк әле, җәмәгать, минемчә, эш бетмәде әле монда. Җыелышны ябарга ашыкма әле син, Самат туган.

Халык тагын тып-тын калды. Самат абый исә ничектер сискәнеп, куркып китте шикелле. Ләкин ул үзен бик тиз кулга алды. Гәүдәгә кечкенә булса да, калын тавыш белән:

– Эһе, исәнме, кодагый, өч көннән соң? – диде. – Җыелыш барганда нәрсә карадың соң син, Хәбир абый, әйтер сүзең булгач? Җыелыш тәмам, дип әйттем бит инде мин, әле генә уянуыңмыни?

– Кызма әле син, Самат энекәш, – диде Хәбир бабай, бүреген йомарлап тоткан килеш халык уртасынарак үтеп, – кызма алай, син сөйләгәндә, без тыңладык бит. Бәлки, син дә әз генә безне тыңлап карарсың, ә?

– Әйдә, әйдә, Хәбир абый!

– Тыңлыйк, иптәшләр, Хәбир абый буш сүз сөйләмәс.

– Кәнишне, тыңларга кирәк!

Халык әнә шул рәвешле шаулаша башлагач, Самат абый Хәбир бабайга сүз бирмичә булдыра алмады.

– Менә болай, җәмәгать, – диде Хәбир бабай ипләп кенә. – Сез теләсә нишләгез, әмма мин үзем Саматның моннан соң да прсидәтел булып эшләвенә риза түгел. Менә без бүген бик күп тыңладык аны, матур сөйләде ул. Шушындый авыр сугыш заманында, икмәкнең граммы да кадерле чакта, шактый гына продуктыларны чигереп тә ташладык. Ярый, Самат үзе ашамаган да булсын ул ризыкларны. Ә бит ул хуҗа кеше, белергә тиеш иде икмәкнең кая киткәнен. Төптәнрәк уйлап караганда, бөтен гаеп Саматта. Нәсиха киткәндә амбар ачкычлары анда калды лабаса...

Башлап китүче булмаганга гына авызларына су кабып утырганнар икән. Хәбир бабайның әлеге сүзләреннән соң халык умарта күче кебек гөжли башлады.

– Дөрес, Хәбир абзый, бөтен гаеп анда! – дип кычкырды берсе.

– Колхоз җилкәсеннән булмыйча, каян алып эчсен ди ул көн дә. Соңгы айда бер аек көне дә булмады ич аның! – дип тавыш бирде икенчесе.

– Ничу монда күп сөйләп торырга, җитәрлек имде инде колхозны, булды, җитте, байтак түздек, алырга да атарга урыныннан! – дип куәтләде өченчесе.

Бик нык кычкырыштылар ул көнне. Тик нәтиҗәсе генә булмады. Самат абый, тыңлап-тыңлап торганнан соң:

– Молчать! – дип, бар көченә кычкырды да, сәламәт кулы белән өстәлгә шап иттереп сугып, барысына да чик куйды. Ә икенче көнне районга барып милиция алып килде дә Хәбир бабайны төрмәгә озаттырды.

– Менә, бер телегезгә хуҗа була алмасагыз, сезгә дә шул булыр! – дип, башкаларга да янап куйган дип сөйләделәр.

Ул көннәрдә мин Искәндәр абыйның тизрәк кайтуын көтә идем. Ул кайтып төшсә, Хәбир бабайга ярдәм итәр, аны коткарыр шикелле иде. Аннары Самат абый үзе дә Искәндәр абый каршында болай этәчләнә алмас иде... Тик ул һаман кайтып җитә алмый иде шул әле.

Хәбир бабайны чынлап ук утырттылар, ахрысы, дип, бөтен авыл халкы борчыла башлаган иде инде. Ләкин атна-ун көннән соң әйләнеп кайтты ул. Аның белән бер милиционер һәм райком секретаре да (башына мамык шәл бөркәнгән бер апа иде ул) килгән иде.

Шул ук көнне яңадан гомуми җыелыш җыйдылар. Тагын Самат абый сөйләргә тотынды. Ул үзенең бернинди гаебе дә булмавын, тырышып эшләвен һәм колхозны алга җибәрергә бар көчен салуын, ләкин Хәбир бабай кебекләрнең аңа аяк чалып, борчып торуларын кайта-кайта сөйләп бирде. Аның сүзләренә караганда, бөтен бәла Хәбир бабайда һәм Хәбир бабай инде күптән тотып атылырга тиеш кеше иде.

Аннары Хәбир бабайга сүз бирделәр. Ул Самат абыйның, колхозны алга җибәрүдән бигрәк, үз корсагын кайгыртучы кеше икәнлеген, көн саен салмыш булып йөрүен әйтте. Әмма райком секретаре:

– Эчкәнен үз күзегез белән күргәнегез бармы соң, иптәш Садыйков? – дип сорагач, тотлыгып калды. Бары бераздан гына:

– Юк, гөнаһсы кирәкми, шешә янында эчеп утырганын күргәнем юк. Әмма кызмача йөрмәгән вакыты сирәк аның, иптәш нәчәлник. Моны бүтәннәр дә раслар дип уйлыйм, – диде.

«Әйе», «шулай», «эчә ул» дип, халык шулай бераз гөрләшеп алса да, сүз алып сөйләүче булмады.

– Димәк, берегезнең дә Самат Мөбиновның эчкәнен күргәне юк? – диде тулы түгәрәк битле райком секретаре, идарә йорты эсселәнеп киткәнлектән, мамык шәлен башыннан аркасына шудыра төшеп. – Шулай булгач, нигә узган җыелышта аңа каршы гауга куптардыгыз соң сез, иптәшләр? Ярый торган эшме инде шушы, йә?

Җыелыш беркавым тып-тын торды.

– Яравын-ярамавын без, надан халык, бик үк белеп бетермибез инде, иптәш Лотфуллина, – диде аннары Хәбир бабай. – Әмма, минем уйлавымча, теге унбиш ситныр икмәк Мөбинов Самат катнашыннан башка гына юкка чыкмаган бит ул. Шушындый кыен заманда, сугыш барганда, шултикле икмәкнең юкка чыгуы бик зур нәрсә ул, сеңлем, дип әйтим инде, нәчәлник булсаң да. Он итеп тартсаң, бер пулк солдатка бер үбит ашатырга җитәрлек икмәк пешереп була лабаса ул бодайдан! Җитмәсә, күз карасыдай кадерле нәрсә – чәчүлек бодай бит ул! Менә шуңа күрә алыштырырга кирәк Саматны, дип әйткән ием теге көнне. Бодайдан башка прадуктылары да байтак югалган бит. Нәсиха бер үзе генә ике ай эчендә шултикле ашамас, минемчә. Отчет собраниесе алдыннан гына барысы да үлчәнеп, исәпкә алынган иде бит ул маллар.

– Ә Самат Мөбиновның амбардан үз өенә берәр әйбер алып кайтканын күрүче булдымы соң? Йә, кайсыгыз әйтә ала?

Райком секретаре үткен кара күзләре белән җыелыштагыларны тикшереп чыкты. Кул күтәрүче юк иде.

– Димәк, берегез дә күрмәде? – диде ул, көтеп-көтеп тә сүз әйтергә теләүче булмагач.

Болай да кечкенә гәүдәсен җыера төшеп, өстәл артына посып, бер сүз дә әйтмичә утырган Самат абый, ниһаять, телгә килде:

– Мәсьәлә ачыкланды бугай инде, иптәш Лотфуллина, – диде ул, райком секретарена мөрәҗәгать итеп. – Хәзер эшкә күчәргә кирәк: Садыйков Хәбирнең нинди дизарганизатыр икәнен күргәнсездер, аны нишләтәбез? Башта ук әйтеп куям: аны шул килеш колхозда калдырсагыз, мин прсидәтеллектән кәтигәрически баш тартам, чөнки ул миңа киләчәктә дә аяк чалачак, авторитетыма халык алдында тап төшерәчәк.

– Әйе, иптәш Мөбинов, сез дөрес әйтәсез, бу эшне болай гына калдырып булмый, – диде райком секретаре.

Җыелыш ни белән бетәр иде икән, һәрхәлдә, Хәбир бабайга бик үк әйбәт булмас иде, әмма шулчак ферма каравылчысы Шәйхи бабай торып басты.

– Мин әллә ни матур итеп сөйли алмам инде, сеңлем, – диде ул, райком секретарена карап, – шулай да тыңлап кара әле. Син әйтәсең, бу эшне болай гына калдырып булмас, дисең, Садыйков Хәбиргә чара күрергә кирәк, дисең. Ни өчен? Прсидәтелгә яла яккан өчен, дисең инде син. Әмма дә ләкин алай түгел бит ул, сеңлем, дөрес әйтә бит Садыйков Хәбир. Булды бит инде Саматның гөнаһлары. Хатын-кыз белән дә чуалмады түгел. Турысын гына әйткәндә, завхузыбыз Нәсиха Хәйретдинованың аянычлы үлеме дә шушы Саматка барып тоташа ич инде, ничу аны яшереп торырга. Сәрхуш булып та бик еш йөри Самат. Аннан килеп, балалары урамга икмәк тә тотып чыккалый, монысын барыбыз да күреп торабыз. Шулай булгач, каян килә ди аңа икмәк тә, каян килә ди эчәргә акча? Знамы колхуз амбарыннан!.. Менә мин моңарчы эчтән тынып утырдым, ул турыда сүз кузгатасым килмәде. Әйтсәм, Мөбиновка авырлык килер, дип уйладым. Инде эш болайга киткәч, Садыйков Хәбирне бер дә юкка гаепләргә җыена башлагач, әйтәм, ни булса – шул, эш дөреслектә булсын, нахак белән эш кылуны сөймим мин. Менә болай булды бит, Самат энекәш, син инде туры әйткәнгә ачуланма, яме: Нәсиха

китеп атна-ун көн торгач, төннәләтеп ат җигеп, амбардан бер йөк әйбер салып киттең бит, әйеме? Мин, нишләвең бу, дип сорагач: «Син бернәрсә дә күрмәдең, яме, Шәйхи абый, күп күрсәң, күзең сукыраер», – дип әйттең бит, әһәме? Аннары шул бер йөк икмәкнең бер капчыгын минем карчыкка кертеп калдыра киткәнсең. Әле ярый кагылмаган иек, әнә чоланда тора ул бер капчык бодай, барып карарга мөмкин. Шулай булгач, ничу гаебеңне кеше өстенә аударырга! Син миңа ачуланма, Самат туган, әгәр үзең Хәбиргә болай каты бәрелмәсәң, әйтәсе түгел ием бу сүзләрне, синең дә биш балаң бар ич, алар хакына әйтмәс ием. Әмма менә хәзер түзә алмадым... Гаепле икәнмен, мине дә алып китеп япсагыз да бер сүзем юк. Күп гомерем калмаган минем. Тик эш дөреслек белән барсын, нахак өскә чыкмасын. Менә шул...

Мәсьәләне бик ныклап берничә көн рәттән тикшергәннән соң, Хәбир бабайны акладылар. Шәйхи бабайга да берни булмады. Самат абыйны, алып китеп, унбиш елга утырттылар, ә завхоз булып эшли башлаган Фәйрүзә апаны председатель итеп сайлап, аның урынына башка кешене куйдылар.

**Тәки сүзендә торган бит!**

Март та үтте, апрель дә бетте, әмма Искәндәр абый нигәдер һаман кайтып җитә алмый әле. Хаты-хәбәре дә юк хәтта. Әллә теге хатны җиңгигә берәрсе шаярып кына язган идеме икән, үлгән кешедән хат килүен күргәч, каушап калганлыктан, гомере беткәнлектән генә җиңгигә Искәндәр абый кулы белән язылган булып күренгәндеме икән соң ул хат?

Басулар кардан арынып та бетмәс борын ук, бу ел да халык тагын черек бәрәңгегә ябырылды. Мәктәптән кайткач, мин дә, көрәк һәм чиләк алып, кырга йөрим. Кулларым җир казыса да, күңелем һаман абыйны уйлый, аны көтә. Бил тиңентен пычракка батып, юлым уңган булса – бер чиләк, уңмаган булса, егерме-утыз черек бәрәңге күтәреп кайтып кергәндә, Искәндәр абый медальләрен ялтыратып әни белән чәй эчеп утыра булыр төсле тоела иде.

Ә ул һич тә истә-оста юк чакта, майның җидесенә каршы таң алдыннан кайтып төште.

– Их, каениш, каениш! – диде әни, абый килеп кергәч, нигәдер кинәт елап җибәреп. – Исән икәнсең ләбаса! Кара син, гомере бетмәгән кеше кайта икән бит!.. Тик... менә килендәш кенә тегеләйрәк булып китте бит әле, каениш. Тәкъдире шулай булгандыр инде, күрешергә насыйп булмагандыр инде сезгә...

– Ярар, җиңги, – диде абый, – барысын да ишеттем инде мин. Ферма йортында ут булгач, кайтышлый шунда кагылган идем, каравылчы Шәйхи абзый барын да сөйләде инде.

Шактый вакыт өй эче тып-тын торды. Әни дә, абый да, башларын аска иеп, телсез калганнар иде.

– Әйт әле, җиңги, – диде аннары абый, – Нәсиха кайчан алай чуала башлады ул Самат белән? Мин киткәч үкме, әллә кәгазь килгәннән арымы?

– Гөнаһысына керер хәлем юк, дөресен әйтим, каениш: синең югалуың турында хәбәр килгәнгә тикле үзен бик әйбәт тоткан ул, авыр туфрагы җиңел булсын. «Тоткан» дип шуңа әйтәм, ул чакларда мин окоп казуда идем. Халык сүзен әйтәм. Авыл халкы белми сөйләми инде ул андый нәрсәне.

– Син соң бер дә кисәтмәдеңмени аны окоптан кайткач, ярамый болай, дип әйтмәдеңмени, җиңги?

– Сөйләштем, каениш, бик күп мәртәбәләр сөйләшеп карадым. Тик ни хәл итим, тыңламады шул. Искәндәрем дә юкка чыккач, бу дөньяның ни кызыгы бар соң миңа, дип кенә җибәрә иде. Шулай дигәч, мин нишли алам инде?..

– Да, алай булгач, Нәсихага гына да үпкәләп булмый икән шул... Их, бу сугыш!.. Барысы да шуның галәмәтләре бит болар. Менә шушылай безнеке кебек язмышка дучар булган кешеләр аздыр дисеңме әллә!

– Һей, ник кенә сөйләп торасың инде, каениш! Әз буламы соң! Әллә кемнәрне әллә нишләтеп бетерде инде бу афәт... Кара, сугыш дигәннән, менә син шуннан кайткан кеше инде, әйт әле, каениш, дөресен генә, кайчан бетәр икән инде ул? Бигрәк озакка китте бит, җелекләрне суырды инде. Җиңәр чамабыз бармы безнең ул немесләрне, әллә юкмы? Аптыраганнан әйтәм инде монысын.

– Бар, җиңги, бар! – диде абый, бераз ачылып китеп. – Дөмектерәчәкбез фашистларны. Хәзер өстенлек бездә инде, хәзер алар безне түгел, без аларны куабыз. Кырык беренче елны гына җикеренгән иде алар, ул вакытлар үтте инде. Шулай да тәмам изеп ташлаганчы байтак гомер узар әле.

– Ала-ай! Тиз бетмәс әле, дисең, алайса... Нишлисең бит, күбенә түзгәнне, әзенә ничек тә түзәр инде халык. Без җиңәсе булгач, әйбәт икән анысы, бик әйбәт!.. Туктале, сине күрү куанычыннан сорарга да онытып торам икән, – диде әни, кинәт бик кирәкле әйберен тапкандай итеп, – син ничек-ничек исән калдың соң?

Разведчик булган икән абый. Бервакыт иптәшләре белән разведкага киткәннәр болар. «Тел» алырга. Аулары уңышлы чыккан, эләктергәннәр бер фашистны. Мең газаплар чигеп, аны батальон штабы урнашкан землянкага алып кайтканнар, әмма землянка янында беркем дә каршыламаган аларны. Ә анда сакчы булырга тиеш икән. Туктатучы булмагач, эчкә үткән абыйлар. Землянкада дөм-караңгы, ди. Кул фонарен яктыртып җибәрсәләр – йа Рабби! – немецлар ята, ди, землянкада. Сакчылары да

йоклаган булган икән. Әмма, фонарь яктысы төшүгә, бары да сикерешеп торганнар да коралларына ташланганнар.

– Билгеле инде, андый чакта күп уйлап тормыйсың, – диде абый, – тоттык та автоматларыбыздан чират бирдек, һәм, дүрт кеше идек, дүртебез дә чыгып сыпырдык. Арттан куып караганнар иде, күрәсең, гомеребез бетмәгән булгандыр, тота алмадылар. Үзебезнең якка чыгарга тырышып берничә көн йөрсәк тә, фронт аша үтеп булмады. Шуннан соң партизаннарга юлыктык һәм алар белән дошман тылында сугышып йөрдек. Ә штабта безне үлгән дип уйлаганнар һәм теге кәгазьне җибәргәннәр.

Искәндәр абыйны көтеп йөргән чакларда мин, күрү белән, аның кочагына барып асылынырмын дип уйлаган идем. Абый үзе дә мине кычкырып көлә-көлә күтәреп алыр, хәлемне сораштырыр төсле иде. Әмма менә очрашкач, бер дә алай мин көткәнчә булмады. Абыйның бик җитди, кайгылы йөзен күрүем булды – бер сүз дә әйтә алмас хәлгә килдем.

– Нихәл, энем? – дип, ул күрешергә кулын сузгач, кыюсыз гына кул бирдем дә шуннан бирле аның әни белән сөйләшүен тыңлап кына утырдым. Ләкин ул сөйләгәндә, аңлашылып җитмәгән бер мәсьәләне ачыклау өчен, үзем дә сизмәстән:

– Немецлар сезнең землянкага ничек килеп кергәннәр соң? – димичә булдыра алмадым.

– Без разведкага киткәч, – диде абый, – немецлар кинәт һөҗүм ясаганнар да безнекеләрне кысрыклап, чигенергә мәҗбүр иткәннәр. Штаб землянкасын үз кулларына алганнар. Без ул чакта разведкада ике көн йөргән идек.

– Алай булгач, авылга кайтканда ничек безнең якка үтә алдыгыз соң? –дип сорады аннары әни.

Бер яктан, солдатлар, икенче яктан, абый хезмәт иткән партизаннар отряды кысрыклый торгач, фашистларның бер дивизиясен тар-мар иткәннәр дә үзебезнекеләр белән кушылганнар икән. Шул сугыш вакытында, ничектер җаен туры китереп, абый немецларның бер бик зур командирын кулга алган. Менә шул батырлыгы өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме биреп, үзен ун көнгә кунакка кайтарганнар булып чыкты.

Күкрәгендәге Алтын Йолдызыннан тыш Искәндәр абый бик зур, бик шәп чемодан һәм заманында яшел булган, ә хәзер уңып-агарып калган юл капчыгы да алып кайткан иде. Тышы бик матур булгач, мин аның ул чемоданы эчендә әллә нинди затлы әйберләр бардыр дип уйлаган идем. Ләкин алай зурлап телгә алырлык әйберләр чыкмады аннан: ярты кирпеч кара икмәк, азрак шикәр, кер сабыны зурлыгында нindидер ак әйбер, сабын, бит яулыгы һәм кырыну приборы – бар булган нәрсәсе шул иде. Теге мин ак әйбер дигәне дуңгыз мае, абыйча әйтсәк, шпиг булган икән. Исеме сәеррәк яңгыраса да, тәме әйбәт булып чыкты ул нәрсәнең. Бик бәрәкәтле дә икән үзе: аз гына ашасаң, тамак шундук туя да көн буе пох итеп йөрисең.

Кирәк нәрсәләрен чемоданнан алып куйгач, юл капчыгын чиште абый. Карап торырга сәләмә генә күренгән шул капчыктан... нәрсә килеп чыкты дисез?

Хәтерегездә микән, сугышка киткәндә: «Исән кайтсам, сиңа гармун алып кайтырмын, энем», – дип әйтте Искәндәр абыем дигән идем. Тәки сүзендә торган бит: гармун гына да түгел, сандык хәтле аккордеон алып кайткан! Гел пыяладан гына ясалган төсле– ялт итеп тора. Сез тагын шунысын әйтегез: гади аккордеон гына да түгел, ә абый белән бергә хезмәт иткән Михаил исемле иптәшеннән калган истәлекле аккордеон икән.

– Михаил белән бертугандай дус идек без. Разведкага да бергә бардык, чолганышта да бергә калдык, партизан булып йөргәндә дә гел бергә идек. Тик менә монда кайтыр көннәрдә генә аерылышырга туры килде, – дип сөйләде абый аның турында. – Үзебезнең гаскәрләр белән кушылу өчен сугышкан вакытта һәлак булды. Әллә үләсен алдан ук сизгән инде, шул көннәрдә генә:

– Әйтүем шушы, Искәндәр, әгәр мин алай-болай була калсам, бу аккордеонымны үзеңә ал һәм минем төсем итеп сакла. Үзең уйнарга өйрәнмәсәң, малаең өйрәнер, – дигән иде. Ул шулай дигәч, мин дә, үлә-нитә калсам, сәгатемне алырсың, дидем. Әмма минем гомерем бетмәгән икән. Михаил, мәрхүм, юк инде. Кара аны, Равил, яхшылап уйнарга өйрән! Михаил абыең сайрата торган иде аны. Шундый итеп уйнар иде, хәтта тәмам эштән чыгып талчыккан вакытларыбызда да җырлап җибәрмичә түзә алмый идек...

Менә нинди аккордеон бит ул! Болай булгач, өйрәнәм инде, шундый итеп өйрәнәм, Михаил абыйның хәтере калырлык булмасын...

Искәндәр абыемнан сорыйсы сүзләрем бик күп иде минем. Немецлар белән безнекеләр ничек итеп сугышуын да, туплар, танклар, самолетлар хакында да, сугыш барган җирләрдә безнең ише халыкның кайда, ничек тереклек итүе, немец малайлары турында да сорашмакчы идем. Тик кайтып төшү белән үк борчыйсым килмәде, ял иткәч сөйләтермен дип уйладым.

Әмма мин уйлаганча булып чыкмады. Кайтып кергән төннең иртәгесен абый кода бабайларга барып кайтты да:

– Мин иртәгә китәм, җиңги, оның булса, юлга азрак ризык әзерләсәң, әйбәт булыр иде, – диде.

– Соң, син, ун көнгә кайттым, дигән идең ләбаса, каениш, – диде әни, аптырашта калып. – Ничек була инде бу? Әллә сине ашатырлык кына азык таба алмаслар дип шикләнәсеңме? Бер дә борчылма,

бүген председатель Фәйрүзә, идарәгә чакыртып, дүрт кило онга боерык язып бирде. Иртәгә үк алып кайтам, бер дә хафаланма. Кунак ич син. Кунакка кайткан кешегә колхоз һәрвакыт ярдәм итә безнең.

– Анысы әйбәт икән, җиңги, әмма мин монда тора алмыйм. Нәсиха искә төшә дә, йөрәкләрем өзелеп киткәндәй була, – диде абый, һаман үз сүзендә кала биреп. – Бар, оныңны хәзер үк алып кайт та ипи изеп куй. Барыбер тора алмыйм мин авылда. Иптәшләр янына фронтка китәм, анда болай ук кыен булмас кебек.

Абый шулай дигәч, әни артык кыстамады:

– Үзең белә торгансыңдыр инде алайса, – диде дә амбарга китте.

Ә кичен, сугыш башланганнан бирле мичебездә беренче мәртәбә пешкән төче коймакны ашап утырганда, әни белән Искәндәр абый арасында шушындый сөйләшү булып алды:

– Әйдә, болай сөйләшик, җиңги, – диде абый, кесәсеннән үз өйләрен бикләгән йозакның ачкычын чыгарып, – менә сиңа ачкыч, иртәгә үк минем өйгә күчегез. Күчегез дә рәхәтләнеп яшәгез. Югыйсә, – ул черек матчасын ике җирдән терәткән өй эченә күз йөртеп чыкты, – күрәсең, бу түшәмнәрнең җимерелеп төшүе дә бик ихтимал.

– Анысы шулай инде, каениш, – диде әни, уйга калып, – түшәмебез нык түгел инде түгелен, бүген җимереләме, иртәгә төшәме дип кенә торам. Шулай да сезнең өйгә күчү бик үк килешеп бетәрме икән соң?

– Сугыш авырлыгы да үзгәртә алмаган икән синең холыкны, җиңги, һаман шулай оялчан икәнсең әле. Берәү булса, инде күптән кереп утырыр иде ул өйгә, ә син әйтә торып та икеләнәсең. Нәрсәсе ошамасын ди аның? Үзең беләсең лабаса, мин иртәгә яңадан сугыш мәхшәренә китәм. Әллә исән калам, әллә юк мин анда. Исән калсам да, монда әллә кайтам, әллә юк әле. Әйдә, ташла ул сүзеңне, иртәгә үк күчегез, яме! Исән калсам, торыр урын гына табармын әле. Шулай бит, энем Равил?

– Әйе шул, абый. Син кайткач та сыярбыз әле. Өегез зур бит сезнең.

– Дөрес әйтәсең, энем! Менә шулай, җиңги, тотыгыз да иртәгә үк минем өйгә күчегез, аңладыгызмы? – диде абый, бу юлы каршы килергә урын калдырмаслык итеп.

– Аңладым, каениш, ярар, рәхмәт, инде алай булгач, исән йөреп сау кайтырга язсын үзеңә.

– Менә монысы икенче мәсьәлә! Күптән шулай диләр аны, җиңги! – диде абый ул турыда сөйләшүне беткәнгә санап.

Ә икенче көнне, абыйны озатканнан соң, без аның өенә күчтек.

*1966*

## **КҮПЕР ЧЫККАНДА**

Алдан ук әйтеп куям, туган: һәрьяктан да үрнәк булырлык дәрәҗәдә ал да гөл түгел минем тормыш. Хәзер Хезмәт герое булып макталып йөргәч тә, син гомер буена шулай әйбәт кенә яшәгән, акыллы гына эшләгән икән бу кеше дип уйлама. Син болай итмәкче буласың, ә дөнья дигәнең, баш бирмәс кырыкмыш тай шикелле, үзе кирәк дип тапкан якка борып ала да китә. Карышып, тезгенен тарткалый башласаң, бер читкә селтәп, авыз-борыныңны җимерергә дә күп сорамый икән кайчакта...

Хәер, барысын да тормышка, башка кешеләргә аударып калдыру да бик үк дөрес булмас. Турысын әйтергә кирәк, үземнең дә чатаклыкларым байтак булды, туган. Кызурак, үзсүзлерәк кеше мин. Әмма шулай да... Тукта, фәлсәфәгә кереп барам түгелме соң әле? Алдан ук үземне акларга җыенам түгелме?.. Юк, болай ярамас! Гаеп миндә күбрәк булганмы, башкалардамы – анысын соңыннан үзең чамаларсың. Фәлсәфәсен үзең чыгарырсың. Сез, яшьләр, андыйга оста хәзер. Аңлы-белемле халык. Ә безгә ныклап торып теләгәнчә укырга да, уйланырга да вакыт булмады. Заманасы андый түгел иде... Ярый, рас үтенгәнсең икән, сөйлим әле мин сиңа үземнең баштан кичкән кайбер хәлләрне. Тик башта ук килешеп куйыйк: бүлдермә син мине! Күңелеңнән кайбер мин сөйли торган хәлләр белән бик үк риза булып бетмәсәң дә, бүлдермә! Бүлдерсәләр, фикерем чуала.

Димәк, килештек шулай.

**1**

1946 елның гыйнварында, армия хезмәтеннән кайтып төшкән айда ук, мине үзебезнең «Чулпан» колхозына председатель итеп куйдылар. Сугышка кадәр ике ел чамасы хисапчы булып эшләвемне искә алмаганда, колхоз белән алай зур алыш-бирешле кеше түгел идем. Ә җитәкчелек мәсьәләсендә тәҗрибәм бөтенләй юк иде. Әнә шул турыда исләренә төшереп:

– Кыстамагыз, иптәшләр, ышанычыгызны аклый алмам. Холкым да бик җиңел. Миннән тәҗрибәлерәк, өлкәнрәк агайлар да бар бит, – дип карышып карасам да, авыл халкы күп сөйләшеп тормады.

– Кыза башласаң – суытырбыз, ялгышсаң – чабуыңнан тартырбыз. Белемең бар – ун класс бетергән, башың эшли – анысын хисапчы чагында күрдек! Сине куябыз – бетте китте! – дип, егерме бишенче яшемдә председатель арбасына җиктеләр дә куйдылар.

**2**

Ә ул арба җиңел түгел икән. Ай-һай, зур икән, мәшәкатьле икән аның йөге!

«Хуҗа» булып эшләргә тотынган көнне үк сизенә башладым мин моны. Колхозыбыз кечкенә булганлыктан (нибары кырык өч кенә хуҗалык), бездә бригадир-фәлән юк. Бар эшне председатель алып бара. Өй борынча йөреп, колхозчыларга көн саен эшкә әйтеп чыгу да аның вазифасына керә. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, беренче эш көнем үк бик җайсыз башланды. Халыкны ындырга, ашлык сугарга җыеп, төрлесен төрле эшкә урнаштырдым да, инде азрак тамак ялгап чыгыйм дип, өйгә кайтып, иртән мичкә тәгәрәтеп киткән бәрәңгеләрне алып ашарга гына утырган идем, борынын турсайтып, салам тарттыручы малай килеп җитте.

– Сине ындырга чакырдылар, Өлфәт абый. Сугу машинасының валын әйләндерә торган чарыгы ярылды! – ди.

– Ә ник алай иртүк ярылды соң ул, энем?

Күрәсең, көтелмәгән күңелсез хәбәрне ишеткәч аптырап калганмын инде, югыйсә мондый мәгънәсез сорауны бирмәс идем.

Йодрык кадәр генә булса да, телгә оста икән малай актыгы:

– Без сорап караган идек тә, әйтмәде шул ник ватылганын! Әйдә, Өлфәт абый, тизрәк киен дә баргач үзең сорарсың. Син председатель кеше бит, бәлки, сиңа әйтер! – диде, хәйләкәр елмаеп.

– Мин чарык коючы түгел ләбаса! Булса, амбарда була инде ул, энекәш. Запас частьлар председатель кесәсендә йөрми торгандыр бит, завхоз кулында булырга тиештер ич алар! Галим абыең шуны белми микәнни? – дидем мин, кискен итеп.

Ләкин салам тарттыручының моңа да җавабы әзер булып чыкты.

– Амбарда булса, сине борчып йөрер идекмени, Өлфәт абый? Амбарда булмаганга монда җибәрде дә инде мине Галим абый! – диде ул, түгәрәк күзләрен елтыратып.

Утызлап кеше эшсез утырганда, тамактан ризык үтәме соң? Салам тарттыручы малайга ияреп, тиз генә ындырга киттем. Халык ындыр табагының читенә ут ягып, шуның тирәсенә җыелышкан. Яшьрәкләр, күрәсең, җылынырга теләптер инде, түгәрәкләнеп тезелгәннәр дә, бияләйләрен атышып, «базар» уйныйлар. Ә барабанга көлтә биреп торучы Галим абый ватылган чарык янында чуала иде. Көн шактый салкын булса да, бүрек колакчыннарын күтәреп куйган, бияләйләре дә җирдә, кар өстендә

ята. Кыяфәте җитди, ачулы иде. Башка чакта гел үзе алдан сүз башлый торган Галим абый бу юлы миңа бөтенләй игътибар итмәде. Бары тик аның янына чүгәләп:

– Нишлибез инде, Галим абый? Запасыбыз юкмыни? – дигәч кенә, тирән итеп көрсенде дә:

– Бар иде ул заманында. Узган җәй районның «Сельхозснаб» складында бар иде. Алып куйыйк, кирәге чыгар, дип, Рәдифкә әйтеп тә караганыем. Тыңламады бит, аксак шайтан. Менә хәзер ике кулсыз калдык инде! – дип җавап бирде.

– Нишләргә, кая барырга киңәш итәсең, Галим абый?

– Районда юк ул, Өлфәт энекәш. Күрше колхозларга барып карасаң гына инде. Бәлки, берәрсендә булмасмы икән.

Тиз генә ат җигеп, «Алга» колхозына киттем. Аннары «Кызыл үрнәк»кә, аннан «Ватан»га. Әмма берсеннән дә таба алмадым. Озынга сузмыйча гына әйткәндә, бер айга якын эзләдек без ул каһәр төшкән нәрсәне. Карап торырга алай бер дә искитмәле әйбер дә түгел кана үзе: унике тешле, уртасы тишек, өч-дүрт килолы, гап-гади чуен кисәге генә. Андый чарыкларны үзебезнең механика мастерскоенда да көненә унбишне ясау берни тормый хәзер. Тик кирәкләре генә юк. Ә ул чакта кадерле иде. Чөнки шул булмаса, шартла – сугу машинасын эшләтә алмыйсың! Тәмам гаҗиз итте ул безне. Башка һичкайдан таба алмагач, завхозны чарык коя торган Ч. заводына җибәреп карадым. Атнага якын гомер үткәреп, ул да буш кул белән кайтты. Без продукциябезне аерым колхозларга өләшмибез, разнарядка буенча районнарга гына озатабыз, дип борып җибәргәннәр. Ә разнарядка буенча кайтуын көтә башласаң, колхоз игене яңа уңыш өлгергәнче дә сугылып бетәчәк түгел.

Уйладым-уйладым да, ни булса – ул, дип, өйне карап торырга бер карчыкны калдырып (ул чакта мин, дию пәрие кебек, берьялгызым яши идем, чөнки ахмакланып хатыным Сәкинәне аерып җибәрдем...), заводка үзем киттем.

Безнең ише авыл кешесенә завод ихатасына үтү дә сират күперен кичүдән ким түгел икән. Шулай да, алай иттем, болай иттем, тырыша торгач, тәки директорның үзенә барып җиттем бит, туган. Карап торырга күркәм генә ир уртасы кеше икән. Белмим, үзе сугышта булгандырмы, әллә заманга хас модага ияреп кенә алай иткәндерме – өстенә карасу зәңгәр диагональ китель кигән. Өстәлендә яшел фуражкасы ята. Каршылавын да хәйран ягымлы каршылады. Өстәл янында утырган җиреннән генә булса да, кул биреп күреште. Шунда мин, рәхимле бәндәгә охшаган бу, болай булса, шәт, борып чыгармас, дип уйлап алдым да, батыраеп китеп, гозеремне сөйләп бирдем.

Алданрак куанылган икән. Тел төбемне төшенеп алуга, кыяфәте бозылды директорның. Сирәк саргылт кашларына хәтле салынып төште. Күренеп тора, мине кабул итәргә ризалык бирүенә үкенә бу хәзер. Тик сиздермәскә тырыша, мөмкин кадәр сабыр, ягымлы булырга тели:

– Хәлеңне аңлыйм, иптәш председатель, – ди бу миңа, – бик яхшы аңлыйм! Әмма, кызганычка каршы, ярдәм итә алмыйм. Андый нәрсә рөхсәт ителми безгә. Колхозда гына андый алыш-бирешләргә юл куелырга мөмкин. Ә бу колхоз түгел, завод бу! Бездә һәр деталь исәптә, һәр детальнең кая, кайчан озатылырга тиешлеге алдан ук билгеләп куелган.

Кара син аны ничек сөйләнә бит, ә?! Колхоз түгел, имеш! Колхозның синең заводыңнан кай төше ким аның? Яхшылабрак уйлаган кешегә колхоз синең заводыңнан мөһимрәк тә әле. Синең чарыгың бар, ә колхоз икмәк үстерә. Бар, торып кара син икмәксез. Ашап кара чарыгыңны!

Мин шулай уйлап, бик нык ачуланып, әмма ачуымны сиздермәскә азапланып торган арада, директор өстәл тартмасыннан бер папка чыгарып, аның эчендәге кәгазьләр арасыннан берсен тартып алды да:

– Менә, ышанмасаң, үзең кара, иптәш председатель: план буенча запас частьлар сезнең районга май башларында гына озатылырга тиеш диелгән монда! – дип, миңа сузды.

Кәгазьдә, чыннан да, ул әйткәнчә язылган иде. Әмма миңа аннан ни файда? Майга кадәр көтәрлек чамабыз булса, өемдә кеше калдырып, йөз илле километр җиргә ат куып килер идеммени! Язгы чәчү башланганчы ничек тә сугып бетерергә кирәк ич безгә игенне! Югыйсә үреп, әрәм булып бетәчәк ләбаса ул!

– Аңлыйм, иптәш, барысын да бик яхшы аңлыйм, әмма булмагач булмый инде! – диде директор, һаман үзенекен сукалавын дәвам итеп.

– Юк инде, Виниамин Илларионович, алай ансат кына кайтарып җибәрмәгез инде сез мине! Йөз илле чакрымга ат куып, башта шушында завхоз килде. Ул бер атна йөреп буш кайтты. Инде мин, председатель кеше, үзем килдем. Юлда ике көнем үтте, монда өченче көнем узып бара. Кайтып җитәргә янә ике көн кирәк булачак. Үзем генә түгел, ат тикле ат куып йөрим ләбаса мин! Монда килмәгән булсам, бер атна эчендә ул ат күпме эш эшләгән булыр иде, беләсезме шуны? Дөрес, формаль яктан сез, әлбәттә, хаклы: мине буш кул белән кайтарып җибәрсәгез дә, бер сүз әйтүче булмаячак сезгә. Ләкин, зинһар, дип әйтәм, сез дә минем хәлемә керергә тырышыгыз. Берәр төрле җаен табыгыз, зинһар!

Директор минем сүзләрне колагына да элмәде бугай: алдында яткан газетаны уку белән мәшгуль иде ул.

– Карагыз әле, Виниамин Илларионович, – дидем мин, аның шулай илтифатсыз булуына хәйран калып. – Тыңлагыз әле, соңгы сүземне генә әйтәм дә китәм аннары.

Директор иренеп кенә башын күтәрде дә, барыбер буш кайтарып җибәрәм бит инде, нигә бу тикле үҗәтләнәсең, дигәнне аңлата торган итеп елмаеп куйды.

Минем йон тагын да ныграк кабарып китте. Бар усаллыгымны җыйдым да, соры-коңгырт күзләренә карап:

– Соңыннан үпкәләштән булмасын, Виниамин Илларионович, шуның өчен башта ук кисәтеп куям: әгәр бүген мине буш борып кайтарсагыз, Аллага ышанучы булмасам да, билләһи, дип әйтәм, бу хәлне болай гына калдырмаячакмын! – дидем. – Менә күрерсез, болай гына калдырачак түгел мин моны. Моннан кайту белән Мәскәүгә генералиссимусның үзе янына барачакмын! Исе китәр инде синең ише авыл мужигына дип уйламагыз. Бик яхшы белә ул мине. Менә бу орденнарны, Кремльгә чакыртып китереп, үз кулы белән тагып җибәрде ул миңа! – дип, шинелемнең изүен чишеп, күкрәгемдәге Дан орденнарын күрсәттем.

Дөресен әйтим, бу нотыгымның файдасы тияренә үзем дә бик үк ышанып җитмәгән идем. Тик килгән җирдә, ичмаса, бераз ачуымны бушатып, аның да күңеленә азрак шом салып китим дип кенә азаплануым иде. Кайчакта беренче карашка бөтенләй көлке тоелган гап-гади генә сүзләр дә кешегә искиткеч нык тәэсир итә икән, туган. «Үзе такты» дигәнемне ишетүгә, колаклары торды директорның. Сирәк, юка чәчләренә тикле кабарып китте, битенә кадәр кызарып чыкты.

– Ярар, ярар, иптәш, – диде ул, каушавын белгертмәскә тырышса да, яшерә алмыйча, – син алай бик каты чәпчемә! Безнең дә үз заданиебез, үз планыбыз бар лабаса. Һәр колхоз председателе шушылай синең кебек заводка килеп, низаглашып йөри башласа – кая китә ул аннары?

– Башкаларда минем эшем юк. Минем үз хәлем хәл. Әгәр чарыксыз җибәрсәгез, үпкәләштән булмасын! – дидем, директорның шөлләп калуын күргәч, батыраеп китеп.

– Ну, ярый алайса, – диде бу, һич тә чигенер чамам булмавын сизенеп. – Ярый, алай бик ерактан да килгән кеше булгач, кагыйдәне бозып булса да...

Шулай диде дә, минут эчендә завод складына шалтыратып, миңа бер чарык биреп җибәрергә кушты.

Ул көнне җир йөзендә миннән дә бәхетле кеше, ихтимал, булмагандыр. Берәү юлдан тапса да игътибар итми китә торган шул чуен кисәге миңа әйтеп бетергесез куаныч китерде. Ә орденнарны «үз кулы белән такты» дип, мин аңа аптыраганнан, бүтән чарам калмаганга гына әйткән идем. Тагамы соң инде! Минем ише Дан ордены алучыларның барысына да үзе тагып тора башласа, бүтән эшкә вакыты да калмас иде аның. Тагу түгел, дөньяда Хәкимов Өлфәт исемле бер татар малае барлыгын белми дә торгандыр әле ул... Шулай да ярдәме тиде!

**3**

Председатель итеп мине гыйнвар ахырында сайлаганнар иде. Теге хәерсез чарыкны юллап алып кайтканчы февраль үтеп китә язды. Ә сугасы иген дөнья әле. Аны ничек тә тизрәк сугып бетерергә кирәк. Машинага тагын берәр хәл булмаса, ихтимал, апрель урталарына бетереп тә булыр. Көннәр озаюга, җылынуга таба бара. Гыйнвар аенда ике көн эшләгәнне хәзер бер көндә башкарырга мөмкин. Мөмкин генә түгел, шулай эшлиләр дә. Халык бик тырыш бездә. Ул яктан шөкер әлегә. Ә менә атлар!.. Ул мескеннәргә карарга да кызганыч. Кабыргаларын ярты чакрымнан санарга мөмкин. Ичмаса, абзарларының да рәте юк. Сугыш елларында ачылып-тишелеп беткән. Түбә саламына кадәр кырык өченче елда колхоз сыерларына азыкка киткән. Узган җәйдә япкан булганнар булуын, әмма хатын-кыз да бала-чага гына япкан түбәнең рәте бик шәптән булып чыкмаган.

Хәзер дә солы саламы белән бодай саламыннан башка фураж бирелми атларга. Кама елгасындагы утрауда, безнең авылдан утыз километрда, колхозның илле җиде гектар болыны бар барын. Тик менә өч ел инде, көч җитмәгәнлектән, ул болындагы печән дә чабылмыйча калып килә икән. Аны бу ел ничек тә чабып-җыеп алырга кирәк инде...

Ә атлар арык. Шулай да игенне язгы чәчүгә тикле сугып бетербез дип уйлыйбыз. Анысына ничек тә түзәләр инде. Әмма шул ук атлар белән язын бөтен колхоз кырын сөреп, чәчеп чыгасы бар бит әле! Дүрт йөз туксан дүрт гектар җирнең өч йөз җитмеш гектарын сөреп чәчәсе бар. Ат башына унөч гектардан артык туры килә. Ә тракторга өметләнергә урын юк. МТСка барып караган идем:

– Сездән зуррак колхозларга да җиткерә алмыйбыз әле, быелга көтәргә туры килер, Хәкимов! – диделәр.

Әйтәм бит, бөтен өмет атларда хәзер. Сугышка кадәр язгы чәчүдә эшләргә тиешле атларны бер ай беркая да җикмичә шәпләп тәрбиялиләр, ял иттерәләр иде. Хәзер ял турында әйткән дә юк инде, хәтта рәтле ашау да эләкми аларга. Солысы да бар колхозның, арышы, бодае да бар. Икмәк планы да күптән түләнеп беткән безнең (план тулмаган, дип, теге директорга чарык бирсен өчен генә әйттем мин). Әйтәм бит, фуражлык кына рәтебез бар. Тик ашатырга ярамый. Чөнки районда планнарын тутырмаган

колхозлар бар. Зуррак колхозларның җире сугыш елларында тулысынча чәчелмәгән – көчләре җитмәгән. Ә план – җир исәбеннән. Кыскасы, планны бөтен район тутыруын күтәргә кирәк...

Ут йотып йөргән чакта, барабанга көлтә бирүче Галим абзый беркөнне төшке ял вакытында яныма килде дә:

– Һаман фуражсыз эшләтә торган булсак, тәмам барып чыгачак бит бу атлар! Ни уйлыйсың син, прсидәтел? – ди.

– Мин дә нәкъ синеңчә уйлыйм, Галим абзый. Болай барса, эшләр шәп булмаячак безнең, – дим. – Ләкин, нишлим соң, фураж ашатырга рөхсәт юк бит.

Галим абзый мине беркавым карап торды да иплəп кенә сүзгә керешле:

– Әй энем-энем!.. Менә безгә бер грамм да фураж бирмәскә кушылган. Ну, без крәстиян халкы бит, үзебез дә уйланырга тиешле. Без дә берәр әмәлен табарга тиештер бит бу хикмәтнең! Чак кына булса да үз башыбызны да эшләтеп карарга ярый торгандыр. Ярый гына түгел, иптәш Ленин безгә шулай кушкан да бит. Әйдә әзрәк үз башыбызны да уйлатып карыйк!

– Ничек итеп, Галим абзый?..

Ул, һич тә икеләнеп тормыйча, элеп алып китте:

– Ничек итеп дисеңме? Әйтик, менә болай: без һәр көнне көндезге уникедән бергә тикле төшке ялга туктыйбыз, шулай бит?

– Әйе.

– Алай булгач, менә шул: төшке ял вакытында атларны ындырда калдырып, аларга солы ашатсак ничек булыр икән?

– Без бит хәзер солы сукмыйбыз, бодай сугабыз ич, Галим абзый?

– Син анысы өчен бер дә шаккатма, Өлфәт энекәш, анысы бик ансат җайлана торган нәрсә аның, тик синең генә ризалыгың булсын. Син каршы килмәсәң, солыны мамин сугып алабыз без аны. Ярты сәгать эчендә бөтен калхуз атына бер атна ашарга җитәрлек солы сугып алырга була!

– Сугуын сугарга булыр да, әмма аның өчен безнең баштан сыйпамаслар бит, Галим абзый?

– Ә син башыңнан сыйпаганны көтәсеңме әллә, наный? Көтмә син аны. Шул ук чакта артык өркеп тә яшәмә.

Төптәнрәк уйлап караганда, атларыбызга фураж ашатырлык кына хакыбыз бар лабаса безнең. Башка калхузларның планы өчен ник без җык күрергә тиеш ди әле? Бер үк төрле мөмкинлекләр бирелгән ич аларга да. Шулай булгач, үзләре өчен үзләре кыймылдасыннар.

– «Берләр – меңнәр өчен, меңнәр – берләр өчен!» дигән сүз бар бит, Галим абзый! Аны да онытырга ярамый ич!

– Шуның белән рәттән үк «Һәркемнән – сәләтенчә, һәркемгә – хезмәтенчә» дигәне дә бар аның, наный. Тотасың икән, һәр икесен дә истә тотарга кирәк! Теләсәң ни эшлә, энем, ну мин иртәгәдән үк атларга солы суктырып ашата башлыйм! Гаепләсәләр – мине гаепләрләр.

Һәм ул, күрәсең, мәсьәләне хәл ителгән санап, минем яннан китеп тә барды.

**4**

Безнең шул сөйләшүдән соң шактый вакыт үтте. Инде игенне сугып бетерергә дә күп калмады. Көнозын эштә булсалар да, төшке ял вакытында солы ашата башлагач, атларга да хәйран гына тән кунып китте. Болай булса, язгы чәчүне ничек тә вакытында ерып чыгарбыз дип эчтән куанып йөри идем. Тик ул куанычымны болыт каплады. Анысы менә болай булды.

Бер дә бер көнне безгә авыл советы йомышчысы – ябык кына, хәлсез генә, шактый олы яшьтәге бер апа килде дә:

– Райкумнан чалтыраттылар. Хәкимов кичке сәгать биштән дә соңга калмыйча килеп җитсен, дип әйттеләр, – диде. Аннары, калын, авыр зәңгәр шәлен чишеп җибәреп, идарәнең ишеге буендагы озын эскәмиягә килеп утырды да сукранырга тотынды: – Әйдә, энем Өлфәт, атыңны тизрәк җик тә, әйләнечрәк булса да, безнең Көрнәле аркылы мине калдыра кит инде син. Бик арыдым, аяк атлар хәлем дә калмады. Монда килгәнче дә таң тишегеннән авыл буйлап кәнсәләргә кеше чакырып йөрдем. Кайсын заем, кайсын ит, кайсын сөт түләве буенча дәштерделәр.

Ат җигеп, юлга чыккач, йомышчы апа тагын зарлана башлады:

– Мин дежур буласы көнне генә көтеп торганнар диярсең: барысына да бүген кирәк, барысы да тизрәк, ди. Иртәгәгә калдырсалар – дөнья бетә диярсең, билләһи. Инде менә монда килергә туры килде. Ичмаса, өемдә кеше юк. Олы кызым урман кисүдә. Кечесе фермыда, төнсез кайтмый.

Мин ябык апаны азрак юатырга тырышып нәрсәдер әйткән булдым.

– Анысы да дөрес инде, Өлфәт энем, – диде ул, шундук минем белән килешеп. – Сезнең ише нәчәлникләргә дә алай бик ансат түгел инде, бер уйлаганда. Шулай да менә шушы Мәгышия апаң әйткәние диярсең, бер дә алай төнгә каршы ук чакырып торырлык тәҗеле эш түгелдер әле!

– Белмим шул, Мәгышия апа.

Икебез дә беркавым сөйләшмичә бардык.

– Карале, Өлфәт энем, – диде аннары Мәгышия апа, миңа таба борылып утырып. – Кайчан тәмам рәтләнер икән безнең эше крәстиян тормышы? Сугыш елларында, ярый, сүз әйтмәдек. Анысы бөтен ил белән килгән каза булды. Инде сугыш бетте ләбаса... Әйт әле, энем Өлфәт, типтереп яшәүләрне күрергә тиз насыйп булырмы икән?

– Булыр, Мәгышия апа, булыр! Сабырлык кирәк. Сугыш беткәнгә ел да тулмаган ич әле. Бер ел эчендә барысын да җайлап булмый инде ул. Син үз авылыбыз каланчасыннан карап кына хөкем йөртмә, Мәгышия апа. Фашистлар безнең илдәге ни тикле кешене йортсыз-җирсез калдырды. Ул кешеләрне тораклы иткәнче, җимерек авылларны, шәһәрләрне, завод-фабрикаларны торгызганчы байтак көч түгәргә туры килер әле.

– Колхозлар фәкыйрь булмасын иде дигәннән әйтүем инде. Юкса эшебез кирегә китмәгәе...

– Китмәс, Мәгышия апа. Яхшыруга таба барабыз. Менә күрерсең, танымаслык булып үзгәрер әле безнең авыллар. Хәтереңдәдер, сугыш алды елларында хезмәт көненә бирелгән икмәкне, халык вакытында амбарга барып алмагач, өй борынча ат белән өләшеп йөриләр иде. Куяр урын таба алмый интегә иде колхозчы. Тагын шулай булыр әле, менә күрерсең!

– Ни генә әйттеңие кана!..

Шул рәвешле сөйләшеп, Мәгышия апаны да, шул вакытта үземне дә юатып, өметләндереп бара торгач, Көрнәлегә килеп җиткәнебезне сизми дә калдым. Мәгышия апаны калдырып ары киткәч, кичкә каршы нигә болай ашыгыч рәвештә чакырдылар икән, дип борчыла, фараз кыла башладым. Бер караганда, алай әллә ни хәвефләнерлек урын да юк шикелле. Колхозның икмәк планы күптән тулган. Артыгын да шактый бирдек инде. Хәзер дә озатып торабыз. Чәчүлек орлыкларыбыз да кирәгенчә әзерләп куелган. Сабан-тырмаларыбыз да ремонтланып бетү алдында тора. Шулай булгач, нигә болай чакырттылар икән?..

Ләкин ашыктырырлык эшләр булган икән шул менә. Ничек кенә булган әле! Башка мәсьәләләрне инде хәл кылып, мине генә көтеп торганнар, ахрысы: килеп керүем булды – райкомның бюро утырышын дәвам итеп, мине тикшерергә керештеләр.

Мәсьәләне тулырак итеп аңлату өчен, башта минем урында эшләп киткән Рәдиф Хәйретдиновның райкомга язган хаты укылды. Ул үзенең, ферма мөдире буларак, көн-төн тырышып эшләвен, колхозны алга җибәрү өчен бар көчен салуын бәйнә-бәйнә аңлатып язган. Аннары, гәрчә аның урынына председатель итеп куйсалар да, Хәкимов Өлфәткә, ягъни миңа, бернинди дә ачуы юклыгын, бу хатны бары тик намуслы совет кешесе буларак кына язуын аңлаткан да: «*Эшли башлавына өч ай тулар-тулмас ук Хәкимов алдау юлына басты,* – дигән. – *Халык төшкә кайтып киткән арада, бодай сугуны туктаттырып, өч тапкыр берәр сәгать буена солы суктырды. Ул солыны, үлчәп керемгә алмыйча, ындырда яшереп саклый һәм һәр көн төшке ял вакытында атларга ашата. Районның «икмәк заданиесе тулмый торып, бер грамм фураж бирмәскә» дигән күрсәтмәне белгән килеш, шушындый җинаятькә барган кешене, минемчә, партиядә тоту турында сүз дә булырга тиеш түгел, иптәшләр! Суд хөкеменә тапшырылырга тиешле эш бу!*» – дип нәтиҗә ясаган.

Рәдифнең шушы хатын укыганнан соң, судка бирергә дип үк әйтмәсәләр дә, мине шулай ук бик нык гаепләп, тагын өч бюро члены чыгып сөйләде. Аннары миңа сүз бирделәр.

– Минем әйтер сүзем юк! – дидем мин.

Соң нәрсә сөйлим? Мәсьәлә болай да ачык бит. Рәдиф барысын да бәйнә-бәйнә тезеп биргән. Шулай ук гаепне Галим абзыйга аударырга да телем бармый. Чөнки мин солы сугуларын белдем. Тансам, ялганлау була. Ялганларлык булсам, партиягә кереп тә тормаган булыр идем мин. Ә партия сафына мин иң кыен чакта – кырык беренче елның декабрендә, йә илем, йә үлем мәсьәләсе хәл ителгән көннәрдә кергән кеше.

Үзем сөйләмәгәч, сорау бирә башладылар:

– Әйт алайса: иптәш Хәйретдинов язган фактлар дөресме?

– Икесе дөрес, өченчесе миңа мәгълүм түгел.

– Сез моның ярамавын белеп эшләдегезме?

– Мин моны бик кирәк булганга эшләдем!..

Үзең дә чамалыйсыңдыр, туган, ул чаклар өчен гаебем зур иде бит минем. Ни эшләтсәләр дә, каршы килә алмас идем. Ләкин мине райкомның беренче секретаре Гадел абый коткарып калды. Ул кызып-ачуланып түгел, җайлап, иплә кенә сөйләп китте. Үзенә кадәр сөйләгән кешеләрне дә алай зурлап хупламады, мине дә бөтенләй бетереп ташламады.

– Иптәш Хәкимовның гаебе зур, – диде аннары. – Күрсәтмә барын белә торып, андый нәрсәгә юл куярга тиеш түгел иде ул. Ләкин монда шуны да искә алырга кирәк: Хәкимов әле яшь, председатедь булып эшләвенә нибары өченче ае гына. Колхоз тормышын да тиешенчә белеп җиткермәгәндер. Армиядән кайту белән сайлап куйдылар аны. Шулаймы, иптәш Хәкимов?

– Әйе, Гадел Салихович! – дидем мин, аның шушылай минем хәлне аңлап сөйләвенә чиксез куанып.

– Менә шуларны искә алып фикер йөрткәндә, иптәшләр, – дип дәвам итте ул, – Хәкимовны бөтенләй үк этеп егарга кирәк түгелдер. Фронтта да начар сугышмаган иптәш Хәкимов. Ике Дан ордены алуга лаеклы булган кешеләр, районыбызда дип әйтмим, республикабызда да күп түгел әле алар...

Әллә ни таза булмаса да, мәһабәт, сылу гәүдәле, кара бөдрә чәчле, коңгырт-кара күзле, озынчарак каратут битле бу кешене моңарчы да ике-өч тапкыр күргәнем бар иде. Әмма моңарчы бер дә алай якыннан очрашып сөйләшергә туры килгәне юк иде. Шунлыктан, ни әйтер икән дип, башкалардан битәр аннан шикләнеп утыра идем. Ә ул, күрәсең, минем турыда әллә никадәр мәгълүматлы кеше булып чыкты!..

Бюро миңа каты шелтә бирү белән тәмамланды. Утырышны ябып, бюро членнарын таратканнан соң, Гадел абый мине үз кабинетына алып керде. Ихтимал, үз кайгыма артык тирән чумып утырганмындыр инде, райком секретареның сул кулы протез кул икәнлеген бөтенләй күрмәгән идем. Анысын кабинетына кереп, каршына утыргач кына абайлап алдым. Шунда ук «әһә, димәк, сугышта булган бу кеше. Димәк, моның белән ачыктан-ачык сөйләшергә дә мөмкин!» дип, эчтән куанып куйдым. Шул ук вакытта, тагын нишләтмәкче була икән бу мине, күрәсең, үземне генә орышырга ниятләнгәндер, дип, күңелемә шик тә төште. Әмма Гадел абый сүзне мин бөтенләй башыма да китермәгән яктан башлап китте.

– Кайсы фронтта булдыгыз сез, иптәш Хәкимов? – диде ул.

– Башта Ленинград фронтында, аннары Беренче Белоруссия фронтында булдым.

– Нинди төр гаскәрдә?

– Пехота.

– Кем булып?

– Башта рядовой, аннары сержант. Кырык беренче елның декабреннән башлап сугыш тәмамланганчы разведчик булып йөрдем.

– Ә Дан орденнарын ни өчен бирделәр?

– Берсен фашистларның тылына үтеп, корал складларын шартлаткан өчен, берсен дошман дивизиясенең штаб офицерын «тел» итеп алып кайткач.

Секретарь бер сүз дә дәшмичә, тыныч кына тыңлап утырды. Аннары папиросын кабызды да:

– Димәк, партизанлыкта йөрергә туры килмәде алайса? – диде.

– Юк, Гадел Салихович. Ә нигә алай дип сорыйсыз әле?

– Нигәме?.. – Әйтимме икән, юк микән дигәндәй, ул бераз уйланып торды. – Колхозда партизаннарча эш итә башлагансыз бит! Шуңа күрә әллә сугышта да партизан булдыгызмы дип уйлаган идем. Ә сез разведчик икәнсез.

Аның тел төбен аңлагач, ничектер уңайсызланыбрак калдым. Колакларым кызышып китте. Ни дип җавап бирергә инде моңа?

– Күрәсең, разведкадан калган гадәт буенча шулай эшләнгәндер инде, Гадел Салихович, – дидем мин. Аннары ачыктан-ачык сөйләшүгә күчтем: – Бүтән бернинди чара таба алмагач, шулай яшертен генә, разведчикларча гына эш итмәкче булган идек. Ләкин, бүген күрдем, тыныч тормышта разведка ясау сугыштагы разведкадан хәтәррәк икән. Теләсә ни әйтегез, Гадел Салихович, әмма атларны исән-сау саклап калу өчен эшләнгән эш иде бу. Егерме сигез баш ат белән язын өч йөз дә җитмеш гектар җирне чәчеп-сөреп чыгасы бар бит әле безнең!

– Синең сүзеңдә дә хаклык бар, иптәш Хәкимов. Мин сине бүген шуңа күрә яклап чыктым да. Разведка турында да дөрес сүз әйттең. Ләкин син бер нәрсәне яхшы аңларга тиеш: сугыш вакытында да разведчиклар үзләре теләгәнчә генә хәрәкәт итмиләр бит. Командирлар биргән боерык буенча, план белән йөри алар разведкага. Ә син...

Шактый гыйбрәтле сүзләр сөйләде ул миңа. Җыеп кына әйткәндә, ул сөйләгәннәрдән мин шуны аңладым: миңа, яшь председательгә, киләчәктә ашыгып эш итәргә ярамый. Алдын-артын уйлап кына эш кылырга кирәк. Чөнки бөтен кеше дә минем төсле уйламаска мөмкин. Мөмкин генә түгел, чыннан да шулай ул. Мең кешенең берсе, мисал итеп әйтсәк, миңа кадәр председатель булып эшләгән әлеге Рәдиф Хәйретдиновның кайбер мәсьәләләр хакында бөтенләй башкача фикер йөртүе гаҗәпмени?..

Гадел абыйны тыңлагач, дөньялар яктырып, офыкларым киңәеп киткәндәй булды. Югыйсә бюрода утырганда, бигрәк тә Рәдиф хатын укыган вакытта, күңелем тәмам суынган иде колхоздан. Барысына да кул селтәп, бөтенләй авылдан ук чыгып китәр дәрәҗәгә җитеп утырган идем. Чөнки шәхси тормышым җимерелгән иде бит минем. Шушы колхоз тормышы белән мавыгып, үземне-үзем шуның белән юатып кына яши идем. Ә менә Гадел абый белән сөйләшкәннән соң, ул ямьсез уйларым бөтенләй онытылды.

Инде чыгып китәм дип торганда гына, Гадел абый миңа тагын бер сорау бирде:

– Колхоз эше буенча бер-беребезне аңлаштык шикелле, ә үз хәлләрең ничек соң? Хатының белән малаеңны алып кайтмадыңмы әле? – диде ул.

Мин башта аптырап калдым. Ни өчен дисәң, Гадел абыйның мин председатель булып эшли башлаганнан бирле безнең авылга бер мәртәбә дә килгәне булмады. Шулай ук районга үзем баргач та, ул хакта сүз кузгатканы юк иде. Ә ул инде минем семьяның таркалуы хакында да белә икән.

– Сез каян беләсез ул турыда, Гадел Салихович? – дидем мин, кызыксынуымны яшерә алмыйча.

Секретарь елмаеп куйды да:

– Үз районыбыздагы колхоз председательләренең хәлен дә белмәсәм, нинди секретарь булыр идем мин? – диде. Аннары тагын җитдиләнде дә җайлап кына дәвам итте: – Кайдан икәне ул кадәр мөһим түгелдер, бәлки, иптәш Хәкимов. Ә менә синең хәлеңне белергә тиеш мин. Сизеп торам, хатыныңны да, улыңны да алып кайтмагансың икән әле. Йә, әйт әле миңа: киләчәктә ничек яшәргә уйлыйсың? Нидән килеп чыкты ул низаг? Уйлап-үлчәп эшләдеңме, әллә һаман шулай партизаннарча бер кизәнүдә генә эшләп ташладыңмы?

– Әйтүе авыр инде анысын, Гадел Салихович. Узган эшне искә төшереп тормыйк ла, – дидем мин, ул хакта бер дә сөйлисем килмичә.

– Ихтыярың, иптәш Хәкимов. Шулай да син тагын бер тапкыр уйла әле, яме! Ир кеше теләсә нинди мәсьәләдә дә егет булып кала белергә тиеш.

**5**

Кайтырга дип атны җигеп чыккач, район урамында яшь кенә бер кыз яныма килде дә:

– Зинһар, алып кайт әле, Өлфәт абый! Төнгә каршы үзем генә җәяү юлга чыгарга куркам, ә кунып каласым килми, иртәгә иртән дәрескә керәсем бар! – диде.

– Кая алып кайтырга соң сезне? Кем сез? – дидем мин, гаҗәпләнеп. Гаҗәпләнми мөмкин түгел, чөнки мин аның кайсы авылныкы булуын да, кем икәнлеген дә белмим. Хәтта моңарчы күргәнем дә юк шикелле иде.

– Мине бер күргән кешеләр онытмый дип йөри идем, ялгышканмын икән! – диде теге кыз, гаҗәеп ягымлы итеп елмаеп һәм йөзенә чак кына үпкәләү билгесе чыгарып. – Биш күреп тә игътибар итмәүчеләр бар икән ич миңа! Көрнәледә укытам мин, Өлфәт абый. Күргәнегез бар бит мине, игътибар итмәдегез микәнни?

– Гафу итегез, әйе шул, күргәнем бар икән шул! – дигән булдым мин, кайда һәм кайчан күргәнемне һич тә хәтерли алмыйча. – Исемегез ничек әле сезнең?

– Гөлүсә дип йөриләр мине, Өлфәт абый. Йә, алып кайтасызмы, утырыйммы чанагызга?

– Мин турыдан-туры «Чулпан»га кайтмакчы идем шул, Гөлүсә.

– Шулаймыни? Әллә мин Көрнәле аша кайтасызмы икән дип уйлаган идем, – диде ул, шундук күңелсезләнеп.

– Йомышым юк иде шул анда.

– Ярар инде, алай булгач.

Шулай диде дә ул читкә тайпылды, ә мин кайтыр якка кузгалдым. Аннары башыма шундый уй килде: «Тукта әле, Өлфәт, ни кыланасың син? Өч-дүрт километр әйләнечрәк була дип, кешене ташлап китәргә ярамый бит инде!» Атны шып туктаттым да артыма әйләнеп карадым. Кыз, нәүмизләнеп, әле һаман юлга карап тора иде.

– Әйдә, Гөлүсә, әйләнеч булса булыр, алып кайтыйм инде алайса!

Ул, тиз генә йөгереп килеп, тәмле хушбуй исләрен аңкытып, чанага менеп утырды. Мин райкомда булган хәлләрдән соң кәефем кырылганга, ә Гөлүсә башта үтенечен кире кагуыма уңайсызланган иде булса кирәк – байтак араны сүзсез генә үттек. Әмма болай бару да кыен иде, кызның күңелен күтәреп җибәрер өчен генә булса да нидер әйтергә кирәк иде аңа.

– Сез Көрнәленеке түгел бугай бит, Гөлүсә. Әйтегез әле, кай як суын эчеп үскән чибәр сез? – дидем мин, киеренке тынлыкны бозып.

– Чибәр булсам, берсүзсез утырткан булыр идегез әле, күрәсең, чибәрлегем чамалыдыр инде, – диде ул, серле елмаеп. – Шулай да комплиментыгыз өчен рәхмәт! Ә туган ягым – Минзәлә, Ык суын эчеп үстем.

Мин аңа текәлебрәк карадым. Чыннан да, бик чибәр иде ул, каһәр. Бигрәк тә иреннәре матур, коңгырт күзләре сөйкемле иде аның. Кай ягы беләндер минем Сәкинәгә дә охшап китә шикелле иде ул.

– Көрнәледә күптәннән эшлисезме инде?

– Дүртенче ел инде, Өлфәт абый. Быел укулар беткәч, үзебезнең якка кайтып китәр идем. Туйдырды...

– Эш туйдырдымы, әллә Көрнәледән туйдыгызмы?

– Эш түгел, эшемне яратам мин анысы. Көрнәледән туйдым. Халкы, бигрәк тә егетләре грубый.

– Ничек инде алай, сезгә тимиләрдер бит алар?

– Тиюен тимиләр, әмма тынгылык та бирмиләр. Клубка чыгар хәл юк, хәзер тагылырга гына торалар.

– Ә сез берсен дә ярата алмыйсызмыни?
– Юк шул, ярата алмыйм, берсе дә күңелемә ошамый. Ә сез Сәкинәне ярата идегезме, Өлфәт абый?
– Бик ярата идем, Гөлүсә! Сез аны беләә идегезмени? – дидем мин, гаҗәпсенеп.
– Бер авыл советында эшлә дә белмә, имеш. Хисапчы чагында бик еш килә иде ул Көрнәлегә. Якын дус ук булмасак та, яхшы таныш идек без аның белән, яшьтәшләр идек.
– Алай булгач, сез миңа абый дияргә тиеш түгел икән. Миннән ике генә яшькә кече иде бит ул.
– Беләм, Өлфәт абый. Ләкин мин сезгә башкача эндәшә алмыйм. Ничектер миннән күп олы шикелле тоеласыз.
– Ихтыярыгыз, алайса.
– Сер булмаса, әйтегез әле, – диде ул, беркавым икебез дә тын гына баргач, – Сәкинәне нигә аерып җибәрдегез сез?
– Булды инде, Гөлүсә...
– Сөйләргә теләмисез, димәк?
– Кызыклы хәл түгел ул.
– Ә минем беләсем килә, Өлфәт абый! Үзегез «ярата идем» дисез, үзегез аерып җибәргәнсез. Яраткан кешене аеру мөмкин микәнни соң?
– Мөмкин икән шул менә. Сез ничек итеп, тәвәккәлләп, төнгә каршы минем белән юлга чыгарга уйладыгыз әле, Гөлүсә? – дидем мин, сүзне икенче якка борырга ниятләп. – Ни әйтсәң дә, ир кеше бит мин, әле утызга да җитмәгән тол ир кеше!
Ул, ялт борылып, миңа сыенабрак утырды.
– Ә мин сездән курыкмыйм, Өлфәт абый. Куркыныч кешегә охшамагансыз сез. Беренче күрүдә үк әйбәт кеше икәнегезне сизендем.
– Яхшы сүзегез өчен рәхмәт!
Тагын беркавым сөйләшмичә баргач, Гөлүсә, кинәт калтыранып, эх, дип куйды да көтелмәгән бер кискенлек белән:
– Ләкин сез джентльмен түгелсез икән, Өлфәт абый! – диде.
– Аңламыйм, Гөлүсә, нәрсә әйтмәкче буласыз?
– Хи-хи-хи! – диде ул, кычкырып көлеп. – Унөч километрның унберен үттек инде, ә сез әле һаман миннән туңмыйсыңмы дип сорарга да догадаться итмисез. Толыбыгызны салып бирмәсәгез, һич югында, куеныгызга сыендырыр идегез, ичмаса! Катып үләм бит инде.
Ул, чыннан да, хаклы иде. Гаеп миндә.
– Гафу итегез, Гөлүсә, мин шундый гамьсез инде! – дип, толыбымны сала башладым.
Ләкин ул:
– Юк, юк, кирәкми, Өлфәт абый, менә болай шәбрәк булыр ул! – дип, мине туктатты да, песи баласыдай йомылып кына, толып эченә кереп утырды. Миңа да искиткеч рәхәт булып китте. Җылы иде каһәрнең тыны! Бер мәлгә тәмам башларны әйләндереп, күз алларымны караңгылатып җибәрде... Ләкин шунда Сәкинәм күз алдыма килеп басты һәм мин, айнып китеп, үземне тезгенләп алдым да, теге йомшак песи баласына бер дә исем китмәгән кыяфәт белән, күктә җемелдәшкән йолдызларга карап бара башладым.
– Минем бүген районга ни өчен килүемне ник сорамыйсыз, Өлфәт абый? – диде Гөлүсә, тагын да ныграк сыена төшеп.
– Йомышыгыз булгандыр инде.
Ул янә кычкырып көлеп җибәрде:
– Бернинди йомышым да юк иде минем, Өлфәт абый!
– Юк иде?
– Әйе, юк иде! – диде ул. Минем гаҗәпсенеп калуымны күргәч, ничектер серле, йомшак итеп пышылдауга күчте. – Бүген сез районга Көрнәле аша киттегез, шулай бит?
– Әйе.
– Менә мин киткәнегезне күреп калдым да җәяүләп юлыгыздан атладым. Әйләнеп кайтышлый очрарсыз дип, юри әкрен генә бардым. Ләкин сез озак юандыгыз, ә мин, бара торгач, район үзәгенә үк барып җиттем. Сез кайтырга чыкканда, мин яңа килеп җиткән генә идем әле.
– Йә тәкъсир! Үлмәсәң, әллә ниләр ишетерсең бу дөньяда! – дидем мин, аптырап һәм аның сүзләрен уенга борырга тырышып: – Нигә юкны сөйләп торырга инде, Гөлүсә?
– Ә мин чынлап әйтәм, Өлфәт абый. Просто тиле хисләремә буйсындым да артыгыздан киттем, һәм бер дә үкенмим. Мин уйлаганга караганда да интереснырак кеше булып чыктыгыз сез.
– Ташлагыз әле юк сүзне! – дидем мин, күңелемнән сәер бер рәхәтлек кичерсәм дә, юри кырыс булырга тырышып.
– Мин, гомумән, ялган сөйли белмим, Өлфәт абый! – диде ул, кинәт җитдиләнеп китеп. – Ә мондый мәсьәләдә алдашуны бөтенләй күралмыйм. Нәрсә уйлыйм, шуны әйтәм мин. Чынлап та, мин сезне болай ук интересный кеше дип уйламаган идем. Тиз кабынып китүчән, шашкын хисле кеше сыманрак

тоелган идегез. Ә сез әнә ничек нык ихтыярлы, сабыр кеше булып чыктыгыз, һәм шуның белән мине бөтенләй әсир иттегез бүген.

Бу сүзләрне ул чын күңеленнән, күзләремә туп-туры карап әйтте. Дулкынланудан бит алмалары комач шикелле кызарган, күзләре очкынланып ялтырый иде.

Миңа да бик уңайсыз һәм кыен булып китте. Ихтимал, аның күңелен юатыр өчен генә булса да, йомшак кына итеп мамык шәленнән чыгып торган бөтеркә чәчләреннән сыйпарга, мин сезгә ышанам, Гөлүсә, игътибарыгызга бик шатмын, дияргә кирәк булгандыр. Башта, чыннан да, шулай итмәкче дә булган идем. Ләкин шундук, нигә кыз баланың күңелен ымсындырырга, лутчы турысын әйтергә дә бирергә кирәк дигән уй башыма килде дә, мин аңа, юри каты итеп:

– Бала-чага шикелле җыен юк-барны сөйләп тормагыз әле, Гөлүсә! – дидем.

Шулай диюем булды, ул куенымнан ялт итеп атылып чыкты да чанадан сикереп төште.

– Юләрләнмәгез, Гөлүсә, әйдә утырыгыз да кайтыйк матур гына! – дип чакырып карасам да утырмады. Аннары үзем дә чанадан төшеп, күтәреп алып утыртмакчы булган идем. Ләкин ул кыр кәҗәседәй җиңел генә йөгереп китте. Мин аны куып тормадым.

– Ихтыярыгыз, алайса! – дидем дә атыма утырып киттем.

Инде Көрнәлегә кайтып җитәргә дә ерак калмаган, утлары җемелдәшеп күренә иде.

Ул, бер сүз дә дәшмичә, баскан җирендә торып калды.

Ике-өч йөз метр киткәч, мин артыма борылып караганда, ул җылт-җылт атлап кайтыр якка килә иде инде...

**6**

Әйе, ул көнне мин Гадел абыйга да, шактый сәер сүзләр сөйләгән теге укытучы кыз Гөлүсәгә дә Сәкинәмне ник аерып җибәрүемне аңлатып бирмәдем. Шуңа аңлатмадым, чөнки шәхси тормышым турында үзем дә сөйләргә яратмыйм, башкалар сөйләгәнне дә бик үк өнәп бетермим. Минемчә, андый эшләрне бары тик ике генә кеше: ир белән хатын гына белергә тиеш... Ләкин, шулай икәнлеген яхшы белсәм дә, бу урында мин яшьлек елларымны, беренче мәхәббәтемне, семья хәлләремне сиңа кыскача гына булса да сөйләп бирмичә үтеп китә алмыйм. Алда сөйләячәк вакыйгалар шунсыз аңлашылмаячак, туган. Аңлашылган тәкъдирдә дә тулы булмаячак. Мин сиңа бернәрсәне дә яшермичә, ничек булган, шул килеш сөйләп бирергә вәгъдә иттем бит. Менә тыңла әле.

Барлык авыл малайлары кебек үк, мин дә җәен каз көтеп, шара уйнап, җиләккә йөреп, ә кышларын чана-чаңгы шуып үстем.

Башка малайларныкы кебек үк, минем дә үз дусларым, үз иптәшләрем булды. Әмма шулар арасында иң якын дустым Рәдиф иде. Кая барсак та, ни кылансак та, без гел аның белән бергә идек. Мине бүтән малайлар кимсетә башласа – ул, аны кимсетә башласалар – мин, бер-беребезне яклап, теләсә кемгә каршы чыгарга әзер тордык. Әзер генә түгел, сугышкан чакларыбыз да булды.

Һич онытасым юк, без беренче класска укырга керәсе елны, сабан туе көннәрендә, Рәдифләргә Казаннан туганнары кунакка кайтты. Рәдифкә бүләк итеп уенчык гармун да алып кайтканнар иде. Бер дә бер көнне, шул гармунын тотып урамда уйнап йөргән чагында, бездән өч-дүрт яшькә зуррак Шайтан Вагыйз дигән малай, кая, кубызыңны уйнап карыйм әле, дип, сагыз урынына ябышты бит Рәдифкә. Рәдифнең гадәте шундый: гармун тикле гармунын гына түгел, гомумән, үз әйберен миннән башка кешегә бирергә яратмый ул. Ә гармунын хәтта миңа да уйнатып караганы юк иде әле. Шулай булгач, ничек уйнатсын ди ул Шайтан Вагыйзгә! Ә Вагыйз китми дә китми. Теле белән Рәдифне юмалый алмагач, куркытырга кереште бу. Алай да эше барып чыкмагач, Рәдифнең гармунын тарта-йолка башлады. Үз дигәненә алай да ирешмәгәч, як-ягына каранып алды да, якын-тирәдә безнең яклы малайлар юклыгын белеп, Рәдифнең эченә тибеп җибәрде. Инде минем дә түземем төкәнгән иде, мин дә Шайтанның ипи шүрлегенә бер менеп төштем. Аннары ул миңа берне ямады. Китте сугыш, китте кычкырыш!..

Эш менә болай булып бетте: каяндыр таяк табып алып, Вагыйз безнең икебезне дә шәп кенә дөмбәсләде дә Рәдифнең гармунын урталай аерып кайтып китте. Хәер, без дә әҗәтле булып калмадык. Берничә көннән соң, ул һич көтмәгәндә, кулында таягы юк чакта тотып алдык та үзен бик әйбәтләп тукмап җибәрдек.

Мәктәпкә укырга кергәч тә Рәдиф белән бер партада утырып укыдык. Өйгә биреп җибәрелгән мәсьәләләрне дә бергә чишә идек. Беренче классны тәмамлаган елны әти миңа чын гармун алып бирде. Гармун уйнарга да Рәдиф белән бергә өйрәндек. Ул миннән алдарак та өйрәнде әле. Өйрәнүен өйрәнде, тик әллә ни оста гармунчы булып китә алмады. Тора-бара бөтенләй бизде. Ә мин, киресенчә, торган саен күбрәк хирыслана бардым. Мәктәптә тәнәфес вакытларында да укытучылар гел миңа уйнарга кушалар иде.

Сигезенчедә чакта (дүртне бетергәч, без үзебездән җиде километр ераклыктагы Янтык урта мәктәбендә фатир торып укыдык), әти-әниләре туганнарының туена киткәч, безнең класстагы бер кыз

аулак өй ясарга булган. Гармун уйный белгәнгә, мине дә чакырды бу. Ә Рәдифне чакырмады. Дустымны калдырып үзем генә бараммы соң инде?

– Рәдифне дә кертерлек булсаң – риза, шунсыз – юк! – дидем мин теге кызга.

Күрәсең, башка гармунчы табар чамасы булмагандыр, сыкраныбрак кына булса да ризалашты кыз.

Әйтелгәч сәгатенә бардык. Үз авылларыннан да биш-алты малай, җиде-сигез кыз җыелган иде. Артык тавышланмыйча гына (укытучылар сизсә – харап!) мин уйныйм, тегеләр җырлый башлады. Аннары кызып, онытылып киттеләр булса кирәк, шәбрәк, кычкырыбрак җырлашырга тотындылар. Төрле уеннар уйнау китте. Йөзек салыш уйнаганда, үзләренең җаны теләгән кызларын алып, малайлар «кәҗәябып», «йолдыз санап» та кергәлиләр. Минем дә исәп юк түгел. Миңа да Сәкинә исемле бер кыз ошый. Минем ул кызны моңарчы да күргәләгәнем бар. Алтынчыда, икенче сменада укый ул. Ләкин моңарчы минем аңа әллә ни игътибар иткәнем юк иде. Ә менә бүген әллә ничек бик якын булып китте. Миннән ике класска кечерәк икәнен дә аңлыйм, шулай да нигәдер тиңдәшем шикелле, яшьтән үк бергә үскән шикелле тоела башлады ул. Аның белән бик рәхәтләнеп «йолдыз санап» керер идем дә бит, ни хәл итәсең, гармун уйнап утыргач, мин йөзек салыш уенында катнаша алмыйм. Шунлыктан миңа җәза бирелми. Ә «кәҗә ябарга» җәзага тап булган кешеләр генә чыгарга тиеш.

Рәдифнең эше рәхәт! Әллә юри җәза алырга тырыша инде шунда: Сәкинә белән өч тапкыр «кәҗәябып» керде бу! Ул, ихтимал, дүртенче мәртәбә дә чыккан булыр иде, тик кинәт бик хәтәр итеп ишек дөбердәтә башладылар. Барыбыз да шып булдык. Чыгып: «Кем ул?» – дип сорарга беребезнең дә йөрәге җитми. Син бар да син бар дип, пышын-пышын бер-беребезне кысташып тик торабыз. Ә ишек аның саен ныграк дөберди, тәрәзә рамнарына кадәр дер селкенә. Ниһаять, хуҗа кыз тәвәккәлләп чыгып китте.

– Беттек, балалар! – диде ул, бик тиз генә әйләнеп кереп. – Укытучы Нәҗип абый килгән! Әйдә, тизрәк киенегез дә минем белән өйалдына чыгыгыз! Мин ишекне ачканда, ишек артында торып торырсыз да, Нәҗип абый өйгә кереп киткәч, чыгып чабарсыз!

Укуга алай искитәрлек һәвәс түгел иде ул кыз. «Отлично» турында әйткән дә юк инде, «яхшы» билгеләрен дә бик сирәк алгалап килә. Ә менә хәзер, шушындый кыен чакта, барыбыздан да акыллырак, кыюрак булып чыкты! Без нәкъ ул әйткәнчә эшләдек: өйалды ишеге артына посып тордык та, Нәҗип абый пыр тузып өйгә кереп китүгә, атылышып чыгып, урамга сибелдек. Үзебез фатирда тора торган йортның капка төбенә ничек кайтып җиткәнемне сизми дә калдым. Ә Рәдиф күренми иде әле. Миңа аны көтеп тормыйча ярамый: бергә чыгып киттек, бергә кайтып керергә тиешбез. Кышкы суыкта урык-сурык ишек ачып йөргәнне фатир хуҗасы яратмый.

Нәҗип абыйдан курыкканлыктан бөтенләй онытып торган икәнмен, капка төбендә Рәдифне көтеп торганда, аяк туңа башлаганга арлы-бирле йөрергә керешкәч, кылт итеп гармунымны теге кызларда онытып калдырганлыгым исемә төште дә йөрәгем жу итеп китте. Бөтен өметем Рәдифтә иде хәзер. Бәлки, ул алып кайтмасмы? Андый чакта минем шикелле куркып-югалып калмый торган гадәте бар иде аның...

Бик озак көттем мин аны ул кичне. Туңып беттем. Шулай да ул кайтмыйча өйгә кермәдем. Ә эш менә болай булган икән. Безнең белән бергә башта Рәдиф тә өйалдына чыккан. Ләкин хуҗа кыз ишекләрен ачып азапланган чакта, гармуныбыз онытылып калуын исенә алган да йөгереп өйгә кире кереп киткән. Гармунны алып чыгып килгәндә исә Нәҗип абыйга юлыккан. Ә Нәҗип абый, Рәдифнең якасыннан ук каптырып:

– Башкаларыгыз кая китте? Кемнәр бар иде? Ничә кеше идегез? – дип сорау алырга тотынган.

Рәдиф башта Янтыктагы үзе белгән зуррак, инде мәктәпне тәмамлап чыккан берничә егетнең һәм кызның исемнәрен әйтеп котылырга тырышып караган. Әмма Нәҗип абый, аның ул сүзләренә ышанмыйча, бик каты кыса башлагач, түзмәгән, аулак өйгә килгән укучыларның исемнәрен әйтергә мәҗбүр булган. Тик минем исемне генә әйтмәгән. Гармунны да, үземнеке дип, үз өстенә алган.

Менә шундый иде минем Рәдиф дустым!

Мин үзем дә аның өчен җанымны бирергә әзер идем. Бервакыт шулай мәктәпкә тәкә куыгы алып килде бу. Тәнәфестә өреп тутырып куйды да, дәрес башлангач, парта астында тоткан килеш кенә, шул куык белән шаярып утыра башлады. Боргычлый торгач, ялгыш шартлап китте бит моның куыгы. Шактый каты шартлады ул нәмәстәкәй. Класстагы укучылар гына түгел, хәтта кара такта янына эленгән карта каршында безгә дәрес аңлатып торган укытучыбыз Галия апага тикле сискәнеп китте. Аннары бөтен класс берьюлы кычкырып көлеп җибәрде. Шартлау безнең парта астында булганлыгын Рәдифнең дә, минем дә кызарышып китүебездән үк аңлап алды булса кирәк, Галия апа кулындагы күрсәткеч таягын Рәдифкә төбәде дә:

– Син шартлаттыңмы? – дип, җан ачуы белән кычкырып куйды.

Рәдиф, җавап бирмичә, башын аска иде.

– Бас әле, Хәйретдинов, синнән сорыйм мин!

Рәдиф иренеп кенә басты, әмма җавап бирмәде.

– Йә, багана булып катып торма, әйт, син шартлаттыңмы? Нәрсә иде ул? – диде Галия апа, Рәдифнең янына килеп, күзенә керердәй булып.

– Юк, мин шартлатмадым, апа, – диде Рәдиф, елап җибәрер дәрәҗәгә җитеп.

– Димәк, син шартлаттың, Хәкимов? – диде Галия апа. Тагын да ныграк ачулана төшеп, миңа текәлде.

Нишләмәк кирәк, «мин түгел» дисәм, эш зурга китәчәк. Ахыр чиктә мәсьәлә барыбер ачыкланыр да Рәдифкә бик кыенга туры килер. Болай да географиядән тарта-суза гына «уртача»га укып килә ул. Шартлауның да Рәдиф эше икәнен белсә, Галия апа аңа чиреккә «начар» чыгаруы да бик ихтимал. Болай да ничектер үртәлүчән, юк кына нәрсәгә дә кызып китә торган укытучы ул. Мондый эштән соң ике дә уйлап тормас...

Секунд эчендә шул фикер башыма килде дә, тиз генә торып басып:

– Гафу итегез, Галия апа, куык минеке иде, ялгыш шартлап китте, – дидем.

Галия апа, чарт иттереп, күрсәткеч таягы белән картага сукты да:

– Бар, югал күземнән, хәзер үк чыгып кит класстан! – дип, мине куды...

Аннары тәнәфестә укыту мөдире Нәҗип абый янына алып кереп тә нык кына «эшкәрттеләр» үземне. Ләкин мин Рәдифкә сукыр бер тиенлек тә үпкәләмәдем. Ик якын дустыңа ничек булышмыйсың инде?..

Безнең дуслык соңрак, икебез дә үсеп, егет булгач бозылды.

**7**

Ул елны без икебез дә, ун классны тәмамлап, колхозда эшли башлаган идек инде. Рәдиф – завхоз, мин – хисапчы. Ул елларда унны бетергән кешеләр бик кадерле иде бит, нигә алай колхозда гына каласы иттегез, диярсең син, бәлки. Минем дә үз хыялым бар иде: авыл хуҗалыгы институтына укырга керергә иде минем исәп. Ләкин хыял бер, чынбарлык бөтенләй башка нәрсә бит ул, туган. Мин унынчыда укыган елны әнием авырый башлады да, мин аны ташлап китә алмадым. Дөрес, Рәдиф, Казанга барып, педагогия институтына имтихан биреп караган иде каравын. Күрәсең, булдыра алмагандыр – имтихан алу вакыты беткәнче үк әйләнеп кайтты да:

– Ун ел укып та бик нык алҗытты инде, җитәр! Колхозда эшләп карарга кирәк бераз, – дигән булып, шыпырт кына завхозлыкка урнашты.

Минем укырга китмәвемнең тагын бер бик җитди сәбәбе бар, туган. Ул турыда һич тә сүз кузгатырга исәбем юк иде дә, шулай булса да яшереп калдыра алмыйм инде мин синнән. Хикмәт шунда, эти бик кызу канлы, бик җиңел холыклы кеше иде безнең. Шуның өстенә нык кына салгалый да иде. Ә салдымы – тавыш чыгара, әнигә бәйләнә, бер дә юкка аны кимсетә башлый. Соңгы елларда бөтенләй азынды бу. Әнинең кыз чагыннан калган, күз карасы кебек итеп саклап тоткан мамык шәлен дә, хәтта бердәнбер самоварыбызны да каядыр башка авылга илтеп сатып эчеп кайткач һәм шуның өчен әни күз яше белән елап, аерылырга җыена башлагач, карап торган бердәнбер сыерыбызны да җитәкләп чыгып китте дә, шул китүеннән җир упкандай юкка чыкты. Исәндерме-юкмы – ул хакта бернәрсә дә әйтә алмыйм. Хаты да, хәбәре дә юк.

Менә шулай, туган. Әтисез дә калгач, кием-салым, ашау-эчү мәсьәләләре дә шактый кыен булгач, миңа институт турындагы хыялларымны онытып торырга туры килде. Әйтмәсәм дә аңлашыла булса кирәк, Рәдиф тә, мин дә ул чакта борыннарыбызга кызлар исе кергән, кызлар дигәндә җәһәннәмнең аргы ягына барып чыгарга әзер торган егетләр идек инде. Кичләрен аулак өйләргә дә йөрибез. Ә үзебез һаман бик дус, бик тату. Беребез ни әйтсә, икенчебез шуңа риза. Гомергә шулай булыр төсле иде. Әмма кешеләр яшьрәк чакта гына шулай эчкерсез булалардыр, ахрысы. Ә олыгая төшкәч, күңелләре тупаслана, муртая, дуслык хисләре кими, шәхси омтылышлары өстенлек итә башлый булса кирәк. Икенче төрле итеп әйткәндә, «минеке», «миңа» дигән нәрсә алгы планга чыга торгандыр, ахрысы. Шулайдыр, шулай булмаса, кайчакта дус белән дус кына түгел, эне белән абый, ата белән бала үзара алдашуга, ачуланышуга һәм дошманлашуга барып җитәр идемени?..

Безнең телгә килешүебез һич тә көтмәгәндә килеп чыкты. Әлеге шул Янтыкта – теге чакта. Нәҗип абый туздырып чыгарган аулак өйдә безнең белән бергә утырган һәм шул вакытта ук инде минем күңелгә кереп калган Сәкинә исемле кыз кырыгынчы ел башында авылыбыздагы туганнарына утырмага килде. Кызлар күрмәгән кеше түгел инде мин. Кайберләрен озата кайткалаганым да бар иде. Әмма Сәкинә... Ул хәзер тагын да чибәрләнеп, тагын да сылуланып киткән. Синең, мөгаен, «Все начинается с дороги», «Крепостная актриса», «Коллеги», «Чистые пруды», «День счастья» исемле фильмнарны караганың бардыр. Менә шуларның барысында да Тамара Семина дигән актриса уйный. Төп рольләрне башкара ул. Әйтергә кирәк, бик шәп итеп башкара. Безнең авылга утырмага килгән елны Сәкинә нәкъ шул Тамара төсле чибәр, тыйнак, нәкъ шулай мәхәббәтле иде. Бер сүз белән генә әйткәндә, килгән көнне үк үлеп гашыйк булдым мин аңа. Ничек итсәм итәм, әмма бүген кич барыбер шул кызны озата кайтам, дип, күңелемә беркетеп куйдым.

Әмма аңа күңеле төшкән кеше бер мин генә булмаганмын, башка егетләрнең дә ике күзен дүрт иткән икән ул. Алары өчен кайгырмаска да була. Рәдиф белән икәүләп тотынсак, каршы тора алучы булмаячак иде безгә. Тик, кызганычка каршы, Рәдифнең үзенең дә Сәкинәгә һушы киткән булып чыкты, туган! Гел аның тирәсендә сырпалана башлады бу. Йөзек салыш уйнаганда җәзага тап булып, бер тапкыр Сәкинәне «йолдыз санарга» алып чыгып, хәтсез генә озак торып керделәр. Ә миңа, әлеге шул гармун уйнап утырганлыктан, «җәзалы» уен уйнарга һич тә җай юк. Ну гармунны уйныйм инде анысы! Җаннарымны биреп тырышам. Сәкинә биегәндә аеруча шәп сайрый гармуным. Талып, тартыша башлаган бармакларым язылып киткәндәй була. Биюен дә бик шәп бии инде, малай! Идәнгә түгел, йөрәккә басып бии. Шундый да дәртле, шундый да килештереп биючене күргәнем юк иде әле. Башкаларга да шулай тоела торгандырмы, миңа калса, минем өчен генә шулай оста биидер кебек ул. Ул биеп, мин уйнап үзара сөйләшәбез, серләшәбез шикелле тоела. Тик ничек итеп чынлап торып сөйләшергә соң үзе белән?..

Аулак өйдән таралышыр вакыт якынлашкач, әйдә бер тартып керик әле, дигән булып, мин Рәдифне өйалдына алып чыктым да:

– Нәрсә, Сәкинәне озатырга исәбең бармы әллә? – дип сорадым.

– Әбизәтелне озатам!

– Суфияң үпкәләмәсме соң?

Хикмәт шунда, шул көннәрдә авылыбызның Суфия исемле кызын сөйләштергәләп йөри башлаган иде ул. Әйтүенә караганда, чын-чынлап ук ярата да. Ләкин минем теге соравыма һич тә исе китмәде Рәдифнең:

– Һәй, таптың сүз! – диде ул, кычкырып көлеп. – Суфия моның янында дүртенче сорт кына ич ул. Аннары тагы беркая да китми бит ул Суфия. Сәкинә кайтып киткәч тә монда кала.

– Калуын кала да бит, соңыннан ул сиңа үпкәләсә, сөйләшергә теләмәсә?

– Үпкәләсә, үпкә бәлеше пешереп ашар!

– Туктале, кызма әле син, Рәдиф. Суфияң бик чибәр, бик акыллы бит! Гел чикерткә шикелле сикергәләп йөрмә инде! Ә Сәкинәне бүген мин озатыйммы әллә дигән идем. Янтыкта аулак өйдә утырган елдан бирле яратып йөрим бит мин аны. Тик сүз катарга гына моңарчы йөрәгем җитмәгән иде.

– Юк, Өлфәт, әйдә, алай мәтәштермә инде син, яме! Дуслыкны бозма. Мин озатам аны бүген. Минем дә бик күптәннән күз төшеп йөри инде аңа. Әгәр арага керсәң, дуслык бетте дип уйла!

Нишләтәсең инде аны? Шулай да:

– Дус итсәң, юл куй миңа, Рәдиф! – дип, тагын бер кат үтенеп карадым каравын.

Әмма Рәдиф күп сөйләшеп тормады.

– Әйткән – бетте! Булмагач булмый, Өлфәт! – диде дә кереп үк китте.

Ул кичне дә, икенче, өченче кичне дә Сәкинәне Рәдиф озата барды. Әмма, яшьләрнең сөйләвенә караганда, кыз белән уртак тел таба алмаган иде әле. Шуннан ары минем дә кан кызып китте Рәдифкә. Шулай булмый хәле юк, чөнки Сәкинә безнең авылга гомергә килмәгән, торса, атна-ун көн торыр. Санаулы көн бик тиз үтә бит ул. Ә Рәдиф инде өч көн вакытны алды. Дусын дус та, ахыр чиктә бездә дә күңел дигән нәрсә бар бит!..

Шулай уйладым да, дүртенче кичне аулак өйгә баргач, әле уеннар башланганчы ук, Рәдифне өйалдына алып чыктым һәм гомеремдә беренче мәртәбә, төрпә итеп:

– Йә, ничек соң, егет, кунак кызы белән эшләр җайланамы? – дидем.

Рәдиф теш арасыннан гына черт иттереп төкереп куйды.

– Сиңа аны белү бик кирәкме?

– Әйе, кирәк.

– Алайса әйтәм: күндердем мин аны, малай!

– Мәтәштермә син, Рәдиф. Мине ахмакка санама! Сөешергә түгел, сөйләшергә дә теләмәгән Сәкинә синең белән!

– Шымчылык итеп күзәтеп йөрдеңмени?

– Юк, мин үзем күзәтмәдем, ләкин барысын да беләм: әйттеләр.

– Ярый алайса, дус кеше буларак, дөресен әйтим: бик үҗәт нәрсә булып чыкты ул кыз, һич кенә дә якын бара торган түгел. Ну шулай да бүген тагын бер тапкыр озатып карыйм әле. Килешә алмасак, иманын укытам мин аның!

– Юк инде, Рәдиф, өч тапкыр барып карадың – җитте! Өчтән ары көч була ул. Бүген миңа юл куй инде син, яме?

– Папрубый барырга!

– Барсам нишләтерсең?

– Анысын соңыннан күрерсең!

– Өркетмә, яме, синнән курка торган күлмәгем күптән тузды инде!..

Тартышка китсә, көч белән алдыра алмаячагын үзе дә сизенде булса кирәк (шаярып көрәшеп уйнаган вакытларда гел мин ега идем аны), өйалдында сөйләшкәндә шактый нык әтәчләнсә дә, теге кичне Рәдиф миңа комачаулап, бәйләнеп йөрмәде.

Сәкинәне ничек озата кайтуымны, капка төпләрендәниләр сөйләшүебезне сөйләп тормыйм, туган. Андый изге нәрсәне, минемчә, үзара сөйләшкән егет белән кыз гына белергә тиеш. Тик шуны гына искәртеп китмәкче булам: картлар әйтмешли, чәчләребез чәчкә бәйләнеп үк туган булганбыз, күрәсең. Сәкинә белән шул ук кичтә аңлашып, сөешеп киттек без.

Бер атна торды ул безнең авылда. Соңыннан да, җае чыккан саен, йә мин Янтыкка барып, яисә ул безнең авылга килеп очраша башладык. Хатлар язышып та серләшәбез. Аннары, көтә торгач, сабан туе да килеп җитте. Алдан сөйләшү буенча, Сәкинә бәйрәмдә безнең авылга килергә тиеш иде. Безнең авылның урманы бик якын, ындыр артыннан ук башлана. Сабан туен һәр ел шунда үткәрәләр. Бик матур аланлык бар безнең анда. Коенырга теләгән кешегә көмеш сулы зур гына күле дә якын гына. Элек шунда бер рус баеның дачасы булган. Билгеле, хәзер анда бернинди дача юк: революция елларында авыл халкы бөтенесен яндырган – капитализмның духы да калмасын, янәсе... Духы чыннан да юк. Ә менә аланы белән күле калган. Исән булсам, шул аланда колхозчылар өчен ял йорты салдырырга әле исәп. Нык итеп, бүрәнәдән эшләтергә уйлыйм. Кыш көне дә торырлык булсын. Авыл халкының җәй көне ял итеп йөрергә вакыты булмый аның. Ә менә кыш көне була. Кышын да бик шәп ул алан. Әллә кайдагы курортларга барып йөргәнче, үз курортыбызда рәхәтләнерләр, ичмаса! Колхозның анлык кына хәле бар хәзер...

Ярый, монысы аның киләчәк эше. Мин сиңа үткән хәлләрне сөйли идем бит әле.

Сүзендә торды Сәкинә – килде сабан туена. Икебез дә бик нык сагынышканбыз икән, очрашкач ук, үзебез дә сизмәстән, сукмак буйлап урман эченә кереп киттек. Аны күргәнче сөйләшеп сүзебез бетмәс төсле иде. Ә менә хәзер, очрашып икәүдән-икәү генә бара башлагач, бөтенләй телсез калдым. Һич кенә дә юньле сүз килми телгә! Әнисенең сәламәтлеге хакында, ничек һәм кемнәр белән безнең авылга килүе турында сораштым да шуның белән сүзем бетте. Ул да дәшми, минем дә тел әйләнми. Әкрен генә атлыйбыз да атлыйбыз. Ләкин болай бару ничектер кыен. Аптырагач, мин чәчәк җыярга тотындым һәм Сәкинәгә бер кочак чәчәк җыеп бирдем. Ул, рәхмәт әйтеп, чәчәкләрне кулына алды да сокланып күкрәгенә кысты. Ә мин, ни эшләвемне үзем дә белештермичә, Сәкинәнең сылулыгына сокланып, исереп китеп, чәчәкләре белән бергә аны кочып алдым...

Бу минем аны гомеремдә беренче тапкыр үбүем иде. Шунда без бер-беребезне мәңге ташлашмаска сүз куештык. Аннары кайтыр якка – сабан туе бара торган аланга таба киттек. Бу минутларда миннән дә бәхетле кеше, белмим, булдымы икән?!

Тик ул бәхетебез озакка бармады. Аланга килеп җитәбез дигәндә генә, Казаннан үзләренә кунакка кайткан туган тиешле бер егетне ияртеп, кинәт каршыбызга Рәдиф килеп чыкты. Кыяфәтләреннән үк күренеп тора – икесе дә бераз салмышлар. Миңа бәйләнергә чамалый болар. Сүзне Рәдиф башлады. Алар юлыбызга аркылы төшкәч, читләтеп үтеп китмәкче идек, Рәдиф җиңемнән тартып туктатты да, йөзенә ачуны китерә торган мыскыллы кыяфәт чыгарып:

– Йә инде, бик алай ашыкмагыз, нурлы йөзләрегезне туйганчы бер күреп калыйк инде, – диде. Карашы нурсызланган зур яшькелт күзләрен, гаҗәпләнгән булып, Сәкинәгә текәде. Сәкинә бер дә исе китмичә йөзен читкә боргач, авызын бәлчәйтеп куйды да:

– Ярар инде, чибәр кыз, боргаланма инде, кыш көне утырмага килгән чагында бер дә болай кыланмаган идең бит! – дип, үбәргә итенә башлады.

Моннан соң да түзеп торырга һич тә мөмкин түгел иде. Рәдифнең кулларын читкә кактым да, нык кына итеп, үзен этеп җибәрдем. Шул арада, арттан килеп, Казан егете минем колакка берне тартты. Әллә көтелмәгәндә китереп сукканга, әллә берәр каты әйбер белән ордымы икән – бер мәлгә күз алларым караңгыланып китте. Шулай да бик тиз өнемә килдем һәм:

– Бар, Сәкинә, йөгер! – дидем дә кизәнеп торып теге егетнең танавына мин дә берне салдым. Үзе шулай йомшак буынлы булгангадырмы, әллә җан ачуым белән мин бик нык эләктергәнменме – мәтәлеп үк китте егет.

Мин Рәдиф тә шулай кулын ходка җибәрер дип көткән идем. Бәйләнеп тә эш майтара алмам дип шүрләгәндерме, әллә сабан туеннан соң тагын бергә эшләргә туры киләчәген исенә төшерепме икән, анысы миңа кагылмады. Ул тимәгәч, мин дә кул күтәреп тормадым. Тиз генә Сәкинә артыннан китеп бардым.

Бер-ике көн үпкәләшеп, бер-беребезне күрмәмешкә салышып йөрсәк тә, сабан туе үтүгә, Рәдиф белән очраша, сөйләшә башладык. Ни әйтсәң дә, беребез – завхоз, беребез хисапчы идек бит!

Мин, шуның белән мәсьәлә ачыкланды, арабыз өзелде бугай дип, тәмам тынычланган идем. Рәдиф үзе дә бер дә алай ачуын сиздермәгән булды. Ләкин ул җәй чыкканны гына көтеп йөргән икән. Анысы ничек булганын соңыннан аңлатырмын, хәзер Сәкинә белән ничек кавышуыбыз хакында тагын берничә авыз сүз әйтеп китим әле мин сиңа, туган.

**9**

Ул килүендә Сәкинә безнең авылда ике көн торды. Өченче көнне кичкә каршы озата киттем мин аны. Теләсәм, ат җигеп илтергә дә булыр иде, билгеле. Әмма җиде километр ара ат белән барганда бик тиз узыла бит ул. Ә минем Сәкинәне биш кенә минутка булса да янымда озаграк тотасым килде. Шуңа күрә җәяүләп кенә озатырга булдым. Иркенләп, бер дә ашыкмыйча бардык без ул көнне. Юл буендагы әрәмәлеккә тукталып, җиләк тә ашадык, чәчәкләр җыеп, мин аңа тәкыя да үреп бирдем. Рәхәтләнеп сөйләштек, туйганчы көлештек. Янтык күренә башлагач та, аерылыша алмыйча, шактый вакыт бер-беребезгә карап, сүзсез генә сөйләшеп тордык. Бары шуннан соң гына, хатлар язышып торырга сүз куешып, ниһаять, аерылыштык. Ул гаҗәеп матур аяклары белән җиңел генә атлап, бер кулына чәчәкләр, икенчесенә косынкасын тотып, басу капкаларыннан кереп киткәнче, мин аңа сокланып, хәйран калып һәм кул болгап тордым...

Их, бу дөнья! Нигә кеше гомерендә бер генә тапкыр була икән андый кадерле минутлар?! Бер-ике сәгатькә генә булса да нигә кире кайтарып булмый икән андый бәхетле чакларны?! Әгәр шулай мөмкин булса, Сәкинәне һич икеләнүсез борып алып кайтыр идем мин. Алып кайтыр идем дә, шул ук сәгатьтә авыл советына барып язылышыр идек. Үзе дә моңа каршы килмәс иде ул, минемчә. Аерылышканда мин аңа, шаярып кына:

– Ә мин сине җибәрмим, Сәкинә. Күтәрәм дә үзебезгә алып кайтам! – дигәч:

– Әйдә, булдыра алсаң, мин каршы түгел! – дигән иде ләбаса.

Дөрес, ул да шаярып әйткәндер әйтүен. Әмма шаярудан чынга күчәргә әллә ни күп кирәк түгел бит. Ярата иде ул мине, үлеп ярата иде. Һичбер арттырусыз әйтәм, әгәр шул көнне тәвәккәлләп, чынлап торып тотынсам, кайтыр иде ул минем белән. Әгәр шул көнне аны алып кайткан булсам, ак сакаллы карт буласы икәнмен мин: бер ел бергә яшәп каласы икәнбез! Ләкин юк, үткәнне кире кайтару мөмкин түгел шул!..

**10**

Кырык беренче ел башында Сәкинә тагын утырмага килде. Бу юлы безнең арага керүче булмады. Рәдиф инде кисәтелгән, авылның бүтән егетләре шулай ук безнең яратышуыбызны белә иде. Шулай да беркөнне аулак өйдә кич утырганда, «кәҗә ябарга» алып чыккан аны Рәдиф. (Ул көнне мин, колхоз отчеты белән районга барып, кич утырырга кайтып җитә алмаган идем.) Ләкин элеккечә үк сагызланмаган ул. Төрле юк-бар турында лыгырданып торган да:

– Син чынлап та яратасыңмы шул чыпчык йомыркасы төсле сипкелле, сары кашлы Өлфәтне? – дип кенә сораган.

Сәкинә дә каушап калмаган.

– Чынлап яратам, Рәдиф! Сипкелле булса да, узган ел сабан туенда теге Казан егете белән икегезне ике якка сибеп китте ич ул! – дип җавап биргән.

Шуннан авызы томаланган тегенең. Үзалдына нидер мыгырданып, тәмәкесен кабызган да аулак өйгә кереп тә тормыйча кайтып киткән.

Сәкинәнең җавабы бик җиткән дип санадым мин. Ул хакта Рәдифкә бөтенләй сүз катмадым. Нишләтим соң, сипкелле булгач сипкелле инде мин. Кашым гына түгел, чәчем дә сары, бакыр төслерәк. Дөресен генә әйткәндә, Рәдифнең дә әллә ни мактанырлыгы юк инде кана. Төс-бит, буй-сын шәп, әлбәттә. Ул яктан тел тидереп булмый. Ә менә аягының рәте юк. Өченче ел сугу машинасының маховигы тирәсендә шаярып утырган чагында барабанны маховик белән тоташтыра торган каеш астына аягын ялгыш кыстырып, бәлагә тарган иде ул. Шуннан соң аягының тубыктан түбән ягы тәмам эштән чыгып калды. Хәзер бик нык аксап йөри. Ул аягына фабрикада тегелгән ботинка да, күн итек тә кия алмый. Фабрика итеген боздыртып, үзенә җайлаштырып, Галим абзыйдан тектереп кенә киярgә мәҗбүр. Алай да юньләп йөри алмый әле. Иярле атка атланып барган кеше сыман, бер батып, бер калкып кына йөри. Менә шул кеше синнән «сипкелле, сары чәчле» дип көлеп йөргәч, кәефең кырылмый нишләр?..

Шулай итеп, ул килүендә бер атна торды Сәкинә безнең авылда. Бер атна буена һәр кичне озата кайттым мин аны. Әмма санаулы көннәр бик тиз үтә шул, каһәр. Тәмам ияләшеп, үзләшеп җиткәндә генә:

– Иртәгә мин китәм инде, Өлфәт, – диде Сәкинә.

– Юк, Сәкинә, беркая җибәрмим мин сине. Риза булсаң да, булмасаң да, алам да калам!

Мин аны чынлап әйткән идем. Сәкинәм, җан кисәгем, дерт итеп куркып китте. Беркавым тәмам аптырап, ни әйтергә дә белмичә торды. Бары шуннан соң гына:

– Юк, Өлфәт, алай куырма әле син мине, – диде. – Без бик яшь бит. Мин яңа гына унсигезгә чыктым. Аннары әниең терелеп китсә, сине армия хезмәтенә дә алып куюлары бар. Бер кавышкач, ике ел аерым торулары бик кыен, диләр ич!

Шулай дигәч, мин каршы килә алмадым.

– Алай-болай армиягә алып куйсалар, мин хезмәт итеп кайтканчы көтәрсеңме соң, матурым? Берәрсенә күзең төшеп, башың әйләнеп китмәсме икән? – дип кенә сорадым.

– Борчылма, бәгырем, көтәрмен. Ике ел гомер күпмени ул? Син кайтканда да егермедә генә булам бит әле мин! – диде ул.

Аннары тагын сабан туе җитте. Бу ел да Сәкинә бәйрәмгә безнең авылга килде. Нигә гел ул гына килә, нигә син бер дә бармадың, дип гаҗәпләнмә, туган. Хикмәте бар аның. Янтык егетләре кунак егетләрне бик үк өнәп бетермиләр. Нигәдер тар күңеллеләр. Менә шуңа күрә андый болгавыр чакта – сабан туе көннәрендә – Янтык егетләре миңа да бәйләнмәсен өчен, Сәкинә үзе безгә килә торган иде.

Бу ел да, нәкъ былтыргыча, сабан туе барган аланда озак тукталып тормастан, очрашкач ук урманга кереп китеп, чәчәкләр җыеп йөрдек. Тик бу юлы әйтер сүз таба алмыйча гаҗизләнмәдем инде мин. Хәзер без бер-беребезгә туганнардай якын идек, үз идек. Сөйләшеп сүзебез бетмәде. Авылга тәмам күз бәйләнгәч кенә кайттык. Ә икенче көнне мин аны тагын авыллары күренә башлаганчы озата бардым. Тагын шулай ук басу капкасыннан кереп киткәнче, кул болгап карап тордым.

Кырык беренче елның унсигезенче июне иде бу.

Ә дүрт көннән соң безнең авылга шомлы хәбәр килде. Башка кешеләр үзләрен ничек хис иткәндер, анысын әйтә алмыйм. Әмма мин үзем, сугыш башланганын ишеткәч, беркавымга өнсезләнеп калдым. Күк йөзләре караңгыланып киткәндәй булды. Юк, сугышка алырлар да шунда үлеп калырмын, дип, үзем өчен хафаланмадым! Минем ише егетләр дә сакламагач, кем саклар ул туган илне? Әнием өчен, Сәкинә өчен кайгырдым мин ул минутларда. Мин исән-имин әйләнеп кайта алмасам, алар нишләр? Ахыр чиктә Сәкинә әле яшь, таза, чибәр. Башта бик нык өзгәләнсә дә, соңыннан сүрелер, бүтән кешене, бәлки, миннән яхшыракны да табар. Ә менә әни... Сырхаулы бит ул. Бер көн аякта йөрсә, ике көн түшәктә ята. Сызламаган җирем юк, ди. Врачларга да күрсәтеп караган идем үзен. Ләкин авыруын тәгаен генә ачыклый да, терелтә дә алмадылар. Шул эти имгәтеп бетергәндер инде бичараны. Ул китеп олакканнан бирле авырый әнием. Мин дә киткәч, ул нишләр? Менә хикмәт нәрсәдә!..

Өч-дүрт көн эчендә авылның бөтен ир-егетләрен дип әйтерлек сугышка алып бетерделәр. Егерме җидесенә иртәнге сәгать тугызга район военкоматына килеп җитәргә кушып, егерме алтынчы июньдә миңа да язу килде. Үзем белән бер атналык азык-төлек, кашык һәм кружка да алып килергә әйтелгән иде ул язуда. Димәк, әни савыкканны көтеп тормыйлар, мине дә хәзер үк алалар? Ә Рәдифкә андый язу юк. Килмәячәк тә аңар андый язу. Аның ише аксак белән нишләсеннәр? Ә мине, сипкелле, сары чәчле булсам да, алачаклар менә...

Колхозның исәп-хисап эшләрен тиз генә бүтән кешегә тапшырдым да, үзебезгә чыбык очы тиешле Хәерниса апага биштәр капчыгы әзерли торырга кушып (әни үзе булдыра алырлык түгел, ул көннәрдә бик нык өзлегеп ята иде), озын-озак уйлап тормастан, Янтыкка Сәкинә янына киттем.

Туп-туры өйләренә барып кердем. Әнисе Саҗидә исемле икәнлеген белсәм дә, үзен күргәнем юк иде әле. Бик җитез, мөлаем һәм минем әнигә караганда шактый яшь, егәрле хатын икән. Кем син, төнгә каршы нишләп йөрисең, дип тә төпченеп тормады. Сәкинә кирәк иде миңа, дигәч:

– Суга гына киткәние, хәзер кайтып җитәр, энем, утырып тор! – дип, түр якларына кертеп утыртты да үзе самовар куярга кереште.

Биш-ун минуттан Сәкинә дә кайтып керде. Заманы шундый иде бит, ни өчен килүемне Сәкинә кыяфәтемнән үк аңлап алды булса кирәк, бер дә алай аптырап калмады. Болай да алсу йөзе тагын ныграк кызарып китте дә, беркавым сүз әйтә алмыйча карап торды. Аннары мин аңа, әйдә, урамга чыгыйк әле, әйтәсе сүзем бар иде, дигәнне аңлатып ым кактым, һәм без су буена төшеп киттек.

Башта инеш буенда, болынлыкта шактый озак сөйләшеп йөрдек. Көлешкән, шаярышкан булсак та, икебез дә борчулы, сагышлы идек. Бу очрашуыбызның соңгы очрашу булырга мөмкин икәнлеген тоеп тору җаныбызны тырный. Аннары без су буендагы тал төбендә бер-беребезгә сыенышып, сүзсез генә уйланып, моңланып утырдык. Искиткеч җылы һәм якты кич иде ул. Күктә ай балкып тора, йолдызлар җемелдәшә. Янтык этләре сирәк-мирәк өреп куя, бакалар бакылдашып ала, таллар арасында кошлар чыркылдаша. Шуннан башка бернинди тавыш юк. Ә бит хәзер кайдадыр сугыш, үтереш бара. Дөнья яңгыратып туплар шартлый, бомбалар ярыла, кешеләр үлә. Иртәгәдән мин дә шул мәхшәргә китәчәкмен...

– Ничек уйлыйсың, Сәкинә, исән-сау әйләнеп кайтырга язармы икән миңа?

– Кайтырсың, Өлфәт! Кайтырга тиеш син, бәгырем! Синсез мин нишлим ди аннары?

– Әйтүем шушы, Сәкинә, алай-болай мин кайта алмасам, үлү хәбәрем килсә дә, шул хәбәрдән соң бер елсыз кияүгә чыкма!

– Юкны сөйләмә, бәгырем! Синнән башка беркем дә кирәкми миңа!

Шулай диде дә, күкрәгемә башын куеп сулкылдап елый башлады. Минем күздән дә яшь бәреп чыкты. Бераздан Сәкинә елавыннан туктады, күзләрен мөлдерәтеп миңа карады да әйтте:

– Әгәр чын-чынлап яратасың икән, калдырма мине, Өлфәт, алып кайт үзең белән!

Мин аптырап, бер мәлгә каушап калдым. Минем өчен көтелмәгән бәхет иде бу. Ахыр чиктә мин дә яшь егет бит! Минем дә бер генә тапкыр булса да сөйгәнем белән бергә булып каласым килә. Ләкин мин бу турыда аңа әйтергә кыймаган идем, күңелен рәнҗетермен, үпкәләтермен дип уйлаган идем. Инде менә ул үзе тәкъдим ясады. Нишләргә соң миңа хәзер?

– Мин әйләнеп кайта алмасам, үкенмәссеңме соң, Сәкинә? Бер төн өчен тол хатын исемен күтәреп йөрергә туры киләчәк бит сиңа!

– Булсын, Өлфәт! Теләсә нәрсә булсын. Мин барысына да риза! Ике-өч кенә, бер генә сәгать булса да синең белән булып каласым килә минем. Башка берни дә кирәк түгел миңа!

Мин ни дип әйтергә дә белмәдем. Сәкинәне кысып кочаклаган килеш, күзләренә карап, өннән чыгып утыра бирдем. Шул арада Сәкинә, әлеге сүзләрен әйткәнгә үзен үзе битәрләгән сыман итеп:

– Ярар алайса, кирәкми! –дип елап җибәрде. Аннары тиз генә сикереп торды да, битен кулы белән каплап, кайтыр якка йөгереп китте.

Мәсьәләне шул ук минутта хәл итәргә кирәк иде. Аны кызганам дип, артыннан бармыйча, мин йә шунда тал төбендә утырып калырга һәм сөйгәнемне мәңгегә югалтырга тиеш. Яисә куып җитәргә дә, син минеке, бәгырем, дип, килен итеп авылга, әни янына алып кайтырга тиеш. Мин соңгысын сайладым...

Ә иртән, сугышка китеп барышлый, авыл советына – Көрнәлегә кагылып, язылышып чыктык.

Мин кайтканчы үз авылыгызда, әнием янында яшәп торсаң да ярый, дип, мәсьәләне Сәкинәнең үз ихтыярына куйган идем. Әмма ул, минем авыру әниемне ялгыз калдырырга теләмәде, бездә – әни янында торып көтәргә булды.

**11**

Сугыш булгач, бигрәк тә разведчик кешегә, төрле чак туры килә. Егермешәр көн, берәр ай буена хат язып салырга мөмкинлек тимәгән вакытлар ла булгалады. Ләкин ник бер үпкәләп карасын Сәкинә! Киресенчә, һәр хатында мине юатып, өметләндереп яза иде. Аның хатларын уку үзе бер гомер була торган иде миңа!

Белмим, нинди изге, сабыр җан булгандыр ул. Инде әйткәнемчә, эти бөтен кием-салымны, бөтен мал-туарны сатып киткәнлектән, безнең тормыш болай да ташка үлчим генә иде бит. Шуның өстенә, мин сугышка китеп баргач, әнинең хәле тагын да авырая төшкән. Тора-бара ул бөтенләй аяктан калган, гел урын өстендә генә ята башлаган. Ләкин Сәкинә ул турыда миңа бер тапкыр да язмады. Мине борчыйсы килмәгән, терелер дип өмет иткән ул. Үз әнисе кебек итеп тәрбияләгән әнине. Чана белән тартып алып барып, район врачларына да күрсәтеп караган. Ләкин әни барыбер савыга алмаган, хәле һаман начарлана барган һәм ул кырык икенче елның унсигезенче февралендә вафат булган.

Бары шуннан соң гына Сәкинә дөресен язды миңа. Әле дә хәтеремдә, хатын менә шушы сүзләр белән тәмамлаган иде: *«Белән, бәгырем, бу хәбәрне ишетү авыр булыр сиңа. Миңа да бик читен, бик күңелсез, әни булмагач. Амбар хәтле өйдә бер башым торып калдым бит. Бернинди киңәшчем, сердәшчем юк. Әни барда кайгымны да, шатлыгымны да аның белән уртаклаша идем. Үзе эшли алмаса да, акыллы киңәшләре, тәмле сүзе белән ярдәм итә, күңелне күтәрә иде. Аннары ул миңа бик зур иптәш булды. Ә хәзер мин берүзем калдым. Үз әнием, кайт Янтыкка, Өлфәт әйләнеп кайтканчы бергә торып торырбыз, дип әйтә әйтүен. Ә мин кайтырга теләмим, өегезне ятим итеп калдырасым килми, тәрәзәләрен кадаклап китәргә кулым бармый. Ничек тә син кайтканчы түзәрмен әле, Өлфәт. Аның каравы син кайткач гөрләтеп яшәрбез. Бездән дә бәхетле кешеләр булмас ул чакта! Ә хәзергә сабыр итик. Син дә артык борчылма, нишлисең бит, терелә алмады әни. Гомере шулай кыска булгандыр инде.*

*Ярый, хәзергә сау булып тор. Дошманнарны тизрәк җиңеп кайт! Тагын бер кабат һавадагы йолдызлар санынча сиңа сәлам озатып, исән-сау кайтуыңны көтеп, Сәкинәң».*

Менә шулай итеп юатып язды ул миңа. Ә шул хатыннан соң бер-ике ай үткәч, улыбыз тууын хәбәр итеп, мине тагын да ныграк хәйранга калдырды. Син аның сабырлыгын, тыйнаклыгын гына күр әле, туган. Бер дә шапырынмыйча, гадәти нәрсә турында гына сүз баргандай итеп, *«Мин монда чишмәдән нәкъ сиңа охшаган сары чәчле, яшькелт-зәңгәр күзле бер кечкенә генә малай алып кайткан идем, Өлфәт. Киңәш ит әле, аңа нинди исем кушыйк икән? Синнән хат килгәнче исем кушмый торам. Озак көттермә, малаеңны зарыктырма, яме»* дип хат язды. Шуңарчы йөкле булуын да хәбәр итмәгән иде ул миңа. Яшьлеге, тәҗрибәсезлеге аркасындадыр инде, әллә исән-имин таба алам, әллә юк, дип, миңа язмыйча яшереп йөргән. Шундый да сабыр, шундый да түземле булырга кирәк бит, ә!

Мин малайга Ирек дип исем кушарга әйтеп яздым. Дөньяда иректән дә кадерле нәрсә юк, минемчә...

Тәки сүзендә торды Сәкинә: мин сугыштан кайтканчы безнең өйдә яшәде. Тик менә мин кайткач...

**12**

Ул көннәр исемә төшсә, йөрәгем өшеп, тыным кысылып куя. Авыр миңа ул турыда сөйләү, бик авыр, туган. Әмма бөтен эшне үзем бозып ташладым. Үзем ахмак булдым. Соңгы елларда нәселдәшлек хакында, үсемлекләргә дә, адәм балаларына да кайбер сыйфатларның нәселдән нәселгә күчүе турында бик күп язалар. Дөрес булырга тиеш ул нәрсә. Әти бик дуамал иде безнең. Аның шул гадәте миңа да күчкән булса кирәк. Югыйсә минем ул юләрлек кайдан килсен икән?..

Менә болай булды ул хәл, туган. Инде белгәнеңчә, мин сугыштан кырык алтынчы ел башында кайттым. Минем урынга калган бер яшь кенә кыз хисапчылык эшен юньләп алып бара алмагач, кырык икенче елда аның урынына Сәкинәне куйганнар һәм ул әле дә шул эшендә эшли иде. Ә Ирек инде зур, дүрт яшен тутырып килә. Кайтып кергән шәпкә ул миннән ятсынып торды. Шулай булмый хәле дә юк, чөнки ул мине гомерендә бер тапкыр да күрмәгән иде бит әле. Ләкин аның ятсынуы озакка бармады. Әнисе:

– Менә, улым, бу шул кеше, синең әтиең бит инде бу! – дип, минем фронттан җибәргән фоторәсемемне күрсәткәч, бер миңа, бер рәсемгә карап торды һәм:

– Чынлап син минем әтимени, абый? – дип сорады.

Мин:

– Әйе, улым, чынлап синең әтиең мин! – дигәч, «ура!» кычкырып, муеныма килеп асылынды. Шатлыгымнан түбәгә менеп, дөнья яңгыратып кычкыргандай булдым мин ул көнне! Андый хәлне үз башыннан кичергән кеше генә аңларга мөмкин. Тик мин берәүнең дә ул хәлгә дучар булуын теләмим. Кешеләр үз балаларын дүрт яшькә җиткәч кенә түгел, туган көннән үк күреп, үз күз алларында үстерергә тиешләр! Мин шулай дип уйлыйм.

Кайтып төшкәннең икенче көнендә үк мине туган-тумачалар, дус-ишләр кунакка дәшә башлады. Башка җирдә, белмим, ничектер, әмма бездә гадәт шундый: читтә йөреп кайткан кешене якын туганнары гына түгел, аз гына чыбык очы тиешлеләренә тикле өйләренә чакырып кунак итәләр. Борыннан килгән ул гадәт хәзер дә шулай дәвам итә...

Кайтуыма атна-ун көн үткәч, урамнан тотып алып кына булса да Рәдиф тә:

– Әйдә, Өлфәт, чәй эчеп, рәхәтләнеп бер сөйләшеп утырыйк әле! – дип, үзләренә алып керде.

Чәй эчеп чыгарбыз дип кенә алып керсә дә, әнисе пилмәнгә хәтле пешереп куйган, мәйләре дә мулдан иде. Мин моңа артык гаҗәпләнмәдем. Ник дисәң, Рәдиф кырык беренче елның сентябреннән бирле колхоз председателе булып эшли икән. Нигә аның пилмәнлек кенә рәте булмасын ди. Сугышка кадәр теләсә кем, теләсә кайчан пешерә иде бит аны. Рәдифнең әнисе Мәсрүрә апа безне якты чырай, ачык йөз белән каршылады. Килеп керүебезгә үк өстәлгә аш-суын китереп утыртты. Ә үзе, барып кайтасы җирем барые, дигән булып, каядыр чыгып китте.

Башта без тыныч кына, төрле вак-төяк нәрсәләр хакында гына сөйләшеп утырдык. Стаканнарны күтәреп куйгач, икебезнең дә телләребез чишелеп китте. Рәдиф минем орденнарны, медальләрне берәм-берәм тотып карады да:

– Биш ел буе ут эчендә йөрүең бушка китмәгән икән, Өлфәт дус, шәп! – дип мактап алды. Бераз нидер уйланып утыргач, тагын сүз башлады: – Ә мин менә аяк аркасында сугышка бара алмадым. Ну мин аңа әнә очы хәтле дә үкенмим. Канса кансов, бөтен кешегә дә мылтык тотып сугышырга димәгән бит! Мылтыксыз сугышучылар да бик күп кирәк булды бу сугышта. Мин үзем, мәсәлән, мылтыксыз сугыштым. Кайберләрен, башкаларга сабак булсын дип, хәтта утыртырга да туры килде. Ну миңа барыбер орден бирмәделәр. Нихәтле тырышып та ярап булмады халыкка. Бик яхшы сизеп торам: быелгы отчет-сайлау җыелышында прсидәтеллектән алырга җыеналар мине. Менә сиңа орден!

– Күрәсең, орденлык эш майтара алмагансың инде, Рәдиф. Бер дә элә-танагы калмаган бит, малай, хуҗалыкның: кая карасаң да, ачык та тишек, нигә тотынсаң, шул юк. Хәтта эшкә ярарлык һәр атка җигеп йөрерлек берәр чана да калмаган, диләр бит.

Рәдиф, чыраен сытып, кашларын җыерды. Кабаланып стаканындагы аракысын эчеп куйды. Аннары ни өчендер үзалдына елмайды да:

– Дөрес, Өлфәт, бик дөрес әйткәннәр! – диде. – Тагын да дөресрәк итеп әйткәндә, ике атка бер чана да калмады безнең хәзер.

– Нигә алай булды соң ул, Рәдиф?

– Нигәме?.. Анысы турында мин сиңа отчет биреп тора алмыйм инде. Отчетлардан районга бирә-бирә дә гарык булып беткән. Нигә икәнен үзең эшли башлагач чамаларсың әле. Минем урынга сине куймак булалар, ди бит!

– Кемнәр?

– Кем булсын, халык, әлбәттә!

– Шулаймыни? Ә миңа әле бу турыда беркем бер сүз әйткәне юк.

– Әйтерләр әле, җыелышта әйтерләр. Ничек соң, сайласалар, эшләр исәбең бармы?

– Ни дип тә әйтә алмыйм, Рәдиф. Чөнки минем бу турыда синнән беренче ишетүем. Ә синең үзеңнең эшлисең киләме соң?

– Дөресен генә әйткәндә, килә, Өлфәт, бик килә! Бу урынымнан төшеп, бүтән эштә эшләүне мин күз алдыма да китерә алмыйм. Әмма белеп торам: очырачаклар мине прсидәтеллектән... Ә син әле, уйлаганым юк, дисең алайса? Уйларга кирәк, Өлфәт дус, бик кирәк сиңа бу турыда уйларга!

– Нигә тумаган тайның билен сындырып, юкка баш ватарга ди әле миңа?

– Тайны инде туган дип исәплә, ә билен сындыру мәсьәләсендә мин сиңа шуны әйтергә тиешмен: сындырсаң, минем билне, үзеңнең яшьтәшеңнең, дустыңның билен сындырачаксың, Өлфәт!

– Моны ничек аңларга инде? Куркытып куюмы, әллә ниндидер үтенечме?

– Теләсәң ничек аңла, ләкин аңла, Өлфәт! Аң-ла-а!

Шуннан соң миңа ризыкның тәме, табынның яме бетте. Чөнки аңлашылды: Рәдиф мине кисәтеп кую өчен чакырган икән. Хәзер инде сүз озайтып утырудан барыбер мәгънә чыкмаслыгын сизенеп, сый-хөрмәте өчен Рәдифкә рәхмәт әйттем дә өйгә кайтырга кузгалдым. «Аңла!» дигәннән соң терсәге белән өстәлгә таянып, башын иеп уйга калган Рәдиф мин ишекләрен ачып чыгып барганда, кинәт сикереп торды да тиле кеше сыман ямьсез итеп шаркылдап көлә башлады. Мин, аптырап, ачкан ишекне япмыйча тукталып калдым:

– Нишлисең, Рәдиф?

Минем сорауны бөтенләй ишетмәгәндәй, ул тагын берәр минут чамасы шулай шаркылдап торды. Аннары бераз тыйлыга төште дә:

– Яп әле ишекне дә кил монда! – диде.

Мин янына килгәч, күзләрен елтыратып, бик зур сер әйткән кешедәй колагыма үрелеп пышылдарга тотынды:

– Үземнән үзем көләм мин, Өлфәт дус! Соң инде сиңа шул сүзләрне әйтеп ялынып торырга тиешле кешемени мин? Син бит минем үтенечне барыбер колагыңа да алмаячаксың. Канса кансов, минем урынга сине булмаса, башка кешене куячаклар, ә мине барыбер чөеп ыргытачаклар быел. Әйдә, чөйсәләр чөйсеннәр инде, үкенерлек түгел: дүрт елдан артык дөньясын шаулатып яшәдем! Башкасы турында әйткән дә юк, мин эчкән аракыны җыеп барсаң, анысы гына да кечерәк бер күл булыр иде. И «теге» якның да кимен куймадым. Дус итеп сиңа гына әйтәм, яшь, чибәр хатын-кызларга да кулым тигәләде!

– Булмагандыр ла?..

– Ә? Булмагандыр дисеңме?.. Ха-ха-ха-ха! Ул миңа ышанмый торган була бит әле! Әгәр алай шикләнәсең икән, кайткач, Сәкинәңнән сора әнә.

– Бу ни дигән сүз, Рәдиф? Минем Сәкинә белән дә булдым дип әйтергә теләвең түгелдер бит?

Рәдиф мыскыллы елмаеп куйды:

– Бигрәк беркатлы кеше инде син, Өлфәт! Күңелеңә авыр алма, малай...

Башта артык исем китмичә утырган булсам да, тегенең соңгы сүзләреннән соң минем эчкә дә корт керде бит, туган. Башымнан хәтта, әллә, сикереп торып, ботарлап ташлыйм микән үзен, дигән уй да йөгереп үтте. Ләкин түземемне җыеп тыелып калдым һәм тагын бер мәртәбә:

– Алдашмыйсыңмы, малай? Шушы сүзләреңне расларлык берәр дәлилең бармы? – дип сорадым.

Ул тагын кычкырып көлеп куйды да:

– Андый эшләрнең дәлиле каламыни, юләр! – диде. – Дәлилем юк, ә менә шаһит кирәк булса – бар, анысы булыр!

– Кем ул?

Рәдиф җавап бирергә ашыкмады, никтер уйга калып, маңгаен ышкып тора башлады.

– Мин җавап көтәм, Рәдиф, кем ул шаһит? – дидем мин, тәкатьсезләнеп.

– Син көтәсең дә бит, ә мин әйтергә теләмәсәм?

– «А»сын әйткән икәнсең, «Б»сын да әйт! Йә сүзләрең ялган икәнлеген таны да хәзер үк гафу үтен! Югыйсә...

– Ул кадәр үк чапаланма син! – диде Рәдиф, минем кыза башлавыма бер дә алай исе китмичә. – Әгәр синең өчен ул кеше бик алай важный икән, әйтәм алайса: Хафиз карттан сорарга мужыш әнә!

– Иртәгә аек баштан да шушы сүзләреңне кабатларсыңмы, Рәдиф?

– Ә хәзер син мине исерек дип уйлыйсыңмы? Икебезгә бер яртыны да эчеп бетермәдек бит әле без. Чепуха бит бу минем өчен! Берүземә бер яртыдан да кызмача гына булып йөрим мин. Каяле...

Рәдиф шкафларындагы шешәгә үрелә башлагач, мин түзеп тора алмадым.

– Җитте, агайне, бик шәп сыйладың! – дидем дә, мәсьәләне бүген үк ачыкламакчы булып, Хафиз картларга киттем. Ләкин ул өйдә юк иде.

– Атна башында ук районда торучы малаебызга кунакка дип киткәние, шуннан бирле кайтканы юк әле, олан, – диде карчыгы.

Үзең дә чамалыйсыңдыр, туган, минем кәефнең рәте-чираты сүтелгән иде инде. Рәдиф сүзләренә бөтенләй үк ышанып җитмәгән идем җитүен. Шулай да Сәкинәм белән башка көннәрдәгечә якын итеп, үз итеп сөйләшү булмады. Үзем никадәр сиздермәскә теләсәм дә, Сәкинә барыбер минем хәлне сизенде.

– Нишләдең син, Өлфәт? Нигә болай соңга калдың, кайда шушылай алыштырып җибәрделәр сине? – диде ул, бик нык хәвефләнеп.

– Мин бүген Рәдифләрдә булдым, аракы эчтек, сезнең ничек итеп сугыш елларында бергәләп колхозны җитәкләп алып баруыгыз турында сөйләшеп утырдык! – дидем мин. «Бергәләп» сүзенә басым ясап әйттем. Аннары, нишләр икән дип, Сәкинәнең йөзенә карадым. Берәр төрле кырын эше булган булса, кинәт коелып төшәргә тиеш иде ул.

Коелып ук төшмәде Сәкинә, әмма секунд эчендә дерт итеп, сискәнеп-кызарып китте. Тик ул үзен бик тиз кулга алды һәм, бер дә алай шаккатмыйча гына:

– Күңелгә килгән нәрсә алга килми калмый шул. Болай соңгаргач, күңелем шикләнгән иде аны, тәки шул аксак шайтан янында булгансың икән! – диде дә кече якка кереп китте.

Шуннан ары ул да дәшмәде, мин дә сүз озайтып тормадым. Минем Рәдифләрдә булганны ишеткәч дерт итеп китсә дә һәм аның шул дерт итеп китүе Рәдиф сүзләрен раслау сыман булып тоелса да, Хафиз карт белән сөйләшеп, мәсьәләне тулысынча ачыкламыйча, эшне зурга җибәрмәскә булдым.

Ул төнне мин керфек тә какмадым, туган. Колагымда һаман Рәдифнең «күңеленә авыр алма...» дигән сүзләре яңгырап торды, күз алдымнан мең кабат Сәкинәнең миңа таныш булган тормышы һәм гадәт-холыклары чагылып үтте. Ләкин аны гаепләрлек бер генә нәрсә дә юк иде минем күңелдә. Димәк, булмаган андый нәрсә. Димәк, шикләнергә урын юк, Сәкинә андый кабахәтлеккә бармагандыр, Рәдиф ялган сөйлидер, дип, үземне үзем тынычландырырга никадәр тырышсам да, шик-шөбһәне тәки башымнан куып чыгара алмадым. Шуның өстенә, шомлы күңелне тагын да шомландырып, төн буе җил улады, буран котырды. Аптырагач, мин санарга керештем. Ләкин аның да файдасы тимәде. Меңгә кадәр санап та йокыга китә алмагач, әле таң беленә генә башлаган булса да, торып киендем дә башта капка төпләрен көрәдем, аннары мал-туар асларын җыештырып, аларның ашарларына салдым. Алай да вакыт бик акрын үткәч, бабай заманыннан ук калган һәм гел ботактан гына торган утын түмәркәләрен ярырга тотындым. Ә колакта гел Рәдиф сүзләре яңгырый һәм мин Хафиз карт белән булачак сөйләшүне күз алдыма китерергә тырыша идем.

Хафиз карт... Үзебездә генә түгел, тирә-як авылларда да бик мөхтәрәм, бик гадел кеше санала иде ул. Туган-тумачалары бәла-казага юлыккан адәмнәр, әҗерен үзе сорап алмый, ни бирсәң шуңа риза, дип, Коръән яки ясин чыгартырга гел шул Хафиз абзыйны чакыра торганнар иде.

Шулай төрлечә уйланып һәм эш белән мавыгып, ничек кирәк алай сәгать унберләрне җиткердем дә, кайтып җитмәде микән дип, тагын Хафиз картларга бардым. Юк, кайтмаган иде әле. Әмма карчыгы Мәрьямниса абыстай бу юлы мине шактый тынычландырып җибәрде:

– Бүген базар көн бит, олан. Шәт, район базарына китүчеләр булмый калмагандыр әле, шулар атына утырып кайтыр дип торам мин аны, – диде.

Вакытны ничек үткәрергә, җанымны кая куярга белмичә аптырагач, өйгә кайтып, әмма өйгә кереп тормыйча гына, егет чактан калган чаңгыларны тезмәдән эзләп табып кидем дә урманга киттем. Ара-тирә ишетелеп куйган тукран тукылдатуларын искә алмаганда, кышкы урманда сихри тынлык хөкем сөрә иде.

Яшел ботакларына ак кар кунган мәһабәт чыршыларга, зифа каеннарга, инде кышның яртысы үтеп барса да, яфраклары әле һаман коелып бетмәгән имәннәргә, кызлар муенындагы мәрҗән шикелле булып, сирәк-мирәк очрап куйган кып-кызыл миләшләргә сокланып карап йөри торгач, үзем дә сизмәстән, сабан туе аланына килеп чыкканмын. Ак юрганга төренеп йоклап яткан ул алан кышын да гаҗәеп матур иде. Аның өстендәге шул ак юрганын ачып карасаң, хәзер дә бөтен тирә-якка хуш ис – җиләк һәм чәчәкләр исе таралыр төсле иде...

Заманында Сәкинә белән менә шушы аланда очрашып, әнә теге – кояш чыгышына таба киткән сукмак буйлап әчкәре кереп, чәчәкләр җыеп йөргән идек бит инде без. Һәм ул чакларда дөнья гел шулай чәчәктән генә торыр, без һәрвакыт шулай шат һәм бәхетле булырбыз кебек иде... Ә менә хәзер... Бүген кич ни буласын әйтүе дә кыен... Әй, бу Рәдифне дә әйтер идем инде... Нигә гел генә миңа килеп кагыла соң әле аның хикмәтләре?..

Мин урманнан әйләнеп чыкканда, Хафиз карт инде кайткан, иләмсез зур гәүдәсе белән бөтен өйне тутырып, чәй эчеп утыра иде. Тиз генә урыныннан кубып, яныма килеп күреште дә:

– Әйдә, батыр, әйдә, мактап җөрисең икән әле, әзер табынга туры килдең! – дип, өстемне салырга кыстый башлады. Чәйләр эчеп үк утырырга һич тә ниятем булмаса да, карт: – Аштан олы булмыйлар, наный, ярамый алай! Аннары әллә кемгә килеп кермәгән ләбаса, сөннәт бабаң лабаса мин синең! – дип, авыз ачарга да ирек бирмичә кыстый башлагач, карышып торырга мөмкин булмады. Шул ук вакытта табын янында Сәкинә белән Рәдиф мәсьәләсен ачыкларга да ничектер җайлырак булыр төсле тоелган иде. Тик менә карчыгы Мәрьямниса абыстай алдында андый четерекле мәсьәләне ничек кузгатып җибәрермен дип кенә борчылган идем. Әллә чыннан да изге кеше булып, шул уйларымны сизенеп алды инде: мин шинелемне сала торган арада, Хафиз карт Мәрьямниса абыстайны тиз генә кече якка алып кереп, аңа нидер пышылдады да, тегесе шундук киенеп каядыр чыгып китте.

Табын янына килеп утыруга, Хафиз картның иңенә кулымны куеп, күзләренә карадым да:

– Бер дә алдашмыйча гына, дөп-дөресен генә әйт әле, сөннәт бабай: мин сугышта чакта минем Сәкинә Рәдиф белән чуалдымы-юкмы? – дидем.

Хафиз карт, минем сүзне бөтенләй ишетмәгән сыман, башта иплəп кенә, өреп суыта-суыта гына бер стакан чәй эчте. Чәен эчеп бетергәч тә, күзләрен самовар борынына текәп, байтак ара дәшми утырды. Бары шуннан соң гына:

– Болай үзең шикләнеп кенә бирдеңме бу сөальне, наный? Әллә берәрсеннән берәр төрле сүз ишетепме? – диде.

– Үземдә бернинди дә шик туганы юк иде, кеше әйтте, Хафиз абзый. Әмма мин бүтән беркем сүзенә дә ышанмыйм, мин бары тик синең сүзеңә генә ышаначакмын!

Хафиз карт никтер каушап калгандай булды: башта моңарчы кып-кызыл булган йөзе агарып китте, аннары уң кашы тартышып куйды. Ләкин бу хәл озакка бармады, ул миңа болай дип җавап бирде:

– Гомеремдә бер генә мәртәбә нахак сүз әйткәнем булса да, тәвәккәлләп бу юлы тагын бер тапкыр әйтерием, «җук» диярием мин сиңа, наный! Әмма ләкин җитмешкә җитеп әйтмәгән нахак сүзне бер бүген генә әйтә алмыйм инде. Хак сүз әйткәннәр сиңа, наный: чуалды Сәкинәң Рәдиф белән, чуалганнарын үз күзем белән күрдем.

– Кайда һәм кайчан күрдең? – дидем мин, Хафиз картның авызына керердәй булып.

– Кая, алай ук сабырсызланма әле! – диде ул, йөзен читкә борып. Аннары бик гадәти хәбәр җиткергәндәй иплəп кенә: – Нигә миңа алай ямьсез карыйсың? Мин алар артыннан шымчылык итеп йөрмәгән ләбаса! Кырык өченче елның җәендә урманда зелпе тамыры җыеп йөргәндә ялгыш кына өсләренә килеп чыктым, наный, – диде.

Шулай итеп, минем соңгы өметем дә өзелде. Кинәт күз алларым караңгыланып китте һәм аяк астымдагы җир чайкалып куйгандай булды. Шактый вакыт телсез-өнсез калып торганнан соң, кинәт бер явыз ерткычка әйләндем дә, бар ачуымны Сәкинәдән алырга булып, өйгә кайтып киттем.

Мин кайтып кергәндә Сәкинә улыбыз Иректе сөеп, аның белән сөйләшеп утыра иде. Мин өстемне чишенә башлагач:

– Менә, улым, безгә әйтмичә генә иртүк каядыр чыгып югалган әтиебез дә әйләнеп кайткан! Әйдәле, сорыйк әле үзеннән: кайда булды икән, ниләр эшләп йөрде икән? Яле, бер үбеп ал әле үзен, безгә әйтмичә шулай озак йөреп кайткан өчен! – дип көлә-көлә сөйләнеп, Иректе күтәреп яныма килде. Килде дә шундук өркеп-аптырап читкә тайпылды. – Бәй, нишләдең син, Өлфәт? – диде ул, минем сөзәргә җыенган үгез кебек каш астымнан карап торуыма шаккатып. – Йөзеңнең бөтен нуры качкан бит синең!

Бер сүз дә дәшмәдем. Бөтен ачуымны берьюлы аңлатып бирердәй сүз таба алмадым. Ни әйтсәм дә, аз булыр төсле тоелды. Шуңа дәшмәскә булдым. Кайчакта дәшмичә орышу да сүз белән ачуланудан ныграк тәэсир итә бит кешегә. Сәкинәгә дә шулай тәэсир итте:

– Йә инде, газаплама, Өлфәт, – диде ул, тагын да ныграк хафага төшеп. – Әйт инде, ичмаса, нигә болай усалланып кайттың? Берәрсе белән бәйләнештеңме әллә?

– Кит каршымнан! – дидем мин, бар көчемә акырып. – Чекерәеп торма, кара елан!

Башта Ирек куркып елап җибәрде, аннары Сәкинәнең күзләреннән мөлдерәп яшь ага башлады. Миңа да ничектер оят, уңайсыз булып китте. Хәтта, әллә икесен дә кочып алып юатыйм микән, дигән уй да башымнан йөгереп үтте. Ләкин бу бик аз вакыт эчендә, секундның бер өлешендә генә булып алды. Мин яңадан ярсыган арысланга әвереледем. Иректе елавыннан туктатырга азапланган Сәкинә каршына килеп, баланы тагын куркытмас өчен, акрын, әмма нәфрәтле итеп:

– Йә, сөйләп күрсәт әле: мин юкта Рәдиф белән ничек типтердең? – дидем.

Бу сүзләремнән соң Сәкинә тәмам өнсез калыр дип көткән идем. Ә ул аз гына гаҗәпсенеп, сөйкемле кара күзләрен миңа текәп торды да, кинәт ачылып китеп, көлеп җибәрде һәм болай диде:

– Төсең-битең бик куркыныч булып кайтып кергәч, әллә чыннан да берәр төрле хәвефле эш булганмы дип торам. Баксаң-күрсәң, бөтенләй юк өчен хәсрәтләнеп йөрисең икән, Өлфәт! Нигә тузга язмаган нәрсәгә ышанып йөрисең, көнче күбәләгем! Арысландай ирем була торып, шул йолкыш белән бәйләнергә башыма тай типмәгән ич минем!

Мин аның бу сүзләрен игътибарга алыр дәрәҗәдән узган идем инде.

– Әһә! Син әле шулаймы? Авызыңны ыржайтып көлеп торасыңмы? – дип алып торып киттем шуннан, алып торып киттем, туган, чыдасаң чыда, чыдамасаң – юк!

Сәкинә, җан кисәгем, шунда да артык хафаланмады. Хәтта мин, тәмам чыгырымнан чыгып:

– Бар, үзең дә, малаең да хәзер үк күземнән югалыгыз! Минем өйдә бүтән эзегез булмасын! – дип акырган чагымда да сабырлыгын җуймады ул. Шунда да иплəп кенә җайларга-көйләргә тырышып карады мине:

– Алай ук тузынма әле, Өлфәт! Андый ниятем булса, башта ук Рәдиф белән йөргән булыр идем. Үзең беләсең бит, Өлфәт җаным, кыз чагымда ук сиңа кадәр ул йөрде ич минем арттан. Яшермим, син сугышка киткәч тә бер тапкыр сүз катып караган иде ул. Ләкин мин аны якын да китермәдем. «Тагын шушы турыда авыз ачасы булсаң, бөтен районга фаш итәм мин сине!» – дигәч, тирәмә дә килгәне

булмады. Соң, үзең уйлап кара инде: сиңа хыянәт итәрлек булсам, башта авыру әниең белән, аннары яшь балам белән чиләнеп, шушы өйдә шушылай ялгыз яшәр идеммени мин? Әнием янына, үзебезнең авылга кайтып китмәс идеммени?

– Ярый, анысы шулай да булсын ди. Ә нигә соң шул Рәдифнең сүзләрен гомерендә бер мәртәбә дә ялган сөйләмәгән Хафиз карт раслап тора икән? Ул гадел картның миндә нинди ачуы бар икән, ә? Син миңа шушы сорауга җавап бир! – дидем мин, бу дәлилем белән Сәкинәне тәмам фаш итмәкче булып.

Ләкин ул моңа да артык шаккатмады. Бары:

– Инде шаһитын да тапканмыни? Әйт әле, ичмасам, Хафиз картны ни дип котыртты икән, анысы нәрсәләр сөйләде? – дип кенә сорады.

– Оныткан булсаң, исеңә төшерәм алайса, – дидем мин, аның һаман шулай киреләнеп, танып азаплануына җен ачуларым чыгып. – Кырык өченче елны урманда зелпе тамыры җыеп йөргәндә өстегезгә килеп чыккан ул сезнең! Хәтерлисеңме?

Сәкинә бер сүз дә әйтмәде. Ул торараштай катып калган иде.

– Хәтерлисеңме? – дип акырдым мин, шартлап ярылыр хәлгә җитеп. – Хәтереңә төшерә алмасаң, әйдә, Хафиз абзыйның өенә барып, тагын бер кат сорашыйк! Ул барысын да аермачык итеп аңлатып бирер.

Түземлелекнең дә бер чиге була торгандыр, ахрысы. Моңарчы бер дә ачуланмаска, ничек тә миңа мәсьәләне аңлатырга тырышып азапланган Сәкинәм, соңгы сүзләремне ишеткәч:

– Әй Раббым, бар икән күрәсе көннәрем! – диде дә кинәт сыгылып төшеп еларга тотынды. Аңа кушылып, моңарчы әнисе алдында утырган Ирек тә шыңшый башлады.

Мин Ирек бераз тынычланганны көтеп тордым да, ниһаять, мәсьәлә ачыкланган һәм мин җиңүче булып калган сыман итеп, теш арасыннан гына:

– Күрәсе көннәреңне хәзер түгел, алданрак уйлыйлар аны! – дидем.

Шуннан соң да берничә минут елап утырганнан ары, Сәкинә кинәт горур гына итеп башын күтәрде дә күз яшьләрен сөртеп алды һәм, миңа туп-туры карап:

– Теләсәң нәрсә уйла, Өлфәт, ләкин минем синең каршыңда тырнак очы кадәр дә гаебем юк. Үтерсәң дә, синең ул Хафиз картың каршына бармыйм мин. Дөресен әйтмәячәген белеп торам мин аның! – диде.

– Булмаганны сөйләп торма – барыбер ышандыра алмассың! Бар, яхшы чакта күземнән югалыгыз! Үзең дә, малаең да!

– Ә мин сиңа аны елап сорасаң да бирәчәк түгел! – диде дә Сәкинә башта Ирекне киендерде. Аннары үзе киенде һәм: – Ярый, Өлфәт, хуш! Шушы сүзләреңне ишетер өчен биш елга якын көтеп торганмын икән мин сине, рәхмәт! – диде дә малайны күтәреп чыгып китте.

Хатын-кыздан болай ансат кына котылып булмый торгандыр ул, мин бераз суынганчы күршегә генә кереп киткәндер, берәр сәгатьтән үк әйләнеп чыгарлар әле, дип уйлаган идем. Инде күз бәйләнә башлаган булуга да карамастан, Сәкинә Ирекне күтәреп Янтыкка, әнисе янына ук кайтып киткән булып чыкты. Мин артларыннан бармадым. Болай шома гына кайтып киткән икән, димәк, үз хәлен үзе белгәндер, гаебе булмаса, алай тиз генә бирешмәс иде, дип уйладым. Шуңа бармадым. Дию пәрие шикелле, өйдә берүзем яши башладым. Күрше-күләннәр, дус-ишләр килеп тә, юләрләнеп йөрмә, бар, алып кайт, дип үгетләп караганнар иде. Ләкин берсен дә тыңламадым, чыгымчы ат шикелле терәлдем дә каттым...

Сәкинә киткәнгә өч атна тулган көнне колхозның отчет-сайлау җыелышы булды. Рәдифне председательлектән азат итеп, аның урынына мине сайладылар. Аны Сәкинә урынына хисапчы итеп куймакчылар иде дә, мин риза булмадым.

– Рәдифне хисапчы итәсе булсагыз, мин председательлектән баш тартам, иптәшләр! – дигәч, килештеләр.

Аксаклыгын искә алып, аны ферма мөдире итеп куйдылар. Анысына каршы килмәдем.

Шулай итеп, без бер казанда кайный башладык. Гөнаһсы кирәкми, ферма мөдире вазифасын әйбәт кенә үтәргә тотынды Рәдиф. Эчүен дә киметте. Барлы-юклы бер ай эчендә фермадагы хәлләрне шактый гына җайга сала башлады. Ә миңа мине аның урынына председатель итеп куйганнан соң үзенең тар күңелендә туган яман көнчелеген тәки җиңә алмаган икән ул. Инде әйткәнемчә, атларга фураж ашатканны да районга ул җиткергән булып чыкты.

**13**

Райкомда шелтә биреп кайтарганнан соң, берәр вәкил җибәреп, кәнүшнигә ташып куйган солыны үлчәп амбарга салдыртырлар дип көткән идем. Ләкин, ни хикмәттер, беркем дә килмәде. Солы хакында да бүтән сүз кузгаткан кеше булмады. Беткән баш беткән инде, мин дөньяда иң кадерле кешеләремне – улым белән Сәкинәмне югалттым, шуннан да артык югалту булырга мөмкин түгел, ни эшләтсәләр дә

эшләтерләр дип, тагын шактый солы суктырып куйдым һәм атларга көн саен дүртәр кило солы ашата башладык...

Шулай итеп, безнең атлар язгы чәчүгә чыкканда шактый көр иде. Эшең уң булганда, «мин» дип мактанып алырга да ярый, дип, ялгышмасам, Каюм Насыйри әйткән бугай. Миңа да бу урында әзрәк мактанып алырга ярый торгандыр.

Ул елны районда язгы чәчүне иң алдан төгәлләгән колхоз безнең «Чулпан» булды. Бик алай зурдан кубып булмаса да (чөнки минем өстә шелтә тора бит әле), район газетасына да язып чыктылар.

Чәчүләр беткәч, бар халыкны кушып, сугыш елларында түгелмичә яткан ферма тересләрен түгә башладык. Яңа ат абзарын төзү өчен саман кирпеч сугарга тотындык. Шул арада печән өсте дә килеп җитте. Аны әрәм-шәрәм итмичә җыеп алырга кирәк иде. Ә ул ансат эш түгел. Искәртеп киткән идем бугай инде, безнең колхоз җирендә бер гектар да печәнлек болын юк. Печәнлегебез авылдан утыз километрда безнең. Кама уртасындагы бер утрауда. Шунлыктан анда көн саен барып-кайтып йөрү мөмкин түгел. Бер баргач, печәнне чабып-өеп бетергәнче шунда торырга туры килә. Шулай ук колхозчыларның да барысын җибәрә алмыйсың. Ялгызакларны, мәсәлән, ничек итеп йорт-җирен калдырып җибәрмәк кирәк? Карт-корыны җибәрүдән фәтва юк. Печән чабу – авыр эш. Аны теләсә кем булдыра алмый. Җитмәсә, авылның ныклап эшләрдәй ир-атлары да бармак белән генә санарлык. Күбесе сугыштан кайта алмыйча ятып калды...

Бик тырышканнан соң да әле печәнгә барырдай нибары уникe хатын һәм өч бөртек ир заты җыелды. Ә чабасы печәнебез илле җиде гектар! Печән чапкычыбыз да юк ичмаса. Барын бар ул, ләкин ватык. Ни эзләп тә һичкайдан запчасть таба алмадым.

Уйладым-уйладым да, әлеге уникe хатын-кызны һәм өч бөртек ирне ияртеп, шул халыкның барысына бер атнага җитәрлек азык-төлек төяп, болынга үзем киттем. Халыкка ышанмаудан түгел. Халык бик гадел, эшчән безнең. Ләкин, сынаганым бар, «хуҗа» үзе эшләгәндә, эш бөтенләй башкача, яхшырак бара инде ул.

Сугышка кадәр, баһадирдай ир-егетләр бар вакытта, ул илле җиде гектар болынны дүрт-биш көн эчендә егып сала торганнар иде. Ә бу ел без бер атна маташып та нибары егерме өч гектарын гына чаба алдык. Бердән, печәне бик калын, эченә керсә, ат күренми. Икенчедән, ни әйтсәң дә, печән чабу хатын-кыз эше түгел бит инде ул. Тагын бер хикмәте бар: ашауның юне юк. Дөрес, токмачлы куе ашын туйганчы ашарга була, икмәге дә бирелә. Әмма печән чапкан кешегә алар гына әллә ни зур куәт кертә алмый шул. Шулай булгач, кешеләрне куырып, ашыктырып та булмый.

Тиешле көнне безгә тагын бер атналык азык китерделәр. Ул көн үзенә күрә бер бәйрәм шикелле булды. Колхоздан җибәргән ризыклар өстенә өйдә калган туган-тумачалары печәнчеләрнең кайсына җиләк, кайсына каймак-май, кайсына чәй әйберләре җибәргәннәр иде. Ә миңа бернәрсә юк. Сәкинәм булса, ул да берәр әйбер җибәргән булыр иде дә соң, ни хәл итәсең...

Бик кыен булды миңа ул көнне. Күңелем тулып, күземә яшьләр килде. Әйбер килмәгәнгә түгел! Печәнчеләр мине үземә җибәргәннән дә болайрак сыйлады ул көнне. Ялгызлык, таянычым, көтәр кешем булмау өзгәләде күңелемне. Ашым – аш, эшем эш булмады.

Безгә азык алып килгән кеше кайтырга җыена башлагач, әйтәсе сүзем барые сиңа, дип, Галим абзый мине читкәрәк алып китте дә:

– Теләсәң нишлә, энем, болай булса, бу печәнне уракка төшкәнче майтарып чыга алмыйбыз без! – диде.

– Ник алай дисең, Галим абзый?

– Ник икәне күз алдында бит, Өлфәт энем: тагын бер грамм да ит алып килмәгәннәр ләбаса! Ә син үгез суеп китерәләр, дип әйткәниең!

Әйе, печән чаба башлаган көнне ашның «коры» икәнлеген күргәч, сугышка кадәр печәнчеләргә көненә берәр кадак ит ашата торганнарые, хәзер андый гадәт юкмыни, председатель, дип, бер теленә шайтан төкергәне, уенын-чынын бергә кушып, миңа төрттереп куйган иде. Ә мин, шаярып:

– Гафу итегез инде, туганнар, онытып җибәргәнмен шул. Юлга кузгалып киткәндә генә искә төште ул нәрсә. Әмма артык хафаланмагыз, алдагы атнада алып килерләр, колхозның нәсел үгезен суеп китерергә кушып киттем! – дип җавап биргән идем. Галим абзыйның шул сүзне искә төшерүе иде.

– Уйнап кына әйткән идем бит мин аны, Галим абзый, – дидем мин, түзә алмыйча көлеп җибәреп. – Нәсел үгезен суярга ярыймы соң инде? Сыерларыгыз кысыр калса, үзегез үк мине каргаячаксыз бит аннары!

Ләкин Галим абзыйның бер дә исе китмәде:

– Ә безгә ни әбизәтелне үгез, безгә тана ите дә ярый, энем!

– Яравын ярар да ул, Галим абзый, ләкин барысы да исәптә бит алар. Бөтен ил буенча терлек арттыру өчен көрәш барган вакытта карап торган уналты баш тананың да берсен суйсак, колагымнан асып куймасларлармы икән соң мине?

– Ә син асмый торган итеп эшлә!

– Алай итеп буламы икән соң?

– Була, энем Өлфәт, бик була! Тик әзрәк башыңны эшләтергә генә кирәк.

– Мәсәлән?

– Әйтик болай: безнең авылның көтүе иртә-кич авыл буендагы күпер аша үтеп йөриме?

– Йөри, шуннан?

– Шуннан шулай: күпердән чыкканда, такта арасына кысылып, берәр тананың аягы сынарга мөмкинме?

– Мөмкинен мөмкин дә, тик моңарчы андый хәлнең булганы юк ич әле.

– Булмаса – булыр! Менә болай тора эш, энем: давай, син миңа шушы безгә ризык китергән атка утырып кайтып килергә рөхсәт ит әле, яме? Калган ягын мин үзем чамалармын аның. Хәзер бер тананы кызганмасак, кышын йөзе белән кайтачак ул!

Бер уйлаганда, Галим абзый сүзендә дә хаклык юк түгел. Дөрес сайрый ул: печәнчеләрне арурак ашатып, печәнне яңгырлар киткәнче, ныклап торып урак урырга керешкәнче чабып-өеп кайтсак, бик шәп булыр иде! Узган кыштагы шикелле, колхоз терлекләренә нәрсә ашатыйк икән, дип баш ватып тормас идек аннары. Ләкин...

– Бернинди законга да сыя торган эш түгел бит бу, Галим абзый!

– Сыймаса – сыяр, син һич кенә дә аптырама аның өчен! – диде Галим абзый, гел үз сүзен куәтләп. – Сыйдырырбыз аны, сыя торган итеп эшләрбез. Закун гына түгел, шайтан үзе дә бәйләнә алмаслык итеп эшлим мин аны. Менә шул: Галим абыең әйткәние диярсең, эшлим. Булдымы?

Мин «юк, Галим абзый, ярамас ул алай! Тиктомалга кайтып китүеңә печәнчеләр дә гаҗәпләнер» дип әйтмәкче булып авызымны ачкан идем, әмма яшь чагында читтә йөреп шомарып беткән һәм шул шомалыгы, үткенлеге, тәвәккәллеге аркасында «Әйтсә Эшли» кушаматы алган Галим абзый мине тыңлап тормады. Кинәт сыгылып төшеп, эчен тотты да инде кайтып китәргә торган азык-төлек китерүченең арбасына барып ауды.

– Әйдә, сеңлем, ку тизрәк атыңны! Үләм ату, эчем бик каты авырта! Һич тә тәкатем юк, әйдә, районд бүлнисенә калдыра китәрсең мине!

Ул моны шундый илереп, чын авыру кеше сыман итеп әйтте, хәтта аны мин үзем дә кызганып куйдым. Шаярма, Галим абзый, төш арбадан, дияргә теләсәм дә, телем әйләнмәде. Ул арада алар атларын чаптырып китеп тә бардылар.

**14**

Тәки үзенекен итте Галим абзый. Икенче көнне, төш авышуга ук, ит төяп килеп җитте. Ит исен сизгәч, печәнчеләрнең ничек куанышканын күрсәң иде син, туган! «Ура!» кычкырып, һавага чөя-чөя, кочаклап үбә-үбә рәхмәт укыдылар үзенә. Әле кичә генә үләр чиккә җитеп авырып кайтып китүе турында бөтенләй искә алучы да булмады. Бары тик кичен, ит ашап кикереп куйганнан соң, чая телле Маһисәрвәр апа гына, кинәт бик зур ачыш ясаган кешедәй итеп:

– Бу ничек болай булды суң әле, Галим, пәрәми: син кичә, бик борсаланып, бүлнискә барам, дип кайтып киткәниең лəбаса, безгә ит китерәселәрен сизгәч, эчең төзәлде дәмени? – дип сорап куйды.

Әмма Әйтсә Эшли бу юлы да югалып калмады:

– Сиңа көлке, тишек борын! – диде ул, бик җитди итеп. – Сиңа кызык. Ә Галим кордашың чүт кенә теге дөньяга китми калды кичә. Клизма ясап, эчне юдыртып чыгармасалар, беткән буласы икән баш. Брач әйтә, тагын биш минут соңга калсаң, бу якты дөнья белән хушлашасы икәнсең, абзыкаем, запур булган сиңа, эчәкләрең шартлыйсы булган тагын биш минуттан, ди. Ярый әле кайтышлый ук район бүлнисенә кагылырга башым җитте. Сразы рәхәтләнеп киттем шуннан ары. Кеше печән чапканда ничек итеп сәламәт башым белән өйдә ятыйм ди инде мин? Килдем менә... Ә син авыз җырып көлгән буласың тагы!

Маһисәрвәр апа:

– Әйттем исә кайттым, Галим кордаш, ачуланма, мин алай ук булганын белмәдем бит! Үземнең миңгерәү башым белән, әллә хатынын бик сагынган да, шуңа авыруга салышып кайтып килде микән дип уйлаганыем, – дигәч, барысы да рәхәтләнеп бер көлешеп алдылар да, шуның белән бетте.

Табын яныннан купкач, Галим абзый мине култыклап алды да:

– Әйдәле, Өлфәт, идарәдән әйтеп җибәргән әманәтләрне тапшырасым бар сиңа, – дип, Кама буена алып китте.

Икебез дә яр буена утырышкач, түбәтәен кыңгыр салды да, хәйләкәр елмаеп:

– Син миңа ачуланма инде, прсидәтел, – диде. – И бернәрсәдән дә хафаланма. Бөтенесен наять итеп, ничек әйткән, шулай эшләдем. Кичтән бажайга барып, көтүне иртәнге эңгер-меңгердә үк алып чыгарга куштым. Ә үзем, әйбәт кенә бер күсәк белән нык кына бау алып, таң тишегеннән күпер төбенә барып утырдым. Көтү күпергә килеп керүгә, йомылып кына сикереп чыктым да матур гына бер чуар тананы мөгезеннән ялт – электереп тә алдым! Ә көтү үтеп киткәч, прәме күпер өстендә бәйләп җыктым да суйдым үзен. Бичара тана җан биргәч кенә теге күсәк белән аягын сындырдым да, бажайга көтүен шул

тирәдәрәк тотып торырга кушып, авылга барып, заффирмы Рәдиф белән завхузны алып килдем. Аннары прәме шунда күпер өстендә тунадык та, ит булды менә. Рәдиф, районн сталаваена илтеп тапшырыйк, дип маташканые маташуын, ну мин авыз да ачтырмадым тегеңә. Шушындый Алла үзе китереп тоттырган нигъмәтне анда илтәләрме соң инде, Рәдиф энем! Ит ашамыйча печән чапкан кешеләрне кайда күргәнең бар? Печәнчеләргә алып барабыз и бетте-китте! дигәч, артык карыша алмады. Карышырые да, миннән өркә ул. Прсидәтел булган чагындагы махинатсияләрен байтак беләм мин аның. Шуңа исәпләшә ул минем белән. Ә запур булган диюем болай гына анисы. Пычак булсынмыни миңа? Бүлнискә кагылуым хак. Теге безгә азык китергән кыз шикләнмәсен дип кереп чыктым мин анда. Брачка да, чуртка да күренеп тормадым. Ишек төпләрендәге эскәмиядә биш-ун минут утырдым да чыктым. Менә шулай, энем Өлфәт, әйтсәм эшлим инде мин!

Нишләтәсең инде аны? Вакытында тыеп кала алмагач, хәзер сүз озайтып торуның файдасы юк иде.

– Ярый, Галим абзый, булган-беткән инде. Ләкин бүтән вакытта мондый эшең кабатланса, яхшылык көтмә! – дию белән генә чикләндем.

Ә тана ите ярап куйды! Бөтенләй бүтәнчә эшли башлады печәнчеләр. «Коры» аш ашаган көннәрдә кайбер печәнчеләрнең покосны йә бик тар алып, яисә күрер күзгә киң алып та, астын чи калдырып чабуларына эчем пошып, кисәтү ясагач:

– Теләсә ни әйт, прсидәтел, әмма үтерсәң дә, шушыннан әйбәтрәк итеп чаба алмыйм! – дип әрепләшүчеләр дә бетте, эчем йомшады, дип, атлаган саен тал арасына йөгерүчеләр дә күренми башлады.

Бәхеткә каршы, көннәр бик матур торды. Чапкан чакта яугалап китеп шиккә салса да, печәнне җыйган көннәрдә ник бер генә яңгыр төшеп карасын. Тотынуыбызга унтугызынчы көн дигәндә төшке ашка соңгы богылны коеп кайттык. Шул ук көнне авылга кайтып китәрбез дип тә ниятләп тора идем, ләкин әлеге шул Әйтсә Эшли Галим абзый:

– Син алай борчак урынына куырма инде, энем Өлфәт! Адәм баласына гел эшләп кенә торырга димәгән, вакыты белән әз генә булса да ял да кирәк аңа! Давай, ашыкмыйк алай. Хатын-кызлар Иделдә бер рәхәтләнеп өс-башларын юсыннар, без, ирләр, сакал-мыекларыбызны кырыйк. Керле кием белән кайту килешми, безнең татар андыйны яратмый ул! – дигәч, башкалар да аның фикерен куәтләгәч, каршы килмәдем.

Шулай да күңелем тыныч булмады ул көнне. Су да коенып карадым. Җәйрәп тын гына агып яткан Кама суларының матурлыгына сокланып, әледән-әле чалт та чолт сикергәләп куйган балыкларны күзәтә-күзәтә әллә кайлардан урап та кайттым. Тик барыбер нидер җитми, нигәдер эчем поша. Хәтта, җәяүләп үзем генә кайтып китимме әллә, дип тә уйлаган идем. Әмма, председатель, паром мәшәкатьләреннән куркып, безне ташлап кайтып китте, дип үпкәләрләр дип, ул уемнан кире түндем. Ә тәвәккәлләп кайтып китсәм, бик шәп буласы икән, туган! Их, әйбәт буласы икән кайтып китсәм!..

Галим абзый сүзендә торды. Көндез үк безнең болыннан ерак булмаган землянкада яшәүче маякчы карттан зур гына көймә алып килеп куйды да кичке аштан соң (ул көнне кичке ашны да гадәттәгедән иртәрәк әзерләгәннәр иде) теләгән печәнчеләрне төяп, Камада йөздереп, җырлатып йөртте. Тавышы әллә ни моңлы булмаса да, үзе дә кушылып җырлады. Аларның җыры бөтен кич буе су өстен тутырып, әллә кайларга яңгырап торды.

Ни кыстап карасалар да, мин алар белән бармадым. Күңелем әллә нишләп боек иде. Акылым белән бик тыныч булырга тырышам. Нигә болай ашкынасың, нигә моңланасың, күңел, дип, үземне үзем орышып та карыйм. Юк, булмагач, булмый инде!

Нәрсә турында уйлый башласам да, уйларым шул Сәкинәгә, улым Ирекка барып тоташа. Гел Сәкинәм күз алдыма килә. Ул – кыз, мин егет чакта сирәк-мирәк кенә күрешүләрне, сабантуйларында урманда чәчәк, җиләк җыеп йөрүләрне исәпкә алмаганда, җәмгысы атна-ун көн генә торып калдым бит мин аның белән. Ай күрде, кояш алды гына булды. Ә онытып булмый менә! Һаман шулай мине сугышка озаткандагыча чибәр булып, тыйнак, мөлаем һәм сабыр булып каршыма килә дә баса. Күзне йомудан мәгънә юк. Маңгай күзеннән тыш адәм баласының күңел күзе дә бар бит әле. Аны берничек йомып та, каплап та булмый! Өстенә яшел сатин күлмәген, аягына зәңгәр брезент туфлиен кигән, башына зәңгәр җирлеккә ак бизәк төшерелгән ефәк косынкасын бәйләгән дә, эх, Өлфәт, нишләдең син, мин сине шуның өчен сөйгән идеммени, дип, шомырт кара күзләрен текәп, тилмереп каршымда тора да тора...

Көндез, эш белән мәшгуль чакларда, ул кадәр читен түгел әле. Ә менә буш вакытларда, бигрәк тә кичләрен йокларга яткач!.. Әйтеп-сөйләп кенә аңлата торган түгел инде ул сагышны... Шул ук вакытта Янтыкка барып, сөйләшеп-аңлашып карарга да көчем җитми, үҗәтлегем ирек бирми. Хафиз карт сүзләре исемә төшә дә, йөрәгем тагын жу итеп китә.

Ә Галим абзый әйтә, ашыкмадың микән, энекәем, Сәкинәңнең бер дә андый-мондый кырын эше сизелгән шикелле түгелие, алай-болай булса, авыл җирендә андый нәрсә сизелми калмый торгание ул, ди. Бүтәннәр сизмәсә дә, мин абайламый калырга тиеш түгелием, мин белмәгән нәрсә юк безнең

авылда. Ну мин бер дә андый-мондый хәлен сизмәдем Сәкинәнең. Хафиз, карт шайтан, ялганнарга да мужыт ул, ди... Аптырадым инде. Нишләргә, кайсына ышанырга да белгән хәл юк...

Мин яр буенда шулай уйланып-өзгәләнеп утырган вакытта, кинәт безнең печәнчеләрнең шалашлары тирәсендә шау-шу башланды. Нигә болай ду куптылар икән, әллә берәрсенең шалашына елан-фәлән керде микән дип, яннарына йөгереп барсам, кайберләре күз яше белән еларга ук тотынган.

– Ни булды, иптәшләр, нигә болай дөнья шаулатасыз?

Гадәттәгечә, бу юлы да Маһисәрвәр апа чәчрәп чыкты:

– Нигә буламыни, пәрәми! Күрмисеңме әллә, яна бит! – диде ул, күктәге кызыл яктылыкны күрсәтеп.

– Шәфәкъ балкышы түгелме соң, Сәрвәр апа? – дидем мин, әле һаман үз уйларымнан арынып җитә алмыйча.

– Бу кадәр дә сантый булырсың икән, Өлфәт энем! Нинди шәфәкъ яктысы булсын ди ул сиңа? Шәфәкъ шул якта була димени? Кояш баешында була бит ул шәфәкъ. Ә бу ут кыйбла ягында лабаса!

Йөрәгем дерт итеп китте. Яктылык, чыннан да, кыйбла ягында, ераклыгы да шул безнең авыл тирәсендәрәк иде! Әгәр ут шунда булса – харап! Янгын сүндерердәй кеше юк анда хәзер. Буйдан-буйга өтеп чыгачак ул ут авылны. Җиле алай зыянлы түгел түгелен. Ләкин ут үзе җил чыгара бит ул! Җитмәсә, көннәре дә бик эссе торды бу арада. Суыбыз да ерак!..

– Җә инде, әйт, ичмаса, берәр сүз, нигә өннән чыгып калдың? Болай карап торып булмый ич! – диде Сәрвәр апа, утка баскандай сырпаланып. – Җигик атларны да китик кайтып тизрәк. Бетә бит ату авыл янып! Сүндерер кеше юк бит анда!

– Ничек кайтып китәсең ди? Төнлә паром эшләми, Маһисәрвәр апа! Паромчы өенә, авылларына кайтып куна ич ул!

– Чукынып кына китсен инде, алай булса! Өем янса да җәл түгел, кадалсын анысы. Страхование бар. Андый гына өй салырлык акчасы чыгарые әле. Ну кәҗәм янса – бетте инде баш! Кәҗәм кәҗә ише генә түгел, сыерыңа алыштыргысызые, билләһи. Кәшифәм кәҗәмне генә чыгарып калса ярарые, Ходаем-бер Аллам! Булмас, чыгара алмас ул йокы чүлмәге! Итәгенә ут капканчы гыр-гыр йоклар да, итәге яна башлагач чыгып чабар, тавык мие капкан нәрсә! Кемгә охшап шулай ваемсыз булгандыр инде! Бер дә кыз балага охшамаган бит!.. Ичмаса, йөзә белмим. Йөзә белсәм, ике дә уйламасыем: Идел тармагын йөзеп чыгарыем да кайтып китәрием!

Әйбәтрәк өйле, сыерлы-сарыклы кешеләр, кайгырышсалар да, артык аһ ормыйча гына торганда, Маһисәрвәр апаның шушылай үрле-кырлы сикеренүе, бер караганда, шактый мәзәк тоела иде, әлбәттә. Тик аңар да ачуланып булмый шул. Күз карасы кебек бердәнбер кәҗәсеннән дә коры калса, нишләр ул? Шулай да паникага юл куярга ярамый иде.

– Ярар, җәмәгать, тынычланыгыз, ул кадәр борчылыр урын юк әле! Син дә алай бик үрсәләнмә, Маһисәрвәр апа! Моннан торып кына бер эш тә чыгарып булмый. Кызың Кәшифә өйдә ич синең, ул-бу булса, кәҗәгезне чыгармый калмас! Минемчә, ул янгын безнең авылда булырга тиеш түгел. Безнең авыл уңдарак, әнә тегендәрәк бит! – дигән булдым мин халыкны да, үземне дә шуңа ышандырырга омтылып.

Бер дә пошынмаган атлы булып, үз шалашыма кереп киттем. Ә үземнең йөрәк, менә чыгам, менә ярылам, дип дөп-дөп тибә, өстемә салкын су койгандай, бөтен тәнем калтырый иде. Йоклау түгел, керфек тә какмадым мин ул төнне. Мин генә түгел, башкаларның да күзен йокы алмады: төне буе борчылып, мыдыр-мыдыр сөйләшеп чыктылар.

Таң сызыла башлау белән торып, атларны җиктек, әйберләрне төядек тә кайтырга чыктык.

Кичә тикмәгә генә пошынмаган, юкка гына кайтып китәргә ашкынмаган икән ул! Төнге янгынның безнең авылда булганлыгын паромчы рус картыннан ук ишеттек. Начар хәбәр бик тиз йөри, диләр шул, яхшысы гына көттереп килә аның.

Безнең авыл янганын һәм бер генә йортның көле күккә очуын әйтсә дә, кем йорты икәнен белми иде паромчы карт. Анысын, кайтып җитәргә унбиш чакрым калгач, Анаташ авылында ишеттек.

– Артык кайгырышмагыз, туганнар, бер генә өй, прсидәтелегезнеке генә янган. Ярый әле өе читтәрәк булган, бүтән йортларны саклап кала алганнар. Ничава, прсидәтел кешенеке булгач, зыянлы түгел, тагын салып керер әле! – дип «юатты» безне шул авылның бер карты.

Без авылга кайтып кергәндә, минем өйнең миче дә кара күмергә әйләнгән баганалары гына утырып калган иде.

**15**

Өең нилектән янган, ут кайдан чыккан, диярсең инде син, туган. Мин печәнгә киткәннән бирле ни миченә, ни казан астына ягылмаган йорт үзеннән-үзе генә кабынып китмәгәндер, билгеле. Берәрсе миңа үч итеп эшләгән эш икәнлеге көн кебек ачык иде. Ә менә кем эше икәнлеген мин бүгенгә хәтле тәгаен белмим әле. Ихтимал, моннан соң да шулай сер булып калыр инде бу мәсьәлә. Хәер, мин аны

ачыкларга тырышмыйм да. Хәзер, инде күп еллар узгач кына түгел, элек, кешедә өйдәш торган чакта да төпченеп йөрмәдем. Гомумән, йортсыз калуыма әллә ни зурлап хафаланмадым мин. Өйне аны, теләсәм, шул ук җәйдә салып керергә мөмкин: халык булышачак иде. Бүрәнәләрен генә тап, салып бирәбез без сиңа өй, дип тә әйтеп карадылар. Ә өй җиткереп чыкканчы безгә кереп тор, дип, печәннән кайтып төшкән көнне үк җиде-сигез кеше үзләре килеп әйтте. Алтыпочмаклы йортта ирле-хатынлы гына торучылары да бар иде. Әмма мин аларга бармадым. Үзем теләп, дүрт балалы, кечерәк кенә өйле, ире сугышта вафат булып калган Әминә апаларда тора башладым. Ялгызлык куркытты мине. Шуңа Әминә апаларга, шау-шулы өйгә күчтем...

Әйе, йорт салу кайгысы юк иде миндә, туган, йорты кадалып китсен иде, тик мин печән чабып йөргән көннәрдә Сәкинә Чиләбегә китеп барган булып чыкты. Көткәндер-көткәндер дә, мин бер тапкыр да Янтыкка яннарына барып карамагач, ачуланып чыгып киткәндер, күрәсең. Малайны да алып киткән. Калдырган булса, үземнең яныма алып кайтыр идем дә бер иптәш булыр иде, ичмаса. Киткәннәренә дүрт айдан артык гомер узды, ә мин бер генә тапкыр булса да хәлләрен сорашып кайта белмәдем шул! Минем ишеләрнең шул инде ул: дуамаллык – алдан, акыл арттанрак йөри... Хәзер бик сөйләшәсе иде дә – Сәкинә юк!

Мин шулай мең төрле уйларга чумып, аптырап-алҗып йөргәндә, райком секретаре Гадел абый килеп төште. Бик кызып урак урган көннәр иде бу. Килеп төшү белән үк машинасына утыртып, ул мине кырга, уракчылар янына алып китте.

Кул белән уручылар да, маңгай тирен агызгычыбыз да (лобогрейканы бездә шулай дип йөриләр) әйбәт, чиста уралар иде. Ул яктан минем йөзгә кызыллык килмәде. Уракчылар эшеннән канәгать булып кайтты Гадел абый.

Аннары дәүләткә икмәк тапшыруның ничек барышын сораштырды. Дөресен әйтергә кирәк, ул мәсьәләдә эшләр бик шәптән түгел иде безнең. Районда иң артта ук булмасак та, мактанырлык эш юк иде. Тагын да дөресрәк итеп әйткәндә, ул эшне мин үзем бик ашыктырмый идем. Башта, яңгырлар башланганчы, урып-җыеп калырга кирәк, калганы үз җае белән барыр әле, дип уйлый идем һәм шул фикеремне Гадел абыйга да әйттем. Ләкин ялгыш уйлаганмын икән.

– Миңа синең күпме уруың гына түгел, күпме икмәк тапшыруың да кирәк! – диде ул, шактый кырыс итеп һәм нык кына орышып алды.

Сүз юк, ул да үзенчә хаклы, чөнки беренче җавапны ул бирә.

Әмма мин дә үземчә хаклы идем. Хикмәт шунда, әлеге дә баягы, колхозыбыз кечкенә булганлыктан, үзебезнең автомашинабыз юк, район автоколоннасыннан да машина артмады. Бөтен кырыбыздагы игеннең ашлыгын уру да, сугу да, дәүләткә илтеп тапшыру да гел шул егерме сигез баш ат җилкәсендә. Шунлыктан сугылган ашлыкны вакытында тапшырып өлгертә алмыйбыз.

Менә шуларны сөйләп биргәч, Гадел абый шушы араларда ук автоколоннадан бер машина җибәртергә вәгъдә бирде. Аннары папиросын кабызып алды да:

– Йә, хәзер үз тормышың хакында сөйлә инде. Нишләргә, ничек яшәргә уйлыйсың? Йорт салырга җыенасыңмы? Исәбең булса, сузма. Хәзер үк хәстәренә кереш! Без дә мөмкин кадәр ярдәм итәрбез, – диде. Аталарча якын итеп, үз итеп, иңемә кулын куйды.

– Йортны салырга булыр ла анысы, Гадел Салихович. Колхозчылар да булышабыз дип тора. Ләкин бер хикмәте бар бит аның: салып куйгач, тагын яндырмаслармы икән соң?

– Да, сорарга да онытып торам икән: үзең кемнән шикләнәсең? Кем эшедер дип уйлыйсың?

– Атап берәүне дә әйтә алмыйм. Бер дә алай үчләшкән кешем юк иде шикелле.

– Ә йортыңны яндырганнар бит. Димәк, кемгә дә булса ошамагансың.

– Күрәсең, шулайдыр инде.

– Әйдә, болай сөйләшик алайса, иптәш Хәкимов: алай күңелең тартмый икән, йорт җиткерергә ашыкма син. Ләкин борыныңны төшермә! Каш ярылып, күз чыкмаган. Дөнья булгач, төрле хәлләр була.

– Яхшы сүзегез өчен рәхмәт, Гадел Салихович!

Инде хушлашып кайтып китәргә җыенгач:

– Ә хатының белән арагыз ничек? Күрешкәнең, сөйләшкәнең бармы? – дип сорады.

– Башта күрергә теләмәдем, үҗәтлегем җиңеп килде. Хәзер сөйләшеп карар идем дә – соң инде: мин болында печән чабып яткан вакытта, малайны ияртеп, читкә – Чиләбегә чыгып киткән.

– Да-а! – диде Гадел абый, беркавым уйланып торгач. – Шәптән түгел икән хәлләрең. Ашыгычлык, дуамаллык харап итә шул сез яшьләрне. Алдын-артын уйлап тормыйсыз, бер кизәнүдә дөньяны җимермәкче буласыз!.. Шулай да уйла әле син, энем, тагын бер кат бик ныклап уйлап кара! Ахыр чиктә Чиләбе җәһәннәм астында түгел ул. Теләгән кешегә анда барып кайту берни тормый. Анысын да хәтереңә алып куй!

Уйландым мин, бик күп уйландым ул көннәрдә. Ахырында шундый нәтиҗәгә килдем: Сәкинәнең кылларын тарткалап карамыйча, Чиләбегә чыгып китәргә ярамый. Башта хат язарга кирәк. Янтыкка барып, әби күзенә күренеп йөрисем килмәде. Сәкинәнең адресын кеше аркылы гына соратып алдырдым да, кичерүен сорап, гафу үтенеп түгел, ә болай гына, улыбыз Ирекнең хәлен сорашып, үзең ничек яшисең, нинди эштә эшлисең, дип кенә хат яздым.

Атна узды, ай үтте – җавап бирмәде бу. Ә минем эч поша. Күңелгә корт керде хәзер. «Менә, Өлфәт, – дим үз-үземә, – җавап язарга да теләми хатының. Димәк, кирәгең шул чама гына инде синең! Йөр инде менә хәзер авызыңны ачып!..»

Мин әнә шулай ни эшләргә белмичә, ике күземне дүрт итеп Сәкинәдән хат көтеп йөргән чакта, шул форсаттан файдаланып калырга теләгән кешедәй, теге Гөлүсә дигән укытучы тагын калкып чыкты бит, туган. Шул кызыкай белән тагын бер тапкыр очрашырга туры килде миңа.

Безнең урман – җиләк һәм чикләвек оясы, дип әйткән идем инде мин сиңа. Дөресе шулай аның, туган. Үзебезнең авыл халкы гына түгел, унар-унбишәр километрдагы авыллардан да килеп җыялар безнең урман җимешләрен. Август ахырларында, чикләвекнең иң әйбәт өлгергән чагында, Гөлүсә дә безнең урманга чикләвеккә килгән дә кайтышлый миңа чикләвек калдырып китәргә ниятләгән. Мин колхозчыларның кенәгәләренә хезмәт көннәрен утыртып торганда, бик батыр кыяфәт белән идарәгә килеп керде бу.

– Кая, фуражкагызны салыгыз әле, Өлфәт абый, иң әйбәтләрен генә, үзегез шикелле сап-сарыларын гына калдырып китим әле шушы чикләвекләрнең. Сезнең өчен дип, боларын баштан ук аеры җыйган идем! – ди.

Шулай диде дә, минем ай-ваема һич карамастан, алдыма ун-унбиш стакан сыешлы бер янчык чикләвек китереп куйды.

– Нигә болай юмартланасыз, Гөлүсә, теге чакта юлда калдырып киткән өченме әллә? – дидем мин, уенын-чынын бергә кушып.

– Ярар инде, Өлфәт абый, – диде ул, колакларына кадәр кызарып. – Ул вакытны искә алмыйк инде! Без хатын-кызларның шулай икәнен беләсездер ич инде, һич тә юкка үпкәләдем мин ул чакта. Ә бу чикләвекне бер дә күпсенмәгез, рәхәтләнеп ашагыз! Сезнең өчен дип җыйдым мин аны. Уф, үләм, тамагым кипте, кая, бер стакан суыгызны эчим әле.

Мин аңа су салып бирдем һәм, ул авыз очы белән генә, вак-вак йотып кына эчкәндә, калкып-калкып киткән күкрәкләренә, ялтыравыклы кара пута белән кысып буган нечкә биленә, нәфис аякларына сокланып карап тордым. Чибәр иде ул, шайтан кызы, бер дә килмәгән җире юк иде. Әллә инде... Шулчак тагын Сәкинәм күз алдыма килеп басты, һәм мин үз уйларымнан үзем оялып киттем.

– Суларына хәтле эчеп туйгысыз шушы «Чулпан»ның! – диде ул, ә үзе стакандагы суның яртысын да эчмичә өстәлгә куйды.

– Тәмле булса, эчеп бетерегез сез аны.

– Тукта, ял итим азрак. Монысын бетергәч, тагын берне эчәм әле мин, Өлфәт абый. Булгач, пар булсын. Гомер буе ялгыз яшәргә димәгәндер бит миңа!

Аның тел төбе тагын минем өчен хәтәр якны каера башлавын сизенеп, сүзне икенчегә борырга ашыктым:

– Сез теге вакытта укулар бетү белән үк үз ягыгызга кайтып китәргә җыена идегез шикелле. Кире уйладыгызмы әллә, Гөлүсә?

– Ә сез минем китүемне теләгән идегез инде, әйе?

– Аннан әйтүем түгел. Миңа бернинди дә зыяныгыз тигәне юк бит. Болай искә төште дә, кызыксынып соравым гына.

– Их, Өлфәт абый! – диде ул, мәгънәле итеп көрсенеп. Аннары кинәт ниндидер бер кискенлек һәм горурлык белән башын күтәреп, түшәмгә текәлде дә, үз-үзенә сөйләгәндәй итеп, ярсып сөйләргә тотынды:

– Беләм, Өлфәт абый, сезнең миңа равнодушный булып кылануыгызны яхшы беләм. Ләкин асылда алай ук битараф түгел бит сез миңа. Сез минем сезне яратуымны сизәсез, шуңа күрә генә шулай кыланган буласыз. Ә мин сезне аның саен ныграк ярата барам. Әйе, Көрнәледән китмәскә булдым мин. Сез өйләнгәнче беркая да китмәскә ант иттем! Менә шул! Ярый, кәефегезне кырган булсам, гафу итегез!

Шулай диде дә, үзенә дип җыйган капчыктагы чикләвеген дә алырга онытып, йөгереп чыгып китте. Мин бер сүз дә әйтә алмыйча калдым. Аңыма килеп, капчыгын бирим дип артыннан чыкканда, ул инде байтак җир киткән иде.

Тәмам хәйранга калдырып китте ул кыз мине! Чынлап ук яратадыр инде, күрәсең. Яратмаса, кыз баланың болай ачыктан-ачык сөйләшергә йөрәге җитмәс иде.

Ләкин мин аны нишләтим соң? Ничек ярдәм итим аңа? Сүз дә юк, чибәр ул, акыллыдыр да, мөгаен. Ләкин мин Сәкинәмне оныта алмаячагымны сизеп торам. Шулай булгач, болай гына, вакытлыча гына мавыгудан безгә ни мәгънә? Юк, булмый бу болай, тагын берәр тапкыр шулай «бәйләнә» башласа, туп-

туры, гафу ит, Гөлүсә, безнең ике арабызда бернинди мәхәббәт була алмый, чөнки минем яраткан кешем бар, дип, дөресен әйтеп бирергә кирәк булыр. Башта авыр кичерсә дә, үзен-үзе алдап йөрмәс, миңа да җиңелрәк булыр аннары.

Ләкин мин аңа бу турыда әйтә алмадым. Шуңа әйтә алмадым, чөнки идарәдә булган әлеге сөйләшүдән соң Гөлүсә ул хакта бүтән сүз катмады. Мин эш белән авыл советына – Көрнәлегә барган чакларда урамда очраштыргаласа да, тыйнак кына исәнләшеп, ягымлы елмаеп, горур гына атлап үтеп китә торган иде...

Ә мин һаман Сәкинә турында уйлыйм, аннан җавап көтә идем. Көтеп-көтеп тә беренче хатыма җавап бирмәгәч, *«Нигә дәшмисең, Сәкинә, нигә тилмертәсең? Аерым яшәсәк тә, ир белән хатын ич әле без, аерылышканыбыз юк лабаса? Нигә, ике-өч сүз белән генә булса да, үзеңнең һәм улыбыз Ирекнең хәлләрен әйтеп язмыйсың? Әллә эшең бик кыенмы, ярдәм кирәкме әллә? Кирәк икән – әйтеп яз, кулдан килгәнчә булышырмын»* дип, гаебемне танып ук булмаса да, шактый җылы итеп, икенче тапкыр да язып карадым. Әмма... юк, анысына да җавап бирмәде.

Шуннан соң тәмам боегып калдым мин, туган. Бер уйлаганда менә хәзер тотам да янына китеп бармакчы булам. Инде җыена гына башлыйм дигәндә, башка тагын икенче төрле уй килә: «Ә Сәкинә чынлап торып миңа хыянәт иткән булса? Галим абзый, андый-мондый эше сизелгәне булмады, дип әйтә әйтүен... Ләкин дөньяда ул сизмичә калган эшләр дә булырга мөмкин ич! Әнә Хафиз карт бүтәнчә раслап тора лабаса!..»

Менә шул уй килә дә, кинәт тагын ярсып, алдагы фикерләремнән кире кайтам, күңелем суынып куйгандай була. Әмма бу хәл озакка бармый, мин тагын сагышка бирелəм, тагын Сәкинәмне тарта башлый күңел... Үзем шул ук вакытта күзгә күренмәгән, әмма мине тоткарлап тора торган киртәне дә ничектер атлап үтә алмыйм...

Тагын дүрт-биш ай көтеп тә икенче хатыма да җавап булмагач, ниһаять, кирелегемне җиңеп: *«Синсез һәм улыбыз Ирексез яши алмыйм мин, Сәкинә бәгырем. Шуның өчен барысын да гафу итәргә әзер торам, тик син дә мине гафу ит! Гафу итәр булсаң, тиз генә хат язып сал. Хатың килгән көнне үк юлга чыгармын да икегезне дә барып алып кайтырмын»*, – дип, тә язып карадым.

Ләкин ул хатыма да җавап килмәде. Өзелеп-өзелеп юксынсам да, күрәсең, гаебе булгандыр, шуңа җавап бирмидер, шикләнә торгандыр, дип, шуннан соң мин аны бүтән борчымадым. Бөтен сагышымны эш белән басарга тырышып, эчтән генә сызып яши башладым.

**17**

Ә вакыт һаман үтә торды.

Безнең аерым яши башлаганга да өч ел гомер узып китте. Колхозның чираттагы отчет-сайлау җыелышына әзерләнеп йөргән көннәрдә мине райкомга чакырттылар. Гадел абый үзе дәштергән икән.

– Йә, сөйлә, иптәш Хәкимов, эшләрең ничек? – диде ул, кул биреп исәнләшкәннән соң.

– Әлегә ярыйсы шикелле, Гадел Салихович, – дидем, аны нәрсә кызыксындырганын тәгаен генә белә алмыйча. Аннары колхоздагы хәлләрнең торышыннан башлап киттем: – Ашлыкны сугып бетердек. Үзегезгә мәгълүм, икмәк заданиесен йөз дә егерме җиде процент итеп үтәдек. Чәчүлек орлыкларыбыз да әзер: чистартып амбарга салып куелган. Ел ахырында колхозчыларга да хезмәт көненә кило өч йөздән исәп-хисап ясадык. Ә хәзер утраудагы болыннан печән ташыйбыз. Аны да алып кайтып бетерсәк, алай зур эшебез калмый да кебек.

– Яхшы, алары бик әйбәт булган, иптәш Хәкимов. Сводкалар караганда ук шулай дигән идек. Инде хәзер син миңа шуны әйт: үз хәлләрең ничек? Хатының белән сөйләшеп карадыңмы? Янына барып кайттыңмы?

– Янына бармадым, әмма хатлар язгалап караган идем, Гадел Салихович.

– Йә, шуннан?

– Хатларыма җавап язмады.

– Хатны төрлечә язарга була аны, Өлфәт энем!

– Мин дә төрлечә язып караган идем, тик берсенә дә җавап булмады. Аннары мин дә язмый башладым. Күрәсең, үз хәлен үзе белә торгандыр инде. Гаебе булмаса, күптән дөньяның астын өскә китерер, акланырга тырышыр иде ул. Хатын-кыз андыйга хирыс бит, сәбәбе генә булсын!

– Ә нигә син бөтен хатын-кыз да шулайдыр дип уйлыйсың әле? – диде секретарь, җитди тонга күчеп. – Син уйлаганның киресенчә булуы да мөмкин түгелмени? Бәлки, хатыныңның гаебе юктыр, шуңа җавап бирми торгандыр ул. Синең, үзең килеп, гафу үтенүеңне көтәдер, бәлки. Синдә булган горурлык белән синдә булган мин-минлек нигә анда булмаска тиеш әле? Менә шул хакта да уйланырга кирәк! Өченче ел бер әйткән идем инде, тагын шул сүзне кабатлыйм: минемчә, янына барып, үзе белән сөйләшеп карарга иде сиңа! Бәлки, тезләнеп алдында гафу үтенергә дә кирәктер әле!

– Нишләргә дә белгән юк инде, Гадел Салихович. Онытa да алмыйм үзен, шул ук вакытта янына барып гафу үтенеп карарга да күңелем тартмый. Рәдиф белән чуалганын белүче бар бит!

– Ну-у! – диде Гадел абый, аптырыйрак төшеп. – Кем күргән, мин беләмме икән ул кешене?

– Аның үзен, ихтимал, белмисездер, ә малаен беләсез: районның культура бүлегендә эшләүче Мәлик Хафизов ул.

– Димәк, Мәликнең әтисе Хафиз карт белә?

– Әйе, Гадел Салихович. Сез аны да беләсезмени?

– Аз-маз беләм. Минем янга кергәне бар аның бер-ике тапкыр. Бер-ике күрүдә генә кешене яхшылап аңлавы, әлбәттә, кыен, хәтта мөмкин дә түгел. Ну шулай да... Бик үк саф күңелле сыман тоелмады ул карт миңа.

– Элек алай ялган сөйли торган кеше түгел иде ул, Гадел Салихович.

– Элек, элек. Элекне куйганнар шул аны элеп! – диде Гадел абый, ничектер минем белән килешергә теләмәгән сыман итеп. Тәрәзә буена барып, бераз уйланып торды да кисәк кенә миңа борылды: – Хәер, мондый чакта кеше киңәше белән генә йөреп булмый инде ул. Үзең кара, Хәкимов. Бала-чага түгел син. Мин сине акыл өйрәтергә чакырмадым монда. Монысы сүз җаеннан гына килеп чыккан нәрсә. Башка мәсьәлә буенча дәштергән идем мин сине. – Секретарь кинәт рәсми төскә керде дә: – Эш менә болай, иптәш Хәкимов, без сине «Ватан»га күчермәкче идек, син үзең шуңа ничек карыйсың? – диде.

Мин бик нык борчуга калдым. Шулай булмый хәле дә юк: «Ватан», бердән, зур колхоз, икенчедән, экономик яктан бик артта калган. Өченчедән, кешеләре авыррак холыклы. Шабашниклыкта йөреп көн күрүчеләрне әйтәм. Дүртенче сәбәбе дә бар: минем председатель булып эшли башлавыма нибары өч ел гына бит әле, шулай булгач, күпме генә тәҗрибәм бар да, андый зур колхозны ничек җитәкләрмен ди мин?

– Әгәр чынлап әйтүегез булса, мин категорический каршы моңа, Гадел Салихович!

– Сәбәбе?

Әлеге дүрт сәбәбемне санап бирдем һәм, шуларга өстәп:

– «Чулпан»да эшләр җайланып кына килгәндә, халыкның да, хуҗалыкның да рәтенә төшенеп бетеп кенә барганда башка җиргә күчеп китәргә һич тә теләгем юк! – дидем.

– Бүтән сәбәпләрең бармы? – диде ул, боларына бер дә алай исе китмичә.

– Бар. «Ватан»га күчеп, тагын бер шелтә алырга теләмим. Теге елдагысы да өстемдә кара тап булып тора әле!

Райком секретаре мәгънәле генә итеп елмаеп куйды. Аннары блокнотына нидер язды да:

– Ярый, анысы безнең гаеп. Киләсе бюрода карарбыз ул мәсьәләне. Кадрларны мактарга оныткалыйбыз да икән шул кайчакта! – диде һәм, шундук җитдиләнеп, сүзне тагын үз җаена борды: – Ә «Ватан»га барырга теләмәвеңнең сәбәпләре җитди түгел, иптәш Хәкимов. Үзебезгә генә ошаган җирдә эшли торган вакытлар да җитәр, әлбәттә. Әмма хәзергә андый чак түгел әле. Иртәрәк әле аңа. Һәркайсыбыздан сәләтенчә таләп ителә әле хәзергә! Һәркайсыбыз булдыра алганча эшләргә һәм мөмкин кадәр күбрәк эшләргә тиеш... Ә синең «Ватан»да эшләрлек сәләтең барына мин ышанам. «Чулпан»да калдыра алмыйбыз без сине. «Ватан» штурвалын тоттырмакчы булабыз. Бүген генә уйланган нәрсә түгел бу. Өең янганнан соң, йорт салырга ашыкма, диюем дә шул максатны күздә тотып әйтелгән сүз иде.

– Миннән башка кеше юкмыни соң, Гадел Салихович?

– Кешесе күп лә аның! Хәзерге председатель Мосафировны калдырырга ярамавын сизенеп, аның урынына төпләнеп калырга теләп, үзләре ымсынып йөрүчеләр дә бар. Әмма безгә андыйлар кирәк түгел. Эш майтарырдай, «Ватан»да тәртип урнаштырырдай кеше кирәк безгә! Сер түгел, «Ватан» – районда иң артта килүче хуҗалык... Кыскасы шул: бар, кайт та «Чулпан»ның отчет-сайлау җыелышын әзерли башла. Көнен билгеләгәч, хәбәр итәрсең, мин үзем барырмын җыелышыгызга.

Мәсьәлә әнә шулай кабыргасы белән китереп куелса да, мин ризалык бирергә ашыкмадым.

– Хәзер генә өзеп берни дә әйтә алмыйм, Гадел Салихович. Халык сайлап куйган бит мине «Чулпан»га. Алар нәрсә дияр бит әле, – дип, эшне бөтенләй үк өзеп бетермичә кайтып киттем.

**18**

Көн шундый суык – авызыңны ачсаң, сулуга каба. Теләсәң, шул зәңгәр суыкны пычкы белән турап, әрдәнәләп өеп куеп булыр төсле. Тере җан ияләре ничек түзә торгандыр, хәтта авыл йортларының капкаларына тикле «тим-ә-ә-ә!», «үлә-ә-әм!» дип елап-сыкрап кына ачыла. Кояш үзе дә туңган, ахрысы, – «колакларын» тырпайтып тора, яктылыгы да кими төшкән. Ярый әле җиле юк. Җиле дә булса, капкаңнан баш тыгып, урамга карый алмас идең!

Ә Гадел абый иртәнге унга ук килеп җитте. Җыелыш көндезге сәгать икедә башланды.

Тиене тиенгә туры килсә, кереме чыгымыннан артма-са, ягъни, киресенчә, чыгымы кеременнән артып китмәсә, колхоз отчет-сайлау җыелышы әллә ни кызыклы да, тавыш-гаугалы да булмый. Бездә андый чатаклыклар юк иде. Шуңа күрә җыелышның отчет өлеше шома гына барды дияргә була. Дөрес, Рәдиф:

– Менә өч ел инде Хәкимов ел саен печән өстендә печәнчеләргә йә тана, йә сыер суйдырып, бушлай ашатып килә. Минемчә, узган елгы сыер итен печәнчеләрдән түләттерергә кирәк, – дип тәкъдим кертергә азаплана башлаган иде башлавын. Әмма халык аңа: «Ниткән түләү ди ул?!» – дип, авыз ачарга да ирек бирмәгәч, Гадел абый да ул мәсьәләне күтәреп алмагач, шундук тотлыгып калды да: – Мин болай гына, колхоз милке өчен эчем пошып кына әйткән идем, түләтмисез икән – кирәк түгел! – дип мыгырданып, урынына утырырга мәҗбүр булды.

Ишек катында торучы Галим абзый:

– Беләбез инде, олан, синең колхоз өчен ничек тырышканыңны сөйләп тору кирәк түгел! – дип иплән кенә әйтеп куйгач, бөтенләй кечерәеп, халык арасына сеңеп калды.

Ә менә сайлау өлеше башланып, Гадел Салихович мине председательлектән азат итүләрен үтенгәч исә җыелыш бик нык кызып китте. Иң элек теге вакытта кәҗәсе өчен кайгырып, нишләргә белмичә сырпаланып йөргән Мәһисәрвәр апа сүз алды:

– Бу ниткән тамаша була инде, иптәш сиклитар? – диде ул, урта рәттә утырган җиреннән сикереп торып. – Калхузны аякка бастырып килгәндә генә нигә алай алып китмәкче буласыз безнең Өлфәтне? Без бүтәннәрдән киммени? «Ватан»да кеше беткәнмени? Алты йөз йортлы авыл бит ул! Үзләреннән сайлап куйсыннар прсидәтел. Юк-юк, Хәкимов Өлфәтне беркая да җибәрмибез без! Адәмчә яши башладык, дип торганда гына эшме соң инде шулай? Башкалар ничек дияр, мин үзем каршы бу эшкә! Менә шул!

Мәһисәрвәр апа артыннан сүз алган Галим абзый да шул рәвешлерәк сөйләде. Тагын биш-алты кеше аларның фикерен куәтләп чыкты.

Болай булса, үзебезнең «Чулпан»да калам, ахрысы, дип куанып утырган идем мин.

Аннары Гадел абый сүз алды:

– Беренчедән, – диде ул, – безнең өчен «Чулпан» да, «Ватан» да, башка колхоз да – барысы да бер үк дәрәҗәдә якын! Берсен дә аерып карамыйбыз. Иптәш Хәкимовны да сезне кимсетеп караганнан күчерергә җыенмыйбыз. Аның сезгә кирәкле кеше булуын да, сезнең аны хөрмәт итүегезне дә бик әйбәт белеп торабыз. Ләкин сез дә мине аңларга тырышыгыз, иптәшләр: халык белән уртак тел табып, бар көчен куеп, чын күңеленнән тырышып эшли торган җитәкче буларак, намуслы партия члены буларак, Хәкимов Өлфәт «Ватан»га аеруча кирәгрәк. Яшерен-батырын түгел, «Ватан»ның хәле кыен. Моны сез үзегез дә беләсез. Аннан килеп, тагын шунысын да искә алыгыз, иптәшләр, әллә кая китми бит Хәкимов, үзегезнең авыл советы урнашкан күрше авылга гына күчәчәк. Киңәш-табыш итәргә кирәк булган очракларда сез дә аның янына баргаларсыз, ул да сезне бөтенләй үк онытып бетермәс дип уйлыйм. Әйдәгез, алай карышмагыз инде сез. Бушатыгыз Хәкимовны эшеннән!

– Туктале, ул тикле куырма әле син безне, – дип, янә Мәһисәрвәр апа сикереп торды. – Уйларга ирек бир әле әзрәк, пәрәми! Үзеннән дә сорап карыйк әле Өлфәтнең, ул үзе нәрсә дияр икән?

Нишләргә инде? Китәсем килми, дисәм, алар мине җибәрмәскә дә мөмкин. Минем, чыннан да, китәсем килми, үз авылың халкы белән эшләү – бер, чит авылда – бөтенләй икенче нәрсә бит ул. Үзебезнең авыл кешеләренең һәркайсының холкын-гадәтен өйрәнеп бетә язган идем бит мин! Ә Көрнәледә бөтенләй таныш булмаган кешеләр белән бөтенесен яңабаштан башларга туры киләчәк. Ярый ла җайларын табып булса... Шул ук вакытта Гадел абыйны уңайсыз хәлдә калдыру да читен. Райком секретаре булганы өчен генә түгел, кеше буларак, акыллы җитәкче буларак хөрмәт итәм ич мин аны.

– Мине азат итүегезне үтенәм, иптәшләр! – дидем мин, беркавым уйланып торганнан ары. – Яхшы гына эшләдек. Хөрмәтегез өчен рәхмәт! Әмма азат итүегезне үтенәм. Семьям да җимерелде, йортым да янды, шуңа күрә монда эшләргә күңелем тартмый. Анысын да искә алыгыз, иптәшләр!

– Рас үзе шулай дип әйтә икән, көчләп булмый инде алайса, – диде Сәрвәр апа. – Йә, әйтеп кара алай булгач, Өлфәт энем, урыныңа кемне куйыйк соң?

– Бәлки, яңадан Рәдифне куярсыз, – дидем мин, аны үз урынымда калдырырга теләүдән бигрәк, халыкның фикерен беләсем килеп. – Белеме дә бар, тәҗрибәсе дә. Аннары хәзер салу белән дә мавыкмый.

Шул сүзем өчен ул җыелышта миңа бик нык үпкәләде халык.

– Аны кую түгел, исемен ишетергә дә теләмибез, син нәрсә, үзең киткәч, колхоз да тәмам эштән чыксын дисеңме әллә, сугыш елларындагысына да үкенеп бетә алмыйбыз әле. Прсидәтел генә ит – шул көнне үк эчә башлый ул, – диделәр.

Кыскасы, пыр тузынды халык. Аннары:

– Халыкны да, крәстиән эшенең рәтен-чиратын да белә, – дип, Галим абзыйны сайлап куйдылар.

**19**

Берәр атнадан «Ватан»да да отчет-сайлау җыелышы булды. Инде әйткәнемчә, хәле мактарлык түгел иде «Ватан»ның. Шуның өстенә тиене тиенгә генә түгел, меңе меңгә туры килеп бетмәгән очраклары

да шактый булып чыкты. Кыскасы, моңарчы председатель булган агайны – юантык гәүдәле, каратут чибәр йөзле бер кеше иде ул – яңадан үз урынында калдыру турында сүз дә булмады. Ә менә кемне сайлау мәсьәләсендә тавыш зурдан купты. Иң элек өстенә тышлы яңа тун, башына яхшы бүрек кигән ир уртасы бер агай сүз алды.

– Үзебезнең авыл кешесен сайларга кирәк, ничу монда читтән килгәнне куярга! – диде ул, минем кандидатура тәкъдим ителгәч. – Читтән килеп эшләп карауачылар, шөкер, булгалады инде. Тик берсе дә колхозны алга җибәрә алмады. И һәм җибәрмәячәкләр дә! Чит кешегә нәрсә аңа: бүген монда ул, ошамады икән – иртәгә койрык сыртта аның. Булсын дип йөрми алар. Ә хезмәт хакын каера беләләр: акчалата кирәк аларга!..

Аның артыннан тагын өч ир, ике хатын-кыз шулайрак сөйләп, мине сайлауга каршы чыктылар.

– Йә, тагын кемнәрдә нинди фикерләр бар, иптәшләр? – диде Гадел абый тыныч кына. Бер-ике минут халыкка карап көтеп торды. Бүтән сөйләргә теләүче күренмәде. – Яхшы! – диде ул аннары. Сәламәт кулы белән чәчен сыпырып куйды да иң алдан сөйләгән яңа тунлы абзыйга мөрәҗәгать итте: – Әйтегез әле, иптәш, нинди эштә эшлисез сез?

– Кая кушсалар – шунда! – диде Галләмов.

– Ә узган ел күпме хезмәт көне эшләдегез?

– Син нәрсә пркарур шикелле дупруслый башладың әле мине?

– Сез алай кызмагыз әле, иптәш! Прокурор булып түгел, җыелыш исеменнән үтенәм бит мин: күпме хезмәт көне эшләдегез?

– Ну сиксән җиде булсын ди. Шуннан?

– Ә ел буена барлыгы ничә көн эшкә чыктыгыз?

– Менә анысын санамаган идем шул, иптәш сиклитар. Кирәк буласын белмәдем. Иренмәүчеләр хезмәт кенәгәсен алсын да санасын... Ә миңа бушны чутлап ни файда?

Гадел абый аның сүзләрен сабыр гына тыңлап утырды. Аннары Галләмовның хезмәт кенәгәсен алып килергә кушты да минем кандидатурага каршы чыккан башка кешеләрдән дә, кайда эшлисез, күпме хезмәт көнегез бар, дип сораштыра башлады.

Әмма алары да батырып эшләүчеләр түгел, колхоз белән бәйләнешләре бик чамалы кешеләр булып чыкты.

Теге өч ирнең икесе балта остасы, берсе мич чыгаручы – гомерләрен күбрәк тирә-як районнарда, хәтта чит өлкәләргә чыгып та эшләп үткәрүчеләр икән. Әлеге ике хатынның ирләре дә шулай ук колхозны куандырырлык эш күрсәтмиләр: кышын вак-төяк эштә эшләп йөрсәләр дә, җәйгә чыккач, колхоз эшенең иң кызу чагында, бер кешене унга бүләрдәй вакытта, Урал ягына китеп, печән чабып, утын кисеп, акча сугып йөриләр икән.

Хезмәт кенәгәсен карап, Галләмовның да колхоз эшенә нибары илле бер көн генә чыкканын, аның да җәен шабашниклыкта йөрүен ачыклаганнан соң, Гадел абый иплән кенә трибуна янына барып басты да, өстенә иске сырма кигән, башына уңып беткән калын шәл япкан кечкенә генә бер хатын-кызга мөрәҗәгать итеп:

– Әйтегез әле, менә сез кайда эшлисез? – дип сорады.

Кечкенә ханым башта сискәнеп-каушап китте. Аннары ялт итеп урыныннан купты да:

– Дуңгызлар карыйм, иптәш сиклитар, дуңгызлар! Безнеңише ирсез-атсыз хатын-кыз кайда эшләсен инде бүтән?! – диде.

– Узган ел күпме хезмәт көне эшләдегез?

– Һей, миннән сорасаң! Көненә ике труддин язабыз дип әйткәннәрие эшкә куйганда. Өченче елымны эшлим инде. Үткән ел күпме труддинем булгандыр, үтер – әйтә алмыйм. Бер дә ул хакта сорашканым булмады.

– Җиде йөз дә унтугыз да җитмеш биш сутый хезмәт көне бар Хәдичә апаның! – дип кычкырды берсе мич артыннан. Күрәсең, бригадир яки ферма мөдире кычкыргандыр, югыйсә алай төгәл әйтеп бирә алмас иде.

– Алай икән! – диде секретарь, мәгънәле генә итеп. – Кызык, бик кызык килеп чыга бит, иптәшләр! Кечкенә генә Хәдичә апа җиде йөз унтугыз хезмәт көне эшләгән, ә чиртсәң, битләреннән кан чыгарга торган тап-таза дүрт ирнең, дүртесенекен бергә кушсаң да, Хәдичә апаныкы хәтле хезмәт көне юк! Бу нәрсә була инде, иптәшләр? Бу килештән ул колхоз ничек алга китсен инде? Җитмәсә, колхозда иң аз эшләүче шул кешеләр, оялмыйча, авыз күтәреп сөйләп торган булалар бит әле! Аларның нигә алай йон кабартулары аңлашыла, әлбәттә: Хәкимов Өлфәт председатель булса, тезгенне нык тотачагын бик яхшы беләләр. Элекке елларда «Чулпан»да да бар иде андый берничә кеше. Ләкин Хәкимов аларга бик тиз чик куйды. Күрше авыл гына бит, ул турыда сезнең авыл шабашниклары да ишеткәннәрдер, билгеле. Галләмов агай да белә булса кирәк ул хакта. Ләкин, иптәшләр, мин сезгә шушы җыелышта авторитетлы рәвештә әйтеп куям: моннан соң шабашникларның юлын ябачакбыз! Сугыш китергән авырлыкларны сылтау итеп, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып йөрүчеләр булырга тиеш түгел киләчәктә!

– Әмма дә дөресен әйттең инде, иптәш сиклитар! – дип, кинәт тәрәзә буенда утыручы бер апа торып сөйли башлады. – Нәкъ өстенә генә китереп бастың инде менә! Бер бүген генә түгел, сугыш башланган елдан бирле шулай килә бездә: җыелыш булса, Галләмов ишеләр бугаз киереп акыра, эшкә килгәндә, анысын безнең ише тол хатыннар эшли. Беркемгә бер сүз әйттерми ул Галләмовлар! Гел алар сүзе өстен чыга. Чыкмасые да, җә өркетеп, җә майлап, прсидәтелне үз якларына аударалар! Син бик дөресен әйтәсең, иптәш сиклитар, Хәкимов Өлфәтне прсидәтел итеп куйсак, аның белән буткалары пешмәсен, аны ярты эчертеп кенә үз якларына аудара алмаслыкларын сизенә алар, шуңа шушылай тыпырчыналар. Әмма дә ләкин алар сүзенә карамаска кирәк! Минем фикерем шул: Галләмов ише шабашникларның сүзен колакка алмыйча, шуларга юри үч итеп, тотарга да Хәкимов Өлфәтне сайлап куярга кирәк. Кертсә ул кертә безнең халыкны денгә. Үткән ел «Чулпан»да кила да өч йөздән бүлеп бирде ул! Без шуның чиреге белән калдык. Ул да атхуттан... Ә җирләребез бертөсле үк. Безнең җир тигезрәк, яхшырак та әле. Сугышка хәтле без һәр җылны «Чулпан»нан күбрәк бүлә торганыек!

Ул апа урынына утырган гына иде:

– Миңа да мөмкинме берничә сүз әйтергә? – дип, алгы рәттән брезент кожанлы, йөзен сап-сары сакал-мыек баскан бер абзый торып басты да рөхсәт иткәнне дә көтмәстән сөйли үк башлады: – Төптәнрәк уйлаганда, чыннан да шулай ич, җәмәгать. Нурҗамал хак сүз әйтте бит! Галләмефе дә, Хәмитофы, Сираефы да – берсе дә колхозны кинәндерүчеләр түгел ич, үзегез дә күреп торасыз. Читтә, шабашниклыкта акча эшләп йөри бит алар. Менә минем киемне карагыз да Галләмеф Закирныкын карагыз: ул өр-яңа җылы тун кигән, мин җыртык бишмәт тә иске кажан киеп йөрим. Ә бит минем кулым да балта тота белә. Мин дә башка авылларга барып йорт салып йөрергә магу. Ну минем алай итәсем килми, сәвисем бар минем. Бөтенебез дә шулай йөри башласак, кем алып барсын калхуз эшен? Минем фикерем шул: Хәкимовны куярга кирәк прсидәтел итеп. Булдыра торган егет ул. Вәт шул! Минем сүзем бетте. Кирәк булса, язып куй, иптәш сиклитар, Сафин Вафа дигән кеше мин.

Вафа абзыйдан соң тагын унлап колхозчы кызып-кызып мине яклап сөйләде. Аннары Гадел абый торып басты да:

– Хәзер, иптәшләр, мәсьәләне тавышка куябыз: кем дә кем Хәкимов Өлфәтне...

– Гафу итегез, Гадел Салихович, минем дә бер-ике сүзем бар иде, – дип, мин үзем трибуна янына чыктым.

– Мәсьәләне тавышка куйганчы, мин сезгә шуны әйтмәкче булам, иптәшләр, – дидем мин. – Зинһар, мине үзе теләп килгән икән дип уйлый күрмәгез! Сезгә килергә һич тә җыенмаган идем. Хәзер дә председателегез булырга атлыгып тормыйм. Сайламасагыз, рәхмәттән башка сүз әйтмәячәкмен. Әгәр сайлыйсыз икән, әйдәгез, алдан ук килешеп куйыйк, соңыннан үпкәләштән булмасын. Сездә эшләмәсәм дә беләм мин: сукранырга яратучылар күп, ә эшләргә теләүчеләр азрак бирeдә. Ул нәрсәне бетерергә кирәк булыр! Иң элек яхшылап эшләргә туры килер. Аннары, рәхим итеп, сорый да аласыз. Бөтенебез бер семья булып, колхозныкы дип түгел, минеке дип, күңел биреп эшләмәсәк, читтән килеп беркем дә алга җибәрмәячәк бу колхозны. Монысы – бер! Икенчедән, читкә китеп, шабашниклыкта йөрүчеләр иртәгәдән үк ул эшне туктатырга тиеш! Өченчедән, һәркайсыгызга бригадир кая эшләргә куша, шунда барырга кирәк булыр. Сәбәпсез-нисез эштән калучылар рәхим-шәфкать көтмәсен! Инде килеп, әгәр минем ялгыш эшләрем була икән, шулай ук күземә теләп әйтүегезне үтенәм. Чыш-пыш арттан гайбәт сату кирәк түгел! Менә шул, иптәшләр. Мәсьәләне тавышка куйганчы, боларны искә алыгыз. Әле соң түгел. Соңыннан тегеләй дә болай, фәлән дә фәсмәтән дип йөрерлек булмасын! Минем таләпләргә риза булган кешеләр генә кулын күтәрсен. Тагы шунысын да әйтеп куям. Кайсыдыр, Галләмов Закир агай иде, ахрысы: «Читтән килгән председательләрне күп күрдек инде, юньләп эшләмиләр, әмма хезмәт хакын акчалата каералар», – диде. Курыкма, Закир агай, мин акчалата алмаячакмын. Барлык колхозчылар кебек үк, мин дә хезмәт көненә эшләячәкмен. Сезгә ни, миңа да шул булыр.

Аннары Гадел абый мәсьәләне тавышка куйды. Җыелыштагы биш йөз алтмыш өч колхозчының уналтысы каршы булды, башкалары, ризалык белдереп, кул күтәрде...

Шулай итеп, мин «Чулпан»нан «Ватан»га күчәргә тиеш булдым, туган. Ләкин сайлап куйган көннәрдә үк анда эшли башламадым. Ни өчен дисәң, алдагы елда мин Казан авыл хуҗалыгы институтында читтән торып укырга имтихан биреп кайткан идем. Нәкъ шул көннәрдә кышкы сессиягә барырга кирәк иде. Шуңа күрә, элекке председатель белән алыш-бирешне кайткач ясарга булып, Казанга кышкы имтиханнарны тапшырырга китеп бардым.

Менә шунда теге укытучы кыз Гөлүсә белән янә очраштык без. Ул да читтән торып Казан педагогия институтында укый һәм ул да, минем кебек, кышкы сессиягә килгән иде. Беренче имтиханымны тапшырып чыккан көнне үк ялт итеп институтка килеп керде бу.

– Хәлегезне белергә килдем, Өлфәт абый, – ди. – Авылдаш итеп үзегез килерсезме дип көттем-көттем дә, сез килмәгәч, үзем килдем менә!

– Мин сезнең Казанда икәнлегегезне белми идем бит, – дидем мин, аның сессиягә киткәнлеген ишеткән булсам да, белмәгәнгә салышып.

Ул минем бу сүзләремне колагына да алмады:

– Йә, нинди белгә белән котлыйм сезне, «отлично» беләнме? – дип, һаман үзенекен тәтелди бирде.

– Юк, «яхшы»сы бик җиткән минем ише читтән торып укыган кешегә.

Өмете акланмаганга борынын җыерып ризасызлык белдерде дә шундук тагын кояштай балкып китте.

– Котлыйм, Өлфәт абый! – диде аннары, кулымны кысып һәм серле итеп елмайды да өстәп куйды: – Имтихан алучы урынында булсам, мин сезгә, һичшиксез, «отлично» куйган булыр идем!

– Яхшы ниятегез өчен рәхмәт, Гөлүсә! Ә үзегезнең эшләр ничек соң? Ничә имтихан тапшырдыгыз әле?

– Уф, үләм! – диде ул, һуштан яза башлаган кешедәй башын тотып, чытлыкланып. – Ниһаять, сез дә минем хәлем белән бер кызыксынырсыз икән? – Аннары кинәт башын күтәрде дә: – Минем хәлләр болай ярыйсы, Өлфәт абый, өч имтиханымны тапшырдым инде, тагын берәү генә калды. Анысы ничек булыр – әйтә алмыйм, ә өчесен гел «отлично»га тапшырдым.

– Молодец, котлыйм үзегезне, Гөлүсә! Мин әле дүрт имтиханның бары тик берен генә тапшырдым.

– Шулаймыни? Ә мин тагы эшләре бетеп килә торгандыр, әллә бергә кайтырбызмы дип килүем иде. Булмый икән инде алайса, – диде ул, сөмсерен коеп.

– Нишләтәсең бит, Гөлүсә.

– Беләсезме нәрсә, Өлфәт абый! – диде ул, тагын рухланып китеп. – Әйдә, киногә барыйк әле бүген. Сезнең дә куанычлы көнегез икән, мин дә имтихан тапшырып чыктым. Әйдәгез, шуны отмечать итеп кайтыйк әле!..

– Бик барыр идем дә, әмма мине бүген кичкә фронтта бергә хезмәт иткән бер иптәшем чакырган иде шул, Гөлүсә, – дип, мин аның үтенечен кире кактым.

Әмма Гөлүсә тиз генә бирешергә теләмәде.

– Ә ул дустың янына икәү барырга ярамыймы соң, Өлфәт абый? – диде, һаман шулай матур, серле итеп елмаеп. – Карамаган кино түгел, анысына бүтән вакытта да өлгерербез әле!

– Алдан сөйләшеп куймагач, икәүләп килеп керү бик үк килешеп бетмәс шул, Гөлүсә. Аннары ул минем өйләнгән кеше икәнлегемне дә белә бит.

– Белсә – бик шәп! Сез мине хатыныгыз дип әйтерсез.

Нишләргә инде бу кызый белән? Мин беркавымга аптырабрак калдым. Аннары, әйдә, ялганларга булгач ялганларга инде, дип уйладым да:

– Ул кеше минем Сәкинәне таный шул, Гөлүсә. Сугышта вакытта рәсемнәрен күргәне булды аның, – дидем.

– Ну хәйләкәр дә кеше инде сез, Өлфәт абый! – диде ул, ачыктан-ачык үпкәләп. – Нигә юкны уйлап чыгарып маташырга инде! Алдашканыгызны күзләрегездән үк күреп торам бит! Ичмаса, дөресен әйтегез аны: синең белән күрешәсем дә, сөйләшәсем дә килми, диегез!

Мин җинаять өстендә тотылган кеше сыман телсез-өнсез калып торган арада, күрәсең, бу кыен хәлдән коткарырга теләп булса кирәк, Гөлүсә мине юатырга ашыкты:

– Ярый, Өлфәт абый, хафаланмагыз. Теләмисез икән – кирәкми, алып бармагыз. Алай атлыгып торудан әйтмәгән идем мин сезгә. Риза булсам, киносына да, театрына да, тагын әллә кайларга да алып барырга җан атып йөрүчеләр дә бетәсе түгел. Тәмам туйдырып бетерделәр инде. Ну әкәмәт тә икән бу ир-ат халкы! Барысына да матур кыз булсын. Хәтта инде чәчләренә чал төшкән һәм, мөгаен, кимендә ике бала атасы булганнарына тикле сүз кушып азапланган була бит. Әнә шул ач күзләрдән котылып тору өчен киногә чакырган идем мин сезне, Өлфәт абый. Аннары минем өчен бик мөһим, бик зур бер мәсьәлә турында киңәш-табыш итеп карамакчы идем.

– Нинди мәсьәлә ул, Гөлүсә? – дидем мин, ниһаять, тел тибрәтеп сүз әйтергә җай чыгуына куанып.

– Улмы?.. – Шулай диде дә, әйтергәме-юкмы дип булса кирәк, беркавым уйланып, аска карап торды. Аннары кинәт башын күтәреп күзләремә текәлде дә тиз-тиз сөйләп китте: – Эш менә болай, Өлфәт абый. Сүз әлеге шул яшь, чибәр кызлар артыннан куган ач күзләрнең берсе турында булачак. Ләкин монысы гади генә түгел, ә особый ач күз. Үземне укыта торган бер доцентның күңеле төшкән миңа. Мин үзем дә сизенеп йөри идем аның шулай икәнен. Әмма моңарчы ул миңа бу турыда сүз белән әйткәне юк иде. Мин тоже берни белмәгәнгә салышып йөри бирә идем. Ә менә кичә ул мине фатирыма кадәр озата кайтты һәм кулымны сорады. Риза булсаң, хәзер үк алып калам, әгәр инде уйлашырга кирәк, дип әйтәсең икән, көтәргә дә була, диде. Киңәш ит әле, Өлфәт абый, нишлим икән?

– Ниндирәк кеше соң ул, Гөлүсә? Өйләнеп аерылышканмы, әллә егет кешеме? – дидем мин, нинди киңәш бирергә дә белмичә.

– Улмы? Ул егет кеше түгел инде, Өлфәт абый. Бала атасы икән инде. Ләкин баласы үзе белән түгел, аерган хатынында калган. Яшькә дә бик яшь түгел – миннән унсигез яшькә олы. Төскә-биткә, буйга-сынга болай симпатичный гына үзе. Институтта да шактый авторитетлы сизелә. Моннан алты ел элек үк инде кандидатлык диссертациясен яклаган. Хәзер докторлыкны язып ятам, озакламый анысын да тәгәлләячәкмен, ди. Әйт әле, Өлфәт абый, нишлим икән, ә?

– Кешегә киңәш ит, үзең теләгәнчә эш ит, диләр бугай мондый чакта.

Ул миннән мондый җавап көтмәгән иде, ахрысы, – йөзе кинәт караңгыланды, күзендәге нурлар юып алгандай юкка чыкты. Беравык идәнгә карап торды. Бары тик шуннан ары гына гадәтенчә ялт итеп башын күтәреп миңа текәлде дә:

– Димәк, сезгә ничек итсәм дә ярый, шулаймы? – диде. – Руслар әйтмешли, сезгә не жарко и не холодно, әйе?

– Соң мин тормыш итәсе түгел бит ул симпатичный белән, – дидем мин, аның кирәгеннән артык төпченә башлавына эчем пошып. – Әгәр аңа кияүгә чыгасыз икән, сез яшәргә тиеш буласыз. Шулай булгач, үзегез карагыз инде, Гөлүсә. Йөрәгегез ничек куша, шулай эшләгез! Башкача мин берни дә әйтә алмыйм. Кешегә киңәш бирү түгел, үземнең семья тормышымны да шушыңарчы рәткә сала алганым юк әле.

Бу җавабымның кискенрәк булганын сизенеп, мин аңа: «Хәер, мондый зур эшкә алыныр өчен бер-береңне яратышу да кирәк, диләр бугай бит, анысы бармы соң ике арагызда?» – дип әйтмәкче булып авыз ачкан идем, ләкин Гөлүсә мине тыңлап тормады.

– Рәхмәт, Өлфәт абый! – диде дә, институт коридорын яңгыратып, тек-тек басып китеп барды.

**20**

Сессиядән кайтып, «Ватан»да эшли башлагач та җиңел булмады, туган, минем хәлләр. Аеруча беренче айларда, халык – мине, мин халыкны яхшылап белмәгән чорда кыенга туры килде. Үз якларына аудару өчен ниләр генә эшләп карамады ул шабашниклар! Мең төрле хәйлә табып, өйләренә алып кереп сыйларга да тырыштылар, төрле «бүләкләр» төртергә азапланучылар да булды. Минем әле һаман буйдак булып йөрүемне сәбәп итеп, гайбәтен дә туйганчы тараттылар...

Һей, туган, ул көннәрдәге хәлләрне искә алганда, хәзер дә аркалар чымырдап китә әле!..

Әлеге шул «Ватан»да эшли башлаган көннәрдә килеп чыккан кайбер хәлләрнең бер-икесен сөйләп үтмичә тәки булдыра алмам, ахрысы.

Март аеның урталары, аяз, җылы көн иде. Икенче бригададан алты ирне кырга салам көрәргә җибәрдек. Тукта әле, нишләп яталар икән дип, төшкә таба яннарына барып карап кайтырга булдым мин боларны. Килсәм, алтысына алтышар метр кар да көрәмәгәннәр. Үзләренә кирәк кадәр урынны гына чистартканнар да, көрәкләрен карга кадап куеп, дөньяларын онытып, карта сугып утыралар! Шулкадәр бирелеп уйныйлар – яннарына килеп басканымны да сизмәделәр хәтта.

Акыра, сүгенә башлаудан үземне чак-чак кына тыеп калдым. Ачуың килмәслек тә түгел бит: иртәгә шушы эскерттән ферма терлекләренә салам ташый башларга тиешләр, ә болар әле ул эскертне көрәргә тотынмаган!

– Кая, миңа да карта өләшегез әле, җәмәгать? – дидем мин, ачуымны бик зур кыенлык белән генә басып, юри исем китмәгән атлы булып күренергә тырышып.

Алтысы да дерт итеп киттеләр. Ә мине сайлаган җыелышта райком секретаре белән әрепләшеп азапланган Галләмов Закир агай исә, карталарын салам өстенә ташлап, сикереп үк торды. Башкалары да карталарын ташладылар. Берсенең дә алып кесәсенә салырга йөрәге җитмәде: нишләргә белмичә, аптырашып тик торалар,

– Нигә авызларыгызны чөйгә элеп, шаккатып калдыгыз? Мине уенга алырга теләмисезмени?

Берсе дә бер сүз дәшмәде.

– Синекеләрме болар, Закир абзый? – дидем мин, чәчелеп яткан карталарны җыеп алып, – мә, кесәңә салып куй!

Закир абзый кымшанып та карамады.

– Синеке түгел, димәк. Кемнеке соң болар?

Берсе дә минеке димәде.

– Ярый, хуҗасы юк, алайса, бик шәп булды әле бу! – дип, куанган сыман итеп, карталарны кесәмә салып куйдым да сәгатемә карадым: уникенче киткән иде.

Кыш көне безнең якларда мондый эштән төшке ашка кайтып тору гадәте юк. Иртәдән алып көндезге икеләргә кадәр эшлиләр дә шуннан соң барып йөрмиләр. Димәк, бу алты ирнең нибары ике-ике сәгать ярым эш вакытлары калган. Нәрсә генә майтара ала инде алар бу килештән?

– Теләсә нишләгез, иптәшләр, – дидем мин, кискен итеп, – кайтып төшке ашны ашап киләсезме яки кайтып тормыйсызмы – анысы сезнең ихтыярда. Ләкин кичкә шушы салам эскертенең, һич югында, яртысы көрәлгән булырга тиеш! Иртәгә моннан салам ташый башлаячакбыз. Әгәр эскерт көрәлмәгән булса, җавабын үзегез бирерсез!

Башкалары, көрәкләрен алып, эшкә кереште. Тик Галләмов Закир агай гына урыныннан кузгалмады. Миңа карап мыскыллы итеп елмайды да:

– Без тырышып караганыек та, барып чыгар төсле тоелмады шул, прсидәтел, кары бик калын булып чыкты, – диде. – Шуңа кәрт сугарга тотындык. Әйдә, алай бик оста булсаң, мә, минем көрәкне ал да үзең көрәп күрсәт әзрәк. Бәлки, син булдыра алырсың, бәлки, мин җаен белми торганмын!

Шулай диде дә көрәген сузды. Мин бер мәлгә аптырап калдым. Белеп торам: эш авыр булганнан әйтми ул моны. Шабашниклыкта йөрүеннән тыеп, төшемле эшеннән мәхрүм иткәнгә шушылай кылана. Минем ачуны китерергә, мине кычкырта башларга маташа. Әгәр мин хәзер дулап китеп, кычкыра-сүгенә башласам, ул миннән дә катырак тузыначак. Аннары артымнан көлеп калачак, үзен җиңүче санап, күңеленнән тантана итәчәк... Юк инде, Закир абзый, алай гына мәтәштерә алмассың син мине, дип уйладым да, ялт итеп кулыннан көрәген тартып алып:

– Бар, хәзер үк, менә шушы минутта ук кайтып кит моннан, корткыч! Үзең эшләмәвең генә җитмәгән, башкаларны да оскыртып ятма! Ахмакка санама син мине, карталарның синеке икәнлеген белми икән дип уйлама! Бар, шушы секундта ук югал күз алдымнан! Калганын кичен идарәдә сөйләшербез! – дип куа башладым тегене.

Күрәсең, минем сүзне уенга алырга ниятләде булса кирәк, Закир агай башта:

– Җә инде, ул тикле чәпчемә, уйнап әйткәнгә дә кызып китмә алай, – дип карышып маташты.

Бәлки, миңа, чыннан да, шунда үземне кулга алып, тыелып калырга кирәк булгандыр. Әмма бер кызгач туктала алмадым:

– Бар, ычкын яхшы чакта, югыйсә ахыры өчен мин җавап бирмим! – дип, көрәк белән өстенә бара башладым. Закир абзый да эшнең уен түгел икәнлеген сизенде, ахры, үзалдына сүгенә-сүгенә шыпырт кына кайтып китте.

Ә мин, җан ачуым белән тегеләр янына барып, кар көри башладым.

Минем дуамаллык аларга да күчте булса кирәк, тегеләр дә кызып-кызып эшләргә тотындылар. Дүрт сәгать буена беркем бер авыз сүз әйтмичә, пыр тузып эшләдек без. Бары шуннан ары гына, ниһаять, алтмышка җитеп килгән Саттар абзый, телгә килеп:

– Әйдә, Өлфәт туган, бер пыскытып алыйк булмаса! Хәйран каты эшләп ташладык бит, – диде. Бүреге белән маңгай тирен сөртеп алды.

Дөресен генә әйткәндә, мин үзем дә аны кызгана башлаган идем инде, тик башлап сүз әйтергә уңайсызланганнан гына дәшми тора идем. Шунлыктан бу тәкъдимен бик рәхәтләнеп элеп алдым:

– Әйдә, Саттар абзый, тартып җибәрегез булмаса!

– Ну усаллык та бар икән үзегездә, Өлфәт туган! – диде Саттар абзый, тәмәкесен төреп тарта башлагач. – Ну кызык иттең син безне бүген! Эт итеп кыйнап киткәннән дә болайрак булды инде бу!

– Ачуны китердегез бит, Саттар абзый! Минем урында булсаң, син дә карта уйнап утырган өчен рәхмәт әйтмәс идең. Миңа гына кирәк түгел ич бу салам, үзем өчен йөрмим ләбаса!

– Беләм, энем, бик әйбәт беләм. Шуңа күрә үпкәләмим дә мин сиңа!..

Кичке сәгать алтыга кадәр эшләдек без ул көнне. Теге агайларның ник берсе сукранып карасын, ичмаса! Сукранырлар иде дә, мин дә шунда, алар белән бергә эшлим бит. Шуңа сер бирәселәре килми. Тагын берәр сәгать эшләсәк, эскертне бөтенләй көрәп үк бетерергә мөмкин булыр иде, күп калмаган иде ул. Ләкин һәрнәрсәнең бер чамасы була бит. Сүземне сүз итәм дип, әтием яшендәге ул өлкән агайларны да аяктан екканчы эшләтергә ярамый ич инде!..

Менә шулай, туган. Шул хәлдән соң Закир агай минем белән сүз көрәштерүдән туктады. Кая кушсалар да, майлаган шикелле эшләп йөри башлады. Әмма шуннан ары барысы да ал да гөл булып китте дигән сүз түгел әле. Соңыннан да байтак булгалады андый чәкәләшүләр.

Гомеремдә онытасым юк. Таифә исемле бер бик чая хатын бар иде Көрнәледә. Беркемгә сүз әйтергә ирек бирми, һичкем белән исәпләшми. Кайчан тели – чыга да китә авылдан. Ачулана башласаң, авызыннан утлар чәчеп:

– Сезнең ике-өч йөз грамм икмәгегез белән бер башым ул алты баламны ничек итеп туйдырыйм мин? Мине бик эшләтәсегез килсә, тәрбияләгез әнә шул балаларны; ашатыгыз да, өсләрен-башларын да карагыз! – дип, бөтен дөньяны сасытып чәрелдәргә тотына.

– Нигә бер башың буласың ди? Ирең бар бит синең, Таифә апа! – дисәң, тагын да ныграк тузына башлый:

– Аның ише ирнең булуыннан булмавы мең артык! Бала тудыртудан бүтәнне беләмени соң ул? Аңа ышанып ятсаң, ике ай да яши алачак түгел ул балалар!

Бер уйлаганда, Таифә апа да хаклы. Ире, үзе сау-сәламәт булса да, чыннан да, төнтек, пешмәгән бер бәндә аның. Йорт-җир эшен белми дә, белергә теләми дә. Тормыш итү өчен дә пошынмый. Хатыны тапканны ашап, хатыны юнәткәнне киеп тик йөри. Фермада төнге каравылчы булып эшли ул. Көннең көн буе буш, эшсез. Аның урынында башка берәү булса, һич югында, чабата ясап сатар, йә итек басарга өйрәнер иде. Инде аларын ук эшләмәсә дә, ичмаса, йорт-җирен, каралтысын ныгытыр иде. Ә бу аркылыны буйга да алып салмый. Каравылдан кайткач, шешенгәнче йоклый да торып ашаганнан соң пожарныйлар янына килеп, әкият сата, тәмәке пыскыта. Әйткәләп тә карадым инде үзенә, әмма файдасы булмады...

Ә хатыны Таифә апа – ут борчасы! Юньләп авылга кайтып та керми. Йә район үзәгенә алып барып сөттер, каймактыр сата, яки авыл буйлап май, йомырка җыеп йөри дә Казанга чыгып китә. Авылда арзанрак алып, шәһәрдә кыйммәткәрәк сатадыр инде, күрәсең. Бару-кайтуына киткән расходларыннан соң күпме табышы каладыр – анысын белгән кеше юк. Ләкин йөри. Бигрәк тә колхозларда кызу эш барган чорларда – печән, урак өстендә һәм бәрәңге алган вакытта бик еш югала ул. Шунысына бик эчем поша минем.

Бер тарыдан ботка пешереп булмый, билгеле. Таифә апа юньләп эшләмәгәнгә карап кына колхозга әллә ни зур зыян килмәс иде. Ләкин яман чир тиз йогучан бит ул. Андыйлар бер Таифә апа гына түгел авылда, байтак. Кызып урак урган көннәрдә тагын да күбәеп киттеләр. Берничәсенең өенә барып, ташлагыз бу эшегезне, соңгысы булсын, дип оялтмакчы, тәртипкә китермәкче булган идем, авыз ачарга да ирек бирмәделәр. Әйтерсең алдан ук сүз берләшеп куйганнар – барысы да бертөрле сөйли:

– Нигә нәсел үгезе шикелле тап-таза ире булган Таифәгә сату итеп йөрергә ярый да, нигә безнең ише тол хатыннарга йөрергә ярамый? Аннан кай җиребез ким безнең? Тыясың икән, башта Таифәне тый, прсидәтел! – диләр.

Менә шуңа күрә Таифә апаның «гастрольләренә» чик куярга булдым мин. Беркөнне Казаннан кайтып килешли очратып, идарәгә алып кердем дә:

– Соңыннан үпкәләштән булмасын, Таифә апа, әйтүем шушы: әгәр дә мәгәр урак беткәнче авылдан чыгып киткәнеңне сизсәм, тотам да спекулянт итеп милициягә озаттырам мин сине! – дип кисәтеп куйдым.

Ул үзе дә бу юлы, алай карышып тормыйча, ризалашкан төслерәк итеп чыгып киткән иде. Шул сөйләшүдән соң өч-дүрт көн үтүгә, ни күзем белән күрим, чиләк-көянтәсен аскан да бакча артлатып кына таң тишегеннән тагын Казан каласы ягына китеп бара бит бу! Минем дә кан кызып китте хәзер. Тиз генә куып җиттем дә каршына бастым:

– Борыл, Таифә апа!

Башта каушабрак калды булса кирәк, күзләрен ялтыратып, сүз әйтә алмыйча торды. Аннары кинәт кызарып-бүртенеп чыкты. Гадәттәгечә, ни әйткәнен дә уйлап тормастан, чәрелдәргә тотынды.

– Чукынып кына китсәңие, энем Өлфәт! Алланың каһәре генә төшсәе үзеңә! Инде котылдым бугай дип кенә барадырыем, тәки күзеңне тәреләндереп килеп җиттең бит, ә! Нигә дип, кем өчен дип болай көн-төн чапкан буласың син? Әллә, чынлап торып, безнең калхузны алга җибәрәм дип йөргән буласыңмы? Йөрмә, наный, булмый ул, була торган нәрсә түгел ул бездә! Кая, тотма әле көянтә башын, кызлар түгел мин сиңа! Җибәр, тиз генә барып кайтыйм әле Казанга. Берсекөнгә иртүк кайтып җитәм мин, менә күрерсең, кайтып җитәм!

– Теләсәң ни әйт, Таифә апа, ләкин беркая да җибәрмим мин сине! Әйдә, борыл яхшы чакта!

– Нигә бу тикле каныгасың син миңа, Өлфәт, – диде ул, күзләремә ялвару катыш нәфрәт белән карап. – Ни зыяным тигәне бар сиңа? Син борып кайтарганга карап кына барыбер калхузны кинәндерерлек эш майтармыйм бит инде мин! Төшмә лутчы аркылы, җибәр көянтәмне! Ике көндә дөнья харап булмас бит, кайткач тырышыбрак эшләрмен! Башка чакта болай кача-поса сораусыз йөрмәм, билләһи менә, йөрмәм!

Ихтимал, инде әзерләнеп юлга чыккан һәм шушылай ялварып үтенгән кешегә соңгы тапкыр юл куйганда да ярар иде. Ләкин Таифә апаның бу сүзләрне чынлап әйтмәвен белеп торам шул мин. Күп мәртәбәләр сүз биргәне бар инде аның. Ике-өч көннән тагын шушылай тотылса, тагын шушы ук сүзләрне кабатлаячак ул! Хикмәт анда гына да түгел иде әле. Иң ачу китергәне шул: соңыннан, эш узгач, Таифә апаның мактанып йөри торган гадәте бар. Өлфәт миңа бер сүз дә әйтә алмый, әйтсә дә, тыңламыйм мин аның сүзен, имеш...

Менә шуңа күрә бүген үз сүземдә нык торырга булдым мин.

– Әйтмә дә, тыңламыйм да, Таифә апа! Борыласың да кайтасың хәзер – бетте-китте! Колхозның урагы урылып бетмичә торып, беркая бармыйсың! Җитте сиңа бүтәннәрне котыртып йөрергә! Әйдә, хәзер үк кайтып, чиләк-көянтәңне калдыр да, урагыңны алып – кырга!

Сүземнән кире кайтмаячагым кыяфәтемә үк чыккан иде, ахрысы, Таифә апа, тәмам өметен өзеп, җан ачысы белән соңгы сүзләрен әйтергә кереште:

– Алланың әче каһәре генә төшсен, имансыз җан! Җир генә йотсыные үзеңне, сары тәре! Кансыз ук икәнсең! Юньле бәндә булсаң, багалмасы шикелле хатыныңны куып җибәрмәсиең син! Гомергә буйдак булып калсаңые, бер Ходаем, гомергә хатын таба алмасаңые, тфү!

Лачкылдатып битемә төкерде дә җир акырып еларга тотынды. Минем урында син булсаң, белмим, нишләр идең икән, туган, әмма минем шуннан соң да түзеп торырлык хәлем калмады. Башкасына исем китмәгән иде минем, алары көн дә ишетелеп тора торган сүзләр. Ә менә хатын мәсьәләсенә кагылгач, йөрәгемне нидер чәнчеп алды да, үземне үзем белештермичә:

– Ах, син әле шулаймы! – дип кычкырып җибәрдем һәм Таифә апаның бер чиләген, йолкып алып, бакча киртәсенең казыгына китереп тә ордым. Яньчелеп үк китте чиләге. Аннары, туктале, эчендә нәрсә бар иде икән соң моның, дип, чиләкнең авызын бәйләгән иске яулыкны чишеп карасам –

йомырка икән! Бер чиләк йомырканың барысы да сытылып беткән иде. Оят та, кыен да булып китте миңа. Әмма нихәл итәсең соң инде? Бер секунд, бары тик бер секунд кына харап итте бөтен эшне!

Мин тилмереп, гафу үтенмәкче булып башымны күтәреп караганда, Таифә апа, сыңар чиләген тотып, йөгереп дип әйтерлек тиз-тиз атлап, арт капкаларыннан кереп бара иде инде.

Нигә алай итүемнең сәбәбен үзем дә аңламыйча, бик мөһим эш башкаручы кешедәй, мин чиләктән йомырка кабыкларын санап читкә алып атарга тотындым. Минем исәп буенча, туксан җиде йомырка булган булып чыкты. Димәк, мин Таифә апага йөзләп йомырка табып бирергә тиеш. Анысын гына ничек тә табарга булыр иде әле, иң хәтәре шул: бөтен авылга, авылга гына түгел, бөтен районга хәбәр таратачак бит ул хәзер! Их, үзем дә инде!.. Шултикле булырга ярыймы соң?!

Кабыкларын чүпләп бетергәннән соң, ярты чиләккә якын йомырка эче калды. Моны кая куярга инде хәзер? Таифә апага илтүдән фәтва юк, барыбер алмаячак...

Уйладым-уйладым да, йомырка тәбәсе пешертеп, механизаторларга илттерергә булдым. Урак өстендә төшке ашны аларга колхоз исәбеннән ашата идек. Көн дә аш та аш кына димәгән, йомырка да ашап карасыннар әле бер!

Шул фикер башыма килгәч, күңелем күтәрелеп китте. Чиләкне тоттым да механизаторларга аш пешерүче карчыкка алып барып бирдем.

Мин Хәерниса карчыклардан чыкканда, урагын иңенә салып, Таифә апа каршыма килә иде. Ну була хәзер хәлләр! Бөтен авылны җыя инде бу! дип котым да калмаган иде. Ләкин алай булып чыкмады. Таифә апа, бер сүз дә дәшмичә генә аска карап, кырга урак урырга китте. Бу хәлне болай гына калдырыр дип һич тә көтмәгән идем мин. Ләкин ул шул көнне кич, уртанчы кызын җибәреп:

– Иртәгә кичкә йөз дә ун йомырканы табып китереп биргән булсын штубы! – дип кенә әйттерде дә, мин колхоздан тиешле йомыркаларын илттерткәч, бу хакта сүз кузгатып йөрмәде. Ә бит, теләсә, бише белән түләттерә ала иде ул!

**21**

Шуннан соң мин бер дә алай дуамалланмаска, ничек кенә ачу килгән чакларда да сабыр булырга үз-үземә сүз биргән идем. Шактый гомер шул сүземнән чыкмыйча йөрдем дә. Әмма берсендә тәки тыелып кала алмадым. Әле дә бик еш уйланам ул турыда. Бер уйлаганда, үземне гаепләп, алай ук кызып китмәскә кирәк иде, дип үкенеп тә куям. Икенче уйлаганда исә, әле ярый шулай иткәнмен, минем урында булса, бүтән кеше дә нәкъ минемчә эшләр иде, дип, үземне үзем юаткан чакларым да күп була. Ләкин шул фикерләремнең кайсы дөрес икәнен бүген дә өзеп кенә әйтә алмыйм әле. Бик четерекле, бик зур эш булды ул, туган. Минә тыңлап кара әле, бәлки, син аерып бирерсең.

«Ватан»да икенче елымны эшли идем мин ул чакта. Урып-җыю эшләре төгәлләнеп килә, көзге чәчүгә чыгарга әзерләнеп йөри идек. Бер дә бер көнне, кырдан, тракторчылар яныннан кайтып килешли, минем туган авыл белән Көрнәле арасындагы Лашман күпере дип йөртелә торган күпердә, һич тә истә-оста юк чакта, Рәдиф очрады миңа. Күпер төбендә бит-кулын юып азаплана иде. Мин сүз катмыйча гына үтеп китмәкче булган идем дә, барып чыкмады. Күпергә килеп кергәннән соң арба дыңгырдый башлагач, Рәдиф башын күтәрде дә, мине танып алып, кулы белән «туктап тор әле» дигәнне аңлата торган ишарә ясады. Мин атны туктаткач, күпергә алпан-тилпән менде дә яныма килеп басты.

– Них... них... хәл, Өлфәт дус? – диде ул, телен чак әйләндереп. – К...аян кил...еш?

– Тракторчылар янына барган идем. Үзеңнең нишләп йөрү? Нигә шултикле күп эчтең? Аягыңда басып торырлыгың да калмаган бит!

– Ниг...гә эчтемме? Ан...нысын мин үз... һык!.. үз...зем беләм аның! Дав...вай, син ми...не кай... һык!.. кай...тарып куй әле, яме!

Шулай диде дә арбага менеп утырды. Ул тагын нидер әйтергә калкынган иде дә, бик каты очкылык тота башлагач туктап калды. Аннары укшырга тотынды һәм, тагын «торып тор» дип ишарә ясап, арбадан төшеп, читкәрәк китте.

– Х-хәзер бетә! – диде ул, байтак азапланганнан соң бераз рәткә керә башлап. Аннары, су буена төшеп, ярга сузылып ятып, су эчеп менде.

Мине үзләренә кунакка чакырган Рәдиф түгел иде инде ул хәзер. Әле утызга гына якынлашып килсә дә, илле яшьлек кешегә охшап, картаеп, ябыгып калган иде. Өстендә дә мин фронттан кайткан вакытта киеп йөри торган зәңгәр галифе чалбар белән зәңгәр гимнастерка түгел, иске гражданский чалбар да беләүләнеп беткән пинжәк. Аягына да элекке ялтырап торган хром итекләр урынына кыршылып беткән кирза итек кигән. Ә башында бер нәрсәсе юк, чәчләре, тузып, күзләренә төшеп тора. Бөтен өс-башы буялып, пычранып беткән.

– Әйдә, Өлфәт, авырсынмый гына авылга кайтарып куй инде син мине, малай! Үләм ату, аяк атлар хәлем дә юк! – диде ул, көн шактый эссе булса да, дер-дер калтыранып һәм хәйран айнып китеп.

– Кайта алмаслык булгач, эчмиләр аны. Теләсәң ни әйт, мин сине илтмим, Рәдиф!

– Дуслык хакына да тыңламыйсыңмы?

– Хатыныңа кул сузган кешене син дус итә алыр идеңме соң?

Рәдиф беркавымга тотлыгып калды. Аннары башын аска иде дә:

– Мин нәкъ менә шул турыда сөйләшмәкче идем синең белән, Өлфәт, – диде.

– Нәрсәсен сөйләшәсең аның? Аңлашасын аңлаштык бугай бит инде.

Мин шулай дигәч, ул бөтенләй айнып киткәндәй булды. Җиңемнән тотып, тонган күзләрен мөлдерәтеп, йөземә текәлеп карады да, чын күңеленнән ялварып:

– Әгәр булдыра алсаң, кичер син мине, Өлфәт! – диде. – Зинһар, кичер мин бөҗәкне! Алдаштым бит мин теге чакта. Сәкинәң белән чуалдым, дип юри әйттем.

– Соң нигә кирәк булды сиңа безнең тормышны бозу? Ни кызыгын таптың инде шуның?

Ул, уңайсызлангандай булып, читкә бераз карап торды да:

– Шул минем урынга сине куясыларына ачуым килүдән булгандыр инде, Өлфәт. Аннары, якын җибәрмәгәне өчен, Сәкинәңә дә хәтерем калган булгандыр, – диде.

Арбадан сикереп төштем дә каршына килеп бастым:

– Чынлап әйттеңме син бу сүзләреңне, Рәдиф?

– Шушы урынымда җир йотсын, әгәр ялганласам!

– Ә Хафиз карт нигә «үзем күрдем» диде икән соң?

– Анысы да минем эш иде, Өлфәт, мин котырттым аны ул чакта. Синең белән сөйләшкән кичнең иртәгесен иртүк районга бардым да Хафиз картны утыртып алып кайттым. Менә шунда, юлда кайтышлый, ялган шаһитлыкка күндердем мин аны. Ул чакта ул карт минем кулда иде әле, минем сүздән чыкмый иде.

Аның шушы сүзләреннән соң бөтен күңелем әллә нишләп айкалып китте дә, ни кылуымны үзем дә абайламыйча:

– Җитте, Рәдиф, артыгын сөйләмә! Булды, рәхмәт! Мә сиңа шуның өчен! – дип, башта авызына берне тондырдым, аннары күтәреп алып күпердән ыргыттым.

Ул лапылдап су читенә барып төште дә тынсыз калды, ә мин, кинәт өнемә килеп, куркып-аптырап киттем: «Нишләдем мин? Әллә бөтенләй харап иттем инде кешене!» – дип хафаланып, йөгереп янына төшкәндә, Рәдиф әле һаман һушсыз ята иде.

Ни эшләргә дә белмичә бераз торгач, мин аны күтәреп алып менәргә дип кузгалган идем, күпер өстеннән:

– Әй Өлфәт, Өлфәт! Шулай ук ярыймы соң инде? Харап иттең бугай бит кешене! – дигән тавыш ишетелде.

Күтәрелеп карасам – Закир абзый. Теге вакытта салам көрәргә барган җиреннән мин куып кайтарган Галләмов Закир абзый! Күпер тирәсендә генә печән чабып йөрүе икән. Шуннан безнең бәйләнешкәнне карап-күреп торган!

Яшерен-батырын эш итәрлек ара да, чама да юк иде хәзер. Беткән баш беткән инде, дип уйлап алдым да:

– Әйдә, анда остарып торганчы төш монда, алып менеп арбага салыйк әле үзен! – дидем мин аңа, бер дә исем китмәгәндәй күренергә тырышып.

Без ярты гәүдәсе суда яткан җиреннән тартып алып күтәрә башлагач, Рәдиф бик каты ыңгырашып куйды. Аннары, күкрәгеннән тотып:

– Үләм, кузгатмагыз! Тимәгез миңа! – дип кычкырды.

– Тукта, Өлфәт, кая, куеп торыйк әле! – дип, Закир абзый башта Рәдифне иплэп кенә җиргә яткызды. Аннары тегенең күкрәген, ян-якларын капшарга тотынды. Уң як кабыргасын капшый башлагач, Рәдиф тагын җан өшеткеч итеп илереп куйды.

– Әһә! – диде Закир абзый, ниндидер нәтиҗәгә килеп. – Болай икән эшләр! Ә син алай ук борсаланма, энекәш! – диде ул аннары, Рәдифкә мөрәҗәгать итеп. – Әллә ни куркыныч нәрсә юк монда. Сынса, бер кабыргаң гына сынгандыр. Кабырга сынганнан берәүнең дә үлгәне юк әле. Тик кенә ят, тик ятсаң авыртмас ул! Кая, Өлфәт, су алып кил тиз генә, авыз-борыннарын юыйк, бу килеш адәм күзенә күрсәтә торган түгел бу.

Башымнан кепкамны йолкып алдым да шуңа тутырып су алып килдем.

Хәйран батыр йөрәкле кеше икән Закир абзый: Рәдифнең ыңгырашуына һич исе китмичә, битен ялт иттереп юып алды. Күрәсең, күпердән барып төшкәндә берәр ташка бәрелгән булгандыр, Рәдифнең маңгаенда да яра эзе бар иде. Үги ана яфрагы ябыштырып, аның да канын туктатты. Аннары әйтте:

– Әйдә, Өлфәт, иплэп кенә күтәреп алып меник инде! Җайлап кына арбаңа салыйк та, өйләренә илтеп куй син моны!

Ул минутларда минем үз башым берни эшләми иде, Закир абзый кушканны гына үтәп йөрдем...

Мин Рәдифне алып кайтып, җитәкләп өйләренә керткәндә, энисе Мәсрүрә апа үзенә урып җәеп йөри иде. Күргәнем юкка, күп булса, бер ел үткәндер, әмма шул арада Мәсрүрә апа, бик нык ябыгып, тәмам карчыкка әйләнгән, бичара: чәчләре дә агарып калган, яңаклары да эчкә баткан, сөйләшүенә хәтле бөтенләй үзгәргән. Элек чат-чат килеп, кеше бер сүз әйткәнче, унны әйтеп ала торган иде ул. Ә хәзер сабыр гына, теләр-теләмәс кенә әйтә сүзен. Мин Рәдифне алып кергәч тә, бер дә алай күтәрелеп бәрелмәде. Хәтта нишләгән, кайда булган, дип тә сорашып тормады.

– Эчеп исерү генә түгел, егылып муены сынса да, сүзем юк, олан! – диде дә, бүтән бер сүз дә дәшмичә, урынын җәюен дәвам итте. Аннары, үзалдына сөйләнгәндәй генә итеп: – Пычак та булмас әле! Күзен-башын тондырып, иртәгә үк баш төзәтергә акча сорый башлар! Озаграк ятса, әзрәк иркен сулыш алырыем, ичмаса, ятмас шул! – диде. Урынын җәеп бетергәч тә, Рәдифкә бөтенләй игътибар итмичә, каршыма килеп: – Әй, Өлфәт наный, тәмам бозылды бит бу малай! Бөтенләй кешелектән чыгып бара инде! Заффирмылыктан да шул эчкән өчен алып ташладылар аны,– диде. Рәдиф аерып җибәргән киленен сагынып искә алды: – Бер генә дә килмәгән җире жугые балакайның, бөтен авыл җаратадырые үзен, минем өчен дә, әнкәй, дип үлеп торадырые. Үкенечкә генә булган икән, менә шушы хәерсезнең эчүенә түзә алмыйча ташлап китте, – диде.

Әйе, мин үзем дә бер-ике тапкыр күреп калган идем Рәдифнең ул хатынын. Узган ел педучилище бетереп кенә килгән бер укытучы кызга өйләнде. Буй-сыны дисеңме, төсе-битеме – бөтенесе бик килгән иде. Балаларны да яхшы укыта, дип мактадылар... Күрәсең, түзәр чамасы калмагандыр, шуңа киткәндер Рәдифне ташлап.

Киленен сагынып елап алганнан соң, Мәсрүрә апа миннән:

– Өйләндеңме әле? – дип сорады да, мин:

– Юк, – дигәч:

– Җөрмә, наный, болай ялгыз, ал да кайт Сәкинәңне! – дип, мине үгетләргә тотынды.

Ләкин мин аның үгет-нәсихәтләрен тыңлап торыр хәлдә түгел, башымда мең төрле уйлар кайный иде. Тиз генә саубуллаштым да Хафиз картларга киттем.

Өйләренә кереп тормадым, ишекләрен шакып, өйалдына гына чакырып чыгардым.

– Әйт әле, сөннәт бабай, теге чакта күпмегә сатылдың син Рәдифкә? – дидем. Һәм, шырпы сызып, йөзен яктыртып карадым.

Башка вакытта бернәрсәгә дә алай шаккатмый торган Хафиз карт бу юлы каушап калды, башта ни әйтергә дә белмичә, ык-мык килеп торды.

– Нигә җавап бирмисең? Зелпе җыеп йөргәндә күрдем, дип, нигә ялганладың? –дидем мин, ярсып.

– Туктале, олан, иплэп кенә әйт әле син: кем әйтте сиңа мин нахак сөйләгән дип? – диде Хафиз карт, ниһаять, үзен кулга алып, батыраеп китеп.

– Кем әйттеме? Рәдиф үзе әйтте! Давай, боргаланмыйча гына сөйләп бир тизрәк: нигә ялганладың син миңа ул чакта? Нигә минем тормышны боздың?

– Сәбәбе шул тамак инде аның, олан, – диде ул, калтыранып. – Тамак тәмугка кертә ул! Үзең дә беләсең, бик авыр заманалары бит ул чакта. Ә Рәдиф кулында ризык барые.

«Синдә генәмени ул тамак, башкаларда юк иде микәнни» дип әйтергә һәм ипи шүрлегенә бер менеп төшәргә бик кыжрап торсам да, Рәдиф белән бүген генә булган хәлне искә алып, мин үземне тыеп калдым һәм:

– Ярый, урының җәннәттә булыр инде болай булгач! – дидем дә, ул кабахәт картның йортыннан чыгып, атыма утырып кайтып киттем.

Гаҗәеп тын, айлы кич иде. Һава саф, салкынча. Сулап туймалы түгел. Ат, ара-тирә пошкыргалап, үз көенә генә атлап кайта. Мин, арбага сузылып ятып, күктәге йолдызларга карап уйланып барам. Кемнәр генә йөрмәгәндер инде бу йолдызлар астында? Нинди генә хәлләргә шаһит булмагандыр инде алар? Хәзер менә мине, мин ахмакны күреп торалар. Мондый да кешене күргәннәре бар идеме икән әле аларның?.. Юктыр, булса да, бик сирәктер...

Нишләргә соң инде миңа? Кая барырга? Рәдиф айныганны көтеп, аның белән үзара мөнәсәбәтне ачыклаганчы шушылай тыныч кына, берни дә дәшмичә генә торып торыргамы? Әллә иртәгә үк улым Ирек белән Сәкинәм янына чыгып китәргәме?.. Вакытының шундый мәшәкатьле чагы туры килүен әйт әле син аның! Бүген-иртәгә көзге чәчү башланырга тора бит! Андый чакта үзең көн-төн карап-тикшереп торсаң да, таманга гына килә әле ул. Узган көз әнә чәчүлек орлык ташучының берсен җавапка тарттырмыйча тәки булмады. Үз күзең белән карап эшләтүгә җитми инде ул. Ышан, әмма тикшереп тор, дип тикмәгә генә әйтмәгән инде Макаренко!..

Анысы шулаен шулай да, ә мин чәчү чәчтереп йөргән арада, Рәдиф эшне судка бирсә? Кабыргасы сынган, диде бит анда Закир абзый... Хәер, сынмаган булса да, рәхәтләнеп рәшәткә артына тыктыра ала ул мине. Гаепләр өчен маңгаендагы ярасы да бик җиткән!.. Шаһит эзләп йөрисе юк: Закир абзый барысын да күреп торган бит! Аның да миңа үпкәсе бар... Юк, сузарга ярамый бу эшне! Үзләрен үк алып кайтып булмаса да, һич югында, Сәкинә белән Ирекне күреп, алларына тезләнеп гафу үтенергә кирәк...

Уйладым-уйладым да болай итәргә булдым, туган: Оренбургта минем әнинең бертуган абыйсы яши иде. Җитмешкә җитеп килә торган ул ялгыз карт әле быел җәй генә минем янга кайтып, айга якын торып китте. Менә шул абый бик авыр хәлдә икән, тиз генә килеп җитәргә кушып, телеграмма суккан, дип, үз урыныма беренче бригада бригадирын калдырдым да, иртән-иртүк торып, Сәкинәм белән улым Ирек янына юл тоттым.

**23**

Казанга барып, поездга утырганнан соң бик нык пошына, борчыла башладым. Билгесезлек өзгәли иде күңелне. Кем белә анда – Чиләбедә нәрсә буласын? Бәлки, Сәкинә инде күптән башка кешегә кияүгә чыккандыр. Яисә, кияүгә үк чыкмаса да, берәрсен яратып йөридер. Андый чибәр, яшь һәм акыллы хатынга берәрсенең күзе төшмәгәндер дип кем әйтә ала?.. Әгәр мин барып кергәндә, ул ире яки яратып йөри торган кешесе белән утыра торган булса?.. Мине күрергә теләмәсә?.. Алай итәргә дә тулы хакы бар ич аның: үз иркендә яшәүче ләбаса ул хәзер! Дүрт ел ярымнан артык бит инде безнең күрешкәнебез юкка. Ул арада ниләр генә булмагандыр дисең?..

Әгерҗене узганда, әллә барып та йөрмим микән, дип борылып кайтып китмәкче дә булган идем. Ләкин аннары кире түндем. Юк инде, бер кизәнгән икәнсең, әйдә сук, гомер буе саргаеп, берни белмичә яшәгәнче, ичмаса, үз күзләрең белән барысын да күреп-белеп кайтырсың...

Кулымдагы адрес буенча сорашып килеп кергәндә, мине, шактый өлкән яшьләрдә булса да, әле нык, җитез һәм ягымлы гына бер карт каршылады. Башта чак кына сәерсенебрәк торса да, кем икәнлегемне, нишләп йөрүемне белешеп алганнан ары, Фәхретдин абзый кинәт яктырып, ачылып китте:

– Кияү тиешле кеше буласың икән алайса! Әйдә, ишек катында гына торма! – дип, шундук түр якка алып керде.

Өйдә ул ялгызы гына иде. Карчыгының Казанда яшәүче малайларына кунакка киткәнлеген, Сәкинәнең эштә булуын, ә Ирекнең урамга уйнарга чыкканлыгын әйткәч:

– Зыян юк, энекәш, үз вакытлары белән бар да кайтырлар. Ә менә килеп чыгуың яраган, бик әйбәт булган анысы! – диде.

Ике бүлмәле квартирада бер дә җитешмәгән нәрсә юк кебек. Аяклы машиналары да, зур гына радиоалгычлары да бар. Стеналарында ике бүлмәдә ике зур-зур келәм. Зал идәнендә дә бик әйбәт берсе бар – өстенә басарга аяк тартмый. «Мондый кешеләрдә яшәгәч, Сәкинә, шәт, азып-тузып йөрмәгәндер әле. Алай булса, Фәхретдин абзый үзләрендә тотмас иде», – дип, бераз тынычланып куйдым мин, аларның өй эчен күздән кичергәч.

– Кунакның ризыгы үзе белән йөрер, дип бик дөрес әйткәннәр икән. Какрас чәй өлгертеп тора идем, әйдәле, чәй янында сөйләшеп утырыйк! – дип, Фәхретдин абзый мине кухняларына алып керде.

Чәе генә түгел, мәе дә бар икән картның.

– Син, энекәш, миңа үпкәләмә, мин үзем булдыра алмыйм аны. Яшь чагында тоткалый торган идем дә, хәзер ярамый ул миңа. Син үзең чамала инде, яме! – дип сөйләнгәләп, анысын да китереп куйды.

Мин инде байтактан эчмәвемне әйткәч, мине дә кыстап тормады. Гаҗәпләнеп телен шартлатып кына куйды да аерылышуыбызның сәбәбен сорый башлады.

– Ала-а-ай! – диде ул, мин бөтенесен аңлатып биргәннән соң, чалара башлаган мыегын сыпырып. – Алай икән! Ашыгыбрак типкәнсең икән шул тәртәгә, энекәш. Сез, яшьләр, кайчакта ашыгычрак кылanучан шул. – Беркавым тынып торды да дәвам итте: – Туганы булганга болай сайрый инде бу дип уйлама, мин сиңа дөресен әйтәм: бик уңган хатын ул Сәкинә! Кадерен белеп кенә тотарга кирәк булган аны сиңа. Авылдан малаен ияртеп килеп кергәннән бирле бездә яши, ник бер андый-мондый кыек эше сизелеп карасын ичмаса! Кемнәр генә килмәде инде үзен сорап, берсенә дә әйләнеп карамый. Минемчә, сине оныта алмый бугай ул, энекәш. Үзе сиздерергә дә теләми теләвен. Әнә шул искитмәгән атлы булып күренергә тырышуы үзе үк сине яратуының бер билгесе инде ул.

Шунда туктап, икебезгә дә тагын берәр чынаяк чәй ясады да янә сөйләргә кереште:

– Безгә килеп кергәндә, йөзенә карарга куркыныч иде Сәкинәнең. Саргаеп, ябыгып беткән иде. Килеп эшкә урнашкач та, берничә ай бик боек йөрде. Шәһәр тормышына күнегә алмыйча интекте бугай. Хәзер ияләште инде. Ә малаең тач үзеңә охшаган инде менә! Синеке төсле үк зәп-зәңгәр күз, бакыр чәч, шундый ук калын каш. Хәтта сипкеленә тикле шушылай синеке төсле үк куе, чуп-чуар. Шуңа тиз танып алдым мин сине. Килеп кергәч дигәнем.

– Минем дөньяда барлыгымны беләме икән соң ул малай, Фәхретдин абзый? Әтисе барын беләме, кайда, дип сорыймы?

– Сорамыймы соң инде, энекәш! – диде ул, тирән итеп көрсенеп.

– Нәрсә дисез соң аңа? Сәкинә ни дип җавап бирә?

– Ирек өчен солдат син, энекәш! Әле һаман армиядә хезмәт итә дип белә ул сине. Барыбыз да аңа шулай дип аңлатабыз. Сәкинәдә синең сугыш елларында җибәргән бер рәсемең бар. Шул рәсемне

күрсәтәбез Иреккә. Башта «әтием безне фашистлардан саклый» дип куанып, мактанып йөри иде. Ә хәзер инде «ник кайтмый соң ул, нигә бик озак тора анда» дип аптырата.

Мин ни әйтергә дә белмичә аптырап утырганда, Фәхретдин абзый кинәт кенә урыныннан купты да:

– Әй, бу карт кешенең башкайлары, бер генә дә юньләп эшли белми бит! Үзем сиңа шул малай турысында кайчаннан сөйләп утырам, ә үземнең шуны чыгып апкерергә уема килмәгән. Әйдәле, апкайтыйк әле үзен! – дип, мине ияртеп алып китте.

Әллә ни ерак та булмаган икән Ирек: күрше йорт ишегалдында иптәшләре белән пыр тузып туп тибеп йөриләр иде. Фәхретдин абзыйны күреп алуга очып кына килде дә картның муенына менеп асылды.

Уф!.. Ул минутлардагы кичерешләремне сөйләп кенә аңлата торган түгел, туган. Уйлап кына кара: малайга инде тугыз тулып килә, ул инде тәмам үсеп беткән, ә мин аны нибары атна-ун көн генә күреп калган кеше бит. Миннән башка, мин юләр атасыннан башка үскән ләбаса ул! Минем хәлгә калуны дуска дип әйтмим, дошманга да күрсәтмәсен...

Фәхретдин абзый дөрес әйткән: Ирегем бетеп үземә охшаган икән! Күзе-кашы гына түгел, авыз-борыннарына тикле, колакларына тикле нәкъ минеке. Буй-сынга да үзем шикелле үк эре буласы...

Мин аның атасы, ул миңа әйләнеп тә карамый ичмаса. Тырнак очы кадәрле дә игътибары юк.

– Нишләп йөрисең, бабай, ник килдең монда? Әни эштән кайтмадымы әле? – дип, Фәхретдин абзый белән мәш килә. Ә минем аның белән сүз башларга йөрәгем җитми. Урынлы-урынсыз сүз ычкындырып, өркетеп, үпкәләтермен дип куркам.

Күрәсең, һаман артларыннан ияреп килүемә сәерсенеп булса кирәк, подъездга кереп баскычтан күтәрелә башлагач кына, Фәхретдин абзыйга елышты да:

– Бу абый ник гел безгә ияреп килә, бабай? – дип сорап куйды.

Җавабы әзер түгел иде булса кирәк, Фәхретдин абзый бер мәлгә тотлыгыбрак калды. Аннары Иректне миңа таба борды да:

– Яхшылабрак кара әле, улым, кемгә охшаган бу абыең? – диде.

– Мин каян белим аның кемгә охшаганын? – диде Ирек, һич тә исе китмичә генә.

– Бу синең әтиең була инде, улым!

Ирек пырхылдап көлеп җибәрде дә, шундук җитди төс алып:

– Ялганлап торма әле, бабай! Нинди минем әти булсын ди бу кеше? Минем әти солдат бит ул! – диде.

– Әтиең инде, улым, алдамыйм мин сине. Солдаттан башта авылдагы әбиеңнәргә кайткан ул. Солдат киемнәрен шунда калдырып килгән. Чын әйтәм, әтиең бу, улым! Кергәч, рәсемен алып карарсың әле менә.

– Карап тормыйча да бик яхшы беләм мин: минем әти түгел бу!

Сизеп торам, инде миңа да сүзгә катнашырга, ничек булса да Ирекнең күңелен табарга, үз ягыма тартып карарга кирәк. Ләкин ул сабыйда үземә хөрмәт уятыр өчен ни әйтергә, эшне нәрсәдән башларга соң? Гадәттә, кеше белән беренче очрашу һәм шул вакытта аның әйткән сүзләре гомер буена сакланып кала бит!

– Әйдә әле, Ирек, берәр уенчык кибетенә алып бар әле син бабаң белән мине! Беләсеңме уенчык кибетен? – дидем мин, ни газапланып та шуннан да юньлерәк сүз дә, тәкъдим дә таба алмыйча.

Үзенә ошаган берәр уенчык алып бирү әллә нинди матур сүзләрдән дә әйбәтрәк булыр, дип уйлаган идем. Дөрес фикер йөрткәнмен икән: шундук күзләре очкынланды малайның.

– Беләм, абый, безнең йорт янында гына ул! Әйдә алып барам! – дип, Ирек мине җитәкләп дип әйтерлек уенчык кибетенә алып керде. Ә инде үз теләге буенча башта уенчык машина, аннары кием-салым кибетеннән әйбәт кенә костюм-чалбар алып биргәч исә бөтенләй үз итеп, күптәнге танышыдай ияләшеп китте. Әй бу гөнаһсыз сабыйлык!..

Шулай да үз әтисе булуыма Ирек бөтенләй үк ышанмаган иде әле. Әйләнеп кайткач та, әнисенең альбомындагы минем рәсемне алып, байтак кына бер миңа, бер рәсемгә карап торды. Аннары:

– Чыннан да минем әтиме бу, бабай? – дип сорады. Бары тик Фәхретдин абзый тагын бер кат:

– Чынлап та әтиең бит инде, улым! Куркып торма инде, бар, кочаклап ал үзен! Бик сагынып кайткан бит ул сине! – дигәч кенә, кыяр-кыймасрак килеп, алдыма менеп кунаклады.

– Ә син китмисеңме инде, әти? Бөтенләйгә кайттыңмы син? – диде ул, мин куанычымнан тәмам тилерер чиккә җитеп, аны озаклап сөйгәннән-үпкәннән соң.

– Минме?.. Китәргә туры килә шул, китәбез, улым. Сине дә, әниеңне дә авылга алып кайтырга килдем. Бик рәхәт безнең авылда! Синең шикелле малайлар да күп. Шулар белән уйнарсың, урманга йөрерсең. Безнең бакча артында гына урман. Кайткач, мин сиңа гармун да алып бирермен әле, яме!

Ләкин Ирек алай тиз генә ризалашырга ашыкмады.

– Ә бабайны алып кайтмыйбызмыни? – диде ул, гаҗәпсенеп.

– Кайтса, аны да алып кайтырбыз, балам!

– Кайтасыңмы, бабай? Кайтабызмы әти белән? – диде Ирек. Ялт итеп Фәхретдин абзый каршына барып басты.

– Бик кайтыр идем дә, өйдә кеше калмый бит, улым. Мин дә синең белән кайтып китсәм, мәчебез ялгыз кала ич, аны кем карар?

– Әйе шул, бабай, мәче бар бит әле безнең! – Аннары малай кинәт миңа мөрәҗәгать итеп: – Юк, кайтмыйм мин авылга! Ә гармунны кайткач посылка белән...

Шунда кисәк кенә ишек кыңгыравы чылтырап куйды. Каян сизенгәндер Ирек:

– Ура! Әнием кайтты! – дип кычкырды да ишеккә атылды.

– Әнием, әтием кайтты! – диде ул, ишекне ачканны да көтмичә куанычын белдерергә ашыгып.

**24**

Сәкинә килеп кергәндә, үле дә, тере дә түгел идем. Ул да мине күргәч тукталып калды. Минем дә сүз башларга йөрәгем җитми, аның да башлап сүз катасы килми иде, ахрысы. Йа Рабби! Ул хәзер элеккегә караганда да чибәрләнеп, яшәреп киткән ләбаса! Әй, килешә дә икән соң үзенә шәһәр киеме! Аягында биек үкчәле ялтыравыклы кара туфли, өстендә зәңгәрсу костюм. Чәчләрен кистергән, бөдрәләтеп җибәргән...

Коточкыч кыен хәлдән мине улым Ирек коткарды. Әйтергә көч таба алмыйча торган арада әле Сәкинәгә, әле миңа карангалап алды да, гаҗәпсенеп һәм куанып:

– Әллә танымыйсыңмы, әти? – диде. – Безнең әни бит инде бу! Нигә күрешмисең?

– Шулаймыни, улым? – дигән булып, мин Сәкинә янына бардым һәм ояла-курка гына кулымны суздым: – Нихәл, Сәкинә? Әйдә, күрешик инде.

Ул озын керфекләрен сирпеп, сагышлы күзләрен күтәреп карады да:

– Әйдә, күрешик алай булгач, – дип, йомшак, җылы кулын бирде.

Күрешмәгәнебезгә инде күпме гомер узган, әмма шундый таныш, шундый якын, шундый үз кул иде ул! Күңелем шундый тулган, нечкәргән, дулкынлану катыш шатлыгым шундый дәрәҗәгә җиткән иде – авыз ачып бер сүз дә әйтә алмадым. Күзләремнән тәгәрәп чыккан яшь бөртекләрен Иреккә күрсәтмәс өчен, аннан да бигрәк Сәкинә белән сөйләшә башларга сүз таба алмыйча, тиз генә икенче бүлмәгә кереп киттем. Сизми дә калганмын, без Сәкинә белән бер-беребезгә карашып, күрешеп торганда, Фәхретдин абзый да шунда кереп утырган булган икән. Мин килеп керүгә:

– Тукта, мин башта үзем сөйләшим әле Сәкинә белән, – дип, зал якка чыкты да: – Бар әле, улым, әтиең янына кереп тор әле! – дип, Иректне минем янга кертеп җибәрде.

Ун-унбиш минутлап мыдыр-мыдыр сөйләшкәннән соң, Фәхретдин абзый минем янга керде. Кыяфәте бик җитди иде аның.

– Бик каты тора әлегә, энекәш, – диде. – Ләкин син егет бул! Әгәр иплән кенә, җаен белеп, егетләрчә сөйләшсәң, алай бик үк этеп җыкмас дип уйлыйм. – Аннары Иректне җитәкләде дә: – Әйдәле, улым, без синең белән кибетләргә чыгып керик. Атаңның иртәдән бирле ашаганы юк икән, бик ашыйсы килгән, аңа тәмле әйберләр алып кайтыйк әле! – дип сөйләнә-сөйләнә урамга алып чыгып китте.

Күкрәгемнән сикереп чыгардай булып гөрселдәп типкән йөрәгемне тотып, өч мәртәбә тирән итеп суладым да, ниһаять, тәвәккәлләп, олы якка, Сәкинә янына чыктым. Ул өстәлгә таянып, башын ике кулы белән тотып, уйга чумган килеш, аска карап утыра иде. Мин янына килеп баскач та, күтәрелеп карамады.

Шунда аны кысып кочаклап, күтәреп аласым һәм, теге чакта сабан туеннан соң озата баргандагы шикелле итеп, онытылып үбә-үбә, зыр-зыр әйләндерәсем килде. Ләкин йөрәгем җитмәде. Кочып алырга түгел, чәчләреннән сыйпарга да курыктым. Үпкәләтермен, ачуланыр кебек тоелды. Шул ук вакытта болай багана шикелле басып тору да читен иде.

– Яңагыма чап әле минем, Сәкинә! – дидем мин, уйлап-уйлап та шуннан бүтән әйбәтрәк сүз таба алмыйча.

Ул бөтенләй игътибар итмәде.

– Мин ялгышканмын, Сәкинә!

Күтәрелеп тә карамады.

– Кичерә алырсыңмы икән син мине, Сәкинә? Улыбыз Ирек хакына булса да кичерүеңне үтенәм мин синнән!

Әллә ташка әйттем, әллә аңа: һаман шулай тик кенә утыра бирде.

– Мин сезне алып кайтырга дип килдем. Бер дә юкка рәнҗеткәнмен мин сине. Рәдиф үзе шуны әйтте: «Сәкинәңә ачу итеп, сине минем урынга куясы булганга үч итеп кенә алдаштым мин», – ди. Хафиз картны да шаһитлыкка ул яллаган булган икән... Йә, әйт инде берәр сүз?

Бары шуннан соң гына башын күтәрде Сәкинә. Мөлдерәп аккан яшьле күзләре белән шактый гомер аптырап, гаҗәпләнеп һәм үпкәләп карап торды да, ниһаять, телгә килде:

– Шулаймыни? Рәдиф шулай дип әйттеме? Шул ук сүзләрне мин үзем дә сиңа әйтмәгән идеммени, Өлфәт?

– Әйтүен әйткән идең дә бит... Үзем ялганлый белмәгәч, мин аңа ышандым тагын... Беләм, кадерлем, авыр сиңа. Авыр булса да, кичер син мине! Улыбыз Ирек хакына кичер! Яратасың бит син мине! Яратмасаң, башта мин сугыштан кайтканчы дүрт ел ярым, аннары менә шушылай тилереп йөргәндә янә дүрт елдан артык ялгыз яшәр идеңмени?

– Кайдан беләсең? Бәлки, мин монда Чиләбедә...

Йөрәк энә кадагандай чәнчеп, авыртып китте.

– Юк, Сәкинә...

– Ярый, – диде Сәкинә, әле һаман агып торган күз яшьләрен сөртеп. – Сине оныта алмавым да хак! Ярый, мин сиңа ияреп кайттым да ди. Ләкин йә сиңа, йә миңа ачу итеп, берәрсе тагын берәр нәрсә ялганласа? Ул чакта нишләрсең? Тагын шулай, күземә күренмә, диярсеңме?

– Беркем дә бутый алмас хәзер безнең араны, Сәкинә!

– Дөнья бит ул, Өлфәт. Председатель бит син хәзер. Ә председатель хатыннары турында чәйнәүчеләр күп була ул. Әйдә, үзеңә дә бәла алып, минем дә йөрәгемне бозып йөрмә инде син! Бер кискән ипине ябыштырып торма! Барыбер ныклап ябыштыра алмассың син аны.

– Бернинди кискән икмәк юк, Сәкинә! Рәдифнең вак җанлыгы аркасында килеп чыккан аңлашылмау гына лабаса бу! Аерым яшәсәк тә, күңелем белән гел синең янда, гел улыбыз Ирек янында булдым мин.

– Әллә син мин уйламаган дип беләсеңме, Өлфәт? Яратмаган булсам, сугышка китәреңә дүрт-биш сәгать вакыт калганда үзем ияреп кайткан булыр идеммени? Биш елга якын көтәр идеммени, син сугыштан кайтып куып җибәргәч тә көттем мин сине. Көн дә менә килеп җитәр, менә килеп керер дип көттем. Ләкин бу сугыш вакытындагы төсле көтү түгел иде инде. Кавышырга өметләнеп, бергә яшәрбез дип көтү булмады монысы... Сүз катып караучылар да булды миңа. Тик берсенә дә ризалашмадым. Әгәр кияүгә чыгып куйсам, син, гаебе булган икән моның, Рәдиф белән типтергән икән бу, дип уйларсың төсле тоелды. Менә ни өчен генә көттем мин сине, Өлфәт!

Мин бу дөрес сүзләргә шаккатып, аңа каршы куярлык бернинди дәлил таба алмыйча башымны иеп, өнсез булып утырдым. Ә ул иплән кенә, ашыкмыйча гына сөйли бирде:

– Инде менә минем турылыклы булуыма, ниһаять, ышангансың икән. Хәзер минем җаным тыныч. Ирекле тол мин хәзер. Нәрсә телим, шуны эшли алам, кем белән телим, шуның белән сөйләшә алам! Ә сиңа кайтасым килми. Куркам! Дуамал син, Өлфәт!

– Туктале син, алай кызма әле, Сәкинә! – дидем мин, җайлы гына башланып киткән сүзнең шушылай куркыныч якка борыла башлавына аптырап. – Ну, булган инде, зур хата эшләнгән... Үз гаебемне танып алдыңа тезләнеп гафу үтенәм бит менә! Шуңа килдем. Синсез, улым Ирексез яши алмаганга килдем!

– Ничава, яшәрсең әле! Мин дә башта шулай дип уйлаган идем. Син куып кайтарып җибәргәч, әллә батып үлимме икән, дип, өч көн рәттән бәке буена төштем. Әни генә тыеп калды: өчесендә дә, артымнан төшеп, борып алып менде.

– Барысын да бик яхшы аңлыйм! Ләкин мин ул чактагы Өлфәт түгел инде хәзер! Зинһар, кичер син мине! Алдагы матур тормышыбыз хакына кичер! Беләм бит, яратасың син мине! Әйт әле, яратасың бит?

– Шул яратуым аркасында шушылай сызланам да инде мин, Өлфәт... Мин тегү фабрикасында эшлим. Анда безнең барысы да хатын-кызлар. Кай чакта ял вакытларында үзара сөйләшәбез шулай. Беренче мәхәббәте белән, яраткан кешесе белән бәхетле яшәүчеләр сирәк икән. Ә менә өзелеп яратмаган кешеләре белән яшәүчеләр һәм бик әйбәт яшәүчеләр шактый.

– Мәхәббәтсез, болай просто үзең хөрмәт иткән кешең белән яшәү – чын яшәү буламы икән соң, Сәкинә?

– Анысын әйтә алмыйм, Өлфәт. Һәрхәлдә, адәм баласына җан тынычлыгы да кирәк бит. Яратам, дип кимсетелеп яшәгәнче, үзең чынлап торып яратмасаң да, сине ярата торган, сине кеше итеп саный торган ир белән яшәү артыгractыр, бәлки.

– Нигә һаман шул бер сүзне тукыйсың, Сәкинә? Әйтеп торам бит инде, элеккесе-ахырысы шул!.. Аннары улыбыз Иrekне дә чуттан чыгарып ташларга ярамый ич.

– Җитәр, Өлфәт, әйдә туктатыйк бу хактагы сүзне. Никтер күңелем ышанмый төсле минем сиңа.

– Димәк, минем белән кайтмыйсың?

– Юк, кайта алмыйм, Өлфәт!

– Бәлки, син торыр урыныбыз юклыктан, өебез булмаудан куркасыңдыр, Сәкинә? Әгәр шулай булса, һич тә аптырама! Бер ай эчендә өй салдырып куям. Тик кайтыгыз гына!

– Әйтәм бит, ышанып җитмим мин сиңа. Холкың дуамал, бер дә юкка көнләшәсең, шуңа шикләнәм.

– Бу юлы кайтмасаң, өй салдыру белән тагын алмага киләм мин сине!

– Йөрмә, Өлфәт! Килмә бүтән!

– Алайса, улыбыз Ирекне алып китәргә рөхсәт ит! Ялгызың гына калгач, иркенләбрәк йөрерсең. Сиңа мәшәкате кимрәк булыр! – дидем, болай әйтүемнең һич урынлы булмавын белсәм дә тыела алмыйча.

– Юк, Өлфәт, – диде ул, һаман шулай тыныч кына, – анысы булмас инде! Аны бик яхшы тәрбияли алам мин. Сугышның иң кыен елларында да артык булмады! Ә хәзер беркемгә дә бирмим мин аны!

Моннан ары да сүз озайтып торуның мәгънәсе юк иде инде.

– Әйтүем шушы, Сәкинә, – дидем мин аңа, кискен итеп. – Синсез яши алмыйм мин. Белеп тор: тагын алмага киләчәкмен!

Шулай дидем дә, Сәкинәмне кинәт кенә күтәреп алып суырып үптем һәм, ул өненә килергә өлгергәнче, тиз генә чыгып китеп, туп-туры вокзалга юнәлдем.

**25**

Шулай итеп, йомшак җәйсә дә, шактый катыга утыртып җибәрде мине Сәкинә. Шуның өстенә алда ни булачагы, авылда мине ниләр көткәнлеге ачык түгел иде. Кем белә бит кайткач нәрсә буласын? Бәлки, Рәдиф мине инде күптән судка биргәндер дә, мине хөкем итү өчен көтеп кенә торалардыр. Шаһит эзләп тә йөрисе юк – Закир абзый бар. Ике арабызда булган хәлләрдән соң миңа ачу саклап йөрмидер дисеңме әллә аны?.. Колхозда эшләр ничек бара икән? Мин юкта берәр мөгез чыгып куймаса ярый инде...

Чиләбедән әнә шулай уйлап, бик аптырап-алҗып кайттым. Ә кайтып төшкәннән соң мәсьәләнең мин уйлаганнан да четереклерәк һәм куркынычрак икәнлеге мәгълүм булды: Рәдифнең ике кабыргасы ук сынган, һәм ул больницада ята булып чыкты!

Башта мин, әллә янына барып, сөйләшеп-аңлашып, гафу үтенеп карыйммы икән, дип уйлаган идем. Ләкин соңыннан, барыбер гафу итмәс, андый кеше түгел ул, тәмле телеңне әрәм итеп йөрүдән башка нәтиҗәсе булмас, дип, уемнан кире кайттым. Ни булса – шул, дип көтә башладым...

Ә колхоз эше өчен юкка борчылганмын икән. Бер дә андый-мондый хәл булмаган. Барысы да үз җае белән бара. Трактор чәчкечләре дә, атлы чәчкечләр дә әйбәт кенә эшлиләр иде.

Гаҗәп тә инде бу тормыш! Сәкинәм белән улым Ирекне тәки алып кайта алмадым. Больницадан чыккач, Рәдифнең ни кылачагы шулай ук мәгълүм түгел. Ләкин менә шундый хәлдә дә кешенең өмете, ышанычы югалмый икән. Чиләбедән кайтып төшкәннән ары ике-өч көн үтүгә үк, райбашкармага барып, өй салдыру өчен агач юллап кайттым. Аннары аны лесхоз эшчеләрен яллап кистердем, үзебезнең колхозда эшләүче автоколонна шоферлары белән сөйләшеп, бер төн эчендә ташытып куйдым да идарә эшеннән бушаган араларда шул өйгә дигән бүрәнәләрнең кабыкларын каезлый башладым. Әйтерсең минем бүтән хәсрәтем юк, әйтерсең дөньяда иң мөһим эшем – йорт салу!..

Беркөнне шулай идарәдә иртәнге эшләрне бетергәч, йорт саласы урынга барып, тагын шул бүрәнәләрне каезларга тотынган гына идем, берәү:

– Куеп тор әле, яшьти, балтаңны! –дип эндәште. Әйләнеп карасам – Рәдиф! Кулымнан балтам төшеп китә язды.

– Син икәнсең әле, әйдә, утыр!

Балтамны бүрәнәгә чабып куйдым да, нинди ниятләр белән килде икән инде бу, нәрсә әйтмәк була икән, дип көтә башладым.

Ул бүрәнәгә килеп утыргач:

– Ни хәлләрең бар соң, Рәдиф, нишләп йөрү? – дидем.

– Менә килдем әле, – диде ул. Янчыгын чыгарып, тәмәке төрергә керește. – Күптәннән күрешкән юк бит, сөйләшәсе сүзләр бар иде синең белән.

– Әйдә, сөйләшик алайса, – дип, мин дә аның янына барып утырдым.

Больницадан чыкканнан бирле кырынмый йөргән, ахры, сакал-мыеклары бик җиткән иде аның. Үзе исерек булмаса да, аракы исе әллә кайдан бөркелеп тора, куллары калтырап-калтырап куя. Күрәсең, кичә эчкәнлектән махмырлый иде.

– Син минем бүлнистә ятып чыкканны ишеткәнсеңдер бит? – диде ул, ниһаять, тәмәке төреп кабызгач.

– Андый эш ишетелми калмый инде ул.

– Кабыргаларым сынганын да беләсеңме?

– Анысын да әйттеләр.

– Кайда сынганы да мәгълүмме сиңа ул кабыргаларның?

– Барысы да мәгълүм, Рәдиф.

– Нишләтим икән соң инде мин сине? Таш капчыкка яптырыйммы? Бик ансат яптыра алам бит, теләсәм.

– Әйе, яптыра аласың, әлбәттә. Ләкин сиңа аннан нинди җиңеллек һәм ни файда булыр? Дәүләт судыннан башка кешенең үз суды, үз хөкеме, үз вөҗданы да булырга тиеш ич! Шул хәлгә үзең җиткердең бит син мине. Аннан тыш та байтак этлекләрең бар. Хәтта өемне дә син яндырдың бит!

Инде әйтеп киткәнемчә, өйгә кем ут төрткәнен мин әлегә кадәр тәгаен генә белмим, Рәдифкә дә «син яндырдың» дип белеп әйтү түгел, ачу килгәннән генә әйттем.

Шунда ул бик аз гына вакытка каушап калды да:

– Ә син күрдеңме мин икәнен? – диде.

– Бөтен хикмәт тә шунда шул – күрмәдем. Күрсәм, шул утның иң кызу янган җиренә тотып аткан булыр идем мин сине!

– Күрмәгәч, сөйләнеп йөрмә!

– Ә минем сөйләнгәнем дә юк, сүз җаеннан үзеңә генә әйтүем.

– Һи! – диде ул, бер-ике минут чамасы уйланып утыргач. – Димәк, куркасың төрмәдән, ә?

– Эш куркуда түгел. Гаиләмнән, җан сөйгән кешеләрдән аердың син мине.

– Ә мин сине шулай да утырттырып куйсам?

– Анысы ихтыярың. Без бер-беребезгә бурычлы түгел инде. Алыш-бирешебез беткән, арабыз өзелгән! Син мине аңларга тиеш, Рәдиф. Үзеңне дә хатының ташлап киткән бит. Шуның хәсрәтеннән тагын да күбрәк эчә башлагансың, шулай ич?

– Эчүен күптәннән эчәм инде мин, – диде ул, тәмәке төпчеген бүрәнәгә басып сүндерә-сүндерә. – Шуңа түзә алмыйча китте дә ул. Акылга керергә бик вакыт иде инде миңа да... Белеп торам, эчүемне ташласам, кире кайтачак минем хатын. Ә менә тыела алмыйм!

Кызганыч иде ул бу минутларда, йөзе ап-ак, иреннәре кипкән һәм дер-дер калтырана иде. Гаҗәп бит, ә: кеше үзенең ялгыш эшләвен дә белә, әмма шуны төзәтергә көч таба алмый!

– Алайса, менә болай итик без, – диде ул, кинәт урыныннан кубып. – Ярый, калдырам мин сине иректә. Үзең өчен түгел, хатының белән балаң өчен калдырам! Давай, син миңа бер литрлык бир дә, син мине белмисең, мин сине белмим. Шуның белән бетсен! Үзең күреп торасың, кәеф шәптән түгел минем, баш бик авырта.

«Шунда да кимсетеп китмәкче буласың, ә, шул көнгә төштеңмени, Рәдиф?» – дип әйтүдән чак кына тыелып калдым да, тагын ачуым чыгып, кесәләремне актара башладым. Кызганычка каршы, янымда бер тиен дә акчам юк иде...

Рәдиф, аксак булса да хәйран тиз атлап, бата-калка барыбер кибет янына китеп барды.

**26**

Ә шул көнне кич мине, бригадирларга наряд биреп, идарәдән кайтырга чыккач, Закир абзый артымнан җитеп туктатты.

– Тыңларга вакытың булса, бер-ике сүзем барые сиңа, прсидәтел, – диде ул.

– Әйтеп кара, Закир абзый.

Ул, нидәндер шикләнгәндәй, як-ягына каранып алды.

– Юк, Өлфәт, урамда сөйләшә торган сүз түгел ул, бик важный мәсьәлә. Бүлмәңдә кеше калмадымы анда синең?

– Юк, бикләп чыктым.

– Әйдә, алайса, шунда кереп утырыйк әле.

– Бик мөһим эшмени соң ул, Закир абзый, иртәгә калдырырга ярамыймыни?

– Ярамый, Өлфәт туган. Бүген үк, хәзер үк хәл итә торган эш! Мәсьәлә менә болай тора, – дип башлады ул, идарәгә кереп утыргач. – Сезнең авылның теге син кабыргасын сындырган Рәдиф бездә ята. Бик исерек. Авызында теле дә юк. Хатын әйтә, төшкә хәтле үк килеп кергәние инде, ди. Кергәндә үк салмышые, ди. Үзе белән бер бүтилкә аракы алып кергән булган, анысын да эчеп бетерә язган инде. Закир абый кирәк миңа, аны күрмичә китмим, дип әйтә, ди. Прсидәтелегез Өлфәтне төрмәгә тыктырырга йөрим, шуңа кирәк миңа Закир абзый, дип әйтә, ди. Мин бүген МТСка гәрүчи алып кайтырга барганыем, әле яңарак кына кайттым да, хатын шушы сүзләрне әйткәч, синең янга йөгердем. Рәдиф йоклап калды. Нишләмәк була икән соң ул, Өлфәт энем? Әллә теге күпердән ташлаган өчен тавыш куптармакчымы икән? Ул хакта ике арагызда сүз булдымы соң?

– Сөйләшкән идек, Закир абзый, – дидем мин, Рәдифнең шулай итенеп йөрүен башыма сыйдыра алмыйча. – Бүген иртән генә сөйләшкән идек.

– Ничек-ничек килеп чыкты соң ул чакта сезнең чәкәләшү?

Мин аңа барысын да әйтеп бирдем.

– Алай икән эшләр! –диде ул, мине тыңлап торганнан соң уйга калып.

– Әйт әле, Закир абзый, ул көнне минем урында булсаң, син ни эшләр идең? – дидем мин, аның фикерен беләсем килүдән бигрәк, авыр тынлыктан котылыр өчен.

– Минме? – Ул, чигәсен кашыган булып, тула эшләпәсен маңгаена ук төшереп куйды. – Мин синең урында булсаммы?

– Әйе.

– Туктале, башта бер тарих сөйлим әле мин сиңа, наный. Сугыш елларында булган хәл ул. Синең сүзләрне тыңлап утырганда искә төште. Кырык беренче елда, сугыш башланган айларда ук, немесләргә әсирлеккә эләктем мин. Кырык өчнең башына тикле алар кулында яшәдем. Бары шуннан ары гына, ничек кирәк алай качып, үзебезнекеләр ягына чыктым. Ишетеп беләсеңдер, әсирнең бөтен тормышы сак астында үтә аның. Эшкә барганда да сак астында, эшләгәндә дә сак астында, кайтканда да сак, кайткач та сак. Бүтәне турында әйткән дә юк инде, дажы бәдрәфкә барганыңны да карап-күзәтеп торалар. Әмма сакчыларның да төрлесе барые. Кайсылары, без әсирләргә ярдәм итмәсә дә, тәк торганда зыян да эшләми. Кушканын үтәсәң, шул җитә. Ә кайберләре фашисның да фашисы инде. Ничек итеп синең җаныңа тию, кимсетү, мыскыллау турында гына уйлый. Беркөнне шундый кабахәтләрнең берсе безне, биш әсирне, урманга агач кисәргә алып барды. Кышкы салкын көние. Башта без эшләгәнне карап, ашыктырып, әрле-бирле сызгыргалап йөрде бу. Аннары туңа башлады булса кирәк, мине чакырып учак яктыртты да шуның каршында җылынып утыра башлады. Ә үзенең күзе һаман бездә, «шнель! шнель!» дип туктаусыз өреп тора. Әз генә туктап, тын алырга да ирек бирми. Үзе бик шат, үзләренчә нидер мыгырдана, тинтәк кеше сыман, тик торганда кычкырып-кычкырып көлгәләп куя. Тора-бара учак җылысы да туйдырды булса кирәк, берәр аршын буе саллы гына агач ботагы кисеп алды да шуны безгә атып уйнарга тотынды бу. Ул томыргач, кайсыбызга килеп тисә, агачны шул кешедән китерттерә. Үзе шашып-шашып көлә. Миңа да өч тапкыр эләктерде. Бер сүз дә әйтмәдем, агач килеп тигән җирем бик каты авыртса да, өчесендә дә тыныч кына илтеп бирдем. Бәлки, тынар, кызганыр, дип өметләнгәнием. Юк, малай, кая ул сиңа туктау! Әле беребезгә, әле икенчебезгә тондырып кына тора. Шуннан соң дүртенче тапкыр бәрде бу миңа. Бу юлы маңгаема ук туры китерде, күземне чак кына чыгармый калды. Мин, авыртуга түзә алмыйча, маңгаемнан аккан канны җиңем белән каплап туктатырга азапланган арада, агачын китерергә кушып, автоматы белән янап, тагын акырырга тотынды бит бу. Шуннан мин нишләде дисең? Йә тәки атып җыгар, ике дә уйлап тормас, дидем дә дүртенче тапкыр илтергә киттем таягын. Бер кулым белән ярык маңгайны тотканыем, берсендә – тегенең агачы. Мин килеп җиткәч, тинтәк алаша шикелле кешнәп көлә-көлә, башта агачын тартып алды, аннары, кулымны сугып төшереп, маңгайдагы яраны карады да, «гуд!» дип кычкырып, яңакка чапты. Ант итеп әйтәм, шуңарчы ул фашиска кул күтәрү турында күңелемә дә килмәгәние. Әмма яңакка чапкач, секунд эчендә әллә нишләп киттем дә, алдын-артын уйлап тормастан, мин дә авызына берне менеп төштем моның! Минем ише коры сөяккә калган, чыкмаган җаны гына булган кешенең сугуы андый әзмәвердәй фашиска нәрсә инде ул? Чебен тешләгән шикелле дә булмагандыр. Ну миңа шуның өчен эләкте! Шундый каты типкәләп кыйнады – ничек исән калганыма әле дә шаккатам. Белмим, ничек атып үтермәгәндер инде. Менә шундый хәлләр... Ну мин шул вакытта бер тамчы да үкенмәдем! Хәзер дә үкенмим. Вчүтки бер иң әшәке фашисның яңагына чаптым бит әле, дип, ул заманнар искә төшкән саен куанып куям. – Чак кына тынып, уйланып торды да Закир абзый тагын дәвам итте: – Әсирлектән котылганнан соң, үзебезнекеләргә кушылып сугыша башлагач, әй бирдем инде үзләренең дә кирәкләрен: очраган бер немесне пүдрәт кырып бардым. Ник дисәң, үзләре бинават, үзләре җиткерделәр мине шул хәлгә... Инде килеп, син теге аксак малайны тәвәккәлләгәнсең икән. Минем урында булсаң, нишләриең, дип сорыйсың. Кистереп кенә әйтүе кыен, кәнишне. Бер караганда, синең дә сәбәбең җитди. Шулай да күпердән үк тотып атарга кирәк булдымы икән?

– Соң, ул Рәдифнең әле генә үзең сөйләп үткән фашисттан кай җире ким, Закир абзый? Бары тик көнчелек аркасында гына минем бөтен тормышымны бозып, туздырып ташлады бит ул.

– Ул яктан караганда, аермасы, ихтимал, әллә ни зур түгелдер. Әмма синең хәл белән минем ул чактагы хәлем арасындагы аерма җир белән күк арасы бит! Миңа нәрсә, мин токтындаем ул чакта. Бернинди бүтән чарам да югые минем. Бүген үтерәләрме, иртәгәме – аның анысы әллә ни әһәмиятле түгелие миңа. Ә син бит иректәге кеше! Сиңа башкачарак эшли алырга да булырые... Әй Өлфәт, турысын әйткәнгә хәтерең калмасын, кызурак канлы кеше шул син, олан! Башың да хәйран яхшы эшли, гаделлегең дә зур, ну кайчакта кирәгеннән артыграк кыланып ташлыйсың. Исеңдәме, салам күрәргә барган җирдән мине ничек итеп куып кайтарганыең?

– Ул заманнарны искә алмыйк инде, Закир абзый, – дидем мин, оятымнан нишләргә белмичә. – Атта да, тәртәдә дә булды инде ул чакта.

– Анысы шулай, узган эш. Әмма андый хәлләрне дә искә төшереп алу зыян итми кайчакта. Әйтик, син ул вакытта тузынганда, минем дә кызып китүем барые бит. Шулаймы?

– Соң сез, эш эшлисе урында, карта суга идегез ләбаса!

– Анысы хак сүз. Ну бит син әле яңа кеше иең. Нинди эш майтара алачагыңны белмидериек ич әле без.

– Бөтенесен дә бер калыпка сапларга ярамый, Закир абзый. Үз районыбызда да хезмәт көненә әйбәт кенә биреп килүче колхозлар бар иде ләбаса ул чакта да.

– Авызымнан тартып алып әйттең бу сүзләрне! – диде Закир абзый. – Имынны шулай шул менә. Хәйран хәлле генә колхозлар барые. Ә син аның нилектән алай булуын беләсеңме? Әйтимме сиңа аның галәмәтен?

– Әйтеп кара.

– Хикмәт колхозның дилбегәсе кем кулында булуда, энекәш. Ә бездә сугыш башланганнан бирле юньле прсидәтел булмады. Балык башыннан бозыла ул. Рәдиф тә шундый черек булды. Салу белән булышты. Әшнәлек, кода-кодагыйлык хөкем сөрде. Менә шуңа каршы иде халык. Ә хәзер, син ничава гына бүлеп бирә башлагач, тагын эшләргә тотындык бит. – Ул, бераз нидер уйланып утыргач, кинәт урыныннан купты да сүзне бөтенләй икенчегә борып җибәрде: – Ә син, Рәдиф алай-болай эшне зурга илтер, дип бер дә шикләнмә. Пычагымны да эшләтә алмый ул! Гаеп үзендә булган ич аның. Шулай булгач, яклый алмыйм мин аны. Бәлки, ул мине шаһит итеп, гаепләүче итеп чакырттырмакчы буладыр. Тотсын менә... Иртән торгач, айныгач, бик хәтәр итеп сүгәм әле мин аны!

**27**

Закир абзый белән шушы сөйләшүнең икенче көнендә үк, балта осталары яллап, мин өйне бурата башладым. Рәдиф эшне зурга җибәрсә, бүленеп калуы да мөмкин икәнен дә белә идем. Шулай булса да үземә бертөрле үҗәтлек белән тизрәк йорт җиткерергә ашыктым. Чиләбедән кайту белән Сәкинәгә дә хат яздым. «*Кайтырсызмы икән, Сәкинә? Кайтыр булсагыз, ым гына как – шундук барып алам мин сезне*», – дидем.

Бу юлы озак көттермәде ул. Ун көн эчендә җавап килде: «*Әйбәт кенә яшибез, тик син киткәннән бирле Ирек кенә: «Әти кая китте, ник безне калдырып китте, алып кайтам, дип әйткән иде бит ул безне, нигә алдалады икән?» – дип аптырата башлады. Ләкин мин һаман шул элекке уемда калам. Юләрләнеп килеп йөрмә! Әгәр кайтырга уйласам, үзебез дә кайта алабыз ла без*», – дип язган иде.

Әнә шуннан соң канатланып йөри башладым мин. «Кайта алабыз» дигән бит! Кем белә, бәлки, шушы араларда ук тып итеп кайтып та төшәрләр дип, көн дә аларны көтеп яши башладым...

Йорт та салынып бетте. Колхоз эше дә ярыйсы бара. Закир абзый җитәкчелегендә арба ясау эшен дә көйләп җибәргән идек. Әйтергә онытып торам икән, сугышка хәтле «Ватан» колхозында арба ясау бик нык алга киткән иде. Көрнәле арбаларын районыбызда гына түгел, күрше районнарда да яхшы беләләр һәм бик теләп сатып алып китәләр иде. Сугыш башлангач, ул эш тукталып кала. Бу ел җәй менә шул хәйран табышлы эшне җайга салып җибәрдек...

Вакыт һаман су урынына ага да тора. Кыш та үтеп китте, яз да килеп җитте. Ә менә Сәкинәнең һаман «кайтам» дип өзеп әйткәне юк әле. Көтә торгач, сагына торгач, ниһаять, түзә алмадым: килергә кушмаса да, язгы чәчүне әйбәт кенә башкарып чыгып, колхозда бераз эшләр җиңеләйгәч, ял көненә барып керерлек итеп, тагын Чиләбегә улым Ирек белән Сәкинәм янына киттем.

Мин килеп кергәндә, Фәхретдин абый карчыгы белән танышларына кунакка киткән, ә Сәкинә белән Ирек өйдә иделәр. Бу юлы Сәкинә дә, мине күргәч, артык шаккатмады, мин дә беренче баргандагы шикелле телсез-өнсез калып тормадым.

Ә Ирек, шундук танып алып:

– О-о! Әтием килде. Безне апкайтырга килдеңме, этием? – дип, алдыма ук менеп утырды.

– Әйе, улым, сезне алып китәргә килдем! – дип, башта аны кочаклап үбә-үбә сөйдем дә: – Теләсәң нишлә, Сәкинә, ләкин бу юлы сездән башка кайтмыйм мин! – дидем.

Ул көнне тагын ниләр сөйләшүебезне тәфсилләп торуның кирәге юктыр, туган. Билгеле, мин әйтү белән үк ризалык бирмәде Сәкинә. Байтак уйланып, икеләнеп утырды. Бары тик Фәхретдин абзый да кайтып:

– Җитәр, сеңлем, һәрнәрсәнең чамасы була! Үзеңне дә, Өлфәтне дә җәберләп, Сак белән Сок шикелле икегез ике якта яшәүгә чик куярга кирәк инде. Гомер ике килми ул, чәчәктәй вакытыгызны заяга үткәрмәгез! – дип, мине яклап бик нык үгетләгәннән соң гына, ниһаять, риза булды.

Шулай итеп, минем дә, ниһаять, дөньям түгәрәкләнде һәм без, чын кешеләрчә, матур гына яши башлаган идек. Әмма...

**28**

Бу урында мин сиңа шактый сәер булган һәм минем чәчләрне агарткан хәлләрне сөйләп китәргә мәҗбүрмен, туган.

Берсе сиңа инде билгеле Гөлүсә аркасында булды. Сәкинәмнән шул шашкын хисле чәчбикә тагын колак кактыра язды.

Теге чакта институтка килеп сөйләшүдән соң, ул мине аңлаган сыман булган иде. Йомышы төшеп, идарәгә килгәндә, урамда очраган вакытларында, гадәтенчә үтә ягымлы, үтә ачык сөйләшсә дә, күз карашы белән һаман әле мине яратуын сиздерсә дә, тел белән әйтеп, әрсезләнеп йөрмәде. Мин үзем дә

мөмкин кадәр җитди, рәсми булырга тырыштым һәм бер дә алай икеле-микеле уйланырга урын калдырмаган шикелле идем. Әмма ул өметен өзмәгән, һаман мине көтеп, ышанып йөргән икән. Ә өмете өзелгәч...

Инде әйткәнемчә, Сәкинә белән Ирекне алып кайтып, куанып-шатланып эшләп йөри башлаган чагым иде ул. Август ае ахырларында беркөнне районга барырга дип ат җигеп тора идем, шул укытучы Гөлүсә яныма килде дә:

– Сезне районга бара икән дип әйткәннәр иде, зинһар, мине дә утыртып алып барыгыз әле? – диде.

– Йомышыгыз бармы, әллә теге чактагы шикелле болай гына барырга уйладыгызмы? – дидем мин, шактый кырыс итеп.

– Ә сезгә барыбер түгелмени, Өлфәт абый?

– Юк, барыбер түгел, Гөлүсә! Йомышыгыз булса гына алып барам мин сезне.

– Йомышым бар иде шул, Өлфәт абый! – диде ул, зәп-зәңгәр күзләрен очкынландырып.

– Барырсыз инде алай булгач, авыл мөгаллимәсен калдырып китү ярамас. Кайтыгыз да әзерләнеп, көтеп торыгыз. Китешли ала китәрмен.

Ул, кинәт яктырып:

– Ә мин инде әзер! – диде дә башта кулындагы портфелен тарантаска китереп куйды, аннары үзе менеп утырды.

Киттек без моның белән. Башта ул да ничектер уйчанланып, моңланып, миңа сүз катмыйча гына барды. Мин дә көннең матурлыгына, җылылыгына рәхәтләнеп, кырдагы игеннәребезнең инде җыелып бетеп баруына куанып килә идем. Үзебезнең «Ватан» межасын үтеп, Качкалак урманы дип аталган кечерәк кенә урманга барып кергәч, Гөлүсә кинәт миңа сыенарак төште дә, күзләрен майландырып:

– Беләсеңме, Өлфәт абый, бу юлы да бер йомышсыз килә бит мин синең белән! – диде.

Мин эсселе-суыклы булып киттем. Атны туктаттым да, ачуланып:

– Нигә болай юләрләнеп йөрисез сез, Гөлүсә? Әйдә, төшегез тарантастан! – дидем.

– Ә син тыңлап бетер, Өлфәт абый! – диде ул, кырыслыгыма һич тә исе китмичә. – Әйе, минем районда бүген дә бер йомышым да юк. Ләкин минем синең белән бергә, бер тарантаска утырып барып кайтасым килде. Соңгы мәртәбә синең белән бергә утырып каласым килде минем, аңлыйсыңмы син шуны, Өлфәт абый, соңгы мәртәбә, дип әйтәм мин сиңа!

– Аңлавым ни дә, аңламавым ни...

– Аңласаң, мине кума, Өлфәт абый, яме! Хәтереңдәдер, кырык алтынчы елның кышында сиңа утырып кайтканда, син өйләнмичә, шушы Көрнәледән китмим, дигән идем мин сиңа. Менә мин сүземдә тордым: син Сәкинәңне алып кайтмыйча китмәдем. Ә хәзер китәм! Ронодан расчет алдым инде мин. Хәзер миңа монда яшәүнең бер кызыгы да юк. Әйдә, туктатма атыңны, йомышым булмаса да, үзең белән алып барып кайт инде син мине бүген. Биш-алты ел үзеңне яратып йөргәнем өчен, бер кечкенә генә теләгемне үтә әле, ичмасам.

– Зинһар, җыен юк-барны сөйләмәгез әле, Гөлүсә! – дидем мин, тәмам аптырашка калып. – Безнең ике арада бернинди гыйшык-мишык та була алмаячагын аңларга күптән вакыт иде бит инде сезгә!

– Акыл белән мин үзем дә шулай уйлый идем, – диде ул, сабырлана төшеп. – Үземне шуңа ышандырырга тырышып та карадым. Ләкин акылдан тыш йөрәге дә бар бит әле адәм баласының. Аны берничек тә акылга буйсындырып булмады шул. Нигә шулай каршылыклы икән бу кеше тормышы? Син яраткан кеше нигә сине яратмый икән? Нигә син үзең күрергә дә теләмәгән кешеләр синең өчен саргаеп-кибеп йөри икән? Шушы Көрнәледә генә дә ничә егет йөрде артымнан! Ә мин аларга әйләнеп тә карамадым. Неужели шулай үзем яратмаган кеше белән гомер итәргә туры килер миңа да?

Мин, хәтта инде нигә бүген районга барырга чыгуыма үкенеп, үземне-үзем тиргәштереп бара идем. Гөлүсә иңнәремнән тотып, илереп күзләремә текәлгәч, башта, әллә тарантастан куып төшеримме, дип тә уйладым. Ләкин аның йөзендәге сагышны, үкенүне һәм газапны күргәч, ул уемнан кире кайттым да, юатырга тырышып:

– Борчылмагыз, Гөлүсә, нигә алай булсын ди! Сез дә яратырсыз әле, миннән йөз мәртәбә акыллырак, шәбрәк кешене яратырсыз! – дидем.

Ул күзләрен мөлдерәтеп тагын бераз миңа текәлеп карап барды да:

– Мин үз хәлемне үзем беләм, Өлфәт абый, син миңа акыл биреп азапланма инде, яме! – диде.

Юатыр сүз таба алмаганлыктан, мин дәшмәдем. Аны ишетмәгәнгә салынып, атның дилбегәсен кагып куйган булдым. Ат җиңел генә юртып китте. Чокыр-чакырлы урман юлы тарантасны шактый нык чайкый башлагач, Гөлүсә тураебрак утырды. Мин, үзен кулга алды, ахры, бу кызыкай, дип, җиңел сулап куйдым. Ләкин шулчак һич тә көтелмәгән бер нәрсә булды. Гөлүсә кинәт минем кулдан дилбегәне тартып алды да, атны шып туктатып, йөрәк тавышы белән:

– Их, Өлфәт абый! – дип куйды. Аннары ниндидер бер кыргый көч белән кочып алып, яшькә чыланган озын керфекләрен битемә тидерә-тидерә, мине үпте.

Кайнар иреннәре биткә тигәч, мин дә аны кочып үпми калалмадым... Акыл белән түгел, ничектер үзем дә сизмәстән...

Нәкъ шул чакны якында гына:

– Алла куәт бирсен, Өлфәт абый! – дип кычкырып көлешә башлаган малайлар тавышын ишеттем һәм, ни әйткәнемне үзем дә абайламыйча:

– Рәхмәт! – дип куйдым. Корт чаккандай сискәнеп, тарантастан сикереп төштем дә тавыш килгән якка бара башладым. Ләкин көлешүчеләрнең берсен дә яхшылап күрә алмый калдым: алар куелыкка йөгерешеп кереп киттеләр, артларыннан куак ботаклары гына селкенеп калды. Миңа шунысы гына ап-ачык иде: ул малайлар – чикләвек җыярга килгәннәр һәм мине белә торган малайлар...

Мин юлымны дәвам иттем, ә оялуыннан мәк чәчәге төсле кызарган Гөлүсә исә:

– Кичер, Өлфәт абый, мин юләрне, минем аркада килеп чыкты бу, – диде дә авылга кайтып китте.

Кичен мин районнан әйләнеп кайтканда, Сәкинә өйдә юк иде. Мине ташлап, Янтыкка, үз авылларына кайтып киткән иде ул. Теге безне урманда күргән малайлар арасында минем Ирек тә булган икән һәм ул, кайткач, әнисенә барысын да сөйләп биргән. Башка чакта шундый сабыр Сәкинәм бу юлы түзә алмаган, Ирекkә «әтиең минем арттан килеп йөрмәсен» дип әйтеп китеп үк барган.

Гөлүсә дә, урманнан борылып кайтып, әйберләрен җыештырган да үз якларына кайтып киткән булып чыкты.

Шулай итеп, тагын Сәкинәсез калдым мин. Шул ук кичне артыннан барсам да, кайтырга түгел, сөйләшергә дә теләмәде Сәкинәм. Мин кергән ишек ябылганчы ук өйләреннән чыгып китте.

Көн саен диярлек Янтыкка барып, кайтырга айдан артык өндәвемә дә карамастан, Сәкинәнең һич тә кайтыр исәбе юк, һаман шулай бик нык хәтере калган килеш тора, йомшар чамасы күренми иде. Хәтта ул Янтыкка инде үзенең яраткан эшенә дә урнашкан, үзебезнең «Ватан»дагы шикелле үк, сыерлар сава башлаган иде.

Белмим, мондый аяныч хәл тагын күпмегә сузылыр иде икән, ләкин үз башы җитептерме, кеше киңәше буенчадырмы, Гөлүсә үзе бозган эшне үзе җайлады бит, туган. Күрәсең, Көрнәледә калган дусларыннан берәрсе безнең аерылышуны һәм аның сәбәбен хәбәр иткән булгандыр инде, бер дә бер көнне яңа урнашкан эш урыныннан – Актаныш ягыннан – минем Сәкинәгә хат язган бу. Ул хатның кайбер юлларын хәзер дә бик яхшы хәтерлим әле мин: *«...Ишетүемә караганда, син Өлфәтне миннән көнләшеп ташлап киткәнсең икән, Сәкинә,* – дип язган иде ул. – *Син мине яхшы беләсең бит, Сәкинә, алдаша торган гадәтем юк минем. Ышан миңа: Өлфәтнең энә очы кадәр дә гөнаһсы булмады ул чакта. Мин, бары тик мин генә гаепле бу эшкә. Яшермим, синең Өлфәтеңне ул сугыштан кайтканнан бирле чын-чынлап яратып йөрдем. Арагыз бозылышып, син аерылып киткәннән соң яратуымны аңа ачыктан-ачык әйткәләп тә карадым хәтта. Ләкин ул сиңа, бары тик сиңа турылыклы булып калды...*

*Ә урманда мин аны үзем кочаклап, үзем үптем. Син теләсәң ни әйт, Сәкинә, ләкин, минемчә, алай зурлап шаккатарлык нәрсә юк монда. Ул мине ратмаса да, мин аны алты ел буена сөеп йөргән һәм, дөресен әйтим, син кайтмасаң, бәлки, үземә булыр дип тә өметләнгән кеше бит... Шул өметем дә өзелгәннән соң сезнең авылдан бөтенләй китеп барырга карар кылгач, күңелем алгысып, хискә бирелеп киткәнмен икән – аннан гына дөнья җимерелмәгәндер бит. Син дә азрак мине аңларга тырыш инде, Сәкинә. Хатын-кыз лабаса син, безнең затның хыялга һәм хискә кайчакта кирәгеннән артыграк бирелеп китүчән булуын үзең дә беләсеңдер... Сүз дә юк, ул чактагы тилелегем өчен соңыннан минем үземә дә бик читен булды. Шуңа күрә, синең күзеңә күренергә кыенсынып, шул ук көнне җыенып, Көрнәледән чыгып киттем дә мин...»*

Шушы хатны алып укыганнан соң гына, ниһаять, игә килде Сәкинәм. Шуннан соң гына без, ниһаять, яңадан кавыштык.

Кавышуын кавыштык, әмма ул арада минем чәчләрнең яртысы агарырга өлгергән иде инде.

**29**

Кайбер кешеләр яртылаш агарган чәч белән дә шактый гомер йөриләр. Ә кайберәүләрнеке тәмам соңгы көннәренә тикле шулай яртылаш агарган килеш кенә кала. Әгәр тыныч кына, борчылмыйча, пошынмыйча, янмый-көйми генә яшәгән булсам, ихтимал, мин дә шул яртылаш агарган чәч белән хәзергәчә йөргән булыр идем. Ләкин алай йөри торган кеше түгел шул мин. Алай йөри дә алмыйм.

Сәкинә белән кавышып, матур гына яши башлагач та, үземнең әлеге кыбырсык холкым аркасында, байтак кына читен хәлләрдә калгаларга туры килде. Хәтерлисең булыр, илленче елларның азагында авыл хуҗалыгын алга җибәрү өчен кукурузны күбрәк чәчәргә кирәк, дип аңлата башладылар. Һәр колхозга аерым-аерым план җиткерелде. Безнең «Ватан» да ике йөз гектар чәчәргә тиеш булды аны. Шуннан соң бик нык пошаманга калдым мин. Чәчүен чәчәрбез дә, унбиш мең пот бодай үсәчәк җир әрәм булып калмасмы?..

Шикләнергә урын да бар иде. Сугыш елларында Михайло исемле бер украин егете белән бергә хезмәт иткән идем мин. Шунда без бик нык дуслашып киттек һәм соңыннан да хат язышып тора башладык. Ул инде сугышка кадәр үк институт тәмамлаган кеше иде. Сугыштан соң үз авылларында агроном булып эшли башлады һәм хатларында кукуруздан бик зур уңыш алуларын әйтеп яза иде.

Шуннан кызыксынып китеп, мин аннан бер гектарлык кукуруз орлыгы соратып алдырып, үзебезнең кырга чәчеп карадык. Ләкин ул безне көткәнчә үк куандыра алмады, ни тырышып тәрбияләсәк тә, телгә алып әйтерлек уңыш бирмәде.

Менә шуңа күрә башта илле гектар гына кукуруз чәчтек без. Ихтимал, юл буена сузып, үткән-барган кешегә биш йөз гектар булып күренерлек итеп чәчелгән булгангадыр инде, районнан килеп карап киткәләсәләр дә, башта аны-моны әйтүче булмады. Әмма «кырын эш кырык елдан соң да беленер» дип бер дә юкка гына әйтмәгәннәр шул. Көзләр җитеп, уңыш җыю көннәре башлангач, шул эш өчен мине шактый нык итеп башта «пешекләделәр», аннары шелтә эләкте.

Анысыннан арынып күп тә эшләмәдем, тагын бер шелтә – бу юлы инде катысы ук. Бервакыт безнең хуҗалыкка да тавык һәм үрдәк үрчетә башларга кушылды: тавыгы ике меңнән артык, үрдәк мең ярым булырга тиеш иде. Шулчак тагын аптырабрак калдым, туган. «Тавык-чебеш» кенә булсалар да, аларга да тәрбия кирәк ләбаса. Үсеп җиткәннән соң итләре бик тәмле дә соң, ләкин үсеп җиткәнче ярты картайта бит әле алар сине. Колхозчының йортында күп дигәндә ун-унбиш баш чебеше була һәм аларны бала-чагасы, карчык-корчыгы туктаусыз ашатып-эчертеп, кош-корт күзеннән саклап тора, ләкин шулай да әлеге ун-унбиш чебешнең барысын да исән-сау килеш үстереп җиткерә алучылар бик сирәк ич... Ә монда, мә сиңа, меңләгән тавык-үрдәк үстерергә кирәк!..

Ярый, тавыкларын ничек кирәк алай үстерергә дә булыр ди инде. Нәни чакларында тилгән-козгыннардан, исәя төшкәч, төлке һәм сасы көзәннәрдән саклап кала алсак, тавык планын ничек тә үтәрбез. Ә менә үрдәкләр мәсьәләсен ничек хәл итәргә?.. Ник дигәндә, су юк бездә. Кечкенә-кечкенә өч бөртек чишмәдән агып чыккан су күпме генә инде ул? Буып куйганнан ары да мең ярым үрдәк берьюлы сыярлык булмаячак!..

Шулай да тавык чебиләрен дә, үрдәк бәбкәләрен дә алып кайттык без һәм кулдан килгәнчә тәрбия итә башладык, туган. Күпме тары ярмасы, күпме он ашаттык, тик файдасы гына булмады. Үрдәк бәбкәләреннән элек тавык чебиләребез кырыла башлады. Аннары канат чыгып, тәмам исәеп килә башлагач, нindидер чир йогып, үрдәкләребез үләргә тотынды. Ветврачлары да ул чирнең серенә төшенә алмады. Без үзебез аны иркенләп йөзәрлек су булмаганнан күрдек.

Әллә соң кошчылар юньләп тәрбияләмиләр микән дип, аптырагач, сыер савудан алып, бер сукраныбрак йөри торган хатын урынына үземнең Сәкинәне дә куеп караган идем. Барыбер нәтиҗәсе булмады.

Икенче елны, әле кар бетәр-бетмәс борын ук, инкубатордан үрдәк бәбкәләре килеп алырга шалтыраттылар. Аннары, без барып җиткәнне дә көтмичә, МТС тракторына арба тагып, үзләре китерделәр үрдәк бәбкәләрен. Ә без тоттык та хәл иттек: тукта, ни булса – ул, озатыйк әле боларны Казанга.

Казан безгә ерак түгел, нибары туксан километр гына. Икенче көнне кичкә үк әйләнеп тә кайтты сатарга барган кешеләр. Үрдәк бәбкәләрен талашып алып бетергәннәр иде.

Ә көз җитеп, колхозлар кош-корт тапшыра башлагач, идарә членнарын җыеп киңәштем дә, колхозчылардан бодайга алмаштырып үрдәк, тавык җыярга карар чыгардык. Ышансаң ышан, ышанмасаң – юк, туган: өч көн эчендә план буенча тиешле тавык һәм үрдәкне җыеп алдык без. Үзебезнең авылдан гына түгел, күрше авыллардан да китерделәр. «Ватан» үрдәк планын йөз дә бер процентка үтәде, дип, район газетасында хәбәр дә чыкты.

Ләкин кайчакта мактауның орышудан битәр нәтиҗәгә китергән очраклары була икән, агай-эне. Ул елны минем белән дә шундыйрак хәл булды. Газетада теге хәбәр басылганнан соң, миңа район күләмендә үткәрeләчәк авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсендә ничек итеп кошчылык өлкәсендә шушылай зур уңышка ирешүебез турында сөйләргә, ягъни тәҗрибә уртаклашырга тәкъдим иттеләр. Ялганларга теләмәдем, чынын сөйләп көлкегә каласым килмәде һәм мин, начальствога шалтыратып, ул җыелышта сөйли алмаячагымны әйтеп, сәбәбен аңлатып бирдем. Бая әйткән каты шелтә миңа әнә шул эшем өчен эләкте...

Бер кирегә китсә китә икән ул эшләр, туган. Өстемдә кара тап булып, күңелемне сызлатып торган теге шелтәдән котылырга да өлгермәдем, аннан да яманрак хәлгә дучар булдым. Һаман да шул үземнең тынгысызлыгым аркасында инде...

«Колхозчылар сыер, сарык асрап, аларга печән җыеп, тиресләрен түгеп мәшәкатьләнергә тиеш түгел, бәлки, шәһәрдәгечә, сөтен дә, маен да, итен дә әзер килеш, колхоздан гына сатып алып торырга тиеш» дигән фикер алга сөрелә башлады. Ялгыш аңлауга урын калмасын өчен, алдан ук әйтеп куям: эшче белән колхозчы тормышы арасындагы аерманы бетерүгә мин дә каршы түгел идем. Хәзер дә хуплыйм мин ул нәрсәне. Ахыр чиктә, ниһаять, шулай булырга тиеш тә ул. Эшләр шуңа таба бара. Әйтик, безнең фермада эшләүчеләр, нәкъ шәһәрдәгечә, атнага биш көн һәм көненә сигез сәгать алмашынып эшли хәзер. Бәйрәм көннәрендә эшләүчеләргә, шулай ук шәһәрдәгечә, хезмәт хакын икеләтә түлибез. Ә колхоз буенча һәр колхозчының эш көненә уртача хезмәт хакы өч сумнан да артыграк туры килә. Ул яктан эшче белән колхозчы арасында хәзер үк инде аерма юк дип әйтергә була...

Ләкин бит бу хәзер шулай. Ә ул елларда эшләр әле башкача иде: көненә өчәр сум түгел, атнасына да ул хәтле эләкми иде колхозчыга...

Башка якларда, белмим, ничек булгандыр, әмма безнең тирәләрдә корылык булды ул елны. Игеннәр дә, печән дә начар иде.

Бүтән елларда халык ничек тә җаен таба: колхоз кырыннан бер сыер һәм өч-дүрт баш сарыкны кыш чыгарырлык печән әзерли торган иде. Әмма ул елны иген дә, печән дә уңмагач, шуның өстенә колхозчыга сыер тоту артык мәшәкать ул, дип тә әйтеп торганда, тирә-як авыллар сыерларын йә суеп сатарга, яки дәүләткә тереләтә тапшырырга керештеләр. Сатучы күбәйгәч, сыерларның бәһасе бик арзанайды. Әйтик, башка елны башмактан бозаулаган һәм җиленнәре кәҗә җилене хәтле генә булган сыер кисәген дә юлың унса гына сатып алырга мөмкин булган акчага ул елны егермешәр литр сөт бирә торган бурадай сыер алу берни тормый иде.

Сыер чебеш түгел: ел саен үсеп, өлгереп тормый. Димәк, быел ике йөз илле сум торган сыерны киләсе елга биш йөзгә дә табып булмавы мөмкин...

Исәпли-уйлый торгач, менә мондый фикергә килдем: колхозга сыер җыя башласак ничек булыр икән?

Шул ук көнне идарә члennарын чакыртып киңәштек тә колхозга савым сыерлар җыярга булдык. Азык запасын исәпләп караганнан соң, туксан биш баш сыер алырга мөмкин, диде зоотехник.

Азык булмагач, сез ни белән туйдырмак булып җыярга ниятләдегез ул сыерларны, диярсең инде син, туган. Хикмәте менә болай аның: күпьеллык үләннәр ул чорда инде тәнкыйтькә дучар ителсәләр дә, әлеге дә баягы, үҗәтлегем белән, люцерна җирен сөрдермәгән идем. Күрәсең, язгы дым белән ныгып калган булгандыр, иген белән печән уңмаса да, люцерна бик шәп иде безнең ул елны.

Сыерларны карап, яхшыларын, күп сөт бирә торганнарын гына кабул итү өчен, бер күз салу белән хайванның нинди икәнен белеп ала торган әлеге шул Галим абзыйны билгеләдек. Колхозларны берләштергәндә, безнең «Чулпан» да «Ватан»га кушылган, һәм Галим абзый хәзер ферма мөдире булып эшли иде.

Терлекләр инде кулга кергән, суясы яки сатасы хайванны бер көн ашату да крестьян өчен бик исәпле чак булганлыктан, нәтиҗә без көткәннән дә әйбәтрәк килеп чыкты. Ун көн эчендә тирә-як авыллардан сиксән өч баш сыер китерделәр. Сатарга теләүчеләр әле һаман күп иде. Әмма дәүләткә терлек кабул итү пункты мөдире, бу хәлне сизеп алып, Хәкимов миңа аяк чала, дип, районга барып тавыш куптарган. Шуннан соң мине чакыртып алдылар да, башта сыер җыюны туктаттылар, аннары, җитәр инде, күп чиләндек без синең белән, дип, мине җавапка тарту турында мәсьәлә куйдылар. Мин берни дә эшли алмадым. Чөнки формаль яктан мин, чыннан да, хаклы түгел идем. Эш шунда, без сыерларның һәр килосын дәүләт бәясеннән биш тиенгә кыйммәтрәк алдык. Бу, бер яктан, закон бозу сыманрак хәл, икенчедән, тирә-як авыл халкы, сыерларын дәүләткә тапшырудан туктап, безнең колхозга ябырылган иде. Биш тиенгә кыйммәтрәк җыйган өчен түгел, әлбәттә. Дөрес, анысы да җирдә аунап ятмый. Дүрт йөз килолы сыер тапшырган кешегә егерме сум дигән сүз ул...

Мине шунда бер буйдан эшемнән алырга да ниятләре юк түгел, Гадел абый урынына килгән секретарь шуны үземә дә сиздереп куйган иде. Әмма эш аңа ук барып җитми калды.

**30**

Тормыш гел бер килеш кенә бармый икән, туган.

Тора-бара авыл хуҗалыгында эшләүче кешеләргә мөнәсәбәт тә, шул җәһәттән авыл халкының хәле дә бик нык үзгәреп китте. Эштә инициатива, эшне яңача оештыру аеруча хуплана башлады. Аннары килеп, хезмәт хакына түләү шартлары да колхозчылар файдасына авышып һәм тотрыклыланып калгач, колхоз эшеннән читләшеп йөрүчеләр дә эшне үзләре сорап алып эшли башладылар. Халык белән эшләү бик нык җайланды, күңеллеләнде...

Ләкин шул ук вакытта бик зур борчуым да бар иде минем, туган. Җәзага эләккәнемә күңелем сыза, шуңа йөрәгем әрни, шуңа үз-үземне тирги идем.

Мең төрле уйларга батып, бик күп тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр кичергәннән ары, ниһаять, тәвәккәлләп, кичерүне үтенеп шикаять язган идем. Бәхетемә каршы, озак көттермәделәр. Бөтенесе мин дигәнчә булып бетте.

Ә аннан соң, ике-өч ел вакыт үткәч, минем өчен көтелмәгән бик зур яңалык булды: мең дә тугыз йөз алтмыш җиденче елда миңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирделәр. Анысы ни өчен икәнен тәфсилләп торасым килми. Башкаларга ни өчен биргән булсалар миңа да шуның өчен, Указдагыча итеп әйткәндә, авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерүдә ирешелгән уңышлар өчен бирделәр.

Бу хәлгә мин шатландым да, офтандым да. Шатландым, чөнки ул исемне бер минем генә хезмәтемә түгел, бәлки безнең «Ватан» колхозчыларының барысының да тырышлыгын искә алып бирелгән дип санадым. Дөресе дә шулай бит, туган. Әгәр Галим абыйлар, Таифә, Маһисәрвәр апалар, Закир абыйлар

һәм алар кебек үк башка бик күп колхозчылар чын-чынлап тырышмаган булса, ничек кенә әйбәт эшләмим, мин берүзем берни дә майтара алмас идем...

Офтандым, чөнки минем дә, ниһаять, мактанып телгә алына башлавымны Сәкинәм-җан кисәгем күрә алмыйча калды. Сыерлар савуда яхшы гына эшләп йөри торган җиреннән кинәт авырый башлады һәм җиде ай түшәктә ятканнан соң дөнья куйды. Казанга гына түгел, Мәскәүгә үк алып барып, профессорларга да күрсәтеп караган идем үзен, әмма: «Хәзер соң инде, берни дә эшләп булмый. Рактан терелтә торган ышанычлы дару әлегә табылмаган», – диделәр.

Хәсрәтемнән үземне үзем кая куярга, нишләргә белмичә өнсезләнеп йөрдем. Искиткеч акыллы, сабыр, тыйнак, ягымлы кеше иде бит минем Сәкинәм. Ирне зур иткән дә – хатын, хур иткән дә – хатын, дип бик дөрес әйткән борынгылар. Председательнең эше болай да бик тынгысыз. Кояштан алда торырга, кояштан соң ятарга туры килә аңа. Яткач та, иркенләп йокларга бирмиләр әле. Тугыз йөз илле йортлы хуҗалыкта («Ватан» хәзер биш авылны берләштерә) еш кына төннәрен дә кичектергесез мәсьәләләр килеп чыга. Озынга сузмыйча гына әйткәндә, тәүлек буе эшли председатель. Фәлән сәгатькә кайтам, дип хатынга әйтеп китеп тә, вакытында кайта алмый калган чаклар турында әйткән дә юк инде. Ә бит хатын, бичара, менә кайтыр, менә кайтыр, дип, ике күзен дүрт итеп көтеп тора. Әмма мин Сәкинәнең шундый чакларда беркайчан да үпкәләгәнен хәтерләмим.

Ярый әле ул елны улым Ирек укуын тәмамлап кайткан иде. Укыган елларында ул, эшкә башка авылга китәм, үзем укыган мәктәптә, үземне укыткан укытучылар белән бергә эшләргә кыенсынам, дип йөргән иде. Инде менә эшләр болайга киткәч, мине ялгыз калдырма, улым, дип, мин үзем дә аның авылга кайтуын үтенгәч, үзебезнең Көрнәле мәктәбенә кайтып математика укыта башлады. Шулай аталы-уллы икәү кыш чыктык. Ә язын, Ирекнең укытуы беткәч, мин аны өйләнергә кыстый башладым. Малай каршы килмәде. Институтта укыганда яраткан кызы булган, укып бетергәч, ул кыз да безнең күрше районга эшкә кайткан икән. Җәйге каникулында шул кызны алып кайтты да, шуннан бирле матур гына яшәп яталар. Өлфәт абзаң хәзер бабай булды инде – оныгыбыз бар.

Үземнең сәламәтлек тә әйбәт әле. Тиз генә бирешергә исәп юк. Тик менә Сәкинәмнең вакытсыз үлеп китүе генә аяныч. Ул вафат булганга да ике елдан артты инде. Әмма мин аны һаман да шулай тере, чибәр һәм акыллы итеп күз алдымда тотам. Күңелемнән һәрвакыт аның белән сөйләшәм, киңәшләшәм...

Инде шушында сүзне туктатырга да мөмкин булыр иде. Ләкин...

**31**

Заманында Көрнәледә укыткан теге Гөлүсә белән тагын бер мәртәбә очрашуымны әйтми калдырсам, хикәям тулы булмас төсле.

Узган ел декабрь аенда Казанга барырга туры килде шулай. Килгән-килгән, берәр спектакль дә карап китим әле дип, үзебезнең татар театрына барган идем. Театрның күргәзмә залында артистларның рәсемнәрен карап йөри идем, иреннәрен, кашларын бик хәтәр итеп буяган бер хатын кояштай балкып яныма килде дә:

– Үзегез танып күрешмәссезме дип көттем-көттем дә, таныр чамагыз булмагач, үзем башлап сүз кушарга булдым. Нихәл, Өлфәт абый? – дип, күрешергә кулын сузды.

Мин аны тавышыннан танып алдым һәм аптырап калудан аркан авып китә яздым. Үзгәрсә дә үзгәрә икән адәм баласы! Тал чыбыгыдай нечкә билле, зифа буйлы, озынча чибәр йөзле элекке Гөлүсәгә тамчы да охшамаган иде ул. Битләре тулган-түгәрәкләнгән, биле колач җитмәслек булып юанайган, элек беленер-беленмәс кенә төртеп торган түшләре зурайган, хәтта заманында кап-кара булган чәчләренә тикле аксыл-сарыга әйләнеп калган иде. Хәер, анысын буяткан булгандыр инде...

Мин каршымда торган шул симез ханым белән элек бездә укыткан чибәр кыз арасында нindидер охшашлык табарга теләп, әмма һичнинди охшашлык таба алмыйча шаккатып торган арада, ул, сүзләрен пулеметтан аткандай сиптереп, үзегез һаман шул «Ватан»да эшлисезме әле, һаман председательме, улыгыз кайда, Сәкинәнең ни хәлләре бар, дип сораштыра башлады. Мин барысын сөйләп биргәч, көрсенеп куйды да:

– Ә теге сез кабыргасын сындырган Рәдиф кайда хәзер, гел шулай эчәме? – дип сорады.

Мин сиңа әйтеп китәргә онытып җибәргәнмен икән, туган. Рәдиф шулай ук гүр иясе булган иде инде. Алтмыш җиденче елның кышында, буранлап торган ачы салкын көнне күрше авылга барып, бик каты эчкән дә шуннан кайтып килешли туңып үлгән иде ул.

Шул хәлне сөйләп биргәч, Гөлүсә әллә ни гаҗәпләнмәде:

– Тәки барып чыккан икән! – диде дә, кемнәндер шикләнгән сыманрак итеп, як-ягына каранып алды. Аннары туп-туры күземә карап: – Теге вакытта Качкалак урманындагы тыйнаксызлыгым өчен сез миңа үпкәләгәнсез инде, Өлфәт абый әйеме? – дип сорады.

– Ул көннәрне искә төшереп тормыйк инде, – дидем мин, нык кына итеп үзен ачуланып ташларга телем кычытып торса да, сүз озайтырга теләмичә. – Әйтегез әле, Гөлүсә, үзегез ничек тормыш итәсез, кайда яшисез? – дип сорадым.

– Казанда мин хәзер, Өлфәт абый. Беркайда да эшләмим, – диде ул, соравын җавапсыз калдыруыма игътибар итмичә. – Хәтерегездәдер, сез икенче курста кышкы сессиягә имтиханга килгәндә, мин, институтыгызга барып, сезне киногa чакырган идем. Шунда мин сезгә бер доцент артымнан йөрүен дә әйттем. Исегездәме?

– Исемдә.

– Исегездә булса, менә шуның белән яшим инде мин. Сезнең белән булган хәлдән соң, үз ягыбызга кайтып бераз укыттым да, бөтен дөньясына үч итеп, Казанга киттем һәм туп-туры шул доцентның квартирына барып кердем. Ул мине бик куанып каршы алды, һәм без аның белән тора башладык. Хәзер ул зур кеше булды инде – профессор. Профессор хатыны мин, Өлфәт абый! Шуңа беркайда да эшләмим.

– Профессор хатыннарына эшләргә ярамыймыни соң?

Ул авыр сулап алды да, кинәт уйчанланып китеп:

– Ярый, нишләп ярамасын! – диде. – Бик эшләр идем дә, профессорым рөхсәт итми. Бик көнче ул, хәтта Колхоз базарына ит алырга да үземне генә җибәрми.

– Ярата торгандыр. Шуңа алай көнләшәдер.

– Һей! – диде Гөлүсә, кычкырып көлеп җибәреп. – Аның коры яратуы миңа пычагымамыни? Их, Өлфәт абый, белсәң иде син минем хәлләремне. Мин бит...

Ул сүзен әйтеп бетерми калды, яныбызга ябык кына, кечкенә генә гәүдәле һәм пеләш башлы бер кеше килде дә, миңа бөтенләй әһәмият бирмәстән, Гөлүсәнең җиңеннән тотып:

– Әйдә тизрәк, чиратым үтә юкса, – дип, театр буфеты ягына ымлады.

Гөлүсә, «менә шушы инде ул профессор» дигән мәгънәне аңлатып, ризасызлык белдереп, миңа күз сирпеп алды да теләр-теләмәс кенә ияреп китте.

**Соңгы сүз**

Менә мин вәгъдәмне үтәдем, туган. Үз башымнан кичкән һәм әле дә минем күңелне борчып торган, төнлә төшләремә кереп йөдәткән нәрсәләрне бер дә арттырмыйча-киметмичә сөйләп бирдем. Калганын син үзең кара инде, нәтиҗәсен үзең чыгар. Мин үз эшләремә үзем бәя бирергә теләмим. Теләсәм дә, дөрес бәяли алмас идем. Мин бары тик шуны гына әйтә алам: барлык эшләремне дә, үземчә, яхшы ният белән, кешеләргә кулымнан килгәнчә изгелек итү максаты белән эшләдем. Хәтта минем өчен җанын бирергә әзер торган һәм мин үзем дә аны өзелеп яраткан Сәкинәмне аерып җибәргәндә дә дөрес эшлим дип уйлаган идем. Ә соңыннан, үзеңә мәгълүм, әнә нинди хәлләр килеп чыкты... Күрәсең, адәм баласының табигате шундыйдыр инде: нинди генә эш кылырга тотынса да, башта үзен хаклы саныйдыр, шуңа инанып тотына торгандыр.

Хәер, алай дип кистереп әйтү дә бик үк дөрес булмас. Андый хәлләр мәсьәләне һәрьяклап уйлап җиткермәү, кызулык аркасында килеп чыга бит алар. Ә нәтиҗәләре йөрәккә уелып кала да гомер буе җанны әрнетеп, чәнчеп тора.

Әлбәттә, фәлсәфәгә бирелеп, уйлана-эзләнә башласаң, минем ул вакытта юләрләнеп китеп бер гөнаһсызга Сәкинәмне җәберләвемне дә, Рәдифнең, Хафиз картның әшәкелекләрен дә, Гөлүсәнең хикмәтләрен дә аңларга һәм билгеле бер дәрәҗәдә акларга мөмкин. Фашистлар китергән аяусыз сугыш нәтиҗәләре дип санарга була аларны. Бер караганда, чыннан да, шулай бу. Егерме яшем дә тулар-тулмас фронтка китеп, дүрт ел буена көнен дә, төнен дә пуля астында йөреп кайту бер дә эзсез генә калгандыр дисезме әллә? Авылның менә дигән ир-егетләрен сугышка алып китеп бетермәгән булсалар, Рәдиф тә ул тикле азына алмаган булыр иде, билгеле. Гөлүсә дә алай ук әрсезләнеп йөрмәс, аңа да үз тиңе, күңеленә ошаган бүтән егет табылыр иде... Ниһаять, колхозлар һәм колхозчылар тормышы да ул тикле үк кытлыкка калмас, гөрләп барган булыр иде...

Әйе, алары шулай. Ләкин шул ук вакытта бар гаепне сугыш кыенлыкларына гына кайтарып калдыру да дөрес булып бетмәс, чөнки сугыш мәхшәрләреннән әйләнеп кайтып, менә дигән итеп яши һәм эшли башлаучылар меңнәр, миллионнар булды! Димәк, хикмәт сугышта гына түгел монда...

Атом көчен һәм коралын уйлап таптылар. Унбиш-егерме ел элек кенә акыл җитмәстәй эш булып тоелган Айның да серләрен ачтылар. Ә менә кеше холкының, кеше психикасының серләренә ахырынача төшенү, аны бары тик яхшы психика гына итү өчен бик күп тырышасы бар әле. Бер минутлык дуамаллык аркасында бер гомерлек фаҗига эшләп ташлаучылар бер мин генә түгел, бар бит әле алар, туган, бар. Һаман шулай булырга тиеш түгел ич инде бу. Космосны өйрәнүгә генә түгел, үз холыклары белән идарә итү чараларын өйрәнүгә дә ныграк игътибар итсен иде кешеләр. Әгәр шуның серләренә төшенсәләр, минем ише шырпысыз кабынып китүчеләр дә, үз хисләрен үзләре йөгәнли

алмау аркасында, бүтәннәргә дә бәхетсезлек китереп, үзләре дә бәхетсез калган Гөлүсә кебек кыбырсык җаннар да, башта башкаларның тормышын бозып, соңыннан үз башларына үзләре җиткән Рәдиф ише яман бәндәләр дә булмас иде.

*1968–1969*

**ЯШЬНӘП ҮТКӘН ЯШЬЛЕК**

**Беренче бүлек**

**1**

Алар Барсайга килеп кергәндә, иртәнге әбәт тирәләре иде. Көн чалт аяз. Кояш бар көченә кыздыра. Җил булмаганлыктан бөркү, тирләтә.

Унсигезенче елның егерменче июле иде бу. Көнне-төнне белмичә урак ура, печән чаба торган чак. Бүтән елларда мондый көннәрдә авыл урамнары буп-буш, өйләрнең тәрәзәләре ябык, капкалары бәйле була торган иде. Ә быел әнә капкаларда бәйләр күренми, тәрәзәләр ачык. Урамда гайре табигый җанлылык: авыл кешеләре икешәрләп, өчәрләп капка төпләренә җыелып, нидер сөйләшеп торалар. Йөзләре борчулы. Боларда урак кайгысы түгел, болай булгач. Күрәсең, ниндидер җитдирәк хәлләр килеп чыккан булырга тиеш...

Миңнулла әнә шуларны уйлап барганда, авылның иң матур җиренә – су буендагы тугайлыкта үзе бер кечерәк авыл сыярлык урын биләп торган зур агач бакчалы, ике катлы йорт турысына килеп җиттеләр. Бу йорт Миңнуллага таныш иде. Февраль аенда Миңнулла шушы йортта Барсай халкын җыйнап җыелыш үткәрде. Ул җыелышта авылның ярлылар комитетын сайлап куйдылар, һәм бу йортны шул комитет карамагына тапшырырга карар кылынды. Ә йортның хуҗасы Сәйфи бай, күрәсең, үз хәлен үзе чамалаптыр инде, Октябрь революциясеннән соң, семьясын төяп, каядыр чыгып сызган да, шуннан бирле тыны-көне юк. «Мөгаен, берәр чит илгә киткәндер, элек тә Әнглияләргә, Мисырларга барып кайткалаган адәм ие ул», – дип сөйләгәннәр иде Миңнуллага аның турында.

Миңнулла олаучысы Заһит абзыйга атны Сәйфи йортының бакча коймасы янында туктатырга кушты. Үзе ялт кына арбадан сикереп төште дә таш түшәп бакча аша салынган, ян-якларына сәрви агачлары утыртылган сукмак буйлап өйгә таба китте. Ләкин болдырга менгәч, аның юлына ау мылтыгы тоткан бер кеше аркылы төште:

– Тукта, энекәш, ярамый сиңа анда керергә!

Мөгаен, бу авылда контрлар корткычлык итә башлагандыр, шуңа идарәгә кораллы сакчы куярга туры килгәндер, дип уйлап алды Миңнулла һәм:

– Ярар, абзый, күрдек: постыңда әйбәт торасың икән, молодец! – дип, эчкә үтеп китмәкче булды.

Әмма сакчы, дәү һәм таза гәүдәсе белән ишекне каплап, селкенмичә дә тора бирде:

– Әйттем бит инде, керергә ярамый, дип!

– Миңа ярарга тиеш, агай, – диде Миңнулла, каны кыза башлаганга шактый ук кискен итеп. – Мин өяз башкарма комитетыннан килгән вәкил!

– Беләм, энекәш, – диде сакчы, һич тә исе китмичә. – Кайдан килүеңне дә, кем икәнеңне дә бик әйбәт беләм: үткән кыш безнең Барсайда кәмитет битната сайлатып киткән Гайсин Миңнулла син. Мужыт, әле үзең дә мине хәтерлисеңдер, ул чакта син бездә кунып киткәниең ич.

Кояш яктысыннан кинәт күләгәгә кергәч күзе алмашынып киткәнгә генә танымыйча торган икән Миңнулла, хәтерли ул бу агайны, бик тә яхшы хәтерли иде. Әйе, Зәйнәпнең, Миңнулла өчен дөньяда иң кадерле, иң якын, иң акыллы һәм иң чибәр Зәйнәпнең этисе Сафиулла абзый иде бу! Узган юлы килүендә Миңнулланы менә шушы агайларга фатирга куйганнар иде. Шунда күргән иде Миңнулла Зәйнәп-сылуны. Шунда гашыйк булган иде Миңнулла ул чибәргә. Дөрес, Миңнулла ул кыз белән зурлап сөйләшә-таныша да алмады. Шулай да аз-маз сүз каткалап карады һәм шул чакта бик мөһим бер нәрсәне сизенеп калды: кыз да аңа битараф түгел, күз карашлары җылы, елмаюлары ягымлы, сүзләре тәмле, дустанә иде. Көлгән чакта бит алмалары уймакланып, тагын да чибәрләнебрәк китә, сүзләрен каушамыйча, кыю итеп әйтә торган шул кыз Миңнулланың күңел түренә әнә шул чакта кереп утырды да гел балкып, гел үзенә тартып тора иде. Миңнулланың башта волком үзәге Карыйга – үзенең туган авылына кайтмыйча, шушы Барсайга килүе дә асылда әнә шул Зәйнәп-сылуга барып тоташкан иде. Шул кыз белән иркенләбрәк бер сөйләшеп, сөйләшергә җае чыкмаса, ичмаса, күреп кенә булса да китәргә иде Миңнулланың исәбе...

– Гафу ит, Сафиулла абзый, син икәнсең бит әле! – диде Миңнулла. – Йә, ни хәлләрдә яшисез соң? Әминә җиңги белән Зәйнәп туташ исән-саулармы?

– Хәлләрнең рәте-чираты китебрәк тора шул әле-е-е! – диде Сафиулла агай. Аннары баш бармагы белән өске катка күрсәтте: – Әнә, тыңлап кара әле анда ни кыланганнарын.

Сафиулла агай белән мавыкканга гына игътибар итмичә торган икән Миңнулла, колак салу белән абайлап алды: өйнең өске катында шактый нык шаулашалар, кайсыдыр хәтта җыр башлап җибәрергә дә азаплана, тик кирәкле сүзләрен генә табып алып китә алмый иде.

– Сәйфи байның олы малае Шакир типтерә, – диде Сафиулла агай, Миңнулланың сораулы карашына җавап итеп. – Кичә төннә кайткан. Үзе белән тугыз-унлап солдат та ияртеп кайткан. Тәмам котырган ул нәрсә. Кичә бөтен авыл халкын урам уртасына җыйдыртып, кәмитет битната персидәтеле Хәкимҗанны үз кулы белән атып үтерде. «Сәвит яклы кешеләрнең барысын да менә шушы хәл көтә,

берсен дә калдырмыйча, менә шушылай атып үтереп бетерәчәкбез», – диде. Кичә минем кызны урамда күреп, тотып алган да, мин сине күптәннән күзләп йөридер идем, әйдә, минеке бул, дип тинтерәтергә тотынган. Тик кешеләр җыелып кына коткарып калган.

Миңнулланың башлары әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте. Ярлылар комитеты председателе Хәкимҗан абзыйны ул бик яхшы белә иде. Коммунист ук булмаса да, Хәкимҗан агай дөньяның ачысын-төчесен күп күргән, акыллы, гадел кеше иде. Авыл халкы арасында дәрәҗәсе дә бар, председатель итеп тә бертавыштан сайлап куйганнар иде үзен. Инде менә шул кеше дөньяда юк икән... Ә Зәйнәп!.. Ну кабахәт Шакир!!!

– Соң, шулай булгач, нигә син ул бандитны саклап торасың монда? – диде Миңнулла, бар ачуын Сафиулла агайдан алырга теләгәндәй каты итеп.

– Башыңа төшкәч, сакламый нишлисең инде, энекәш? – диде тегесе, гел шулай бер дә пошынмыйча гына. – Бүген иртән Шакир ике солдаты белән өйгә килеп керде дә, мин синең киявең булырга телим, кызыңны бир миңа, дип давайлый башлады. Ярый әле кызны төнлә шыпырт кына күрше авылга, туган тиешле кешеләребезгә илтеп кайтканыем. Югыйсә яман буласые хәлләр,

– Кыскарак кына итеп әйтеп бир әле, Сафиулла абзый! – диде Миңнулла, түземсезләнеп. – Шуннан нишләде теге кабахәт, ни белән бетте?

– Нәрсә булсын? Мин кызның кайда икәнен белмим, кичә син урамда тотып бәйләнә башлаганнан ары кайтып кына күренде дә, әти-әни, бәхил булыгыз, мине эзләп мәшәкатьләнеп йөрмәгез, бу хурлыкка түзеп тора алмыйм, башкайларымны юк итәм, дип, без алай-болай аңыбызга килгәнче, өйдән чыгып та китте, шуннан бирле кайтканы юк, дип җавап бирдем. Хатын да минем сүзләрне куәтләде. Шуннан ары теге кабих, төкерекләрен чәчеп: «Ах, шулаймы? Син әле кызыңны миңа бирергә теләмисеңме? Алдашып маташасыңмы? Кызыңның кайда икәнен әйткәнчегә кадәр ишек төбендә сакта тор алайса!» – дип, менә шушы мылтыкны тоттырып, шушында бастырып куйды. И һәм әйтте: «Әгәр качып китәсең икән, – диде, – җиде кат җир астыннан булса да табып, фәлән җиреңнән асып куям, бел аны!» – диде.

– Кулыңда мылтык лабаса синең, Алла бәндәсе! Җитмәсә, ике көпшәле бит әле. Адәм мәсхәрәсенә калып, ул контрны саклап торганчы, шушы мылтыгың белән аның үзен атып үтерергә ярамый идемени?

– Әй, ансат та инде, ә! Әй, җиңел дә соң кешегә акыл өйрәтүләре! – диде Сафиулла агай да, ниһаять, кыза башлап. Һәм мылтыгының патроннигын ачты. – Син башта менә моны кара!

Ике көпшәнең дә патрон урыннары буш – мылтык корулы түгел иде. Бу хәлгә аптырабрак калып, Миңнулла ни әйтергә белмичә торган арада, Сафиулла агай дәвам итте:

– Так шту, менә шулай, агайне! Даже бу мылтык корулы тәкъдирдә дә, син әйткәнчә эшләп булмасые. Патамушты әнә анда, өске катта, Шакирны тагын өч солдат саклап тора әле. Ә тагын алтысы үзе белән бергә типтереп яталар. Шуның өстенә алар кулында минеке шикелле корылмаган мылтык кына түгел, бумбыларына тикле бар аларның анда. Ә мин нәрсә? Мине ул прусты кызык итеп, кызны бирмәгәнгә ачу итеп кенә бастырып куйган монда.

– Кызылгвардиячеләр отряды бардыр ич авылыгызда?! Нигә шуларны ярдәмгә дәшмәдең?

– Кызмасана, энекәш, юкка. Синдәге баш миндә дә бар ла анысы әзрәк. Әйе, барые безнең этрәт. Мин үзем дә шуның бер әгъзасы булып йөридерием. Унҗиде кеше иек без. Ну узган атнада ундүртебезне фрунтка апкиттеләр. Өчебезне, ярамыйсыз, дип алмадылар. Мин үзем, например, менә шушы сул аяк бөгелмәү аркасында калдым. Уналтынчы елда гирман сугышында ранный булганыем. Карале, энекәш, син менә этрәт тә этрәт дисең. Үзеңнең этрәтең кая соң синең? Сине өяздә этрәт башлыгы булып йөри дигәннәрие бит.

Отряд башлыгы гына түгел иде Миңнулла. Зуррак иде аның дәрәҗәсе. Пермь губернасының Усы өязе башкарма комитеты председателе урынбасары һәм кызылгвардиячеләрнең өяз штабы члены иде ул.

Өязгә караган авылларда контр элементлар кыбырсый башлавы турында соңгы көннәрдә хәбәрләр ишетелә башлаган иде. Шуңа күрә партиянең өяз комитеты өяз башкарма комитеты хезмәткәрләрен, шул мәсьәләне тикшереп, кирәк булса, контрларга карата катгый чаралар күреп, кыскасы, җирле комитетларга ярдәм итеп кайтырга дип, авылларга чыгарып җибәрде. Миңнулланы, синең эшнең нәтиҗәсе зуррак булачак, дип, Карый һәм Кече Ашап волостьларына керә торган авылларга билгеләделәр. Миңнулланың Усыдан чыгып китүенә бүген өченче көн. Кичә ул Ильиновка авылында булды. Анда алай зыянлы нәрсә юк иде. Ярлылар комитеты дилбегәне кулында нык тота икән. Тик урта хәллегә караганда байга якынрак торган, шулай да авыл халкының миһербанлылыгы аркасында сөрелмичә калган һәм соңгы көннәрдә, барыбер озакка бармаячак бу советлар, тиздән безнең якларга азатлык армиясе килеп җитәчәк тә иске тәртипләрне яңадан кайтарачак, дип, халык арасында лыгырдап йөри башлаган бер бәндәне авыл советына дәштереп, ару гына пешекләп чыгардылар да, шуның белән эш беткән иде. Ә бүген Миңнулла Барсай ярлылар комитетының хәлен белеп, кирәк булса, ярдәм дә итеп, кичен үзенең туган авылы Карыйга, әти-әниләре янына кайтып кунарга ниятләгән иде. Ләкин

монда мәсьәләләр катлауланган булып чыкты бит әле. Эшнең болайга ук китәрен белсә, Миңнулла үзе белән Шакир-контр шикелле тугыз кешелек кенә түгел, унтугыз кешелек кораллы отряд алып килгән булыр иде дә бит, ләкин...

– Бөтен бәла дә менә шунда, Сафиулла абзый, отрядсыз гына килгән идем бу юлы! – диде Миңнулла, бик нык үкенеп. – Әгәр отряд...

Аның сүзе шунда бүленеп калды, чөнки өске каттан кемдер бик әшәке итеп сүгенеп, абына-сөртенә аска төшеп килә башлаган иде.

– Бар, энекәш, ычкын исән чакта! – диде Сафиулла агай, коты алынып. – Бар, тизрәк Усыга кайт та этрәт алып килү җаен чамала!

Миңнулла йөгерә-атлый урамга чыкканда, Заһит абый кырпу бүреген салып куеп, кәләпүштән генә калган да, арбасына аяк бөкләп утырып, әле шешәсендәге сөтен, әле кулындагы ипи кыерчыгын каба-каба, бик тәмләп ашап утыра иде. Миңнулла, аның янына килеп:

– Әйдә, Заһит абый, ашавыңны куеп тор да, кузгалыйк әле моннан тизрәк! – дигәч, дерт итеп сискәнеп китте.

– Һәй, юлың уңгыры, син икәнсең ич әле! Котымны алдың, – диде ул. – Кай арада эшеңне бетереп чыктың соң син? Атның аркалыгын төшереп кенә өлгергәнием бит әле, – дип мыгырдана-мыгырдана, шешәсен бөкеләп, икмәген төреп капчыгына тыкты. Шуннан ары гына Миңнуллага күтәрелеп карады һәм, шаккатып:

– Ни булды сиңа, олан? Йөзең аппак булган лабаса! Әллә бер-бер хәл килеп чыктымы? – диде.

Олаучысының куркак кеше икәнен белә иде Миңнулла. Өченчекөн Карый һәм Ашап волостьларына барасы икәнен белгәч үк:

– Әллә бүтән кеше белән сөйләшеп карыйсыңмы, наный. Бер дә кузгаласым килми, аягым тартмый шунда барырга. Әллә ниткән хәвеф-хәтәрләргә таруыбыз бар, – дип, шактый карышып азапланган иде бу агай.

Тик Миңнулла, кесәсеннән наганын чыгарып:

– Менә бу нәмәрсәкәй безнең белән булганда, шайтанның үзеннән дә курыкма син, Заһит абзый! – дигәч кенә, анда да шул наганнан шикләнеп кенә ризалашкан иде.

Юлда килгәндә дә әледән-әле тынгысызланып:

– Ай-һай, наный, напраснырак кузгалмадык микән? Шушы карап торган бердәнбер атымнан да колак кактырырга йөрмисең микән син мине? Яхшы чакта әллә борылып кайтып кына китәбезме? – дип сөйләнеп килгән иде.

Хәзер аңа Барсайның комбед председателен атканнарын һәм әтисе йортында Шакир-контрның ни кыланып утыруын әйтсәң, йөрәге ярылачак.

– Чүп тә юк, Заһит абзый! Мин барында берәүдән дә шикләнмә син! – диде Миңнулла, тегене тынычландырмакчы булып.

Әмма олаучы тынычланмады:

– Алла, диең, наный! Әстәгыфирулла, диең! Алтатарлы кеше бер син генә түгелдер дөньяда. Бу заманда синнән башка да җитәрлектер андыйлар, Алланың бер үзенә тапшырдык, дип сөйләш, ичмаса, аны!

Заһит агай әнә шуларны такмаклый торган арада, Миңнулла тиз генә аркалыкны күтәрде, ат башына кидереп куелган солылы капчыкны салдырып алды да, дилбегәне үз кулына тотып, атны кайтыр якка борды. Зәһәр генә итеп сыптырып та алды. Әллә ни шәп җилдерә алмаса да, ат ару гына юыртып алып китте.

Ул минутларда Миңнулланың күңелендә бер генә уй бөтерелә иде: «Тизрәк Карый волкомына кайтырга да, шуннан кораллы отряд алып килеп, айнып җиткәләгәнче, Шакир-бандитны да, аның шайкасын да кулга алырга!»

Ләкин Карыйга алай тиз генә кайтырга язмаган икән шул.

**2**

Инде авылдан чыгып барганда гына, тыкрык буендагы каравыл өе янында җыйналган утыз-кырыклап кешене күреп алды Миңнулла. Күреп алды да, атын туктатып, Заһит агайга шул туктаган урыннарында көтеп торырга кушты. Үзе, теге кешеләр янына барып:

– Исәннәрмесез! – диде.

Ләкин аңа берәү дә игътибар итмәде. Җыендагыларның барысы да, муеннарын сузып, каравыл өенең нигрәсендә кызып-кызып нидер сөйләп торган яшь кенә, чибәр генә, кара мыеклы кешегә текәлгәннәр һәм, мөкиббән китеп, шуны тыңлыйлар иде. Миңнулла да ул кешене күрү белән танып алды: үзләренең Усы өязендәге Чирканды авылы мулласы малае, әле узган елда гына Уфада «Галия» мәдрәсәсен тәмамлап кайткан Хәйретдинов Хәйрулла иде бу.

Тагын нәрсәләр лыгырдап йөргән була икән монда дип, Миңнулла аның сүзләренә колак салды.

– Әле менә шушы араларда гына яңадан тортызылган Милли Шура әгъзасы вә үзебезнең милләт язмышын кайгыртучы хак мөселман буларак, – дип сөйли иде теге, – мин сезгә кыл дөресен генә әйтәм, җәмәгать: безгә патшасы да, камунистлары да сукыр бер тиенгә дә хаҗәт түгел! Патшасы да гомергомергә без мөселманнарны кимсетеп, талап килде, камунистлары да игелек күрсәтәчәк түгел. Камунистлары хәтта патшадан да залимрәк аның, беләсегез килсә. Патша заманында без мөселманнарны «гололобый» дип мыскылласалар да, аң-белем алырга ирек бирмәсәләр дә, ичмаса, денебезгә вә Аллага тел тидермәделәр. Ә менә бу камунист дигәннәре, совет дигәннәре Аллага вә дингә каршы чыгучылар алар! Әйе, җәмәгать, мин сезгә кыл дөресен әйтәм, денебезне бетермәкче безнең ул камунистлар. – Нотыгы халыкка ничегрәк тәэсир иткәнен чамалау өчен булса кирәк, Хәйрулла, шунда туктап, беркавым җыендагыларга карап торды. Тегеләрнең селкенмичә дә тыңлаулауларын күргәч, тагын да кодрәебрәк дәвам итте: – Шулай, җәмәгать, моннан да зуррак золымның һичкайчан булганы юк әле. Үзегез уйлап карагыз: без сезнең белән күпме кан түгеп, күпме көч куеп бер залимнән – рус патшасыннан котылу өчен революция ясадык, ә влачны кемнәр алды? Влачны камунистлар тартып алды. Бу ни дигән сүз? Бу менә нәрсә дигән сүз, җәмәгать: бер залимнән күп залимнәргә, патшасына караганда да яманрак залимнәргә килеп каптык без. Ә бит революцияне без ирек өчен дип, хөррият өчен дип ясаганыек, җәмәгать. Хәлбуки безгә хөррият дигән нәрсә тәтемәде. Камунистлар дәүләт башында утырган тәкъдирдә тәтемәячәк тә ул безгә. Ни өчен дисәгез, камунистларны безнең ише мөселман динендә булган бәндәләр генә түгел, урыслар үзләре, вә һәм Җир шарында иң бай, иң көчле Америка вә Англия илләренең патшалары да яратмый. Нимечләр, чихлар, мадьярлар вә шулар ише бүтән бик күп халыкларның совет влачына каршы икәнен әйтеп тә торасы юк инде. Тик шуны гына исегезгә төшереп үтүне лязим күрәм: менә шул милләтләр барысы берләшеп, камунистларга, советларга каршы сугыш башлап җибәрде. Безгә аларга каршы торып азапланудан хасият юк, җәмәгать. Без, татар вә башкортлар, үзара бер булып, үз өязләребездәге вә вулысларыбыздагы совет влачын алып ташлап, үзебезнең иркле милли мәмләкәтебезне – Идел-Урал дәүләтен төзергә тиешбез. Ошбу изге максатны гамәлгә ашыру өчен безгә нәрсә эшләргә кирәк соң? Безгә моның өчен иң элек үзебезнең милли гаскәребезне төзергә кирәк, җәмәгать! Аннары шул гаскәр сафларына бөтенебез бердәм булып басып, борынгы ата-бабаларыбыз шикелле арысланнардай батыр булып, аяусыз булып дошманга каршы көрәшергә кирәк. Шунсыз безнең татар-башкортка ирек вә хөррият булачак түгел! Шунсыз безнең мөселман халыкларына якты көн килмәячәк! Шунсыз...

Миңнулла шуннан арыгысын тыңлап торуны кирәк тапмады, чөнки «мөселман кардәш»нең бу нотыгы аңа таныш иде инде.

Узган елның декабрь аенда Усы өязенең земская управасы каршындагы Милли Шура оешмасы өяз мөселманнарының съездын үткәрде. Усы укомы председателе Емельян Петрович Колеговның тәкъдиме буенча Миңнулла да шул съездда катнашты. Миңнулла ул чакта үзләренең Карый волостенда эшли, съездга аны шул волость делегаты итеп җибәргәннәр иде. Делегатларның күпчелеге, әлбәттә, сәүдәгәрләр, куылудан калган байлар, мулла-монтагайлардан гыйбарәт иде. Съездны намаз укып ачтылар. Көн тәртибенә куелган мәсьәләләр артык күп булганга, аларны хәл итүне ансатлаштыру максаты белән берничә комиссия төзеделәр. Укымышлы, шуның өстенә тагын сугышта да булып кайткан кеше буларак, Миңнулланы хәрби комиссия составына сайладылар. Ә ул комиссиягә оешачак милли гаскәрнең структурасын билгеләү бурычы йөкләтелгән иде. Менә хәзер Барсай авылында, бәләкәй генә бер йортның нигрәсендә, төкерекләрен чәчә-чәчә, авыл апайларына нотык сөйләп торучы Хәйрулла да шул комиссиядә булып, анда да нәкъ менә шушы сүзләрне лыгырдаган иде. Миңнулла нәкъ менә шушы бәндә аркасында милләтчеләр кулына каба язып калган иде дә ул чакта!

Миңнулла ул съездда чыгыш ясарга тиеш түгел, аңа съездда каралган мәсьәләләр һәм съезд кабул иткән программа белән танышып кайту бурычы гына йөкләнгән иде. Ләкин әлеге шушы Хәйрулла менә хәзер такылдап торган нотыгы белән чыгыш ясагач, Миңнулла түзеп тора алмады. Председательлек итүче кешенең рөхсәтен сорап тормастан, атылып трибунага менде дә:

– Иптәшләр! – дип кычкырды.

Моңарчы чыгыш ясаган делегатларның барысы да сүзләрен «әфәнделәр» дип башлаганнар иде. Шуңа Миңнулланың «иптәшләр»е залдагы милләтчеләргә аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте: алар ду килеп шаулаша башладылар. Ләкин Миңнулла янә бер тапкыр, бу юлы тагын да ныграк итеп «Иптәшләр!» дип кычкыргач, кинәт шып булып калдылар һәм трибунага текәлделәр. Миңнулла бик нык дулкынланып, әмма сүзләрен ачык әйтеп сөйләп китте:

– Минемчә, без биредә юкка гына вакыт үткәреп, һич кирәкмәгән нәрсәләр турында баш ватып утырабыз! Менә миннән алда бик дәртләнеп сөйләгән адәмнең нотыгына игътибар итик. Ул ярты сәгать буена татар-башкорт милли дәүләтен төзергә, ә аның өчен башта милли гаскәр оештырырга кирәклеге хакында сүз алып барды. Әйе, милли гаскәрне чыннан да оештырырга кирәк безгә. Ләкин ул, әлеге адәм уйлаганча, буржуйларны яклап керәшә торган гаскәр түгел, бәлки Совет дәүләтен саклап калу өчен көрәшә торган гаскәр, революция гаскәре, татар белән башкортларның азатлыгы өчен генә түгел, бөтен Россиядәге барлык халыкларның азатлыгы өчен көрәшә торган гаскәр булырга тиеш! Ә

теге адәм әйткәнчә, милли гаскәр төзергә тырышу – контр сүзе, революция дошманнары тарафыннан уйлап табылган нәрсә ул! Ул өйрәткән юлдан китсәк, чит ил дошманнары белән берләшеп, байлар-буржуйлар бик тиз кулга алачак безне. Киресенчә, Рәсәйдәге барлык милләт халыклары белән берләшеп, бер нык йодрык булып, революция дошманнарына, чит ил капиталистларына каршы күтәрелергә кирәк безнең мөселман халкына. Миннән алда сөйләгән бәндә үзе әйтмешли, без мөселман кардәшләребезне менә шул бөек һәм изге максатка әйдәргә тиешбез! Тик шул чакта гына безнең татар халкы бүтән халыклар белән тигез хокуклы булыр, тик шул чакта гына безнең халкыбыз хөррияткә һәм якты көн күрә башлауга ирешер! Бу минем үз фикерем генә түгел, иптәшләр. Бу – чын мәгънәсендә ирек һәм тигезлек өчен көрәшүче Коммунистлар партиясе фикере, шул партиянең бөек җитәкчесе Ленин фикере!

Хәйрулла нотыгыннан соң залны дер селкетеп кул чапкан милләтчеләр, Миңнулла сүзен тәмамлагач, бер мәлгә телсез калып тордылар. Тик ул трибунадан төшеп, урынына утырырга бара башлагач кына өннәренә килеп, төрлесе төрле яктан кычкыра башлады:

– Кызыл әтәч!

– Большевиклар шпиуны!

– Милләт сатучы!

– Денсез, кяферләргә сатылган нәрсә!

Миңнулла шулайрак буласын алдан ук чамалап торган иде. Шуңа тегеләрнең кычкырышуына артык әһәмият бирмәде.

Тәнәфескә чыккач, Миңнулла янына аңа электән таныш булган бер делегат килде дә:

– Сиңа хәзер үк моннан китәргә кирәк, егет. Большевиклар агенты дип кулга алырга җыеналар сине. Чирканды Хәйрулласының Чегән Гата белән шул хакта сөйләшеп торганын үз колагым белән ишеттем! – диде.

Әйе, Миңнуллага бу контрлар җыенында калу, чыннан да, куркыныч иде хәзер. Һәм калып торуның әллә ни хаҗәте дә юк иде. «Съезд мәсьәләләренең күбесе инде каралды, программасы, нигездә, ачыкланды – чеп-чи милләтчеләр программасы булачак ул. Шулай булгач, инде кайтып китәргә дә ярый торгандыр», – дип, Миңнулла болдырга чыккан гына иде – каршына, мыскыллы елмаеп, Чегән Гата килеп басты:

– Гайсин Миңнулла әфәнде син буласыңдыр бит?

– Әйе, мин – Гайсин. Ләкин әфәнде түгел!

Миңнулла шуннан бүтән сүзгә килешеп тормыйча гына үтеп китмәкче булган иде, әмма Гата аның кулыннан тотып алды һәм, гел шулай ачу китергеч елмайган килеш:

– Ярый, анысы ни важны. Анысын ошатмасаң, «иптәш» дияргә дә була. Без алай артык нәзберек халык түгел. Тик син, Гайсин иптәш, ашыкма китәргә. Мин сине Идел-Урал мәмләкәте исеменнән кулга алырга тиеш булам хәзер, – диде.

– Беренчедән, синең съезд делегатына кагылырга бернинди дә хокукың юк! Икенчедән, андый дәүләт булганын мин белмим!

– Белмәсәң, белерсең! Мин сине булачак, төзелеп ята торган Идел-Урал мәмләкәте исеменнән кулга алам, Гайсин! Каяле, кесәләреңне тикшереп карыйк, коралың юкмы икән?

Эшләр болайга ук китә башлагач, Миңнулла наганын тартып чыгармакчы иде, кызганычка каршы, өлгерә алмый калды: арттан аның кулларын тотып алдылар да каерып бәйләп тә куйдылар. Миңнулла кычкырырга итә башлагач, башта авызын уч белән капладылар, аннары тире бияләй тыктылар. Төрткәли-типкәли, съезд бара торган йортның ихатасына алып чыктылар. Анда җигүле пар ат тора иде. Тиз генә Миңнулланың башына капчык кидерделәр һәм аны чанага төртеп ектылар. Шыгырдап капка ачылганы ишетелде. Кемдер ачы итеп сызгырып җибәрде. Кайсыдыр чыжлатып чыбыркы белән атларга сукты. Атлар урыннан ук кушаяклап торып чабып китте.

Ләкин күп тә үтмәде, мылтык аткан тавышлар ишетелә башлады. Миңнулланы алып китеп баручылар:

– Булмады, янабыз, ахрысы! – дип, башта бик каты сүгенешеп алдылар, аннары Миңнулланы чанадан ташлап калдырып, артларыннан куа килүчеләргә ата-ата, ары киттеләр...

Гата шайкасы кулына әнә шулай чак-чак кына эләкмичә калган иде Миңнулла. Уком председателе Емельян Петровичка рәхмәт инде: андый-мондый хәл килеп чыга калса дип, съезд бара торган йортны күз уңында тотарга кушып, дежурга биш кешелек отряд билгеләп куйган булган икән.

Миңнулланы коткарган отряд кешеләре шул ук көнне Гатаны һәм аның ике ярдәмчесен дә тотып алып кайтып, өяз каталажкасына ябып куйганнар иде. Ләкин хөкем итәргә өлгерә алмый калдылар. Иректә калган шайкадашлары коткарган тегеләрне. Төн уртасында, каталажканы саклаучы агай йокымсырап утырган чакта килеп кергәннәр дә, аны куркытып, каталажка ишеген ачтырганнар һәм Гаталарны чыгарганнар. Аннары кулын артка бәйләп, авызына чүпрәк тыгып, каталажкага сакчының үзен бикләп киткәннәр иде. Соңыннан тагын шунысы да ачыкланды: бу эш шулай ук менә хәзер Барсай

мужикларын милли Идел-Урал дәүләте төзергә үгетләп торган Хәйретдинов Хәйрулла коткысы белән эшләнгән булып чыкты...

Хәйрулланың әнә шул чактан бирле күзгә-башка күренгәне юк иде, инде менә тагын каяндыр калкып чыккан, хәерсез! Күрәсең, аклар белән тыгыз элемтәдә булгандыр да, ак бандалар һәм унбиш миллионга чит ил буржуйларына сатылган Басарик җитәкчелегендәге чехословак корпусы гаскәрләре бу якларга үрмәләвен сизенеп, тагын үзенең кабахәт эшенә керешкәндер. Яки акларның үзләрендә үк хезмәт иткәндер дә тегеләр аны яшерен агентлары итеп бу тирәләрдәге хәлләрне тикшереп, хәбәр итеп торырга кушып җибәргәннәрдер.

Әле һаман Барсай халкын үгетләвен дәвам иткән Хәйруллага карап торган арада менә шундый уйлар үтеп китте Миңнулла күңеленнән. Һәм ул, әллә шушында атып ук үтерим микән бу ата контрны, дип, кесәсендәге наганын капшап куйды. Ләкин коралсыз кешегә тиктомалга ату егетлек булмас дип, уеннан кире кайтты һәм, ни кылганын үзе дә сизмәстән, нәкъ узган елгы Милли Шура съездындагыча, ялт кына Хәйрулла янына – өй ниргәсенә менеп басты да, тегене тыңлап торучы халыкка мөрәҗәгать итеп:

– Иптәшләр! – диде.

Хәйрулла телен тешләгәндәй тынып калды. Ә Миңнулла муенын кысыбрак торган күлмәк якасының төймәсен ычкындырып җибәрде дә кызып-кызып сөйләп китте:

– Сез бу кешегә тамчы да ышанмагыз, иптәшләр! Милләтне яклаган булып дошман сүзен сөйли бу бәндә. Совет власте бетмәячәк! Коммунистлар шулай ук бетмәячәк. Чөнки аларның башында Ленин үзе тора! Ә Ленин ул гаделлек яклы, эшчеләр һәм крестьяннар яклы! Халык җилкәсен кимереп, халык мөлкәтен ашап, симереп яткан байларга каршы ул Совет дәүләте, халыкны алдап көн күрүче муллаларга каршы! Ә менә сезне ниндидер милли мәмләкәт төзергә вәгазьләп тора торган бу адәм – Чирканды мулласы малае! Шуңа совет властен яратмый ул, шуңа коммунистларга каршы сөйли. Ә дин саятыннан бер дә хафаланмагыз, иптәшләр: совет власте дингә кагылмый ул. Дин тоту-тотмауны халыкның үз иркенә куя. Икенче төрле итеп әйткәндә, дин дәүләт эше итеп каралмый, хөкүмәт аның өчен акча тотмый. Тотмаса тотмас, иптәшләр, патша хөкүмәте дә ул эш өчен безнең халыкка бер тиен дә бирми килде ләбаса! Шулай булгач, бу мәсьәләдә сезгә һичнинди зыян тимәячәк. Безнең бүгенге көндәге төп бурычыбыз менә нәрсәдән гыйбарәт, иптәшләр: хәзер без, бар көчебезне биреп, ак бандаларга, яшь Совет дәүләтен буып ташларга тырышучан чит ил дошманнарына, байларга һәм менә бу Чирканды мулласы малае кебек контр элементларга каршы көрәшергә тиешбез!

Миңнулла боларны бер тын белән шундый ышанычлы, шундый тәэсирле итеп сөйләде, авыл агайлары исләре китеп, сулу да алмыйча тыңлап тордылар. Хәйрулла да теш агартып сүз катмады. Тик Миңнулла сөйләп бетергәч кенә, кодрәтләнеп китеп:

– Менә, җәмәгать, бу бәндә камунистның иң азгыны инде! Камунистлар менә шушындый әтәч халык инде алар: очып кунарга гына торалар. Мин әле сезгә әйтәсе сүзләремнең яртысын да әйтергә өлгермәгән идем, ә менә бу адәм, кешенең сүзен бүлеп, үзенекен такылдап та алды. «Рөхсәт итегез, җәмәгать, миңа сүземне дәвам итәргә», – дип, сандугач урынына сайрый башлаган иде, ләкин авыл агайлары:

– Мәтәшмә, энекәш, юк белән. Әйтәсе сүзең бар икән, менә шушы камунист егет шикелле өздереп, кыска гына итеп әйтергә кирәк аны, ничу су буе итеп сузарга! – дип, аңа ирек бирмәделәр. Миңнулланы урап алдылар да: – Син өяздән килгән нәчәнник бугай, наный, әйт әле безгә, өяз сәвите ни карый соң анда? Нигә бу араларда дилбегәне бик йомшаттыгыз? Куылган байлар тагын кайта башлады лабаса! Тагын мужикка көн бетә бит инде, болай булса! – диешеп, төрле яктан сукранырга тотындылар.

«Әһә, бу агайларның совет властена карата иманнары нык икән!», дип куанып куйды Миңнулла. Һәм ул иплән кенә аларның сорауларына җавап та бирә башлаган иде. Әмма шулчак җыендагыларның берсе:

– Карагыз әле, җәмәгать, тагын кайсыларыдыр килә анда безнең авылга! – дип, халыкның игътибарын җәлеп итте.

Барысы да ул күрсәткән якка борылдылар. Артларыннан тузан болыты күтәреп, атларын бик нык куалап, Барсайга дүрт җайдак якынлашып килә иде. Халык төрлечә фараз кылып торган арада, тегеләр ут өермәседәй ажгырып килеп тә җитте. Аларның өчесен Миңнулланың күргәне юк, әмма берсе таныш – шурачылар съездында үзен кулга алган әлеге Чегән Гата иде.

Бүтәннәре җыен читендә тукталып калды, ә Гата аты белән халык арасына ук килеп керде дә:

– Старостагыз мондамы? – дип кычкырды.

– Юк, монда түгел, – диделәр аңа.

– Кайда ул?

– Сәйфи бай малае Шакир кайтты, ул дәштергәние бугай аны.

– Латны. Ә дисәтникләрдән монда кемнәр бар?

Гатага җавап бирүче булмады.

– Дисәтникләрдән кемнәр монда? – дип акырды Гата.

Тик шуннан соң гына кап-кара сакал-мыегына күптән пәке тимәгән, сәләмә генә киемле, чандыр гына гәүдәле бер кеше тегеңә якынрак килде дә куркып кына:

– Мин ием дисәтник, Гата туган, – диде.

– Синең ише туган белән мин күпер башында к... юган! Нигә ирләрне Васкрисинскигә кумыйсың, өтек? Әйткәннәрдер бит сиңа бар булган ир-атларны, коралландырып, Васкрисинскигә аппарырга кирәк икәнен?

– Безгә бер дә ул хакта әмер биргән кеше булмаганые шул, Гатаулла. Дисәтник булырсың, дип тә Шакирҗан миңа бүген иртә белән генә әйткәние әле. Безнең ир-атлар нигә дип барырга тиеш була икән соң ул урыс авылына? Ниткән корал икән инде ул тагын?

Гатаның чыннан да нәкъ чегәннәрнеке кебек каратут йөзе бүртенеп, тагын да каралыбрак китте:

– Ах, туң ми! Син әле коралның нәрсә икәнен дә белмисеңмени? Менә шушындый була ул корал! – диде дә, кесәсеннән наганын тартып алып, шул наган түтәсе белән десятникның күкрәгенә төртте. Бичара агай һык итеп китте дә хәлсезләнеп җиргә чүкте. Ә Гата, аңа бөтенләй игътибар итмичә, ике тапкыр рәттән һавага атып җибәрде. Куркышып-аптырашып калган авыл агайларына карап, калын һәм карлыккан тавыш белән җикеренергә тотынды:

– Нигә авызларыгызны ачып торасыз, ахмаклар! Мин әйткәнне ишетмәдегезмени? Барыгыз, хәзер үк өйләрегезгә кайтыгыз да мылтыклары булганнар – мылтыкларын, мылтыгы булмаганнар сәнәк-күсәкләр алып, менә шушында җыйналыгыз! Бер сәгать вакыт бирәм мин сезгә! Кем дә кем бер сәгать эчендә килеп җитми – миңа әбиҗәтсе итмәсен! Җәһәннәм тишегеннән табып, кулымдагы менә шушы наган белән атып үтерәчәкмен! Ишеттегезме?!

Түгәрәк ак сакаллы бер бабай:

– Без анда барып ни эшләрбез икән соң, Гатаулла? – дип сораган иде, Гата аңа:

– Баргач күрерсең шунда, ә хәзер, бар, тизрәк кушканны үтә! – диде дә каядыр китмәк булып атын бора башлады. Шулчак теге «мөселман кардәш» аның каршына чыкты һәм, башы җиргә тиярдәй итеп бөгелеп:

– Әссәламегаләйкем, Гатаулла абзый! – диде.

– Чукын инде! – диде Гата, тегенең сәламен алып тормыйча гына. – Син дә мондамыни әле, Хәйрулла әфәнде? Ниләр кыдырып йөрү?

– Безнең эш билгеле инде, Гатаулла абзый: Милли Шура съезды карарларын гамәлгә ашыру артыннан йөргән көн.

Гата гамьсез генә сорап куйды:

– Ничек соң, эшегез барып чыгар төслеме?

«Мөселман кардәш» әле һаман таралырга ашыкмыйча, тегеләрнең сүзен тыңлап торган авыл агайлары арасыннан Миңнулланы күрсәтте:

– Менә монавындый денен вә милләтен кяферләргә саткан адәм калдыклары булмаса, барып чыгар иде дә, шушылар аяк чала шул, Гатаулла абзый! Бәлки әле, хәтерлисеңдер: үткән ел Усыда уздырылган мөселманнар съездында көфер сүз сөйләп бөтен съездның тәртибен бозган, аннары килеп сезнең башыгызга җитә язган ата камунист Гайсин Миңнулла дигән адәм инде бу!

– Шу-у-лаймы-ни? – диде Гата, бик каты исе киткән атлы булып. Аннары, бармагын изәп, Миңнулланы үз янына чакырды. – Ну-ка, ну-ка, кил әле монда, денеңнән язган нәрсә!

Миңнулла бер сүз дәшмичә баскан урынында торуын дәвам иткәч, Гата атыннан сикереп төште дә үзе Миңнулла каршына килеп басты. Берничә секунд икесе дә күзгә күз терәшеп тордылар. Гатаның иләмсез зур һәм таза гәүдәсенә, бәбәкләрен кан баскан нурсыз соры күзләренә карап тору бик читен булса да, түзде Миңнулла – карашын читкә бормады. Текәлеп бер карау белән теләсә кемнең өрәген ала торган Гатаның бу хәлгә җен ачуы чыкты: тешләрен шыгырдатып куйды да утын тукмагы кадәр йодрыгын Миңнулланың ияк астына китереп терәде:

– Яле, дөресен генә сөйләп бир әле, кызыл этәч: ни эшләп йөрисең син монда? Һаман шулай халыкны денсезлеккә өндәп, милләткә каршы котыртыпмы? Яле, яхшы чакта бөтенесен дә иплән кенә әйтеп бир әле!

– Иң элек мин допрос алырга җыенучы кешенең үзе кем булуын белергә теләр идем, – диде Миңнулла, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып. – Әгәр ул кешенең шуңа вәкаләте бар икән, мин аңа җавап бирергә әзер!

– Ах, кызыл этәч, әле сиңа вәкаләт кирәкмени?! Менә сиңа ул вәкаләт!

Гата Миңнулланың күн курткасы изүеннән шундый итеп тотып тартты – дүрт төймәсенең дүртесе дә берьюлы шатырдап өзелеп, атылып киттеләр. Аннары Гата үзе белән килгән җайдакларга боерды:

– Яле, бөркетләр, акылга утыртып алыгыз әле бу ахмакны! – Тегеләр атларыннан төшкән арада, Гата: – Каяле, коралың юк микән, Алладан җәяүләп качкан нәрсә! – дип, Миңнулланы тентергә үрелде.

«Коралны алсалар – бетте баш. Ичмаса, үзен дә дөмектереп калыйм!» дигән уй йөгереп үтте Миңнулла күңеленнән һәм ул:

– Тукта, үзем бирәм! – диде дә куртка кесәсеннән наганын алып, атып җибәрде.

Атуын атты, ләкин тидерә алмады. Гата читкә тайпылып калды. Ул арада Гатаның ярдәмчеләре килеп җитеп Миңнуллага ябырылдылар һәм наганын каерып алырга тырыша башладылар. «Тере килеш бирелмәскә!» – дип уйлап алды Миңнулла. Әле һаман кулыннан ычкындырмаска тырышкан наганын үзенә таба борып, чакмага басты. Ләкин пуля аның күн фуражкасын тишеп кенә үтеп китте.

Ниһаять, Гата аның наганын тартып алды. Аннары каерылып яңагына сукты. Ул шунда берочтан Миңнулланы атып үтермәкче дә булган иде, тик ярдәмчеләренең берсе, аның кулыннан тотып:

– Ашыкма, Гатаулла, моңарчы кеше үтермәгәнне, хәзер генә гөнаһлы булма! Синнән башка да үтерүчеләр табылыр, – дигәч, тыелып калды һәм, суярга салган дуңгыз тавышы белән чинап җибәреп, Миңнулланың колак төбенә тагын берне сугу белән генә чикләнде.

Аннары ярдәмчеләренең икесенә Миңнулланың аягын-кулын бәйләргә кушты, ә берсенә, арбада дер калтырап утырган Заһит абыйны күрсәтеп:

– Син әнә теге мәхлукның атын тугарып алып кил. Менә бу «яшь этәч»не, шуңа атландырып, Васкрисинскигә илтергә кирәк булыр, – диде. Һәм бик дустанә рәвештә Хәйрулла белән сөйләшә башлады.

Ләкин теге кеше (Миңнулланы үлемнән саклап калган агай) атны тугармыйча гына алып килде.

– Мин сиңа нәрсә дип әйттем? – диде Гата, тегеңә күзенең агы белән карап.

– Әллә җиккән килеш кенә аппарыйкмы дигәнием, Гатаулла. Арбасы белән сбруе да ару гына күренә бит.

– Дурак булсаң да, акыллы сүз әйттең бу юлы! – диде Гата, тегенең карары белән килешеп. – Әйе, шулай итү хәерлерәк булыр. Как раз тегеләрнең камандиры, берничә подвода алып кайта алмассызмы, дип калганые. – Аннары йөзенә мәет төсләре иңгән Заһит абыйга карады да: – Ә син нигә өнеңнән чыгып утырасың әле? Өегезгә кайтып, корал алып килергә дигән боерыкны ишеткәнсеңдер ич! Марш тизрәк өеңә! – диде.

– Мин бу авыл кешесе түгел, Гатаулла туган, – диде Заһит абый, усак яфрагыдай калтыранып.

– Кайсы авылныкы суң син?

– Усыныкы.

– Ә монда нишләп йөрисең?

«Миңнулла белән килгәнне әйтсәм, йә мине дә бәйләп салырлар да әллә ниләр сорап дупруслый башларлар» дип курыкты Заһит абый. Шуңа күрә:

– Сыерыбыз жугалганые, шуны эзләп йөрүемие, – дип алдашты.

– Латны, пунятны! Бар, эзлә инде алайса. Ә атың безгә кирәк, без алып торабыз. Исемең ни атлы синең?

– Заһит.

– Ә фамилияң?

– Зариф улы.

– Латны. Пунятны! Ә мин ат карагы Гата булам. Чегән Гата дип йөриләр мине. Ишеткәнең бармы?

– Ишетмиләрме суң инде, Гатаулла туган, бик күп ишеткәнем бар синең хакта. Әмма ләкин сине ярлы кешеләрнең атларына тими дип әйтәләрие ләбаса. Нигә дип мине шушы бердәнбер арык алашамнан мәхрүм итмәкче буласың?

– Белеп сукалыйсың син, Заһит кордаш. Дөрес, ярлы-ябагайны әбиҗәт итә торган гадәтем жугые минем. Ну бу юлы, бигайбә, синең атыңны алып торырга туры килә. Син бер дә хафаланма, атыңны, хаҗәте бетүгә, прәме үз өеңә китереп бирерләр.

– Юк инде, Гатаулла туган, шушындый мәхшәрдә, ата – улны, ана кызны белмәгән заманда, бердәнбер атымнан аерыла алмыйм инде мин! Теләсә ни әйт, әмма алашамны кая алып барсагыз – мин шунда барам. Эшегез беткәч, үзем алып кайтырмын.

– Син ул атны кая апкитәсен беләсеңме суң, туң ми? Хәрби часка апкитәбез бит без аны! Ә анда сугышка кертеп җибәрергә дә күп сорап тормаслар!

– Хет дөньяның аргы ягына җибәрсеннәр. Мин атымнан калмыйм! Атсыз ни эшлим мин, алты баламны ничек туйдырыйм? Җитмәсә тагын, хатын да инде елдан артык урын өстендә ята!

Гата, өметен өзеп, кулын селекте:

– Чукын инде алайса: раз яхшылыкның кадерен белмисең икән, бар! Ну миңа үпкәлисе булма соңыннан!

– Әй, Алланың рәхмәтле бәндәсе! – диде Заһит абый, үз алашасына өстәп тагын бер алаша биргәндәй куанып. – Сине безнең ише фәкыйрь-фокрага шәфкатьле дигәннәрие, тәки шулай икәнсең, Гатаулла!

– Ярый, артык күп сайрама. Кая, кил әле монда! – дип, Гата Заһит абыйны якасыннан эләктереп арбадан җиргә алып куйды. – Атыңның койрыгына алай бик каты береккәнсең икән, менә болай итәбез инде аны! – дип сөйләнә-сөйләнә, Заһит абыйның билендәге эзәрен чишеп алды һәм шул эзәре белән кулын каерып бәйләде. Аннары ансат кына итеп тегене яңадан арбасына күтәреп куйды. Ярдәмчеләре Миңнулланың да аягын-кулын бәйләп куйганнар иде, Гата аны да шул ук арбага сузып салып,

арбадагы йөк җебе белән үрәчәгә бәйләде. Аннары ярдәмчеләренең берсенә, әлегә шул Миңнулланы аттырмыйча калганына:

– Мә, тот дилбегәне дә атлатып кына Васкрисинскигә алып бара тор! Без озакламый артыгыздан куып җитәрбез. Килеп җитмәсәк, авылга үзең генә барып кермә, Бурсык чокыры турында көтеп тор, яме? – диде.

**3**

Миңнуллаларны илтүче агай башта әсирләргә бөтенләй игътибар итмичә, тик үзенә генә аңлаешлы көйгә борын эченнән ниндидер җыр мөгрәп барды. Аннары, кинәт тынып калып, Миңнуллага борылып утырды да:

– Син укымышлы кешегә охшагансың, әйт әле миңа, энекәш: нишли бу замана, кая таба бара? – дип сорап куйды.

– Ә синең, агай, аның кая таба баруын һаман төшенә алганың юкмыни әле?

– Һаман төшенә алганым юк шул әле!

– Алайса тыңла яхшылап: узган ел илдә революция булды. Менә синең белән безнең ише ярлы крестьян халкы һәм шәһәрләрдәге завод-фабрик эшчеләре үзара берләшеп, гомер-гомергә хезмәт халкын талап килгән патша һәм байлар хакимлеген туздырып ташлап, үзебезнең хакимлекне, эшче-крестьяннар хакимлеген урнаштырдылар. Аңлашылдымы?

– Надан дигәч тә, син мине бөтенләй үк башсызга санама, малай! – диде агай, шактый ачулы итеп. – Боларын мин аның синнән башка да беләм: үз күз алдымда булган хәлләр! Җүнле бәндә булсаң, син миңа менә хәзер дөньяда ниләр барганын аңлатып бир. Әтү, панимаеш!..

– Ә син ашыкма, абзый кеше, сабыр ит чак кына. Аннары менә болай булды: безнең Рәсәйдә дәүләт хакимлеге эшче-крестьяннар кулына күчкәч, чит ил буржуйлары... ә син буржуй дигән сүзнең мәгънәсен беләсеңме?.. Ярый, кызма, белсәң бик әйбәт! Әнә шул чит ил буржуйлары, үзләрендә дә революция килеп чыкмасын дип шыр җибәреп, барысы берләшеп, безнең яшь Совет дәүләте өстенә ябырылдылар. Ягъни безгә каршы сугыш ачтылар. Аларга революция көннәрендә чит илләргә чыгып сызган үзебезнең элеккеге байлар һәм буржуйлар килеп кушылды. Менә шулар хәзер совет властен юкка чыгарып, яңадан иске тәртипләрне, яңадан үз хакимиятләрен кайтарырга маташалар. Ә без, большевиклар, эшче-крестьяннар белән берлектә шул явыз көчләргә каршы көрәш алып барабыз! Йә, ничек, төшенеп барасыңмы?

– Болары аңлашыла. Үзем дә азрак чамалыйдырыем. Син миңа менә шул нәрсәне ачык кына итеп әйтеп бир: кайсылары җиңеп чыгар икән суң аларның? Акларммы, әллә сез – кызылларммы? Вәт бит нәрсәдә хикмәт!

– Ни атлы син, агай?

– Элек Нуретдин ие, ә Гата хәзер Ябалак дип йөри.

– Нигә?

– Минем күз төнлә дә шәп күрә, шуңа.

– Зыян юк. Анысы аның кушамат кына. Ә үзеңнең чын исемең әйбәт икән: диннең нуры дигән сүз.

– Йә, ярый, син мәсьәләне читкә алып китмә: кайсылары өстен булып чыгар икән бу аклар белән кызылларның?

– Син үзең ничек уйлыйсың соң, Нуретдин абзый?

– Ничек дип уйларга да аптыраган инде. Сезнең ише сәвит яклылары килә дә, безгә иярегез, безнең эшебез хак, без җиңәбез, диләр. Сәвиткә каршылары әйтә, без генә дөрес юлдан барабыз, безгә иярегез, безнең белән барсагыз гына игелек күрерсез, ди. Бер караганда, сезнеке хаклыдыр шикелле, икенче карасаң, тегеләрнеке дә дөрес булып чыгар сыман. Ә пука тегеләре дә, болары да крәстиян хисабыннан, аны талап көн күреп килә әле. Ахыры ни белән бетәр – анысын бер Алла гына белә торгандыр.

– Бер ул гына түгел, без кызыллар җиңеп чыгачагын меңләгән, миллионлаган кешеләр белә, Нуретдин абзый. Шулай буласына чын күңелләреннән ышаналар! Һәм шул җиңү көнен якынайту өчен көрәшәләр! Синең шикелле әүле-тәүле булып, бүген кем көчлерәк булса, шуның җырын җырлап йөрүче кыйбласыз адәмнәр дә бар барын. Әмма, бәхеткә каршы, андый аумакайлар күп түгел.

– Син, давай, мине алай кыйбласызлар чутына тыкма, парин! Пука мин берегезнең җырын да җырламыйм әле. Иманым шаһит, шушы көнгәчә нә сезгә, нә тегеләргә кушылганым юк!

– Ничек алай була инде ул? Гата җырын җырлап йөрисең бит син!

– Тучны! Әйе, Гата белән йөрим. Ну бит Гата шулай ук берегез яклы да түгел! «Карап карыйк, кайсылары өстен чыгар, шуннан ары кай якка кушылырга икәнен күз күрер, – ди ул. – Ә хәзер ничу безгә алар белән буталып йөрергә. Без үз кәсебебезне белик тә иплән кенә, дөньяда яшәүнең кадерен белеп кенә яши бирик, – ди. – Кеше үтермибез, кан коймыйбыз, ярлы крәстиян малына кагылмыйбыз. Байларныкын урлап кына көн күрәбез ич», – ди.

Миңнулла тегеңә ни дип җавап бирергә белмичә аптырап калды. Гатаны һәм аңа ияреп йөрүче менә шушы Нуретдин агайны ул гап-гади ат караклары гына дип уйлый иде. Ә аларның әнә үз фәлсәфәләре, дөнья хәлләренә үз карашлары бар икән ләбаса! Үзләрен юлбасарлар итеп түгел, гадел, әйбәт кешеләргә саный икән бит алар!..

– Караклык теләсә кайчан караклык булып кала инде, Нуретдин абзый! – диде Миңнулла, шуннан да шәбрәк җавап таба алмыйча.

Болай да тын алырга куркып, бер авыз сүз дәшмичә килгән Заһит абый, Миңнулла тегеңә әнә шулай дип әйткәч, бөтенләй елар чиккә җитеп:

– Җитеп торыр мәллә инде сиңа, олан! – диде.

Ләкин аның бу кисәтүе Нуретдин агайга ошамады:

– Тик кенә тор, надан! Үз акылың юк икән, ичмаса, акыллы кешеләрнең сүзен тыңлый бел! – Аннары, Миңнуллага мөрәҗәгать итеп: – Алай дип карасак, сезнең сәвит блачыгыз да шулай ук карак булып чыга түгелме суң, парин? – диде.

– Ничек алай булып чыга икән ул, Нуретдин абзый, аңлатып бирә алмассыңмы?

– Ничекме? Ә менә ничек: сез талап кына калмадыгыз, байларның үзләрен дә Себергә сөрдегез ләбаса! Хәлбуки без байларның үзләренә беркайчан да кагылмадык. И һәм кагылмабыз да! Артык малларын гына урлыйбыз без аларның.

– Син, Нуретдин абзый, кармак белән бармакны бутама! Беренчедән, без революцияне сезнең кебек төнлә, кача-поса түгел, бәлки көпә-көндез, ачыктан-ачык ясадык. Бөтен ярлы халык белән бергәләп ясадык. Икенчедән, байлардан тартып алынган җирләрне шул җирләрне эшкәртеп иген игә торган кешеләргә – крестьяннарга бүлеп бирдек. Завод-фабрикаларны бөтен халык милкенә, дәүләт милкенә әйләндердек.

– Ә без урлаган ул малларны кая куя дип беләсең син? Без дә аларны шул ук крәстиянгә сатабыз лабаса!

– Менә шулай шул – сатасыз!

– Суң бөтенләй үк бушка биреп булмый бит инде! Безнең дә тамак бар, безнең дә хатыннар, бала-чагалар бар, аларны туйдырырга кирәктер бит!

– Юк, Нуретдин абзый, юлбасарлык дигән нәрсә, кай ягыннан гына килеп карасаң да, юлбасарлык булып кала инде ул. Юньле юлда йөрмисең син. Ул Чегән Гатага ияреп, менә шушылай аның уң кулы булып йөрүеңне алга таба дәвам иттерсәң, башың харап булачак синең!

Миңнулла кыек атып туры тидерде булса кирәк, Нуретдин агай исе китеп аңа карап куйды:

– Ә кем әйтте әле сиңа мин аның уң кулы дип?

– Әйтмичә дә бик әйбәт күренеп тора!

– Кит аннан?

– Бер дә китәсе юк, дөресе шулай!

– Һы, һы-һы!..

Нуретдин абзый әнә шулай дип куйды да, тынып калып, нидер уйланып бара башлады.

– Карале, Нуретдин агай, муендагы бауны аз гына бушат әле, бөтенләй сулыш алыр хәл калмады бит монда, – диде Миңнулла, аның уен бүлеп.

– Шулаймыни? Хәзер рәтлибез аны! – дип, Нуретдин абзый Миңнулланың муенындагы бауны бөтенләй чишеп үк алды. Аннары арба төбендәге печәнне җыеп, егетнең баш астына мендәр итеп куйды да: – Ничә яшьтә син, энем? – дип сорады.

– Быел унсигез тула.

– Икмәктер, диген.

– Икмәктер, шулай!

– Ә мин сиңа егерме бишләр тирәсе бардыр инде дип торадырыем.

– Шулай бик олы күренәммени?

– Шулай олы күренәсең шул, наный. Хәер, яшь кенә башыңнан өяз тикле өяздә эшләп йөргәч, шулай булмый хәлең дә булмас. Ә син миңа ничәләр бардыр дип уйлыйсың?

– Илле бишләрдән дә ким түгелдер инде.

– Һи-һи-һи! Кырык икене дә тутырып җиткерә алганы юк бу абзаңның! Угрылык белән көн итү кешене еллап кына түгел, сәгатьләп картайта икән ул, олан! Әле моннан бер ел элек кенә янып торган егет ием мин. Ә хәзер әнә син миңа илле бишне бирдең.

– Семьяң, бала-чагаларың бармы, Нуретдин абзый?

– Шушы яшькә җитеп аларсыз буламы суң. Ике кыз, бер малай атасы инде мин. – Бераз уйланып барды да тирән итеп көрсенеп дәвам итте: – Алтынчы ай китте үзләрен күргән юкка. Кешеләрдән сораштыргалап торам, болай исән-саулар үзләре. Акчага да интектермим. Таныш-белеш аркылы җибәреп киләм. Ну менә үзләрен күрә алмыйм.

– Кайда соң алар?

– Барда ягында.

– Ә нигә кайтып күреп килмисең?

– Һы, ансат кына сиңа. Бар, кайтып күренеп кенә кара, хәзер тотып трибуналга озаталар да расхутка чыгаралар мине анда! Фрунттан качкан кеше бит мин.

– Патша армиясеннән качкансыңдыр бит?

– Патша армиясеннән качкан булсам, уйлап та тормасыем мин!

– Шулай-мы-нииии? Үзебезнең армиядән качкан дезертирмыни әле син?

– Шулайрак булганые шул.

– Ник качкан идең соң?

– Япь-яшь кенә көенчә үлеп каласы килмәде.

– Бу кәсебең дә сугыштагы шикелле үк куркыныч бит синең. Монысына йөрәгең җиткән, ә?

– Ничек итеп булса да көн күрергә кирәк бит инде. Бүтән барыр җирең калмагач, шулай тәвәккәллисең икән аны.

– Алга таба ничек көн итәргә исәбең?

– Ул хакта уйлаган юк әле, бүгенгесе кыйбат.

– Уйланырга кирәк, Нуретдин абзый. Хәзер, дөньяның буталчык чагында гына болай иркен йөрисез сез. Акларны җиңеп илдә тәртип урнаштыргач, көн бетәчәк сезгә!

– Анысы шулаен шулай да бит, ну, ни эшлим? Ул көнгә калмас өчен кая барырга, ни кылырга кушасың син миңа?

– Хәзер безнең аяк-кулларны чиш тә, әйдә, китик бергәләп. Котыл шул Гата шайкасыннан.

– Хуш. Шуннан син мине кая аппармак буласың?

– Усыга.

– Һы, ансат кына икән! Анда мине рифкумга тапшырып, трибуналга озаттырасың киләмени?

– Ревкомга баруын барырбыз. Тик син трибуналдан курыкма. Трибуналга җибәрмәсләр. Мин барысын аңлатып бирермен дә, хәлеңә керерләр. Аннары йә фронтка озатырлар, яки Усының үзендә кызыл отрядчы итеп калдырырбыз.

– Карап-карап торам да, бик белгән атлы булып, «мин» дә «без» дип кенә сөйләнәсең син, малай актыгы! Кем суң син, берәр төрле нәчәнник мәллә анда?

– Өяз башкарма комитеты председателе урынбасары мин.

– Ышанмыйм!

Миңнулла Заһит абыйны күрсәтте:

– Менә бу агай каслый ала!

Нуретдин агай әле һаман куркуы бетмәгән Заһит абыйга борылды:

– Йә, нишлим, ышаныйммы мин бу малайга, кордаш? Чыннан да өяз кәмитетендә эшлиме ул?

– Мин аның кайда эшләгәнен дә, кем икәнен дә белмим – беренче күрүем бүген!

– Менә ишеттеңме инде! – диде Нуретдин агай, Миңнулланың «ялганын тотканга» кәефе килеп.

Заһит абыйның җавабына Миңнулла шаккатты. Ләкин аның белән бәхәскә кереп тормады. «Шулай әйтүне кирәк тапкандыр. Болай да минем аркада нужаланып йөри бит, бичара» – дип фикер йөртте ул. Һәм тирә-якны тыныч кына күзәтеп бара башлады.

Сулда – юл буенда ук шактый текә тау. Тау бите – урманлык. Ләкин агачлары куе түгел. Аланлыклары күбрәк. Ә аланлыклар тап-такыр: печәннәре чабып алынган. Аннары көтү дә йөргән булса кирәк: сыер «коймаклары» бик еш күренә. Бу таудан кыш көне чаңгы шуарга бик шәптер. Миңнуллаларның үз авыллары тирәсе тип-тигез, рәхәтләнеп чана-чаңгы шуарлык бер генә тау да юк. Шуңа, тау күргән саен, күңеле җилкенеп куя аның!.. Ә уң якта – бодай кыры. Урыны-урыны белән бәбкәләр дә күренә. Ура башлаган булганнар. Ләкин хәзер кырда бер адәм заты юк. Воскресенск җирләре инде бу. Воскресенск халкының да кайгысы уракта түгел булса кирәк. Хәер, нинди урак кайгысы булсын ди: Чегән Гата әнә Барсай ир-атларын да Воскресенскига куып калды бит әле анда. Тикмәгә йөрми торгандыр инде. Тукта, бәлки, бу агай да белә торгандыр андагы хәлләрне.

– Нуретдин абзый, тагын шул Гата хакында сорыйм әле: Барсай мужикларын нигә Воскресенскига апкилмәкче ул?

– Нәрсә дидең әле син, малай?

Нindидер үз уена чумып бара торган Нуретдин абзый Миңнулланың соравын абайламыйчарак калган иде. Миңнулла соравын кабатларга мәҗбүр булды.

– Ә-ә-ә-ә, син аны әйтәсең икән! – диде теге, ниһаять, уйларыннан аерылып. – Васкрисинскидә акларның бер звуд солдаты килеп урнашкан бугай. Әмма ләкин звуд командиры кызыллардан шикләнә икән. Ни өчен дисәң, бу тирәләрдә нindидер Колчин дигән бер кеше зур гына кызыл этрәт оештырган, ди. Көтмәгәндә килеп чыгып, шуның этрәте акларга күп зыян китереп тора икән. Бүгендә таңында ул этрәт Васкрисинскигә дә һөҗүм итүе ихтимал, имеш. Шул этрәткә каршы тору өчен тегеләр күрше авыллардан ир-атларны җыйнарга булганнар бугай. Тәгаене шулайдырмы – кырт кистереп кенә әйтә алмыйм. Ни өчен дисәң, тегеләрнең камандиры Гатаулла белән сөйләшкәнен мин читтән генә тыңлап тордым. Ну ишетелгән сүзләреннән әнә шул сиңа әйткәнчәрәк аңладым.

– Син русча язу танышсыңмы, Нуретдин абзый?

– Китапча хәрефе белән язылганны гына аз-маз браматлыйм, әмма кулдан язылганны – булмый!

– Алайса, менә минем күкрәк кесәсендәге язуны ал әле!.. Инде шуның китап хәрефләре белән язылган җирен укып кара!

Нуретдин абзый барган уңайга гына укый башламакчы иде, арба дыңгырдаганга хәрефләр сикерә башлагач, атны туктатып торырга мәҗбүр булды.

– Тәк! – диде ул, Миңнуллага Усы өяз башкарма комитеты тарафыннан бирелгән белешмәне шактый зур азап белән укып чыккач. – Карале, син, малай актыгы, чынлап та өяздә зур урында эшлисең, ахры, ә?

– Әйттем бит инде мин сиңа, өяз башкарма комитеты председателе урынбасары, дип!

– Мине коткарып кала алам дип ихлас әйтәсеңме син, наный? Чынлап та мине трибуналдан саклап калырлык кодрәтең бармы?

– Сине алдап ни файда миңа? Әйдә, бор атны читкә дә, Гата килеп җиткәләгәнче, китик кереп урман эченә!

– Адашмабызмы суң? Усыга исән-имин генә барып җитә алырбызмы?

– Курыкма, күземне бәйләсәләр дә, адашмыйм мин бу тирәләрдә.

– Ярый, энекәш, Аллага тапшырып тәвәккәлләдек алайса. Гата Чегән әйтмешли, беткән баш беткән, муен калса, җиткән, әйдәле, алаша! Әнә как раз тауның да сөзәгрәк җиренә җиткән икәнбез...

Урманга борылып, алар инде берәр җир буе чамасы китәргә дә өлгергәннәр иде. Ләкин шуннан артыгын булдыра алмадылар. Башта ату тавышы ишетелде, аннары әлеге ике ярдәмчесе белән Гата үзе куып җитте.

– Кая олагыргае ниятең, Ябалак?! – диде ул, Нуретдин абзыйга бик хәтәр җикеренеп.

– Мин килеп җитмәсәм, көтеп тор, дип үзең әйткәннең түгелме суң, Гатаулла? – диде тегесе, бер дә аптырап тормыйча. – Кеше-кара күз алдында торганчы, ышыккарак кереп көтеп тору хәерлерәк булыр дигәнием.

– Шулай дисәң генә инде, – диде Гата, шундук йомшый төшеп. Аннары Миңнуллага ымлады: – Бу денен саткан нәмәрсә ничек, тыпырчынмыймы?

– Кая анда тыпырчыну! Син аның муенын шундый итеп кысып бәйләгән – җан тәслим кыла язды, бичара. Бавын чишеп, баш астына печән салып кына коткарып калдым үзен.

– Яраган. Әйбәт иткәнсең анысын. Безгә аны тере килеш илтеп тапшырырга кирәк, әҗерен зуррак итеп бирерләр.

– Карале, Гатаулла, сорарга да онытып торам икән: син бит Барсайдан халык җыйнап апкилмәк булып калганыең, кая суң ул халык?

– Аналарын сатасы бар ул Барсай мужикларының! – диде Гата, әрем капкандай чыраен сытып. – Шул җыелып торган чакларында барысын сөреп кенә алып киләсе калган икән аны! Таралдылар да, ярыкка кереп качкан тараканнар шикелле, юкка чыктылар. Ник берсе әйләнеп килсен, ичмаса! Ну, ничава, анда Сәйфи бай малае Шакир унлап солдат ияртеп кайткан, ди. Мин анда әлеге Чирканды мулласы малае Хәйруллага шул Шакир янына барып, Воскрисинскидәге хәлне аңлатып бирергә әйтеп калдырдым. Бик отчайный нәрсә ул Шакир дигәннәре. Бәлки, ул берәр әмәлен табар әле.

**4**

Воскресенск урамы халык белән шыгрым тулы иде. Солдатлар дә күп, гражданскийлар тагын да күбрәк. Русы, татары, ире-хатыны, хәтта бала-чагаларына тикле шунда кайнаша. Әйтерсең кырмыска оясын кемдер туздырган да шуның кырмыскалары өскә чыккан! Воскресенскиның үзендә генә бу тикле кеше булырга тиеш түгел иде. Мөгаен, бүтән авыллардан да килгәннәрдер. Солдатларның барысы да диярлек сугыш мылтыгы аскан. Ә гражданскийларның кораллары бик чуар: ау мылтыгыннан башлап, кылыч, сөңге, сәнәк, багор һәм гап-гади күсәк тотканнарына кадәр бар. «Ак бандитларга ияргән фетнәчеләр икән инде болар, – дип уйлап куйды Миңнулла. – Әгәр Гата атларны туктата калса, мөгаен, шушында безнең башка җитә инде бу тилергән халык!»

Ләкин Гата урамда тукталып тормады. Туктатырга теләп, ат башыннан тотарга үрелә башлаган кешеләргә дә:

– А ну-ка, брысь! – дип, тегеләрне атының күкрәге белән читкә кактырып, юл ярып барды.

Миңнуллаларны чиркәү каршындагы ике катлы өй каршына китереп туктаттылар. Шундук атыннан сикереп төшеп, Гата өйгә кереп китте. Ә Нуретдин абзый Миңнуллага борылып карады да, Гатаның җайдаклары ишетмәсен өчен, акрын гына:

– Ярар, наный, Аллага тапшырдык инде. Без дигәнчә барып чыкмады шул! – диде.

– Алданрак тәвәккәлли алмадың бит!

– Документыңны баштарак күрсәтмәдең ич.

Дүрт солдат ияртеп, өйдән бер офицер чыкты. Ул иң элек, каршына ук килеп, күзенә керердәй булып, Миңнуллага, аннары Заһит абыйга текәлеп карап торды да:

– С прибытием вас, голубчики! – дип мыскыллап көлеп куйды. Аннары солдатларына ишарә итте: – А ну-с, принимайтека-с как следует!

Тегеләрнең икесе – Миңнулланы, икесе Заһит абыйны арбадан алып аттылар да, кул-аякларын чишеп, типкәли-типкәли ихатага алып кереп, караңгы таш сарайга яптылар.

Солдатлар төртеп җибәргәндә таш стенага бәрелеп, Миңнулланың яңагы сыдырылган да кан ага башлаган иде. Тиз генә кулъяулыгын алып, шул сыдырылган төшенә басты. Ә Заһит абыйга тагын да катырак эләккән булса кирәк, бик нык ыңгырашып, ул һаман идәндә ята иде. Миңнулла аның янына килеп чүгәләде:

– Хәлең ничек, Заһит абый?

– Миңнулла-а-а, синме? – диде Заһит абый, ыңгырашуын дәвам итеп.

– Мин, Заһит абый. Хәлең ничек, дим?

– Ни ачуың бар иде миндә? Нигә дип үтерергә алып чыктың мине, ә?

– Болай буласын белсәм, сине алып чыгу түгел, үзем дә Барсай ягына аяк атламаган булыр идем дә бит, нишлим соң, белмәдем, Заһит абый!

– Әйтмәдеммени мин сиңа, әллә сабыр итеп торыйкмы, дип?

– Хәзер үкенүдән файда юк, буласы эш булган инде. Нигә бик ыңгырашасың, әллә берәр җиреңне сындырдылар укмы?

– Тән авыртканга түгел, җан авыртканга сыкранам! Тотып атсалар, хатын нишли инде анда минем? Балалар нишләр?

Бу бандитлар кулына бер килеп капкач, исән котылуларына ышанычы бик аз булса да, Миңнулла аны юатырга тырышты:

– Кайгырма, Заһит абый! Менә күрерсең, тикшерерләр-сорашырлар да бүген үк кайтарып җибәрерләр әле. Мине тоткарласалар да, сине җибәрерләр. Синең белән нишләсен алар?

Заһит агай яткан җиреннән торып ук утырды. Өмет тулы карашын Миңнуллага төбәде:

– Чынлап та исән калырбыз дисеңме, олан?

– Ул хакта шикләнмә дә, Заһит абый! Бая Нуретдин абзый әйткәнен ишеттең ич: безнекеләр шушы Воскресенскига таба килә, диде бит ул. Бәлки, бүген төнлә үк килеп җитеп коткарырлар әле!

– Рәхмәт, туган, яхшы сүзеңә! Фәрештәнең амин дигән сәгатьләренә туры килә күрсение инде берүк! Шушы тоткыннан исән-имин котыла алсам, Корбан бәйрәмендә танамны суеп, бөтен авыл халкын корбан ашына дәшәрием, Аллаһы бирса! Колһуаллаһы әхәде-аллаһы сама-а-ады, ямиәлиде...

Емельян Петрович Миңнуллага, ярлылар комитетларына ярдәм итәргә кирәк булуы мөмкин дип, шактый зур сумма акча бирдертеп җибәргән иде. Ул акчаларны Миңнулла, хәвефсезрәк булсын дип, аякчуына урап, итек кунычына тыккан иде. Заһит абый җаны-тәне белән бирелеп әлеге «Колһуаллаһы»ны укый башлагач, Миңнулла әнә шул акчаларны хәтерләде һәм: «Боларны моннан барыбер табып алачаклар. Бандитлар кулына эләккәнче, ичмасам, шушында ятсыннар», – дип, ул акчаларны сарайның стена ташлары арасына кыстырып куйды.

Тәрәзәсе берәү генә, ул да кечкенә булганлыктан, сарай эче ярым караңгы иде. Шуның өстенә Заһит абый мөкиббән китеп укынып утыргач, Миңнулла аны берни сизми калды дип уйлаган иде. Ләкин агаебыз алай ук гамьсез булмаган, Миңнуллага күз салып торган икән. Догаларын укып, теләкләрен теләп бетергәннән ары, Миңнулла утырган улак буена килде дә:

– Нәрсә кыстырдың син анда, олан? Акчамы? – диде. Һәм Миңнулланың җавап биргәнен дә көтмичә: – Мә, минекен дә кыстыр шунда үзеңнеке янына, теге кяферләр кулына калып әрәм булмасын! – дип, өч тәңкәлек акча сузды.

Бу заман өчен өч тәңкә акча чүп кенә иде, әлбәттә. Ләкин Миңнулла ул хакта сүз озайтып тормады.

– Бик дөрес әйтәсең, Заһит абый! Монда булса, беркая да китмәс алар. Шайтаннан яралган шушы акларны җиңгәч, минекен дә, үзеңнекен дә килеп алырсың, ярыймы! – дип, тегенең өчлеген дә үзенең акчалары янына кыстырып куйды.

Кеше ишетеп тормыймы дигән сыман итеп, Заһит абый башта як-ягына каранып алды, аннары Миңнулланың колагына пышылдады:

– Синеке ничә тәңкә соң, олан?

«Кара инде син бу адәм баласын, үлем бусагасында басып торганда да һаман акча белән кызыксына бит!» – дип, күңеленнән бик нык гаҗәпләнсә дә, Заһит абыйга бу уйларын сиздермәскә, тегенең гайрәтен чигермәскә булды Миңнулла.

– Җитәрлек, Заһит абый. Синеке шикелле ике ат алырлык бар!

Заһит абыйның күзләре шундый ялтырап куйды – сарай эчләре яктырып киткәндәй булды.

– Чыннан әйтәсеңме син моны? И шул акчаны миңа бирмәк буласыңмы?!

– Мин беркайчан да яхшы кешеләргә ялган сүз сөйләмим, Заһит абый!

– Әй, рәхмәтле җан! Бар бит, агай, Ходайның изге бәндәләре! Рәхмәт, Миңнулла, мең яшә, олан!

– Әйт әле, Заһит абый: бая теге безне монда алып килгән Нуретдин агайга нигә мине белмим дидең? Әгәр син шул чакта дөресен әйтеп, минем сүзне раслаган булсаң, без хәзер менә бу таш сарайда ятасы кешеләр түгел идек. Иректә буласы идек без хәзер.

– Әй, наный, искә төшермә, ичмаса, шул ахмаклыкны! Ник алдаштыммы? Надан булганга, баш җитмәгәнгә инде! Теге адәм барыбер безнең белән качып китәргә риза булмый, янәсе. Ә минем синең белән бергә йөри торган кеше икәнемне белсәләр, мине дә тотып ябулары ихтимал. Ә белмәдем-күрмәдем дип барсам, атымны биреп торган өчен рәхмәт әйтәләр дә кайтарып җибәрәләр, имеш. Ну тинтәк тә булган инде үзем дә! Ә алар, кем син, нишләп йөрисең, дип сорап та тормадылар, арт якка дыңк иттереп тибеп, яптылар да куйдылар. Һей, болай буласын белгән булсам! Алдашып торган булырыеммы, җүләр!..

– Ашыкма, сорарлар әле, Заһит абый. Җиде бабаңнан алып җиде әбиеңә тикле сорашырлар. Син инде шул сүзеңнән кайтма, ничек кенә талкысалар да, син мине белмисең дә моңа кадәр күргәнең дә булмаган.

– Шулай итимме, әллә сине белүемне, синең олаучың булып килгәнемне әйтеп, дөресен сөйләп бирим микән, наный? Ни өчен дисәң, карга карганың күзен чукымый, мужыт, тегеләрнең нәчәнниге синең дә нәчәнник икәнеңне белгәч, хәлеңә керер дә тоткынлыктан азат итеп кайтарып җибәрер. Менә шул чакта, синең аркада, мужыт, мин дә котылырмын дип әйтүем инде бу.

– Юк, Заһит абый, бу очракта алай булуы мөмкин түгел. Икебез дә карга булсак, әлбәттә, ул мине чукымас иде. Ләкин мин карга түгел, мин бөркет бит. Син дә бөркет. Тоткында булсак та, икебез дә бөркет без синең белән. Ә ул – карга. Һәм ул карга без бөркетләрне беркайчан аңлый алмаячак. Шулай булгач, сиңа мине белмим дип барудан хәерлесе булмас. Югыйсә...

Тышкы якта, ишек тирәсендә, ачкычлар чылтыраганы ишетелде.

– Кемдер керә, ахрысы, тагын безне кыйнарга микән? – диде Заһит абый. Һәм, качып котылырга теләгәндәй, сарайның караңгы почмагына сыенды.

Ишек авызында кулына мылтык тоткан, табак битле, курнос борынлы, бая Миңнулланың яңагын ерттырган солдат пәйда булды. Аның мичкәдән чыккандай калын, котсыз тавышы яңгырады:

– А ну, красные татары, вылазь!

Әсирләрне өйнең бер бүлмәсенә алып керделәр. Нечкә кара мыеклы, чандыр гәүдәле, күкрәгенә Георгий тәресе таккан офицер кукраеп өстәл янында утырган килеш кенә Миңнулладан сорау ала башлады. Исем-фамилиясен сорады. Миңнулла әйткәч, өстәлендә яткан кәгазьгә карап алды. Күрәсең, Миңнулланы белә торган берәр кешедән сорашып, язып куйган булгандыр да, алдашмый микән дип, хәзер тикшереп каравыдыр.

– Туган елың? – диде аннары офицер.

– Тугыз йөзенче.

Офицер иңбашларын сикертеп куйды:

– Мин шаярганны яратмыйм, Гайсин.

– Ә минем шаярырга җыенганым да юк. Нигә алай шиккә калдыгыз әле?

– Бик яшь икәнсең бит.

– Хикмәт яшьтә түгел, баштa!

– Кара син нинди кыю икәнсең! Туган урының?

– Усы өязенең Карый авылы.

Ул тагын кәгазенә күз салып алды.

– Так! Хәзер кайда һәм кем булып эшлисең?

– Усыда. Өяз башкарма комитеты председателе урынбасары.

Офицер янә теге кәгазенә күз төшереп алды һәм аның чырае яктырып китте – мөгаен, үзендәге мәгълүматлар белән Миңнулла биргән җаваплар туры килә иде булса кирәк. Ләкин офицер үзенең канәгатьлеген сиздерергә теләмәде, тагын элеккечә бик җитди булырга тырышып, сорау алуын дәвам итте:

– Барсайга ни өчен килгән идең?

– Эш белән.

– Мин дә уйнап йөрүең булгандыр дип уйламыйм. Нинди эш белән, дип сорыйм мин синнән?!

– Кызлар күзләп кайтырга иде исәп.

– Димәк, әйтергә теләмисең? Яхшы. Соңыннан әйтерсең. Безнең түземлек җитәрлек, көтеп тә тора алырбыз.

Аннары ишек төбендә торган сакчыга боерды:

– Тегеләрне алып кер әле, Мирон.

Барысын да ишетеп, көтеп үк торганнар иде, ахры, сакчы ишекне ачып дәшүгә, Гата белән Хәйрулла кереп җиттеләр.

Офицер, бармак изәп, Гатаны үзенә якынрак китерде дә Миңнулладан сорады:

– Таныйсыңмы бу кешене, Гайсин?

– Бер-ике тапкыр күргәнем бар.
– Кем ул?
– Ат карагы Гата. Кушаматы – Чегән.
– Нигә атып үтерә яздың син аны?
– Кызганычка каршы, язып кына калдым шул, үтереп булмады.
«Ишеттеңме?» дигәнне аңлатып, офицер Гатага карап алды. Гата ачуыннан «и-их!» дип акырып җибәрде дә Миңнуллага ташланмакчы иде, ләкин офицер, сикереп кубып, «стоп, не горячись!» дигәч, тыелып калырга мәҗбүр булды.
Аннары офицер Миңнулланың каршысына ук килеп басты да:
– Ә син ошыйсың миңа, разбойник! – диде.
– Разбойниктан ишетәм!
– Булды, Гайсин, әйдә, җитди сөйләшүгә күчик. Карый отрядында бүгенге көндә ничә кызылгвардиячегез бар?
– Өч йөзгә якын.
– Төгәлрәк итеп әйтә алмыйсыңмы?
– Ике йөз илле тугыз.
– Кораллары нинди һәм күпме?
– Барысында да сугыш мылтыгы. Биш пулеметлары бар.
Офицерның күзләре шар булды:
– Каян килгән аларга ул пулеметлар?
– Дутов гаскәреннән качкан пулеметчылар алып кайткан.
– Ялганлыйсың бит, кызыл эт!
– Минем этнең кызылын очратканым юк әле, ә ак этләр тулып ята!
– Молчать! Телеңне артык озайта башласаң, маңгаеңа пуля җибәрергә дә күп алмам мин!
– Җибәреп кенә карагыз. Мине атсагыз, сезне безнекеләр ике көн дә яшәтмәячәк!
– Ә кемнәр соң ул «без-не-ке-ләр»? Кайда алар?!
– Адым саен. Тик алар, сез аклар шикелле, бугаз киереп, шаулап йөрми, эш эшлиләр!
– Минем нервлар нык, Гайсин! – диде офицер, тешләрен кысып. – Ну, кара аны, һәрнәрсәнең бер чиге була, шул чиккә китереп җиткермә мине! Әйт әле, соңгы мәртәбә Ашапта кайчан булдың?
– Өченчекөн.
– Анда ник барган идең?
– Ашап отрядына өяздән корал илттек.
– Күпме һәм нинди кораллар?
– Ике йөз утыз бер сугыш мылтыгы, сигез йөз «кыяр»*, өч пулемет.
– Ашап отрядында ничә кеше?
– Дүрт йөз җитмеш өч. Барысында да ау, сугыш мылтыгы. Өч пулеметлары бар. Шуның өстенә бер рота солдат та килергә тиеш иде. Ихтимал, инде килеп тә җиткәннәрдер.
Офицер, пошаманга калып, ишекле-түрле йөренгәләп алды. Аннары, Гатага мөрәҗәгать итеп:
– Ишетәсеңме, Чегән? – диде. – Ничек уйлыйсың, ышанырга буламы моңа?
Бая Миңнуллага ыргылганда үзен тоткарлаганы өчен офицерга бик нык хәтере калган иде Гатаның. Шуңа тегеңә теләр-теләмәс кенә җавап бирде:
– Мин берни дә әйтә алмыйм: бу арада ул тирәләрдә булганым юк.
– Мин синнән Ашапта кайчан булдың дип түгел, әсир әйткән сүзләргә ышаныргамы дип сорыйм!
– Анысы инде үз ихтыярыгыз, гаспадин афитсир. Ә мин үзем күрмәгән, үзем белмәгән нәрсә хакында берни дә әйтә алмыйм.
– Яхшы. Алайса күреп-белеп кайтырга кирәк булыр. Бар, хәзер үк чарасына кереш. Иртәгә, иртәнге сигездән дә соңга калмыйча, Ашап отряды турында төгәл мәгълүматлар әзер булсын!
– Ә күпме түлисең?
– Курыкма, ким-хур итмәм. Бар, юлыңда бул!
«Менә ул нинди икән! – дип уйлап калды Миңнулла. – Ат карагы гына түгел, шымчылык белән дә шөгыльләнә икән бит бу адәм актыгы!»
Гата чыгып киткәч, моңарчы акыллы песи генә булып утырган җиреннән калкынып, Хәйрулла да:
– Олег Васильевич, можно мне кое-что уточнить? – дип, телгә килә башлаган иде, ләкин тегесе аңа тик торырга ишарә ясады. Тере мәет булып бер читкә поскан Заһит абый каршына килеп басты да:
– Әйдә, мужик, инде синең белән гәпләшеп алыйк! – диде.
– Мин урычча белмим шул, знакум, – диде теге бичара, бер Миңнуллага, бер офицерга тилмереп карап.
– Он, Олег Васильевич, говорит, что по-русски не понимает, – диде Хәйрулла, куштанланырга ашыгып.
– Ну вот и переведите ему мои слова.

Хәйрулла әсәрләнеп торып ук басты һәм, Заһит абыйның борын төбенә килеп:

– Сөйләшеп алыйк, ди ул синңа! – диде.

– Ә-ә-ә! Шулай димени? Сөйләшергә булыр анысы, нигә булмасын ди.

– Он говорит, что готов с вами беседовать...

– Спроси у него: откуда он, кто и что может сказать по поводу красных отрядов.

Ләкин Заһит агаебыз офицер теләгән әңгәмәче булып чыкмады. Исем-фамилиясен һәм югалган сыерын эзләп йөрүен генә әйтте дә тегенең барлык сорауларына да «белмим» дип кенә барды. Заһит абыйны кара тиргә батырганчы тинтерәтеп тә бернинди юньле мәгълүмат ала алмагач, офицер Хәйруллага:

– Ташла, барыбер рәт чыгачак түгел бу ахмактан! – дип кул селекте. Ләкин шултикле тырышуының аз гына булса да әҗерен алып каласы килде булса кирәк: – Дурак! – дип, йодрыгы белән Заһит абыйның күкрәгенә төртте.

Заһит абый, бичара, «гыңк» итеп артка мәтәлде һәм шул чакта аның башындагы бүреге белән түбәтәе төшеп китте. Түбәтәй кызыл эчле иде. Шуны күреп алгач, офицер күркә шикелле кызарып-кабарып чыкты:

– Ах, менә ничек! Татар кызылгвардиячесе икәнсең бит син, идиот! – Шулай диде дә түбәтәен алырга дип иелгән Заһит абыйны тибеп екты. Заманында бик шәп булган, әмма хәзер беләүләнеп беткән кызыл сатин эчле түбәтәйне офицер үзе иелеп алды. – Кара син аны, нинди пароль уйлап чыгарганнар! Карале син аны... – дип сөйләнә-сөйләнә, түбәтәйне әйләндергәләп карады да өстәленә куеп, Миңнулла янына килде: – Ну-ка, синеке дә шундыймы? – дип, аның да башындагы күн фуражкасын салдырып карамакчы иде. Миңнулла ирек бирмәде. Фуражкасын үзе салды да ачу белән:

– Мә, кара! – дип, тегеңә сузды. Офицер фуражка эченнән Миңнулланың булмаган түбәтәен эзли башлады, ә Миңнулла сүзен дәвам итте: – Унбиш ел элек тегелгән инде ул агайның түбәтәе. Һәм аның кызылгвардиячеләргә бернинди мөнәсәбәте дә юк!

Ләкин офицер аның ул сүзләрен ишетмәгәнгә салышты. Түбәтәе булмаганга җене чыгып, Миңнулланың фуражкасын ертып ук ыргытты. Аннары ишек төбендә торган сакчыга әсирләрнең кесәләрендәге әйберләрен алырга боерды.

Заһит абыйның кесәсеннән ипи валчыгы да чыкмады. Миңнулланың Зәйнәпкә бүләк итәргә дип әзерләп куйган алтын йөзеген, Барсайда үзен күрергә туры килмәсә, берәрсе аркылы калдырып китәрмен дип Зәйнәпкә язган хатын һәм армиядә хезмәт иткән чагында Гәрәй абый бүләк итеп биргән кесә сәгатен алдылар.

Аннары, ниһаять, кайчаннан бирле нәрсәдер әйтергә кыҗрап утырган Хәйруллага чират җитте.

– Ә хәзер, Хәйрулла Хәйретдинович, сез әйтеп карагыз инде: Карый һәм Ашап отрядларында күпмешәр кеше һәм аларның күпмешәр кораллары бар? – диде офицер, өстәл янына барып утырып.

– Мин нәкъ менә шул турыда әйтергә теләгән идем дә инде, – диде Хәйрулла, кош тоткандай куанып. – Гайсин әйткәннәрнең берсе дә дөрес түгел, Олег Васильевич. Карый отрядында ике йөз илле тугыз түгел, нибары егерме тугыз кеше. Шуларның нибары унберендә генә сугыш мылтыгы бар, бүтәннәрендә ау мылтыгы. Аларының да яртысы берәр көпшәле генә әле. Ә пулемет дигән нәрсә аларның төшенә дә кергәне юк!

– Ишетәсеңме, Гайсин? – диде офицер, канәгать елмаеп.

Хәйрулла әйткәннәрнең барысы дөрес иде. «Тәкиаклар агенты икән бу, кабахәт!» – дип уйлап алды Миңнулла. Ә офицерга:

– Ишетәм, ләкин ул моннан ярты ел элек булган хәлләр хакында сөйли! – дип җавап бирде.

– Ну, сез нәрсә әйтерсез, Хәйрулла Хәйретдинович?

– Ышанмагыз, Олег Васильевич, Карыйда мин нибары дүрт көн элек кенә булдым, – дип чәрелдәде тегә.

– Ә мин әле кичә генә шунда идем! – диде Миңнулла, һич тә бирешергә теләмичә. – Хәзерге заманда өч көн эчендә әллә нинди үзгәрешләр булырга мөмкин.

Офицер икеләнеббрәк калды. Ләкин артык исе китмәгән атлы булырга тырышып:

– Дәвам итегез, Хайретдиныч! Ашапта эшләр ничегрәк тора? – диде.

– Ашаптамы? Ашапта да хәлләр ул әйткәнгә якын да килми. Нибары җитмеш өч кенә кеше аларның отрядында. Бер рота түгел, бер солдат та юк анда. Пулеметлары шулай ук юк. Җитмеш өч кешегә утыз җиде мылтыклары бар, шуларының да күбесе ау мылтыклары гына!

Хәйрулла биргән мәгълүматлар бу юлы да дөрес иде. «Китаптан карап укыймыни, кара син аны, ничек барысын белеп-ятлап алган, кабахәт!» – дип уйлады Миңнулла һәм, һаман да сүзен куәтләп:

– Сафсата! – дип кычкырды. – Мин Ашаптан бүген иртән генә чыккан кеше – барысы да нәкъ мин әйткәнчә андагы хәлләр!

Офицер кем фикеренә күбрәк ышангандыр – анык кына итеп әйтүе кыен. Тик шунысы бәхәссез: ул шактый аптырашта калган иде. Әмма бүтән төпченеп тормады. Икенче бүлмәдән аюдай таза бер солдатны дәшеп чыгарды да, Миңнулланы күрсәтеп:

– Менә бу «кунак»ны Богородскига штабка илтергә кирәк. Тиешенчә «сыйлап» озатыгыз. Ләкин кисәтеп куям: «сый» эзләре күренеп торырга тиеш түгел! Теге чактагы шикелле, Николай Харитонович тавыш куптарырлык булмасын! – диде.

– Бузделыны, вашесокородие! – дип, солдат Миңнулланы ишегалдына алып чыгып бастырды да: – Менә болай килешәбез, парин: хәзер мин сиңа берне сугам, шунда егылып китмичә түзеп кала алсаң, бүтән кагылмыйм. Әгәр егылсаң, үпкәләмә, тагын кабатларга туры киләчәк! – диде. Һәм кизәнеп тә тормастан утын тукмагы кадәрле йодрыгы белән китереп орды.

Үпкә-бавырлары өзелеп киткәндәй булды Миңнулланың. Әмма түзде – егылмыйча калды.

– Вот эт-та да! – диде солдат, күңеле булып. – Менә монысы шәп! Күпме кеше арасыннан мин сукканда аягында калучысы син тик икенче кеше! Әгәр минем ихтыярымда булсаң, каһәрләнеп китим, менә шушы минутта ук өеңә кайтарып җибәрер идем мин сине. Ну, ни хәл итмәк кирәк, безнең Олег Васильевич ул эшкә бара торган кеше түгел шул.

**5**

Миңнулланы Богородск авылына алып бардылар да тикшерү комиссиясе карамагына тапшырдылар. Комиссия элек волость идарәсе булган таш йортның бер бүлмәсендә урнашкан иде. Комиссия председателе – куе кара сакаллы, гражданский киемдәге кеше – Миңнулланы алып килгән солдатларның берсе (аны монда ике солдат китергән иде) биргән пакетны ачып укыгач, кәефе килеп, үзалдына елмаеп куйды. Аннары шул пакет эчендә килгән, Зәйнәпкә дип язылган хатны тотып, Миңнулла каршына килеп басты:

– Сезнекеме бу, Гайсин әфәнде?

– Әйе.

– Рәхим итегез.

– Рәхмәт, – диде Миңнулла, хатны алып. – Ләкин минем бүтән әйберләрем дә бар иде.

– Нәрсәләр иде, мәсәлән?

– Кесә сәгате белән алтын йөзек.

Сакал пакетны алып килгән солдатка шундый итеп карады – теге куырылып калды.

– Җир йотсын, без алмадык, вашесокородие! – диде ул, үрә катып һәм честь биреп.

– Алайса кайт да командирыңа әйт: Гайсин әфәнденең сәгате белән балдагын бүген үк китереп җиткергән булсын!

– Слушаюсь, вашесокородие! – диде солдат һәм өреп очыргандай юкка чыкты.

Сакал өстәл янына барып утырды. Папирос кабызды.

– Ә хәзер, Гайсин әфәнде, менә монда өстәл янына килеп утырыгыз да ачыктан-ачык сөйләшүгә күчик.

– Мондый шартта андый сөйләшү була микән?

Сакал елмайгандай итте:

– Замечаниегез урынлы. Ләкин сез үзегезне әсир итеп түгел, ә минем коллегам дип хис итегез.

– Бу мөмкин түгел. Коллегалар – бертөрле һөнәр ияләре, ә безнең һөнәрләребез – капма-каршы.

– Бу замечаниегез белән дә килешәм. Ну, алайса, мине үзегезнең иң якын кешегез дип уйлагыз.

– Якын кешеләр бер-берен яхшы белергә тиеш. Ә мин сезне беренче күрәм.

– Сез хаклы. Кичерегез, гаеп миндә. Таныш булыйк: Николай Харитоныч, – диде ул, кулын сузып, – Кошкарев. Тикшерү комиссиясе председателе.

– Гайсин, – диде Миңнулла, кулын биреп. Аннары тегенең өстәлендә яткан донесениегә ымлады: – Ә калганнары сезгә инде билгеле.

– Анысы шулай. Ләкин безнең эштә кайбер формальностьларны сакларга туры килә.

Һәм ул әле донесениедә язылганга, әле Миңнуллага карый-карый, аның исемен дә, туган җирен дә, эш урынын да сорашып-тикшереп чыкты. Аннары Карый һәм Ашап отрядлары хакында төпченергә тотынды. Миңнулла аңа да нәкъ Воскресенскидагыча җавап бирде.

– Ә менә болары инде бөтенесе дә ялган! – диде сакал, никадәр генә тыныч булырга теләсә дә сабырлыгын җуя башлап. Күрше бүлмәнең ишеген ачты да кемгәдер: – Юрий Сергеич, рәхим итегез! – диде.

Ул дәшкән кеше килеп кергәч, Миңнулланың күз аллары караңгыланып китте. Чөнки ул кеше Миңнуллага таныш. Усы өязенең хәрби штабы члены Юрий Сергеевич Михайлов иде. Сабыр гына, акыллы гына күренгән кырык бишләр тирәсендәге бу агай беркайчан да артыгын сөйләми, үзенә тапшырылган эшне һәрвакыт төп-төгәл үтәп бара торган иде. «Бу бичараны да эләктергәннәр икән», – дип уйлап куйды Миңнулла. Ул арада Юрий Сергеевич та Миңнулланы таныды һәм:

– О-о-о-о! Кого я ви-жу! Здравствуй, Миңнулла, здравствуй, дорогой! – дип килеп, кочаклап ук алды.

Михайловның авызыннан бик зәһәр аракы исе килә иде. Аның сүзләреннән бигрәк Миңнулла әнә шунысына игътибар итте. Хикмәт шунда, әле күптән түгел генә өяз башкарма комитеты хезмәткәренең туган көнендә бергә утырганда, менә шушы кеше, миңа ярамый, егетләр, дип, грамм да эчмәгән иде. Ә хәзер әнә чөгендер күк кызарып чыккан. Ләкин Миңнулланы барыннан да бигрәк шаккатырганы Михайлов өстендәге ак офицер киеме булды. «Әллә акларга сатылган микән бу!» – дип тетрәнеп куйды Миңнулла.

Михайловның артык төчеләнүен сакал ошатып бетермәде:

– Ярый, ялашуларны туктатып торыйк, Юрий Сергеич! – диде дә Миңнуллага эндәште: – Сезгә танышмы бу кеше, Гайсин әфәнде?

– Юк, таныш түгел.

– Ишетәсеңме? – диде сакал, мыскыллы елмаеп. – Сине танымыйлар! Бәлки, син, чыннан да, аны күргәнең юктыр?

– Ах-ха-хах-ха! Ул мине танымый! – диде Михайлов һәм, очынып килеп, Миңнулланың яңагына сукты. Аннары күзенә керердәй булып сорады: – Йә, таныдыңмы инде?

– Юк, танымадым! – диде Миңнулла. Шул уңайдан тегенең эченә тибеп җибәрде.

Михайлов мәтәлеп барып төште. Берәр минут чамасы тынсыз ятты. Аннары, сикереп торып, тагын Миңнуллага кизәнә башлаган иде, Кошкарев юл куймады:

– Азрак кан таратып алдыгыз, җитеп торыр! Ә хәзер бер сорау сиңа, Юрий Сергеич: Карый һәм Ашап волостьлары отрядларында ничәшәр кеше бар һәм аларның кораллары күпме?

Михайлов чалбар кесәсеннән бәләкәй генә блокнот чыгарды да, шуннан карап, бөтенесен төп-төгәл итеп әйтеп бирде.

– Ә менә Гайсин әфәнде әйткән саннар бөтенләй бүтән төрле бит әле монда! – диде Кошкарев.

– Алдаша ул! Мин әйткәнгә ышаныгыз, Николай Харитоныч, мин бит аларның хәрби штабында учет бүлегендә эшләдем!

– Ә без синең сатлыкҗан икәнеңне баштан ук белдек, шуңа һәрвакыт ялган мәгълүматлар гына биреп бардык! – диде Миңнулла.

Кошкарев дәшми торды. Аннары, кисәк кенә күтәрелеп, Михайловка әйтте:

– Синең бу Гайсиның яхшылап сөйләшкәннең кадерен белми икән бит. Давай телен башкачарак ачтырып кара. Башларга мөмкин!

Михайлов Миңнулланы коридорның аргы башындагы эт оясы хәтле генә бүлмәгә алып керде. Анда өстәл-фәлән юк, тик бер иске урындык кына бар һәм ул урындыкта мир үгезе шикелле дәү гәүдәле бер солдат утыра иде. Түгәрәк тулы битле, калын кара кашлы һәм кысынкырак кара күзле кеше иде ул. «Үзебезнең Пермь ягы татары булырга тиеш» дигән фикергә килде Миңнулла. Ә солдат әйтерсең аның бу уйларын сизеп алды да, шуңа ачуы чыгып, уң кулы белән Миңнулланың изүеннән каптырып тотты, сулы белән яңагына чапты. Миңнулланың күзеннән бер көлтә ут очты, колаклары чыңлап куйды. Йә, ничек, дигән сыман итеп, теге татар Михайловка карады. Михайлов хуплап баш каккач, каерылып торып, тагын берне китереп орды, Миңнулла чайкалып китте, ләкин егылмады.

– Син нәрсә, ашамадың мәллә бүген, рядовой Халитов? – диде Михайлов, солдатка ризасызлык белдереп. – Бүтән чакта болай озак мәтәшми торган идең бит! Әллә юри шулай акрын кыланасыңмы?

– Үзем дә аптырыйм инде, гаспадин Михайлов, – диде теге. – Адәм генә түгелдер бу, тимердән яратылгандыр! Минем кул авырта, ә ул уйлап та бирми!

– Каяле, карап карыйк әле! – дип, Михайлов солдатын читкәрәк какты да, йодрыгын боксерларча йомарлап, Миңнулланың күкрәк авызына китереп төртте. Миңнулла, сыны катып, идәнгә чүкте.

Ул сулу ала башларлык хәлгә килгән арада, менә шулай итәргә кирәк аны, Халитов, дип, Михайлов солдатка акыл өйрәтә торды, Миңнулла, ниһаять, әзрәк хәл алып, аягына баскан иде, Кошкарев килеп керде:

– Йә, Гайсин, дөресен сөйли башлыйсыңмы инде? – диде. – Чыгымлап торудан мәгънә булмаячак. Усы, Орда, Барда өязләре хәзер безнең кулга күчте. Шушы ике-өч көн эчендә Пермь үзе дә, Пермь губернасы да тулысы белән безнең карамакта булачак!

– Син бу әкиятеңне әбиеңә сөйләрсең, Кошкарев, яме! Самодержавиене туздырып ташлаган совет власте аның калдык бандитларына гына бирешеп тормый инде ул!

– Ах, син әле һаман акылыңа килмәдеңмени! – дип чинады Кошкарев һәм алар өчәүләшеп тагын Миңнулланы дөмбәсләргә тотындылар.

**6**

Тигез, зур болын. Бил тиңентен үлән. Үлән арасында – чәчәкләр. Миңнулла чалгы белән шул чәчәкле үләнне чаба. Көн эссе. Тирләтә. Миңнулла, маңгаена агып төшкән эре һәм тозлы тир тамчыларын учы белән сыпырып, чалгысын янап ала да каерылып-каерылып чабуын тагын дәвам итә: чажж-чожжж, чажжж-чожж... Аның артыннан кечерәк тау теземе шикелле булып печән покосы

сузылып килә... Ай!.. Кинәт печән арасыннан сызгырып кара елан килеп чыкты да Миңнуллага ташланды. Ләкин чага алмады – Миңнулла читкә тайпылып калды. Чалгы сабының түтәсе белән еланның башын дөмбәсләргә тотынды. Ә елан бирешми. Һаман тартыша, кырыкка бөтәрләнеп, һаман Миңнулланың аягын чагарга омтыла. Аптырагач, Миңнулла болгап торып китереп суккан иде, шартлап, тотка турыннан чалгы сабы сынып чыкты. Ә еланга берни дә булмады. Елан башын читкә борырга өлгереп калды. Аннары, Миңнулланың буш кул белән калганын күреп, үзе һөҗүмгә күчте. Хәзер инде аннан качып кына котылырга мөмкин иде. Миңнулла җан-фәрманга йөгерә башлады. Шулчак кинәт дөньяны кара болыт каплап алды. Чәчәк һәм үләннәрне бөгеп, ачы җил исәргә тотынды. Елан каядыр юкка чыкты. Еракта, Урал тавы итәгендә Зәйнәп пәйда булды. Миңнулланы күреп, үзе янына килергә чакырып, кул изәде. Миңнулла аңа каршы йөгермәкче иде, ләкин булдыра алмады: ниндидер бер яшерен көч аның аякларын җиргә беркетеп куйган да кузгалырга ирек бирми иде. «Мин бара алмыйм, Зәйнәп, үзең кил!» – дип кычкырмакчы булды Миңнулла. Ләкин тавышы чыкмады. Кул изәмәкче булды – кулы күтәрелмәде. Миңнулланың хәлен аңлап алды булса кирәк, Зәйнәп үзе аңа таба йөгерә башлады. Шундый да җиңел, шундый да ансат йөгереп килә, әйтерсең аңа үләннәрне җиргә кадәр бөгеп исә торган ачы җил бөтенләй тоткарлык итми, әйтерсең аңа канат куйганнар һәм ул очып кына килә. Аралары һаман якыная бара. Әнә Зәйнәпнең елмаюларына тикле күренә башлады инде. Хәзер, хәзер килеп җитәчәк тә... Юк, булмады. Миңнулла күрешергә кулын сузгач, әллә кайдан гына аэроплан кадәр бер каракош пәйда булды да һәркайсы берәр аршын буе тырнаклары белән Зәйнәпне эләктереп алды. Ләкин очып китмәде. Миңнулланың буе җитмәслек кадәр генә күтәрелде дә колак яргыч ямьсез тавыш белән шаркылдап көләргә тотынды. Зәйнәпне коткармакчы булып, Миңнулла үрелеп-сикереп карый, әмма һич кенә дә буе җитми... Аннары теге хәшәрәт кешечә сөйләргә тотынды: «Әйдә, егет кисәге, тырыш, ныграк сикер! Бармак очың белән генә кызга кагыла алсаң да – кыз синеке!» – ди. Ә үзе Миңнулла Зәйнәпкә үрелеп җитәм дигәндә генә, ялт, күтәрелеп куя. Ә Зәйнәп, коты чыгып, телсез калган. Бер сүз дә әйтә алмый. Бары яшь тулы күзләреннән генә аның бөтен өмете Миңнуллада икәнлеге, коткар, дип ялваруы күренеп тора... Аннары, әйдә, алайса куып тотып кара, дип, хәшәрәт кош, түбәнтен генә очып, тауга таба китте. Миңнулла да аның артыннан иярде. Йөгерә, йөгерә, ләкин җитә алмый бит тегене куып. Ә хәшәрәт кош коточкыч ямьсез итеп шаркылдап көлә: «Эх син, кызыл этәч! Мине дә куып җитә алмагач, нигә дип Кошкарев белән тарткалашып азапланасың? Яхшы чакта аның шартын кабул итеп кал, югыйсә соң булуы мөмкин!» – ди. Үзе, хәзер җитәсең, хәзер җитәсең, дип, Миңнулланы алдалап гел тауга таба оча. Ә Миңнулланың көче һаман кими, сулышы һаман кысыла бара… Менә ул инде тәмам хәлдән таеп, һушсызланып егыла ук башлады һәм… уянып китте. Йөрәге читлегеннән чыгардай булып гөрс-гөрс тибә, бөтен тәне сызлый, башы авырта һәм үтереп эчәсе килә иде.

**7**

Ул йөзтүбән ята, болай яту аңа бик уңайсыз иде. Әйләнеп ятарга ярамый: телгәләнеп беткән арка тиресе кунадай каткан, селкенгәндә дә үзәкләргә үтеп сызлый иде. Шулай да көч-хәл белән генә торып утырды. Тирә-ягына карады. Кичә тегеләр кыйнап ташлаган бүлмәдә ялгызы гына иде ул. Болын да, Зәйнәп тә, каракош та, Урал тавы да юк. Бүлмә буп-буш. Хәтта кичәге бердәнбер урындыкны да алып чыгып киткәннәр. Тимер рәшәткәле тәрәзәдән төшкән кояш нурлары күзне чагылдыра. Дөнья тып-тын. Стенага тотынып кына аягына басып, Миңнулла ишек янына барды. Этеп карады. Ишек бикле иде.

Тышкы яктан татарча әйткән тавыш ишетелде:

– Ни кирәк, олан? Тышка чыгарга кысталдыңмы әллә?

Миңнулла, эчәсем килә, дип әйтергә теләгән иде, авызы кипкәнлектән тавышы чыкмады. Ишекне шакырга мәҗбүр булды.

Сакчы, ишекне ачып, эчкә башын тыгып карагач, Миңнулла кулы белән ишарәләп, эчәсе килгәнен аңлатты.

– Хәзер, наный! – диде сакчы агай һәм бүтән бүлмәдән бер стакан су алып килеп бирде.

Эчкән шикелле дә булмады Миңнулла – ике генә йотты. Шулай да сүз әйтә алырлык хәлгә килде һәм теге мәрхәмәтле агайдан, тагын бер стакан алып килә алмыйсыңмы, дип сорады. Коридорда беркем булмаса да, агай шикләнеп як-ягына карап алды. Аннары суны чиләге белән үк алып килеп, Миңнулла алдына куйды:

– Мә, тиз генә туйганчы эчеп кал! Күрсәләр – беттем, сиңа бер йотым да су бирмәскә кушканнарые.

Миңнулла чиләк янына тезләнгән генә иде, болдыр баскычыннан менеп килүче кешенең аяк тавышы ишетелде. Агай секунд эчендә сулы чиләкне үз урынына кертеп чыкты да:

– Әйдә, әйдә, бетмәде инде синең кысталуың! – дигән булып, Миңнулланы «бәдрәфкә» алып чыгып китте.

Аннары, аны тагын тикшерү бүлмәсенә алып керделәр.

Кошкарев бүлмәдә үзе генә утыра иде. Бүген ул кичәге кебек тәмле телләнеп тормады.

– Менә нәрсә, Гайсин, – дип, турыдан-туры эшкә кереште. – Синең алда хәзер ике мөмкинлек бар. Йә син безнең взводны Ашапка алып барып, волость башкарма комитетын кулга алырга ярдәм итәсең, яки без сине атарга мәҗбүр булабыз. Әгәр беренчесенә риза булсаң һәм шуны уңышлы башкарып чыксаң, мин үзебезнең югары командованиедән сиңа хәрби чин һәм яхшы хезмәт хакы биреп, үзеңне ким дигәндә рота командиры итеп билгеләүләрен сораячакмын.

Бу тәкъдим шундый көтелмәгән нәрсә булды – Миңнулла ни дияргә дә белмичә тотлыгып калды. Аның хәлен Кошкарев та сизде бугай.

– Ашыкма, Гайсин, уйла яхшылап! Ун минут вакыт бирәм мин сиңа, – дип, ялгызын гына калдырып чыгып китте.

Авыр мәсьәлә иде бу Миңнулла өчен. Нишләргә? Әгәр бу бандитның тәкъдимен кире какса, тотар да атар. Кыяфәтенә һәм сөйләшүенә караганда, шактый зыялы, мәрхәмәтле кеше сыман күренсә дә, асылда, таш бәгырьле бәндә икән бит. Кичә, җене кубып, ахырдан әнә ничек тешләрен ыржайтып тотынды! Йодрыгы белән генә түгел, наган түтәсе белән төйде Миңнулланың башын...

Әллә, Кошкаревның тәкъдименә риза булган булып, отрядларын ияртеп барырга да безнең отрядлар урап алырлык җиргә китереп кертергә тырышырга микән? Алай барып чыкса бик шәп булыр иде, ләкин уйлаганча гына барып чыгар микән соң? Ярый ла безнекеләр Ашапта авыл башларына күзәтүчеләр куйган булса. Ә куймаган булып, болар отряды бернинди тоткарлыксыз барып керсә һәм безнең отряд кешеләрен кулга төшерсә? Ул чакта аның турында нәрсә дип уйлар халык? Әлбәттә, Гайсин сатлыкҗан булып чыккан икән, диячәкләр. Аның изге ният белән йөрүен кайдан белсен алар? Кайчаннан бирле революция эше өчен, советлар власте өчен көрәшеп йөрсен дә, менә хәзер шул эшләрен берьюлы юкка чыгарып ташларгамы? Юк, алай егетләрчә булмый...

– Мин сезнең тәкъдимне кабул итә алмыйм! – диде Миңнулла, Кошкарев әйләнеп кереп сораулы карашын төбәгәч.

Теге әйтерсең аның сүзләрен бөтенләй ишетмәде. Өстәл артына барып утырды. Кесәсеннән бер сәгать белән бер йөзек чыгарды да:

– Менә, Гайсин әфәнде, рәхим итегез! Болар сезнең әйберләр. Воскресенскидан китерделәр, – дип, Миңнуллага сузды.

Әйберләр, чыннан да, Миңнулланыкы иде.

– Рәхмәт инде кайгыртуыгыз өчен, – диде Миңнулла, әйберләрен барып алгач.

– Йә, хәл иттегезме? – диде Кошкарев.

– Мин сезнең шартыгызны кабул итә алмыйм! Үзем чын күңелемнән инанып йөргән эшкә хыянәт итәргә намусым кушмый!

– Син ныклап уйладыңмы, Гайсин? Яшьлек кирелеге, ялган горурлык кына түгелме бу? Син бит әле бик яшь, неужели яшәүдән туйдың да инде?

– Яшисе бик килә. Ләкин сатлыкҗан булып түгел, кешеләрчә яшисе килә!

– Димәк, үз фикереңдә каласың?

– Әйе, мин революция эшенә турылыклы булып калам!

Кошкарев бүтән бер сүз дә дәшмичә нидер язды. Үзе янына тагын ике кешене чакырып кертте дә шул язуын тегеләргә укытып, икесеннән дә кул куйдыртты. Аннары, Миңнулла каршына килеп басып, шул язуын үзе кычкырып укып чыкты. Бу – тикшерү комиссиясенең Миңнулланы атарга хөкем иткән карары иде.

– Соңгы сүзең итеп нәрсә әйтергә телисең?

– Сезгә әйтүдән ни мәгънә?

– Что ж, – диде Кошкарев, – теге дөньяга китәргә алай бик атлыгып тора икән, ярдәм итик бу яшь кешегә. Каяле, сиңа аларның барыбер кирәкләре булмас инде анда, – дип, Миңнулланың йөзеге белән сәгатен алды.

Шул ук Кошкарев боерыгы буенча, күн курткасын, күн итеген һәм чалбарын салдырып алып, Миңнулланы эчке күлмәк белән эчке ыштаннан гына калдырдылар. Аннары мылтык аскан ике солдат һәм наган таккан бер офицер аны атарга алып китте.

Иртәнге сәгать тугызлар тирәсе иде бу. Бүген дә көн кичәгечә бик эссе иде. Богородск чиркәве тирәсендә чиркәү чәүкәләре чыркылдаша. Авылның аргы башында чаптырып барган атлы арба тавышы, шуның артыннан өтәләнеп өргән эт тавышы ишетелә. Бер генә тәрәзәле, җиргә иңгән өй каршында ике бәләкәй малай төчергәләнеп нигез туфрагыннан «бәлеш» ясап утыралар иде. «Минем дә шушылар шикелле гамьсез, рәхәт чакларым бар иде бит», – дип уйлап алды Миңнулла...

Авылны чыккач, чишмәдән су алып кайтып килүче бер карт марҗа очрады. Ул, Миңнулла үтеп киткәндә тукталып:

– Господи, опять ведут! Какой молодой! Господи, помилуй! – дип сөйләнеп, чукынып калды.

«Берәр җиргә барырга чыкканда тулы чиләккә очрасаң, юлың уңа, ди торганнар иде. Пычагым да дөрес түгел икән! Менә бу карчыкның ике чиләге тиң тулы булудан миңа ни файда хәзер!» – дип уйлап куйды Миңнулла. Менә хәзер, нибары берничә минуттан, үзен атачакларын бик яхшы белә иде ул.

Ләкин шуңа каршы торырлык бернинди дә чарасы юк иде. Күрәсең, әнә шул чарасызлык нәтиҗәсендәдер, ул бер дә хафаланмый, кайгырмый иде. Күңеле моңарчы беркайчан булмаганча битараф, уе ачык иде аның. Менә хәзер елга буена алып барырлар, туктатырлар, аннары офицер солдатларга «Целься!» дияр. Тегеләр мылтыкларын төзәгәч, офицер «Пли!» дип кычкырыр. Һәм атып җибәрерләр. Шуның белән барысы да бетәр, юкка чыгар. Берни дә тоймый калыр Миңнулла. Тик шунысы гына кызганыч: кичә Зәйнәпне күреп китә алмады. Их, могҗиза булсын иде дә хәзер, менә шушы су буеннан Зәйнәп сикереп менеп бассын иде... Юк, алай итмәсен. Алай итсә, аны да тотып атар бу кабахәтләр. Тегеләргә күренмичә, Миңнулланың үзенә генә күренеп һәм үзе дә Миңнулланы күреп торсын иде ул кыз... Миңнулла аңа, хуш, Зәйнәп, сау бул, мин сине ярата идем, ләкин яратканымны әйтергә теге чакта кыймадым, ә бүтән вакытта сезнең якларга барып чыгарга туры килмәде, дияр иде... Йә менә хәзер Миңнуллага әти-әнисен күреп калырга мөмкин булсын иде. Ике айдан артты бит инде аларны күргәне юкка. Аннары соңгы тапкыр аерылышкан чакларында да бик үк әйбәт килеп чыкмаган иде. Әтисе, бичара, әллә барып йөрмисеңме инде ул Усыга, синнән башка да кеше табарлары әле, әллә шушы үзебезнең Карыйда гына эшләвеңне дәвам иттерәсеңме, улым, син монда булсаң, безгә дә тынычрак булыры, ичмаса, дип калган иде. Менә шунда Миңнулла, ярар, әти, хатын-кыз башы белән әни сүз әйтмәгәндә, син кирегә сукалап утырма, үзеңнең кулыңнан килми икән, кулыннан килгән кешегә карышма, яхшы теләк теләп кал, ичмаса, дип, артыгын дорфарак әйтеп ташлаган иде. Шуның өчен әтисеннән гафу үтенеп кенә булса да каласы иде менә хәзер... Ә әнисе ничек тә аңлар Миңнулланың хәлен. Ул яктан молодец аның әнисе. Син инде балигъ булган кеше, улым, ни эшләгәнеңне үзең беләсеңдер, дип кенә тора. Миңнулланың бер эшенә дә каршы килми, киресенчә, аның совет органнарында эшләп йөрүенә горурлана гына иде ул. Менә хәзер Миңнулланы ни өчен атарга хөкем иткәннәрен белсә дә, мөгаен, дөрес эшләгәнсең, балам, сатлыкҗан булып гомер иткәнче, гаделлекне яклап шәһит китүең артыграк, дияр иде ул... Елар иде елавын. Әмма, тегеләргә хезмәткә күч, дип әйтмәс иде... Атканда кисәтеп тормыйча, Миңнуллага сиздермичә, арттан гына атсыннар иде, ичмаса. Ә башта менә шушы елгадан туйганчы бер су эчәргә рөхсәт итсеннәр иде.

Шул үтенечләрен әйтмәкче булып, Миңнулла артына әйләнгән иде, сакчы:

– Атлавыңны бел! – дип, штыгы белән төртеп, авыз ачарга да ирек бирмәде.

Елга яры буйлап берәр чакрым чамасы баргач, бик зур бер баз сыман чокыр янына җиттеләр. Миңнуллага шуның янында туктарга куштылар. Өстенә бастырык юанлыгы ике агачтан басма салынган ул чокырда егерме-утызлап мәет ята, алардан авыр ис килә иде.

– Күрдеңме? – диде офицер, читтән торып кына.

– Мин күрәм, ә син нигә якынрак килеп карамыйсың?

– Менә нәрсә, Гайсин, – диде офицер, – шушында ятып каласыңмы, әллә Николай Харитоныч әйткәнгә риза буласыңмы? Бу – синең тормышыңны сайлап калу өчен соңгы мөмкинлек. Бер минут вакыт бирәм уйларга. – Аннары солдатларга боерды:

– Приготовиться!

Солдатларның мылтык затворларын тартып куйганы ишетелде.

Миңнулла өчен иң кыен, иң хәлиткеч секундлар иде бу. Шунда, секундның меңнән бер мизгелендә генә, әллә риза булыргамы дигән уй да килеп китте аның күңеленә. Ул чак кына тыелып калды. Бу яман уйның тагын әйләнеп килүе мөмкин иде. Шуннан куркып, тизрәк әйтеп калырга ашыкты:

– Хатын-кыз түгел бит мин кат-кат сөйләшергә!

– Тагын егерме секунд вакытың бар әле, Гайсин, уйла! – диде офицер.

– Атыгыз инде тизрәк!

Офицер тәки минут үткәнче сәгатенә карап торды. Аннары Миңнуллага чокыр аша салынган басмага керергә кушты һәм солдатларга боерды:

– Целься!

«Менә хәзер, хәзер, аталар да барысы да бетә. Тоелмый да калачак!» – дип, үзен-үзе юатты Миңнулла. Тегеләр атканчы ничек тә егылып төшеп хурлыкка калмаска тырышып, тар басмадан аягын шудырып кына атлавын дәвам итте. Менә ул басманың уртасына да килеп җитте, ләкин һаман «Пли!» дигән команда булмады әле. Шул чакта офицер аңа:

– Кире борыл! – дип кычкырды.

Миңнулла туктап калды. Ләкин борылырлык хәле юк, аяклары тартышып калган иде аның. Моның шулай икәнлеген офицер да төшенеп алды булса кирәк, әле һаман мылтыкларын Миңнуллага төбәп торган солдатларга:

– Отставить! – дип кычкырды һәм Миңнуллага басмадан чыгарга ярдәм итәргә кушты...

Миңнулланы яңадан Богородскига алып кайттылар. Атарга дип алып киткәндә салдырып алган киемнәрен китереп бирделәр. Киенергә куштылар. Ләкин Миңнулла – мәет тулы чокыр өстендә басып, аркасына мылтык төбәлгәнне тоеп торган кеше – тегеләрнең бу әмерен үти алмады: киемнәрен кулына тоту белән һушыннан язып, идәнгә ауды.

Ул башта кешеләр сөйләшкән тавыш ишетте һәм: «Монда да нәкъ дөньядагыча сөйләшәләр икән!» – дип гаҗәпсенеп уйлап алды. Чөнки ул үзен инде үлгән дип белә иде. Аннары күзләрен ачты. Тирә-як караңгы иде. «Монда кояш юк икән», – дип нәтиҗә ясады Миңнулла. Акрын гына кулын кымшатып карады – кымшанды! Икенчесен селкетте – анысы да селкенә иде. Аннары үзенең эчәсе килгәнен тойды һәм: «Монда да шулай сусыз интектерәләр микәнни?» – дип кайгыга калды. Ә мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар әле һаман ишетелә иде. Бәлки, монда торып йөрергә дә була торгандыр, бәлки, монда эчәргә су да бардыр, дип, шуны тикшереп карамакчы булып, ул торып утырды.

– Ыһы, һушына килде теге иптәш, – дип, Миңнулла янына ике кеше килде.

Шуннан соң гына Миңнулла үзенең теге чокырдагы мәетләр арасында түгел, ә тере кешеләр арасында икәнлеген аңлады.

Үзара сорашу-сөйләшү башланды. Менә бу – алар утыра торган караңгы таш келәт – тикшерү комиссиясенең КПЗсы икән. Монда утыручылар, Миңнулладан башка тагын биш кеше, төрлесе төрле волостьтан һәм төрле сәбәпләр буенча аклар кулына эләккән кешеләр. Аларны да инде берничә кат тикшергәннәр, кыйнаганнар. Яңаклары, күз төпләре кара янып шешеп чыккан.

– Сине кичә көндезге сәгать унберләрдә кертеп ташладылар. Сулыш алганың да сизелмидерие. Без сине, беткән, ахрысы, бу егет, дип уйлаганыек инде! – диделәр Миңнуллага. – Үлмәсә дә үлми икән адәм баласы: нәкъ бер тәүлек ятканнан ары өнеңә килдең менә!

Миңнулланың киемнәрен дә шушында кертеп атканнар иде. Теге иптәшләрнең ярдәме белән киенде дә, хәле бетеп, тагын йөзтүбән ятты. Болай яту аңа кыен, әмма чалкан ятарга һич мөмкин түгел – аркасындагы яралары бик каты сызлый иде.

Бераздан кичә атарга алып барган солдатларның берсе кереп, Миңнулла янына килеп карады да:

– Әһә, тере икәнсең! – дип, нигәдер куанган сыман итеп чыгып китте.

Аннары Миңнулланы тагын Кошкарев янына алып керделәр. Кошкарев аны күптәнге әшнәсен каршылагандай елмаеп каршы алды. Култыклап алып килеп, өстәле янына утыртты. Миңнулланы алып кергән солдатны чыгарып җибәрде дә, дустанә елмаеп:

– Бәлки, башта бергәләп иртәнге ашны ашап алырбыз, ә? – диде.

– Ике-өч тәүлеккә бер тапкыр азрак ашап алу зыян итмәс иде, – диде Миңнулла. – Ләкин мин, әгәр мөмкин булса, башта бер туйганчы су эчәр идем!

– Нигә су? Без аның судан шәбрәген дә табабыз! – диде Сакал һәм, күрше бүлмәнең ишеген ачып, ике кешелек ашамлык кертергә кушты.

Күрәсең, алдан ук әзерләп торганнардыр, шундук парлары чыгып торган ит бәлеше, ике буш стакан һәм бер графин аракы кертеп куйдылар. Кошкарев ике стаканга да яртышар итеп салды да:

– Йә, сезнең исәнлеккә! – дип эчеп куйды.

Эчәсе килүдән бигрәк тамак чатнавын басар өчен, Миңнулла да тотты.

Икесе дә сүзсез генә бераз ашап алдылар. Аннары Сакал Миңнулла стаканына тутырып ук салды да:

– Тагын берне күтәреп җибәрегез, комиссарлар эчәргә ярата, диләр! – диде.

– Үзегезгә дә салыгыз, урядниклар да кимен куймый торган иде! – дип, Миңнулла да тегенең стаканына тутырып салып куйды.

Кошкарев сискәнеп китте:

– Минем урядник булганны син кайдан беләсең, Гайсин әфәнде?

– Кыяфәтегездән күренеп тора! – дигән булды Миңнулла. Ә чынында аңа Кошкаревның Чернушка ягында урядник булып эшләгәнен әлеге караңгы келәттәге әсирләрнең берсе әйткән иде.

Теге ярты стакан аракы Миңнулланың кан тамырлары буйлап таралырга өлгергән иде инде. Шунлыктан тәнендәге җәрәхәтләрнең сызлавы да басыла төшкән кебек булган иде. Шунда аның күңеленә монысын да тәвәккәлләп куйсам тагын да җиңелрәк булып китмәсме дигән уй килде. Һәм ул:

– Әйдә, якты киләчәк өчен боларын да күтәрик, булмаса! – дип, тагын эчеп куйды.

Кошкарев та:

– Мин риза бу тостка! Рәхәтләнеп эчәм мин моның өчен! – дип, тамчысын да калдырмыйча йотып җибәрде. Аннары: – Үзем рус булсам да, яратам шушы татарларның ит бәлешен, ну шәп тә нәрсә инде! – дип, комарланып бәлеш ашарга тотынды. Табаның төбенә төшеп җитә язгач, «гы-ы-ык» иттереп бер кикерде дә, кашыгын куеп, тагын сүзгә кереште: – Шәп әйттең әле син киләчәк турында, – диде ул, Миңнулланың баягы тостын искә алып. – Ул якты көннәргә күп калмады инде. Фронтлардан көн саен куанычлы хәбәрләр килеп тора бу араларда. Чиләбе – бездә, Самара – бездә, Уфа – бездә, Оренбург – бездә. Тиздән кызылларның тагын бер бик мөһим үзәге – Казан шәһәре дә безнең кулга күчәргә тиеш! Аннары божраны кыса-кыса китереп, Пермь дә, Кунгур да безнең кулга күчәчәк! Беләсеңме син бу ни дигән сүз?..

Кошкарев бик белдекле кыяфәт белән әйткән бу хәбәрләр Миңнулла өчен берсе дә яңалык түгел, ул аларны Усыда чакта ук белә иде инде. Шуңа ул Сакалның лыгырдавын исе китмичә генә тыңлый бирде.

– Бу, – дип дәвам итте Кошкарев, үз соравына үзе җавап биреп, – безгә, азатлык армиясенә, карышып торудан мәгънә юк, без барыбер кызыл этләрне туздырып ташлап, көлләрен күккә очырачакбыз дигән сүз! Бу – бая син әйткән якты киләчәк тиздән, бик тиздән килеп җитәчәк дигән сүз! Бу – Советларны юкка чыгарганнан ары без синең белән типтереп яшибез дигән сүз! Ә син, юләр, кичә киреләнеп, Алла үзе кулыңа китереп тоттырган форсатны ычкындыра яздың. Рәхмәт әйт инде миңа туры килүеңә. Минем урында башка берәү булса, теге мәетләр чокырыннан кире кайтарып тормас иде. Кешенең нинди икәнлеген бер күрүдә сизәм мин. Белдем мин синең менә шушылай акылга утырачагыңны, шуңа саклап калдым тормышыңны. Әйдә, якты киләчәк өчен тагын берәрне күтәреп куйыйк әле!..

Кошкарев, графинны алып, башта үзенә салды. Аннары Миңнулла стаканына үрелгән иде, ләкин Миңнулла стаканын учы белән каплады да:

– Миңа җитеп торыр, болай да күз алларым әлҗе-мөлҗе килә башлады, – дип, читкә алып куйды. Һәм әйтте: – Кичерегез, Кошкарев әфәнде, ләкин без икебез ике төрле телдә сөйлибез булып чыкты бит әле! Мин тостымны үзем көткән, үзем ышанган якты киләчәкне – коммунистик киләчәкне күздә тотып әйткән идем!

Кошкаревның күзләре шар булды. Ул нидер әйтмәкче иде, әмма ачуы килүдән буылып, беркавым тынсыз-өнсез торды. Аннары, кабалана-кабалана, стаканын тутырып салды, голт-голт итеп эчеп җибәрде. Стаканын болгап торып идәнгә бәрде дә, Миңнулланың каршына килеп басып:

– Әле син мине һаман аңламадыңмыни, сволочь?! – диде.

– Кызганычка каршы, бик үк төшенеп җитә алганым юк шул әле, үз ягыгызга аударып, минем белән нишләмәкче буласыз соң сез? – диде Миңнулла салкын гына итеп.

– Курыкма инде, ахмак! – диде Кошкарев, тагын ягымлыга әверелеп. – Көчең җитмәстәй эш кушмыйбыз без сиңа. Булдырырдаен гына тапшырачакбыз!

– Конкретрак мөмкин түгелме?

– Алдан ук серне чишеп куярга тиеш булмасам да, үзеңне якын иткәнгә әйтәм инде алайса: без синең үзебездәге мөселман солдатлары арасында агитатор булуыңны телибез. Бигрәк тә әсир ителгәннәр белән эшләргә, аларны безнең якка өндәргә кирәк булачак.

«Ыһы, менә нәрсә өчен тырыша икән бу Сакал! Менә ни өчен мине атарга алып барган җирдән кире алып кайтарткан икән, паразит!» – дип уйлап алды Миңнулла. Ә үзе тыныч кына җавап бирде:

– Ышанычыгыз өчен рәхмәт, Кошкарев әфәнде, ләкин аклый алмам мин сезнең ул ышанычны. Сөйләү осталыгым юк минем.

– Аңа осталык кирәкми! – диде теге, әсәрләнеп. – Үзеңнең элек кем булганыңны һәм үзең теләп безнең якка чыкканыңны әйтеп, әсирләрне дә шулай эшләргә чакырсаң – шул бик җиткән! Отлично булачак!

«Ах, менә ничек? Үзегез асып, атып, өркетеп, максатыгызга ирешә алмагач, Гайсин аркылы эш итмәкче буласызмыни? Тотыгыз менә...»

– Әйдә, болай эшлик, Кошкарев әфәнде, тотыйк та безнең якка чыгыйк! Шулай акыллырак булыр ул. Һәм без сезнең белән, чыннан да, менә дигән итеп бергәләп эшләрбез.

Кошкарев шуннан ары бер сүз дәшмәде. Күзен тутырып беркавым Миңнуллага карап торды да, сакчыны чакырып:

– Минемчә, акылга җиңеләйгән бу егет. Бар, алып китеп әсирләр янына ябып куй үзен! – диде.

**9**

Кошкарев Миңнулланы бүтән чакыртмады. Ә икенче көнне иртән, әле кояш та чыкмас борын ук, тоткыннарны урамга алып чыгып, икешәрләп тезделәр һәм кулларын артка каерып бәйләделәр дә акларның тыл ягына – Янапай авылына бара торган олы юл буйлап алып киттеләр. Кичә, Миңнулла Кошкарев белән «әңгәмә» алып барган арада, теге караңгы келәткә тагын егермеләп әсир китергәннәр иде. Аннары янә бер тапкыр унберне, икенчесендә унҗидене китерделәр. Шулай итеп, алар иллегә якын кеше җыйналганнар иде.

Әсирләрнең күбәюе күңелле хәл түгел иде, әлбәттә. Тагын да яманы шул, ул кешеләр бер тирәдән генә түгел, төрлесе төрле җирләрдә әсир ителгәннәр. Усы, Орда өязләрендә, хәтта Көнгер өязендә аклар кулына капканнары да бар иде. Бу – аклар әлеге өязләрдә шактый көчәя бара дигән сүз иде. Шул ук вакытта әсирләр белән сөйләшүнең Миңнулла өчен куанычлы ягы да булды. Әсирләр барысы да кызыл отрядчылар һәм кызылармеецлар булып, кайсы аклар ягына разведкага барганда, кайберләре - отряд алдында дозорда барганда эләккән кешеләр иде. Ә иң мөһиме шул: ул иптәшләрнең әйтүенә

караганда, безнекеләр Көңгер, Уинск, Усы, Орда һәм Ашап якларыннан һөҗүм итеп, атларны куып киләләр иде!

– Тиздән Богородскига да килеп җитәргә тиешләр, Кошкарев безне шуңа болай таң тишегеннән озату ягын карады, – диде Миңнулла белән рәттән баручы агай. Карап торырга йомыкый гына күренсә дә, сүзгә бик җәптәш һәм дөньяны шактый күргән кеше булып чыкты ул. Уинскида әсир иткәннәр аны. Ә үзе шул өязнең Харис авылыннан икән. Өяз базарыннан үз авылларына кайтып барган атлы булып, разведкага барган чагында эләктереп алганнар. Дүрт бала атасы. Кырык тугызынчы яше белән бара икән. Агай бер дә алай аһ ормый.

– Ничава, – ди, – беренче генә плин төшү түгел, нимесләрендә дә, пүләкләрендә дә булган бар инде. Так шту боларыннан әллә ни өреккән юк. Ни әйтсәң дә, болар үзебезнең урыслар әле! – ди. – Аннары тагын шунысын чуттан чыгарырга ярамый: фрунт эшләрен Ленин үз кулына алган, ул тотынса, барыбер үз дигәненчә алып барып чыга инде – барыбер капут ясаячакбыз ул акларга! – ди. – Канса кансоф, алай-болай аклар баганага элә или маңгаеңа пуле җибәрә икән, анысына да шаккаткан юк, туган: минем балалар үсеп бетте инде, ә хатынны мин болай да яратып тормыйдырыем. Безнең заманда көчләп өйләндерәләрие. Мине дә эти-әни көчләп өйләндергәннәрие. Бер кавышкач ияләштек, тату гына тордык. Ну яратып тору булмады инде ул. Так шту, хатын дип тә алай ис китте юк! – ди. – Ә менә сине алай-болай итә калсалар, анысы начар булачак, энем! – ди. – Син әле яшь. Самый каймак чагың. Өйләнеп торып җибәреп, дөнья гөрләтеп яшәр чагың синең! – ди. – Аннары килеп, яшь кенә булсаң да, зур урында эшләгәнсең икән. Значит, башың бардыр, башың булмаса, шушы яшеңнән өяз тикле өязгә эшкә алмасларые. Ну шулай да бер хата җибәргәнсең. Шушындый чакта этрәтсез юлга чыгарга ярыймы суң? Үзең белән алып баралар аны, – ди. Аннары тагын юатырга тотына: – Ярар, туган, адәм баласының берсе дә хатадан хали түгел аның. Бик алай аптырама. Эшең өчен дә артык хафаланма. Синең урынга бүтән берәүне куеп торырлар әле. Мужыт инде куйганнардыр да. Синең урынга гына түгел, патшалар урынына да кеше табалар, – ди. Беркавым нидер уйланып дәшми бара да янә сүзгә керешә: – Карале, туган, яшь кенә булсаң да, байтак ил-җир гизгән икәнсең: Мәскәвендә дә, Казанында да, Питрбурында да булганың бар икән инде. Әйт әле миңа, Ленинны күрергә туры килгәне булмадымы сиңа? – ди. Миңнулла, юк шул, Сәмигулла абзый, дигәч: – Ах-ма! Анысы бик жалкы икән! Үзем күрә алмасам да, ичмаса, аны күргән кешене генә булса да күрәсие бер! Безнең ише прастуй адәм генә микән ул, әллә Аллаһы Тәгалә тарафыннан илче итеп, безнең ише ярлы халыкка ярдәм итәргә җибәрелгән берәр фәрештә-мазар микән? – ди...

Ә вакыт һаман үтә тора. Әсирләр Богородскидан егерме бер чакрымдагы Янапайга якынлашканда, кояш төшлеккә җитеп килә иде инде. Бүген дә көн бик эссе. Күк йөзе чип-чиста. Дөнья тып-тын. Тик еракта, Орда якларында ара-тирә туп тавышлары ишетелгәләп кенә Миңнулланың болай да борчулы күңелен тагын да ныграк борчуга сала. Тирләтә. Миңнулланың эчке күлмәге аркасына ябышкан. Тозлы тир сеңгән ул күлмәк болай да сызлап торган яраларга ышкылып, үзәкләргә төшеп авырттырып бара.

Бәлки, шушында туктап бераз ял иттерерләр дип өметләнеп килсәләр дә, әсирләргә Янапайда су да эчермәделәр. Авыл халкы, бу кемнәр, кая алып барасыз боларны, дип кызыксына башлаудан шикләнеп булса кирәк, басу капкасы төбендә үткән-сүткәнне тикшереп торучы сакчылар аларны, Янапайның урамына да кертмичә, ындыр артлатып кына үткәреп җибәрделәр.

– Димәк, бу авылда акларның хәле мактанырлык түгел икән! – диде әлеге Сәмигулла абзый Миңнуллага. – Хәлләре ару, көчләре җитәрлек булган чакта, алар, менә без кызылларны ни эшләтәбез, дип мактаныр өчен, әсирләрне юри авылның уртасыннан үткәрә торганнарые.

– Аларын ук каян беләсең, Сәмигулла абзый? Әллә аклар кулында да булганың бармы инде?

– Һы, бармы? Ничә тапкыр, дип сора син. Унберенче майда Оринбур тирәсендәге Ново-Сиргиефка дигән стансаны саклап азапланганда, Дутыф бандитлары камап алды безнең этрәтне. Унҗиде кеше иек, унҗидебезне дә берьюлы әсир иттеләр. И рәтләп сорау алып та тормастан, эшкә – акуп-траншилар казырга куштылар. Җүнләп ашату юк, ә эшне бер караңгыдан икенче караңгыга тикле эшләтәләрие. Унике көн шулай чиләндек. Ярый әле, бәхеткә каршы, ул катржаннар хезмәтеннән Блюхер этрәте коткарды. Егерме өченче майда әлеге шул Оринбурдан ерак булмаган Сырт дигән стансыда Дутыф гаскәрләрен кырып ташладылар да, безне коткарып, үзләре белән бергә ияртеп киттеләр. Аннары без ак казаклардан Оринбурны алдык. Ну, аны үз кулыбызда озак тотып тора алмадык. Май ахырында чихлар курпысы фетнә күтәреп ак казаклар белән Дутыф гаскәрләренә ярдәм итә башладылар да бишенче июльдә безне кысрыклап чыгарып, Оринбурны тагын үз кулларына төшерделәр. Шул чакта мин, бәхетсез, янә акларга каптым. Ну бу юлы алай артык тинтерәтергә җитешә алмый калдылар. Этап белән Чиләбе ягына куа башлагач, икенче төнне үк бер урманлыкта җаен туры китереп сыпырттым мин алар кулыннан! Арттан ата-ата куып караганнарые да тидерә алмадылар. Кайда нәрсә туры килә, шуның белән ризыкланып, көндез кырларда, чокыр-чакырларда посып ята-ята, төнлә-төнлә генә үзебезнең якларга кайтып җиттем. Кайтсам, бездә дә тынычлык юк, бездә дә шул аклар и фетнәчеләр дөньяны болгатып яталар икән. Мин, кәнишне, кайту белән үзебезнекеләр этрәтенә язылдым. Инде

менә тагын әсирлеккә эләктем. Менә шулай, энекәш, эшләр. Шундый хәлләрне башыннан кичергән кеше бу абзаң!

Янапайдан соң әсирләрне Уфа тракты буйлап алып киттеләр. Биш-алты чакрым баргач, юл урманга килеп керде.

– Зур урман булырга тиеш бу, – дип куйды Сәмигулла агай. – Куллар бергә бәйләнмәгән булса, качып китәр өчен бик шәп икән дә, кулларыбыз бәйле шул.

Ул бу сүзләрне акрын гына, Миңнулла ишетерлек итеп кенә әйткән шикелле иде. Ләкин яннан килүче сакчының колагы очлы икән:

– Йә, чыгыгыз әле сафтан! – диде ул татарчалатып.

Сакчы белән шаяру хәтәр эш – буйсынырга туры килде.

Шул арада колонна башында баручы атлы офицер да борылып килеп җитте һәм, кызарынып-бүртенеп, ни булды тагын, дип җикеренә башлаган иде, сакчы иплэп кенә:

– Зыян юк, менә монысы кече хаҗәтенә бик кысталган, гаспадин әфицир, – дип, Сәмигулла абзыйны күрсәткәч, артык төпченеп тормады:

– Давай, тиз генә эшен бетерсен дә – сафка! – дип, тагын алга китеп барды.

Сәмигулла абзый, чалбарын чишә-чишә:

– Әй, әүлия дә кеше икәнсең, кордаш, прәме чыдар әмәл калмаганые! – дип рәхмәт укырга тотынган иде, ләкин сакчы аңа җәелергә ирек бирмәде:

– Тик кенә тор да мине тыңла! – диде ул пышылдап кына, ләкин бик җитди итеп. – Син безнең күрше авылныкы икәнсең. – Миңнуллага ымлады: – Бу егет тә ару гына нәрсә күренә. – Колонна артыннан барган сакчыга ымлап: – Ул да минем авылдаш. Без, аның белән сөйләшеп, сезнең икегезне коткарырга булдык. Озакламый бер күпергә җитәбез. Анда урман бик куе. Шунда җиткәч, мин сезнең кулыгыздагы бауны кисәрмен дә тиз генә урманга кереп сызарсыз, яме. Мин артыгыздан сезгә тидерерлек итмичә генә ата-ата чапкан булырмын. Ә хәзер, барыгыз, сафка! Иң арттагы рәткә басыгыз да тыныч кына атлавыгызны белегез.

Сакал-мыегын тап-такыр итеп әле бүген иртән генә кырган, өстенә яшел инглиз гимнастеркасы, аягына ыштыр урап инглиз ботинкасы кигән бу сакчы агайга икесе дә күңелләреннән алдан ук рәхмәт укып, сафка барып бастылар. Икесе дә үзләрен инде иректә дип хис итә башлаганнар иде.

Ләкин аларның өмете акланмады. Күпер төбенә җитәргә берәр җир буе ара калгач, тегеләрнең ниятен сизенеп алгандай, атлы офицер чатырдап тагын колонна артына төште дә Миңнулланың яныннан гына бара башлады. Ул монда чакта сакчы агай тегеләрнең кулларын бәйләгән бауны, әлбәттә, кисә алмый иде. Бөтен өмет күпер тирәсендә, һичьюгы, күперне чыккач булса да, теге тоз күз офицерның алга китүендә иде.

Күпергә дә җиттеләр, күперне үтеп тә байтак ара киттеләр. Ләкин офицерның алга чыгарга уенда да юк иде. Әсирләр урман куелыгын үтеп, ачыклыкка җиткәч кенә колонна башына китте ул.

– Булмады... – диде сакчы агай, теге киткәч тозлап-борычлап бер сүгенеп. – Сизенде бугай теге тәре – ирек бирмәде!

**10**

Бүген августның сигезе. Миңнулла һаман исән әле. Һаман дошман кулында. Башта аларны Пермь губернасының Атыр Чишмә, Алмаз авыллары аша Уфа губернасының Бирск өязендәге Аскын авылына алып бардылар. Бик ашыктырып, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр куып алып барганнар иде. Ләкин ашыгуларының нәтиҗәсе булмады: әсирләрне Аскында кабул итмәделәр. Яңадан Пермь губернасына – Алмазга кайтардылар.

Болай арлы-бирле йөртүләренең сәбәбе соңыннан ачыкланды: Стәрлетамак, Шафран якларыннан Бирскига таба Блюхерның партизан отряды һөҗүм итеп килә икән, шуңа әсирләрне Аскында алып калырга курыкканнар. Миңнуллалар төркеменә Аскында тагын унөч әсир кушып җибәргәннәр иде, моны шулар әйтте.

Әсирләрне Алмазда бик зур бер таш амбарга яптылар. Анда аларга кадәр дә җиде әсир утырган булган икән. Шулай итеп, җәмгысы алтмышка якын җыелганнар иде. Ләкин аларны аз-азлап алып китеп бетерделәр. Аклар үзләренә окоп казырга һәм башка шундый эшләргә озаттылар булса кирәк. Кайберләрен атканнар, имеш, дип тә сөйләнделәр. Сәмигулла абзыйны да монда килгәннең икенче көнне үк алып киттеләр. «Минем ише прастуй солдатны атып ни файда аларга. Берәр авыр эшкә илтеп тыгалар инде мине. Ну мин алардан барыбер ычкынам, энем. Ә менә син нишләрсең икән?» – дип киткәндә дә үзе өчен аптырамыйча, Миңнулла өчен борчылып китте, бичара. Аны ни эшләткәннәрдер – билгесез... Ә Миңнулланы тик бер тапкыр гына чакыртып, кем идең, кайда әсир иттеләр, фәлән дә фәсмәтән дип сораштылар да шуннан бирле борчыганнары юк әле. Кичә кичтән бу келәттә ул ялгызы гына калган иде. Төнлә тагын бер кешене китерделәр. Алмаздан кырык чакрымнар тирәсендәге Чернушка тимер юл станциясе начальнигы урынбасары булган ул. Моннан бер атна элек станциягә

аклар бәреп кергән. Ә бу агай – Степан Петрович Соловьев – соңгы минутына кадәр безнекеләрне эвакуацияләү белән мәшгуль булып, качып китәргә өлгермәгән. Аклар кулына эләккән. Башта аны атып үтермәкче дә булганнар. Ләкин кем икәнен белгәч, тимәгәннәр генә түгел, күтәреп дип әйтерлек йөртә башлаганнар. Шулай булмый хәле дә юк: станция начальнигы урынбасары (ә начальнигы эвакуациягә китеп өлгергән) уен түгел ул сиңа!

Тыштан тегеләргә бик теләп хезмәт итеп йөргән атлы булган Степан Петрович. Ә үзе безнекеләр белән бәйләнештә торган: нindидер «бик җитди» сәбәпләр табып, тегеләр йөге төялгән составларны йә вакытында җибәрмәү ягын караган, яки алданрак озаткан. Һәм, билгеле инде, моның составлары «нигәдер» гел безнекеләр кулына эләгә башлаган. Шуннан аклар шиккә калган. Степан Петровичны, кулга алып, Алмазга озатканнар.

– Тагын бер генә тәүлек тегеләргә сиздермичә эшли алган булсам да, үзебезнекеләр килеп җитәчәк иде, ну, кызганычка каршы, сизенделәр шул бандитлар! – дип үрсәләнде Степан Петрович. Аннары, тынып калып, караңгы амбарда әрле-бирле нидер уйланып йөрде дә, Миңнулланы култыклап алып, бергәләп качып китәргә өнди башлады: – Монда сезне олы хаҗәткә бәдрәфкә алып чыгалар икән. Шуннан файдаланып калырга кирәк. Төнлә, беребез кысталган атлы булып, ишекне ачтырабыз да, сакчыны тынсыз итеп, шыпырт кына чыгып сыптырабыз. Мин ишек ярыгыннан карадым, монда урман якында гына икән, күп куйганда да бер чакрымнан артмас. Урманга исән-сау барып җитә алсак – котылдык дигән сүз!

Аның шулай артык дәрәҗәдә ашкынып, әле юньләп белеп тә бетермәгән кешегә серен бик тиз ачуын ошатып бетермәде Миңнулла. Моны мине провокацияләү өчен утырткannар булса кирәк дип шикләнде. Шуңа күрә, күңеленнән тегенең фикере белән тулысынча риза (ул үзе дә качып китү турында баш вата иде) булса да, тыштан битараф кыланып:

– Сез нәрсә, дөньядан туйдыгызмыни? – дигән булды.

– Туйган булсам, мин син маңканы качарга үгетләп тә тормас идем, – диде Степан Петрович, чын-чынлап Миңнуллага үпкәләп.

Миңнулла аңа амбарны төнлә бер генә сакчы түгел, ике сакчы саклавын әйткәч тә аптырап калмады:

– Ә сакчыларны сәгать ничәдә алыштыралар? – дип сорады. Миңнулла сигездә алыштыралар икәнен әйткәч, тагын да кодрәтләнебрәк китте: – Бик шәп алайса, эш пеште дигән сүз! Сигезенче яртыларда караңгы төшә башлый. Сигез туларга ун минут кала – сакчы әле ялгыз чагында – тотабыз да бәдрәфкә дип ишекне ачтырабыз. Монысын мин эшлим. Син миңа караганда яшьрәк, җитезрәк. Көчлерәк тә күренәсең. Син минем арттан атылып чыгасың да, сакчыны күз ачып йомганчы буып алып, авызына менә минем кулъяулыкны тыгасың. Тыны да чыкмый кала тегенең. Ә мин шул арада аның мылтыгын алам да кулын артка каерып бәйлибез. И – әйдә су буена! Анда елга аркылы ару гына басма бар. Шул басманы үзебезнең арттан суга алып ташлыйбыз да – урманга! Аннан кичке караңгыда эзләп табып карасыннар инде безне!

– Монысы турында уйлап карарга ярый шикелле, – диде Миңнулла. Ләкин әле һаман аклар агенты түгелме икән дип шикләнеп: – Шулай да берәр көн сабыр итәргә кирәктер, – дип өстәде.

– Юк! – диде Степан Петрович, Миңнулла белән һич тә килешергә теләмичә. – Иртәгәгә калдырсак – беттек. Акларның хәле монда көнләп түгел, сәгатьләп начарлана бара. Алар үзләре дә сәгате-минуты белән китеп барырга приказ гына көтеп торалар. Мине алып килгән сакчыларның сөйләшүеннән шулай аңлашылды. Син бер нәрсәне яхшы аңла: киткәндә үзләре белән сөйрәп йөрмәячәк алар безне. Обязательно шушында атып калдырачаклар!

Шуннан ары гына Миңнулла, ниһаять, бу агайның чынлап торып сөйләвенә ышанды һәм ул дигәнчә тәвәккәлләп карарга ризалык бирде.

Алар билгеләнгән вакытның килеп җитүен түземсезлек белән көтә башлаганнар иде инде. Ләкин максатларына ирешү мәсьәләсе бик шиклегә әйләнеп китте әле монда. Алар сүз беркетеп куюга ун минут үтте микән, сакчы:

– Соловьев, киттек! – дип, Степан Петровичны алып чыгып китте дә шуннан кайтарганнары юк әле. Кайтарырлармы-юкмы – билгесез.

Шулай да көтә Миңнулла. Ә көткәндә, үзегез беләсез, вакыт коточкыч акрын үтә. Тоткында чакта бигрәк тә! Моның шулай икәнлеген Миңнулла бик яхшы белә инде. Унбишенче елның ахырында Петербургның жандарм участогында утырып чыккан иде инде ул. Хәер эстәп көн күргән чагы иде. Ашарлык кына юнәтә иде юнәтүен. Әмма торыр урыны юк – шунысы бик тә кыен иде. Шуңа күрә, ичмаса, туйганчы бер җылыда йоклармын дип, үзе теләп эләккән иде ул. Каурыйлы эшләпә кигән бер ханымның кибетчегә сузган акчасын тартып алган иде дә шуның өчен ябып куйганнар иде аны. Анда, чыннан да, җылы иде. Туйганчы ук булмаса да, ару гына ашаталар иде. Ә барыннан бигрәк – җаны тыныч иде Миңнулланың. Тамак туйдыру өчен хәер эстәп, йөз кызартып йөрисе юк иде. Тик бер ягы гына кыен – вакыт бик акрын үтә иде анда. Ул инде анысына күнегә дә башлаган иде. Ләкин анда да озак тотмадылар. Кем син, әти-әниләрең кем, кайда тудың, дип тинтерәттеләр дә, Миңнулла, әти-

әниемне дә, туган җиремне дә белмим, хәтта чын исемемне дә белмим, дип, үз сүзендә бик каты торгач, атна тулган көнне үк, бар, үз көнеңне үзең күр, ну бүтән урлашу белән шөгыльләнмә, дип, артына тибеп чыгарып җибәрделәр...

Ә менә монда, Алмаз баеның таш амбарында, жандарм участогында яткандагы шикелле генә түгел. Монда бүген вакыт андагыга караганда мең мәртәбә акрынрак үтә. Ниләр генә уйлап, нәрсәләр турында гына хыялланып карамады инде Миңнулла! Усыда хәзер ниләр бар, анда эшләр ничек икән? Хәзер кайтып керсәң, иптәш Колчин нишләр иде икән дип тә уйланып утырды. Моннан исән-сау котыла алсам, киләчәктә акыллырак булыр идем – ерак юлга чыкканда, үзем белән кимендә дүрт-биш кешелек кораллы отряд алып чыгар идем, дип тә планлаштырып куйды… Әй, үзем дә булмаган җан шул мин, шунда Барсайга барган җирдә әтисеннән Зәйнәпне кая илтеп куйганын да сорап китә алмадым инде, дип үкенүе дә күп булды... Акылы булган кеше үз якларына командировкага чыккан чагында иң элек туган авылына, әти-әниләре янына кагылыр иде. Ә мин, юләрләнеп, башта авыл советларының хәлен үз күзем белән күреп кайтыйм дигән булып, Ильиновкаларга, Барсайларга барып йөргән булдым, дип, үзен кат-кат орышып та алды...

Ә менә хәзер үзенең бала вакытларын күз алдына китереп, шулар хакында уйлана башлады.

...Миңнуллаларның өендә әтиләре түгел, әниләре хуҗа иде. Төскә-биткә чибәр, гәүдәгә баһадирдай таза булса да, әтиләре чамадан тыш юаш кеше аларның. Яшьләй ятим калып, үз авылларының бер баенда, Галәветдин байда, башта йомышчы малай, аннары хезмәтче булып үскән. Белеме дә бик чамалы: әнисе исән чакта мәдрәсәгә бер кыш кына йөреп калган. Анда да юньләп түгел. Өс-башына рәтле киеме булмаганга, кышкы суыкларда унар көн укуга бара алмый яткан чаклары еш иде. Аннары үзе дә алай укыйм дип атлыгып тормаган булса кирәк. Нигәдер Миңнуллага шулай тоела. Эшкә дә кулы әллә ни ябышып тора дип әйтеп булмый. Җир, иген эшен, дөрес, белә, яратып эшли анысын. Әмма бүтәнгә юк инде бичараның. Хәтта ир-атларның иң пешмәгәне дә булдыра ала торган нәрсәгә – тавык чалырга да йөрәге җитми... Ә менә Миңнулланың әнисе!.. Ир-ат булып туган булса, нишләмәс иде икән ул? Әле менә шушы хатын-кыз башы белән дә... Галәветдин байның бердәнбер кызы булган ул. Шуңа бик кадердә үскән. Ни сораса, әтисе шуны алып биргән аңа. Ә кыз әллә ни күп нәрсә сорамаган: бәләкәй чагында үзе шикелле авыл балалары белән җиләккә йөргән, таш-таш уйнаган, ә исәя төшеп остабикәдән укырга өйрәнгәч, китапка хирысланган. Аның бу хирыслыгын әнисе бик үк ошатып бетермәсә дә, әтисе хуплаган. «Укысын! Укыса, остабикә булыр да кадер-хөрмәттә генә йөрер», – дигән. Кыз, чыннан да, әтисенең өметен аклар шикелле күренгән. Авылларындагы остабикә «мәктәбен»дә иң алдынгы укучы булган. Галәви агай зур расходларга төшеп, аны Петербургка хатын-кызлар гимназиясенә урнаштырырга да тырышып караган икән, ләкин нияте гамәлгә ашмаган: безнең уку йорты тик христиан динен тотучылар өчен генә, дип, кызны укырга алмаганнар. Шуннан соң Галәви агай Гайниҗамалны үзләренең кибетендә сату итәргә өйрәткән. Ә үзе сәүдә эшен тагын да киңәйтеп, төрле шәһәрләргә йөри башлаган.

«Нихәл, әтием, юлларың уңдымы?» – дип сораган кыз, бервакыт атасы Мәкәрҗә ярминкәсеннән кайткач. «Синең бәхеткә булсын инде, балам, – дигән Галәви бай, – уңды, бик уңды: үз гомеремдә күпме сату-алу итеп, бу тикле үк отышлысына туры килгәнем җугые әле», – дигән. «Әтием, – дигән аңа кызы Гайниҗамал, – эшләрең уң булып кайтсаң, мин сиңа бер бик зур үтенечемне әйтермен дип адарынып торганыем. Әйтсәм, үтәрсең микән шуны?» – дигән. «Малымның яртысыннан артыгын ук сорамасаң, үтәрмен, кызым!» – дигән әтисе. «Курыкма, әтием, – дигән кыз, – сиңнән бер тиен көмеш тә сорамыйм мин. Үзебезнең Хәлиуллага кияүгә чыгарга хәер-фатиханы бирсәң – миңа шул җиткән!»

Кызының бу сүзләрен ишеткәч, Галәветдин агай лып итеп кәнәфигә утырган да шактый вакыт теленнән язып торган. Ә теленә килгәч: «Беренче һәм соңгы кабат әйтәм, кызый, тыңла яхшылап, – дигән. – Мин сине шул уҗым бозавына муеныма пычак салсалар да бирәсем юк! Бүтән ул хакта теш агартып сүз әйтәсе булма миңа!» Кызы Гайниҗамал һич кенә дә аптырап калмаган: «Нишләргә икән суң инде безгә, әтекәем? Без Хәлиулла белән тора башлаган идек шул инде», – дигән. Аннары, болай да авызын ачып катып калган әтисен тәмам шаккатырып: «Бергә торгач, балабыз да булыр инде!» – дип тә өстәгән. Ә үзләре кая әле анда бергә тору! Хезмәтче Хәлиулланың Гайниҗамалга ул хакта сүз әйтү түгел, күтәрелеп караганы да булмаган.

Кызы белән ике араларында булган әнә шул сөйләшүдән соң Галәветдин авыруга сабып, өч көн урын өстендә яткан. Ә терелеп аягына басу белән хезмәтчесе Хәлиулланы дәштереп керткән дә, бугазлап алып: «Син чынлап ук минем кызым белән яши башладыңмыни инде, ахмак?!» – дигән. «Бүтән торыр җирем булмагач, нишлим суң инде, бай абзый», – дигән егет, тегенең ни әйтергә теләгәнен бөтенләй аңламыйча. Галәви агай исә аны бик белеп җавап бирде дип уйлаган да: «Бар, эттән туган нәрсә, хәзер үк күземнән югал! Минем йортымда бүтән эзең дә булмасын!» – дип, типкәләп чыгарып җибәргән.

Шул ук көнне байның кызы Гайниҗамал да өйләреннән чыгып китеп, алдан сөйләшеп кую буенча, сиксән яшәр бер карчыкка фатирга кергән. Ә икенче көнне кая барырга, ни эшләргә дә белмичә

каравыл өендә утырган Хәлиуллланы әлеге карчык аркылы чакыртып китергән дә болар чынлап ук бергә тора башлаганнар.

Хәер-фатиха бирү турында әйткән дә юк инде, хәтта кызын күрергә дә теләмәгән Галәветдин агай. Кайгысыннан сәүдә итүен ташлап, эчүгә сабышкан. Әмма кызның әнисе яшьләрне ташламаган. Галәви агайга сиздермичә генә тегеләргә әйберләр илткәләп, кулыннан килгәнчә ярдәм күрсәтеп торган. Шулай елдан артык вакыт үтеп киткән. Боларның беренче балалары – Миңнулланың абыйсы Зәйнулла дөньяга килгән. Шуннан соң да кызы белән киявен күрергә теләмәгән Галәви бай. Тик Зәйнулла аягына басып, урамнарга чыккалап йөри башлагач кына, ниһаять, түзә алмаган: кояш белән бергә торып, үзенең иң шәп юртагын җиккән дә өчесен дә төяп өенә алып кайткан. Ул чакта Миңнулла тик ана карынында гына булган әле.

Галәветдин бабасы белән Гайшәбикә әбисен Миңнулла төштә күргән шикелле генә хәтерли. Аңа өч тулганда – әбисе, дүрткә чыккач, кинәт кенә бабасы үлеп киткәннәр. Миңнулла аны-моны аңлый башлаган чагында, алар гаиләсендә сәүдә белән шөгыльләнүче кеше юк иде инде. Шулай да тормышлары нык иде аларның. Һәр елны кышка ике баш ат, ике сыер, егермеләп сарык калдыра торганнар иде. Болар – барысы да Миңнулланың әнисе тырышлыгы нәтиҗәсе. Әтиләре шул җир сөрү белән терлек асты чистартудан башканы белми дә, белергә дә теләми иде. «Көч белән эшли алудан тыш, адәм баласы азрак кына булса да баш белән дә эшли белергә тиеш ләбаса, Хәлиулла! Нигә шул хакта азрак уйлап карамыйсың? Нигә бер дә кешеләр белән аралашмыйсың? Нигә дөнья хәлләре белән кызыксынмыйсың?» – дип, әнисе күпме генә әйткәләп караса да, әтисе ыжлап та бирми: кайчакта бөтенләй дәшми кала, ә кайчакта: «Куйсана инде, әнисе, булмастай нәрсәләрне сорап җанны кыйнамасана инде! Кемгә кияүгә чыкканыңны алдан ук белеп чыктың бит!» – дип кенә куя да шуның белән бетерә торган иде.

Аның әнә шул тиешле урынында ир була белмәве аркасында ундүрт яшеннән укуын ташлап, бер башы чит җирләргә чыгып китәргә мәҗбүр булды да инде Миңнулла. Бабалары вафат булганнан соң сату-алу белән эш итүне ташласалар да, һәртөрле мулласыдыр, побыдыр, өяз начальникларыдыр, чуртыдыр-гуртыдыр Карыйга килгән чакларында, иске гадәтләре буенча, фатирга Миңнуллаларга туктала торганнар иде. Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә, бит пешә бит инде. Итне кызганмый торган иде әниләре. Мул итеп пешерә иде. Ә менә шул пешкән ит белән кунак сыйлап табын янында утыруны һич тә яратмый. Кунак сыйлау ир-ат эше булырга тиеш дип саный. Ә әтиләре андый чакта ничек тә бер эш тапкан булып, чыгып китү ягын чамалый да, кунакны тәрбия кылу әниләренә кала иде. Ә килгән кешеләрнең төрлесе була. Кайберсе алдан кабып кергән була, кайберсе кесәсенә берәр чәкүшкә кыстырып керә дә, бик нык туңдырды, эчкә суык үтмәсен, аш астына салып калдырыйк әле, дигән булып, табын янында сала торган иде. Ә капкан кеше, үзегезгә мәгълүм, кирәкмәгән нәрсәләрне дә лыгырдый башлый бит инде. Әнә шундый әрсез һәм ямьсез кунаклар киткәч, әнисенең:

– Сөйләшмәсәң сөйләшмә, ашамасаң ашама, ичмаса, табын янында утырсаң да ярар иде! – дип, әтиләренә үпкәләп елап җибәргән чаклары була торган иде.

Барсай бае шадра Сәйфи аларга аеруча еш керә һәм әнисенең дә, Миңнулланың да ачуын китереп, аеруча күп сөйләнә иде. Теге чакта да шулай булды. Кышын Сарашта мәдрәсәдә укып, Миңнулланың җәйге ялга кайткан вакыты иде ул. Миңнулла шуннан алып кайткан күчтәнәчләр белән чәй эчеп купканнар гына иде, әлеге шул шадра килеп керде. Кабып кергән: табак кадәр бите белән сугым пычагы җитмәслек юан муены кара-кучкылланып кызарып чыккан, хәтта теле дә билтәкләнә башлаган. Миңнулла бу кешене бүтән чакта да өнәми иде. Ә менә шундый ямьсез хәлендә килеп кергәч, ул көнне бөтенләй күралмас булды. Шуның өстенә тагын, әнисе чәй яңартып, чәй утырткач, Сәйфинең теле отыры озынаеп китте дә Миңнулланың җен ачуларын чыгарды.

– Әйдәле, абый, тотып ярыйк шушы шадра тәрене! – диде Миңнулла, урманга барырга ат җигә башлаган абыйсы Зәйнулла янына ишегалдына чыгып.

Ләкин абыйсы:

– Кит моннан, нәрсә сөйләп торасың син, төрмәгә кереп утырасың киләмени? – дип, ишетергә дә теләмәде.

Абыйсы да әтисенә охшаганрак шул аның. Юаш. Ә әтиләре өйдә юк иде. Хәер, өйдә булса да мондый эштә ярдәм көтеп булмый инде аннан. Миңнулла ни эшләргә белмичә аптырап өйләренә кергәндә, Сәйфи һаман әрсезләнүен дәвам итә иде әле:

– Шушы матурлыгың була торып, ничек яшисең син шул мокыт Хәлиулла белән? – дип лыгырдап тора. Миңнулла кече якка үткәч, тагын да ныграк йөгәнсезләнеп китеп: – Бер кочаклаттырсаң да ярты байлыгымны бирер идем мин сиңа! – дип үк ычкындырды бу.

Менә шуннан соң Миңнулланың түземе төкәнде инде. Ни кылуын үзе дә белештермичә, ботаклы башы теленмәгәнлектән кистәнгә охшап калган чыра агачын эләктереп, ул атылып олы якка чыкты да, исерек бай аны-моны абайларга өлгергәнче, шул агач белән тегенең маңгаена китереп тә орды. Бай шундук өнсез калып, сыерылып төште. Ә Миңнулла: «Менә сиңа матур хатын! Менә сиңа, шадра тәре!» – дип, тагын берничә мәртәбә тамызды да әле чыгып китәргә өлгермәгән абыйсын дәшеп кертте.

Икәүләп көчкә сөйрәп, байны ишегалдында аты җигүле торган тарантасына чыгарып салдылар. Бәладән башаяк дип, Миңнулланың абыйсы шундук урманга китеп барды. Ә Миңнулла, урамга чыгып, кеше-кара күренмәгән чакны саклап торды да, әле һаман өненә килмәгән Сәйфинең юртагын, ишегалларыннан чыгарып, Барсай ягына кайтарып җибәрде.

Ике көннән, Миңнулланы кулга алырга дип, өйләренә урядник килде. Урядникка ияреп барырга һич ярамый – төрмәгә тыгып куячаклары көн кебек ачык иде. Шуңа күрә Миңнулла, хәзер, бәдрәфкә генә чыгып керәм, дигән булып, бакча артлатып кына авылларыннан сызды.

Ачтан үлмәс өчен, ул авылдан авылга хәер эстәп йөрде. Шулай йөри торгач, Оренбургка барып җитте. Мондый кәсеп белән көн күрүчегә бер урында озак юанырга ярамый – ояты бик зур иде. Аннары ул, үзенең исәнлеген белгертеп, аның өчен борчылмаска кушып, әнисенә хатлар да язгалап тора иде. Хат салган җирдә шулай ук тоткарланырга ярамый, шул хатларындагы штемпельләре буенча эзләп табулары бар иде. Шуңа ул әнисенә хат язып салган саен икенче җиргә күчеп китәргә мәҗбүр иде. Йөри торгач, Оренбургтан Казанга, Казаннан Мәскәүгә, Мәскәүдән Петербургка барып җитте. Петербургта жандарм участогында утырып чыккач, яңадан Мәскәүгә, аннан Казанга килде.

Унбишенче елның соңгы ае кергән иде инде. Казанга килеп төшүнең икенче көнендә үк ул бер офицерга юлыкты. Юлыгу дигәнебез әлеге шул хәер эстәгәндә булды инде. Егетнең бәхетенә каршы, офицер кешелекле булып чыкты. Миңнулла бер кибет янында: «Ярдәм итә алмассызмы?» – дип торганда, офицер аны кеше күз алдыннан читкәрәк дәшеп алды да:

– Дөресен генә әйт әле, егет: шушы тазалыгың белән нигә бер җирдә дә эшләмичә хәер сорашып йөрисең син? – диде.

– Бик эшлисе дә – эш юк!

– Эш табып бирсәм, эшлисеңме?

– Ат урынына эшләр идем, абый! Ләкин мине эшкә алмыйлар бит.

– Анысы өчен хафаланма, мин әйткәч, алырлар!

Офицер Миңнулланы берничә байга тәкъдим итеп карады. Ләкин аны, документы юк дип, берәү дә эшкә алмады. Дөресен генә әйткәндә, Миңнулла үзен эшкә алмаганга сөенде генә. Эшли башласам, жандармнар табып алып, төрмәгә утыртып куярлар дип курыккан иде ул.

– Нигә болай сукбайлыкта йөрисең син, энекәш? Туган җиреңне, әти-әниеңнең кемнәр икәнен генә булса да әйт, ичмаса. Мин сиңа бары яхшылык кына телим бит! – дип, офицер бик үтенгәч, Миңнулла аңа үзенең серен ачмыйча булдыра алмады.

– Менә монысы икенче мәсьәлә! – диде офицер, куанып. – Димәк, сиңа авылыгызга кайтырга да, берәр җиргә эшкә урнашырга да ярамый икән. Алайса әйдә, риза булсаң, мин сине үзем белән фронтка алып китәм.

– Мин риза да соң, ләкин армиягә яшем җитми бит әле минем, – диде Миңнулла.

– Анысы өчен борчылма! – диде офицер. – Буең-сының килгән. Калганын үзем җайлармын мин аның.

Һәм, чыннан да, барысын да җайлады ул: Миңнуллага, 1895 елгы итеп, ягъни аны биш яшькә олыгайтып, белешмә юллап алып бирде дә аны үзе белән ияртеп фронтка китте.

Миңнулла башта әлеге офицерның денщигы, аннары адъютанты булып йөрде.

Гәрәй исемле иде теге офицер. Фамилиясе – Гарипов. Артиллерия батареясы командиры иде. Сөйләшүенә карап кына бер дә татар димәссең: русчаны су урынына эчә. Миңнулла белән дә кеше алдында гел русча сөйләшә торган иде. Русча сөйләшергә дә, русча укырга да һәм артиллерия эшенә дә Миңнулла шул Гәрәй абзыйдан өйрәнде. Ә унҗиденче ел башында Гәрәй абзый Миңнулланы үзе белән яшерен революцион түгәрәк утырышларына да йөртә башлап, сәясәткә алып кереп китте. Шунда Миңнулла партиягә керде. Февраль революциясе алдыннан түгәрәк члennарыннан унике кешене, шул исәптән Гәрәй абзый белән Миңнулланы да кулга алдылар. Ләкин суд ясарга өлгерә алмадылар: революция булды да, алар, төрмәдән котылып, үзләре хезмәт иткән частька кайттылар. Шунда аларны полк комитетына да сайлаганнар иде. Әмма Вакытлы хөкүмәт тарафдарлары кулга алу куркынычы килеп чыккач, комитет җитәкчесе аларга бүтән частька күчеп китәргә киңәш итте.

Анда да озак эшли алмадылар. Бер провокаторның чагуы нәтиҗәсендә Гәрәй абзыйны тагын кулга алдылар. Болай булса, минем дә эзгә төшәрләр дип, Миңнулла шуннан соң, армиядән качып, туган авылы Карыйга кайтты.

Язган хатлары килеп торганга (армиядә хезмәт итә башлагач, хатларны курыкмыйча яза иде инде), Миннулланың әнисе артык хафаланмаган, ләкин бик нык сагынган иде. Ә әтисе, күрше авылга тегермәнгә барып кайткан кеше белән күрешкәндәй генә итеп:

– Нихәл, малай, син дә кайттыңмыни? – дип кенә сорады да шуның белән вәссәлам.

Абыйсы Зәйнулла да әллә ни шаккатмады.

– Әле ярый авылдан чыгып качарга башың җиткән, югыйсә эшләрең харап булырые. Син киткәч, үзеңне ел буе эзләп-сагалап йөрделәр! – диде дә каядыр чыгып китте.

Әнисеннән сорашып, Миңнулла Шадра мәсьәләсен дә ачыклады. Ул имансызга пычак та булмаган. Миңнулла тукмаган көнне үк аңына килгән һәм Карыйга, волость урядникгына жалоба белән чапкан.

Миңнулла әйләнеп кайтканда, заманнар шактый үзгәргән: Карыйда һәм Карый волостена кергән авылларда патша власте вәкилләренең дәрәҗәсе шактый кимегән иде инде. Карыйга кайтып, кемнең кем икәнен аера башлагач, Миңнулла үзенә фикердәшләр туплап, халыкны байлар кулындагы җирләрне тартып алырга һәм совет оештырырга өнди башлады. Аннары күрше авыллардагы революцион фикерле кешеләр белән дә элемтә урнаштырып, агитация эшен тагын да киңәйтеп җибәрде.

Ләкин контрлар да тик кенә ятмаган иде шул. Унҗиденче елның август ахырларында, ярлы халыкны Вакытлы хөкүмәткә каршы көрәшкә оештыруда гаепләп, Миңнулланы тагын кулга алдылар. Башта аны Усыга өяз суд тикшерүчесенә илттеләр. Аннары Көңгер төрмәсенә алып барып яптылар. Унбер тәүлек шул төрмәдә утырганнан соң, үзе оештырган революцион комитет членнарыннан өч кеше, дүрт йөз тәңкә залог калдырып, Миңнулланы порукага алдылар. Шуннан соң...

Шуннан соңгысы билгеле инде: Октябрь революциясе булды. Патша самодержавиесе бәреп төшерелү турындагы хәбәр килеп җитүгә, ревком членнары белән бергәләп, моңарчы волость үзәге булган Карыйда волость советы төзеделәр. Аның председателе итеп бертавыштан Миңнулланы сайлап куйдылар. Шул көннәрдә Усыда өяз советы да оештырылган иде. Өяз советы башкарма комитетының кушуы буенча, Миңнуллага күршеләрендәге Юго-Осокино һәм Ашап волостьларында да советлар оештырып йөрергә туры килде. Аннары аны шушы елның февраль аенда өяз башкарма комитетына эшкә алдылар...

Миңнулланың уйларын бүлеп, келәт ишеге ачылды да, сакчы:

– Гайсин, әйдә, сине чакыралар! – дип кычкырды.

## 11

Степан Петровичны ни эшләткәннәрдер – анысын Миңнулла белә алмады. Ә менә ул үзе әсирлектән исән-имин котылып бара бугай инде. Миңнулла хәзер Алмаз урманында. Ябалдаш чыршы астында утыра. Урман тып-тын. Яфрак арасында тычкан кыштырдап куюын исәпкә алмаганда, шылт иткән тавыш та юк. Әйтерсең дөньядагы барча җан иясе үлеп беткән. Шомлы, куркыныч тынлык. Үч иткәндәй, җил дә исми, ичмаса. Аз гына агачларны шыгырдатса да ярар иде. Ә болай Миңнулланың сулу алганын ишетүләре бар. Аны куып килгән солдатлар нибары утыз-кырык адымда – урман буенда гына. Алар Миңнулланы сагалыйлар. Пошкырып, аяклары белән таптанып, тынлыкны бозмасыннар өчен, куа килүчеләрнең башлыгы атларын да ераккарак алып китеп торырга боерды. Ә җәяүгә калган солдатларга:

– Аның әллә кая качарлык арасы юк әле. Шушы тирәдә генә булырга тиеш ул, эзләгез яхшылап! – дип, бик каты кисәтеп куйды.

Башы эшли икән имансызның! Дөрестән дә, Миңнулланың ерак китәргә арасы булмады. Ишек ачкан сакчыны кисәк кенә касыгына төртеп тынсыз итте дә пуля урынына очты Миңнулла. Ә сакчы өненә килеп, разбуй сала-сала мылтыгыннан атарга керешкәндә, Миңнулла елга буена төшеп җиткән иде инде...

Дөрес, барысы да алдан уйлаганча шома барып чыкмады чыгуын: басманың бөтен такталарын да алып ташлап тора алмады Миңнулла. Шулай да аргы як ярдагы бер торыгын алып ташларга өлгерде. Шул аңа бик ярап куйды. Куа килүчеләр басма юклыкка аптырашып, суга сикерергә кыймыйча торган арада, Миңнулла шактый ерак китеп өлгерде һәм урманга тегеләрдән алдарак барып җитте. Ул башта, йөгерүен дәвам итеп, урман эченә үк кереп качмакчы булган иде. Ләкин аяк астында чыбык-чабыклар бик шатырдый башлагач, тукталып калырга мәҗбүр булды һәм бер яшь, ябалдаш чыршы ботаклары арасына кереп посты... Ихтимал, әлеге шул чыбык-чабыкларны, коры яфракларны кыштырдатып йөгергәндә куа килүчеләр аның кайда икәнен сизенеп, урап алган да булырлар иде. Ләкин, Миңнулланың бәхетенә, шул тирәдә генә бер тукранның бик кызып тукылдатып торган чагы туры килде. Тегеләргә аның кайда икәнен абайларга шул ирек бирмәде. Куа килүчеләр, тукраны да шул кызыллар яклы бит, дип, бик каты сүгенешеп, мылтык атып куркытканнан соң гына тынып калды ул. Рәхмәт ул изге кошка!

Миңнулла качканда сигез тулып килә иде. Хәзер тугызлар бардыр инде. Кирәк чакта, үч иткәндәй, караңгысы да тизрәк төшми бит аның. Куа килүчеләр сүгенешеп һаман урман буенда йөри. Ичмаса, ачуын китереп, тамак төбе кытыклана башлады Миңнулланың. Шулкадәр тамак кырып бер рәхәтләнеп йөткереп җибәрәсе килә – түзә торган түгел. Ничек тә чыдарга кирәк инде. Йөткерсә – бетте!.. Әһә, тегеләр янына, атын бик каты чаптырып, тагын кемдер килде. Өлкән командирлары булса кирәк – җикеренә башлады:

– Нигә урман буенда терәлешеп каттыгыз? Нигә качкынны эзләмисез? Үзе сезнең янга килеп чыгар дип көтәсезме әллә?

Тегеләре дә югалып калмады. Берсе:

– Бар, бик акыллы булсаң, үзең кереп эзләп кара! – ди. – Ләкин шуны исеңдә тот: син аны тапканчы, кызыллар үзеңне эләктереп алмасын! Әле кичә кич кенә шушы тирәләрдә кызылларның разведкачылары йөргәнне үз күзләрем белән күреп кайттым!

«Әһә, боларның үз хәлләре дә бик үк шәптән түгел икән әле!» – дип куанып куйды Миңнулла.

Тегеләр тагын бераз тарткалашып тордылар да, бәхетең инде, кызыл эт, тота алмадык, тота алсак, тереләй тунаган булыр идек, дип сүгенешеп кайтып киттеләр.

Берәрсен сакка калдырмадылар микән дип, Миңнулла алар киткәч тә шактый гомер шым гына утырды. Аннары сакланып кына урман буена чыкты һәм тимер юл ягына таба китте. Степан Петрович, кача алсак, шул якка китәрбез, безнекеләр шунда булырга тиеш, дип әйткән иде аңа...

Август аенда гына була торган тып-тын һәм салкынча төн иде бу. Агачыннан өзелеп ботакларга бәрелә-бәрелә төшкән нарат күркәсе, коры яфрак арасында нидер эзләнеп йөрүче тычкан кыштырдаулары, адәм баласы елаган аваз чыгарып, мәче башлы ябалаклар кычкырып куюы – барысы да Миңнулланы сискәндереп, сагайтып җибәрә иде. Шулай бара торгач, баягы тукран исенә төште. Бер уйлаганда, чыннан да, гаҗәп бит, тукран булып тукран кешегә ярдәм итә: Миңнулланың тормышын саклап калышты. Ә менә кешеләр, ни эшләгәннәрен аңлап эшли торган һәм аңлап эшләргә тиешле кешеләр, бер-берсен ничек үтерү өчен әллә ниләр кыланалар. Мылтыклар, пулеметлар, туплар уйлап тапканнар, кешелек акылы ирешкән иң зур нәтиҗәләрнең берсе булган аэропланны да хәзер бер-берсен үтерү өчен файдалана башладылар – бомбалар ташлыйлар. Ныклабрак уйлап карасаң, коточкыч хәл бит бу! Дөньяда иң усал, ерткыч җанварлар да бер-беренә тимиләр ләбаса! Дөрес, кайчакта бәрелешеп-сугышып алалар. Ләкин бит алар хайваннар, аңсыз җан ияләре. Кешеләр шул аңсыз хайваннардан да аңсызрак микәнни соң инде? Бер хәзер генә түгел, элек-электән бер-берләренә каршы сугышып, бер-берләрен кырышып килгән бит адәм балалары. Нигә алай икән, нидән башланды икән аларның үзара шулай дошманлашуы? Әгәр алар үзләренең бөтен тырышлыкларын, акылларын бары тик бер-беренә ярдәм итүгә, бер-беренә гел яхшылык эшләүгә генә юнәлткән булсалар, бу җир йөзендә күптән менә хәзер без төзергә тырышып йөри торган тигез хокуклы кешеләр дәүләте төзелгән булыр иде инде. Ә алар, кызганычка каршы, тарихның буеннан-буена һич кирәкмәгән нәрсәләр: бер-берен үтерү, берәүне икенче берәүгә хезмәт иттерү, берсенең илен икенчесе яулап алу белән шөгыльләнгән. Шуның нәтиҗәсендә менә дигән хан сарайлары урынында таш өемнәре генә утырып калган. Зур-зур шәһәрләр җир белән тигезләнгән. Кем өчен, нигә шулай эшләнгән бу? Нindидер ахмак ханнарның яки патшаларның нәфесен, мин-минлеген канәгатьләндерү өченме?.. Тик шуның өчен генәме? Әллә кешеләрнең табигатенә үк хасмы икән мондый явызлык?.. Юк, алай булырга тиеш түгел. Совет илендә андый хәлләр булмаячак! Тик менә аның дошманнарыннан гына тизрәк котыласы иде бит!..

Урман буйлап сигез-ун чакрым баргач, Миңнулла тимер юлга килеп чыкты да, Степан Петрович өйрәткәнчә, көнчыгыш якка – Чернушка станциясенә таба китте... Бичара Степан Петрович ничек качарга, кая качарга, кайчан качарга икәнен барысын да исәпләп-уйлап куйган иде, ә үзе шул максатына ирешә алмады. Менә хәзер алар икәү бергә булса, ничек әйбәт булыр иде! Миңнулланың бу юлдан гомерендә бер тапкыр да ни җәяүләп, ни поезд белән үткәне юк. Ә Степан Петровичка мондагы һәр шпал таныш булгандыр. Менә бит дөньяда нинди үкенечле хәлләр була. Картлар моны язмыш дип атый инде. Ә бу...

– Тукта, кем килә!

Үзенең уйларына бирелеп бернинди дә хәвеф-хәтәр көтмичә барганда, Миңнуллага кинәт әнә шулай дип кычкырдылар. Ул аны-моны абайларга өлгергәнче, кинәт җир астыннан калыккандай, юлның ике ягыннан ике солдат килеп чыкты да Миңнулланың күкрәгенә штык терәделәр.

– Кем син?

– Мин – кеше!

– Кеше икәнеңне күрәбез, син безгә шунысын әйт: акмы син, кызылмы?

– Ак та түгел, кызыл да түгел.

– Кая барасың, ни эшләп йөрисең?

– Эш белән йөрим.

– Нинди эш белән?

Төн караңгы булганлыктан, солдатларның аклармы, кызыллармы икәнлеген һич тә аерырлык түгел иде. Шуңа Миңнулла тегеләргә җавап биреп тормаска булды һәм ипле генә итеп:

– Ә ни эшләп йөрүемне һәм кая баруымны мин бары тик сезнең командирыгызга гына әйтәчәкмен! – диде.

Тегеләр артык төпченеп тормады. Миңнулланың кесәләрен тентеп, бер әйбер дә таба алмагач (аның бар булган әйберләрен Богородскида Кошкарев алып калган иде бит), кулларын артка каерып бәйләделәр. Аннары берсе шул урыннарында сакта калды, берсе Миңнулланы үзе барган уңайга – Чернушка ягына таба алып китте.

Байтак баргач уңга борып, солдат Миңнулланы урман эченә әйдәде. Тар гына сукмак буйлап дүрт-биш чакрым баргач, тирән чокыр ярына ясалган бер землянкага килеп керделәр. Землянка эчендә җиделе лампа янып тора. Идәндә өч солдат йоклап ята, ә ике солдат зуррак кешенең уч төбе кадәр генә булган өстәл янындагы бәләкәй бүкәннәрдә йокымсырап утыралар иде. Солдатлар барысы да яшел чалбар, яшел гимнастерка кигән. Утыручыларының башларында фуражка. Ятканнарының да, утырганнарының да иңнәрендә погоннары юк. Күкрәкләрендә һәм җиңнәрендә кызыл тасмалар да күренми иде. «Аклар, ахрысы, болар! Котылып кына барганда тагын килеп каптым, болай булгач!» – дип уйлап алды Миңнулла. Читләтебрәк бармыйча, тимер юл буйлап килгәненә үкенеп, үзен-үзе орышып куйды.

Йоклаучыларның берсе башлыклары икән. Аны уяттылар. Кырык белән илле арасындагы чандыррак кына гәүдәле ул агай, йокысыннан айный алмыйча, беркавым күзләрен ышкып торды. Аннары әлеге солдатлардан бушаган урындыкларның берсенә үзе утырды, икенчесенә Миңнулланы утыртты да, кем син, нишләп йөрисең төннәләтеп, дип сораштырырга тотынды. Тегеләрнең акләрмы, кызыллармы икәнен тәгаенли алмаганга, Миңнулла аңа да баягыча җавап бирде һәм үзен штабка илтүләрен таләп итте.

– Шунда мин барысын да сөйләп бирермен. Ә хәзер, гафу итегез, мин сезгә берни дә әйтә алмыйм, ярамый! – диде.

– Яхшы, – диде тегеләрнең командиры, өметен өзеп, – бу киребеткәннән барыбер рәтле сүз ишетеп булмас, ахры. Бар, Семенычка илтегез! Ул бик тиз ачар аның телен.

Миңнулланы тагын урман эчләтеп алып киттеләр. Алар ун-унбиш йортлы гына бер авылга килеп җиткәндә яктырып бетә язган иде инде. Кырый йортның ишегалдында ике солдат ат эчертеп торалар иде. Миңнулланы алып килгән кеше алардан:

– Командир тордымы әле? – дип сорады.

Тегеләр, бар, кереп кара, дип шаярып җавап биргәч, сакчы Миңнулланы өйгә алып керде. Анда тәртип ягы бик чамалы: ике өстәлнең икесендә дә кыр сумкалары, карталар, револьверлар аунап ята; берсендә тартылып бетмәгән тәмәке төпчеге пыскый; стена буенда кылычлар сөялгән... Командир дигәннәре инде торган, ләкин юынырга өлгермәгән иде булса кирәк: чәчләре тузгыган, күз кабакларының йокы шешенкелеге бетмәгән иде. Шулай да Миңнулла аны танып алды: узган ел фронттан качып кайтканда, Миңнулла белән Әгерҗедән Карыйга тикле бергә кайтып, Миңнуллаларда ике кич кунып, мунчалар чабынып киткән Лысьва кешесе Александр Семенович Колчин иде бу! «Дядя Саша, здравствуй!» – дип кычкырасы килде Миңнулланың. Ләкин тегенең акмы-кызылмы икәнен белмәгәнлектән, тыелып калды. Шул арада Александр Семенович үзе дә Миңнулланы танып алды һәм:

– Миңнулла, кадерлем, син бит бу! – дип, гимнастеркасын төймәләп тә бетермичә, кочаклап үбәргә тотынды. Икесенең дә күзләреннән шатлык яше бәреп чыкты. Аннары, берсен берсе бүлә-бүлә, узган ел Карыйда аерылышканнан бирле кайларда булулары, ниләр эшләүләре турында сорашырга керештеләр.

**12**

Теге чакта Миңнуллаларда кунып киткәннән соң, Александр Семенович Лысьвага кайтып җитә алмаган. Аны юлда тотып алганнар да яңадан фронтка озатканнар. Анда штраф ротасында немецларга каршы сугышып йөргән. Аннары тагын качып киткән. Әмма бу юлы Лысьвага кайтырга ашыкмаган. Барда тирәләренә кайтып җиткәч тукталып, үзе шикелле өч «дезертир» белән бергә, качкын булып, урманда яши башлаган. Байларның һәм сәүдәгәрләрнең малын урлап көн күргәннәр. Бер байның юлына каршы чыккан чакта, болар белән бай арасында атыш башланган да Александр Семенович шунда яраланган. Ярасы төзәлгәнче өч айга якын «эшкә чыга алмыйча» урманда, бүген Миңнулла күргән землянкада яткан. Ә иптәшләре «эш»не дәвам иткән. Акларга хезмәт итәргә теләмәгән кешеләр хисабына качкыннар төркеме һаман зурая барган. Ярасы төзәлеп «госпитальдән» чыккач, качкыннар үзләре белән җитәкчелек итүне тагын Александр Семеновичка тапшырганнар. Аклар бу якларга да килеп җиткәч, Александр Семенович үзенең егетләре белән акларның кечерәк обозларына һөҗүм итүдән дә тартынып тормаган. Шулай итеп, алар кулына кием-салым һәм азык-төлек кенә түгел, корал да эләккәли башлаган. Әнә шулай акрынлап үрчи-арта килеп, аның группасы хәзер шактый зур отрядка әверелгән. Утыздан артык атлары, ике пулеметлары, хәтта бер җиңел туплары да бар. Шактый зур районны үз контрольләрендә тоталар икән.

– Ләкин шушы көнгә кадәр Кызыл Армия гаскәрләре белән бәйләнешкә керә алганыбыз юк әле, – диде Александр Семенович. – Коралны да, кием-салымны да, хәтта азык-төлекне дә гел үзебез юнәтергә туры килә: аклар һәм контрлар хисабына яшибез.

– Бик кыен түгелме соң алай? – диде Миңнулла. – Аклардан ничек сакланасыз? Ни әйтсәң дә, алар кадровый гаскәр бит.

– Әйе, сугыш тактикасын белү ягыннан алар, чыннан да, бездән өстен. Корал мәсьәләсендә дә иркенлек аларда. Сан ягыннан өстенлекләрен әйткән дә юк инде. Ләкин без алардан куркып тормыйбыз. Безнең үз өстенлекләребез бар. Беренчедән, җирле халык безнең яклы. Икенчедән, безнең отряд җыйнак һәм бердәм: тиз генә күченеп китә, маневр ясый ала. Өченчедән, отрядтагы кешеләрнең яртысыннан артыгы шушы тирәнекеләр – урманнардагы һәр агачны ук булмаса да, һәр сукмакның кая алып барганын күз бәйләп тә белә алалар. Дүртенчедән, без тагын үзебез ише ике отряд белән элемтәдә торабыз. Менә иртәгә дә Биктанышов җитәкчелегендәге Бирск отряды һәм матрос Морзыев отряды белән бергәләп, Алмаздагы акларга налет ясап кайтырга исәп бар әле. Андагы хәлләр турында син нинди мәгълүматлар бирә аласың?

– Минем мәгълүмат белән генә әллә кая барып булмас, Александр Семенович. Анда караңгы таш амбарда ятып нәрсә күрәсең дә ни беләсең? Миңа калса, солдатлары артык күп түгел бугай. Аннары безнекеләрдән шикләнәләр дә икән. Урман буенда мине эзләп йөргән чакларында сөйләшүләреннән шулайрак сизелде.

– Куркулары яхшы. Ләкин аларның анда көчләре аз түгел. Ике батальон солдатлары бар. Кораллары да күп.

– Алай булса, ниятегез барып чыгар микән соң?

– Тәвәккәлләргә туры килә. Бөтенләй үк туздыра алырбыз дип әйтүе кыен, ну безгә алар кулындагы әсирләрне коткарырга кирәк.

– Мин соңгы әсир идем бит инде анда!

– Юк, брат! Син утырган урын бөтенләй башка, үлемгә дучар ителгәннәр арасында утыргансың син! Синең белән булганнарның күбесен атып бетергән алар. Анда тагын бер гади әсирләр төркеме бар әле. Соңгы мәгълүматларга караганда, өч йөзгә якын кеше булырга тиеш. Менә шуларны коткарырга кирәк безгә!

– Монысы – изге теләк. Монысы өчен тәвәккәлләргә була!

– Булуын булыр инде ул, Миңнулла. Тик беләсеңме нәрсә... Синең планнарың ничегрәк? Кая барырга, ни эшләргә уйлыйсың?

– Мөмкин кадәр тизрәк өязгә кайтырга иде исәп. Кайда югалды икән бу дип аптырап беткәннәрдер.

– Анысы шулай, әйе, көтәләрдер. Ләкин хәзергә анда кайта алмассың әле, дустым. Усының бу ягындагы барлык волостьлар да диярлек дошман кулында. Мин синең исән-сау кайтып җитәреңә ышанмыйм.

– Алайса, ни эшләргә икән соң миңа?

– Мин сиңа Усы өязен дошманнан чистартканчы отрядта калып торырга киңәш итәр идем.

– Мин бит әле тере мәет. Чыкмаган җаным гына бар. Зыяннан башка бернинди файдам тиячәк түгел.

– Ничек кенә тиячәк әле! Мин синең отряд комиссары вазифасын өстеңә алуны телим.

– Комиссарың юкмыни?

– Бар. Бик әйбәт кеше. Ләкин ул – рус. Ә минем отрядның яртысыннан артыгы татарлар. Бер дә русча белмәгәннәре күп. Кыскасы, миңа татар комиссар кирәк. Син кирәк миңа, Миңнулла!

– Комиссар кеше сугышчыларга һәр яктан үрнәк булып торырга тиеш. Бу хәлемдә мин аларга нинди үрнәк күрсәтә алам?

– Аңлыйм, дустым, хәлең җиңел түгел икәнен бик яхшы аңлыйм. Ләкин мин синнән мылтык тотып атакага баруны таләп итмим. Сугышчыларга Совет дәүләтенең сәясәтен һәм, шуңа бәйләп, отряд алдында торган конкрет мәсьәләләрне аңлатып бирсәң – бик җиткән.

– Башкаларга аңлатудан элек, ул бурычларны мин үзем дә юньләп белмим бит әле.

– Ленинның «Барысы да Көнчыгыш фронтка» дигән мәкаләсен укыганың бармы?

– Бар.

– Совет дәүләтен саклап калырга кирәк икәнен, ә аның өчен бөтен эшче-крестьяннар ак бандаларга каршы аяусыз көрәшергә кирәк икәнен беләсеңме?

– Беләм.

– Соң тагын атаңның башы кирәкмени инде сиңа! – диде Александр Семенович, әсәрләнеп. Һәм, бүтән сөйләшеп торырга урын калдырмаслык итеп: – Шушы минуттан үзеңне комиссар дип исәплә! Ә мин хәзер отрядны сафка тездертәм. Сине сугышчыларга тәкъдим итәм дә бераз сөйләшеп алырбыз үзләре белән, – дип чыгып китте...

Башта Александр Семенович икешәр рәт булып сафка баскан һәр сугышчыны бик җентекләп карап-тикшереп чыкты. Кайберләре янында тукталып, исемнәрен әйтеп, хәлләрен сорашты. Кайберләрен мактап алды. Кайсыларына замечание ясады. Шуннан соң «Вольно!» командасын бирде дә дүрт-биш минут чамасы речь тотты. Аның рече, нигездә, Миңнуллага бая әйткәнне тулырак итеп, шактый гына «тозлы» сүзләр дә кыстырып сөйләп чыгуга кайтып калды. Аннары ул акларның кабахәтлекләре хакында сөйләргә керешә һәм әнә шуның нәтиҗәсе итеп, сугышчыларга Миңнулланың кара көеп, тоташ кутырга әйләнеп беткән аркасын ачып күрсәтте:

– Монысы гына ничего әле, – диде ул, сүзен дәвам итеп. – Ни генә булса да, иптәш Гайсин исән-имин качып котылган әле ул бандитлардан. Ә менә аның белән бергә әсирлектә булган алтмышлап бүтән иптәшләренең барысын атып үтереп бетергәннәр! Алмазда булган бу хәл. Шул ук Алмазда хәзерге моментта нәкъ менә минем белән сезнең шикелле үк Совет яклы өч йөзләп кеше аклар кулында тоткында ята. Аларны шулай ук үлем көтә. Хәзерге моментта безнең алда торган иң изге, иң зур бурыч – әнә шул иптәшләрне ак бандалар кулыннан азат итү! Ничек кенә булса да, иртәгәдән дә калмыйча, без менә шушы бурычны үтәп чыгарга тиешбез, иптәшләр! Ә аны үтәү өчен...

Аннары Александр Семенович отряд кайчан һәм кайсы юнәлештән һөҗүм итәргә тиешлеген аңлатып бирде дә:

– Все поняли, товарищи, то, что я вам говорил? – дип сорады.

– По-о-няли! – дип җавап бирде сафтагылар.

Александр Семенович алгы рәттә торган нык гәүдәле, кап-кара кашлы, кара күзле чибәр генә бер агайны бармак ишарәсе белән үзе янына чакырып китерде дә:

– А ну-ка, Шакирзян, расскажи-ка мне, что ты понял? – диде.

– Я бит паруски низнает, товарищ командир, – диде теге.

– Менә күрдеңме инде? – диде Александр Семенович Миңнуллага. – Менә ничек «понятно» аларга. Мин сөйләгәннең яртысын да аңламады алар. Яле, үзегезнең туган телегездә сөйләп бир әле шуларга!

Миңнулла отряд командиры сөйләгәннәрне тәрҗемә иткәч, йөзләре үк яктырып китте безнең агай-эненең. Миңнулланың «аңладыгызмы» дип сораганын да көтмичә:

– Күптән шушылай чарт ярып әйтеп бирергә кирәгие аны!

– Менә хәзер төшендек, ичмаса!

– Маладис, энекәш, мең яшә! – дип кычкырдылар.

**13**

Колчин отряды авылдан кичке эңгер төшкәч чыгып китте. Алмаздагы әсирләрне азат итү операциясе иртәгә иртән генә башланырга тиеш булса да, төнлә уңайрак позиция алып, һөҗүмгә барасы урыннар белән әйбәтрәк танышып куярга кирәк дип, Александр Семенович шулай алданрак кузгалуны мәгъкуль күрде.

– Дошманның башын чабармын дип үк вәгъдә итә алмыйм. Ләкин кылыч тотарлык һәм ат өстендә торырлык кына рәтем бар. Мин дә барам! – дип сорап караса да, Александр Семенович Миңнулланы алып бармады.

– Сабыр ит, Миңнулла, өлгерерсең әле. Ә хәзер сиңа дәваланырга һәм бик яхшылап ял итәргә кирәк! – диде дә, отрядның лазаретына үзе илтеп куеп, андагы фельдшерга: – Менә бу иптәш безнең яңа комиссарыбыз! Ләкин син аңа комиссар итеп түгел, ә гап-гади авыру сугышчы итеп кара. Дәвала. Беркая чыгарма! – дип калдырып китте.

Лазарет дигәннәре авыл карчыгының алты почмаклы йортының түр ягыннан гыйбарәт иде. Анда ашыгыч кына әтмәлләп куйган биш агач карават булып, шуларның өчесендә яралы сугышчылар ята. «Госпиталь» начальнигы – чандыр гына, җитез генә, бик хәтәр итеп ике якка бөтереп җибәрелгән кара мыеклы, өстенә ак халат, башына ак кәпәч кигән һәм кыяфәтенә карап кына ничә яшьтә икәнен һич тә чамаларга мөмкин булмаган Гыйлемдар агай – Миңнулланы кырыс кына каршыласа да, ахырдан гаҗәеп әйбәт кеше булып чыкты. Үзе Оренбургныкы икән. Сугышка кадәр ат фельдшеры булган.

– Ә хәзер менә атларны гына түгел, кешеләрне дә дәваларга туры килә. Минем врачлык чамалы гына инде, энекәш, – диде ул.

Үзе турында әнә шулай артык зур фикердә булмаса да, эшнең рәтен белә икән. Миңнулланың аркасын ниндидер дарулар белән майлап җибәргән иде – җаннары рәхәтләнеп китте егетнең. Аннары:

– Мә, шушыны йотып җибәр дә төренеп ят! – дип, ясмык кадәр генә бер дару каптырган иде, Миңнулла кичке уннардан алып бер уянусыз иртәнге тугызга кадәр йоклаган.

Александр Семеновичның:

– Миңнулла, тор! Тор инде! – дип аягыннан селкетүенә уянып китте ул. Торып утырырга да өлгермәде, тегесе балаларча куанып, пулеметтан аткандай сиптерергә тотынды:

– Әйткән идемме мин сиңа, отрядтагы татар иптәшләргә мәсьәләне үзегезнең телдә аңлатып бирергә кирәк, шул чакта арысланнардай сугышачак алар, дип. Тәки шулай булып чыкты бит! Бүгенге сугышта татар дуслар ут өерде акларны! Морзыев отряды белән бергәләп, сиздермичә генә Алмаз янына ук килеп, иртәнге биштә, акларның рәхәтләнеп йоклаган чакларында «ура!» кычкырып авылга бәреп кердек тә тотындык урырга, тотындык урырга – тегеләр киемнәрен дә рәтләп кияргә өлгерә алмыйча чыгып качарга мәҗбүр булдылар. Ну мылтыкларын калдырмаган, сволочьлар! Ярый әле Алмазның көньягына Биктанышов отряды засадага куелган иде. Ну кызык хәлләр булган соң анда. Аклар Алмаздан чыгып кача башлагач, Биктанышовныкылар да эшкә керешмәк булып күтәрелгәннәр икән, тегеләрнең командиры:

– Братцы! Безгә ярдәмгә киләсезме? Әйдә, тизрәк булыгыз, югыйсә эшләр харап! – дип, боларга үзе каршы чыккан.

– Әйе, – дигәннәр аңа, – сезгә ярдәмгә киләбез. Яле, ташлагыз әле коралларыгызны да күтәрегез әле кулларыгызны! Каршылык күрсәтергә маташудан файда юк, сез – чолганышта!

Ак сволочь ак сволочь булып кала шул инде. Шунда да солдатларына:

– Бирелмәскә! Ятарга һәм соңгы сулышка кадәр сугышырга! – дип кычкырган теге паразит һәм револьверыннан безнекеләргә атарга тотынган.

Ну, эш алайга киткәч, билгеле инде, Биктанышовныкылар шундук тынсыз иткән тегене. Шунда бер уңайдан каршылык күрсәтергә маташкан солдатларын да хәл иткәннәр.

– Ә әсирләрне коткара алдыгызмы соң? – диде Миңнулла, түземсезләнеп.

– Ничек кенә коткардык әле! Берсенә-бер кагылырга өлгерә алмый калды аклар. Конюшняның ишеге бикле иде, ачкычын, күрәсең, качканда сакчы үзе белән алып киткәндер. Ишекне үз кулым белән ватып ачтым да:

– Хәзерге минуттан сез ирекле, иптәшләр! Дүрт ягыгыз кыйбла: кая телисез – шунда китә аласыз! Кемнәр коткарды дип сорасалар, Колчин отряды кызылгвардиячеләре коткарды, диярсез! Шуннан башка без сездән берни дә таләп итмибез! – дидем.

Колчакчылар шултикле куркытып, өннәрен алып бетергән бичараларны – әсирләр башта аптырап, ышанмыйча тордылар. Тик, каным кызып китеп:

– Ике минут эчендә урамга чыгып тезелмәсәгез – яхшылык көтмәгез! – дип кычкыргач кына, урамга чыгып тезелделәр. Санаткан идем – ике йөз дә илле җиде кеше булып чыкты.

– Бүтәннәрегез кая, сез бит болай гына булырга тиеш түгел идегез? – мин әйтәм.

– Кичә кичтән утыз икебезне каядыр алып киттеләр, – дип җавап бирделәр.

– Ярый, – мин әйтәм, – монысы аңлашылды. Инде хәзер, барыгыз, таралыгыз – сез ирекле.

Ышанасыңмы, Миңнулла, ник берсе урыныннан кузгалып карасын тегеләрнең! «Без беркая да китмибез, китеп тагын аклар кулына эләгәсебез килми! Давай, ал безне үзеңнең отрядыңа, командир!» – диләр.

– Шуннан?

– Шуннан нәрсә? Миңа аларны отрядка алудан ни мәгънә? Үзләре ябык, хәлсез, үзләренең ни юньле киеме, ни коралы юк. Шулай булгач, мин аларны отрядка алып нишлим? Сәяси-тәрбияви яктан чыгып караганда, аларның үз илләренә, үз өйләренә кайтып китүләре отрядта калуларына караганда күп мәртәбә файдалырак бит!

– Сез моны нәрсәне күздә тотып әйтәсез? – диде Миңнулла, тегенең эшне кая таба борганын төшенеп җитмичә.

– Ул әсирләрнең ике йөз иллесе, кайбер авыллардан яки шәһәрләрдән икешәр-өчәр кеше булган дип исәпләгәндә дә, кимендә йөзләп авыл һәм шәһәргә кайтырга тиеш, шулаймы?.. Шулай. Ә кайткач, алар аклар турында ничек дип сөйләячәк тә аларны үлемнән коткарган без кызыллар турында ни дип сөйләячәк? Совет властен яклап, аңа ярдәм итәргә кирәк дип сөйләүче менә дигән агитаторлар булачак бит алар!

– Карале, чыннан да шулай икән ич! – диде Миңнулла, тегенең белән килешеп. Аннары сорады: – Соңыннан нишләде ул иптәшләр, кайтып киттеләрме?

– Тәмам интегеп беттем бүген мин алар белән. Сырып алдылар да һаман, отрядыңа яз да, отрядыңа яз, диләр. Берсе-бер китәргә теләми. Нишләргә хәзер? Уйладым-уйладым да тегеләрне ике рәткә тезеп, яшьрәк-егәрлерәкләрен, безнең авыр шартларда да бирешмичә сугыша алырдайларын сайлап алдым. Утыз тугыз кеше булды андыйлары. Ә калганнарына, гафу итегез, иптәшләр, башкаларыгызны алырга һич тә мөмкинлегем юк, дидем. Шуннан соң да күбесе китәргә теләмичә, мине генә ал инде, диешеп торалар иде әле. Ну, бәхеткә каршы, шул чакта отрядның бер отделениесендәге егетләр дошманның биш олавын эләктереп алып килделәр. Йөкләрен чишеп карасак, берсендә безгә әҗәл даруыдай кирәкле патроннар, ике йөге – пешкән икмәк, ә калган ике йөгендә өр-яңа солдат мундирлары белән солдат ботинкалары! Үзең беләсең, минем отряд егетләренең киемнәре алай зарланырлык түгел. Ә артык әйбер төяп йөрүнең безнең эше күчмә халыкка шулай ук хаҗәте юк. Шуңа күрә тоттым да киемнәрне әлеге әсирлектән котылган кешеләргә өләшергә куштым.

– Барысына да җиттеме?

– Гимнастеркалары белән чалбарлары җитте, хәтта азрак артып та калды әле. Тик ботинкалары гына җитеп бетмәде. «Ну анысы өчен бигайбә инде, иптәшләр, – дидем мин аларга. – Заказ биреп кайтарткан әйберләр түгел. Ә хәзергә сау булыгыз! Исән-имин генә өйләрегезгә кайтып җитүегезне телим! Отрядыңа алмадың, дошманнарны кыйный алмый калабыз инде дип бер дә борчылмагыз. Совет властеның дошманнары тылда да, кызганычка каршы, җитәрлек әле, шулар белән көрәшегез!» – дидем. Аннары, юлыгызга булыр дип, теге ике олау икмәкне бүлеп бирдерттем. Тик шуннан ары гына таралыштылар.

– Кызганыч, мин шуларның берсен дә күрә алмыйча калдым бит, – диде Миңнулла, үзенең авыру булуына үкенеп.

– Анысы, әйе, чыннан да кызганыч, – диде Александр Семенович, аның белән килешкәндәй итеп. – Ә шулай да бу җиңүне җиңел аягың белән син алып килдең безгә! Моңарчы күпме бәрелешләрдә булып, бу кадәр зур уңышка ирешкәнебез юк иде әле. Ә үзең катнаша алмаганга артык хафаланма. Дошманның тиз генә бирелергә исәбе юк әле анда. Киресенчә, һаман совет властен кысрыклап килүен дәвам итә. Сугышырга өлгерерсең.

## Икенче бүлек

### 1

Ләкин Миңнуллага ныклап торып сугышырга язмаган икән. Ул – егерме өч тәүлек буена дошман кулында, типке астында яшәгәндә бирешмәгән кеше – Колчин отрядында комиссар вазифасын үти башлагач, тәнендәге җәрәхәтләре инде төзәлеп килүгә һәм ашау яклары да аруланууга карамастан, көннән-көн ябыга, хәлсезләнә барды. Ә иң яманы шул: еш кына кан төкерә башлады. Бу, әлбәттә, Кошкарев белән «дустанә сөйләшүләр», таш амбарның җир идәнендә тәүлекләр буе һушсыз ятулар нәтиҗәсе иде. Моның шулай икәнлеген Миңнулла үзе дә яхшы белә. Ләкин ул, Колчин бу егет сугыштан шүрле икән, тылга китәсе килә икән моның, шуңа авыру булып кылана дип уйламасын өчен, сер бирмәскә, сәламәт булып күренергә тырыша иде. Шулай ул дошман белән бәрелештә бер катнашты, ике катнашты, өч катнашты. Ихтимал, әле алга таба да шулай дәвам иткән булыр иде, ләкин беркөнне Колчин аны «җинаять» өстендә тотты.

Шактый озак тартышканнан соң, ниһаять, унбер генә йортлы бер авылны аклардан азат итеп, шунда ялга туктаганнар иде. Мондый киеренке вакыйгалардан соң хәле тагын да кыенлашасын белеп, Миңнулла фатирга ялгыз гына урнашты. Азрак ял итеп алырга дип яткан гына иде, Колчинның адъютанты килеп керде:

– Әйдәгез, иптәш комиссар, Александр Семенович минуты белән килеп җитәргә кушты!

Акларның бер мичкә самогонын кулга төшергәннәр икән. Колчин азрак татып та караган иде булса кирәк, болай да түгәрәк тулы йөзе тагын да тулышып, алсуланып киткән. Миңнулланы да килеп керү белән кыстый башлады. Нишләсен, ул да азрак авыз итеп куйды. Ләкин кызмача кешедән тиз генә котылып буламыни?

– Шушы стаканыңдагыны бетереп куймасаң, мин синең белән бүтән сөйләшмим дә! Атакага барганда алда идең бит, шулай булгач, монысын да ялт иттереп куярга тиеш син! – дип, чәер урынына ябышты теге.

Бәлки, командир хаклыдыр, бәлки, авыруыма сихәте тияр дип, Миңнулла да тәвәккәлләгән иде, шундук күңеле болганып, укшыта башлады. Миңнулла тиз генә ишегалдына чыкты һәм гөрләтеп кан косып җибәрде. Ул арада Александр Семенович та чыгып җитте һәм, егетнең хәлен күреп, исе китеп торды. Аннары әйтте:

– Син, Миңнулла, минем үзем өчен дә, отряд өчен дә бик кадерле, ифрат дәрәҗәдә кирәкле кеше! Отрядка син килгәч, ярты кайгым беткән иде минем. Халыкны ышандырып, ялкынлы итеп сөйли аласың. Сүз белән генә түгел, сугыш вакытында да үрнәк күрсәтәсең аларга. Ләкин, шулай булса да, мин сине менә шушы минуттан комиссарлыктан азат итәргә тиеш булам, кадерлем. Хәлең бик шәптән түгел икәнлеген моңарчы да сизенә идем. Әмма үтәр әле дип уйлый идем. Ә синең эшләр әнә кая ук барып җиткән икән! Тыныч җирдә, урынга ятып дәваланырга кирәк сиңа, егет!

Миңнулла, зыян юк, үтәр, эчкәннеке генәдер бу, сез мине бөтенләй үк сызып ташларга җыенмагыз әле, Александр Семенович, дип караса да, Колчин эшне бик кызу тотты:

– Мин – коммунист, иптәш Гайсин, күрә торып кешене үлемгә дучар итәргә минем хакым юк! – диде дә, ун кешелек атлы отряд биреп, Миңнулланы икенче көнне үк Усыга озаттырып куйдыртты.

### 2

Эш сәгате инде күптән чыккан булса да, өяз башкарма комитеты председателе Емельян Петрович Колегов кайтып китмәгән иде әле.

– Ниһаять, кайттыңмы, иптәш Гайсин! – диде ул, куанып. – Сине эзләтә-эзләтә чәчләр агарып бетә язган иде инде монда! Берсе әйтә, исәндер ул, ди. Икенчесе әйтә, үтергәннәр аны Воскресенскида, үтергәннәрен үз күзләре белән күрүчеләр булган, ди… Әйдә, әйдә, якынрак килеп утыр да сөйлә әле: кайларда булдың, ниләр күрдең, ничек исән калдың?..

– Ярый, ничек булса да булган, иң мөһиме шул – үзең исән-сау әйләнеп кайткансың! – диде ул, Миңнулла аңа башыннан үткән хәлләрне сөйләп биргәч. – Ну шулай да мин бер нәрсәне һич тә аңлый

алмыйм: теге чакта йә Карый, йә Ашап волкомыннан отряд алмыйча, нигә башта Барсайга ялгыз гына барасы иттең син?

– Волкомга караган авыллардагы хәлләрне үз күзем белән күреп кайтмак булган идем, Емельян Петрович.

– Юк, минемчә, син нәрсәнедер яшерәсең монда! Күзеңнән күреп торам – яшерәсең!

Эшләр болайга киткәч, Миңнулла серне ачарга, Зәйнәп турында сөйләп бирергә мәҗбүр булды.

– Менә монысына мин ышанам! – диде Емельян Петрович. – Үзем дә шундыйрак бер нәрсә түгел микән дип уйлаган идем аны. Эх, егет, егет! Яратам дип, хатын-кыз артыннан йөри торган заманмы соң хәзер? Ил күләмендә генә түгел, бөтен дөнья күләмендә буржуйларга каршы иң кискен көрәш барган хәзерге вакытта гына түгел, тыныч заманнарда да менә дигән ир-атлар харап булган лабаса шул мәхәббәт дигән чир аркасында. Хатын-кызның итәге киң аның, энем, аңа барысы да сыя. Тарихка гына күз сал азрак: күпме сугышларның башы шул хатын-кызларга барып тоташа! Күпме байлык туздырылган, күпме халык кырылган, күпме балалар ятим калдырылган, күпме патшалар тәхетләреннән колак каккан шул ярату дип атала торган йөгәнсез хис аркасында! Инде килеп, менә син... Шулай башсызланып йөрергә ярыймы соң инде синең шикелле җаваплы эштә эшли торган кешегә! Уком председателе урынбасары лабаса син, Гайсин!

Рәхмәт көтмәгән иде Миңнулла. Ләкин бу агай мәсьәләне болай тирәнгә алып кереп, тарихка һәм сәясәткә үк китереп терәр дип тә уйламаган иде. Шулай да бирешергә теләмәде.

– Тарихта сез әйткәннәрнең киресен раслый торган мисаллар да аз түгел, Емельян Петрович.

– Мәсәлән?

– Мәсәлән, теге сез әйткән зиннәтле сарайларның җимертелүе генә түгел, салдырылуы да шул ук мәхәббәт дигән нәрсә белән бәйләнгән бит. Аларның күбесе хатын-кызлар хөрмәтенә, хатын-кызлар истәлегенә яки шуларга атап салынган!

Миңнулланың бу җавабына каршы куярлык дәлиле юк иде булса кирәк, Емельян Петрович нервланып ишекле-түрле йөренеп алды һәм, ныклап ук ачулана башлап:

– Син, егет, мине андый юк-бар белән бутарга маташма! – диде. – Үзең уйлап кара азрак: күпме көч, күпме кан түгеп яулап алынган революция язмышы кыл өстендә торган хәзерге вакытта башкалар да, менә шушылай синең кебек, дөньяларын онытып, яраткан кызы артыннан чаба башласа һәм дошман кулына синең кебек барып каба башласа, кая китәр ул аннары? Кем сугышыр ул дошманга каршы, кем саклап калыр совет властен?

– Ярар ла инде, Емельян Петрович, очраклы гына килеп чыккан бер нәрсәдән әллә нинди зур нәтиҗәләр ясамагыз, зинһар. Сүз дә юк, мин гаепле. Гаебемне таныйм һәм кичерүегезне сорыйм. Ләкин шунысын да әйтми кала алмыйм: әгәр әнә шул Барсай кызын яратмаган булсам, аклар шул тамаша кыйнаганда мин, ихтимал, түзә алмаган булыр идем!

– Йа Рабби! – диде Емельян Петрович, аптырап. – Ул әле һаман бернәрсә дә аңламаган икән! Ну, егет, әгәр бүтән чакта шушылай сөйләнеп утырсаң, билләһи дип әйтәм, минут та тотмыйча берәр атнага каталажкага ябар идем мин сине! Кызганычка каршы, вакыты андый түгел. Син миңа менә болай, – ул муенына баш бармагы белән аркылы сызып күрсәтте, – кирәк хәзер! Шуңа гына кичерәм мин сине. Ә хәзер, давай, конкрет эшкә күчик...

Емельян Петрович өяз башкарма комитеты аппаратларындагы хәлләрне аңлатып бирде. Миңнулла «командировкада» йөргән арада анда да шактый үзгәрешләр булган икән. Кайбер иптәшләр үзләре теләп фронтка киткән. Кайберләрен эшләрен тиешенчә алып бара алмаганга азат иткәннәр. Ә берсе теге сатлыкҗан Михайлов белән аклар ягына сызган.

– Шулай да хәзер эшләр ярыйсы инде, – диде Емельян Петрович. – Тик менә үземә урынбасар итеп куярлык кешене генә таба алмыйча йөри идем әле. Синең кайтып төшүең бик тә яхшы булды. Давай, иртәгәдән үк шул постка җигел дә йөкне бергәләп тарта башларбыз!

– Андый эшне эшләрлек хәлем булса, Колчин отрядыннан да китәсе түгел идем мин. Сәламәтлекнең рәте китебрәк тора шул, Емельян Петрович. Кимендә ун-унбиш көн ял кирәк миңа. Шуңа күрә үзебезнең авылга кайтырга да эти-әни тәрбиясендә булып, азрак рәткә кереп килергә иде исәп.

Петрович, күңелсезләнеп китеп, берәр минут чамасы уйланып торды да:

– Революция язмышы хәл ителгән бу көннәрдә безнең җиңүне теләгән бер генә кеше дә авырырга тиеш түгел! – диде. – Ә коммунист кеше, иптәш Гайсин, бигрәк тә!

– Барысын да бик яхшы аңлыйм, Емельян Петрович. Ләкин сез дә мине аңлагыз: хәлем әйбәт түгел минем.

Өстәлдә яткан кызыл йолдызлы фуражкасына карап, Петрович беркавым уйланып утырды. Аннары, кинәт кенә дәртләнеп китеп:

– Яхшы, – диде. – Алайса, син дигәнчә эшлибез. Урынбасар мәсьәләсен хәзергә ачык калдырып торабыз. Ә син иртәгә үк үзеңнең Карыеңа кайтып китәсең. Шунда ял итәрсең, дәваланырсың. Ләкин шул ук вакытта кайбер эшләр белән дә шөгыльләнергә туры килер. Мәле, тот әле кулыңа каләм белән

кәгазь дә язып бар әле ниләр эшләргә кирәк булачагын. Башладык: а) Карый волостена караган авылларда партия ячейкалары төзергә; б) җирле халыктан кызылгвардиячеләр отрядлары оештырырга; в) волость хәрби комиссариаты төзергә; г) фронтка кешеләр мобилизацияләүне оештырырга; д) комбедларга продналог җыюда ярдәм итәргә. Булдымы?

– Булуын булды да, Емельян Петрович, ләкин мин боларның... – дип, Миңнулла авыз ача башлаган иде дә тегесе:

– Ярый, Гайсин, иртәгә бәйрәм түгел, кайтыйк инде, – дип, сүз озайтып торырга юл куймады һәм: – Сау бул! Ә иртәгә секретарь килгәч, мин сиңа вәкаләт мандаты яздыртып бирермен, – диде дә, кайда туктадың, кереп кунар җирең бармы, дип сорарга да онытып, кайтып китте.

Миңнулла исә кичкырын кеше борчып йөрергә арусынмады, өяз кызылгвардиячеләр отряды штабына барып кунды.

**3**

Карый волкомында хәлләр шәптән түгел икәнлеген Емельян Петрович сүзләреннән үк сизенгән иде Миңнулла. Әмма андагы эшләр ул көткәнгә караганда күп мәртәбә мөшкелрәк булып чыкты.

Теге чактагы шикелле көтелмәгән күңелсезлекләргә юлыгып, тагын әти-әнине күрми калмагаем дип, Миңнулла бу юлы Карыйга, туп-туры өйләренә кайтып керде. Әтисе дә, әнисе дә өйдә иделәр. Әтисе, гадәтенчә, бер дә алай исе китмичә генә каршы алды:

– Син дә исән икәнсең әле, улым, нихәл? – дип кул биреп күреште дә, эше шуның белән беткәнгә санап, шыпырт кына сәкегә барып утырды.

Ә менә әнисе, бичара, ни эшләргә белмәде инде! Башта:

– Әй, балакаем, әй, җанкисәгем, исән икәнсең ләбаса! Исәннәр генә икәнсең, күз нурым! Сине Бугурутскига апкитеп атып үтергәннәр, имеш, дип котларыбызны алып бетергәннәрие бит безнең! – дип, дөньядагы бар кешенекеннән дә йомшак җылы куллары белән Миңнулланың битләрен, киемнәрен сыпыра-сыпыра, сөенеченнән бер елап алды. – Кайларда гына булдың, ниләр эшләттеләр сине, бала: коры сөяк белән тирегә генә калгансың ич! Кай җиркәйләрең авырта? Бигрәкләр бетерешкәнсең бит! – дип, кайгырып, икенче тапкыр елады. Шуннан соң, әй, үзем дә инде, онытылып утырам икән, каяле, чәй куеп җибәрим әле, дип, самавырга тотынды. Үзе шунда, эш арасында, Миңнулланың кайларда булганын инәсеннән җебенә хәтле сораштырырга да онытмады. Аннары үзләрендә булган хәлләрне сөйләргә кереште:

– Алланың каһәресе генә төшсен инде, улым, акларына да, байларына да. Шулар болгата бөтен дөньяны. Менә әле атна-ун көн элек кенә безнең дә котларыбызны алып, теңкәләребезгә тиеп беттеләр. Теге Чирканды мулласының малае Хәйрулла дигән нәрсә җиде төн уртасында дүрт мылтыклы кеше ияртеп керде дә, бер каммуныңның башына җиттек, икенче каммуның кая, дип, Зәйнулланы таптырырга тотынды. Ярый әле шуннан ике көн алдан гына абыең фрунтка язылып китеп барганые. Мин тегеләргә, кайда икәнен белмим, сугышка алып киттеләр аны, дигәч, әлеге шул Хәйрулла дигәне, әһә, анысы да сәвитләрне яклап сугышырга киттемени, дип, тешләрен ыржайтып килеп, яңагыма чапты. Аннары, малайларыңның байларны талап җыйган алтыны кая, дип дупрусларга тотынды. Безнең өйгә андый нәрсәнең кергәне дә жук, нахак сүз сөйләп гөнаһлы булма, дигәч, малайларың гына түгел, син үзең дә камунист, ахры, җен карчыгы, дип җелегемә тиде. Аннары бер сарыгыбызны суйдылар да итен үзләре белән алып киттеләр. Йөрәк-бавырларын да калдырмадылар.

– Абыйга ник бәйләнә соң алар, әни? Коммунист түгел иде бит ул.

– Камунист булды шул инде ул да. Сине үтергәннәр дип ишеткәч, аның урынына үзем калам дип, камунист булганые. Һәй, улым, безнең Карыйдагы хәлләрне белсәң син!

– Ниләр булды тагын, әни?

– Ярар, сөйләп кенә бетерә торган түгел ул. Вулкумга баргач, үзең күрерсең, тикшерерсең әле. Әйдә, дөнья хәлләрен куеп торып, һәйбәтләп бер чәй эчик әле башта. Синең өчен кайгырып инде кайчаннан бирле җүнләп чәй дә эчкәнем жугые.

**4**

Миңнулла волком бинасына барып кергәндә, барлык бүлмәләр дә шыр ачык һәм буш, тик ишегенә «Председатель» дип язганында гына сакалын ялт иттереп кырган, башына колакчын бүрек кигән бер агай, дөньясын онытып газетага текәлеп, өстәл янында утыра иде. Миңнулла кергәнне әллә сизмәде, әллә сизмәгәнгә салышты – күтәрелеп тә карамады. Тик Миңнулла юри каты итеп икенче тапкыр сәлам биргәч кенә, ниһаять:

– Безнең хәлләр ничава. Әмма моңарчы безгә ишек шакып керә торганнарые! – диде. Ләкин Миңнулланың комиссарлар кия торган күн тужуркадан, бил каешына наган тагылган икәнен күргәч, кинәт йомшара төшеп: – Әйдә, түргә уз! Сине кем дип белик, кайдан килеш? – дип тезеп китте.

Урыныннан торып, өстендәге брезент кожанын рәтләгәндәй итте. Кожан эченнән пинжәк кигән, пинжәген каеш белән буган һәм шул каешына кылыч тагылган иде. «Волком дежурные булса кирәк», – дип уйлап алды Миңнулла.

– Мин шушы авыл егете. Өяздән килдем. Исемем – Миңнулла. Фамилиям – Гайсин. Ә сез үзегез кем буласыз?

– Безме?.. Кая, дукумитыңны күрсәт әле, энекәш.

Миңнулла үзенең Карый волостена өяз вәкиле буларак андагы эшләрнең торышын тикшерергә җибәрелүен, кирәк очракта хәтта волком составын үзгәртергә дә вәкаләте булуын раслаган мандатын сузды.

– Рәхим итегез!

Агай бик зур дикъкать белән, ләкин хәрефләрне йөзтүбән тотып «укый» башлады. «Шыр надан, ахрысы! – дип уйлап алды Миңнулла. – Кем икән соң бу?»

– Тәк, – диде агай, мандатны «укып» чыккач. – Пунятны. Значыт, уязни кәмиттән килгән иптәш буласың икән? Бик хуп, бик хуп, әйдә, түргә уз. Зерә дә кирәк чакта, зерә дә вакытында килеп төштең бит әле син! Әтү безнең эшләрнең рәте-чираты китеп, эт – баш, сыер аякка әйләнеп барадырые монда. Фамилияңне ничек дигәниең әле?

– Гайсин. Ә сез үзегез кем буласыз соң?

– Безме? Без, иптәш Гайсин, шушы Карый авылыныкы Сабитов Сәгыйдулла булырбыз.

– Мин сезне нигәдер белмим, Сәгыйдулла агай?

– Белмәвең гаҗәп түгел, беләм, дисәң гаҗәп булырые. Күп еллар читтә йөргән кеше мин. Кайтуыма ике ай да тулмаган әле.

– Кайда идегез?

– Баку якларында. Нефте эшендә чиләндем.

– Нигә кайтасы иттегез соң?

– Туган илемне сагынып кайттым.

– Ә волкомда кем булып эшлисез?

– Кучер булып эшләгәнием. Ну пука вулкум персидәтеле урынында эшләп торырга туры килә әле.

– Ә председатель үзе кайда?

– Аклар ягына сызды ул.

– Кайдан беләсез? Сезгә әйтеп киттемени кая барасын?

– Әйе. Мине дә үзе белән китәргә кыстаганые. Ну мин бармадым.

– Нишләп?

– Какуй интирис миңа симияне, бала-чагаларны ташлап, әллә кемнәргә ияреп йөрергә? Болай да өч ел чегән тормышында яшәттем инде ул бичараларны.

– Кем иде соң ул председатель?..

Сораша торгач, Миңнуллага мәнә нәрсәләр мәгълүм булды: июль ахырларында Советка каршы элементлар Карыйда фетнә күтәргәннәр дә элекке волком председателен атып үтергәннәр икән. Волком членнарыннан өч кешене кулга алып, каядыр озатканнар. Өяздән отряд китереп ул фетнәне бастыргач, волком аппаратын яңадан оештырырга туры килгән. Әмма әлеге шул контрларның тырышлыгы белән аның составына күбесе Советка каршы кешеләр кертелгән. Председатель итеп билгеләнгән Шәйхелислам Шәйхетдинов белән секретарь итеп билгеләнгән Гарифулла Таҗиевлар, эшли башлауларының беренче көннәреннән үк контрлар коткысына бирелеп, шулар мәнфәгатен кайгырта башлаганнар. Ә менә хәзер, бу якларга кызыл гаскәрләр якынлашып, тегеләрнең артларына су керә башлагач, волком эшен ташлап, тәннәләтеп аклар ягына сыптырганнар. Волость идарәсе комиссары шулай ук аларга ияреп тайган. Менә шул хәлләрдән соң, бөтенләй үк хуҗасыз булып тормасын дип, волком председателе вазифасын Сәгыйдулла агай үз өстенә алган да кулыннан килгәнчә эш итеп торган көне икән.

– Сез партия членымы?

– Түгел. Теләктәш ләкин. Партиягә керергә исәп бар иде дә, укый-яза белмисең дип, алмадылар.

– Минем мандатны укыдыгыз бит.

– Мин болай гына, фурмысы килсен өчен генә укыган атлы булдым.

– Председательлек итү читен түгелме соң?

– Бу заманда кемгә җиңел инде ул, энекәш. Кыен булса да, түзәргә туры килә.

– Кайчаннан бирле председатель инде?

– Бүген атна була.

– Ниләр эшләдегез шул бер атнада?

– Шәйхеттинев заманында, фронтка кешеләр җыйнап җибәрергә кушып, өяздән кәгазь килгәние. Авылларга шул хакта күрсәтмәләр җибәрдем. Аннары авыл ярлылары кәмитетләренә прутналук җыярга кушып хәбәр иттердем.

– Ничек соң, үтиләрме күрсәтмәләрегезне?

– Бик алай ашкынып тормыйлар шул үтәргә. Бер кеше дә, бер олау икмәк тә җибәргәннәре юк. Миннән һаман сорашасың да сорашасың, үзеңнән дә сорыйм әле: син үзең нинди эш белән чыккан кеше соң? Әллә шул прутналук белән мибилизация буенча йөрүме?

– Алар белән дә кызыксынам. Эшлисе эшләр күп иде, Сәгыйдулла агай, ләкин кайдан башларга аптырабрак калдым әле.

– Әгәр син безгә ярдәм итеп, безнең эшне юлга салырга дисең икән, иң башта син минем автарититны күтәрү чарасын уйла. Иң башта Карый халкы да, вулыс авылларындагы халык та мине персидәтел итеп танырга тиеш! Югыйсә минем белән исәпләшергә теләмиләр. Бүтәннәре турында әйтеп тә тормыйм инде, хәтта хатынга тикле, синнән персидәтел чыкканчы, кызыл кар явар, шайтан да кушмаганга йөрмә куштаннанып, дип, нирбыга тия. Менә шуның авызын томалар өчен дә, бүтәннәрне ышандырыр өчен дә миңа бик һәйбәт кенә пичәт кирәк булыр.

– Волкомның печате булгандыр ич. Кая соң ул?

– Кая булсын, әлеге шул Шәйхеттинов апкиткән инде. Син мине тыңлап бетер әле. Аннары килеп, вулкумда палитаттил, зиматтил, прутаттил вә һәм шуның ише башка аттиллар да булырга тиешле бит инде. Шуларны да тергезеп җибәрергә туры килер.

– Алары шулай. Ләкин, укый-яза белмәгәч, председатель булып эшли алырсыз микән соң, агай? Бик мәшәкатьле эш бит ул.

– Камунист түгел дип кенә әйтмәсәң, анысы өчен хафаланма, энекәш. Башы эшләп, сиклитары әйбәт булган нәчәнниккә уку-язуны белүнең алай артык кирәге юк аның. Дукумитларга кул куя белсә, шул җиткән.

– Ә секретарь итеп кемне алмак буласыз соң?

– Алып торасы юк, эшли инде ул.

– Кем ул, кайда?

– Үземнең малай. Йомыш белән бер җиргә генә җибәргәнием әле.

– Русча укый-яза беләме?

– Әйе.

– Кайда укыган иде соң ул?

– Кайда дип, алай мәптекләргә йөреп үк укыганы булмады булуын. Тегендә, нефте чыгара торган җирдә, урысы-татары бергә яшидерие. Урыс малайларыннан өйрәнгән инде шунда.

– Ничә яшьтә улыгыз?

– Озакламый унҗидегә чыга.

«Миннән бер генә яшькә кече икән, – дип уйлап куйды Миңнулла. – Чыннан да укый-яза белсә һәм тererәк булса, берәр эшкә тартырга кирәк үзен».

– Волкомыгызның хуҗалары качып киткәнен өязгә нигә шушыңарчы хәбәр итмәдегез, Сәгыйдулла агай?

– Башта үзеңә бер сорау бирим әле, энекәш: син безгә ялгызың гына килдеңме, әллә этрәт беләнме?

– Отряд белән.

– Туты шул менә! Ярый әле этрәт алып чыгарга акылың җиткән. Берүзең генә чыксаң, минем белән менә шушылай итеп төпченеп тора алмаган булырыең.

– Нишләп?

– Ялгыз юлга чыгулар бик хәвефлегә әйләнеп китте бу араларда. Әле кичәгенәк кенә Усыга барырга дип кузгалган ике кешенең башына җиткән контрлар. Кешеләре кемнәр диген әле син аның: алтмышка җиткән бер карчык та алты-җиде яшендәге бер сабый бала бит!

**5**

Эш майтара алырдай һәм совет властена турылыклы кешеләрне табып, Карый волкомын яңабаштан оештырганчы атнадан артык вакыт үтеп китте. Ярый әле Сәгыйдулла абзыйның малае Фәйзулла булды. Миңнулла шикелле яшьтән революцион түгәрәкләрдә катнашып йөргән кеше булмаса да, сәяси яктан бик әйбәт мәгълүматлы һәм акыллы егет иде ул. Кулына эләккән газеталарны, китап һәм брошюраларны берсен дә калдырмыйча укып бара икән. Унынчы сентябрьдә Казанның, уникенче сентябрьдә Сембернең аклардан азат ителүен дә белә. Ленинга һөҗүм булганын да ишеткән иде. Тик, Ленин тикле Ленинга атарга кемнең кулы барсын икән дип, ул хәбәрнең чыннан да дөрес булуына гына ышанмаган. Хәтта Миңнулла Ленинның Каплан тарафыннан яралануы турында газетада басылган мәкаләне күрсәткәч тә, юк, барыбер ышанмыйм, минем өчен барыбер исән ул һәм гомерем буена шулай исән булып калачак, дип, үз фикереннән кайтмады.

Волкомга председатель сайлау мәсьәләсе килеп баскач, Миңнулла, һич икеләнмичә, ул урынга әнә шул Сабитов Фәйзулланы тәкъдим иткән иде. Әмма, булдыра алмас, яшьрәк әле ул дип, аның фикерен хупламадылар. Фәйзулла үзе дә риза булмады:

– Бүтән теләсә нинди эшкә куйсагыз да риза, ләкин андый зур җаваплылыкны үз өстемә ала алмыйм, – диде ул. – Тәҗрибәм дә, андый эшкә маһирлыгым да юк минем.

– Алайса, кемне тәкъдим итәсез соң? – диде Миңнулла. – Ягез, кемнәрдә нинди фикерләр бар?

Сәгыйдулла агай урыныннан торды да, бүреген йомарлый-йомарлый:

– Кемне дип, менә... мин... моңарчы эшләп килдем ләбаса. Нүжәли артабан да эшли алмам икән, – диде.

Җыелыштагылар мыек астыннан гына елмаешып куйдылар. Хуплап сүз әйтүче булмады.

Председатель булырга бүтән кулай кеше дә, теләүче дә юк иде. Ахырдан Миңнулланың үзенә килеп туктадылар.

– Минем хәлем әйбәт түгел, иптәшләр. Авырып йөрим. Дәваланып, азрак ял итеп китәргә дип кайткан кеше генә бит мин. Ярдәм итүен итәрмен, ләкин председатель итеп үзегезнең арадан берәрегезне куегыз! – дип караса да, тегеләр:

– Син бит аяклы авыру. Курыкма, артык борчымабыз. Безгә синең киңәшең кирәк, эшнең рәтен белеп-әйтеп торуың кирәк. Калган ягын үзебез чамаларбыз без аның. Волком эшләрен бер кат тәртипкә салганчы гына эшләп тор инде, энекәш! – дип чатябыштылар.

Аннары әлеге укымышлы егет Фәйзулла да:

– Әгәр син председатель булсаң, урынбасарың булып эшләргә мин каршы түгел, – дигәч, Миңнуллага ризалык бирүдән башка чара калмады...

**6**

Хәле шәптән булмаса да, җаваплылыкны өстенә алгач, Миңнуллага шул көнне үк эшкә керешергә туры килде. Ә эш муеннан иде. Аннары килеп, аны һәрнәрсәне дөрес хәл итә ала торган җитәкче дип санасалар да, ул үзе дә мондый эштә башлап йөргән кеше түгел иде бит әле. Шуңа беренче көннәрдә бик кыен булды. Волком председателенә дип килгән кешеләр, Миңнулла бүлмәсенә кергәч, аның председатель икәнлегенә ышанмыйча интектерделәр. Зур көрәк сакаллы, дәү таза гәүдәле бер рус карты белән булган әнә шундый аңлашылмау күңеленә аеруча нык сеңеп калды Миңнулланың. Башта ишек шакып, тыйнак кына булып килеп кергән иде ул карт. Ә менә өстәл артында әле яңа гына мыек чыга башлаган Миңнулланы күргәч, сәлам дә биреп тормастан:

– Тфү, черт, тагын урынында түгел икән! – дип кире борылып чыга башлады.

– Ә кемне эзли идегез соң сез? – диде Миңнулла.

– Волком председателе Гайсин кирәк иде лә!

– Рәхим итегез алайса. Мин – Гайсин.

– Лыгырдап тормасана, молокосос!

Шулай диде дә, ишекне шартлатып ябып, чыгып та китте. Күрәсең, волком ишеге төбендә постта торучыга ник мине алдап керттең дип бәйләнгәндер, болдырда кычкырышкан тавышлар ишетелә башлады. Аннары сакчы, аркасына мылтык терәп, картны Миңнулла бүлмәсенә алып керде дә:

– Уф, нишләтим икән, иптәш Гайсин, бу томананы? Синең волком председателе икәнлегеңә һич кенә дә ышанмый бит! – диде.

– Ни йомыш иде сезнең, агай? – диде Миңнулла, каны кыза башласа да, тыштан тыныч булырга тырышып.

– Йомышымны мин бары тик волком председателенә генә әйтергә телим. Кая ул? – диде карт, гел үз туксанын туксанлап.

Инде Миңнулла да кызды:

– Мин председатель, дип әйтеп торам бит инде сиңа!

Карт барыбер ышанмады.

– Давай алайса мине председательнең урынбасарына алып кер! – диде ул сакчыга. – Бу молокососка сөйләп сүз әрәм иткәнче, ичмаса, председатель урынбасарына сөйләрмен.

– Атып кына үтеримче, иптәш Гайсин, шушы төнтекне? – диде сакчы, картка ачуыннан тәмам калтырана башлап. – Бер ахмакны үтергәннән генә дөнья харап булмас әле.

Ләкин картның исе дә китмәде:

– Кемне атып үтермәкче буласың әле син, анаңнан ялангач туган нәрсә?! – диде ул, бер дә ашыкмыйча гына сакчыга борылып. – Кулыңа мылтык тоттырганнар икән, кемне атсам да ярый дип уйлыйсыңмы әллә син? Әй, афәт! Атарсың менә, аттырырмын мин сиңа! Әйдәле, председатель урынбасары янына алып кер әле мине. Күрсәтим әле мин сиңа кемне атарга исәп иткәнеңне!

Бу картны Сабитов янына кертеп торудан мәгънә юк – аңа да ышанмаячагы көн кебек ачык иде. Шул ук вакытта йомышын йомышламыйча чыгарып җибәрү дә ярамый, чөнки аның нindider мөһим эш белән килгәнлеге кыяфәтеннән үк күренеп тора. Шуңа Миңнулла кискенрәк чара кулланырга булды:

– Әгәр үзегезнең кем икәнлегегезне һәм нинди эш белән килүегезне хәзер үк әйтмисез икән, мин сезне кулга алырга мәҗбүр булам, бабакай! – диде ул. – Йә, кайсына риза буласыз?

Бары шуннан ары гына йомшарып китте карт.

– Ярар, сөйлим инде алайса. Тик башта сакчыңны чыгарып җибәр әле.

Сакчы чыгып киткәч, карт өстәл янына ук килеп утырды да:

– Матвеевка авылыннан Степанов Григорий булам. Григорий Петрович. Пожалуйста, менә туу турындагы таныклыгымны да алып килдем, – диде. Миңнулла ышанмаудан бигрәк картның күңеле булсын өчен генә таныклыгын карап кире биргәч, Григорий Петрович, пышылдап кына:

– Мин синең Гайсин икәнеңә ышанам, ну шулай да син дә берәр документыңны күрсәт әле, энекәш, – диде.

Миңнулла мандатын сейфтан алып күрсәткәч, картның йөзе кояштай яктырып китте һәм ул ни гомер көттереп йөдәткән серен чишәргә кереште...

Григорий Петрович җентекләп, озаклап сөйләгән ул сернең асылы бик гади һәм менә нәрсәдән гыйбарәт иде: Матвеевка авылында урта хәлләләр чутында йөри торган җиде кулак бар һәм алар артык икмәкләрен дәүләткә тапшырырга теләмичә, яшереп саклыйлар икән. Григорий Петрович аларның икмәкләре кая яшерелгәнен белә, әгәр Миңнулла волостьтан продотряд җибәрсә, отрядка ярдәм итәргә дә әзер икән.

Картның бу тәкъдиме бик мөһим: кулакларның яшергән икмәген табып, фронтка озатырга кирәк иде. Ләкин отрядсыз кая барасың? Ә отряд ул көнне өйдә юк, азык-төлек бүлеге начальнигы белән икенче бер авылга киткән иде.

– Әйдә бүген үк барыгыз минем белән! – дип, карт бик ашыкса да, Миңнулла аны:

– Шушы араларда барып чыгарбыз, тыныч бул, Григорий Петрович, – дип ышандырып калырга гына мәҗбүр булды.

**7**

Аклар кулында тоткын булып яткан чагында, Миңнулла, әгәр исән-имин кайта алсам, иң элек әти-әнине, аннары Зәйнәп-сылуны күреп сөйләшер идем, дип күңеленә беркетеп куйган иде. Нинди генә ашыгыч эшләре булса да, берсе белән дә исәпләшеп тормастан, Барсайга барып кайтырга иде исәбе. Карыйга кайтып эшли башлаганына инде менә икенче атна китте, әмма кичектергесез көндәлек эшләр артыннан йөреп, тәки шул Барсайга бара алганы юк иде әле.

Ул кайчан шул максатына ирешер иде икәнен әйтүе кыен, әмма, Григорий Петрович чыгып китү белән, Зәйнәп үзе волкомга килеп керде.

Узган җәйдә ул тагын да чибәрләнебрәк киткән. Йөреш-хәрәкәтләре сылу-салмакланган. Кыяфәтендәге балалык чалымнарының эзе дә калмаган. Күз карашлары җитдиләнгән, хәтта кирәгеннән артыграк та җитдиләнеп киткән шикелле. Буйга да сизелерлек үскән. Ә күзләре нишләптер бик моңсу. Аннары тәнгә дә бик ябыккан. «Замананың авырлыгы безнең ир-ат халкына гына түгел, кыз балаларга да кагылмыйча үтми икән шул», – дип уйлап алды Миңнулла. Әгәр менә шушы кызны күрсә, сөйләшеп сүзе бетмәс шикелле тоела иде Миңнуллага. Ә менә хәзер, кыз аның янына килеп кергәч, ул нигәдер югалды да калды. Әйтәсе сүзләре кинәт онытылды һәм теле тотлыкты.

– Нихәл, Зәйнәп? – диде ул, ниһаять, телгә килеп. – Үт әйдә, тарсынып торма!

– Син булгач, тарсынмыйм инде, – дип, кыз өстәл янына килеп утырды.

– Кайчан килдең, Зәйнәп? Шушындый мәхшәрдә ничек курыкмыйча юлга чыктың?

– Авыл кешеләренә ияреп килдем. Куркып кына ятып булмый гел. Курка-курка туеп та беттем инде.

– Барсайданиләр бар соң? Сафиулла агай белән Әминә апа ару гына торалармы?

Кызның ике күзеннән дә мөлдерәп яшь чыкты:

– Син әле ишетмәдең дәмени, иптәш Гайсин, бездә ниләр булганын?

– Нәрсә, әллә берәр күңелсез хәл булдымы, Зәйнәп?

– Әти белән әни юк инде минем, – диде кыз, тыелгысыз аккан күз яшен сөртә-сөртә. – Сәйфи бай малае Шакир атып үтерде икесен дә.

Миңнулланың башы әйләнеп китте.

– Ни өчен, Зәйнәп?

– Шул ми... минем өчен инде. Кызыңны бир, дип бик аптырата башлагач, әти мине башка авылга илтеп куйган иде. Шуннан теге, табып бирегез кызыгызны, дип, башта әнине дә, әтине дә кыйнаган, аннары аларның күз алдында безнең өйне яндырган. Әти белән әни минем кайда икәнне һаман әйтмәгәч, икесен дә атып үтергән. Ә мине күрше авылдагы туганнарыбыз яшереп асрады. Сине волком председателе итеп куйганнар дигәч, монда килдем әле менә. Миңа берәр эш таба алмассыңмы икән дигән идем.

– Эше булыр ла аның. Тик менә ниндирәге кирәк соң сиңа?

– Мин барысына да риза. Волкомыгызга җыештыручы итеп алсагыз да ярый. Шушында кунып йөрергә рөхсәт итсәгез, миңа берни кирәк түгел. Ә авылга кайтмыйм мин. Теге хәшәрәт Шакир килеп чыгып үземнең дә башыма җитәр дип куркам.

– Азрак укый-яза белмисеңме соң, Зәйнәп?

– Укый да, яза да беләм.

– Кит аннан! Кадимчәме, җәдитчәме?

– Җәдитчә.

– Соң нигә күптән шулай дип әйтми утырасың аны! Молодец та кеше булып чыгасың бит әле син, болай булгач! Алайса, әгәр риза булсаң, мин сине волкомга секретарь итеп алам, яме! Шунда минем янда азрак русчасын да өйрәнерсең дә аннары үзеңне халык мәгарифе бүлегенә алырбыз. Әле өченчекөн генә мәгариф бүлеге ачарга дип өяздән күрсәтмә килгән иде.

– Ә мин русчасын да ипилек-тозлык кына сөйләшә алам. Аз гына укый да, яза да беләм шикелле, – диде кыз кыю гына итеп.

Аның бу сүзләре Миңнулланы тәмам хәйран итте.

– Син минем сорауны яхшылап ишетеп җавап бирдеңме, Зәйнәп? – диде ул, кызга ышанып бетмичә. – Русча сөйләшү һәм русча укый-яза алу турында сораган идем мин синнән.

– Мин дә шул турыда әйтәм. Бала чагымда бездә фатирда рус тимерчесе торды. Аларның минем шикелле кызлары бар иде. Шул чакта мин аннан русча сөйләшергә һәм азрак кына укырга-язарга өйрәнеп калдым. Ә ул кыз миннән безнең татар телен өйрәнде.

Миңнулла, өстәлендә яткан газетаны алып, Зәйнәпкә сузды:

– Менә шушы газетаны укып кара әле!

«Правда» газетасының унберенче сентябрьдә чыккан саны иде ул.

Алай бик үк йөгерек итеп булмаса да, Зәйнәп шул газетаның баш мәкаләсен хәйран иплә генә укып китте: «Казань взята. Белые бегут по шоссе к Симбирску. Важнейший передовой пост белогвардейского движения пал...»

– Молодец, – диде Миңнулла, көченнән килсә айга сикерердәй куанып. – Булды бу! Менә шушы минуттан үзеңне волкомның халык мәгарифе бүлеге мөдире дип сана!

– Ой, андый зур эшне булдыра алырмынмы икән?

– Ничек кенә булдырырсың әле, дустым! Курыкма, бергә эшлисе бит. Ярдәм итәрмен.

– Алайса тырышып карармын.

**8**

Азрак ял итеп, какшаган сәламәтлеген «ремонтлап» килү нияте белән кайткан Миңнулланың ял итәргә түгел, ял турында уйларга да вакыты юк иде хәзер. Дөрес, әнисе Гайниҗамал апа тырыша инде тырышуын. Үзләренең сыеры иртә буаз булганлыктан инде күптән ташланса да, каяндыр табып, сөтен-каймагын да, мәтрүшкәсен дә, тагын әллә нинди шифалы үләннәр дә кайнатып эчертә. Бурсык мае да тапкан. Миңнулла яратмаса да, аны да көчләп-көчләп эчертә.

Әллә әнисенең әнә шул тырышлыгы нәтиҗәсе булды, әллә бу егет көн-төн эш белән мәтәвекләнеп йөри, моның миңа игътибар итәр чамасы бөтенләй күренми, барыбер җиңеп булмас, ахрысы, бу ташбашны, дип, авыру үзе курыктымы – Миңнулланың хәле Карыйга кайткач сизелерлек яхшырды: аңа ит куна башлады, эченнән кан килүе туктады.

Ә өяздән тагын яңа күрсәтмәләр килә торды. Элек Кызыл Армиягә, нигездә, үзе теләгән кешеләрне генә алган булсалар, хәзер сәламәтлекләре ярардай унсигез яшьтән алып кырык яшькә кадәрге барлык ир-атларны фронтка озату мәҗбүри итеп куелды. Сугышка барырга яраксыз дип табылган ир-атлардан авылларда хәрби дружиналар төзү, июль-август айларында кулаклар коткысы белән күп кенә авылларда оештырылган бунтлар нәтиҗәсендә таркатылган ярлылар комитетларын яңадан оештыру, сугышчы кызылармеец семьяларына ярдәм итү, тагын шуның ише мең төрле мәшәкатьләр – барысы Миңнулла өстендә. Кыскасы, кая анда ял да, кая анда авыру турында уйлап торырга вакыт. Хәтта тәүлегенә дүрт-биш сәгать кенә эләгә торган йокысын да тыныч кына йокларга ирек бирмиләр, кайбер мәсьәләләрне төн уртасында торып хәл итәргә туры килгән чаклары да бик еш була.

Бүген дә Миңнулланы бик иртә уяттылар. Кичә волостьның бер авылында фронтка кешеләр җыеп озату белән шөгыльләнеп, аннары партячейка җыелышы үткәреп йөреп, Карыйга төнге берләрдә генә кайтып яткан иде ул. Ә иртәнге биштә волком дежурные килеп җитте:

– Әйдәле, наным Гайсин, синсез эш чыгарып булмый анда. Бажук авылы мужиклары үзләренең комбед персидәтелен тотып алып килгәннәр дә, каталажкагызга ябып куегыз шушы бәндәне, дип тинтерәтәләр. Волком персидәтеле рөхсәтеннән башка беркемне дә ябарга хакыбыз юк безнең, дигән идек, бик каты тавыш күтәрделәр. Персидәтелнең үзен алып кил алайса, диләр. Араларында берсе аеруча нык җикеренә. Өяз ривкумыннан килгән вәкил мин, давай әйткәнне тизрәк үтә, ди. Югыйсә үзеңне дә ариставайт итәрбез, ди.

Миңнулла Бажук председателен – япон һәм герман сугышларында катнашкан, соңгысыннан бер кулын өздереп кайткан Харисов Мөхлис агайны яхшы белә иде. Волостьта иң ышанычлы һәм иң эшлекле председательләрнең берсе ул. Тик Миңнуллага ошап бетмәгән бер ягы бар: чамадан тыш таләпчән һәм кирәгеннән артык кызыбрак китүчән.

Миңнулла волкомга килеп кергәндә дә, Мөхлис агай дежурный белән каты гына әрепләшеп тора иде.

– Нихәл, Мөхлис агай? Тагын кысыр хатыннан бала таптырып йөрисеңме әллә? – диде Миңнулла, уенын-чынын бергә кушып.

– Син алай уенга борма әле, иптәш Гайсин. Бу юлы мин таптырмыйм, бу юлы минем үземнән таптырырга маташалар әле!

– Кемнәр ул? Ни өчен?

– Кем икәнен шайтан белгәнме аның! Ниндидер бер дурак нәрсә килеп чыкты да аристовайт итеп алып килде менә!

– Әйдә, коридорда тормыйк, кереп сөйләшик әле! – дип, Миңнулла Мөхлис агайны бүлмәсенә алып кергән иде – шаккатып калды: бүлмә тәмәке төтене белән тулган һәм шул төтен эчендә унлап кеше ду килеп сөйләшеп утыралар иде. Барыннан да гаҗәбрәге шул булды: теге кешеләрнең берсе Миңнуллага инде күптәннән таныш – әлеге «милләт хадиме» Хәйретдинов Хәйрулла иде.

Хәйрулла да аны танып алды бугай: нидер лыгырдап торган авызын япты да, секунд эчендә кара көеп, телсез калды.

Миңнулла, тиз генә сакчы янына чыгып:

– Отряд командирына әйт, хәзер үк биш кеше алып, монда, минем янга килсен! – диде. Үзе бүлмәсенә яңадан керде: – Сез кайда, иптәшләр, волком председателе бүлмәсендә утырасызмы, әллә каравыл өендәме?

– Без персидәтелне көтеп утырабыз! – диде араларыннан берсе.

– Бик әйбәт. Менә мин булам инде председатель. Ә хәзер, менә бу иптәшегездән башкаларыгыз, – ул Хәйрулланы күрсәтте, – барыгыз да бүлмәдән чыгып торыгыз!

– Алар минем белән килгән кешеләр. Аларның да әйтәсе сүзләре бар! – дип, Хәйретдинов ризасызлык белдерә башлаган иде, ләкин Миңнулла:

– Мин берьюлы ун-унбиш кешене тыңлый алмыйм: Наполеон булып Наполеон да берьюлы тик ике кеше белән сөйләшә алган! Бер дә курыкмагыз, алар белән дә вакыты җиткәч сүз булыр! – дип, эшне бик коры тотты. – Йә, синнән башлыйк, Мөхлис агай, – диде ул, Бажук мужикларын чыгарып җибәреп, форточканы ачып куйгач. – Кемнәр һәм ни өчен кулга алдылар сине?

– Кичә кич, – дип башлады Мөхлис агай, – минем янга идарәгә менә шушы кеше килеп керде дә: «Мин өяз вәкиле, халыкка аңлатасы нәрсәләр бар», – дип, төнләләтеп җыелыш җыйдыртты. Җыелышка килгән кешеләрдән: «Ярлылар комитетыгыз ничек эшли? Сезне кыерсытмыймы?» – дип сораштыра башлады. Андый чакта, үзең беләсең, зарланучылар табыла инде ул. Берсе әйтә, камбид кешеләре минем ашлык суга торган машинамны алды, ди. Икенчесе әйтә, минем атымны алып фәлән кешегә бирделәр, ди. Җиребезне кисеп алдылар, дип тә кычкыра башладылар. Артык малларын законлы төстә алганны әйтми бит алар. Алдылар, ди и шуның белән вәссәлам! Ә менә бу адәм, – ул тагын Хәйруллага ишарәләде, – тегеләрне тыңлап торды да прәме шул җыелыштагы халык алдында ук, ул атларны нинди дикрит нигезендә канфискатсияләдегез, җирләрне нинди дикрит нигезендә кисеп алдыгыз, фәлән дә фәсмәтән дип мине тыкырдата башлады. Ә безнең кулда чыгарып күрсәтергә бернинди дә дикрит юк. Вулыстан язып җибәрелгән күрсәтмәләр белән авыл ярлылары җыелышларының беркетмәләре генә бар бездә. Мин шулай дип әйткәч, менә шушы имансыз нәрсә бөтен халык алдында торып басты да: «Сез боларның берсен дә закон нигезендә эшләмәгән, шуңа күрә менә шушы минуттан мин сезнең камбидны таратам, камбид председателен кулга алам», – диде. Аннары халыкны таратты да мине үзе белән менә монда алып килде. Ярлылар комитеты тарафыннан үзләрен кимсетелгән дип санаучылар да аңа ияреп килде. Әлеге ул кеше әнә шулар иде инде. Менә шул, иптәш Гайсин.

Мөхлис абзый сөйләгән хәлләргә Миңнулла күңеленнән бәя бирә барган иде. Ләкин бер дә алай законга каршы килә торганын тапмады. Барысы да әле шушы елның унберенче июлендә Ленин имзасы белән игълан ителгән декрет нигезендә эшләнгән кебек тоелды аңа. Урыннардагы совет власте бит ул – ярлылар комитетлары. Шулай булгач, авылларда тигезлек урнаштыруны гамәлгә шул комитет ашырмыйча кем эшләсен ди инде?

– Мөхлис агай сөйләгәннәр дөресме? – диде Миңнулла Хәйруллага.

– Мин барысын да законча эшләдем! – диде теге бик батыр итеп.

– Июнь аенда ярлылар комитетлары һәм җирле советлар турында декрет чыккан иде. Сез ул декрет белән танышмы?

– Таныш.

– Шулай булгач!

– Анда ярлы халыкны кимсетмәскә кушкан.

– Әйе, ярлы халыкны шул менә! Ә Бажук комбеды ярлыларны түгел, байларны гына «кимсеткән».

– Байлар инде барысы да качып бетте.

– Калганнары да җитәрлек әле аларның! Әйтегез әле, сез кем? Һәм нигә сез волком белән сөйләшмичә, аның рөхсәтеннән башка Бажукта җыелыш үткәрдегез?

– Без күптәнге танышлар бит инде, иптәш Гайсин! – диде Хәйрулла, ыжлап та бирмичә.

– Мин ул турыда әйтмим. Кайда һәм кем булып эшлисез, дим мин!

Кесәсеннән алып, Хәйретдинов командировка кәгазе сузды. «*Моны күрсәтүче Хәйретдинов Хәйрулла Хәйретдин улы*, – диелгән иде анда, – *җирле партия һәм совет органнарына агитация-масса эшен яхшыртуда практик ярдәм итү өчен Карый һәм Ашап волостьларына җибәрелә. Бу эшне тормышка ашыру барышында җирле совет органнары иптәш Хәйретдиновка һәрьяклап булышлык күрсәтергә тиеш...*»

Үз күзләренә үзе ышанмыйча, Миңнулла командировка бланкасына язылган әлеге сүзләрне тагын бер кат укып чыкты. Ләкин анда барысы да дөрес, барысы да нәкъ менә шулай иде. Хәтта өяз идарәсе комиссариатының печатенә хәтле ап-ачык булып төшкән һәм РКП(б)ның өяз партия ячейкасы секретаре имзасы да дөрес иде. Тик өяз идарәсе комиссариатының командировканы теркәү номеры гына куелмаган иде анда. Ә ул куелган булырга тиеш, чөнки шул хакта катгый күрсәтмә бар иде. Миңнулла менә шуны искәрткәч, Хәйретдинов:

– Миңа аны теркәтергә кирәк икәнен әйткән кеше булмады, – дип җавап бирде.

«Кем белә инде аның дөресен генә, – дип уйлап алды Миңнулла. – Бәлки, чыннан да, бу адәм үзе белмәгәндер, ә искәртүче булмагандыр».

– Ярый, – диде Миңнулла, ризалашырга мәҗбүр булып. – Анысы шулай да булсын ди. Ә менә өяздән килгән, хәтта губерна үзәгеннән килгән вәкилләрнең дә волбашкарма рөхсәтеннән һәм волбашкарма вәкиле катнашыннан башка бер генә авылда һәм бер генә төрле җыелыш та үткәрергә хакы юк икәне мәгълүмме сезгә?

– Мин укомда яңа гына эшли башладым. Барлык күрсәтмәләрне белеп бетермәвем дә мөмкин.

«Сөйләшә белә, кабих! Неужели әле кайчан гына совет властеның кан дошманы булып йөргән шушы адәм, фикерен үзгәртеп, безнең җырны җырлый башлады микән?..»

– Сез партия әгъзасы түгелсездер бит, Хәйретдинов?

– Нигә алай шикләнеп кенә сорау бирәсез? Узган елдан бирле партия әгъзасы инде мин!

– Мин Милли Шура турында түгел, Коммунистлар партиясе турында сүз алып барам, Хәйретдинов! – диде Миңнулла, тегене шаярып сөйләшә дип уйлап һәм ипи шүрлегенә менеп төшүдән үзен кыенлык белән генә тыеп.

Ул Хәйретдиновның бүтән теләсә нинди сүзенә, теләсә кем булуына ышанырга әзер, әмма аның Коммунистлар партиясе члены булуын һич тә күз алдына китерә алмый иде.

Ләкин Хәйрулла аны шаккатырып үзенең партия билетын сузды. Билет, чыннан да, Хәйретдинов исеменә бирелгән иде! Барыннан да гаҗәбрәге шул, Хәйретдиновның бу билеты РКП(б)ның өяз комитеты тарафыннан бирелгән.

– Соң син әле моннан бер ай элек кенә контр идең бит, Хәйретдинов, ә билетыңда партиядә унҗиденче елдан бирле тора дип язылган. Моны ничек аңларга инде?

– Мин беркайчан да контр булмадым! – диде теге, күзен дә йоммыйча. – Аклар лагеренда партия заданиесен үтәп кенә йөрдем мин!

– Барсай мужикларына сөйләгән нотыгың да партия заданиесен үтәү йөзеннән идеме?

– Әйе.

«Карале син бу паразитны, кызармый да бит, ичмаса!»

– Безнең өйгә җиде төн уртасында килеп кереп, минем абыйны таптырырга теләп, әнинең теңкәсенә тиюең һәм соңыннан безнең сарыкны суйдырып алып чыгып китүең дә партия кушуы буенча булмагандыр бит?!

– Әйе, анысы да партия кушуы буенча! Гайсин акларга сатылган дигән хәбәр таралган иде. Шуңа күрә азрак тикшерү үткәреп алырга туры килде.

Юк, тегенең сүзләренә дә, документларына да ышанып җитә алмады Миңнулла. Хәйретдиновның өяз вәкиле булып килүен, күрсәтмәләр бирергә хокукы бар икәнлеген, аның күрсәтмәләрен үтәмәсә, соңыннан үзенә кыенга туры килүе мөмкинлеген бик яхшы белеп торса да, бу юлы бернинди кагыйдәгә дә буйсынмаска булды:

– Сез мине гафу итегез, Хәйретдинов, – диде ул, – кайбер нәрсәләрне ачыклаганга кадәр мин сезне кулга алып торырга мәҗбүрмен.

– Кемне? Мине, өяз башкарма комитеты вәкиленме? Миңа кагылырга бернинди дә хокукың юклыгын беләсеңме син, Гайсин? – дип, Хәйретдинов этәчләнә башлаган иде, әмма Миңнулла аның белән артык вакланып тормады. Тегенең партия билетын да, командировка кәгазен дә үзенең сейфына салып куйды да, инде килеп җитеп, әмер көтеп торган отряд командирына:

– Менә бу кешене КПЗга илтеп ябыгыз әле, иптәш Ногманов! – диде.

Аннары Хәйретдиновның биографиясен һәм партиягә ничек, кайчан кергәнлеген бик җентекләп тикшереп, шул хакта үзенә хәбәр итүләрен үтенеп, шуңарчы аны сак астында тотачагын әйтеп, өяз башкарма комитеты председателе һәм өяз партия ячейкасы секретаре исемнәренә язу язды да аны, бер кызылгвардиячегә биреп, Усыга җибәрде. Шуннан соң, безнең дә сиңа сүзебез барые, дигән теге Бажук «кимсетелгәннәре» исенә төшеп, алары ни җырлар икән, аларын да тыңлап карарга кирәк дип, коридорга чыккан иде, волком дежурные:

– Юк инде алар, иптәш Гайсин. Башлыкларын сак астында алып киткәнне күргәч, шыпырт кына таралып бетте алар! – диде.

**9**

Ишеткәне булса да, Миңнулланың Матвеевканы моңарчы күргәне юк иде әле. Урман буена сыенып утырган матур гына бер авыл икән. «Контрларга чыннан да бик уңай икән шул монда, – дип уйлап куйды Миңнулла, Григорий Петровичның волкомда әйткән сүзләрен исенә төшереп. – Урман орынып тора: ашлыкны гомер таба алмаслык итеп яшерергә мөмкин». Авыл зур түгел. Йөз-йөз егерме йорттан артык булмас. Чиркәүләре дә күренми. Димәк, бик борынгы авыл булырга тиеш түгел. Аннары тагын шунысына игътибар итте Миңнулла: авыл өйләренең түбәләре күбесенеке йә калай, йә черепица яки такта белән ябылган, бер генә салам түбә дә юк. Каралтылары да нык. Күбесе биек койма белән уратылган. Ә бит, яшерен-батырын түгел, рус авылларында өйләр гадәттә зур булса да, каралтылары болай төзек һәм нык булмый торган иде. Бу авылда зур-зур таш келәтләр дә байтак күренә. Хәтта икешәр катлы йортлар да бар. «Димәк, тормышлары таза боларның. Мөгаен, иген игүдән тыш, тагын ниндидер кәсеп белән шөгыльләнәләр булса кирәк», – дигән нәтиҗәгә килде Миңнулла.

Авылга килеп кергәч, беренче очраган ир уртасы кешедән:

– Ярлылар комитетыгыз кайда? – дип сораган иде, теге:

– Безнең андый нәрсәне ишеткәнебез юк! – дип җавап бирде.

– Ә авыл советы бармы соң?

– Әнә шул тыкрыктан уңга борылгач, сул яктан икенче йорт председательнеке булыр.

Теге кеше күрсәткән өй турына килеп, Миңнулла атыннан сикереп төшүгә, өр-яңа урыс капка ачылып китте дә, баһадирдай киң җилкәле, имән түмәркәседәй нык һәм юан гәүдәле, каны бәреп чыгарга торган кып-кызыл йөзле, утыз-утыз икеләр тирәсендәге бер ир килеп чыкты. «Авылга кереп җитмәдек, инде икенче тап-таза ир кешегә юлыктык. Болар нигә фронтта түгел икән соң?» Миңнулла әнә шулай уйлап алган арада капкадан чыккан кеше, каш астыннан гына сөзеп карап, Миңнулланы һәм аның белән килгән кызылгвардиячеләрне тикшереп чыкты да, ясалмарак кына елмаеп:

– Исәнмесез! Кемнәр буласыз, кайдан киләсез? – диде.

Ул шулай сөйләнгән арада, Миңнулланың колагына болдыр баскычыннан кемнәрдер бик ашыгып кына төшеп, абзар ягына йөгерешкән шикелле тоелды.

– Саумысыз, – диде Миңнулла. – Авыл советы председателе сез буласызмы?

– Әйе.

– Алайса, бик яхшы. Без волкомнан идек. Минем фамилиям – Гайсин. Ә сезгә ничек дип мөрәҗәгать итәргә?

– Волкомның кайсы бүлегеннән?

– Мин волком председателе булам. Сезнең авыл хәлләрен белеп китәргә дип килү иде. Кайда сөйләшәбез: өегезгә алып керәсезме, авыл советыгызның махсус бинасы бармы?

Миңнулла әнә шулай кыю тотынгач, теге, шактый йомшарып:

– Мин – Сидор Андреевич Шишков, – диде. – Безнең әлегә авыл советы бинабыз юк. Монда, минем өйдә генә сөйләшербез. Бер генә минут көтеп торыгыз инде, зинһар. Безнең өйдә тәртипсезрәк чак иде. Рәхим итеп, атларыгызны ишегалдына урнаштыра торыгыз!

Сидор Андреевич шактый озак торып чыкты. Ләкин бу юлы иң якын туганнарын каршыларга чыккандай бик ачылып чыкты һәм Миңнулланы да, аның белән килгән дүрт кызылгвардиячене дә кыстый-кыстый өйләренә, аның да әле түр ягына ук алып керде. Анда инде өстәл әзерләнгән, табын тутырып ризык куелган иде. Эчемлекләре дә җитәрлек күренә. Өй эче кәбестәле аш исе, ит исе һәм аракы исе белән тулган. Кыскасы, бу йортта кунаклар булганлыгы әллә кайдан сизелеп тора. Ләкин өйдә Сидор Андреевичның хатыны һәм ике баласыннан башка беркем дә юк. «Бая хуҗа безнең каршыга чыгып сөйләштереп торган арада ишетелгән тавышлар кунакларныкы булган, күрәсең, – дип фикер йөртте Миңнулла. – Кызык, нинди серле кунаклар булды икән ул? Хуҗа нигә аларны безгә күрсәтүдән курыкты икән?..»

Сидор Андреевич табынга кыстый башлады. Мондый ризыклардан баш тарту гөнаһ булыр иде. Аннары утыз-кырык чакрым юл килеп, тамаклары да ачыккан иде. Миңнулла кыстатып тормады. Иң алдан өстәл артына үзе кереп утырды да тартыныбрак торган гвардиячеләренә:

– Әйдәгез, иптәшләр, раз әзер ашка туры килгәнбез икән, ашап алыйк, – диде һәм, хуҗаның шешә ачып стаканнарга аракы сала башлавын күреп: – Ә сез ул нәрсә белән мәшәкатьләнеп тормагыз, Сидор Андреевич, безнең арада эчә торган кеше юк! – диде.

Бәлки, күңелләреннән бик үк риза булмаучылары да булгандыр, әмма гвардиячеләр Миңнулланы дөрес аңладылар һәм барысы да берьюлы диярлек, әйе, әйе, Сидор Андреевич, беребез дә эчми безнең, дип, аның сүзен куәтләделәр. Хуҗа да ялынып тормады:

– Ихтыярыгыз, алайса. Теләмәгән кешенең авызыннан коеп булмый. Ну мин үзем, гафу итегез, бераз тотыйм әле, – дип, ярты стакан эчте дә ул хакта сүз шуның белән бетте.

Бертын ашап алдылар. Сүзне Сидор Андреевич башлады:

– Сез шул продналог мәсьәләсе буенча килгәнсездер инде, иптәш Гайсин?

«Теге җиденең берсе шушы үзе түгел микән әле?» – дип уйлап алды Миңнулла. Алдан ук өркетеп куймас өчен артык исе китмәгәндәй генә җавап бирде:

– Аның белән дә кызыксынабыз.

– Тәк-тәк! – диде хуҗа, Миңнулланың җавабыннан бик үк канәгать булып бетмичә. – Тагын да мөһимрәк эшләрегез бармыни әле бездә?

– Әйтегез әле, Сидор Андреевич, ярлылар комитеты бармы сезнең авылда?

– Юк.

– Нигә юк?

– Авыл советы әйбәт кенә эшләп килгәч, аны оештырып торуның хаҗәтен күрмибез.

– Кемнәр ул «без»?

– Совет членнары һәм халык.

– Ә Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенә кешеләр җыйнау мәсьәләсе ничегрәк тора? Соңгы айда, мәсәлән, армиягә авылыгыздан ничә кеше озаттыгыз?

– Бу айда китүче булмады. Ә узганында өяздән бер иптәш килеп вәгазьләгәч, ике кеше үзләре теләп киткәннәр иде.

– Ә сез Совет дәүләтенең унсигез яшьтән алып кырык яшькә кадәр булган ир-атларның хәрби хезмәткә яраклылары барысы да армиядә хезмәт итәргә тиеш дигән карарын беләсезме?

– Безгә ул хакта күрсәтмә килгәне юк әле. Кайчан чыккан иде икән соң ул карар?

– Моннан өч ай элек үк инде. Сезнең аны белмәвегез сәер, бик сәер, Сидор Андреевич!

– Өяздән дә, волость үзәгеннән дә еракта яшибез бит, иптәш Гайсин. Һәр яңалык безгә бик соңлап килә.

– Дәүләткә икмәк тапшыру мәсьәләсендә эшләрегез ничегрәк? Һәр крестьян семьясы үзенә ашамлык һәм чәчүлектән арткан икмәген дәүләткә тапшырырга тиеш икәнлеген беләме авылыгыз халкы?

– Беләләр. Анысын кат-кат аңлаттык без аларга.

– Ничек соң, аңладылармы, тапшыралармы? Күпме икмәк җыеп озаттыгыз?

– Җыюын күп кенә җыйган идек. Тик дәүләткә тапшыра алмадык. Усыга илтергә барган чагында олауларга юлбасарлар һөҗүм иткән дә бөтен икмәкләрен талап алып киткәннәр.

– Кызганыч, бик кызганыч. Ә авылыгызда партия ячейкасы бармы, Сидор Андреевич?

– Юк, ләкин партиягә керергә теләүчеләр бар. Мәсәлән, мин үзем дә керер идем.

– Авыл халкының гомуми җыелышларын кайда үткәрәсез?

– Минем җыелышлар үткәргән юк әле. Күптән түгел, сентябрь аеннан гына председательлек итәм әле мин. Ә болай җыелышлар каравыл өе янында үткәрелә торган иде.

– Алайса, менә болай итегез: шул каравыл өе янына халыкны җыйнагыз! Әлеге шул продналог, РККАга мобилизация, партиягә кабул итү мәсьәләләре хакында халык белән сөйләшеп алырга кирәк булыр. Авыл советыгызның йомышчысы бардыр бит?

– Барын бар анысы. Ләкин халыкны мин үзем дәшеп чыгармын. Йомышчыга гына артык исе китми безнекеләрнең.

– Анысы сезнең ихтыярда, Сидор Андреевич. Ләкин сәгать икегә халык җыелып беткән булсын. Монда эшне бетереп, мин бүген үк кайтып китүгә тиеш.

– Тырышып карармын, әмма, ай-һай, икегә үк җыйнап булыр микән.

– Әйдә, алай булгач, икәүләп өй борынча йөреп чыгабыз.

– Што сез, што сез, иптәш Гайсин! Волком председателен өй борынча халык җыеп йөртергәярыймы соң? Юк, юк! Хәзер, мин үзем, үзем!.. Безнең авыл зур түгел бит, хәзер җыеп алабыз без аларны!

– Сезнең авылда Степанов Григорий дигән кеше бармы?

– Степанов Григорий... Григорий Степанов... Петрович түгелдер?

– Әйе, Петрович!

– Бар андый адәм.

– Нindиерәк кеше ул?

– Ничек дип әйтергә инде сиңа? Ярлы гына, куштан гына бер карт инде шунда.

– Сез аны җыелышка кадәр минем янга чакырыгыз әле, зинһар.

– Ярый, чакырырбыз.

**10**

Сидор Андреевич сәгать икенче яртыга әйләнеп кайтты. Ләкин Григорий Петрович һаман килеп җитмәгән иде әле. Ник озаклады икән ул агай дип сорарга Миңнулла авызын ачкан гына иде, Шишков үзе үк әйтеп бирде:

– Степанов өйдә юк икән. Күрше авылга тегермәнгә киткән.

– Кызганыч, ләкин ни хәл итмәк кирәк. Ә халык җыелып бетәме инде?

– Мин әле генә каравыл өеннән кайттым. Нигәдер килгән кеше күренми әле анда. Бераз көтәргә туры килер инде.

Ике дә тулды. Өч тә үтеп китте. Дүрт тә булды. Ә каравыл өендә янгын сакчысыннан һәм Миңнулла белән Сидор Андреевичтан башка адәм заты күренми иде әле. Миңнулла, бу хәлгә бик нык гаҗәпсенеп, нигә җыелмый икән халык, әллә сез аларга бөтенләй әйтмәдегезме, дип сорагач, Сидор Андреевич:

– Үзем дә аптыраган инде. Барысына әйтеп чыктым, киләбез дип калганнар иде. Ни көтеп ята торганнардыр, шайтан белсен! – дип куйды. Әмма үзе, Миңнулла ни кыстап караса да, авылны тагын бер кат әйләнеп чыгарга теләмәде: – Бер әйтелгән бит инде, җиткән. Килергә тиешләр! – дип, гел үз сүзендә кала бирде.

Ахыр чиктә ул хаклы булып чыкты. Бишенче ун минутларда җыела башлаган халык бишенче яртыга җыелып та бетте. Җыелышка җитмеш-сиксән кеше килгән иде.

Сидор Андреевич җыелышны ачып җибәрде дә «сүзне кадерле кунагыбыз, волком председателе иптәш Гайсинга» бирде.

Миңнулла продналогтан башлады. Фронттагы кызыл сугышчыларга һәм шәһәрдәге завод-фабрика эшчеләренә икмәк җитмәвен, аларга бары тик крестьяннар гына ярдәм итә алуын һәм ярдәм итәргә тиешлеген аңлатып бирде дә:

– Ләкин, иптәшләр, – диде, – менә шушы бик тә мөһим эшкә нигәдер сез салкын карыйсыз. Шушы көнгәчә Совет дәүләтенә бер пот ашлык та тапшырганыгыз юк икән әле!

– Как так тапшырмаган! Әле узган атнада гына йорт башыннан өчәр пот та бишәр потлап җыйдылар бит! – дип кычкырдылар халык арасыннан.

– Анысы шулай. Ләкин ул икмәкне сез Совет дәүләтенә түгел, бәлки аның дошманнары кулына тапшыргансыз ич! – диде Миңнулла.

– Ну анысы инде безнең гаеп түгел. Аннары килеп, ул икмәкне талап алган кешеләр дә шул ук бер Алла бәндәләре бит. Аларның да тамагы бар, аларга да ашарга кирәк ләбаса! – диде калын тавышлы бер кеше.

Җыелыштагылар, кайсы аны хуплап, кайсы аның белән килешмичә, нык кына шаулаша башладылар. Ләкин калын тавышны хуплаучылар күбрәк иде. Шуңа Миңнулла, бу мәсьәләне куертып, тавышка куеп тормады:

– Ярый, артык ашлыгыгызны дәүләткә үз ризалыгыгыз белән бирергә теләмисез икән, продотряд китертеп җыйнатып алдырырга туры килер алайса! – диде дә, Кызыл Армиягә кешеләр мобилизацияләү мәсьәләсенә күчеп, Совет хөкүмәтенең шул турыдагы декретын укыды.

– Аңладыгызмы? – диде ул, тып-тын калган җыелышка мөрәҗәгать итеп.

– Аңлавын аңладык, ну без сугышка бармыйбыз! – дип кычкырды берсе. – Җитәр, сугышып туйдык инде!

Тагын берничә кеше «шулай», «дөрес», «беребез дә сугышка барырга теләми» дип, тегене яклап тавышланышып алдылар.

«Нишлибез инде хәзер» дигәнне аңлатып, Миңнулла Сидор Андреевичка карады. Ә Сидор Андреевич берни дә булмагандай тыныч кына утыруын дәвам итте. Аның бу мәсьәләгә битарафлыгы кыяфәтенә үк чыккан иде. «Димәк, моңа таянып булмаячак» дигән фикергә килде Миңнулла. Инде бер башлаган эшне ничек тә ахырына җиткерү өчен мәсьәләне тавышка куйды:

– Кем дә кем Совет дәүләтенең гомуми хәрби бурыч турындагы декретына җавап итеп, үзе теләп фронтка китәргә риза – шуларның кул күтәрүләрен сорыйм.

Бер кул да күтәрелмәде.

Бу авыл советының исеме генә бар, эше юк икәнлеге, шуңа күрә дә контр элементлар өстенлек алганлыгы көн кебек ачык иде хәзер Миңнуллага. Мондый шартта бер мәсьәләне дә иректә рәвештә тавышка кую юлы белән хәл итү мөмкин түгел иде. Шуңа Миңнулла җыелышны таратырга да иртәгә иртән отряд белән өй борынча йөреп, эшне урында хәл итәргә дигән фикергә килде.

– Ярый, иптәшләр. Алайса, җыелышны шушының белән тәмамлыйбыз. Өйләрегезгә таралырга мөмкин.

– Юк әле, көн тәртибендә тагын бер мәсьәлә бар иде бит әле! – дип кычкырды теге калын тавыш.

Инде караңгы төшкән, ә өстәл янындагы бердәнбер фонарьның яктысы шул өстәл тирәсеннән ерак китә алмаганлыктан, ул кешенең үзен күреп булмый иде. Миңнулла, аның сүзләрен болай гына, кызык өчен әйтелгән сүзләр генә дип уйлап, җавап биреп тормаска иткән иде. Ләкин җыелыштагылар берсе дә урыннарыннан кузгалмагач һәм теге адәм әлеге соравын тагын бер кабатлагач:

– Сез нинди мәсьәлә хакында әйтәсез? – дияргә мәҗбүр булды.

– Партиягә дә язасың икән дигәннәрие бит сине.

Бүтән мәсьәләләргә каршы чыккач, монысына да каршы булачак инде болар, дип, Миңнулла ул турыда сүз дә кузгатып тормаска уйлаган иде. Ә алар әнә үзләре башлады.

– Партиягә язмыйлар, абзый кеше, – диде Миңнулла. – Партиягә кабул итәләр. Әллә партиягә керергә исәбегез бар идеме?

– Бар иде шул менә!

– Бик әйбәт. Җыелыштан соң, рәхим итеп, минем янга килерсез дә сөйләшербез-киңәшербез.

– Безнең арада партиягә керергә теләүчеләр тагын бар әле! – дип тавыш бирделәр халык арасыннан.

– Шулаймы? Алайса, болай итик: теләге булган иптәшләр барыгыз да калыгыз, ә башкаларга өйләренә кайтырга мөмкин.

Җыелыштагыларның берсе дә урыннан кузгалмады.

– Бәлки, сезне тыңларлар?! – диде Миңнулла, Шишковның һаман шулай гамьсез утыруына исе китеп.

– Әйткәнне ишеттегезме? – диде теге ваемсыз гына итеп. – Партиягә керергә теләгән кешеләр генә калсын, диелде.

– Ә без барыбыз да керергә телибез! – дип кычкырды калын тавыш.

– Сүз Коммунистлар партиясенә кабул итү турында булачак, иптәшләр, – диде Миңнулла.

– Беләбез!

– Ә коммунистлар партиясенә тик эшчеләр һәм ярлы крестьяннар гына кабул ителә! Һәм һәркем аерым-аерым кабул ителә.

Җыелыштагылар тагын ду килә башлады:

– Ул нинди кеше аралау ди тагын!

– Кайда монда гаделлек?

– Без бөтенебез берьюлы керергә телибез!

– Барыбызны партиягә алмыйсың икән, яхшылык көтмә!

Эшләр болайга киткәч, Миңнулла моның алдан уйлап куелган провокация икәнен төшенеп алды да:

– Тавышланмагыз, иптәшләр, таралышыгыз. Болай аяк өсте генә хәл итә торган мәсьәлә түгел бу. Җыелышны иртәгә иртән дәвам итәрбез. Шуңарчы мин иптәшләр белән сөйләшеп, киңәшеп куярмын да нәкъ уртак бер фикергә килербез, – диде.

Әмма халык һаман таралырга уйламый да иде әле.

– Сез ник бер сүз дә дәшмисез, иптәш Шишков? – диде Миңнулла, Сидор Андреевичның телен йоткан шикелле тын гына утыруына җене чыгып.

Тик шуннан ары гына теге йокысыннан уянып киткән кешедәй сискәнеп куйды да, сикереп урыныннан торып:

– Ишеттегезме сез җыелыш ябык дигәнне?! Тагын ничә тапкыр кабатларга кирәк? – диде.

Ул моны артык каты итеп тә әйтмәгән иде. Ләкин җыелыштагылар минуты белән таралыштылар да беттеләр.

– Теләсәгез, сез ул халыкны «Барыня»га да биетә аласыз, ахрысы, Сидор Андреевич! – диде Миңнулла, кайтырга чыккач. – Моның сере нәрсәдә: куркамы алар сездән, әллә шулай нык хөрмәт итәләрме?

– Төрлесе бардыр инде, – диде Сидор Андреевич. – Ә тыңларга тиеш алар мине. Үзләре сайлап куйган кешене дә тыңламасалар кая китә ул аннары? Шулай да бүген канәгать түгел әле мин алардан.

– Артык шаулашканга әйтүегезме?

– Анысы да булды. Аннан да бигрәк, озак җыелдылар. Сез бит бүген кайтып китмәкче идегез. Ә хәзер менә кунарга туры килер инде. Төнләләтеп юлга чыгып йөрмәссез бит. Якын гына ара түгел. Аннары төрле кораллы бандалар да күбәйде бу араларда.

– Кунарга туры килер шул инде, болай булгач. Эшлисе эшләрнең берсенең дә юньләп очына чыга алмадык бит әле. Иртәгә иртүк сезнең белән һәм авыл советы членнары белән өй борынча йөреп, кемнең күпме ашлыгы барын исәпкә алырга да артыгын дәүләткә тапшыру чарасын күрергә кирәк булыр. Шунда берочтан фронтка барырга яраклы ир-атларның исемлеген дә терки барырбыз.

– Ыһы, шулай итәрбез.

– Сидор Андреевич, әлеге бөтен авыл халкын берьюлы партиягә кертергә тырышу кем коткысы белән эшләнгән нәрсә икән ул?

– Бер дә әйтә алмыйм шул, иптәш Гайсин.

– Шулаймы? Ярый, анысы соңыннан ачыкланыр. Әйтегез әле, Сидор Андреевич, җыелышта нигә алай битараф утырдыгыз сез? Нигә бер мәсьәлә буенча да миңа ярдәм итмәдегез?

– Начальник кеше үзе беләдер ни эшләргә кирәген дип уйладым мин. Шуңа белер-белмәс тыкшынып, комачаулыйсым килмәде.

«Ай-һай, шулай булды микән? Киресенчә, мине көлкегә калдырырга түгел идеме икән исәбең?» – дип уйлап алды Миңнулла. Ләкин уен тегеңә әйтмәде. Чөнки ул әле Сидор Андреевичны бик аз белә, ялгышырга да мөмкин иде...

Кай арада өлгергәндер, Сидор Андреевич Миңнулла белән килгән кызылгвардиячеләрнең дүртесен дүрт фатирга урнаштырып та куйган иде инде. Ә Миңнулланы ул үзләренә алып кайтты. Бу авылның кайбер кешеләренә карата да, Сидор Андреевичның үзенә карата да Миңнулла күңелендә сәбәбе әлегә үзенә дә бик үк анык булмаган ниндидер шик туган иде. Шуңа ул, дөнья эшен белер хәл юк, төнлә андый-мондый хәл килеп чыга калса, бөтенебез дә бергә булу хәерле дигән фикергә килде:

– Юк, Сидор Андреевич. Сез безнең барыбызны да бер фатирга урнаштырыгыз инде!

– Алай булгач, нишләргә икән соң? – дип, Шишков бераз уйланып торды да: – Әһә, алайса болай итебез. Ишегалдында минем тагын бер бәләкәй өй бар анда. Хәзер шуны ягып җылытабыз да – эше бетте! – диде.

Бәләкәй дигән өе дә әйбәт кенә булып чыкты тегенең. Ике агач караваты, дүрт кешегә җитәрлек урын-җире дә бар иде.

– Егетләрең шунда ятсын, ә үзең зур өйдә кун, – дип, Сидор Андреевич бик кыстап караса да, Миңнулланың күңеле тартмады.

– Мин яшь кеше, миңа монда да ярар. Ә зур өйдәге йомшак урында менә бу агай йоклар, – дип, иң өлкән кызылгвардиячене калдырып, үзе бәләкәй өйгә чыкты.

Алар ут сүндереп яткач күп тә үтмәде, ишегалдында кемнәрдер бик каты шаулаша башлады. Ни булды икән дип, Миңнулла сикереп торып чалбарын кия генә башлаган иде, фонарь тотып, ажгырып, алар янына балта һәм күсәкләр тоткан алты кеше килеп керде.

– Ни булды, агайлар? Ник болай кычкырышасыз? – диде Миңнулла.

– Кычкырышабыз икән, значит сәбәбе бар! – диде мир үгезедәй тазасы һәм Миңнуллага инде тавыш калын тавышлысы. – Давай, киен дә чык әле безнең белән урамга. Шунда сөйләшербез!

«Әһә, менә син нинди шәп кеше икән! – дип уйлап алды Миңнулла. – Барысыннан да күбрәк тавышланып, җыелышны таркатуың гына җитмәгән, инде монда да килеп җиткәнсең. Димәк, ата контр инде, болай булгач!»

– Нәрсә сөйләшмәкче буласыз сез? Нигә җыелышта әйтмәдегез әйтәсе сүзләрегезне? – диде Миңнулла, сабырлыгын югалтмыйча.

– Давай, телеңә күп салынма! – диде калын тавыш. – Ыштаныңны тизрәк төймәлә дә – киттек! Шунда барысын да аңлатырбыз без сиңа!

Бүтәннәр дә шаулаша башлады:

– Әйе, әйе, шунда күрсәтербез без сиңа күрмәгәнеңне!

– Карале син, анасының табут тактасын... безнең актык икмәкне талап алып китеп, үзебезне сугышка, пуля астына озатмакчы була икән!

– А ну, давай, тизрәк кыймылда!

Инде аңлашылды: бу кешеләр яхшы ният белән йөрүчеләр түгел. Юк, боларга ияреп чыгарга һич тә ярамый иде хәзер!

– Әйтәсе сүзләрегезне иртәгә әйтерсез, – диде Миңнулла. – Ә хәзер, барыгыз, кайтып ятыгыз! Мин бүген сезнең белән сөйләшергә теләмим.

Ул арада, нигә алып чыкмыйсыз инде шул кызыл этне, дип, өйгә тагын җиде-сигез кеше килеп керде. Хәл тәмам куркынычка әйләнде. Ичмаса, гвардиячеләр дә ярдәм итә алырлык түгел – кылыч, мылтыклары түр почмакка сөяп куелган, ә үзләре торырга өлгермәгәннәр иде.

Теге яңа кергән кешеләр ябырылып үзенә таба килә башлагач, Миңнулла өстәлдә яткан «кыярын» тиз генә үрелеп алды да:

– Туктагыз, мужиклар! Тагын бер генә адым атласагыз да, менә шушы бомбаны ташлыйм һәм барыгызны да шартлатам! – дип кычкырды.

Аның шул тәвәккәллеге ярап куйды. Бунтчылар шүрләп шып туктап калдылар.

– Хәзер үк чыгып китегез моннан! – диде Миңнулла, тегеләргә өннәренә килергә ирек бирмичә. – Мин өчкә кадәр санаганчы чыгып китмәсәгез, бөтенегез дә күккә очачаксыз! Бер... ике...

Миңнулла җиңде: бунтчылар шыпан-шыпан гына башта өйдән, аннары, сүгенешә-сүгенешә, ишегалдыннан ук чыгып киттеләр. Ул арада гвардиячеләр сикерешеп торып, киенеп беткән иде инде.

Сез нигә миңа ярдәмгә килмәдегез, нигә шундый бунтчыларга юл куясыз, дип әйтмәкче булып, Миңнулла Шишков янына зур өйгә керергә теләгән иде, өйалды ишеге тыштан бикле булып чыкты. Шишков каядыр киткән. Кая китте икән? Гаҗәп, өйләрендә хатыны, ике баласы һәм бер гвардияче агай да бар иде бит әле анда. Аларны өстән бикләп китте микәнни?..

Бунтчылар әле һаман таралышмаган, Миңнулланы сүгеп, һаман капка төбендә торалар. Яңадан котырып килеп керә күрмәсеннәр дип, Миңнулла капканы эчтән бикләде дә, Шишковның кайдан һәм ничек кайтып кергәнен саклап торырга кушып, йортның ал һәм арт капкалары төбенә берәр гвардияче куйды. Үзе калган ике гвардияче белән әлеге бәләкәй өйгә керде дә, азрак ял итә алырга ниятләп, чишенеп тормыйча гына урынга ятты.

Ләкин мондый чакта адәм баласының күзенә йокы керәмени? Миңнулла ирексездән әле яңа гына булып үткән хәл турында уйлана башлады. Уйланмаслык та түгел бит. Кара син ул контр элементларны! Җыелышны өзүләре генә җитмәгән, Миңнулланың үзен дә үтермәкче булып килгәннәр. Имеш, ул аларны фронтка, үлемгә җибәрергә дип килгән. Имеш, икмәкләрен тартып алырга җыена... Үзе өчен түгел, Совет дәүләтен саклап калу өчен көрәшкә җибәрергә тели ләбаса ул аларны! Закон буенча йөри. Икмәкләрен дә келәтләреннән себереп алып чыгарга җыенмый. Чәчүлеккә һәм семья членнарына яңа өлгергәнгә җитәрлектән артыгын гына җыймакчы иде бит ул. Шулай дип, җыелышта шар ярып әйтеп тә бирде. Тагын ник явызланып йөри икән бу агайлар? Кем коткысы белән шушылай төнләләтеп бунт күтәрмәкче булды икән болар?.. Ә Шишков үзе каядыр чыгып тайган. Миңнулланы үтергәннән соң җавап бирергә туры килсә, берни белмим, берни күрмәдем, мин ул чакта бөтенләй өйдә үк юк идем, дип әйтмәкче булгандыр инде ул. Кем белә, бәлки, җыелышны соңга калдыруны да шул ук Шишков юри оештыргандыр. Председатель булуыннан файдаланып, корткычлык белән шөгыльләнеп ятмый микән ул? Нәрсәдер бар монда, бар... Дүрт кешелек отряд белән генә тәртип урнаштыру мөмкин булмас бу авылда. Соңыннан, зуррак отряд белән килеп, совет властен бөтенләй яңабаштан оештырырга кирәк булыр. Ә хәзер... Хәзер Шишковның кайтканын гына көтеп торырга да, кайтып керү белән аны кулга алып, Карыйга алып китәргә һәм шунда ныклап торып сөйләшергә кирәк... Авыл агайларының холкы кызык: нинди җикеренеп, кабып йотардай булып килеп кергәннәр иде, бомбаны шартлатам дигәч, минут эчендә чыгып тайдылар. Кешене үтермәкчеләр, ә үзләренең җаны кадерле...

Миңнулла менә шуларны уйлап ятканда, урам як капка төбендә торган сакчы килеп керде дә:

– Зур гына сакаллы бер кеше килде анда, мин – Степанов, миңа Гайсин кирәк, аның белән сөйләшәсе сүзем бар, ди.

– Хәзер үк минем янга керт! Үзең сакта торуыңны дәвам ит!

– Йа Алла! – диде Григорий Петрович, Миңнулла янына кергәч. – Исән икәнсең әле, улыкаем! Үтерергә теләгәннәр бит сине! Әйткән идем бит мин сиңа бездә ныклы совет власте юк әле, килгәндә, әйбәт кенә кораллы отряд алып кил дип. Сөйлә әле, балакай: ничек башыңны саклап ала алдың?

Миңнулла өстәлдә яткан бомбага ымлады:

– Әнә шул нәрсә коткарды. Ә сез моңарчы кайда булдыгыз, Григорий Петрович? Мин сезне авылыгызга килү белән чакырткан идем, Шишков, өйдә юк, тегермәнгә киткән, дип кайтып әйтте.

– Тегермәнгә?

– Әйе!

– О-о-о! Алайса, барысы да аңлашыла! Аның эше икән, димәк. Ә ул үзе көндез минем өйгә килеп керде дә: «Мин бүген Полянкага барган идем, шунда кызың Мария очрады. Зинһар, әйт әле этигә, тизрәк килеп җитә күрсен, улыбыз бик нык авырый, дип калды, диде. Барсам – онык җен урынына уйнап йөри. Мария әйтә, мин Шишковны күргәнем дә юк, ди. Шуннан уйга калдым: раз Шишков мине монда алдалап җибәргән икән, димәк, аңа миннән котылып тору кирәк булган. Димәк, нindидер этлек эшләргә әзерләнә. Ул бик яхшы белә, мин авылда чакта барысын да бик яхшы күреп-белеп торам. Төнге каравылчы бит мин. Раз, мин әйтәм, Шишков мине алдаларга уйлаган икән, тукта, болай авыз ачып, кунып ятмыйм, шыпырт кына кайтып,ниләр мәтәштергәнен карап карыйм әле моның. Шулай дип уйладым да – әйдә авылга. Кайтсам, әйтәләр: каравыл өендә җыелыш булды, диләр. Анда ниләр булганын да сөйләп бирде күршем Петр. Шунда җыелыштан кайтканда, теге беркөн мин әйткән контрларның, болай бармый бу, бүген төнлә волком әтәченең муенына кызыл муенса тагарга яки бүтән берәр төрле әмәлен табып юк итәргә кирәк, дип сөйләшкәннәрен дә ишетеп калган. Менә шуннан ары мин...

Григорий Петровичның сүзе шунда бүленеп калды, чөнки сакчылар, аркасына мылтык терәп, Шишковны алып кереп киләләр иде.

– Бу нинди тамаша бу, иптәш Гайсин? Мине тоткарларга ни хаклары бар аларның? – дип, Шишков Миңнулланы күрү белән бик кызып тотынган иде, Миңнулла, аңа бөтенләй игътибар итмичә, сакчыларга:

– Арестантның кулын бәйләгез! – диде. Шишков тагын да ныграк тавыш куптара башлагач, йоклаган кешеләрне уятмасын дип, авызын да томалатты. Аннары олы өйнең ачкычы кайда икәнен сорады. Шишков, белмим дип, баш чайкагач:

– Яхшылык белән әйтмәсәң, өйалды ишегеңне ватабыз, – дип тә куркытып карады. Әмма Шишков һаман белмим дип барды. Тик Миңнулла, тотып атам хәзер, дип маңгаена наган терәгәч кенә, яшергән җиреннән ачкычны алып бирде.

Кече якта, берни тоймыйча гырлап, Миңнулла белән килгән кызылгвардияче агай йоклап ята һәм аның авызыннан аракы исе килә иде. «Тәки алдалаган – исерткән икән үзен Шишков-контр!» – дип уйлап алды Миңнулла. Аны уятырга кушты да олы якка үтте. Зур агач караватта, өсләрендәге юрганнарын ачып ташлап, ике сабый – Шишков малайлары йоклый, ә хатыны Клавдия түтәй, өстенә киенгән килеш, бер почмакта сулкылдап елап басып тора иде.

– Елама, Клавдия түтәй, үзеңә дә, балаларыңа да тимәбез без, – диде Миңнулла, бичара хатынны кызганып.

– Ә Сидорны нишләтәсез?

– Аны үзебез белән алып китәргә туры килә.

Клавдия түтәй кычкырып ук еларга тотынды:

– Ой-йой-йой! Аллакай гынам! Аллакай гынам минем!..

Аның тавышына уянып, балалары да куркышып еларга тотынды. Шул гөнаһсыз сабыйларга карагач, тәннәре чымырдап, күңелләре әллә нишләп китте Миңнулланың. Әйе, әтиләренең совет властена дошман, корткыч икәнен белми шул алар. Тик яраткан әтиләре итеп кенә беләләр. Ихтимал, Шишков аларны үзе дә бик яраткандыр, аларга карата гадел булырга тырышкандыр, аларга гел яхшылык кына эшләгәндер.

Миңнулла Шишковка хатыны һәм балалары белән хушлашырга кушты. Шишков балаларын да, хатынын да кочып-кочып үпкәннән соң, тегеләр өчесе дә, аңа ябышып, отыры үзәк өзгечрәк итеп елый башладылар. Шуңа Миңнулланың гвардиячеләргә, әйдә, алып китегез инде тизрәк, дип әйтергә теле бармады. Ул арада Григорий Петрович, килеп, аның колагына:

– Әллә калдырасыңмы, энекәш, балалары бик кызганыч бит, күз яшьләре төшәр, – диде.

– Үзем дә шулайрак уйлап тора идем, Григорий Петрович. Ләкин калдырсак, корткычлыгын тагын дәвам итәр бит ул.

– Итмәс. Шүрләде инде ул.

Шуннан соң да байтак икеләнеп торды Миңнулла. Ахырдан балаларны кызгану хисе җиңде һәм ул үз кулы белән Шишковның кулларын чиште дә:

– Ярый, Сидор Андреевич, балаларың һәм Клавдия түтәй хакына бу юлга кичерәм мин сине. Ләкин кара аны, алга таба да контр эш алып баруыңны дәвам итсәң, миңа үпкәлисе булма! Шушы көннәрдә үк сезнең авылга тагын киләчәкмен. Шуңарчы продналог җыюны юлга сал! Ярлылар комитеты оештыр! Кызыл Армиягә яраклы ир-атларыгызның исемлеген төзеп куй!

– Бөтенесен дә эшләп куям, иптәш Гайсин! – дип, Шишков Миңнуллага мең-мең рәхмәтләр әйтеп калган иде. Ләкин...

**11**

Миңнулла Матвеевкадан кайтканга ике тәүлек тә тулмаган иде, яман хәбәр китерделәр: төнлә каравылда торган чагында Григорий Петровичны үтергәннәр иде.

Унбиш кешелек отряд белән Миңнулла шул ук көнне Матвеевкага барды. Григорий Петровичны танырлык та түгел – шултикле каты кыйнаганнар.

Миңнулла эшне авыл советы председателе Шишков белән сөйләшүдән башламакчы булган иде, ул нияте барып чыкмады: Сидор Андреевич өйләрендә юк һәм аның кайда икәнен берәү дә, хәтта хатыны Клавдия түтәй дә белми иде.

– Кичә кичке аштан соң өйдән чыгып киткән иде, шуннан бирле кайтканы юк, кайда йөри торгандыр, – дип җавап бирде ул, үзе дә бик нык кайгырып.

«Димәк, Григорий Петровичны үтерүдә Шишковның да катнашы бар инде, болай булгач! – дигән уй телеп үтте Миңнулланың миен. – Их, теге чакта кулга алгач ычкындырасы калмаган икән аны! Кызганган булдым бит. Аннары Григорий Петрович та балаларын кызганып, калып торсын, дигән иде. Ә Шишков, паразит, әнә Петровичның үзен кызганмаган! Ну, кабахәт җан! Ну, әгәр минем кулга тагын эләксәң...»

Миңнулла авыл советының бүтән членнарыннан сораштырып караса да, Григорий Петровичның үлеменә кагылышлы бернинди мәгълүмат ала алмады. Шуннан соң ул Матвеевка халкын кайгы митингысына җыярга кушты. Халыкны Григорий Петровичлар ишегалдына җыйдылар. Болдырга мәрхүмнең табутын чыгарып куйдылар. Шул табут янына басып, Миңнулла сүз алды. Ул Григорий Петровичның гаделлек сөюче, туры сүзле һәм чын күңеленнән совет властена бирелгән кеше булганлыгын әйтеп китте дә:

– Шушы яхшы кеше инде менә безнең белән бергә эшли алудан, сөйләшә алудан мәхрүм, – диде. – Аның гомерен контрлар кискән. Ул контрлар сезнең авылныкы. Кайберләре, бәлки, менә хәзер дә

сезнең арагызда басып торадыр әле. Аларны табарга һәм хөкем итәргә кирәк. Ләкин моны без – волком хезмәткәрләре генә башкарып чыга алмыйбыз. Сезнең ярдәм кирәк безгә, иптәшләр! Григорий Петровичның үлеме – авыл советы председателенең корткычлык юлына басуы нәтиҗәсе. Менә хәзер дә председатель Шишков каядыр юкка чыккан. Моннан алдагы килүемдә миңа каршы бунтны да, һичшиксез, ул оештырган булгандыр. Кыскасы шул: сезнең авыл советы үз вазифасын үти алмады, иптәшләр. Совет властен ныгыту өчен тырышасы урында, авыл ярлыларына һәрьяклап ярдәм итәсе урында, корткычлык эше алып барган ул. Шуңа күрә менә шушы минуттан авыл советыгыз таратылган дип исәпләгез. Ә хәзер, әйдәгез, Григорий Петровичны мәңгелек йортына илтеп кайтыйк та, каравыл өе янына җыелып, авыл советының яңа составын сайлап куярбыз. Кемнәрне сайлау турында уйлаша торыгыз. Шунысын исегездән чыгармагыз: авыл советы составына тик ярлылар гына сайланырга тиеш!..

**12**

Миңнулла бүген дә теге көнге шикелле тавыш-гауга чыкмаса ярар иде дип шикләнгән иде. Әмма җыелыш гаҗәп тыныч һәм эшлекле үтте.

– Сезнең арагызда Коммунистлар партиясе члены бармы? – диде Миңнулла, Григорий Петровичны җирләп кайткач, яңадан җыйналган халыкка мөрәҗәгать итеп.

Дөресен әйтергә кирәк, ул моны коммунист булуына ышанып түгел (әле өченчекөн генә берәү дә юк иде бит), болай гына сораган иде. Ләкин аның гаҗәпләнүенә каршы, халык арасыннан «бар!» дигән тавыш ишетелде. Ул да булмады, тавышның иясе, үзе дә алгарак үтеп:

– Мин – коммунист, иптәш Гайсин, – диде.

Чынлап сөйли микән бу кеше дип, Миңнулла тегеңә сынабрак карады. Башына колакчын бүрек, өстенә солдат шинеле кигән, урта буйлы, сул кулын сөлге белән бәйләп муенына аскан утыз биш-кырык яшьләрендәге бу кеше алай шаярып сөйләшүчегә охшамаган иде.

– Монда, минем янга рәхим итегез, иптәш! – дип, Миңнулла тегене үз янына дәшеп китерде.

Агайның исеме Сергей, фамилиясе Семенов, атасының исеме Степан икән. Шушы авылда туып үскән. Ярлы крестьян малае. Шушы елның сентябрь аенда үзе теләп акларга каршы сугышка киткән. Пермь губернасында, Өченче армия сафында хезмәт иткән. Шунда партиягә кергән. Көнгер юнәлешендә дошманга каршы сугышта яраланган. Ләкин аны госпитальгә алмаганнар. Синең яраң әллә ни авыр түгел, син аяклы яралы, аннары туган җирең дә якын гына, кулың төзәлгәнче, өеңдә дәвалана тор, ә бездә авыр яралыларга да урын җитми, дип кайтарып җибәргәннәр.

– Бик әйбәт булган әле кайтарулары! – диде Миңнулла, чын күңеленнән куанып. – Югыйсә сезнең монда бер коммунист та юк иде. Сез менә бу кешене беләсезме? – диде аннары, халыкка мөрәҗәгать итеп.

– Беләбез! – дип кычкырдылар аңа.

– Яхшы беләсезме?

– Яхшы беләбез!

– Алайса, авыл советы составына мин менә шушы иптәшне тәкъдим итәм. Кем дә кем Семенов Сергей Степановичны авыл советына член итеп сайларга ди – кулларыгызны күтәрегез!

– Яхшы. – Миңнулла үзе белән рәттән басып торган отряд командирына карады: – Яле, тиз генә санап алыйк, Федор Михайлович!

Сергей Степановичны сайларга ризалык белдереп, кырык алты кеше кул күтәргән булып чыкты.

– Ә каршылар? – диде Миңнулла.

Каршылар егерме өч кеше булды.

– Бер якка да кул күтәрмәүчеләр?

Андыйлар җиде кеше иде.

– Шулай итеп, – диде Миңнулла, – күпчелек тавыш белән иптәш Семенов Сергей Степанович Матвеевка авыл советына член итеп сайланган дип исәпләргә! – Аннары, карандашын тешләп ни язарга белмичә аптырап калган беркетмә язучыга карап: – Беркетмәгә менә шулай дип язып куярга кирәк! – диде.

Тагын ике кешене сайларга кирәк иде.

– Кемдә нинди тәкъдимнәр бар, иптәшләр? – диде Миңнулла.

Бер кеше, миндә тәкъдим бар, дип кулын күтәреп алгарак үтәргә итенә башлаган иде, ләкин аны, тик кенә тор син, Фрол, сүз монда байлар советы турында түгел, ярлылар советы турында бара, дип, аңа ирек бирмәделәр. Сергей Степанович тәкъдиме белән советка тагын ике ярлы кешене сайладылар.

Аннары Миңнулла яңа сайланган совет алдында торган бурычларга тукталып, хәзерге чорда шул бурычларның иң мөһиме дәүләткә икмәк тапшыруны юлга салу икәнен аңлатты.

– Ә сез, – диде ул, җыелыштагыларга мөрәҗәгать итеп, – авыл советына менә шул ифрат дәрәҗәдә мөһим бурычны тизрәк гамәлгә ашыру өчен кулыгыздан килгәнчә ярдәм итәргә тиешсез. Сезнең

авылда икмәк бар. Мәсәлән, мин үзем дә җиде кешегезнең яшерелгән икмәкләре булуын беләм. Кимендә иллешәр поттан артык икмәкләре бар аларның. Ә Кызыл Армиягә икмәк кирәк! Завод эшчеләренә икмәк кирәк. Аларга көненә нибары бер әчмуха бирелә торган икмәкнең дә җитмәгән чаклары була. Ә монда иллешәр потлап икмәк яшереп яталар. Шушы җыелыш алдында катгый итеп әйтеп куям: икмәкләрен яшергән кешеләр әгәр иртәнгә кадәр үзләре килеп миңа икмәкләренең кайда икәнлеген әйтеп бирмәсәләр – үзләренә үпкәләсеннәр. Без аларны, Совет дәүләтенә каршы корткычлык эшләүчеләр буларак кулга алып, үзегезнең авыл халкы алдында ук атып китәчәкбез! Миндә икмәк барын белми торгандыр әле дип уйламасын ул кешеләр. Минем кулда Григорий Петрович язып калдырган исемлек бар. Ул исемлектә кемнең икмәге кайда яшерелгәнлеге дә күрсәтелгән. Григорий Петрович төнге урам каравылчысы иде бит. Ул барысын да күзәтеп, белеп торган. Кулаклар шуңа үтергән аны. Тагын шунысын да искәртеп куям: икмәкләрен үз ихтыярлары белән дәүләткә тапшырырга риза булган кешеләргә тимәячәкбез. Ә бүтәннәре рәхим-шәфкать көтмәсен...

Аннары Миңнулла сүзне икенче көн тәртибенә – партиягә кабул итү мәсьәләсенә күчереп, Коммунистлар партиясе членнарының бурычларын, хокукларын аңлатты һәм партия сафына тик ярлылар гына кабул ителүен әйтте дә:

– Менә шул бурычларны үтәргә әзер торган иптәшләрнең кул күтәрүләрен сорыйм, – диде.

Җыелыштагыларның тик икәве генә кул күтәрде.

– Беркөн бөтен авылыгыз белән партиягә кермәкче булган идегез бит, хәзер кире уйладыгызмыни? – диде Миңнулла, бу хәлгә азрак сәерсенеп.

– Беркөнгеләр бүген монда юк инде, энекәш! – диде кул күтәрүчеләрнең берсе. – Син отряд белән килгәнеңне белгәч, аннары Григорий Петровичлар ишегалдында каты гына итеп сөйләп тә алгач, сыпыртты инде алар җыелыштан.

– Зыян юк, җыелыштан китсәләр дә, совет властеның гадел хөкеменнән ерак китә алмаслар! – диде Миңнулла. – Ә партиягә керергә теләгән иптәшләр белән җыелыштан соң аерым сөйләшербез.

Кызыл Армия һәм аңа ярдәм итү мәсьәләсенә күчкәч, Сергей Степанович сүз сорады. Аның ни сөйләячәген Миңнулла белми, шуңа аңа сүз биргәндә эшне бутап ташламаса ярый инде дип шикләнебрәк кенә биргән иде. Әмма Сергей Степанович сәяси яктан да, ил һәм фронт хәлләреннән дә хәбәрдар һәм хәйран шома телле кеше булып чыкты. Башта халыкка Совет хөкүмәтенең шушы елның унбишенче гыйнварында кабул ителгән «Эшче-Крестьян Кызыл Армиясен төзү турында»гы карарын аңлатты, аннары июль аенда Советларның V Бөтенроссия съезды булып, анда Совет Конституциясе кабул ителүен һәм ул Конституциядә совет халыкларына ирек, тигез хокук бирелү белән беррәттән социалистик Ватанны дошманнардан саклап калу өчен унсигез яшьтән алып кырык яшькә кадәр булган ир-атларның хәрби хезмәт итүе мәҗбүри итеп куелуын сөйләп бирде дә сүзен партиянең Урал өлкә комитеты мөрәҗәгатеннән: «Уралның ирек сөюче уллары, көрәшкә күтәрелегез! Кызыл Армия сафларына басыгыз! Сезнең тирәдәге Урал таулары ярыкларында, чокыр-чакырларында хыянәтчеләр һәм контрреволюционерлар үзләренең каберләрен тапсын! Кызыл Урал куркыныч астында! Барыгыз да кулларыгызга корал алыгыз!» – дигән юлларны укып тәмамлады. Степан Сергеевичның нотыгын хуплап кул чаптылар.

Җыелыштан соң теге ике иптәшне партиягә кабул итеп, Матвеевка авылы тарихында беренче партия ячейкасы төзеделәр. Аның секретаре итеп Степан Сергеевич сайланды.

Аннары авыл советы членнары арасында эш бүлештеләр. Арабызда синнән дә тәҗрибәлерәк кеше юк, дип, бертавыштан тагын шул Степан Сергеевичны авыл советы председателе итеп сайладылар.

Авыл советы һәм партия ячейкасы членнары бергәләшеп, ашлыкларын яшереп ятучыларның исемлеген төзеделәр. Андыйлар, ягъни кимендә илле поттан артык ашлыгы булган кешеләр, мәрхүм Григорий Петрович әйткәнчә, җидәү генә түгел, егерме өч булып чыкты.

Дәүләткә тапшырырга тиешле икмәкләрен әле тапшырып бетермәгән һәм тапшырырга алай атлыгып тормаган кешеләр дә байтак иде. Аларның исемлеген төзеп, үзләрен авыл советына чакыртып сөйләшергә булдылар.

Ахырдан Кызыл Армиягә кешеләр җибәрү мәсьәләсенә тукталып, армия хезмәтенә ярарлык ир-атларның исемлеген төзеделәр. Бу авылда андыйлар да күп – утыз ике кеше иде. «Башка авылларның ир-атлары барысы да диярлек сугышта. Дөрес, бөтенесе дә безнең якта түгел. Дошман ягында йөрүчеләре дә бар... Утыз-кырык чакрымда гына фронт сызыгы. Бер якта аклар, бер якта безнекеләр. Аклар, ничек кенә итеп булса да, Пермьгә бәреп керергә, тимер юлны үз кулларына төшереп, Урал аръягындагы гаскәрләре белән кушылырга тырыша. Ә бу авыл мужикларына әллә бар ул сугыш дигән нәрсә, әллә юк. Сәбәбе нәрсәдә соң моның?»

– Бөтен хикмәт урманда! Урманның якын булуында! – диделәр Миңнуллага. – Кызыллар килеп армиягә җыя башласа да, аклар килеп мобилизация игълан итсә дә, урманга кереп качалар. Урманда аларның кыш торыр өчен землянкаларына кадәр бар, дип сөйлиләр. Менә күрерсез әле, теге беренче исемлеккә кергән кешеләрне иртәгә эт белән эзләп тә табып булмас. Төнлә шыпырт кына сызып бетәр шулар!..

Ләкин, асылда, эшләр алай ук начар булмады. Йорт саен тикшереп йөри башлар өчен, иртән отрядына күрсәтмәләр биреп торганда ук беренче исемлеккә эләккән кешеләрнең бишесе, үзләре килеп, Миңнулладан, син кичәге сүзеңдә торасыңмы, энекәш, дип сорадылар да, Миңнулла, әйткән сүз – аткан ук, дигәч, артык икмәкләрен үзләре алып килеп тапшырдылар. Тагын дүртесенекен – тентү вакытында, җидесенекен авыл советы һәм партия членнары күрсәтүе буенча таптылар. Шулай итеп, егерме өч кешенең уналтысыннан дүрт йөз потка якын икмәк җыеп алынды. Ләкин җидесенең икмәкләрен дә, үзләрен дә таба алмадылар. Бу яктан теге агайның сүзе хак булып чыкты. Әмма икмәкнең җыйналган кадәресе дә аз түгел иде. Аннары егерме ике кешене фронтка озаттылар.

Ләкин иң мөһиме шул: Матвеевкада, ниһаять, чын мәгънәсендә совет яклы кешеләрдән гыйбарәт булган авыл советы, чын мәгънәсендә коммунистлардан торган партия ячейкасы төзелде!

Ә теге контр элементлар, әлегә качып котылсалар да, әллә кая китә алмас, бүген булмаса, иртәгә аларның койрыгы кысылачагына Миңнулланың шиге юк иде.

**13**

Матвеевка байларыннан җыеп алынган икмәкне унбиш олауга төяп Карыйга кайтып кергәндә, Хәйретдинов Хәйрулла мәсьәләсе буенча җибәрелгән гвардияче Усыдан әйләнеп кайткан һәм Колчин аңа менә шушы язуны биреп җибәргән иде:

*«Иптәш Гайсин! Мин синең Хәйретдиновка карата күргән кискен чараңа бик гаҗәпләндем. Без монда тикшереп карадык. Аның биографиясендә бер дә алай шикләнерлек нәрсә юк. Хәйретдинов унҗиденче елдан бирле партия члены. Шушы язуны алу белән үк аннан гафу үтен һәм аны тоткыннан азат ит!*

*Бездәге мәгълүматларга караганда, сезнең яктагы волостьларда хәлләр көннән-көн кыенлаша – контрлар активлаша бара. Ничек тә түзәргә тырышыгыз! Хәзергә сезгә корал белән дә, кешеләр белән дә ярдәм итә алмыйбыз, чөнки үзебездә дә эшләр сәгать саен кискенләшә бара. Рухыңны төшермә! Җиңү барыбер безнең якта булачак!*

*Коммунистларча сәлам белән – Е.Колчин».*

Колчинның бу җавабы Миңнулланың җен ачуын чыгарды. Чөнки аның мәсьәләне җентекләп тикшереп тормавы, ашык-пошык кына, кул астындагы документларга карап кына җавап биргәнлеге көн кебек ачык иде. Ә иң яманы: Емельян Петровичның Миңнулла әйтеп язган фактларга ышанмавы ярылып ята иде. Әгәр ул Миңнуллага ышанса, үзең кара инде, Гайсин, мин сиңа ышанам, ничек кирәк тапсаң, шулай эш ит ул Хәйретдинов белән, дип, яки, һич тә булмаса, син аны сак астында безгә озат, без монда яхшылап тагын бер кат барысын да тикшерербез, дип язар иде. Ә ул, үз-үзенә бик нык ышанып, Миңнулла сүзләрен бөтенләй искә дә алмыйча, «азат ит!» дип боерган. Ә бит ул аңа Хәйретдиновны инде күптәннән һәм яхшы белүен, аның совет властена кан дошман икәнен ап-ачык итеп язып җибәргән иде югыйсә!..

Миңнулла башта, әллә үз кулым белән атып үтерим микән шул кабахәтне, аның контр икәнлеген исбатлый торган фактлар җитәрлек бит инде, дип тә уйлаган иде. Әмма соңыннан бу заманда ниләр генә булмый, бәлки, Хәйретдинов, чыннан да, аклар ягында партия заданиесе буенча гына йөргәндер, бәлки, ул, чыннан да, коммунисттыр дигән шик күңеленә килде дә Емельян Петровичның боерыгын үтәргә булды. Ләкин гафу үтенергә күңеле һич тә тартмады.

– Бар, Хәйретдинов, – диде аңа Миңнулла, – бу юлга азат итәм мин сине. Әмма, кара аны, бу якларда бүтән эзең дә булмасын!

– Рәхмәт, Гайсин! Бу изгелегеңне мәңге онытмам! – дип өтәләнеп чыгып китте теге.

Миңнулла өйләренә төшке ашка кайтып килмәкче булып курткасын киеп торганда, аның янына, бик ашыгып, өч хәрби килеп керде.

– Мин – Пенза полкының батальон командиры Мидхәт Мостафин! – диде аларның өстенә кайры тун кигән һәм бил каешына наган таккан.

– Бик әйбәт. Ә мин волком председателе Гайсин Миңнулла булам. Үтегез, утырыгыз!

Соңгы көннәрдә Миңнулла хәрбиләргә инде күнеккән, фронтка китеп баручы частьларның командирлары аның янына еш сугыла торганнар иде. Кайсылары Карыйда кунып китәргә ниятли дә солдатларын фатирларга урнаштыру өчен ярдәм сорап керә. Кайсыларына олаулар кирәк була. Кайсыларының азык-төлек мәсьәләсе койтыланган була да шул җәһәттән ярдәм итүне үтенеп киләләр иде. Әлеге батальон командиры да шундыйрак бер үтенеч белән кергәндер дип уйлаган иде Миңнулла. Ләкин эш ул көткәнгә караганда күп мәртәбә җитдирәк булып чыкты.

– Безнең утырып торырга да, озаклап сөйләшергә дә вакытыбыз юк, иптәш Гайсин, – диде теге агай. – Хәл бик җитди: без чигенергә мәҗбүрбез, аклар үкчәгә диярлек басып килә! Ә сез хәзер, менә шушы минуттан ук, волкомыгызны һәм волкомда эшләүче коммунистларның семьяларын эвакуациягә әзерли башлагыз!

– Кайдан килә соң ул аклар? – диде Миңнулла, тегеңә ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

Фронт сызыгының бу якларга да якынлашып килүен, Колчак бандалары кысрыклавы нәтиҗәсендә безнең гаскәрләр чигенергә мәҗбүр булуын Миңнулла белә иде. Карыйның дошман кулына калу мөмкинлеген дә сизенеп йөри иде. Ләкин ул хәл менә шушылай кинәт кенә, көтмәгәндә генә килеп чыгар дип башына да китерми иде. Гомумән, артык борчылырга урын юк, чөнки волостька караган авыллардан бер дә андый хәвефле хәбәрләр ишетелми иде. Әмма Мидхәт агай уйнап сөйләшми иде булса кирәк:

– Подъелничная – Верхотурка – Комарово юнәлешеннән! – диде ул.

Монысы инде Миңнулла өчен бөтенләй көтелмәгән нәрсә иде. Ни өчен дигәндә, ул юнәлеш иң нык, иң ышанычлы санала иде моңарчы. Анда Кама җыелма полкы тора. Аның командиры Козьминыхны Миңнулла бик әйбәт белә – полкка азык-төлек белән ярдәм иткәне бар иде. Шул чакта Миңнулла аның белән андый-мондый хәл килеп чыгып волкомны эвакуацияләргә туры килә калса, корал һәм сугышчылары белән ярдәм итү хакында сүз куешып та кайткан иде. Ни карады икән соң анда ул Козьминых? Нигә акларны болай тиз генә үткәреп җибәрде икән?

– Козьминых дошманга сатылган! – диде Мидхәт агай.

Аның бу сүзләре Миңнулланың башына чүкеч белән суккандай булды.

– Сез ни әйткәнегезне белеп әйтәсезме, иптәш Мостафин? – диде ул, шаккатып.

– Мин моны бик белеп әйтәм, энем! Күп сөйләшеп торыр чак түгел, хәзер үк эвакуация чарасына керешегез!

– Алай булгач, иң башта икмәкне чыгарып калырга кирәк була инде. Ә аны без үз көчебез белән генә майтара алмабыз. Ярдәм итә алмассызмы икән безгә?

– Анысыннан гына эш калмас. Икмәгегез байтакмы әллә?

– Тугыз йөз потлар чамасы булыр.

– Кайдан килде ул кадәр хәзинә?

– Байлардан һәм продналог түләргә тиешле крестьяннардан җыйдык.

– Кайда ул икмәгегез? Нигә дәүләткә тапшырмадыгыз?

– Соңгы ике көн эчендә җыйналган икмәк ул. Биш йөз потлабын әле бүген генә алып кайттык. Шуңа Осага озатырга өлгермәгән идек. Ә икмәкнең кайда икәнен күрсәтергә хәзер берәр иптәшне җибәрермен сезнең белән.

– Аңлашылды. Алайса, без аны хәзер!..

– Сезнең уегызча, аклар кайчан Карыйга килеп җитәчәк, иптәш Мостафин?

– Иң күп куйганда да ике сәгатьтән монда булачак алар! – диде комбат, бер дә икеләнеп тормыйча.

– Ә сез аларны Карыйга кертмичә күпме тоткарлый алырга ниятлисез?

– Аңламыйм, ничек инде «тоткарлый алырга»?

– Соң сез безне бөтенләй сугышсыз гына дошман кулына калдырып китәргә җыенмыйсыздыр лабаса?!

– Ә-ә-ә! Син әнә нәрсә турында әйтәсең икән! Юк инде, агай-эне, аклар белән тартышырлык мөмкинлегебез юк безнең. Соңгы ике тәүлек эчендә генә дә, әнә шул каршы торырга тырышып, батальонның яртысыннан артыграгын югалттым инде мин. Ул чакта, ичмаса, санаулы гына булса да, патроннарыбыз бар иде. Ә хәзер кеше башына берәр патроныбыз да юк. Шулай булгач, ничек итеп - баштанаяк коралланган дошманны тоткарлый алмак кирәк?

Батальон командиры Миңнуллага әнә шулай дип җавап бирде дә, ничек ашыгып килеп кергән булса, шулай ук ашыгып чыгып та китте.

Миңнулла бер киңәшчесез, бер ярдәмчесез торып калды. Бөтен нәрсә аның җаваплылыгында иде хәзер. Дөрес, икмәк мәсьәләсе хәл ителде, анысы дошман кулына калмас: батальон командирының икмәк өчен чукынырга әзер икәнлеге кыяфәтеннән үк күренеп тора иде. Ләкин икмәкне урнаштырудан тыш та эшлисе эшләр бетәсе түгел иде бит әле. Барыннан да элек волком документларын җыйнап-төреп куярга кирәк. Аннары килеп, волком аппаратында эшләүче иптәшләрне, аларның семьяларын һәм, гомумән, ак бандалар кулына калырга теләмәгән Карый кешеләрен бөтенесен дә ничектер җайлап кына, артык өркетмичә генә эвакуациягә әзерлисе бар. Әти-әниләрен калдырып китү шулай ук куркыныч: аклар Карыйга басып кергәч, малаегыз волком председателе булган икән, коммунист икән дип, теге чакта Хәйрулла тинтерәткән шикелле тинтерәтә башлаулары, хәтта кулга алулары да бик мөмкин. Ниһаять, Зәйнәп... Ул кыз волкомның халык мәгарифе бүлегендә бик теләп һәм тырышып эшли башлаган иде. Зәйнәп волостька кергән авылларның укый-яза белгән һәм Совет яклы булган кешеләрен җыйнап, балаларны яңача, советча укыта башлау мәсьәләсе буенча киңәшмә үткәргәч, шул киңәшмәдә катнашкан өяз мәгариф бүлеге вәкиле – тәҗрибәле педагог һәм коммунист иптәш, аны бик нык ошатып:

– Бу кызны мәгариф бүлегенә алып дөрес иткәнсез, иптәш Гайсин. Яшь кенә булса да, тырыш, кыю һәм иң мөһиме, эшне оештыра белә икән. Кыскасы, укыту-тәрбия мәсьәләсендә Ходай биргән сәләте күренеп тора! – дип канәгать булып киткән иде.

Шул киңәшмәдә һәр авылга кимендә берәр укытучы билгеләнгәннән соң, Зәйнәп ул авылларга укыту биналары, ягъни мәктәпләр булдыру мәсьәләсен хәл итү өчен янып йөри башлаган иде. Байтак авылларда мәктәп биналары билгеләнгән дә иде инде. Ләкин, кызганычка каршы, Зәйнәп ул эшне ахырына кадәр җиткерә алмады – өченчекөн кинәт кенә тиф белән авырып китеп, аяктан егылды. Хәле бик авыр. Вакыт-вакыт саташып китеп, кешеләрне дә танымый. Аны алып китәргәме, калдырып торыргамы? Алып китсәң, болай да хәл эчендә генә яткан кешенең бөтенләй өзлегеп китүе мөмкин. Калдырып китәр идең, беренчедән, фатир хуҗасы үзе дә кылт-мылт кына йөри торган карчык. Икенчедән, аклар басып кергәч, Карыйдагы контрлар Зәйнәпне шул ук сәгатендә сатачак. Дөрес, Зәйнәп әлегә партия члены түгел түгелен. Ләкин аклар партия членнарын гына түгел, совет органнарында эшләгән кешеләрнең барысын да дошман саныйлар бит! Аннары шунысы да бар: Карыйга аклар белән бергә Шакир кабахәт килеп кермәс дип кем әйтә ала?..

**Өченче бүлек**

**1**

Пенза полкының батальон командиры ничек кенә ашыктырса да, эвакуациягә ике сәгать эчендә әзерләнеп чыгып китә алмадылар. Һәм алай ашыгуның кирәге дә булмады. Мостафин батальоны үтеп киткәч, Карыйга аклар түгел, үзенең штабы белән Бирск бригадасы командиры Василий Иванович Дедкин килеп керде дә:

– Эвакуациягә китәргә туры килер, анысыннан бөтенләй үк котылып булмас, – диде. – Ләкин артык кабаланмагыз. Яхшылап җыеныгыз. Коммунист семьяларының берсен дә калдырмагыз. Чөнки аклар гадәттә эшне коммунистларның семья членнарын җәзалаудан башлыйлар. Без, һичьюгы, иртәнгә кадәрле булса да дошманны Карыйга кертмәскә тырышырбыз!..

Күченә башлагач мәшәкате күп була икән аның. Волком әйберләрен олауларга төяп озатып җибәргәнче генә дә тәүлеккә якын вакыт үтеп китте. Ярый әле шул кичтә Фәйзулла Чиркандыдан кайтып җиткән иде. Эвакуация олауларын Миңнулла аның җаваплылыгына тапшырып җибәрде. Фәйзулланың әтисе Сәгыйдулла агай да, мин дә аклар кулына калмыйм, монда калсам, Шәйхетдинов әйләнеп кайтачак та, теге чакта үзе белән ияреп китмәгәнгә ачу итеп, әбизәтелне минем башка җитәчәк ул, дип, олаулар белән китәргә булды. Гомер буе ат җигеп юл йөргән кеше булуын искә алып, Миңнулла аны Фәйзулланың ярдәмчесе итеп билгеләде.

Ә Миңнулланың әти-әнисе Карыйдан китәргә теләмәделәр. Әнисе, кырт кисеп:

– Без үзебезнең Карыйдан бер җиргә дә китмибез, улым. Шушы яшебезгә җитеп, бу дөньяда берәүгә дә зыян китергән кешеләр түгел без. Шулай булгач, Колчак солдатлары гына түгел, Никулай патша үзе килсә дә, куркырлык эшебез юк! – диде.

Бәлки, әти китү ягындадыр, бәлки, ул әнине китәргә күндерә алыр дип өметләнгән иде Миңнулла. Шуңа:

– Әллә китү хәерлерәк булыр микән, әти? – дип әйтеп караган иде. Әмма әтисе бу юлы да аның өметен акламады:

– Әнкәң әйтсә – белеп әйтә, улым, калырга туры килер инде, – дип җавап бирде дә, терлекләргә печән биреп керим әле дип, ишегалдына ук чыгып китте.

Әнисенең бер әйткән сүзеннән кире кайта торган гадәте булмавын яхшы белгәнгә күрә, Миңнулла ул хакта бүтән сүз озайтып тормады.

Ә Зәйнәп мәсьәләсе тәки хәл ителмичә һәм бик үкенечле булып калды.

Каласыңмы, китәсеңме дип сорарга Миңнулла башта аның янына барган иде. Ләкин кыз, җан тиргә батып, саташып ята булып чыкты. Аннары Миңнулла киңәш сорап әнисенә килде.

– Безнең теге волкомның мәгариф бүлегендә эшли торган кыз тиф белән авырый бит әле, аны нишләтик икән, әни?

– Авыру кешене кузгатып йөрү ярамас, улым! – диде әнисе.

– Калдырып китү дә хәвефле шул. Ни юньләп карар кешесе юк аның. Аннары килеп, волкомда эшләгәнен белсәләр, аклар бер-бер хәл ясавы да бар.

– Үзе нәрсә ди соң ул бала, сорадыңмы үзеннән?

– Сөйләшә алырлык түгел шул.

– Алайса, әйдә хәзер үк барыйк та үзебезгә апкайтыйк без аны, улым! Гафифә карчык андый хастаны тәрбия кылырлык кеше түгел, үзе кеше тәрбиясенә мохтаҗ ул, бичара. Мин үзем карап торырмын ул баланы. Бәлки әле, сез чыгып киткәнче хәле дә арулана башлар да, китәсе килсә – китәр, каласы килсә – калыр.

Әни кеше сизмиме соң? Сизенә иде бугай ул Миңнуллаunion Зәйнәпне яратканын. Һәм моның шулай булуын күңеленнән хуплый да иде бугай. Беркөнне Миңнулла төшке ашка кайтмагач, аңа төшке аш китерә килгән чагында волкомда Зәйнәпне күреп:

– Бигрәк тә мәхәббәтле инде шушы бала, үз кызым шикелле күрәм үзен! – дип тә әйтеп куйган иде.

Зәйнәпне өйләренә алып кайткач, аны чыннан да үз кызы шикелле якын итеп карый башлады. Кыз икенче көнне аңына килеп сөйләшә башлагач:

– Күптән үзебезгә апкайтасы калган икән аны! Әнә безнең йортка килү белән хәле рәтләнә башлады балакайның! Юк, беркая да җибәрмим мин аны, – дип, куанычыннан ни эшләргә дә белмәде.

Әмма Зәйнәпнең каласы килми. Ул:

– Китәм! – дигән иде.

Ләкин...

Усыга аклар бәреп кергәнлектән, ул якка юл тотарга һич ярамый. Көңгер дә куркыныч астында, анда бару шулай ук мөмкин түгел. Аннары килеп, олы юл буйлап барырга гомумән мөмкинлек юк, чөнки анда бертуктаусыз – кайсы чигенү ягына, кайсы акларга каршы – безнең гаскәрләр агылып тора иде. Әмма иң кыены шул булды: волком олауларын кая таба озатырга икәнен Миңнуллага беркем, хәтта бригада командиры Василий Иванович та тәгаен генә әйтә алмады. Маршрутны, тәвәккәлләп, Миңнулланың үзенә сайларга туры килде. Шишмәрә – Харис авыллары аша Таныкка бара торырга кушты ул Сәгыйдулла агай белән Фәйзуллага. Ә үзе волкомның кызылгвардиячеләр отряды белән Карыйда калды. Чөнки Василий Иванович, махсус приказ биреп, Карый отрядын үзе командалык итә торган Бирск отряды составына керткән һәм аның командиры итеп Миңнулланы билгеләгән иде.

Миңнулла Карыйда каласы булгач, «Алайса, мин дә калып торам, киткәндә үзең беләк алып китәрсең, яме!» – дип, Зәйнәп тә калган иде.

Миңнулла отрядына Василий Иванович бригаданы азык-төлек һәм аклар бик нык кыса башлап, чигенергә туры килгәндә кирәк булачак транспорт белән тәэмин итү бурычын йөкләгән иде. Бригада Карыйны саклап өч тәүлек буена каты сугыш алып барды. Ул көннәрдә Миңнулла үзенең отряды белән гел транспорт мәсьәләсе белән генә шөгыльләнде: волостьның әле дошман кулына эләкмәгән авылларыннан иллегә якын җигүле ат җыйнап алып кайтты. Дөрес, ул атларны бөтенләйгә түгел, вакытлыча, бригада йөкләрен икенче җиргә күчерү өчен генә җыйдылар. Соңыннан хуҗаларына кайтарып бирелергә тиеш иде ул атлар. Ләкин ат хуҗалары барысы да диярлек үзләре ияреп килде. Миңнулла аларга:

– Хәвефле юлга чыгасыз бит, агай һәм апайлар, алай-болай юлда дошман белән бәрелешергә туры килеп, пуля-мазар тиеп куйса, ни эшләрсез? – дип әйтеп караса да, аны тыңларга теләмәделәр:

– Йә атларны калдырасың, яки атлар белән үзебезне дә алып барасың! – диделәр.

Кызганычка каршы, Миңнулланың шиге урынлы булып чыкты. Бригада йөген төягән олаулар Карыйдан кузгалып күп тә китмәгән, аклар засадасына юлыккан һәм шунда теге ат хуҗаларының уникесе һәлак булып калган иде.

Бирск бригадасы киткәннән соң да Миңнулла үз отряды белән Карыйда бер төн кунды әле. Чөнки Василий Иванович аңа:

– Син, Гайсин, отрядың белән Карыйда каласың һәм, бригаданың чигенүен тәэмин итеп, соңгы чиккә кадәр дошманны тоткарлап торасың! – дип боерып киткән иде.

Чамасыз озын тоелган гыйнвар төне чагыштырмача тыныч узды. Дошманның биш кешелек атлы разведкасы, тугыз кешелек чаңгычылар группасы Карыйга килеп керергә омтылып караганнар иде, әмма отряд егетләре аларны якын да җибәрмәделәр. Шул бәрелеш вакытында ике колчакчыны әсир иттеләр. Әсирләрнең әйтүенә караганда, Карыйдан биш-алты чакрымдагы күрше авылда акларның күпсанлы гаскәре тупланган. Ләкин аклар алга барырга шикләнәләр, чөнки Карыйда кызылларның көче зур дип уйлыйлар, шуңа үзләренә ярдәмгә яңа көчләр килгәнне көтеп торалар икән.

– Ә өстәмә көчләр кайчан килеп җитәргә тиеш соң? – дип сорагач, әсирләр, анысын тәгаен генә әйтә алмыйбыз, ләкин бер-ике көнсез булмас әле, дип җавап биргәннәр иде. Әмма асылда алай булып чыкмады.

**2**

Әле яхшылап яктырылып та җитмәгән иде, Карыйның көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш ягыннан чакрым ярым киңлегендәге фронтны иңләп, дошман һөҗүмгә күтәрелде. Ә Миңнулла отрядында нибары егерме өч кеше булып, аларның дүртесе авылның икенче башындагы юлны саклап торырга җибәрелгән иде. Мондый хәлдә меңләгән аклар гаскәренә каршы торып азапланудан мәгънә булмас иде. Шуңа Миңнулла болай да бик санаулы гына булган патроннарны аттырып тормады.

– По ко-оням! – дип команда бирде дә теге дүрт иптәшне дә алып китү нияте белән, отрядны ияртеп, авылның икенче башына ыргылды.

Ләкин авылның ул очыннан дошман сугышчылары инде бәреп кергән һәм, «ура!» кычкырып, күпергә якынлашып киләләр иде. Ә безнең сакчыларның берсе дә күренми. Алар ни караган, нигә дошман бәреп кергәнне сизми калганнар – бу хакта Миңнуллага берни дә мәгълүм түгел иде. Хыянәт иткәннәр дияргә дә нигез юк. Чөнки шул дүрт кешенең берсе Миңнулланың бертуган абыйсы – Зәйнулла иде ләбаса! (Ул аягы яраланып, әле атна-ун көн элек кенә фронттан кайткан һәм, ярам артык зыянлы түгел, атка атланып йөрергә була, тик ятканчы, ичмаса, аз булса да файдам тияр, дип, волком отрядына язылган иде.) Бүтәннәре хыянәт итсә дә, ул үз энесенә хыянәт итмәс бит инде. Йомшаграк холыклы булса да, беркайчан да иманын сата торган кеше түгел иде ул. Аннары фронттан шактый үзгәреп, сәяси яктан активланып, тереләнеп кайткан иде...

Ләкин ни булса да булган, сакчыларның берсе дә күренми иде. Ә аклар өч яклап һаман якынлаша, һаман боҗраны кысып киләләр.

Зәйнәп тә Миңнулла белән китәргә тели, һәм Миңнулла аны алып китәргә вәгъдә дә биреп куйган иде бит әле. Ләкин хәзер, эшләр менә шушылай көтелмәгәнчә килеп чыккач, аның өйләренә кайтып ат җигеп (авыру Зәйнәпне бары шулай гына алып китеп була!) торыр арасы калмагач, аклар кулына эләкмәс өчен, секунд та тормыйча, авылдан чыгып китәргә мәҗбүр иде. Ул:

– Отряд, минем арттан! – дип боерды да, атын читән аша сикертеп, кыр өсләтеп кенә авылдан чакрым ярым чамасындагы урманга таба элдертте.

Үз сугышчылары дип уйладылар булса кирәк, башта аклар аларга атмады. Тик отряд инде урман буена барып җиткәч кенә ут ачтылар. Шулай да отрядның ике атын, бер кешесен яралап өлгерде кабахәтләр! Яралы атларны калдырып китәргә туры килде, ә яралы агайны, ияргә салып, үзләре белән алдылар.

Туып үскән җирләре булганлыктан, Миңнуллага бу урманның һәр сукмагы таныш иде. Әнә шул үзе генә белгән сукмаклар буйлап бик зур саклык белән Миңнулла отрядын Карыйдан сигез чакрымдагы Бажук авылына алып барды. Бажук урамнары гаскәриләр белән дыңгычлап тутырылган иде: безнең гаскәрләр, чигенеп баручы гаскәрләр. Миңнулла алар янында тоткарланып торырга теләмәде. Отряд Бажукны ындыр артлатып үтте дә тагын урман сукмаклары буйлап арыга – Шишмәрә авылына таба китте. Шулай итеп, Зәйнәп-сылу аклар басып кергән Карыйда калды. Зәйнулла абыйсы белән теге өч кызылгвардиячененң язмышлары Миңнуллага шулай ук билгесез иде.

**3**

Миңнулла отряды Шишмәрәгә килеп җиткәндә, кышкы ялкау кояш инде батып та бара иде. Олы юл белән килгәндә, Шишмәрә Карыйга әллә ни ерак түгел, нибары утыз биш-кырык чакрым гына. Ә менә бүген кача-поса урман сукмаклары аша килеп җиткәнче көн үтеп китте. Инде кар шактый калын иде, шуңа атларны артык куып булмады. Болай да салкын көн кичке якта тагын да ныграк суытып җибәрде. Аннары атларны да ял иттерергә кирәк иде. Шуңа Миңнулла бүген Шишмәрәдә кунарга ниятләп, авыл советын сораштыра башлаган иде, Карый волкомының обозы да шушы авылда туктаган икәнлеге мәгълүм булды. Фәйзулла белән аның әтисе Сәгыйдулла агай җитәкчелегендәге ул обоз Шишмәрәгә өченчекөн үк килеп җиткән. Ләкин дошманга юлыгудан шикләнеп, Сәгыйдулла агай шунда туктап торуны кирәк тапкан. Шикләнергә нигезләре дә булган шул: Шишмәрәгә килеп җитәр алдыннан аларга ниндидер кораллы банда һөҗүм иткән һәм арттагы ике олауны кулларына төшергән икән. Ул олауларда килүче биш кеше дә (икесе ир-ат, бүтәннәре хатын-кызлар) шунда тегеләр кулына эләккән.

– Ярый әле Шишмәрә якын булды, – диде Фәйзулла Миңнуллага. – Ераграк чакта һөҗүм иткән булсалар, харап иде безнең хәлләр!

– Син үлемнән шулай нык куркасыңмыни, Фәйзулла?

– Үзем өчен курыкмыйм ла! Үлдең – беттең. Нәрсәсе бар аның ул хәтле. Хатын-кызлар, бала-чагалар бар бит безнең белән. Шуларны кызгандым.

Вакытның һәр минуты алтынга тиң: Шишмәрәгә төнлә аклар килеп җитүе мөмкин – олауларны монда калдырырга ярамый иде. Отряд кешеләре һәм атлары инде нык кына йончылган булса да, Миңнулла Шишмәрәдә ялга тукталып тормаска, олауларны Харис авылына – тынычрак урынга алып китәргә карар кылды.

Аларны юлга әзерләгән арада аяк өсте генә диярлек тамак ялгап һәм атларын ашатып-эчертеп алдылар да тагын кузгалдылар. Отрядының яртысы белән Миңнулла үзе алдан китте, яртысын обозларны арттан саклап барырга калдырды.

Юлда аклар белән дүрт тапкыр чәкәшеп алырга туры килде. Дөрес, алар унар-унбишәр кешеле аерым группалар гына иде. Әмма барыбер шактый зыяннары тиде: отрядның өч кызылгвардиячесен үтерделәр, олауда бара торган ике кешене яраладылар, атларга дигән фураж төялгән өч олауны кисеп алып калдылар, бер атны яраладылар. Акларның үзләренә дә ару гына эләкте: җиде атлары, биш-алты кешеләре сафтан чыгарылды.

Ләкин болар гына отрядның югалтуын җиңеләйтә алмый иде. Миңнулланың тик бер генә юанычы бар: «Ярый әле, башлары җитеп, Фәйзулла белән Сәгыйдулла агай Шишмәрәдә отрядны көтеп торган. Үзләре генә юлларын дәвам иткән булсалар, бандитлар берсен дә калдырмыйча кырып бетерәсе икән. Ярый әле сабыр иткәннәр», – дип кенә азрак тынычландырды ул үзен.

**4**

Отряд Харис авылына килеп кергәндә, сәгать иртәнге тугыз тулып унынчы киткән иде. Кешеләр дә, атлар да арыган, ачыккан. Аларны фатирларга урнаштырырга, ял иттереп, кунып китәргә кирәк, шунсыз юлны дәвам итү мөмкин булмаячак. Авыл халкының әйтүенә караганда, бу тирәләр әлегә шактый тыныч, акларның күпләп күренгәне юк. Аннары авылның, биш-алты гына кешедән гыйбарәт булса да, үзенең дә кызылгвардиячеләр отряды бар, һәм ул отряд членнары, чиратлашып, Харисның ике башында, олы юл өстендә дежур торалар иде. Шуның өстенә тагын ул отрядның командиры да Миңнуллага таныш кеше – аклар кулында тоткында чагында Богородскидан Алмазга тикле этапта Миңнулла белән бер бәйдә барган, бергә качарга җыенган Сәмигулла агай булып чыкты.

Сәмигулла агай барыбер үз дигәнен иткән: аклар аны теге чакта Алмазга алып барып япканның өченче көнендә үк качып китеп, туп-туры шушы үзләренең Харис авылына кайткан. Июль аенда контрлар оештырган бунт вакытында бу авылның ярлылар комитеты да таркатылган һәм Сәмигулла агай кайтып төшкәндә дә башлыксыз торган булган. Шуннан Сәмигулла агай, тәвәккәлләп, комбед председателе вазифасын үтәүне үз өстенә алган һәм ару гына эшләп килә икән.

Миңнулланы танып алгач, ул бот чабып, исе китеп торды. Аннары:

– Әйткәнием бит мин сиңа, исәнлектә очрашырга язсын, дип! Менә тагын очраштык бит, энекәш! – дип, аркасыннан кагып куйды.

Сәмигулла агай да ял итеп, кунып китү ниятен хуп күрде һәм олауларны икешәрләп-өчәрләп фатирларга үзе урнаштырып йөрде. Ә Миңнулланы:

– Андый-мондый хәл килеп чыгып, маминт кына күтәрелергә туры килә калса, бер күчтә булуыгыз хәерлерәк, – дип, отряды белән бергә ике катлы бер зур йортка урнаштырды.

Узган көн ак бандалар белән чәкәләшкән чакта яраланган атны суеп, итен үзләре белән алып килгәннәр иде. Итле аш пешереп, табынга утыргач, өй турына унлап җайдак гаскәриләр килеп туктады. Барысының да аркаларында сугыш мылтыгы, бил каешларында – кылыч. Тик берсенең генә мылтыгы юк. Анысы бил каешына агач кобуралы маузер таккан, иңенә кыр сумкасы, күкрәгенә бинокль аскан иде. Озынчарак каратут йөзле, кыска кара сакаллы, үткен карашлы, урта буйлы, өстенә нык кына кыршылган күн тужурка, башына кызыл тасмалы папаха кигән ул кеше иң беренче булып өйгә килеп керде дә:

– Исәнмесез, иптәшләр. Сез кемнәр буласыз? Командирыгыз кем? – диде.

– Исәнмесез. Мин – командир, – диде Миңнулла. Әмма нишләп йөрүләрен әйтергә ашыкмады. Сораучының кем икәнлеген ачыкламыйча торып, капчыкны чишеп ташларга ярамый иде. – Фамилиям – Гайсин. Исемем – Миңнулла. Ә сез үзегез кем буласыз?

– Кара син аны нинди кыю сөйләшә! – диде маузерлы кеше. – Сиңа ничә яшь, иптәш Гайсин? – «Иптәш» сүзен юри басым ясап әйтте.

Миңнуллага әле өченчекөн генә унсигез тулган иде.

Дөресен әйтсәм, маузерлы тагын, нигә бик яшь, фәлән дә фәсмәтән дип төпченә башлар, дип уйлады ул. Шуңа:

– Егерме өчтә! – дип җавап бирде.

– Оһо! – диде маузерлы. – Ә мин сиңа унҗиде-унсигездән ары юктыр дип уйлаган идем.

– Сез минем сорауга җавап бирмәдегез бит әле, – диде Миңнулла. Бу хәрбинең сүзне гел шаяру ягына борырга теләвенә эче поша башлаган иде аның.

– Ах, да, кичер, иптәш Гайсин, – диде маузерлы, дустанә елмаеп. – Кичер, зинһар, онытып торам икән. Блюхер мин.

Миңнулланың чәчләре үрә торды.

– Урал партизаннары отряды командирымы? – диде ул, тегенең сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

Блюхер турында ул инде шактый күп ишеткән, газеталардан да укыганы бар иде. Һәм әнә шул ишеткәннәре, укыганнары нигезендә Миңнулла аны инде яратып та өлгергән иде. Ләкин ул аны ничектер гайре табигый итеп, Алып батыр сыман таза, дәү кеше итеп күз алдына китерә иде. Ә бу... Шул күкрәгенә аскан бинокле белән бил каешына аскан маузеры булмаса, үзе белән килеп кергән кызылармеецлардан һич тә аерылып тормас иде.

– Оһо! – диде Блюхер. – Болай булгач, миңа үзем турында сөйләп тә торасы юк икән. Әйе, нәкъ шул кеше мин. Бәлки, хәзер сез дә үзегез белән яхшылабрак таныштырырсыз, иптәш Гайсин?

Миңнулла аңа барысын аңлатып бирде дә:

– Табын әзерләгәндә килеп кергән кешегә безнең халыкта мактап йөрисең дип әйтәләр. Сез дә менә мактап йөрисез икән әле. Әйдәгез, табынга рәхим итегез, – диде.

– Без монда нәкъ менә шул тамак ялгап алу нияте белән тукталган идек тә! – диде Василий Константинович. – Ләкин без күбәү – унбер кеше. Сез ашыгызны безгә исәп тотып пешермәгәнсез бит.

– Зыян юк, Василий Константинович. Бары – бергә, югы – уртак, диләр безнең халыкта. Ашы җитәр, анысы мул итеп әзерләргә кушылган иде. Тик менә... – Миңнулла әйтергәме-юкмы дип икеләнеп калды.

– Нәрсә «тик менә»?

– Ат ите пешергән идек без, Василий Константинович.

– Ах, әнә нәрсә! Сез руслар ат итен ашар микән дип әйтмәкче буласыз инде, әйеме? Бер дә борчылмагыз, иптәш Гайсин. Талымлап тора торган заман түгел хәзер! – Ул үзе белән кергән кызылармеецларга карады: – Шулай бит, егетләр?

Аңа бертавыштан:

– Так точно, иптәш командир! – дип җавап бирделәр.

Ашын да, итен дә кунаклар бик яратып ашады. Василий Константинович карап торырга шактый кырыс, күңелсез адәм булып күренсә дә, асылда, йомшак күңелле, җор сүзле кеше икән. Отряды белән дошманга каршы көрәшә-көрәшә, Урал тауларын үтеп безнең якка чыккан чагында, үзенең партизаннарына коралны да, кием-салымны да, азык-төлекне дә дошманның үз кулыннан тартып алырга туры килгәнлеген мәзәк итеп сөйләп алды да:

– Хәзер дә эшләр җиңел түгел. Колчакның көче күп, аңа бөтен дөнья капиталистлары ярдәм итә, – диде. – Ләкин җиңү барыбер безнең якта булачак! Чөнки хаклык безнең якта. Эшче халык безнең якта! Ә халык белән хаклык икесе бергә булганда, аларны бернинди корал белән дә җиңеп булмый!

Хуҗаларына рәхмәт әйтеп, табын яныннан купкач, Василий Константинович Миңнулланың үзен генә дәшеп алды да:

– Так, – диде. – Инде ни эшләргә, кая юл тотарга уйлыйсыз?

– Мин үзем Сарашка бару мәслихәтрәк булмасмы дип тора идем.

– Нинди максат белән?

– Бездәге мәгълүматларга караганда, Сараштa хәзергә тынычрак икән. Шуның өстенә анда Кызыл Армия частьлары да байтак, аларга Сарашны ничек итеп булса да саклап калырга боерык бирелгән, ди. Аннары, минем белүемчә, анда телефон да бар. Пенза бригадасы командиры иптәш Дедкин карамагында безнең бу отряд. Ул үзе белән бәйләнеш тотарга боерган иде. Бәлки, мин ялгыша торганмындыр. Бәлки, сез яхшырак киңәш бирерсез, Василий Константинович?

– Юк, шуннан да яхшырак киңәш бирә алмыйм, иптәш Гайсин, – диде Блюхер. – Без монда Сараш аша үтеп килдек. Әйе, хәзергә анда тыныч. Аклар тиз генә үтеп керә алмас Сарашка. Киресенчә, андагы безнең гаскәрләр үзләре һөҗүмгә әзерләнәләр. Шунда юл тотудан да хәерлесе булмас сезгә. Тик олы юлдан бармагыз. Аклар засадасына эләгүегез мөмкин. – Ул сумкасыннан карта алды да, шул картадан күрсәтеп, аңлатырга тотынды: – Менә моннан, урман әчләтеп, бәләкәй юллардан, Искилде, Танып авыллары аша барыгыз, ярыймы! – Аннары ул үз отряды кешеләренә мөрәҗәгать итте: – Йә, бөркетләр, җылындыгыз, тамакларыгызны туйдырдыгыз. Ә хәзер иптәшләргә барысы өчен дә бик күп рәхмәт әйтик тә по ко-о-оням!

– Сер булмаса, әйтегез әле, Василий Константинович, сез кая барасыз? – диде Миңнулла, озатырга чыккач.

– Республика реввоенсоветына чакырганнар, шунда барам, – диде Блюхер. Аннары: – Ярый, иптәш Гайсин, сау булыгыз! Уңыш телим сезгә! – диде. Адъютанты инде әзерләп тотып торган атына җиңел генә менеп атланып, юырттырып китеп барды.

**5**

Отряд та, олаулар да Сарашка хәвеф-хәтәрсез барып җиттеләр: бәхетләренә каршы, юлда ак бандалар очрамады.

Василий Константинович белеп әйткән: Сараштa безнең гаскәрләр, чыннан да, бик күп иде. Шунлыктан үз җаваплылыгындагы алтмышлап кешегә ничек фатир табарга инде дип борчылган иде Миңнулла. Ләкин бу мәсьәлә дә чагыштырмача ансат хәл ителде.

Сараштa волком телефоныннан тыш фронт телефон станциясе дә урнашкан иде. Шул станция аша Миңнулла, Бирск бригадасы командиры Василий Иванович белән бәйләнешкә кереп, үзләренең хәлен аңлатты.

– Молодец, – диде аңа комбриг, – Сарашка килеп бик яхшы иткәнсез, иптәш Гайсин! Хәзер отрядың да, олауларың да шунда торып торсын. Якын көннәрдә безнең бригада Карый һәм Ашап волостьларын дошманнан азат итәргә тиеш. Шуннан соң олауларыгызны кире алып кайтырсыз. Ә хәзергә отрядың

белән Сарашка якын-тирәдәге авыллардагы кулак амбарларын тикшереп, яшереп яткан икмәкләрен җыйный тор! Бригаданың иң кыен мәсьәләсе – азык-төлеккә бәйле мәсьәлә.

– Тырышырбыз, Василий Иванович. Сез үзегез кайда соң хәзер?

– Мин хәзер Усыда, өяз башкарма комитеты бинасында!

– Ничек инде ул Усыда? – диде Миңнулла, исе китеп. – Усыны аклар басып алды дип үзегез әйткән идегез бит!

– Әйе, алганнар иде. Ләкин без аларны аннан бәреп чыгардык инде! Ярый, боерыкны үтә, иптәш Гайсин. Эшнең барышы турында миңа көн саен телефон аша хәбәр итеп тор!

Икмәк мәсьәләсендә эшләр менә болайрак тора иде. Күрше авыллардагы байларның амбарлары барысыныкы да шып-шыр. Булган икмәкләрен башта аклар, алардан калганын безнекеләр алып бетергән. Яшергән икмәкләре барын-югын берәү дә әйтә алмый. Булса да, кар астыннан эзләп табу мөмкин түгел иде. Шулай да байларда икмәк бар, тик ул сугылмаган, эскертләргә өеп куелган килеш тора.

Ә сугу машиналарын йә ватканнар, йә яшергәннәр. Ләкин Миңнулла барыбер җаен тапты. Чәпләр ясатып, үзләре белән килгән коммунист семьяларындагы эшкә яраклы кешеләрдән һәм отрядындагы кызылгвардиячеләрдән теге игеннәрне суктыра башлады. Шулай итеп, ике йөз җитмеш потлап арыш һәм бодай суктырган иде инде ул.

Ә бүген эшләре тагын да әйбәт бара: бер байның сугу машинасын яшергән җиреннән табып алып, шуның белән фуражга солы суктыра башлаганнар иде.

Көндезге сәгать уннарда Миңнулланы телефонга чакырдылар. Василий Иванович шалтыраткан икән.

– Нигә минем боерыкны үтәүнең ничек барышы турында хәбәр итмисең? Мин сиңа көн саен хәбәрләшеп торырга кушкан идем бит. Ә синең инде өченче көн бер тапкыр да шалтыратканың юк! – диде ул Миңнуллага, шактый нык ачуланып.

Миңнулла аңа әллә ничә тапкыр шалтыратып караган иде. Әмма ул сөйләшергә теләгәндә Василий Ивановичны таба алмыйлар, ә Василий Иванович үзе шалтыратканда Миңнулла каядыр киткән чак туры килә иде булса кирәк.

– Ну, ничек соң анда синең эшләр? – диде Василий Иванович, Миңнулла шул хакта аңлатып биргәч, йомшара төшеп. – Икмәк әзерли аласыңмы азрак?

– Көн-төн шуның артыннан йөрим инде, Василий Иванович.

– Йөрүен аны ахмак та йөри ала. Нәтиҗәсе бармы соң ул йөрүнең? Күпме ашлык әзерләдең?

– Ике йөз җитмеш потлап арыш белән бодай суктырып куйдык инде. Бүген атларга фуражга солы сугабыз. Машина ватылмаса, кичкә утыз-кырык потлап солы булырга тиеш.

– Неужели! – диде Василий Иванович, куанып. – Синнән бернинди дә хәбәр булмагач, рәт чыкмады бугай моннан дип, бик каты ачуланып йөри идем үзеңә. Болай булгач, рәхмәттән башка сүз юк инде. Карале, энекәш, анда сезнең тегермән яклары ничегрәк тора. Берочтан тарттырып та алып булмас микән ул ашлыкны?

«Бәлки, сиңа ипи итеп пешереп тә бирергә кирәктер», – дип уйлап алды Миңнулла. Ләкин Василий Ивановичның үзенә алай дип әйтергә батырчылык итмәде. Күңеленнән дошман кулына эләкми калган тегермәнле авылларны барлап чыкты. Андый авыл икәү иде. Тегермәннәре эшлиме аларның, юкмы – анысын Миңнулла белми иде. «Икесенең берсендә ничек тә эшли торгандыр әле», – дип уйлап алды да:

– Тырышып карарбыз, иптәш бригада командиры, – дип җавап бирде.

– Тырыш әле, улкаем, яме! Югыйсә эшләр кыен безнең монда...

Шул сәгатендә үк Миңнулла һәр ике авылга да тегермәннәрнең хәлен белешеп кайтырга кешеләр җибәрде.

Кичкә мәсьәлә ачыкланды. Тегермәннәрнең тик берсе генә төзек һәм аның да ташы бик акрын әйләнә булып чыкты. Берни эшләр хәл юк. Шулай булса да, Миңнулла икенче көнне иртүк шул тегермәнгә ике олау бодай җибәрде.

Ташы акрын әйләнсә дә, тегермән һаман тарта торды һәм әзер онны бригадага алып китә бардылар. Шулай да тартасы ашлык байтак, тагын өч-дүрт көнгә җитәрлек иде әле.

Ләкин аны тартып бетерә алмадылар. Беркөнне кичкырын Василий Иванович үзе Сарашка, Миңнулла янына килде:

– Давай, хәзер үк үзегезнең олауларыгызны юлга әзерли башла! Кире Карыйга кайтасыз. Ашапны аклардан чистарттык, хәзер Карый өчен сугышабыз. Сезнең олаулар кайтып җиткәндә, Карый да безнең кулда булачак! – диде ул.

Туган авылларына кайтырга чыккач, кешеләр генә түгел, хәтта атлар да аеруча бер дәрт белән ашкынып атлаганнар иде. Тик аларга Карыйга кайтып җитү насыйп булмаган икән. Василий Иванович дөрес әйткән. Ашап, чыннан да, Бирск бригадасы кулында, хәтта бригаданың штабы да шунда күчеп өлгергән. Ә Карый һаман дошман кулында иде әле. Аклар аны калдырып китәргә һич тә җыенмыйлар иде.

Хәлнең менә шушылай четерекле икәнен күреп, Миңнулла олауларны яңадан Сарашка илтеп торырга да ниятләгән иде. Әмма Василий Иванович бик ышандырырлык итеп әйтте:

– Алай мәшәкатьләнеп йөрүнең кирәге юк, Гайсин. Бүген без, һичшиксез, Карыйны алачакбыз! – диде.

**6**

«Бүген» дә үтте, аннан соң да ике көн узып китте, әмма Карый һаман дошман кулында кала бирде.

Канкойгыч авыр сугыш көн-төн дәвам итә. Бригада солдатлары утыз биш градуслы суыкта тәүлекләр буена җылы өй күрмичә, япан кырда кар өстендә ятып, әледән-әле атакага күтәрелеп, дошманга каршы батырларча сугыш алып бара. Соңгы көннәрдә коралга да кытлык әллә ни зур түгел: теләгәнчә атарлык булмаса да, патроннары, снарядлары һәм гранаталары да бар. Ләкин дошман көчле. Аның чигенергә нияте юк кына түгел, киресенчә, үзе һөҗүмгә күтәрелергә план корып ята. Сугыш барышында әсир ителеп, безнең кулга эләккән солдатлары да шул турыда әйтә, дошман ягыннан өзлексез явып торган пуля һәм снарядларның көннән-көн арта баруы да шуны күрсәтеп тора иде.

Миңнулла бик үтенеп сораса да, Василий Иванович аның отрядын сугышка кертмәде.

– Синең хәрби хезмәткә өйрәтелмәгән һәм гомумән сугышка яраксыз ул кешеләрең белән генә әллә ни зур эш майтарып булмас, Гайсин. Бригаданың үз сугышчылары да үз түгел, тик аларны туйганчы ашатырга гына кирәк. Тамаклары тук булса, берсе биш кешегә торырлык алар. Син бу як авылларда кайда нәрсә барын, кемнең кем икәнен бик яхшы беләсең. Давай, син бригаданы азык-төлек белән тәэмин итүне кайгырт! – диде.

Сүз дә юк, сугышчыларны икмәк белән тәэмин итү, әлбәттә, бик мөһим. Моны Миңнулла бик яхшы аңлый. Ләкин, шулай булса да, үзенең туган авылы өчен барган сугышта мылтык тотып катнашасы килгән иде аның. Ә авылы – Карый – әнә орынып кына тора. Иң күп куйганда да алгы сызыктан чакрым-чакрым ярым чамасында гына. Кычкырыбрак сөйләшкән чакларында, дошман солдатларының тавышларына кадәр ишетелә. Шул авылда аның әнисе белән әтисе... Шунда аның сөйгән кызы Зәйнәп... Миңнулла алар белән саубуллаша да алмыйча китеп барды бит теге чакта... Алар аны ике күзләрен дүрт итеп көтәләрдер... Улларының икесе дә Совет яклы, икесе дә коммунист, икесе дә Кызыл Армиядә икәнен белеп, аклар бик каты җәберләмәсә генә ярый инде үзләрен... Аннары килеп, абыйсы Зәйнулланың да кайда булуы һәм, гомумән, исәнме-түгелме икәнлеге билгеле түгел бит әле Миңнуллага. Ә белергә һич тә җай юк. Карыйга барып килү турында уйларга да ярамый: анда акларның бер полк һәм чехословакларның бер батальон гаскәре тора. Кешене түгел, чыпчыкны да якын җибәрмиләр. Аннары Миңнулланың алайлар итеп, үз кайгысын кайгыртып йөрергә хакы да, вакыты да юк. Чөнки ул – отряд командиры. Аның отрядына сугышчан задание – бригаданы азык-төлек белән тәэмин итү бурычы йөкләнгән.

Якын-тирәдәге авылларның барысында да диярлек бандитлар булып киткән. Ә алар аягы баскан җирдә юньле нәрсә каламыни? Халыкның чәчүлеккә дип, күз карасыдай итеп, үзләре ач булсалар да, ашамыйча саклап тоткан икмәкләрен, карап торган бердәнбер атларын, сыерларын гына түгел, хәтта соңгы кәҗәләренә тикле талап алып киткән ул кабахәтләр! Ә ир-атлары безнең Кызыл Армия сафларында булган семьяларның исә, икмәкләрен һәм малларын гына талап калмыйча, үзләрен дә атып йә асып үтереп киткәннәр. Кыскасы, гади халыктан икмәк юнәтүгә исәп тотып булмый, киресенчә, ачтан үлмәсеннәр өчен, аларның үзләренә ярдәм итәргә кирәк иде.

Ә шулай да Миңнулла отряды үзенә йөкләтелгән бурычны үтәп чыкты! Ярлы халыкның соңгы кадак ашлыгын тартып алсалар да, ак бандалар байларга кагылмаган иде. Киресенчә, Василий Иванович бригадасы кысрыклый башлагач, ашыгыч кына чигенергә мәҗбүр булып, үзләре белән алып китәргә өлгермәгән икмәкне әлеге шул байларга калдырып киткән иде алар. Ә байлар халыкның үз икмәген үзенә ун бәясенә сатып, спекуляция белән шөгыльләнеп яталар. Үз икмәкләрен исә инде күздән үк бик нык яшергәннәр: ындыр артларына, бакчаларга күмгәннәр; каралты коймаларын ике катлап, койма араларына тутырганнар; тезмәгә печән араларына тыкканнар; урман куелыкларына базлар казып, шул базларга илтеп күмгәннәр; идән асты базына тагын бер баз казып, шул базларга тутырганнар; изге урын дип тормаганнар, чиркәү һәм мәчет идән асларына яшерүгә кадәр барып җиткәннәр иде.

Барыбер барысын табып алып чыктылар. Отряд гвардиячеләре дә бик нык тырышты, әлбәттә. Ләкин, барыннан да бигрәк, бу эштә авыл халкының ярдәме зур булды. Байлардан табылган ике пот икмәкнең бер поты авыл ярлыларына бүлеп биреләчәк, дип игълан иткәч, эш аеруча җанланып китте, биш көн эчендә бригада сугышчыларын өч атна туйдырырлык икмәк җыйналды. Шул ук вакытта ачлыктан инде шешенә башлаган авыл ярлыларына да шактый зур ярдәм булды. Отряд эшен бетереп киткән чакта, ул бичаралар елый-елый рәхмәт укып калдылар.

Әмма барыннан да мөһимрәге шул: әлеге икмәк әзерләү барышында һәр авылның туксан биш процентын тәшкил иткән ярлы халыкта Кызыл Армиягә һәм совет властена карата ышаныч туды.

Колчакның солдатлары гына түгел, Колчак үзе килеп үгетли башласа да, совет властена булган иманы какшамаячак инде ул халыкның...

Анысы шулай. Ләкин Карыйдагы дошманның коралы да, сугышчылары да Бирск бригадасыныкыннан ике-өч мәртәбә артык һәм аны чигенергә мәҗбүр итү мөмкин түгеллеге көн кебек ачык иде. Башта бик оптимист булып йөрсә дә, соңыннан Василий Иванович та моның шулай икәнлегенә, ниһаять, ышанды булса кирәк. Егерме икенче февраль көнне Миңнулланы штабка чакыртып китерде дә:

– Мылтык тотып сугыша алырдай гвардиячеләреңне генә үзең белән калдыр да бүтән барлык кешеләреңне һәм обозыңны тылга озату чарасына кереш! – диде. – Бригаданың фланглары ышанычлы түгел. Ә күршеләребезнең хәле безнекеннән дә начаррак. Усыны тагын дошман басып алды. Өяз башкарма комитеты таратылган, аның урынына Икенче армиянең политбүлеге каршында өяз революция комитеты оештырылган. Бер бездә генә түгел, бөтен Көнчыгыш фронтта хәлләр кыенлашып бара. Өченче армиядә дә югалтулар бик күп. Монда, Көңгер һәм Пермь юнәлешендә, Англия, Япония, Америка капиталистлары тарафыннан һәрьяклап бик яхшы тәэмин ителгән Колчак армиясенең яңа көчләре, чехословак гаскәрләре сугышка керде. Тиздән безгә чигенергә туры киләчәк. Шуңа күрә обозыңны һәм кешеләреңне тизрәк озатып калырга кирәк.

– Кая озатырга икән соң аларны, Василий Иванович?

– Кая озатыргамы? Тукта, карап карыйк әле... – Ул, иңенә аскан кыр сумкасыннан алып, картасына текәлде. Көньяк, көнбатыш һәм көнчыгыш яклар тоташы белән дошман кулында. Тик төньякка таба гына чигенергә мөмкин иде.

– Югары Сипкә озатырга кирәк булыр. Хәзергә шуннан да ышанычлырак урын юк! – диде Василий Иванович.

**7**

Миңнулла отряды волком олауларын Югары Сипкә илтеп тәүлек ярым вакыт үткәреп кайтканда, Бирск бригадасы Ашапны калдырып, Чиркандыга чигенергә мәҗбүр булган һәм анда да көч-хәл белән генә тотынып тора иде. Василий Иванович Миңнулланы күрүгә, ни хәл барып кайттыгыз, дип сорашып та тормастан:

– Молодец, Гайсин, бик вакытлы кайтып җиттең! Гвардиячеләрең минем карамакка кала. Ә үзең хәзер үк артиллерия батареясына барып кайт әле. Ул батареяга Овчинники – Турай һәм Овчинники – Воронино юлы буйлап бәреп керергә омтылган дошман гаскәрләрен тоткарларга боерык бирелгән иде. Ләкин нигәдер юньләп атканнары ишетелми, – диде.

Миңнулла барганда, батарея командиры лаякыл исерек һәм авыл башындагы бер йортта нindидер ике хатын-кыз белән рәхәтләнеп эчеп, күңел ачып утыра иде. Аның белән сөйләшүдән мәгънә чыкмаслыгын белеп, Миңнулла батарея тупчылары янына барды.

– Нигә дошманга атмыйсыз? – диде Миңнулла, ачуланып.

– Бушка атудан ни файда? – диде берсе. – Координацияләүче юк. Шуңа дошман якынлашкач туры наводка белән генә атарга мәҗбүрбез.

Миңнулла ни эшләргә дә белмичә аптырап торган арада, атын кушаяклатып чаптырып, Василий Иванович үзе килеп җитте.

– Ни булды? Нигә атмыйсыз? – диде ул, нигәдер тупчыга түгел, Миңнуллага мөрәҗәгать итеп.

Миңнулла хәлне аңлатып бирде.

– Ах, сволочь Егоров! – диде Дедкин. – Менә эш нәрсәдә икән! – Аннары адъютанты белән ярдәмчесенә боерды: – Барыгыз, шул хәерсезнең коралын алып, үзен дә, кәнизәкләрен дә бәйләп, штабка илтегез! – Тегеләр киткәч, Миңнуллага борылды: – Йә, Гайсин, әйтеп кара әле: минем урында син булсаң, менә шушындый хәлдә ни эшләр идең?

– Командирлыктан азат итәр идем.

– Мин дә күптән шулай эшләгән булыр идем дә, ләкин батарея белән командалык итәргә бүтән кешем юк шул минем! Шуңа түзәргә туры килә. Ә ул, адәм актыгы, шуны бик яхшы белә һәм, патша армиясендәге гадәтен куып, вакыт-вакыт менә шушылай чыгырыннан чыгып китә. Эх, нишләргә соң инде, ә? Снаряд булмаса да бер хәл иде. Снарядлар җитәрлек була торып, дошманга ут яудырырга мөмкинлек юк бит!

– Рөхсәт итсәгез, батарея утын үзем координацияләп карар идем, Василий Иванович, – диде Миңнулла.

Коры теләк, яхшатлы булып күренер өчен генә әйтелгән сүз түгел иде бу. Герман сугышында Гәрәй абзыйның адъютанты булып йөргәндә, Миңнулла аннан артиллерия эшенә дә бераз өйрәнеп калган иде. Дөресрәге, син әле яшь, дөнья булгач, бәлки, кирәге чыгар, дип, Гәрәй абзый аны үзе өйрәткән иде.

– Әгәр шушы батарея белән командалык итә алсаң, ул чакта мин сине...

Василий Иванович сүзен әйтеп бетерергә өлгермичә калды, чөнки аның янына икенче батальон командирының элемтәчесе йөгереп килде дә, еларга җитешеп:

– Иптәш комбриг, аклар алгы сызыкка бөтенләй якынлашты, тиздән урап ала башлаячаклар. Комбат берәр чара күрүегезне үтенде! – диде.

– Хәзер, хәзер, – диде Василий Иванович сабыр гына итеп. – Хәзер бирербез без аларның кирәкләрен. Бар, улкаем, бар, комбатыңа шулай дип әйт. Бер адым да чикмәскә боерды Дедкин, диген! – Аннары Миңнулланың иңенә кулын куйды: – Йә, энекәш, Аллага тапшырдык. Бөтен ышаныч синдә. Ничек тә дошманны тоткарларга, ничек тә иртәнгә кадәр генә булса да түзәргә кирәк! Армия командующиеның боерыгы шундый.

Аклар, кара болыт шикелле ишелеп, һөҗүм итеп килә. Ә безнең алгы сызыктагы пехотачылар, каушап калып, тәртипсез рәвештә чигенә башлаганнар иде. Тик Миңнулла командасы буенча туплар беренче залпны биргәч һәм Василий Иванович, үзе аларның каршына чыгып: «Бер адым да чигенмәскә! Минем боерыкны тыңларга!» – дип, бик зәһәр итеп кычкыра башлагач кына тукталды алар.

Ә тупчылар тагын рәттән өч залп биреп, снарядлар дошман солдатлары арасына төшеп ярыла башлагач, аклар куркып, тукталып калды. Бу хәлиткеч момент булды. Дошманның каушап калуын күргәч, гайрәтләнеп китеп, безнең пехотачылар да чигенүдән туктап ут ачтылар. Аклар ятарга мәҗбүр булды. Алар да мылтык һәм пулеметлардан бик нык ата башлады. Күрәсең, туплары килеп җитмәгән булгандыр – туптан атмыйлар, шуңа күрә өстенлек әлегә безнең якта иде.

Шулай ике яктан да атышып, ләкин бер як та уңышка ирешә алмыйча, тәмам караңгы төшкәнче тартыштылар. Аннары атуны туктатырга боерык булды. Безнең як туктауга, шуны гына көтеп торган шикелле, аклар да тынып калды.

Сугыш тукталса да, ут позицияләреннән китмәскә дип боерган иде бригада командиры. Көндез дә җилсез һәм куе зәмһәрир суык булган иде. Ләкин сугышчылар туктаусыз хәрәкәтләнеп, нервыланып торганлыктан, ул турыда уйларга вакыт юк, шуңа әллә ни зыянлы тоелмаган иде. Ә менә атышлар тынгач һәм караңгы төшкәч исә, җилекләргә үтеп туңдыра башлады. Миңнулланың үзенә ул хәтле үк куркыныч түгел, аның аягында өйләреннән киеп чыккан, әле олтан да салынмаган яңа киез итек, башында җылы төлке бүрек. Әтисенең бүреге. Улының эвакуациягә китәргә тиешлеген белгәч, әнисе:

– Хәзер картуз киеп йөри торган чак түгел. Кыш уртасына кереп барабыз. Ки әтиеңнең шушы бүреген, кимәсәң, мәңге риза-бәхил түгел! – дип көчләп кидерде.

Рәхмәт аңа! Фуражка кигән булса, менә хәзер нишләр иде? Дөрес, күн курткасының җылысы әллә ни түгел түгелен. Ләкин аягы белән башы җылыда булгач, түзәргә була. Ә менә тупчыларның хәле яман. Күбесенең аякларында чорнау урап кына кигән ботинка. Төкерегең җиргә төшеп җитмәс борын ката торган шушы суыкта япан кырда төн кунарга тиеш алар. Инде төнге унберенче, ләкин ашарга китергән кеше юк әле. Җылы аш ашап алганда да азрак хәл булып китәр иде. Авыл да ерак түгел кана. Нибары дүрт-биш йөз метрлар чамасында гына. Ләкин анда барырга ярамый: позициядән бер адым да китәргә рөхсәт юк. Катып үлмәс өчен, солдатлар әүмәкләнешкән, биешкән, йөгерешкән булалар. Ләкин көне буе сугыш мәхшәрендә кайнаган сугышчыларның да түземе төкәнергә мөмкин ич. Әле алда ел озынлыгы төн бар лабаса! Ә Василий Ивановичтан бернинди хәбәр юк иде. «Бу тупчыларны монда тоту акыллы кеше эше түгел. Беренчедән, дошман төнлә һөҗүм итмәс. Чөнки ул узган көн дә көне буе сугышты. Аның солдатлары да тимер түгел, аларга да ял итәргә кирәк. Икенчедән, батареядан алда, ким дигәндә ярты чакрымда, бригаданың пехотачылары тора. Дошман атакага ташлана калса, аны башта шулар тоткарлаячак. Шулай булгач, тупчыларны авылга алып кайтып, җылы өйгә урнаштырудан һәм чиратлап кына булса да йоклатып алудан да хәерлесе булмас. Шушы ук кешеләрнең иртәгә тагын сугышасылары бар бит. Ял итеп алсалар, иртәгә яхшырак сугышачак алар», – дигән фикергә килде Миңнулла һәм, тәвәккәлләп, тупларны да, тупчыларны да авылга алып кайтты. Аннары шул турыда Василий Ивановичка әйтмәкче булып һәм тупчыларны ашату мәсьәләсен хәл итүне дә күздә тотып, бригада штабына барды. Миңнулла рапорт ясаганда, боерык булмыйча торып позициядән киткән өчен комбриг ачуланыр инде дип шикләнебрәк торган иде. Хәвефләнүе бушка гына булды.

– Бик дөрес эшләгәнсең! – диде комбриг, куанып. – Батареяны алып кайтып бик яхшы иткәнсең! Разведка мәгълүматларына караганда, безнең каршыдагы дошман гаскәрләренә ярдәмгә тагын акларның Ишим полкы да китерелгән. Ихтимал, алар иртән тагын һөҗүмгә күтәрелер. Ә бездә аларга каршы торырлык көч юк инде. Үткән көндә дә югалтулар бик зур булды. Хәзер барлык частьларга да, дошманга сиздермичә генә позицияләрен калдырып, чигенә башларга боерык бирәм. Шулай кирәк. Бүтәнчә мөмкин түгел. Ә син, бар, хәзер үк батареяң белән Фокага таба кузгал!

– Ә Егоров айнымадымыни соң әле?

– Ә ул хәзер мәңге айнымаячак! – диде Василий Иванович, кырт кисеп. – Аттым инде мин аны. Мин аның кыланышларына алыштырырга кеше булмаганга гына түзеп килгән идем.

– Димәк, аның үлеменә мин сәбәпче булган булып чыгам?!

– Нигә син буласың ди!
– Мин аны алыштырмаган булсам, ул бүген дә исән булыр иде бит.
– Юк, исән булмас иде. Тәмам гарык иткән иде инде ул безне. Бар, Гайсин, боерыкны үтә!
– Ә волком олаулары нишләр икән соң, Василий Иванович? Алар да минем җаваплылыкта бит!
– Алар өчен кайгырма! Урынбасарларың бар бит синең анда. Мин аларга обозларыгызны да, кешеләрегезне дә Фокага күчерергә боерык бирдем инде.

**8**

Волком олаулары Фокага барып җитә алмаган. Атлары арыганлыктан, Фокадан дүрт-биш чакрымдагы бер бәләкәй генә авылда туктап торалар иде.

Батарея сугышчылары ярдәме белән олауларны Фокага илтеп җиткергәч, өяз ревкомы да шушы волостька караган Михайловский заводында урнашканлыгы мәгълүм булды.

Фатирларга урнашып, атларын тугарырга да өлгермәделәр – Миңнулланы ревкомга чакырттылар. Ревком председателе Олег Николаевич Шапошников дәштергән иде аны. Ул Миңнулланың кайдан килүен, ни эшләп йөрүләрен сорашты да, шул сәгатендә үк бригада командиры Василий Иванович белән телефоннан сөйләшеп, аны батарея командиры вазифасын үтәүдән азат иттерде. Аннары ревкомның чираттан тыш утырышын үткәреп, шул утырыш карары нигезендә Миңнулланы Яңа Уртавыл волостена ревком председателе итеп билгеләделәр. Аның карамагында Кызыл Яр, Елпачиха һәм Сараш волостьларыннан эвакуацияләнгән һәм совет органнарында эшләү буенча аз-маз тәҗрибәләре булган иптәшләрне (алар барысы унбер кеше иде) тапшырдылар да:

– Үзегезне фронтка барабыз дип исәпләгез – Яңа Уртавыл хәзер фронт полосасында! – дип, юлга чыгарып җибәрделәр.

Озатып калганда, Шапошников, Миңнулланы читкәрәк алып китеп:

– Барып җиткәч, синең карамакка тапшырылган бу иптәшләргә, сәләтләренә карап, эшне үзең бүлеп бирерсең, яме! – диде. – Барып урнашу белән, иң элек, ревком председателе буларак, егерме сигезенче дивизия командиры Азинның үзен күреп сөйләш һәм алга таба аның күрсәтмәләре буенча эш итәргә кирәк булыр. Ул волостьта моңарчы продналог җыюга бөтенләй игътибар ителмәгән. Төп эшең итеп икмәк хәзерләүне сана! Эшләгән эшләрегез һәм ревкомдагы хәлләр турында язма рәвештә йомышчы аркылы миңа хәбәр итеп тор! Сау бул! Эшеңдә уңыш телим!

Яңа Уртавыл өяздәге иң зур волостьларның берсе булып буйга – кырык, аркавы егерме биш чакрым мәйданны биләп тора иде. Өяздә эшләгән чагында Миңнулланың бу якларда да булгалаганы бар, ә Тирән Күл, Важады һәм Сөзәк Тау авылларын аеруча яхшы белә иде ул. Тирән Күлнең ярлылар комитеты председателе Миңнуллага Яңа Уртавылга капыл гына барып кермәскә, башта отряды белән разведка ясап кайтырга киңәш итте.

– Югыйсә ул тирәдә хәлләр бик ышанычлы түгел, бәлагә таруыгыз бар, – диде ул.

Шуңа Миңнулла олауларны Тирән Күлдә калдырып, ун кешелек отряд белән Яңа Уртавылга китте. Анда хәлләр Шапошников әйткәнгә караганда да хәтәррәк булып чыкты: волком аппараты үзенең төп эшен – авылларда совет властен ныгыту һәм аңа ярдәм итү, ярлы крестьяннар мәнфәгатен кайгырту турында уйламый гына түгел, киресенчә, корткычлык белән шөгыльләнә: ярлыларны кимсетә, аларга түли алмаслык налоглар сала, ә байларны яклый, аларга һәр җәһәттән ярдәм итеп килә икән. Авылның биш-алты атаклы контры аклар ягында хезмәт итеп йөри, шул ук вакытта семьялары белән дә тыгыз элемтә тоталар, хәтта ун-унбиш көнгә бер өйләренә дә кайтып китkәлиләр икән. Кыскасы, волком составында ышанычлы, Миңнуллага ярдәм итәрдәй юньле кеше дә юк иде.

Менә шул мәсьәләне ачыклагач, ул волком члennарын җыйнады да аларга Усы ревкомының Яңа Уртавыл волкомын тарату турындагы карарын укыды.

– Без ул карарга буйсынмыйбыз! – дип, волком члennарыннан берничә кеше тавыш күтәрә башлаганнар иде дә, Миңнулла, бик коры гына итеп:

– Димәк, сез совет властена да буйсынмыйсыз? Ә андый кешеләрне кулга алырга туры киләчәк! – дигәч, авызларын йомып шыпырт кына кайтып киттеләр.

Аннары Миңнулла үзе белән килгән иптәшләрдән ревком төзеде. Ревкомда финанс, хәрби, җир, азык-төлек, тәэминат, идарә бүлекләре оештырылды, аларга бүлек мөдирләре билгеләнде. Ревком председателе булуы өстенә Миңнулла хәрби һәм идарә бүлекләре белән җитәкчелек итүне дә үз өстенә алды. Харитонов Игнатий укый-яза белүче, заманында диңгезче булып хезмәт иткән, эш рәтен белә торган тәвәккәл һәм акыллы кеше иде. Шуңа аны үзенең урынбасары итеп билгеләде. Ә Хәбибрахманов, киресенчә, йомшак характерлы, армиядә гомумән хезмәт итмәгән, тыныч шартларда гына эшләргә өйрәнгән, ләкин үз эшен һәрвакыт җиренә җиткерә торган иптәш булып чыкты. Аны Миңнулла хуҗалык һәм социаль тәэминат бүлеге мөдире итеп билгеләде.

Юлда килгәндә үк Миңнулла Уртавыл волостена керә торган авылларның ындырларында сугылмаган эскертләргә игътибар иткән иде. Яңа оешкан ревкомның беренче эше итеп ул әнә шул

мәсьәләне күтәрде. Волостьның әлегә аклар басып алмаган авылларыннан ярлылар комитеты председательләрен чакыртып китереп, аларга Кызыл Армия гаскәрләрен азык белән тәэмин итү бүгенге көннең төп бурычы икәнлеген аңлатты.

– Шушы бурычны үтәмәгән комбед председательләре хәрби приказга буйсынмаган булып саналачаклар һәм сугыш чоры законнары нигезендә кискен җавапка тартылачаклар! – диде.

Бу эш тизрәк гамәлгә ашсын өчен, шул ук җыелышта һәр авылга ике җаваплы кешене (берсе ревком вәкиле, берсе комбед председателе) билгеләделәр.

Яңа Уртавыл үзе дә ике мәхәлләле зур авыл. Ныклап торып тотынганда, аннан да байтак икмәк җыеп алырга мөмкин икәнлеген әйткәннәр иде инде Миңнуллага. Шул хакта халык белән сөйләшү өчен авылның гомуми җыелышын җыйдыртты. Волость авылларына икмәк әзерләү оештырырга барырга тиешле ревком членнарын да шул җыелышка чакырды. Докладны үзе ясады. Башта илдәге гомуми хәлләрне, Совет дәүләте алдында торган мөһим бурычларны аңлатты. Шуннан губерна, өяз хәлләренә кайтты һәм, ниһаять, үз волостьлары алдында торган конкрет бурычлар турында сөйләде. Докладны, нигездә, игътибар белән тыңладылар. Ләкин ахырдан, фикер алышулар башлангач, өстенә сары яңа кайры тун, пеләш башына кара бәрхет түбәтәй кигән бер агай торып басты да:

– Сайравын матур сайрыйсың син, җегет, – диде. – Ике сүзеңнең берендә сәвит блачы дисең, аны саклап калырга кирәк, аны саклап калыр өчен фрунттагы салдатларга икмәк кирәк, икмәк тапшырыгыз, дип давайлыйсың. Ә менә минем шуны беләсем килә: без сәвит блачына ярдәм итәбез итүен дә, әмма дә ләкин сәвит блачы үзе ник бер дә ярдәм итми икән суң без керәстиянгә? Бүтәне турында әйткән дә жук инде, хәтта чалбар тегеп кияргә манфактура да кайтармый башлады бит суңгы вахытларда! Алга таба да болай барса, шыр ялангачка калдырмас микән безне ул сәвит блачы?

«Каян китереп төрттерергә кирәген белә бу адәм!» – дип уйлап алды Миңнулла, аптырабрак калып. Аннары, шыпырт кына, үзе белән рәттән президиум өстәле янында утырган Уртавыл ярлылар комитеты председателеннән сорады:

– Нindirәк кеше бу? Продналогын түләп бетергәнме?

– Бер кадак икмәк тә биргәне юк! – диде председатель.

Миңнулланың эченә җылы кереп китте һәм ул пеләшнең үзенә сорау бирде:

– Иң элек син миңа шуны әйт әле, агай: совет властена үзеңнең күпме ярдәм иткәнең бар? Мәсәлән, конкрет алганда, быел дәүләткә күпме икмәк тапшырдың?

– Карак белән дөнья тулган хәзерге заманда, тапшырырсың сиңа! Узган атнада унҗиде пот әзерләп куйганыем, иртәгә илтеп бирәсе төнне бөртеген дә калдырмыйча урлап апчыгып киттеләр.

Теге агайның бу җавабына каршы Миңнулла ни дип әйтергә дә белмичә төртелеп торган арада, Уртавылның комбед председателе сикереп торды да:

– Урлатырга теләгән кешенекен шулай урлыйлар инде, Мәҗит абзый! – диде. – Син, караклар да фәлән-фәсмәтән дигән булып, авыл халкына яла якма, яме! Ул икмәгеңне кемнәр «урлаганын» бик яхшы беләбез без. Малаең армия хезмәтеннән качып урманда дезертирлыкта йөргәч шулай була инде ул!

– Син аның кайда йөргәнен каян беләсең? Күргәнең булды мәллә? – диде пеләш, ачуыннан чөгендер шикелле кызарып.

– Күргәнем булды шул! – диде председатель. – Синең икмәгең урланганнан ике көн элек кенә төнлә өегездән чыгып китеп барганда күрдем.

– Күргәч тоталар аны!

– Бик тотасы идем дә элэктерә алмый калдым шул – ул атлы, ә мин җәяү генә идем.

Тик шуннан ары гына пеләш телен тешләп, тынып калды. Баштарак нык кына шаулаша башлаган бүтәннәр дә койрыкларын кысарга мәҗбүр булдылар.

Җыелыш продналоглары түләнмәгән кешеләр ике-өч көн эчендә түләп бетерергә тиеш дигән карар кабул итте. Суктырылмыйча эскертләрдә яткан игеннәре җыйнаулашып сугып, ашлыгын дәүләткә тапшырырга дип яздылар.

Чиктән тыш ярлы семьяларга һәм сугыш инвалидларына комбедның ярдәм фондын булдыру мәсьәләсен шулай ук карарга кертеп, законлаштырып куйдылар.

**9**

Ә икенче көнне Миңнулла Азин дивизиясе штабына барды. Штаб Казан тимер юлындагы Куяды станциясендә урнашкан иде. Ул килгәндә, штаб начальнигы да, дивизия командиры Азин үзе дә урыннарында юк, частьларга киткәннәр иде. Аларны өч сәгатькә якын көтеп торырга туры килде. Командир белән штаб начальнигы икесе бергә кайттылар. Штаб дежуры Миңнулланың командир белән сөйләшергә теләвен әйтеп чыкканнан соң ун минут чамасы үткәч, Азин аны үзе дәшеп кертте.

– Тыңлыйм сезне, ни йомыш? – диде Азин, кырыс кына итеп.

– Мин – Яңа Уртавыл ревкомы председателе Гайсин. Усы өяз ревкомы кушуы буенча сезнең белән элемтә урнаштырырга дип килдем.

Миңнулланың «Гайсин» дигәне аңа «Азин» дигән кебегрәк ишетелде булса кирәк. Владимир Мартынович беркавым Миңнуллага текәлеп карап торды да, тагын да кырысрак итеп:

– Нинди Азин ул тагын? – диде.

– Азин түгел, Гайсин!

Шуннан соң гына Владимир Мартыновичның йөзе яктырып китте:

– Алай булса, икенче эш!

Аннары ул Миңнуллага урын тәкъдим итте. Миңнулла утыргач, аның документларын сорап алды. Аларны җентекләп тикшереп чыкты һәм, бу юлы инде шактый ягымлы итеп:

– Яхшы, – диде. – Партия членымы син, иптәш Гайсин?

– Әйе.

– Яхшы. Димәк, синең белән җитди сөйләшергә мөмкин булачак.

– Әлбәттә.

Азин Миңнулланың кайда туып үскәнен, кайларда укыганын һәм эшләгәнен, Уртавылга ничек килеп җитүләрен, килгәч ниләр эшләүләрен сораштырды. Аннары:

– Соңгы көннәрдә безнең фронт полосасында Колчак шпионнары күбәеп китте. Сезнең тирәләрдә сизелмиме андыйлар? – диде.

– Өзеп кенә әйтүе читен, – диде Миңнулла. – Бу якка килеп эшли башлавыма нибары өченче генә көн бит әле. Дезертирлыкта йөрүчеләр бар икән. Мөгаен, шуларның кайберләре аклар белән элемтә тота торгандыр.

– Обязательно ул дезертирлар кайтып йөри торган йортларны күзәтү астына ал. Кил әле бирерәк! – дип, ул Миңнулланы үз янына чакырып утыртты да Яңа Уртавыл волостеның барлык авыллары да күрсәтелгән картасын алып, аңа конкрет задание бирергә кереште. – Менә, – диде ул, Ушья-Тау авылын күрсәтеп, – сез шушы авылдан алып Яңа Уртавылга һәм Яңа Уртавылдан алып Урадыга кадәрге арада ышанычлы сак урнаштырырга тиешсез! – Аннары Азин кулындагы карандашы белән Яңаулга төртте. – Дөрес, бу авыл сезнең волостька керми. Бирск өязенә карый ул. Һәм үзе волость үзәге булып тора. Ләкин син менә шушы Яңаул станциясендә яшерен пост булдыр, һәм ул пост белән даими тыгыз элемтә тот. Ә икмәк әзерләргә керешүең бик шәп булган. Хәзер иң кирәкле нәрсә – икмәк! Азык-төлек әзерләүне алга таба да дәвам ит! Бигрәк тә байларның амбарларын кат-кат тикшерегез. Килеп, үзегездәге хәлләр белән мине таныштыруың өчен рәхмәт. Киләчәктә шулай элемтәдә тор. Уңыш телим!

Азин, эшне беткәнгә санап, капыл гына урыныннан купты һәм саубуллашу өчен кулын сузды.

Сузган кулны кире кагып булмый иде, Миңнулла да аңа кул бирде. Ләкин китәргә ашыкмады.

– Менә сез, иптәш дивизия командиры, – диде ул, – безгә Ушья-Таудан алып Урадыга кадәрге арада сак урнаштырырга боерык бирдегез. Минем белүемчә, ул ара ким дигәндә унбиш километр, ә минем отрядта нибары егерме ике генә кеше. Әле кичә генә шуларның бишесен укырга җибәрергә, унысын Кызыл Армия карамагына тапшырырга дип өяздән күрсәтмә килде. Шулай итеп, волком отрядында нибары җиде кеше кала. Алар белән ничек саклармын икән мин ул унбиш-егерме километр араны да ничек Яңаулда яшерен пост урнаштыра алырмын икән? Аннары бит безнең корал ягы да бик сыек, иптәш дивизия командиры.

– Отрядыңны зурайтырга, кимендә илле кешегә җиткерергә кирәк! – диде Азин. – Укырга китәргә тиешлеләрен тотма, җибәр. Ә Кызыл Армиягә хәзергә берсен дә озатмый тор. Мин Усының өяз ревкомы белән бу хакта үзем сөйләшермен, ул яктан тыныч бул. Шулай итеп, унҗиде кешең кала. Тагын утызны волость авылларыннан үзең җыйнарсың. Ә мин сиңа бер генә солдатымны да бирә алмыйм, Гайсин, чөнки һәр кешем санаулы, һәр кешем алтынга тиң хәзерге моментта!

– Кеше белән ярдәм итә алмасагыз, һичьюгы, бераз корал бирегез инде, иптәш Азин.

– Яз, нәрсәләр кирәк! – диде Азин, син бәйләнчектән барыбер котылып булмас дигәндәй, кырыс итеп.

Миңнулла егерме сугыш мылтыгы, йөз граната, биш ящик мылтык патроны, биш йөз наган патроны сорап гариза язды. Азин аның гаризасын укыды да, син нәрсә, корал заводы бар дип беләсеңме әллә бездә, дигән шикелле итеп, күзен тутырып беркавым карап торды. Ләкин бер сүз дә әйтмәде, Миңнулла гаризасы өстенә кыйгачлап: «Биш рус винтовкасы, ун граната, бер ящик винтовка патроны, ике йөз наган патроны биреп җибәрергә», – дип язды. Аннары Миңнуллага сузды һәм:

– Бар, складтан алырсың. Шушыннан артыгын берничек тә бирә алмыйм. Коралны үзегез табарга тырышыгыз: акгвардиячеләрне һәм шуның ише бүтән контрларны күбрәк кулга төшерегез дә коралларын үзегезгә алыгыз! – дип, ишеккә кадәр килеп, аны озатып калды.

Февраль аенда фронтта әллә ни зур үзгәрешләр булмады. Күрәсең, көннәр бик салкын торгангадыр, аклар алай зурдан кубып һөҗүм итмәде. Ләкин алар кул кушырып, тик кенә ятмый, бик тырышып сугыш эшенә өйрәнәләр. Тирә-як авыллардагы ярлы халыкның актык сарык һәм сыерларын талап суялар. Соңгы кадак оннарын тартып алып, шул оннан көмешкә куып, типтереп яталар. Шуның өстенә авыллардагы контр элементлар да ул бандалар белән тыгыз элемтә тота, аларга һәрьяклап ярдәм итеп тора иде.

Шунлыктан бу чорда ревкомның эше җиңеләймәде генә түгел, киресенчә, тагын да арта төште. Яшерен рәвештә безнең якка үтеп кергән ак бандалар һәм үзләре безнең якта булсалар да, күңелләре белән совет властеның бетүен теләп торган кулаклар тарафыннан эшләнгән корткычлыкларны тикшерү өчен волостьның берәр авылына барып кайтмый калган көне бик сирәк була Миңнулланың.

Менә бүген дә биш кешелек гвардиячеләре белән Кульга авылыннан кайтып килеше. Ярлылар комитеты утырышы барган вакытта, тәрәзәдән атып комитет председателен яралаганнар һәм шул ук төнне өен дә яндырганнар иде. Чана җигеп йөрү хәвефле булганлыктан (контрлар һөҗүм иткәндә качып котылырга алай бик уңайсыз), Миңнулла үзе дә, кызылгвардиячеләре дә җайдак иделәр. Көне алай чамасыз салкын булмаса да, бик җилле. Яхшы ук буранлап та тора. Кар кашларга, керфекләргә сылана. Юл бөтенләй диярлек кар астында калган. Әле ярый атлар акыллы: үзләре чамалап баралар. Ул бичараларга да кыен: тез тиңентен кар ерып атларга кирәк бит. Җитмәсә, җиле каршы... Атларның да керфекләре ап-ак. Кисәк-кисәк аеруча котырып куйган җил карны бөтереп аларның колак һәм борыннарына да тутырмакчы. Шуңа күрә атлар әледән-әле пошкырып, башларын чайкап барырга мәҗбүр...

Ап-ак кыр уртасына куелган кара стена булып урман күренде. «Шөкер, исән-сау гына монда да килеп җиттек, – дип уйлап алды Миңнулла. – Димәк, кайтасы юлның яртысыннан артыгын уздык дигән сүз. Ә урманда ул кадәр үк салкын булмас. Юлы да арурак булырга тиеш – өстән әллә ни күп яумый бит. Бәлки, урманны, биш-алты чакрым араны, юырттырып кына үтеп булмасмы әле...»

Урманга кереп бераз баргач, гвардиячеләр: «Бик туңдырды, азрак туктап, аякларны җылытып алыйк», – диделәр. Миңнулланың үзенең дә тешләре тешкә тими башлаган иде, рәхәтләнеп риза булды. Атларыннан төштеләр дә тизрәк җылыныр өчен бияләй атып уйнарга тотындылар. Шул уен белән мавыгып, алар урман юлыннан бик шәп артлы чанага утырып өч кеше килеп чыкканны абайламыйча калдылар.

Бу очрашу чанадагылар өчен дә көтелгән хәл түгел булса кирәк, алар да бер мәлгә каушап калды. Ләкин алар алданрак исләренә килде: атларын туктатып, берсе пулеметтан, икесе наганнан гвардиячеләргә атарга кереште. Миңнулла, мәсьәләне аңлап алып: «Агач артына посыгыз да – сугышка!» – дип команда биргән арада ике кызылгвардиячене сафтан чыгарып өлгерделәр: берсе, башына пуля тиеп, шундук үлде, икенчесенең кулы яраланган иде.

Ә бандитлар, атларын кирегә борып алып, качып китәргә маташалар иде инде.

«Тере килеш ычкындырмаска кирәк!» дигән уй йөгереп үтте Миңнулланың башыннан, һәм ул үзенең гвардиячеләренә:

– Атларына атыгыз! – дип боерды, үзе дә, тегеләрнең бер атына төзәп, рәттән ике пуля җибәрде.

Кем пулясы тигәндер, бандитларның кирегә чаба башлаган атларының берсе башта сөрлегеп китте, аннары кызганыч итеп кешнәп җибәрде дә гөрселдәп егылды. Икенчесе, мичәүдәгесе, постромкаларын өзеп, чабып китте. Чанадагыларның икесе сикереп төшеп урманга кереп качмакчы булган иде. Ләкин гвардиячеләрнең пулясы икесен дә аяктан екты. Ә өченчесе, пулемет калканы артына ышыкланып чанада яткан килеш, һаман атуын дәвам итә иде әле. «Зыян юк, – дип уйлап алды Миңнулла, – атар-атар да патроннары беткәч бер туктар. Күпме генә тыпырчынса да, хәзер барыбер безнең кулдан ычкына алмый инде ул!»

– Атуны туктатырга! – диде Миңнулла үз гвардиячеләренә, чөнки калкан артына яшеренгән кешегә тидерү мөмкинлеге бик шикле иде. Аннары шул чанадагыга кычкырды: – Әй, син дә туктат файдасызга атуыңны да яхшы чакта үзең бирел!

Чанадагы кеше атудан туктады, ләкин бирелергә исәбе юк иде.

– Биш минут вакыт бирәм уйларга! – диде аңа Миңнулла. – Әгәр шуннан соң бирелмәсәң, безгә үпкәләмә!

– Тот менә!.. – дип татарчалатып сүгенеп җавап бирде теге. Аның тавышы бик нык таныш шикелле тоелды. Ләкин кем тавышы – анысын Миңнулла һич тә хәтерли алмады.

Миңнулла биш минут көтте. Шуннан соң гвардиячеләренә урман эчләтеп шуышып барып, теге явызны урап алырга боерык бирде...

Дүрт кешегә берүзе каршы тора алмаслыгын сизенеп, теге адәм эшне зурга җибәрмәс дип уйлаган иде Миңнулла. Ләкин ул көткәнчә булмады. Тере килеш бирелмәде чанадагы. Соңгы чиккә кадәр әле пулеметтан, әле наганнан ата-ата каршылык күрсәтте дә:

– Хыялланма мине тереләй кулыңа төшерергә, кызыл этәч! – дип, соңгы патронын үз маңгаена атты.

Миңнулла ялгышмаган, чанадагы контр, чыннан да, аңа таныш булган икән. Чирканды мулласы малае Хәйретдинов Хәйрулла иде ул.

Хәйрулланың кесәләрен тентегәннәр иде, бер кесәсеннән Колчак армиясе офицеры билеты, икенчесеннән Коммунистлар партиясе билеты чыкты. Ә чана башына тагылган ике капчыкка бик күп кәгазь һәм алтын акчалар тутырылган иде.

Хәйрулланың кая һәм нинди максат белән баруы булгандыр, анысын тәгаенли алмадылар. Кызганычка каршы, аның иптәшләре шулай ук икесе дә җан тәслим кылганнар иде.

**11**

Март башында, төгәлрәк итеп әйткәндә, дүртенче числода, чит ил капиталистлары тарафыннан корал белән дә, кием-салым белән дә тулысынча тәэмин ителгән йөз утыз мең кылыч һәм штыклы Колчак гаскәрләре бөтен Көнчыгыш фронт буйлап һөҗүмгә күчте. Колчакның планы – Уралдан көнбатышка таба барып Иделгә бәреп чыгу һәм, шунда акгвардиячеләрнең һәм интервентларның бүтән группалары белән кушылып, Мәскәүгә юл тоту иде.

Әйтергә кирәк, ул көннәрдә колчакчыларның һөҗүме шактый уңышлы барды. Алар унынчы мартта Бирскины, унөченче мартта Уфаны, унсигезенче мартта Минзәләне һәм Минзәлә өязенә караган Актаныш, Байсар, Пучы авылларын басып алдылар.

Уртавыл волостена аклар әлегә тоташ һөҗүм итеп килеп җитмәсәләр дә, аерым группалары белән халыкны талауларын көннән-көн ешайта баралар иде. Ревком карамагындагы илле-илле биш кешелек, аның да яртысы җәяүлеләрдән торган отряд белән генә егерме чакрым сузылган фронтта ышанычлы сак куеп, дошманга каршы уңышлы көрәш алып бару, әлбәттә, мөмкин түгел иде. Миңнулла өяз ревкомына да, егерме сигезенче дивизия командиры Азин исеменә дә шул хакта рапорт язып, һичьюгында, тагын бер илле кешелек отряд һәм корал җибәрүне сорап караса да, файдасы булмады. Ревкомнан, мөмкинлегебез юк, дип җавап бирделәр. Ә Азин: «Кешеләр белән дә, корал белән дә ярдәм итә алмыйм, иптәш Гайсин. Монда, фронтның алгы сызыгында, безнең эшләр сезнекеннән дә читенрәк. Отрядыңны җирле кешеләр хисабына тулыландыр. Коралны аклардан яулап алыгыз. Чигенергә аерым приказ булганга кадәр ничек тә түзеп тору кирәк! Әзерләгән икмәкнең һәр потын дивизиянең азык-төлек бүлегенә тапшыра бар!» – дип язып җибәргән иде.

Шулай да егерме сигезенче мартта өяз ревкомы боерыгы буенча волость ревкомы карамагына унике кешелек атлы отряд килеп төште. Һәм бик вакытлы килеп төште. Чөнки егерме тугызынчы мартта акларның бер ротасы Уртавылга һөҗүмгә ташланды. Менә шул чакта әлеге атлы отряд бик ярап куйды. Теге көнне Хәйрулладан калган пулеметны алып кайтып, аңа шактый гына патроннар да юнәткәннәр иде. Шулай итеп, волком отрядындагы җитмешләп кораллы кеше һәм бер пулемет белән аклар ротасына каршы күтәрелделәр һәм тегеләрне чигенергә мәҗбүр иттеләр.

Ләкин акгвардиячеләрнең моның белән генә тукталып калмаячагы, монысы аның капшап, разведка ясап караулары гына икәнлеге ачык иде. Разведка мәгълүматларына караганда, Уртавылга тегеләрнең ике полкы һөҗүмгә әзерләнә, һәм ул һөҗүм иртәгә иртән башланырга тиеш иде. Шуңа күрә Миңнулла утызына каршы төндә Карый волкомы һәм Уртавыл ревкомы кешеләрен һәм әйберләрен Уртавылдан утыз чакрымдагы Чыгакул авылына озатты.

Разведка мәгълүматы дөрес булып чыкты: аклар утызы көнне иртүк ике полк белән Уртавылга һөҗүм башлап, аны урап алырга керештеләр. Мондый чакта барлы-юклы корал белән шултикле зур көчкә каршы торудан мәгънә юк иде. Миңнулла отряды Важадыга чигенергә мәҗбүр булды.

Йә Уртавылны сугышсыз-нисез кулга төшерү куанычыннан бәйрәм ясарга булганнардырмы, яки авылны талау белән шөгыльләнгәннәрдерме – утыз берендә аклар күренмәде.

Утызында аклар Яңаулны да басып алганнар иде. Ә утыз берендә Миңнулла егерме сигезенче дивизия штабы белән телефон аша бәйләнешкә кереп, Азинның бронепоезд белән Балыкчы станциясеннән Яңаулга, аны аклардан азат итәргә дип киткәнлеген белде. Һәм ул Уртавылны калдырырга туры килгәнлеген әйтеп, алга таба ни эшләргә, кая барырга икәнлеге хакында киңәшеп кайту нияте белән Азинны эзләп үзе Яңаулга китте.

Яңаулны алгач, аклар станциядән бер-ике чакрым җирдә тимер юл рельсларын һәм шпалларын сүтеп куйганнар икән. Азин бронепоезды шул төшкә җиткәч туктап калырга мәҗбүр булган. Шуны гына көтеп торган аклар, авыр тупларыннан атып, бронепоездны сафтан чыгарганнар. Дөрес, ахыр чиктә азинчылар Яңаулны аклардан кире кайтарган иде кайтаруын. Әмма «каты яраланган» бронепоездны «һушына китерә» алмаганнар иде әле. Миңнулла Азинны әнә шул бронепоездны төзәттерергә тырышып йөргән чагында туры китерде.

Азинның бик ашыкканлыгы, кәефе шәптән булмавы кыяфәтенә үк чыккан иде. «Болай да кырыс кеше, мондый чакта хәлне аңлатканны юньләп тыңлап торса ярый инде» дип, Миңнулла аның янына шикләнебрәк кенә барган иде. Ләкин Азин аны куанып каршы алды:

– О-о-о! Иптәш Гайсин! – диде ул, аны шундук танып алып. – Бик шәп булды бит әле синең монда килеп чыгуың! Нихәл соң? – дип кул биреп күреште һәм мәш килеп шул тирәдә кайнашкан тимерьюлчылар яныннан читкәрәк алып китте дә: – Ну, давай, сөйлә, сезнең эшләр ничек анда? Уртавылны кулыгызда тотасызмы әле? Икмәк әзерлисезме? – дип сораштырырга тотынды.

Миңнулла Уртавылны калдырып китәргә мәҗбүр булуларын әйткәч, Азин:

– Шәп түгел анысы! Мин килеп җиткәнче ничек тә түзеп торырга иде, – диде.

Миңнулла акларның Уртавылга ике полк белән һөҗүм иткәнлекләрен, шунлыктан аларга каршы торуның барыбер нәтиҗәсе булмаслыгын әйткәч кенә:

– Алайса, чигенеп дөрес иткәнсең! – дип, Миңнулла карары белән килешергә мәҗбүр булды. Аннары күңелсез генә дәвам итте: – Әйе, бу араларда бер сездә генә түгел, дивизиядә дә, бөтен фронтта да хәлләр кыенлашып китте шул. Вакытлыча чигенергә туры килә. Әле менә сиңа да, әгәр үзең килмәгән булсаң, ревкомны һәм большевиклар семьяларын Михайловский заводына эвакуацияләргә кушып хәбәр иттермәкче идем. Бар, хәзер үк кайт та шул боерыкны үтәргә кереш!

– Мин ревком кешеләрен һәм олауларын Чыгакулга озаткан идем инде, иптәш дивизия командиры!

Азин, башта ризасызлык белдереп, Миңнуллага күзенең агы белән карап алды. Аннары, «а ну-ка, ну-ка, ну-ка» дип, кыр сумкасыннан картасын алып Чыгакулны эзләп тапты.

Чыгакул фронт сызыгыннан Михайловскийга караганда эчкәрерәк, тынычрак урында иде. Моның шулай икәнлеген Азин да төшенеп алды бугай, бу юлы инде Миңнуллага баягыча өтеп ала торган итеп түгел, җылы итеп карап:

– Әйе, обозларыңны Чыгакулга эвакуацияләп, ихтимал, син дөрес иткәнсең, Гайсин! – диде. – Ә отрядың кайда хәзер?

– Ваҗадыда.

– Ул тирәдә хәлләр ничек?

– Анда да озак түзеп булмас, иртәгәләрдән дә соңга калмыйча дошман тагын һөҗүмгә күчәргә тиеш.

– Ә син ни эшләргә, акларны тоткарлау өчен нинди чара күрергә уйлыйсың?

– Менә шул хакта сездән киңәш һәм ярдәм сорарга дип килдем дә инде мин! Үз көчебез белән генә тоткарлый алмаячакбыз ул акларны. Уртавылга ике полк белән һөҗүм итте алар. Разведка мәгълүматларына караганда, аларга өстәмә көчләр килүе һаман дәвам итә. Әгәр аларны Ваҗадыга кертмичә торыйк дип саныйсыз икән, минем отрядка ярдәмгә кимендә бер полк җибәрүегезне үтенәм, иптәш дивизия командиры.

– Менә нәрсә, – диде Азин, гадәтенчә кискен тонга күчеп, – син, давай, булмастай нәрсәләрне сорап баш катырма, яме! Сиңа полк түгел, бер солдат та бирә алмыйм. Минем дивизиянең фронты йөзләрчә километрга сузылган хәзер. Ваҗадыны дошман кулына бирмичә тору өчен мөмкин булганның бөтенесен эшлә. Дошманны бер сәгать тоткарлап торуның да әһәмияте зур хәзерге моментта!

«Дивизия тикле дивизия командиры, ә үзе берни белән дә ярдәм итә алмый», – дип күңеле төшеп, Миңнулла китәргә дип атына атлангач, Азин аның янына килде дә:

– Син миңа үпкәләмә, Гайсин, – диде. – Мөмкинлегем юк бит. Алга таба барлык мәсьәләләр буенча да өяз ревкомы күрсәтмәсе нигезендә эш итәрсең. Әгәр аклар бик нык кысрыклый башлап, чигенергә туры килсә, Михайловский заводына чиген. Сау бул! Колчак бандаларын туздырып ташлагач күрешербез дип уйлыйм.

– Ә сез нигә мине отрядым белән үз дивизиягез составына алмыйсыз соң, иптәш Азин?

– Бик алган булыр идем дә, өяз ревкомы рөхсәт итми шул. Мин хәтта синең үзеңне генә алырга да сорап караган идем, шуңа да риза булмадылар! Ярый, хуш хәзергә! Уңыш телим!

– Сезгә дә шулай ук, Владимир Мартынович!

Беренче апрельдә колчакчылар күпсанлы гаскәр белән Ваҗадыга һөҗүм итте. Миңнулла отряды, Азин боерыгын үтәп, аларга каршы батырларча сугышты. Сан ягыннан аз булса да, отрядның позициясе уңайрак (отряд тау өстендә, ә аклар астан, болынлыктан һөҗүм итә) иде. Дошман никадәр генә ярсып килсә дә, аның өч атакасын отряд кире какты. Ләкин колчакчылар дүртенче тапкыр, бу юлы инде тагын да зуррак көч белән ябырылгач һәм отряд гвардиячеләренең патроннары беткәч, Миңнулла Ваҗадыны калдырырга боерык бирергә мәҗбүр булды. Авылның икенче башында инде иярләп куелган атларына атландылар да Чыгакул ягына юл тоттылар. Аннан Михайловский заводына китмәкчеләр иде. Ләкин Чыгакулда тукталып, кунып китәргә туры килде. Чөнки ревком олауларына Чыгакулга җитәр алдыннан ак бандалар һөҗүм итеп, ике кешене үтергәннәр, өчесен яралаганнар икән. Олаучылар тагын һөҗүм булудан куркып, ары китәргә батырчылык итмичә, Чыгакулда торалар иде. Шуңа күрә Михайловский заводына икенче апрель көнне кич кенә барып керделәр.

Олауларын һәм отрядын фатирларга урнаштыру өчен ярдәм сорарга һәм ары таба ни эшләргә, кая барырга икәнен ачыкларга дип, Миңнулла өяз ревкомына килде.

Өяз ревкомы председателе урынында Шапошников түгел, бәлки Миңнуллага бөтенләй таныш булмаган бер кеше утыра иде.

– Соколов, – диде ул, Миңнулла кереп исәнләшкәч, – Сергей Владимирович.

Миңнулла үзләренең хәлен сөйли башлаган иде, ләкин Соколов, аны тыңлап та бетермичә:

– Нигә, кем рөхсәте белән чигендең? Яңа Уртавылда акларның исе дә юк бит әле! Син – хыянәтче! Мин сине хәрби кыр судына озатам, коралыңны хәзер үк өстәлгә куй! – дип җикеренергә тотынды һәм, шундук телефонга ябышып, милиция чакыртты.

Миңнулла, бил каешына тагылган наганын алып, тегенең өстәленә куйды. Эчке кесәсендә бер ак офицердан алган браунингы да бар иде. Аны бирмәде. Ә Соколов тентеп тормады. Гомумән, бүтән сөйләшеп торуны кирәк тапмады Соколов. Аның чакыруы буенча кергән милиционерга:

– Мин бу кешене кулга алдым. Алып китегез дә утыртыгыз. Ә иртәгә Сарапулга хәрби кыр судына озату турында приказ бирермен! – диде дә шуның белән эшен бетерде.

– Әле мин отряд һәм ревком кешеләрен фатирларга да урнаштырмаган бит. Йөзгә якын кеше урамда көтеп тора мине! Бәлки, шуларны урнаштырырга гына рөхсәт бирерсез, Сергей Владимирович?

– Алар өчен кайгыртуны мин үз өстемә алам, – диде теге. – Телеңә салынып торма, бар, атла!

– Нигә болай кулга алды ул сезне, иптәш Гайсин? – диде милиционер, урамга чыккач.

– Ә сез мине каян беләсез?

– Кече Ашаптан мин. Сез укомда эшләгәндә безнең авылга да килгәнегез булды бит.

– Әйе шул. Сезнең исем-фамилиягез ничек, иптәш?

– Иван Тимофеевич Поздяев.

– Бик әйбәт. Мине нигә кулга алдылар дисез инде сез, ә, Иван Тимофеевич. Алла белсен ни өчен икәнен! Ә ул Соколов нинди адәм соң? Кайчан куйдылар аны ревком председателе итеп?

– Бер атна чамасы гына әле безгә килеп эшли башлаганына. Кайдан килгәндер, нинди адәмдер – анысын әйтә алмыйм.

– Минемчә, ышанычлы кеше түгел ул!

– Ышанычлы булмаса, андый җаваплы эшне тапшырмаслар иде, иптәш Гайсин.

– Анысы шулаен шулай. Ләкин нәрсәседер, кай җиредер ошамады аның миңа.

Шулчак Миңнулланың күңеленә «Әгәр бу милиционердан партиянең өяз комитетына алып кереп чыгуын үтенеп карасам, риза булмас микән?» дигән уй килде һәм ул шул фикерен Поздяевка әйтте.

– Рәхим итегез, – диде Поздяев, берсүзсез риза булып.

Партиянең өяз комитеты председателе Кибардин әле кайтып китмәгән, комитет секретаре Ясыйров белән нәрсә турындадыр сөйләшеп утыра иде. Миңнулла мәсьәләне аңлатып бирде дә:

– Сезнең бу Соколов дигән кешегез фронт хәлләре белән йә бөтенләй таныш түгел, яки ул сатлыкҗан! – диде. – Уртавылда акларның исе дә юк әле, сез аны үзегез алдан ук дошманга ташлап качкансыз, ди. Ә мин аннан отрядны соңгы чиктә, дошманга каршылык күрсәтер чама калмагач кына алып киттем. Мин өченчекөн генә егерме сигезенче дивизия командиры Азин белән сөйләшеп, аңа да хәлне аңлаттым. Миңа гына ышанмасагыз, ул тирәләрдәге хәлләрне Азинга шалтыратып белешә аласыз.

Кибардин белән Ясыйров Миңнулланы зур игътибар белән тыңладылар. Ләкин сак астыннан азат итмәделәр.

– Без сиңа ышанабыз. Әмма мәсьәләне ачыклаганга кадәр Соколов боерыгын үтәргә туры килә, – дип, Миңнулланы өяз милициясе бүлегенә җибәрделәр.

Милициядә аны бер буш бүлмәгә яптылар. Бераздан Поздяев аңа ипи белән сөт кертте. Тамак ялгап алгач бераз хәл булып китсә дә, Миңнулланы йокы алмады. Дошман кулына эләккән булса бер хәл: анда инде берни дә эшли алмыйсың, ул кадәр үк ачуың да килмәс иде. Ләкин менә җаның-тәнең белән хаклык өчен, совет властен саклап калу өчен көрәшеп йөргәндә сине хыянәт итүдә, ил сатуда гаепләсеннәр әле. Йокы качу гына түгел, акылдан язарсың бу хурлыкка!

Ә бит Миңнулла ревкомга килгәндә үзен шушылай ябып куярлар дип түгел, рәхмәт ишетермен дип көткән иде. Чыннан да, рәхмәт ишетерлек кенә эш башкармадымы әллә ул Уртавыл ревкомында?.. Михайловскийга килгәндә Миңнулла, өяз ревкомыннан сорап, Карый якларына кайтып килергә дә (яшерен генә, авыл крестьянынча киенеп кенә, әлбәттә) ниятләп тора иде. Әти-әнисенең, абыйсының һәм бик авыр хәлдә калган Зәйнәпнең язмышлары һаман билгеле түгел, шуңа бик борчыла иде ул. Менә хәзер ул үзе тоткында, сак астында ятарга мәҗбүр... Ә бит Соколов аны аттырып үтерергә дә мөмкин. Хыянәтче дип, дошман күренмәс борын ук постын ташлап качып киткән, дип язып җибәрсә – хәрби кыр суды өчен шул бик җиткән! Кибардин тикшербез дип калды калуын да, ләкин Пермьнән яисә армия штабыннан нindiдер бик ашыгыч, бик мөһим күрсәтмә килеп төшеп, Миңнуллаларны онытып җибәрүе дә ихтимал лабаса аның!..

Ябылуда ятуына тәүлек тулып килгәндә, сакчы ишектән башын тыкты да:

– Әйдә, Гайсин, сине Соколов чакыра! – дип, үзе белән ияртеп алып китте.

«Ни эшләтмәк була икән ул мине? – дип уйлады Миңнулла юлда барганда. – Азат итәрме, әллә чыннан да кыр судына озатырга ниятләде микән? Әгәр шулай итәргә маташа башласа, билләһи, кесәмдәге браунинг белән башта аның башына җитәм, аннары үземә атам!..»

Кабинетында Соколов ялгызы гына иде. Йөзе чытык, нидәндер канәгать түгеллеге әллә кайдан сизелеп тора. Ул башта: «Бар, хезмәтеңне дәвам ит!» – дип, сакчыны чыгарып җибәрде. Аннары өстәл тартмасыннан кичә Миңнулладан алып калган наганны алып бирде дә:

– Мин сине кызгандым, иреккә чыгарырга булдым, Гайсин, – диде. Ашыкмыйча гына папирос кабызды, тирән итеп ике-өч тапкыр суырды. – Ләкин син революция алдындагы, совет власте алдындагы җинаятеңне йолу өчен Яңа Уртавылга, волостьны эвакуацияләргә бүген үк кире китәргә тиешсең.

– Сезгә ничә тапкыр әйтергә кирәк инде Уртавыл аклар кулында дип! Анда барудан хәзер ни мәгънә? – диде Миңнулла, җен ачулары чыгып.

– Ансат эшне аны ахмак та эшли. Ә син менә кыен шартларда эшләүнең җаен тап! – диде Соколов, һаман үз кирелеген өстәп.

– Ярый алайса, болай итәбез: Уртавылга, әйдә, сезнең белән бергәләп киттек, яме!

– Юк, мин үзем бара алмыйм! Минем урында булсаң, син үзең дә китә алмас идең. Мондый җаваплы моментта мин ревкомда булырга тиеш. Әгәр алай бик таләп итәсең икән, синең белән бергә аппараттан берәр иптәшне җибәрергә мөмкин булыр.

– Мөмкин генә түгел, кирәк! – диде Миңнулла. – Югыйсә сез миңа тагын ышанмаячаксыз бит.

Соколов стена шакып күрше бүлмәдән бер юан гына, бәләкәй генә һәм бик куркак кыяфәтле кешене чакырып кертте дә аны Миңнуллага тәкъдим итте:

– Таныш булыгыз: ревкомның финанс бүлеге мөдире Култышев Иван Митрофанович.

Миңнулла да үз исем-фамилиясен әйтте. Соколов, Миңнулла белән кая барырга, ни эшләргә туры киләчәген аңлаткач:

– Юлга хәзер үк кузгалырга кирәк, иптәшләр, – диде. – Башта Уртавылны, аннары волостька караган авыллардагы икмәкне эвакуацияләрсез. Ләкин барыннан да элек йөз илле-ике йөз баш җигүле ат җыйнап монда минем карамакка озатырга кирәк булыр. Моны сугышчан бурыч итеп санагыз! Бу эшкә җаваплы итеп сине билгелим, иптәш Гайсин. Ә син, иптәш Култышев, иптәш Гайсинга ярдәмче булырсың. Менә сиңа, иптәш Гайсин, шул хакта мандат! – дип, бер кәгазь сузды. Анда болай дип язылган иде:

РСФСР
Усы өяз ревкомы
3 апрель, 1919 ел
№ 1319
Михайловский заводы

**Мандат**

*Моны күрсәтүче Гайсин Миңнулла Хәлиулла улы Усы ревкомы тарафыннан Яңа Уртавыл волостена эвакуация үткәрү өчен җибәрелә.*

*Волостьтагы авыл ярлылар комитетлары үзләренең эшләрен ип. Гайсин күрсәтмәләре нигезендә алып барырга тиеш.*

Ревком председателе – *С.Соколов*
Секретаре – *А.Катряев.*

– Синең бу мандатыңа исе китәр инде колчакчыларның! – диде Миңнулла, басыла башлаган ачуы яңадан кабарып.

– Әгәр ревком боерыгын үтәргә теләмисең икән, мин сине тагын кулга алырга мәҗбүр булачакмын, Гайсин! – дип, янә милиция чакырмакчы булып, Соколов телефон трубкасына тотынды.

«Юк инде, бүген алай ансат кына кулга ала алмассың син мине!» дигән уй йөгереп үтте Миңнулла башыннан һәм ул наганын тартып чыгарды да теш арасыннан гына:

– Куй трубканы урынына, Соколов, югыйсә атам! – диде.

Соколов секунд эчендә агарып чыкты, өтәләнеп трубканы кире куйды. Сизелер-сизелмәс кенә аның кулы да калтырый башлады. Кыскасы, аның аптырап-каушап калганлыгы әллә кайдан күренеп тора иде. Миңнулла күңеленә кичә үк килгән провокатор түгел микән бу адәм дигән шик тагын да арта төште һәм ул:

– Әйдә, киен, Соколов, партия өяз комитетына, Кибардин янына барабыз! – диде.

– Миңа боерык бирергә хакың юк икәнен беләсеңме, Гайсин? – дип, Соколов башта карышырга маташа башлаган иде, ләкин Миңнулла, совет властена каршы эш итә торган кешеләрне минем хәтта атарга да хакым бар, дип, бик каты тотынгач, буйсынырга мәҗбүр булды.

Миңнулла үзенең болай итәргә хакы булмавын да, моның өчен үзен утыртып куярга мөмкин икәнлекләрен дә бик яхшы белә иде. Ләкин шул ук вакытта, әлегә ачык дәлиле булмаса да, Соколовның Совет яклы кеше булмавына да бөтен күңеле белән инанган иде. «Провокатор булмаган кеше мин әйткәнгә ышанып, йөзгә якын кешене эвакуация ясарга дигән сылтау белән инде күптән дошман кул астында калган Уртавылга җибәрергә боерык бирмәс иде!» – дип фикер йөртте ул. Шуңа тегене җилтерәтеп партиянең өяз комитетына алып барган иде. Кызганычка каршы, уком председателе Кибардин урынында юк, каядыр киткән булып чыкты. Ә уком секретаре Ясыйров, Миңнулланы тыңлап та бетермәстән:

– Син үзеңне генә коммунист дип, тик мин генә совет власте өчен янып йөрим дип уйлама, Гайсин. Без барыбыз да коммунистлар һәм барыбыз да, нәкъ синең шикелле үк, Совет иленең дошманнарына каршы көрәшәбез. Һәркайсыбыз үзенә тапшырылган эшне башкара һәм шуның өчен үзе җавап бирә! Минемчә, синең иптәш Соколовка бәйләнергә бернинди нигезең дә, хакың да юк. Әгәр соңыннан кыен хәлдә калуыңны теләмисең икән, бар, хәзер үк аның боерыгын үтәргә кереш! – дип кырт кисте.

Моннан ары да карышып торуның мәгънәсе булмаячагы көн кебек ачык иде.

– Ярый, – диде Миңнулла, ниһаять, сыкранып кына ризалашырга мәҗбүр булып, – ярый, мин сезнең боерыкка буйсынам. Ләкин, карагыз аны, бу эшнең ахыры өчен җаваплылыкны мин үз өстемә алмыйм.

– Син боерыкны үтә! – диде Соколов, Ясыйров та аның яклы булганга аеруча кодрәеп.

– Ә безнең волком кешеләре һәм олаулар кайда соң хәзер? Аларны ни эшләтергә боерасыз?

– Алар өчен хәсрәтләнмә, – диде Соколов, – мин аларны юллап озаттым инде!

– Ничек озаттың? Кая озаттың син аларны? – дип, Миңнулла тегенең өстенә килә башлаган иде, араларына Ясыйров килеп кереп, якалашырга ирек бирмәде.

– Хафаланма инде юкка! – диде Соколов, бик нык каушаган булса да, сиздермәскә тырышып. – Әллә кая түгел, Уртавыл волостена бара торырга куштым мин аларга!

– Кайчан җибәрдең аларны?

– Бүген иртән.

– Ә отряд кайда минем? Аны да берәр җиргә озатмагансыңдыр ич?

– Тугыз кешең калды, утыз сигезен фронтка озатырга туры килде.

– Әһә, син мине шул кабахәтлекләрне тынычлап эшләр өчен ябып тоттыңмыни әле, әшәке җан! – дип, Миңнулла наганын алды да Соколовка төбәп атып та җибәрде.

Ул аның маңгаена тидермәкче иде. Ләкин нәкъ курокка баскан чагында гына әлеге шул Ясыйров аның кулын аска басты һәм пуля Соколовның сул ботына эләкте. Ләкин Соколов аягында торып калды һәм, Миңнулла өстенә ыргылып, аның кулындагы наганын сугып төшерде. Култышев, коты алынып, чыгып йөгерде. Соколов Миңнулланы тибеп екты һәм кобурасыннан наганын алды. Ул, ихтимал, Миңнулланы шунда атып та үтерер иде, тик бу юлы да араларына Ясыйров кереп, коткарып калды. Кыска һәм юантык гәүдәле, карап торырга үшән генә булса да, ул агай гаҗәп җитез һәм көчле кеше булып чыкты: Соколов наганын Миңнуллага төзи башлауга, яшен ташыдай атылып, тегенең наганын каерып алды. Шуннан соң гына, ниһаять, тынып калды алар. Аннары, ике милиционер ияртеп, Култышев та әйләнеп керде.

Милиционерлар кергәч, бу кабахәт җан Соколов мине тагын яптырып куя инде, болай булгач, дип уйлаган иде Миңнулла. Шул хакта тегенең әмер бирүен көткән иде. Соколов, чыннан да, әмер бирде. Ләкин аның әмере Миңнулла уйлаганча түгел иде:

– Нигә авызыгызны ачып калдыгыз? – диде ул милиционерларга. – Әйдәгез, яраны бәйләргә ярдәм итегез!

Өстәл тартмасында мамыгы да, бинты да, йоды да бар икән. Соколов чалбарын төшереп, күрсәтмәләр биреп торды, тегеләр булдыра алганча тырышып, аның ярасын бәйләделәр. Ярасы алай зыянлы түгел, пуля Соколовның сум итен тишеп кенә үткән иде.

– Икенең берсен сайла, Гайсин, – диде Соколов, тыныч кына итеп, – йә хәзер үк минем боерыкны үтәргә чыгып китәсең, яки мин сине тагын кулга алырга мәҗбүр булачакмын.

Тоткында ятуга караганда иректә булу хәерлерәк иде Миңнуллага. Аннары аны олаулар белән киткән кешеләр язмышы да бик нык борчый иде. Шуңа ул, аягы һич кенә тартмаса да, Култышевны һәм отрядыннан калган тугыз кызылгвардиячесен ияртеп, Михайловскийдан чыгып китте.

Дүртенче апрель киче иде бу. Көндез җепшетеп, кояш ашап иләкләткән юл кары туңып, пыялага әверелгән. Ул пыяла ат тояклары астында чылтырап ватылып бара иде. «Их, акгвардиячеләрне дә менә шушы пыяла карны ваткан шикелле ансат кына сытып барасы иде», – дип уйлап куйды Миңнулла.

Урман эчләреннән үткән чакта инде уяна башлаган бөре, ылыс һәм нарат сагызы исләре аңкый. Ул исләр борынны рәхәт кытыклап кына калмыйча, эчкә, тәннең бөтен күзәнәкләренә үтеп кереп, күңелләрне җилкендерә. Инде туйдырып бетергән иярдән төшеп, җәяүләп, шушы хуш исләр белән тулы һаваны сулап, урман моңын, урман тавышын тыңлап, таңга кадәр Зәйнәп белән серләшеп йөрисе килә Миңнулланың...

Ләкин бу мөмкин түгел. Аңа хәзер ашыгырга, мөмкин кадәр олауларны куып җитәргә тырышырга кирәк. Югыйсә аларның дошман кулына барып кабуы бик мөмкин.

Әмма аның бу теләге тормышка ашарга язмаган икән шул. Степановка авылына килеп җитәргә ярты чакрым чамасы калганда, аларны бер төркем хәрбиләр туктатты. Степановкага Икенче армиянең бер часте килеп урнашкан, теге солдатлар шул частьның сакчылары икән. Сакчылар Миңнулланы часть командиры янына алып бардылар. Кичә бу частька армия штабыннан вәкил килгән булган. Ул да часть командиры янында иде. Алар белән сөйләшкәч, Миңнуллага менә нәрсә мәгълүм булды: әлеге часть Степановкага килеп кергәндә, Соколов озатып җибәргән Усы һәм Уртавыл волкомнары олаулары да шунда барып җитеп, ялга туктаган булганнар. Ләкин армия штабыннан килгән вәкил – интеллигент кыяфәтле һәм ут борчасыдай җитез хәрәкәтле, үзе татар булса да, русчаны су урынына эчә торган бер агай иде ул – аларга озаклап ял итеп торырга ирек бирмәгән. Кая баруларын, ни эшләп йөрүләрен сорашып белгән дә:

– Уртавыл күптән колчакчылар кулында, ул якка барырга һич тә ярамый безгә! – дип, хәрби олауларга ияртеп, волком олауларын Сарапул – Әгерҗе – Вятские Поляны маршруты белән тылга озаткан иде.

Алайса, без дә кузгалыйк тизрәк, югыйсә куып җитүе тагын да кыенлашыр дип, Миңнулла да үзенең кечкенә отряды белән олаулары артыннан китмәкче булган иде, әмма армия штабы вәкиле:

– Алай итүнең хаҗәте юк. Алар үзләре дә әйбәт кенә барып урнашыр. Ә сез, иптәш Гайсин, хәзер ятып ял итеп алыгыз да иртәгә кире Михайловскийга кайтып, өяз ревкомы карамагында эш итә башларсыз! – диде.

– Менә бу иптәш ревком вәкиле, – диде Миңнулла, Култышевка ымлап. – Ул ни әйтер икән соң?

– Минемчә дә, Михайловскийга кайтырга кирәк. Никадәр тизрәк кайтсак, шулкадәр яхшырак булачак! – диде Иван Митрофанович.

Кайтуын кайтасы да, ләкин Соколов аларга ике йөзләп җигүле ат алып кайтырга кушкан иде бит әле.

Менә шуңа күрә, һичьюгында, ун-унбиш баш җигүле ат алып кайтып булса да ярар дип, Миңнулла Шумково авылына кагыла кайтырга уйлады.

Шумковода аларның эшләре әйбәт кенә булды. Кичтән акларның ун кешелек отряды килеп, Шумково авылына утыз биш җигүле ат әзерләп, йорт башына берәр мич ипи пешереп һәм йөз капчык он хәстәрләп куярга әмер биреп киткән булганнар икән.

Колчакчыларны сөенешеп көтеп алган контр элементлар, куштанланып, унөч җигүле ат, утыз дүрт капчык он әзерләп куйган һәм авыл халкына үзләренең оннарын биреп, кырык бер мич икмәк салдырганнар. Ул икмәкне җыйнап алып, инде олауларга да төяп куйган булганнар. Тик аклар аларны алып китәргә генә өлгермәгән. Бандитлар кулына калганчы, үзебезнең халыкка эләксен, ичмаса, дип, Миңнулла икмәкне дә, олауларны да үзләре белән Михайловскийга алып кайтырга карар кылды.

**15**

Алар кайтып кергәндә, Михайловскийда Усы ревкомы урнашкан бина урынында кара күмер генә өелеп калган иде. Ни булганын сорашырга дип, Миңнулла партиянең өяз комитетына барды. Ләкин анда да берәү дә юк, бөтен бүлмәләр буп-буш иде.

Инде ни кылырга, кая барырга белмичә торганда, Миңнулла янына бер рус карчыгы килде дә:

– Син Гайсин түгелме, улкаем? – дип сорады.

– Әйе, мин Гайсин булам, әбекәй.

– Алайса, мә, Петр Иванович моны сиңа тапшырырга кушып калдырган иде, – дип, карчык Миңнуллага конверт бирде.

– Сез Петр Ивановичның кеме буласыз? – диде Миңнулла, конвертны ачып, эчендәге хатын алган арада.

– Беркеме дә түгел. Мин укомның җыештыручысы идем.

Миңнулла хатны укырга тотынды: *«Иптәш Гайсин!* – диелгән иде анда. – *Югарыдан килгән күрсәтмә нигезендә, уком Михайловскийдан эвакуациягә китәргә тиеш булды. Казан губернасының*

*Арча өязенә барачакбыз. Шушы язуны алу белән, син дә, үзең белән булган барлык иптәшләрне җыйнап, әлеге маршрут буенча юлга чык. Моны укомның катгый боерыгы дип сана.*

*Соколов мәсьәләсендә син мең тапкыр хаклы булгансың, иптәш Гайсин. Әйе, хыянәтче булып чыкты ул. Бүген төнлә ревком карамагындагы барлык акчаны, бөтен кыйммәтле әйберләрне һәм Кызыл Армиягә озатырга дип авыллардан җыйган утыз сигез җигүле атны алып, үзенең иярченнәре белән Колчак ягына качып киткән. Киткәндә Ясыйровны атып үтергән. Һәм документларга да ут төрткән.* «Их, кичә атып үтергән булсам шул кабахәт җанны!» – дип уйлап алды Миңнулла һәм язуны, укуын дәвам итте*: – Ул явызның тагын да кабахәтлекләр эшләве мөмкин. Әгәр аның имзасы белән сиңа берәр төрле күрсәтмә килә калса, зинһар, үти күрмә аны! Әгәр үзеңә алай-болай очрап куя калса, уйлап та тормыйча кулга ал шул контрны! Нигә алдың дип җавапка тарттыра башласалар, минем шушы язуны күрсәтерсең.*

*Сау бул. Тизрәк безне куып җитәргә тырыш.*

*Кибардин. 5/IV.1919».*

– Уком кайчан авылдан чыгып китте? – диде Миңнулла әле һаман үзе янында басып торган теге карчыкка.

– Бүген иртәнге сәгать җиделәрдә.

Миңнулла сәгатенә карап алды – уникенче киткән иде.

– Рәхмәт, апа, әманәтеңне үтәвең өчен!

– Рәхмәт белән тамак туймый, улыкаем. Коры рәхмәт белән генә калдырма инде син мине. Азрак ярдәм дә итеп кит!

Акча бирмәкче булып, Миңнулла кесәсеннән бумажнигын чыгарган иде, карчык кулын гына селекте:

– Юк, улыкаем, акча кирәкми миңа! Хәзерге заманда акчаның кадере юк аның. Син миңа, булдыра алсаң, берәр бөтен генә булса да икмәк калдырып кит, икмәк булмаса, он да, ярма да ярый. Тик ашый торган әйбер генә булсын!

– Өеңдә кемнәрең бар, әбекәй?

– Берүзем генә мин. Синең шикелле ике малаем бар иде дә, берсен аклар үтергән, икенчесе исәнен исән бугай әле дә, тик ул миңа ярдәм итә алмый шул – фронтта. Кибардин барында ярый иде, ул рифкумнан ипи паегы бирдертеп тора иде. Тик ул да китеп барды шул инде менә.

Карчыкның шушы сүзләрен тыңлагач, Миңнулланың күз алдына үз әти-әниләре килеп басты. Алар да менә шушы карчык шикелле тилмереп йөрмиләр микән?..

– Тукта, әбекәй, мин олаулар янына барыйм әле.

– Ай, рәхмәт, улыкаем, ай, рәхмәт! – дип такмаклап, карчык җайдак Миңнуллага ияргән иде дә, Миңнулла, аны кызганып, шушында капка төпләрендә генә көтеп торырга кушты һәм тиз генә олаулар янына барып, өч бөтен пешкән икмәк җибәрттерде.

## 16

Никадәр тырышсалар да, өяз комитеты олауларын куып җитә алмадылар. Хикмәт дүрт-биш сәгатькә соңга калып чыгуда гына түгел иде монда. Фронт хәлләре сәгатьләп кыенлаша бара иде. Шуңа күрә олауларны аклар кулына төшерүдән сакланып әллә нинди урау юллардан үтәргә мәҗбүр булдылар. Шулай да унҗиде олауның бишесен югалтырга, бер кызылгвардиячене һәм Култышевны юлда җирләп калдырырга туры килде. Ә турыдан барсалар, хәлләр тагын да хөртирәк булган булыр иде.

Өяз комитеты олаулары Арчада туктаган иде. Икенче армия вәкиле тарафыннан хәрби олаулар белән бергә Вятские Поляны юнәлешенә озатылган Карый һәм Яңа Уртавыл волостьлары олаулары да исән-сау килеш бу якларга килеп җиткән икән. Алар Арчадан дүрт-биш чакрымда гына Кәче авылына урнашканнар иде.

Партиянең Усы өяз комитеты председателе иптәш Кибардин Миңнуллага башта олауларны Арчада торган хәрби частька тапшырырга кушты. Аннары Карый һәм Уртавыл волкомнарының печатен, архивын һәм барлык материалларын өяз комитетына тапшырдылар. Отрядындагы кызылгвардиячеләрне һәм Сәгыйдулла агай малае Фәйзулланы Арчадагы хәрби частьның штабы карамагына алдылар. Карый һәм Уртавыл волостьларыннан эвакуациягә килгән кешеләрне, шул исәптән олаулар башлыгы булып килгән Сәгыйдулла агайны да, Кәчедә урнаштырып, социаль тәэминатка куйдылар. Ә Миңнулланың үзен Казанга, Икенче армиянең политбүлеге карамагына җибәрделәр.

Ул көннәрдә Казаннан Кукмарага, Кукмарадан Казанга поездлар бик еш йөреп торса да, аларга утыру мөмкин түгел: Казаннан килүчеләре – фронтка баручы солдатлар, сугыш кораллары белән,

Казанга баручылары сугышта яраланган сугышчылар белән шыгрым тулы була иде. Шуңа күрә Миңнулла Казанга җайдак кына барды.

Икенче армиянең политбүлегендә аны Таежников фамилияле бер кеше кабул итте. Куе кара мыеклы, утыз биш-кырык яшьләр тирәсендәге ул агай Миңнуллага Арчадан Усы өяз комитеты тарафыннан биреп җибәрелгән белешмә-характеристиканы бик җентекләп укып чыкты да, бүтән берни сорап тормастан:

– Яхшы, – дип кире сузды. – Хәзер губерна хәрби комиссариатына барыгыз. Анда сезгә кунарга урын һәм паек бирерләр. Шунда кунарсыз, ял итәрсез дә иртәгә иртән яңа төзелеп ята торган мөселман бригадасының командиры Ибраһимов карамагына барырсыз. Мин сезнең хакта аңа телефоннан әйтеп куярмын. Уңыш телим сезгә!

Миңнулла шул чорда төзелә башлаган татар бригадасы турында белә иде инде. Ул бригаданың Алатырь шәһәрендә тупланpropу һәм аның Икенче армия составына кертелү-кертелмәве икеле икәнлеге дә мәгълүм иде аңа. Ә аның бары тик Икенче армиядә, аның да Азин дивизиясендә каласы килә иде. Шуңа ул Таежников яныннан чыгып китәргә ашыкмады һәм, тәвәккәлләп:

– Мине Икенче армиядә калдыруыгызны үтенер идем, – диде.

– Мин сезнең үтенечне бик рәхәтләнеп канәгатьләндерер идем, иптәш Гайсин. Икенче армиягә дә сугыш эшен һәм политик эшне сезнең шикелле әйбәт белә торган кешеләр бик кирәк. Ләкин алай эшләргә минем хакым юк. Чөнки Республика Революцион Хәрби Советының татар милләтеннән булган барлык сугышчыларны, ә командирларны һәм политхезмәткәрләрне бигрәк тә, төзелеп ята торган татар бригадасына җибәрергә дигән катгый күрсәтмәсе бар.

– Анысы шулайдыр. Ләкин һәр кагыйдәнең чыгармасы була бит, иптәш Таежников. Үтенечемне канәгатьләндерсеннәр өчен миңа кая, кемгә мөрәҗәгать итеп карарга киңәш бирәсез?

– Бу мәсьәләне тик Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясенең политбүлек мөдире генә хәл итә ала. Ләкин, белмим, ул да уңай хәл итәр микән сезнең үтенечне. Чөнки татар бригадасына сугыш эшен белә торган тәҗрибәле командирлар җитми. Ә мин сезне Ибраһимовка полк командиры урынбасары яки аерым батальонның командиры итеп тәкъдим итәргә ниятләгән идем.

– Ышанычыгыз өчен рәхмәт, иптәш Таежников. Шулай да мин башта Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясенең политбүлек начальнигы Камил Якуповка мөрәҗәгать итеп карар идем.

– Әллә сез аны беләсезме?

– Күреп түгел, газеталарда басылган мәкаләләре буенча гына.

– Күреп белсәгез, тагын да яхшырак буласы икән дә, ни хәл итәсең бит. Мин каршы түгел, теләсәгез, аңа мөрәҗәгать итеп карагыз.

Дөресен әйтергә кирәк, Миңнулла Камил Якупов янына кергәндә, сиңа тагын ни җитми инде, барысы да менә шушылай, синең шикелле үз мәнфәгатең генә кайгыртып, минем янга килә башласа, кая китә ул аннары, дип ачуланмагае дип шүрләбрәк кенә кергән иде. Ләкин кереп аны күрү белән курку-каушавы шундук бетте. Чөнки Камил Якупов, дәрәҗәсе зур булса да, ифрат ягымлы адәм икән. Кыйгач кара кашлы, яфраклары кабарып торган кылыч борынлы, кечкенә, әмма үткен күзле, артка тарап куелган озын, калын коңгырт чәчле ул кеше Миңнулланы күптәнге танышыдай якын итеп каршылап, кул биреп күреште дә бүлдермичә генә аның гозерен тыңлады. Шуннан ары иплəп кенә:

– Совет властен яклап кайсы армиядә сугышсагыз да барыбер түгелмени, иптәш Гайсин? – диде.

– Барыбер түгел шул, иптәш Якупов! – диде Миңнулла, тегенең артык каты кыланмаганына куанып һәм шуңа батыраеп китеп. – Безне чигенергә мәҗбүр иткән дошманны шул ук юллардан кирегә кууда катнашасым килә минем. Үземә таныш җирләрдә сугышканда совет властена ярдәмем күбрәк булыр дип уйлыйм.

– Бары шул гынамы Икенче армиядә калырга теләвеңнең сәбәбе?

«Тагын атаң башы кирәкмени инде сиңа?» – дип уйлап куйды Миңнулла һәм ни әйтергә белмичә төртелеп калды. Минем анда Кошкарев, Шишков, Соколовлар кебек контрлар белән исәп-хисапны өзәсем бар, дияргә теләсә дә, ул аларны белми бит, дип кире түнде. Әти-әнисенең, абыйсы Зәйнулланың һәм, ниһаять, сөйгән кызы Зәйнәпнең язмышларын ачыкларга омтылуын әйтергә шулай ук җөрьәт итмәде. Шушындый зур эшләр турында сүз барганда, вак-төяк шәхси нәрсәләр белән баш катырып торалармыни, дип, Якупов ачулануыннан шикләнде. Әмма шулай да ул, һаман үз фикерен алга сөреп:

– Моннан да җитдирәк сәбәпнең булуы мөмкин дә түгел, минемчә. Һәм сез минем үтенечемне кире какмассыз дип ышанам, иптәш Якупов! – диде.

Миңнулланың бу сүзләре, әтисе әйтмешли, фәрештәнең амин дигән сәгатенә туры килде, ахры: Якупов сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды да, бүтән бер сүз әйтмичә, Миңнулла белешмәсенең арткы ягына: «Иптәш Гайсинны Икенче армиядә калдырырга мин каршы түгел», – дип язып һәм кул куеп бирде.

– Рәхмәт сезгә, Камил абый! – диде Миңнулла, куанычыннан очып китәрдәй булып.

– Исән бул, энекәш! Уңыш телим сиңа! Ә хәзер Таежниковка бар, – дип, Якупов аны, ишек төбенә тикле килеп, кул биреп озатып калды.

* * *

Башта аны Икенче армия штабы каршында оештырылган политхезмәткәрләр курсында ун көн укыттылар. Аннары, ул чорда Әгерҗе тирәсендә акларга каршы кискен сугышлар алып бара торган егерме сигезенче дивизиянең (Азин дивизиясенең) ике йөз кырык җиденче полкына беренче батальон комиссары итеп билгеләп, фронтка озаттылар.

Ул килеп җитәсе көнне генә әлеге батальонның командиры дошман пулясыннан һәлак буласын һәм аңа батальонда эшне комиссар түгел, ә командир булып башлап җибәрергә туры киләчәген Миңнулла белми иде әле.

*1971–1975*

Литературно-художественное издание

**Нуруллин** Вакиф Нуруллович

**ГРОЗОВАЯ МОЛОДОСТЬ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Нуруллин** Вакыйф Нурулла улы

**ЯШЬНӘП ҮТКӘН ЯШЬЛЕК**

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.10.2010.
Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 18,48.
Тиражы 3000 д. Заказ О-709.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**
«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.